# Казан утлары

3.1985

*Бөек Җиңүнең 40 еллыгына*



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

3

1985

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН


## *Бу санда*

8 МАРТ — ХАЛЫКАРА ХАТЫН-КЫЗЛАР КӨНЕ


А. ҖӘЛӘЛОВ. Кызларыбыз — яу батырлары . . . 3
К. БУЛАТОВА. Әлмәт урамында. *Шигырьләр* . . . 10
В. ТУКТАРОВА. Язгы нурлар. *Шигырьләр* . . . . 14
К. ШӘФИКОВА. Бишекләр. *Шигырьләр* . . . . . 15
Ф. ГАЛИЕВА. Яшәү — бәхет. *Шигырьләр* . . . . 16
М. ФӘЙЗУЛЛИНА. Салют биргән. *Шигырьләр* . 17


ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ


А. ГАЙФУЛЛИНА. Иске җыр. *Шигырьләр* . . . 18
Д. САЛИХОВА. Җыр. *Шигырьләр* . . . . . . . 20

Г. КАШАПОВ. Язмышыңа ышан. *Роман* . . . . 21


«БАТЫРЛЫК ДӘВАМ ИТӘ» КОНКУРСЫНА


М. ХУҖИН. Бәхет җире. *Хикәя* . . . . . . . . 108

Р. ГАТАУЛЛИН. Мәхәббәткә — мәрхәмәт! *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . . 113


ТУКАЙНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА


Т. ХАҖИӘХМӘТОВ. Уральскида Тукай урыннары . . . . . . . . . . . . . . . . 118
Н. ӘХМӘРОВА. Шагыйрьне без дә күрдек . . . . 119


МАРИЯ АЛЕКСАНДРОВНА УЛЬЯНОВАНЫҢ ТУУЫНА — 150 ЕЛ


М. СӘЙДӘШЕВА. Иң бәхетле ана . . . . . . . . 120


КПССНЫҢ XXVII СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП


А. ГЫЙЛӘҖЕВ. Шәһәр юллары авылга илтә . . 125


БӨЕК ҖИҢҮНЕҢ 40 ЕЛЛЫГЫНА


М. НИЗАМИЕВ. Сүнмәс балкыш . . . . . . . . 140
М. РАФИКОВ. Ил кызлары . . . . . . . . 147

УНБЕРЕНЧЕ БИШЬЕЛЛЫК: КЕШЕЛӘР ҺӘМ ЭШЛӘР

Ф. БӘЙРӘМОВА. Ак төннәр илендә . . . . . . 150
Т. ГАЛИУЛЛИН. Уртак елга — катлаулы уйлар . 154

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Р. КУКУШКИН. Диңгезче егет моңы . . . . . . 159

СӘНГАТЬ

Ф. ӘҺЛИУЛЛИНА. Ташны җырлату авырмы? . . 170

ЮБИЛЕЙЛАР

Җ. МИҢНУЛЛИН. Фидакарьлек . . . . . . . . 177
М. БАКИРОВ. Балалар фольклоры . . . . . . . 179
Л. ИХСАНОВА. Каләмдәшне сагынганда . . . . 183

ЮМОР САТИРА

КИЗӘНЕВ. Ораторга киңәш. *Шигырьләр* . . . . 185

Кызыклы хәлләр . . . . . . . . . . . . 188

Культура тормышы көндәлеге . . . . . . . . 189

Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . . . 192

*Баш редактор*
РЕНАТ ХАРИС

*Редколлегия*
МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
ӘХӘТ ГАФФАР
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
*(җаваплы секретарь)*
ТУФАН МИҢНУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
*(баш редактор урынбасары)*
РӘФЫЙК НӘФИКОВ
НУРИХАН ФӘТТАХ
СИБГАТ ХӘКИМ
РИЗВАН ХӘМИД
НИЛ ЮЗИЕВ
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

К Международному женскому дню — 8 Марта. Статья **А. Залялова**, стихи **К. Булатовой**, **В. Туктаровой**, **К. Шафиковой**, **Ф. Галиевой**, **М. Файзуллиной**. Творчество молодых: стихи **А. Гайфуллиной**, **Д. Салиховой**.
Роман **Г. Кашапова** «Поверь судьбе своей». Стихи **Р. Гатауллина**. На конкурс «Подвиг продолжается» рассказ **М. Хузина** «Земля счастья».
К 100-летию Тукая: рисунок **Т. Хазиахметова**, статья **Н. Ахмеровой**.
К 150-летию Марии Александровны Ульяновой: статья **М. Сайдашевой** «Самая счастливая мать».
Навстречу XXVII съезду партии. Очерк **А. Гилязева**. «Пути-дороги ведут в село».
К 40-летию Великой Победы: Статья **М. Низамиева**. «Неугасимое сияние». **М. Рафиков**. «Дочери Родины».
Статья **Т. Галиуллина** о поездке в Австрию. Очерк **Ф. Байрамовой** «В стране белых ночей».
Материалы к юбилею Н. Исанбета и А. Ахмета.
В рубрике «Юмор и сатира» стихи **З. Нури**.
Занимательные истории. Дневник культурной жизни.
«На наших обложках»: творчество художника **В. Кудselькина**.

Безнең адрес: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2

Телефоннар: баш редактор – 53 – 07 – 60, баш редактор урынбасары — 53 – 07 – 09, җаваплы секретарь – 53 – 07 – 09, проза, поэзия, очерклар бүлекләре — 53 – 07 – 61, тәнкыйть, сәнгать, хатлар бүлекләре — 53 – 07 – 63.

Техник редактор Р. Сөләйманова. Корректорлар Т. Сибгатуллина, Г. Салихҗанова.

Производствога бирелде 3.01.1985 ел. Басарга кул куелды 22.03.1985 ел. ПФ 05096. Офсет ысулы белән басыла.
Кәгазь форматы 70 × 108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 64 100. Заказ Ф-2. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 1985 ел.

**Азат Җәләлов,**
тарих фәннәре докторы, профессор

# КЫЗЛАРЫБЫЗ — ЯУ БАТЫРЛАРЫ

Прогрессив кешелек дөньясы совет халкының Бөек Ватан сугышында җиңеп чыгуына 40 ел тулуны билгеләргә әзерләнгән бу көннәрдә, 8 Март тантанасы уңаеннан, ул чорда совет хатын-кызлары күрсәткән батырлыкларга аерым тукталасы килә. Бөек Ватан сугышында безнең хатын-кызлар ил белән бергә гаҗәеп кырыс сынау үттеләр. КПСС Үзәк Комитетының «1941—1945 елларда совет халкының Бөек Ватан сугышында Җиңеп чыгуына 40 ел тулу турында»гы карарында бу хакта: «...совет хатын-кызлары тиңе булмаган ныклык һәм хезмәт героизмы күрсәттеләр»,— диелә.

Коммунистлар партиясенең һәм Совет хөкүмәтенең чакыруына җавап йөзеннән хатын-кызларыбыз ир-егетләр белән бергәләп бер үк сафта яу кырына чыгып киттеләр. Кызларыбызның бу сугышта күрсәткән патриотик каһарманлыгы кебек башка бер генә күтәрелеш тә кешелек тарихына мәгълүм түгел иде әле. Социализм иленең йөз меңнәрчә кызлары хәрәкәттәге армия сафында булырга ашкындылар. Аларның һәрберсе Ватаныбызның азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен күтәрелгән изге көрәштә үз өлешен кертергә тырыша иде.

«Мине Кызыл Армия сафына алуыгызны сорыйм!»— дип яза ВЛКСМның Саба район комитеты секретаре С. Н. Фәизова.— Фронтка җибәрсәгез, фашист басып алучыларына каршы аяусыз сугышырга ант итәм. Барлык көчемне, бөтен осталыгымны һәм, кирәк икән, соңгы тамчы канымны да илебез халыкларының киләчәктәге матур тормышы хакына бирәчәкмен...»

Үзләрен хәрәкәттәге армия сафларына җибәрүне үтенеп, Зеленодольск шәһәренең бер төркем кызлары район хәрби комиссариатына мөрәҗәгать итәләр. Элемтә идарәсе хезмәткәре Александра Лывинаның гаризасын дулкынланмыйча уку мөмкин түгел. «Илебезгә басып кергән фашистлар өеренең кабахәтлеге минем җанымда моңарчы сизелмәгән нәфрәт хисен уятты. Мин шәфкать туташлары курсын тәмамладым, мотоцикл йөртергә, телеграфта эшләргә өйрәндем. Иптәш хәрби комиссар! Мине сугышка җибәрүегезне үтенәм! Ватанымның азатлыгы өчен гомеремне дә кызганмам...»

1942 елның язында һәм җәендә Татарстандагы комсомол оешмаларына комсомол сафында булган яшүсмерләрне — гвардия миномет частьларына, кызларны исә һава оборонасы гаскәрләренә алу турында хәбәр килә. Бу яңалык яшен тизлеге белән тарала һәм хәрби комиссариатларга гаризалар ява башлый. Казан пристане нормировщицасы,

комсомол комитеты члены Раиса Ходигина: «Мин, илемнең гап-гади кызы, сугышчыларның алгы сафында буласым килә,— дип яза.— Кызыл Армиягә санитарка итеп алуыгызны үтенеп сорыйм. Теләгемә каршы килмәсәгез иде!»

Моңа охшаш гаризаларны Мамадыш кызлары А. Тарасова, Л. Белобородова, А. Долина, Н. Исаева да язалар, Тәтеш, Арча, Буа һәм башка шәһәр-районнардан күп санлы гаризалар керә.

Кызларның үтенечләре ихлас күңелдән язылган, илгә бирелгәнлекнең матур үрнәген күрсәтеп торалар. Бу сүзләрдә Совет иленең миллионлаган хатын-кызларының теләкләре чагыла. Шунысы мөһим: Кызыл Армия сафларына чакырылган кызлар алдан белдергән омтылышларын яу кырында раслап та күрсәтәләр. Бөтен дөнья безнең патриоткаларның Мәскәү, Сталинград, Севастополь, Одесса, Ленинград өчен барган сугышларда һәм партизан отрядларында җан аямый көрәшүләрен күреп хәйран калды. Дошман белән күзгә-күз килеп сугышканда, безнең кызларның социалистик Ватанга һәм Ленин партиясенә бирелгәнлек, илне басып алучы фашистларга нәфрәт, социализм, тынычлык, халыклар азатлыгы дошманнары белән килешмәүчәнлек кебек иң изге сыйфатлары өстенлек алды.

Алар ирләр белән бер сафта иң кискен бәрелешләрдә катнаштылар. Зоя Космодемьянская, Наталия Ковшова, Мария Поливанова, Мәгубә Сыртланова, Ольга Санфирова кебек күп кенә кызларга Советлар Союзы Герое дигән данлы исемнәр бирелде һәм алар турындагы легендага тиң хәбәрләр бөтен дөньяны таң калдырды.

Кызларыбыз күрсәткән каһарманлыклар әлегәчә ачылып та җитмәгән. Эзләнүләр дәвам итә. Моннан берничә еллар элек татар халкының батыр йөрәкле кызы Советлар Союзы Герое Ольга Санфирова турындагы беренче хәбәрләр ишетелгән иде инде. Ул — Тамань авиация полкы очучысы. Без башта шуннан артыгын белә алмадык. Архивларда кадерләп саклана торган документларны җентекләп тикшерә-тикшерә кыю очучының тормыш юлына кагылышлы яңа мәгълүматлар табылды.

Ольга 1917 елның 2 маенда Куйбышев шәһәрендә туа. 1936 елны, аэроклубта укып чыкканнан соң, ул Мәскәүгә, санитария авиациясенә эшкә килә. 1941 елның декабреннән башлап Ольга — Кызыл Армия сафларында. Ул 1933 елда комсомолга керә. Аның автобиографиясендә: «Укуым һәм сугышчылар һөнәренә өйрәнүемнән тыш мин агитатор, комсомол бюросы секретаре, авиаэскадрилья парторгы, политукулар җитәкчесе булып та эшлим. Миллэтем — татар. 1942 елдан Ленин партиясе члены»,— дип язылган.

Ольга Санфирова Тамань полкы составында Идел буеннан Польшага кадәр юл үтә. Шушы сугышчан юлда ул гади очучыдан гвардия капитаны, сугышчан самолетлар эскадрильясы командиры дәрәҗәсенә кадәр үсә. 1942 елның ахырыннан башлап 1944 елның декабренә чаклы арада гына да аның командалыгында 3270 сугышчан очыш ясала, гитлерчыларга бихисап зур зыян китерелә.

Кызга бирелгән сугышчан характеристикада: «Гвардия капитаны Ольга Санфированың сугышчан хезмәте полктагы һәр кешегә якты үрнәк булып тора, — дигән юллар бар.— Дошман зениткаларының һөҗүменә туры килгәндә дә, искиткеч катлаулы шартларда да ул гаҗәп оста, кыю, аяусыз сугыша белә».

Искитмәле батырлык үрнәкләре күрсәткәне өчен Ольга Сугышчан Кызыл Байрак, I дәрәҗә Ватан сугышы, Александр Невский орденнары белән бүләкләнә.

1945 ел башында Ольга Польшаны азат итүдә катнаша. Бәрелешләр бик кискен хәлдә бара. Февраль аенда, Польшаның Пошковшниц шәһәре тирәсендә, чираттагы очышны уңышлы тәмамлагач, Ольга Санфированың самолетына дошманның очраклы бер зениткасы ата

башлый. Самолетка ут каба. Ольга һәм аның ярдәмчесе Руфина Гашева парашют белән сикерергә мәҗбүр булалар. Ольга нейтраль зонада һәлак була.

1945 елның февралендә, һәлакәтеннән соң, Ольга Александровна Санфировага Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

Кыю очучы кызларның Советлар Союзы Герое исемен алган икенчесе Мәгубә Сыртланова 782 хәрби очыш ясый. Ул гади очучыдан эскадрилья командиры урынбасары һәм партоешма секретаре дәрәҗәсенә кадәр үсә. Төнге очышларның берсендә аның самолеты унике җирдән ватыла. Моторның бер цилиндры тишелә. Әмма кыз үзенең «ПО-2» самолетын аэродромга кадәр алып кайта.

Һава хәлләренең нинди булуына да карамастан, курку белмәс Мәгубә самолетка утырып чыгып китә һәм, бомбаларны нәкъ кирәкле төшкә ташлап, исән-имин әйләнеп тә кайта. Аның кыюлыгы да, төгәллеге дә бөтен эскадрилья өчен үрнәк төсендә телдән-телгә мактап сөйләнә. Мәгубә немец-фашист басып алучыларын Төньяк Кавказда, Тамань һәм Кырым ярымутрауларында, Белоруссиядә, Польшада, Көнчыгыш Пруссиядә һәм, ниһаять, Германиянең үз күгендә бомбага тота. Советлар Союзы Герое булып, ул туган илгә исән-имин әйләнеп кайта, әле сугыштан соң да озак еллар Казанда эшли.

Асия Илмәтова, Сания Фәхретдинова, Бикә Шакирова, Фәния Чанышева кебек медицина хезмәткәрләре йөзләрчә сугышчыларның гомерен саклап калуда җаннарын аямыйлар. Хәрби частьларның берсеннән Казанга килгән хатта мондый юллар бар: «Сез җибәргән санитаркалар кыюлыклары, фидакарьлекләре белән безнең сугышчыларның һәм командирларның чиксез хөрмәтен казанды».

Без Татарстан кызы, медицина хезмәте лейтенанты Сара Камалова күрсәткән батырлыклар белән хаклы рәвештә горурлана алабыз. Ул, Ленинград, Көнбатыш, Төньяк-Көнбатыш һәм III Балтик буе фронтларындагы канкойгыч бәрелешләрдә катнашып, үзен Ленин комсомолына лаек көрәшче итеп танытты. Нык холыклы бу кыз үзен көчле ихтыярлы, курку белмәс сугышчы буларак ир-егетләрне дә сокландыра. Тәүлек буена диярлек сузылган бер һөҗүм вакытында Сара утлы сугыш кырыннан 47 яралы сугышчыны алып чыга. Икенчесендә, дошман тылында калып, бик четерекле шартларда, берничә ярдәмче белән ул яралы алты сугышчыны егерме чакрымлык сазлык аша куркынычсыз урынга илтеп җиткерә. Сара Камаловага еш кына дошманга каршы атышырга да туры килгәли. Аның батырлыгы турында күкрәгендәге Кызыл Йолдыз ордены һәм башка бүләкләре ачык сөйлиләр.

Фронтның башка тармакларында да безнең кызлар ир-егетләр белән иңгә-иң торып сугышалар. Медицина хезмәте өлкән лейтенанты комсомолка Р. Капкаева, төз атучылар М. Туктамышева, З. Габделвәлиева, зенитчылар Н. Әхмәтҗанова, З. Хәлиуллина, З. Максудова, С. Җиһаншина, М. Сабирҗанова... Аларны санап бетерү мөмкинмени?!

Совет хатын-кызлары, кулга корал алып, үзләре сугышып кына калмадылар, башка сугышчыларның батырлыгын да тәэмин итәргә тырыштылар. Алар якыннарын яу кырына: «Кыю булыгыз! Дошманны җиңеп кайтыгыз!» — дигән сүзләр белән озатып калдылар. Татар халкының фронтовикларга язылган хатына да: «Курку белмәс, намуслы, нык холыклы улларыбыз һәм кызларыбыз! Сезгә күкрәк сөтләрен имезгән әниләрегез, шәфкатьле булырга өйрәткән әтиләрегез сезгә кояш нурларыдай кайнар сәламнәрен җибәрәләр һәм немец-фашист басып алучыларыннан үч ала-ала, армый-талмый алга барырга хәер-фатиха бирәләр», — дип язылган.

Әниләрнең, туган-тумачаларның солдатларга җибәргән һәр хаты кайнар патриотизм рухы, Ватанга мәхәббәт, фашист ерткычларына

нәфрәт һәм дошманны җиңүгә тирән ышаныч белән сугарылган. Казан җитен комбинаты мастеры Сафронов, хатыны белән бергәләп, фронттагы уллары Анатолийга мондый хат салалар: «...Сиңа, кадерле улыбыз, сүзебез шул: сугышчан постыңда нык тор! Дошманга төз ат! Фашистларны кыйнаганда каушап калма! Еландай шуышып, безнең җиргә кергән ул явызларны җир йөзеннән себереп түгәргә көчеңне кызганма! Онытма: син — Ватан алдында, халкыңның лаеклы улы булырга ант иттең...» Анатолий Сафронов исә әти-әнисенең теләген тулысынча канәгатьләндерә. Ул Кырымда, Сталинград янында, Белоруссиядә сугыша, Берлинны штурмлауда катнаша.

Әниләрнең сугышка киткән балаларына язган һәрбер хатлары Бөек Җиңүне якынайтуда зур этәргеч иде.

Татарстан кызлары арасында Берлингача барып җиткән батырлар да бар: Зәкия Туишева, Фәгыйлә Миңнегалиева, Асия Ханипова, Мәрьям Нигъмәтҗанова... Р. Ш. Насыйрова исә рейхстаг стенасына: «Монда Идел буеннан башлап җиңүле сугышлар кичергән Казан кызы да булды»,— дип «имза»сын да салып калдыра.

Билгеле булганча, сугыш чорында халык хуҗалыгын фронт таләп иткән кысага кертергә туры килде. Бу юлда зур-зур промышленность предприятиеләрен ашыгыч төстә көнчыгышка күчерү аерым бер урын алып тора. Шундый завод-фабрикаларның 30 дан артыграгы Татарстанга килеп урнашты. Республиканың Совет власте елларында шактый алга китәргә өлгергән көчләре аларны тиз арада эшләтә башларга мөмкинлек бирә.

Татарстан ул елларда бик күп сандагы эвакуацияләнгән кешеләрне дә кабул итә. Партиянең өлкә оешмасына яңа килгәннәрне торак урын, эш, көнкүреш кирәк-яраклары, азык-төлек белән тәэмин итү кирәк була. 1941 елның 21 августында партиянең Татарстан өлкә комитеты көнбатыштан күченеп килгән гаиләләрнең балаларын сөт, йомырка, ит, бәрәңге белән бушлай тәэмин итү турындагы мәсьәләне карый. Колхоз-совхозлар бу җаваплылыкны үз өсләренә алырга тиеш дигән махсус карар кабул ителә. Татарстан Совнаркомы Украина, Белоруссия һәм Балтик буендагы совет республикаларыннан күченеп килгән кешеләргә ярдәм йөзеннән 550 мең сум акча бүлә.

Татарстан хезмәт ияләре исә эвакуацияләнгән кешеләрне якын кардәшләрен каршылагандай кабул итәләр. Өйләренең түреннән урын бирәләр, соңгы телем ипиләрен, уртак ризык итеп, табыннарына куялар.

Иң кыен чакларда безнең кешеләргә көч каян килде соң? — дигән сорауга бары бер генә җавап бар — үзара туганнарча дус яшәү аларны җиңелмәс итте.

1942 елның язына Татарстан үзенә эвакуацияләнгән 226 мең кешене, 100 гә якын балалар учреждениесен сыйдырды. Казанда яшәүче кешеләр саны 401 меңнән 515 меңгә җитте. Килгәннәр исә, тормышның кыенлыкларына баш имичә, безнең кешеләр белән кулга-кул тотынып эшли дә башладылар. Аларны халык хуҗалыгының, культура эшләренең теләсә кайсы тармагында очратырга мөмкин иде.

Завод-фабрикаларны эш көчләре белән тәэмин итү авырайганнан-авырая барды. Иң әүхәтле кешеләр фронтка китеп торганлыктан, 1942 ел башында Татарстандагы эшче көчләр икеләтә кимеде. Мәскәү инструментлар заводы эшчеләренең чакыруына кушылып, Казандагы Язу җайланмалары заводы хатын-кызлары фронтка киткән ирләрне алмаштырырга алындылар. Казан, Зеленодольск, Чистай, Бондюг кебек шәһәрләрнең фашистлар белән канга-кан сугышучы ирләрен станокларда үз хатыннары, апа-сеңелләре алмаштыра башлады. Кызлар санаулы көннәр эчендә моңарчы гел ирләр генә үтәгән һөнәрләргә өйрәнделәр. Мәсәлән, Ленин исемендәге җитен комбинатындагы хатын-кызлар токарь, фрезерчы, электромонтер эшен үз-

ләштерделәр, хәтта балта остасы, электромонтажчы булдылар. 1942 елны ук инде республика промышленностендагы тулаем хезмәтнең 50—70 процентлабы хатын-кызлар җилкәсенә төште. Халык хуҗалыгындагы бу борылыш зур хәрби-политик әһәмияткә ия.

Завод-фабрикаларда яшьләрне яңа һөнәрләргә өйрәтү тизләтелгән алымнарга күчте. Мәсәлән, «Спартак» аяк киемнәре тегү комбинаты эшчеләре А. М. Богатырева, Ф. Сафина кебек социалистик индустрия нең ветераннары үзләренең тәҗрибәләрен яшь-җилкенчәкләр белән бик теләп уртаклашалар. 1942 елның беренче яртысында Казан фабрикаларында гына да 18,5 мең кеше өр-яңа һөнәргә өйрәнә. Хезмәт ияләрендәге бу күтәренкелек хәрби хуҗалыкның хәлиткеч урыннарында кирәк кадәр көч тупларга мөмкинлек бирде.

Сугыш елларындагы хезмәттә социалистик ярышның яңадан-яңа алымнары кабынып китте: алдынгылыкка чыгу, яңа һөнәргә өйрәнү, йөкләмәне вакытыннан алда үтәү өчен узыша-узыша эшләделәр. Планны ике йөз, өч йөз, биш йөз процентка җиткереп үтәүчеләр булды. Бераздан хезмәт күрсәткечен 1000 (!) процентка үтәгән Урал фрезерчысы Д. Ф. Босой үрнәген маяк итеп алучылар күренә башлады. Казан егете Алексей Бирюков, мәсәлән, 1942 елның 3 маенда сменалык эшен 1325 процентка үтәде. Слесарь Фәйзи Абдрахманов, тегү фабрикасы эшчесе Нина Ульянова кебек башка уңганнар да нормаларын 900—1000 процентка үтәүгә күчтеләр. «Спартак» комбинатындагы Ксения Алексеева унбер ай эчендә планнан тыш 30 мең пар итеклек өлге кисә. Аңа, Татарстанда беренче буларак, тылдагы гвардияче исеме бирелә һәм ул Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә. 1942 елны Бондюг химия заводының 123 эшчесе — ике еллык, 20 кешесе өч еллык планны үтиләр. Алар арасында М. Шәмсевәлиева, М. Груздева кебек уңган кызлар бар.

Һәр коллективта фронт өчен кирәкле һөнәрләргә яшьләрне өйрәтү хәрәкәте башлана. Казан кетгут заводы мастеры Н. Павлова берүзе тулы бригаданы укыта. Д. Ильина алты кызны кетгут җепләрен шомартырга өйрәтә. Ампулалау цехы уңганнары И. Куликова, З. Гыйниятуллина, З. Варламова ике-өч атна эчендә унбер кызны һөнәрле итәләр. Шушы кызлар смена нормаларын икешәр-өчәр йөз процентка үти башлыйлар.

Тылдагы хезмәт коллективларына фронт бригадалары дигән мактаулы исем бирелә башлагач, Татарстан кызлары тагын да тырышыбрак эшләргә тотыналар. 1943 елның 1 июленә 204 коллектив фронт бригадасы исеменә лаек дип табыла, Бөек Җиңү алдыннан исә аларның саны 1642 гә җитә.

Өздереп шуны әйтергә кирәк: Татарстан промышленность предприятиеләре, аерым алганда, В. И. Ленин исемендәге җитен комбинаты, «Спартак» аяк киемнәре тегү комбинаты, Бондюг химия заводы Кызыл Армияне сугыш кирәк-яраклары, кием-салымнар белән тәэмин итүдә зур өлеш керттеләр. Бу чорда күрсәткән хезмәт батырлыклары өчен мех комбинаты — Ленин ордены, В. В. Куйбышев исемендәге завод Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде. Горбунов исемендәге, моторлар төзү һәм вертолетлар ясау берләшмәләре дә орденнар алдылар.

Бу өлкәдә хатын-кызлар җитәкләгән Кызыл Байраклы фронт бригадалары сугыш елъязмасы битләрендә күренекле урыннарны тоталар.

Совет иленең тылдагы хәле авыл хуҗалыгындагы эшләргә нык бәйле иде. Кызыл Армиянең фронттагы җиңүчән адымнары да, нигездә, турыдан-туры авылга, колхоз-совхозларның, МТСларның җитештерүчән көчләренә килеп тоташты.

Сугышның беренче айларында ук Татарстандагы колхоз председательләренең —65, бригадирларның 66,3 проценты фронтка китте: 1942 елда гына 2700 кеше өр-яңадан колхоз председателе вазифасын үтәргә алынды. Алар арасында хатын-кызлар да бик күп иде. Сугышка киткән механизаторларны алмаштыру да кызлар өлешенә төште. СССР Верховный Советы депутаты П. Ангелина, В. Бахолдина, М. Мухортова кебек патриоткаларның мөрәҗәгатен Татарстан кызлары хуплап каршыладылар һәм кыю рәвештә машина-тракторларның руленә тотындылар. Лаеш районының Рождествено МТСы дирекциясенә язган гаризаларында комсомолкалар: «Без бу хәлләргә читтән генә карап тора алмыйбыз,— дип күрсәттеләр.— Кулларына утлы корал тотып Ватанны саклаучы ир-егетләрне алмаштыру йөзеннән безне трактор бригадаларына билгеләвегезне сорыйбыз!»

Партиянең өлкә комитеты 1941 елның 25 июнендә үк Татарстанның барлык райкомнарына, механизаторлар әзерләү өчен, кыска сроклы курслар ачарга тәкъдим кертә. Тракторчылар, комбайнчылар, тагылма механизм белән эшләүчеләр әзерләнә. Шушы җәйдә үк 5 мең яшүсмер өйрәтелә, аларның 75—80 процентлабы кызлар була. 1943 елга тракторчылар арасындагы хатын-кызлар, 1940 ел белән чагыштырганда, 4 проценттан 75 процентка кадәр үсә. 1944 елны колхоз эшендәге хатын-кызлар өлеше 80 процент тәшкил итә. Колхоз-совхоз, МТСлардагы җитәкче постларда гына да Татарстанның ун мең хатын-кызы эшли. Колхоз председательлегенә 320 хатын-кыз тартыла, трактор бригадаларының 447 сен кызлар җитәкли.

1942 елның социалистик ярышында Хәтимә Хөснетдинова җитәкләгән бригада алга чыга (Кукмара районы). Хәтимәгә комсомолның Татарстан өлкә комитеты күчмә Кызыл Байрагын һәм акчалата бүләк бирәләр. ВЛКСМ Үзәк Комитеты Татарстанның 32 тракторчысын «СССРның иң яхшы тракторчысы» значогы белән бүләкли. Алар арасында Суфия Галиева, Исдимә Җамалиева (Казанбаш МТСы), Екатерина Кайманова (Буденный МТСы) кебек уңганнар бар.

Кукмараның Сәгурә Мостафина җитәкчелегендәге тракторчылар бригадасы кызлары СССР күләмендә өченче урынга чыга. Кызыл Юл, Балтач, Саба, Буа һәм башка МТС кызлары да телдән төшми макталалар.

Игенчеләрнең алдынгылары җирдән мөмкин кадәр мулрак уңыш алу өчен ярышка кушылалар. 1944 елны Дөбъяз районының «Алга» колхозында Әлфия Ибраһимова җитәкләгән звено арышның гектарыннан —206 пот, бодайны —132 пот, тарыны 114 пот алып, республика күләм рекорд куя. Тәмте районында Мәдинә Кадыйрова, Чистайда Александра Ефимова, Арчада Рәшидә Гаффарова звенолары ярышучыларның иң алгы сафында баралар.

Татарстан авыл хуҗалыгы эшчәннәре ил өстенә Гитлер бандалары ябырылган чорда фронтка һәм ил ихтыяҗларына 131 миллион пот икмәк, 39 миллион пот бәрәңге һәм яшелчә, 59 миллион пот ит, 200 миллион литр сөт һәм ярты миллион поттан артык йон тапшыралар. Бу байлык дошманны җиңүдә сизелерлек ярдәм булып тора.

Даһи Ленинның гражданнар сугышы чорында, тылның кайгыртучанлыгын сизгәндә, Кызыл Армия җиңү хисен тоеп сугыша, дип әйтеп калдырган сүзләре бар. Бөек Ватан сугышы елларында бу хакыйкать үзен тагын бер кат раслады. Сугышның беренче көннәрендә үк илебезнең һәр тарафында фронтка ярдәм итү хәрәкәте башланып китте. Кешеләр фронт фондына акчаларын, дәүләт займы облигацияләрен, кыйммәтле бизәнчекләрен керттеләр. Татарстанның күп кенә эшчеләре, дошманны җиңгәнчегә кадәр дип, ай саен бер көнне фронт фондына бушлай эшләргә карар кылдылар. 1941 елның сентябрендә сугышчылар өчен җылы киемнәр әзерләү хәрәкәте көчәйде. 9 сен-

тябрьдә завод-фабрикаларда әйберләрне җыю митинглары уздырыла башлый. Шундый бер митингта, эшчеләр китергән кием-салымнарны кабул иткәч, ВЛКСМның завод комитеты секретаре Р. Гатауллина болай ди: «Сезнең бу бүләкләрегез, солдатларыбызның тән җылысын саклаганга күрә генә түгел, безнең күңелләр саф булганга да, Кызыл Армиягә карата изге теләктә торганыбыз өчен дә сугышчыларга кышкы салкынны үткәрмәячәк! Фронтовиклар явыз дошманга каршы чыкканда, яннарында безне дә, күп миллионлы халкыбызны да үз яннарында итеп тоярлар...»

1941—1942 елларда Татарстан хатын-кызлары фронтка 23 мең тун, 54 мең пар киез итек, 59 мең телогрейка һәм сырган чалбар, 106 мең җылы эчке кием һәм ун меңнәрчә бияләй-оекбаш кебек нәрсәләр озата.

Мәскәү янында кан коюлы сугышлар барган көннәрдә совет халкы Кызыл Армияне коралландыру өчен мая туплый башлады. Татарстанның хатын-кызлары, яшьләр һәм карт-карчыклар үз байлыкларыннан җыелган акчаны танклар, самолетлар ясарга тапшырдылар. 1942—1944 елларда Татарстан кешеләре биргән акчага төзелгән «Татарстан колхозчысы», «Кызыл Татарстан» исемле танк колонналары һәм авиаэскадрилья фронтның төрле тарафларында дошманның котын алды.

Сугышчыларга күчтәнәчләр, кием-салымнар җибәрү аерым-аерым да була торган иде. Бу күренешне бер тәртипкә китерү йөзеннән 1942 елның мартында партиянең Татарстан өлкә комитеты ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе Гали Динмөхәммәтов җитәкчелегендә махсус комиссия оештырыла. Комиссия зур эш башкара. Кызыл Армиянең XXIV еллыгы уңаеннан Татарстан хезмәт ияләре фронтка 666 мең сумлык бүләк озаталар. 1942 елның 1 Май бәйрәменә фронтка —52 мең, Октябрь бәйрәменә — 100 мең посылка һәм коллективлардан җыелган 35 вагон бүләк җибәрелә. Сугыш елларында Татарстаннан фронтка киткән бүләк-күчтәнәчләр 40 миллион сумлык дип исәпләнә.

Сугыш еллары заемына, акча-әйбер лотереяларына язылуда да Татарстан хатын-кызлары зур оешканлык һәм активлык күрсәтәләр. Бу чаралардан ил 1 миллиард 236 миллион сум акча ала.

Туган Ватанга ябырылган дошманны тизрәк җиңеп, илне азат итү өчен Татарстан хатын-кызлары хезмәтләрен, мал-мөлкәтләрен генә түгел, хәтта каннарын да кызганмадылар. 1941 елның көзендә үк Казанда 5700 кеше донорлар сафына баса. Татарстан кан алу өлкә станциясе Көнбатыш фронтның эвакогоспитален һәм республикадагы госпитальләрне канәгатьләндереп тора. Шуның өстенә Казаннан фронтка көн саен 60 (!) литр кан озатыла.

Бөек Җиңү сәгатен якынайтуда Татарстан әдәбият-сәнгать вәкилләренең фидакарьлеге дә мактауга лаек. Язучыларның, композиторларның, рәссамнарның һәм артистларның күбесе фронтка китә. Тылдагылар исә хәрби частьларга шефлык тәртибендә культура хезмәте күрсәтә башлыйлар. Сугышның беренче елында гына да хәрәкәттәге агитбригадалар хәрби частьларда һәм эвакогоспитальләрдә — 2500 концерт, 70 спектакль куялар. Бригадалар Калинин, Брянск, Карелия, III Балтик буе фронты кебек иң хәтәр якларга бара. Юлга чыгучыларның күпчелеге хатын-кызлар була.

Без, шушы хакыйкатьләрдән чыгып, хатын-кызларыбызның Бөек Ватан сугышы елларындагы фидакарьлекләре алдында бил бөгеп баш ия без.

# Клара Булатова

## Әлмәт урамында

Һәр очраган үтә сәлам биреп,
Бар да таныш монда.
Очынып йөрим яшь чактагы кебек
Әлмәт урамында.

Катлы-катлы биек якты йортлар,
Урам иркен, озын.
Мин бит, Әлмәт, шушы йортларыңа
Нигез салган кызың.

Тезем-тезем челтәр тәрәзәләр
Көнгә куйган йөзен.
Урамыңда әле суынмаган
Минем яшьлек эзем.

Юк, үтмәгән язлар тиккә генә
Янып шушы җирдә.
Шунда янсын, шунда җыры калсын
Калган гомернең дә.

Һәр очраган белән сәламләшәм,
Якын дуслар монда...
Яшь чактагы кебек очынып йөрим
Әлмәт урамында.

## Үзеннән-үзе туган җыр

Урамнар буйлап киләм дә,
Яңа җыр уйлап киләм.
Уйламыйм, үзеннән-үзе
Туганны җырлап киләм.

Җырлардай күркәм матурлык,
Яктылык тирә-якта.
Май ае салкыннарында
Алмагач чәчәк ата.

Шомыртлар ап-ак күбек тә,
Балкыплар тора көлеп.
Бар микән тагын шундый ямь
Бу яклардагы кебек?

Алмалы-гөлле бакчалар
Йортларны күмә нурга.
Күчереп кенә шуларны
Куясы иде җырга.

Язарга микән соң әллә
Шушында гына чүгеп?
Ярамый, юләр диярләр
Шул кыяфәттә күреп.

Исемең шагыйрь икән лә,
Җыр белән шагыйль икән;
Илаһи халәтеңне тик
Барсы да аңлый микән?

Өзелә генә күрмәсен,
Ашыгып кайтам өйгә.
Чәчми дә түкми үзеңә
Тапшырыйм кайнар көйгә.

Урамнар буйлап йөгерәм,
Торасың микән көтеп.
Капылдан туган җырымны
Кабул ит бүләк итеп.

Үзеннән-үзе туа җыр
Бәхетле якта гына,
Кемнедер янып-шашынып
Яраткан чакта гына.

*

Китүемә күптән, егерме ел үткән
Калдырганга киртләч зәңгәр тауларны,
Ләкин шул тауларга тартылган һаман да,
Сагынган һаман да җаным аларны.

Үткән яшьлек монда, тәүге сөю шунда.
Мәгънәсе бар микән тәүге диюнең?
Тәүгесе дә булмый, соңгысы да булмый,
Бердәнбере генә була сөюнең.

Ара өзелде дип, бар да күмелде дип,
Күңел сүрелде дип юкка йөргәнмен.
Аерылганга күптән, егерме ел үткән —
Егерме ел буе берне сөйгәнмен.

*

«Ул» да шулай... соңгы чиккә җиткәч,
Авызлыклап калды йөрәген...
Мине белеп миннән баш тартканның
Хәтерләмим бәхет күргәнен.

Бер гөнаһсыз җиңел уйнаклыкны
Кабул итәлмәгән ир-йөрәк,
Колы булып кырыс горурлыкның
Ялгызлыкта яши иңерәп.

Онытуыңа шундый ышанасың!
Мескенлеккә таңгәл көчлелек.
Син «аңарга» бик нык охшагансың,
Бәхетсездер шуның төсле үк.

*

Еллар буе тыя алган хиснең
Ник җибәрдек тезген-йөгәнен.
Ничек соң син батырчылык иттең?
Ничек соң мин котыла белмәдем?

Иңнәремә генә кагылдың тик...
(«Ачулана калса ни әйтер?..»)
Сыенмаска гына иде дә бит,
Баш әйләнеп китте нишләптер.

Дуслыкның да шунда, ни гаҗәптер,
Бөтенлеге сынды, кителде.
Хәзер инде минә дерелдәп йөр
Тотылмаган карак шикелле.

*

Мин язмыштан зарлана алмыйм,
Бай яшәдем дөньяда.
Тиңдәшләр дә, сердәшләр дә,
Көндәшләр дә булганга.

Алар инде кайсы кая
Таралышты, югалды.
Янәшәмдә гомерлегем,
Бердәнберем — син калдың.

Син бит минем тормышымда
Ярдәмчем дә, сердәш тә.
Син үлгәнче кирәк миңа,
Кирәк әле үлгәч тә.

Ансыннан да качып булмас,
Гомернең бер чиге бар,
Минем йөрәк тынар тиздән
(Врачларның шиге бар)...

Йомгаклыйсы эшләрем күп,
Каралама язмалар,
Өй тутырып, өелеп-өелеп,
Чәчелеп-түгелеп калалар.

Арада бар шундый җырлар,—
Югалмаска тиештер,
Син аларны тәртипкә сал,
Укучыга ирештер.

Гомер буе кеше өчен
Янып тузган йөрәгем
Үзе белән алып китмәс
Кешеләргә кирәген.

Син — яшәвем дәвамында
Ышаныч та, терәк тә.
Син үлгәнче кирәк миңа,
Кирәк әле үлгәч тә...

## Төшләремә кереп йөдәтмә син

Калдың инде, калдың еракта син.
Еракларда кайтып йөрәккә,
Төннәремдә мине уятма син,
Төшләремә кереп йөдәтмә.

Бер-беребездән сугыш аермады,
Мәрхәмәтсез үлем алмады,
Аерылудан иреннәрдә калды
Баланнарның әче аллары.

Икебез дә йөри бер сукмакта,
Бер һаваны сулый икебез.
Бизмәннәрдә үлчәп баккан чакта
Икебезнең гаеп бертигез.

Рәхәтлеккә салмый беркемне дә
Ялгызлыкта апрель таңнары.
Йөрәгемдә — әрнү, иренемдә —
Баланнарның әче аллары.

## Безне кемнәр чагыштырсын...

Безне кемнәр чагыштырсын,
Нәрсә уйлап, ни юрап?
Яралышта ук аерма:
Мин — хатын-кыз, син — ир-ат.

Төрле затта төрле фигыль,
Төрле фикер туадыр.
Син — мин түгел, мин — син түгел,
Үзлегебез шундадыр.

Әмма күзләр яктылыкны
Бер кояштан җыядыр,
Иҗатларда уртак кыйбла,—
Берлегебез шундадыр.

●

Чук тәлгәшле миләш ботаклары
Янып, салынып тора, күр әле!
Аннан гына агач ярлыланмас,
Берсен генә өзеп бир әле!

Юк, кирәкми! Тукта, өзә күрмә!
Тулы торсын тәлгәш күзгәчә.
...Матурлыкның гомере озын була
Саксыз куллар иртә өзмәсә.

●

Өндәү билгеседәй туры
Калырга күпме тырыш —
Сорау билгесе шикелле
Бөгә дә куя тормыш.

Калмады бугай күрмәгән
Шул тормыш юлларында,
Яшәүдән мәгәр шулай мин
Туярга уйламыйм да!

Кирәксә өндәсен әйдә,
Кирәген сорасын ул,
Тик минә соңгы ноктаны
Ашыгып куймасын ул.

Утлардан суга, сулардан
Утына кереc бар.
Аласын алган бу җиргә
Әле күп бирәсе бар.

## Венера Туктарова

# ЯЗГЫ НУРЛАР

*

Кояш керә иртән өемә
Зур кунак булып,
Нурлары сине сорыйлар
Күзгемә кунып.

*

Җирнең язгы сагынуларын
Гөрләвекләр җырга сала,
Кайгыларын, сагышларын
Кояш, ахры, үзенә ала:
Янар өчен.

*

Чишмә яны, чишмәлекләр —
Йөрәккә изге урын,
Беркайчан да алар миңа
Карамадылар кырын.

Чишмә яны, чишмәлекләр —
Иң тылсымлы бер урын,
Шунда тыңлыйм Җир-Ананың
Җырланмаган күп җырын.

*

Кемне күрмим, кемгә дәшмим,
Кем очрамый юлымда,
Уйлаган уй, җырлаган җыр
Бары синең турыда.

*

Урман моңсу, сукмак, юллар,
Моңсу күк йөзе,
Җил бүген шаяра сыман
Җирдә берүзе.

*

Яз, синең канатларыңда
Күкләргә мендем,
Тәшкәч, Җирне һаман башка
Төсләрдә күрдем.
Төштә чөнки хыялланып
Такыя үрдем,
Өндә дусның мыскыл катыш
Көлүен күрдем.

Күрдем газета, журналда
Ил-җирсезләрне,
Ипи, дип кул сузып торган
Күп үксезләрне.
Сугыш кайтавазы килде
Ничәмә илдән,—
Такыялар үреп булмый
Пуля һәм көлдән.

*

Күк йөзе — зәңгәр түбә,
Тау битен кояш үбә.

Су буласын кар сизә,
Әлегә суык — түзә.

Бөреләр нурлар тәрә.
Беркемгә дә күрсәтми —
Агачка күлмәк тегә.

## Кәүсәрия Шәфикова

### Бишекләр

Мин тугач, бишек элгәннәр,
Әнкәм, әбкәм алмашлап
Тирбәткәннәр, мин бишектән
Төшмәдем шуннан башлап.—
Бишегемнән алып тормыш
Салган үз бишегенә.
...«Бишекләрдә тирбәләдер
Бәхетле кеше генә»—
Әгәр шулай уйласалар,

Бик дөрес, бәхетле мин.
Йокымнан көлеп уянам,
Аткан таңнарым имин...
Була, кайчак бишегемне
Тирбәтә җил я давыл...
Мин түзгәч түзәрмен инде,
И тормыш син, бишекләргә
Наз белән генә кагыл.

*

Кояшлы да, былбыллы да
Күңелем, кырлар кебек киң дә.
Юмартлыкта макталсам да,
Саран була беләм мин дә:
Ялганчыга күңелемдә
Урын да юк,
Җылым да юк,
Җырым да юк.

## Шулай микән?

Аллы-гөлле икән тормыш,
Нурларына коендым.
Күктән бәхет йолдызларым
Алларыма коелды.

Шулай микән? Ә чынында
Бәлки тормыш авырдыр?!
Җиңел булмас, авырдыр,
Кеше генә сабырдыр!

●

Ябышып туңмаган ничек
Тәрәзә бозларына?—
Ал чәчәкләр көлеп баккан
Пыялада җемелдәгән
Ак кыш йолдызларына.

Тәрәз кебек бозга туңган
Чагы була күңелнең.
Шул хәлдә дә тере калган
Өмет кебек түгелмени
Чәчәкләре бу гөлнең?!

# Фәһимә Галиева

## Яшәү — бәхет

Елмай әле, елмай, якты дөнья,
Мин мөкиббән сиңа, мөкиббән:
Ил язмышын иңнән төшермәскә
Ихлас җаным күптән күнеккән.—
Мин мөкиббән сиңа, якты дөнья,
Эштә янып-көеп, яратып...
Төсем калыр җирдә, мәхәббәтем,
Яшәү матурлыгын яңартып.

Тәрәзәмә килә кайчак җилләр,
Кайгыларым әллә кайтамы?
Кайгы — нәрсә? Яшәү — бәхет, диеп
Каршысына чыгам һәр таңның...

Елмай әле, елмай, якты дөнья,
Мин мөкиббән сиңа, мөкиббән:
Ил язмышы — минем үз язмышым,
Урталыкта, юк, юк, интекмәм.
Күзне камаштырып елмай, дөнья.
Якты күге булып Ватанның
Яшәү — бәхет, яшәү — көрәш, диеп
Каршысына чыгам һәр таңның.

## Саф көмеш

Ярына мин башны куям:
Кушыла Идел уема,
Котмәгәндә күңелемә
Саф көмеше коела.

Идел — һәрчак ил абруйлы,
Хатирәнең яктысы.
Ярларында көлеп тора
Гомеремнең яртысы.

Идел кичү җиңелме соң?
Кайгылар да бар төсле...
Язмышыма үзем куштым:
Мин — Иделнең варисы.

Ярларына башны куям,
Кушыла Идел уема.
Рәхмәтем зур. Күңелемә
Саф көмеше коела.

## Шигъриятнең чулпы тавышы

Җирне бизә, күңелләрне яктырт,
Җил-давылда сына җырыңны:
Шигъриятнең чулпы тавышлары —
Керәш рухы яшәү чорының.

Көмеш кенә түгел безнең өлеш,
Алтыннарың торсын бер читтә.
Янып торган еллар күкрәгендә
Ялкын булуларга ни җитә!

Еллар авазында кайтавазлар —
Без казганган көннәр табышы:
Армас, талмас, мәңге дәртен җуймас
Шигъриятнең чулпы тавышы.

*Әлмәт*

# Мәрзия Фәйзуллина

## Салют биргән

Ватан сугышы барганда
Бабаем көтү көткән.—
Кәҗәләрнең сөте безнең
Бөтен авылга җиткән.

Җәйләүләрдә малкайларны
Йөрткән салмак атлатып.
Җиңү котлап салют биргән —
Чыбыркысын шартлатып.

## Нәни мәргән

Курокны тарттым,
Кыр казы аттым.
Атуын аттым,
Көйгә буш кайттым.

Нигә дисеңме?
Син белмисеңме?

Нигә шаккаттың?
Мин тирда аттым!

Армиягә мин
Үскәч китәрмен:
Чын мәргән булып
Хезмәт итәрмен!

# Алсу Гайфуллина

## Иске җыр

Башта йөрде җирне буйлап,
Кешеләрне юатты.
Ә аннан соң юкка чыкты
Һәм исемен югалтты.

Яңа җырлар күп язылды,
Купшылары бар иде.
Ә бер әби: «Әле җирдә
Иске җыр да бар!»— диде.

Шунда тынды бөтен җиһан,
Колак салды бу сүзгә,
Һәм иске җыр яңгырады,—
Моңарчы ничек түзгән!

Җыр яңадан илләр гизде,
Үз исемен белдертте.
Көлгән чакта елатты ул,
Елаганда — көлдертте.

Искермиләр, ахры, җырлар,
Бары качып яшиләр;
Без үзебез дәшми торып,
Башлап һич тә дәшмиләр.

Онытылып барган чакта
Алар хәбәр бирәләр.
Юк, җырлар да үзләренең
Бәяләрен беләләр.

Тик яңа җырлар язарга
Алар ирек бирәләр,
Сагындырып кына кайчак
Безнең янга киләләр.

...Ә барыбер түзалмыйлар,
Канатланып киләләр!

●

Сүтелде... үрелгән толымнар.
Ә үргән чагында
Мин теләк теләдем.
Бары тик син генә, син генә
Дип типте йөрәгем.

Беркемгә чишмәгән серемне
Чәчемә урадым, Чәчемә сөйләдем,
Мин үргән толымнар чыннан да нык иде.
Тик алар мәңгегә таралды бит инде!..

Нигәдер сүтелде
Үрелгән толымнар.
Ник чиштем серемне?—
Үкендем соңыннан...

Бөтенләй арылган.
Иң якты хисләргә
Тәрәзләр ябылган,
Иң йомшак күңелгә
Кадаклар кагылган,
Иң изге кешегә
Гайбәтләр тагылган–
Арылган.

Җир әйтә: «Мин чиста,
Ак пәрдә ябынган»,—
Ә пәрдә астында
Җир ялган калдырган.
Яшереп маташкан,
Тик ялган табылган.
Чыннан да, бу җирдә
Яшәүдән арылган.

Сандугач җырлаган,
Канатын кагынган.
Бер җырчы бу җырга —
Бу моңга табынган,

— Сандугач, җырла,— дип,
Көн саен ялынган.
Тик тиздән аңлаган:
Барыннан арылган.

Ялганнар юылмый —
Файда юк сабыннан...
...Ә бераү дәртләнеп
Яшәүне сагынган!!!
Һәм шунда бөтен җир
Юынган, кагынган,
Бәхеткә шундый бер
Кеше дә табылган.

Бу җирләр яңадан
Эш белән сарылган,
Кешелек ваз кичкән
Тормышның салыннан.—
Агымга кушылып,
Акмаган кешелек.—
Мөгаен, шуңа без
Аталдык «Кеше» дип.

●

Ап-ак кар. Ап-ак кар.
Бу җирдә
Нәрсә юк.
Нәрсә бар —
Барын да каплаган ап-ак кар.

Ап-ак кар. Ап-ак кар.
Бу җирдә
Ышану, көтү бар —
Аларын капламас ап-ак кар.

●

Сүзеңдә булмаган ялганны
Күзеңдә барыбер күрермен.
Һәм уйнап һичкайчан чакырма
Син мине. Я чынлап килермен,
Белдеңме?!

# Дания Салихова

## Җыр

Моң агыла, түшәмнәрдә тетрәп,
Керфекләрдән саркып керә күзгә.
Бөтерә дә уйнап пәрдәләрне,
Талгын гына, идән буйлап йөзә.

Җанны каплап торган катлы-катлы
Кабыкларны алып ата-ата,
Үтеп керә керфек арасыннан,
Карашларга якты булып ята.

Алып ата чуар кабыкларны
(Нәкъ бертөсле ачык җаннар монда),
Күпме залда үз күзенә баккан,
Үз-үзенә кайткан — Олы Моңда.

Үзен бөек итеп тойган күпме,
Күпме — бөек гади булып калган...
Матурлыкка баш иясе килә.
Матурлыкны ничек алкышларга?!

●

*Хәсән Туфан истәлегенә*

Баш очыңнан, шаулап-гөрләп,
Якыннарың үтеп бара —
Аккош күле аккошлары:
Икесе ак, берсе кара.

Син яраткан, син табынган,
Синең шатлык, синең яра,
Гомер соңың юлдашлары —
Икесе ак, берсе кара.

Сагынып-сагынып кайтулары
Ераклардан, ара-ара...
Күпме хәбәр көтеп торган:
Икесе ак, берсе кара.

Көннәр үткән — аккошлардай
Туган илдән еракларда.
Соң, aклары булды микән?
Барысы кара? Барысы кара...

Язлар килгәч, кара кабер
Калкып чыкты күксел карда...
Үтеп бара аккошлары —
Икесе ак, берсе — кара.

●

Җир — җанлылык, күк — сафлыктыр,
Су — гүзәллек, ут — янулар
Изге кәгъбә кешелектә
Без табынып бу кануннар.
Учларыма кысып барын
(Гасырлардан килгән бирнә),
Мәхәббәтнең каршына мин
Чыгып бастым, якын килмә!—
Яздырырмын узганыңнан,
Яндырырмын — карармын да:
Каршы килеп кара менә
Изге көчләр карарына.
Җиреңкүгең, утың-суың
Алып килдем, җыйнадым да...

Барысы сиңа — учларымда...

Казан утлары АЭС әдәби пост

## Газиз Кашапов

# ЯЗМЫШЫҢА ЫШАН

РОМАН

*Татарстан АЭСын төзүчеләргә багышлыйм*

### Беренче бүлек

### I


Кышның чатнама салкын көннәре. Кичә градусниктагы терекөмеш баганасы кырык икене күрсәтә иде, бүген дә шуннан күчәргә уйламый бугай.

Сәгать телләре иртәнге алтыны сукты да тагын үзенә билгеләнгән вакыт мизгелләрен санарга керешге.

Фазыл Айбулатов йокысыннан уянган иде, ләкин янәшәсендәге хатынын уятмагаем дип, юрган астыннан чыгарга иренеп ятты. Бүлмәдә ярыйсы гына салкынча иде. Хәер, бу бер дә гаҗәп түгел. Моннан унбиш еллар элек, Кама буендагы зур төзелешләр башланганда, ашык-пошык салынган эре панельле бу йортларда яшәүчеләр байтактан инде җылы җитмәүдән зарланалар.

Айбулатов, хатыны Йолдызбануның:

— Чаллыярда гына дүрт йөз мең кеше яшәрлек йортлар салдырыштың, яңа проектлар белән саташтың, булдырдың, шуларның берсеннән адәм рәтле фатир да алмыйсың. Ни уйлыйсың син?— дип битәрләвен исенә төшереп, ирен чите белән генә елмаеп куйды.

Чынлап та, кайгырта башламый булмас, ахрысы. Югыйсә, әнә, Айбулатовның нинди йортта яшәве берләшмә җитәкчесе, вак-төяккә дә вакыт табучы Вергилий Никифорович Дикопольцевка кадәр үк барып ишетелгән. Беркөнне, актив җыелышы вакытында тәнәфескә чыккач: «Син, Айбулатов, шундый зур коллективның җитәкчесе була торып, иске квартирада яшисең дип ишеттем, дөресме?»— дип куйды. Һәм шундук шәһәр Советы башкарма комитеты председателенә күз кысты. Янәсе, син нәрсә карыйсың, дус кеше...

Бәлки, ул хаклыдыр да... Менә бит Йолдызбануы ваннадан чыккач та өйдә халат белән генә йөреп суык тидергән...

Айбулатов кичә генә Казаннан кайткан иде. Бүген иртәрәк барып, урынбасарлары белән сөйләшеп алырга, мондагы яңалыкларны белешергә, үзендәге хәбәрләрне аларга җиткерергә кирәклеген исенә төшереп, урын-җир җылысын таратмаска тырышып кына юрган астыннан чыкты.

Йолдызбану уяу ята икән.

— Алты гына тулды лабаса, кая ашыгасың, Айбулатов?— диде ул гәүдәсен җылы юрган астына яшеребрәк.— Егерме биш ел бит инде шулай, таң этәче кебек торасың да эшкә йөгерәсең. Азрак картая бе-

ләсеңме син, кеше кебек сәгате җиткәч кенә эшкә барырга өйрәнәсеңме-юкмы?

Фазыл ул арада инде җылы, озын халатын киеп өлгергән, билдәмәсен бәйләп маташа иде. Хатынының зарлануын, рәсми булырга тырышып, фамилия белән сөйләшүен, гадәтенчә, елмаебрак тыңлап торды, каршы яктагы йорт тәрәзәләрендә берән-сәрән кабына башлаган утларга тиз генә күз сирпеп алды һәм, үзе дә сизмәстән ниндидер эчке бер тойгы көченә буйсынып, ятакка таба атлады.

Ул Йолдызбануының юрган читеннән карап торган кара күзләренә төбәлде, аның юрганын рәтләбрәк куйгандай итте, мендәр өстенә сибелгән чәчләренең болын чәчәкләредәй исен аермачык тойды.

Йолдызбану иренең дулкынлана башлавын сизеп:

— Я инде, картаеп акылга туймаган нәрсә...— дип әйтергә өлгермәде, Фазылның кайнар иреннәре аны өтеп алды...

Кинәт торшер өстендәге телефон шалтырый башлады. Айбулатов, телефон трубкасын колагына китерүгә, Кама буе төзелеш берләшмәсе ярдәмчесе Алексей Мирковның:

— Фазыл Артышевич, йөреп кайттыгызмы?— дигән йомшак тавышын ишетте.

Айбулатов күңелен биләп алган дулкынланудан арынып җитмәгән иде әле. Мирковның сүзләрен җавапсыз калдырды.

— Алло, алло...

— Тыңлыйм, тыңлыйм, Алексей... Рәхмәт...— диде Айбулатов, трубканы сул кулыннан уңына күчереп.— Тагын нәрсә булды икән дип торам... Эш сәгате җитмәгән түгелме соң әле, Алексей?..

— Шулаен шулай, Фазыл Артышевич, менә «Атакай»ның йокысы качкан... Мин иртәрәк килеп, тегесен-монысын караштырып куйыйм дисәм, ул әллә кайчан килеп утырган... Сезне, сезне күрәсе килә Атакайның...

Айбулатов бу тирәдә генә түгел, илдәге иң зур төзелеш берләшмәләренең берсен җитәкләгән атаклы Атакайның, таңнан барып, кабинетында тикмәгә генә утырмасын сизә иде, Мирковның әйтмәячәген алдан ук белсә дә, сорап куйды:

— Безне... төзелеш тәгәлләнә дип, бүтән берәр планетага күчермиләрдер бит?..

Мирков Айбулатов сүзләрендәге шаяртуны бөтенләй ишетмәгәндәй кыланды.

— Эшкә барышлый ук керергә кушты Вергилий Никифорович,— диде ул үзенең вазифасын үтәлгәнгә санап.

— Ярый алайса, керербез!

Айбулатов җитәкләгән йортлар төзү комбинатына мондагылар өстенә тагын дң бер мәшәкатьлерәк бурыч — Кама елгасы буенда корыла башлаган атом электр станциясен төзүчеләр өчен өр-яңа шәһәр сала башлау йөкләнәчәген башына да китерми иде.

...Баскычтан төшеп урамга чыгу белән Айбулатов кырык ике градуслы салкыннан беркадәр куырылыбрак килде.

...«Да-а, бик шәптән түгел бит әле бу»,— дип уйлап алды ул.

Дөрестән дә, мондый салкыннар төзүчеләр эшенә аяк чалу гына түгел, беренче кварталга билгеләнгән эшләрне дә тәмам туктатып, сыртларына салып тора.

Димәк, тагын шул ук «давай, давай»га ташланырга туры киләчәк.

Айбулатовның институтны бетереп төзелешләрдә эшли башлаганнан соң җаны сөймәгән, хәтта күрәлмаган нәрсәсе «давай, давай» белән салынган биналар, корылмалар иде. Аның бабасы — үзенең үтә үткенлеге, җитезлеге, тапкырлыгы белән дан казанган, сабыр холыклы, һәр эшне җиренә җиткереп, «булсын»га эшли торган кеше иде мәрхүм.

Бервакыт алар бакча тирәсендәге киртәләрне рәтләргә керештеләр. Бабасы каядыр югалган арада Фазыл, эш күрсәтергә тырышып, төбе черек багана领 чокырга утыртып та куйды. Бабасы, билгеле инде, килү белән моны күреп алды. «Нишләп бу черек баганаңы утырттың, улым?»— дип сорады.

Фазыл үзе дә сизмәстән күршеләре Бәдри абзыйның сүзләрен кабатлап: «Ярап торыр әле, бабай»,— дип ычкындырды.

Бабасы, моны ишеткәч, бер сүз әйтми генә багана янына килде, сырты белән баганага терәлде дә беркадәр алга таба авышты... Черек багана, имәндәй таза гәүдәле кеше көченә каршы торалмыйча, шундук сынып төште.

«Менә, улым Фазыл,— диде шул чагында бабасы,— гомерең озындыр әле синең, төрлесен күрерсең, йортлар да салырсың, бакча киртәләре дә тотарсың, ләкин бер нәрсәне онытма: үз гомереңдә «ярап торыр»га йорт салма, «ярап торыр»га хатын алма!»

Фазыл Айбулатов җир йөзендәге иң кирәкле хезмәтләрнең берсен — төзүчелек һөнәрен сайлады.

Дөрес, аңа биналарны ялан-ялан үз дигәненчә генә корырга туры килмәде. Нигә яшерергә, «ярап торырга» салганнары да булмады түгел, булды.

Ерак барасы түгел, менә алар — күз алдында. Чаллыярда автогигантны кора башлаганчы ук, ГЭС төзүчеләргә дип салынган төссез, барысы да бер калыпка кидерелгән бишәр катлы йортларны гына карагыз. Дөрес, соңыннан, автогигант заводларында эшләүчеләр өчен өр-яңа шәһәрне инде бөтенләй яңача салдылар, күз явын алырдай итеп торгыздылар. Хәер, әле аларында да Айбулатов күп кенә житешсезлекләр күрде. «Кеше бит ул асылда күңеле белән табигать гармониясенә омтыла»,— дип уйлады ул. Һәм, менә ничә еллар инде, «аңлы хаос» принцибын яклап, башы исән чыгарын-чыкмасын да белмәстән, бәхәсләргә ташлана...

Кама елгасын буып торган ГЭС плотинасы өстендә, исәпсез-хисапсыз катлаулы корылмалар тезмәсе, мәһабәт краннар, тимер-бетон һәм пыяладан торгызылган биналар, плотина өстендәге күпернең яңа субайларына әвереләчәк арматуралар, поезд кранына асылынган шпалрельслар күренә иде.

Фазыл Айбулатов менә ничә ел инде, һәр яңа туган иртәдә шушы панораманы күрә. Ул мондагы һәр үзгәрешне сизә һәм, бәлки шулай якыннан белгәнгә күрәдер, алар аша әлегә күңелендә сурәте калкып чыкмаган архитектура ансамбльләрен төсмерли иде.

Бирәдә гигант төзелеш башланганда Айбулатов үзенең Йолдызбануы һәм бер-берсенә тотынып диярлек үсеп килүче өч улы белән әнә теге якта — аязрак иртәләрдә каралып-яшелләнеп күренә торган нарат урманнары артындагы Карабугада нефтьчеләргә яңа йортлар салу белән мәшгуль иде. Әнә ул чагында ук нинди дә булса зур төзелешкә барып, андагы беренче казыкны кагып, күңелгә берсеннән-берсе ятышлырак, кешеләргә һәртөрле уңайлыклары булган йортлар, мәрмәр сарайлар, тагын әллә нәрсәләр торгызу турында хыяллана иде.

«Теләгәннең теләге кабул булыр»,— ди иде бабасы. Һич көтмәгәндә борын-борыннан тыныч кына иген үстереп, терлек асрап яткан басу-дала киңлеге шау-шуга күмелде, бөтен илгә генә түгел, читләргә, океан артындагы дәүләтләргә барып яңгырарлык гигант төзелеш башланып китте. Айбулатов ике дә уйлап тормастан шундагы төзү-монтаж идарәсенә баш инженер булып күчте. Нәкъ ике ел ярым йөрде ул теге яктан бу якка. Фатир сорамады, тулай торактагы сиртмәле койкага яткан чакта ятты, ятмаганда кая житте шунда, күбрәк төзүчеләр куйган вагоннарда йоклады. Шундый көннәрнең берсендә ул: «Әгәр дә үзең мон-

да, икенче өлешең — хатының белән балаларың тегендә икән, барлык көчеңне сәләтеңне биреп эшләп булмый»,— дигән фикергә килде.

Килде... һәм икенче көнне үк теге якка — Карабугага кайтып, Йолдызбануга әйтте:

— Әгәр минем белән бергә яшисең, балаларны үстерәсең килә икән — юлың якты, әйдә берсекөнгә квартира карарга кил Чаллыярга,— диде.

Йолдызбану ул чагында гигант төзелеш башланасын имеш-мимешләр аша гына белә иде әле.

— Соң, Фазыл, анда балаларга юньле мәктәп тә юк бит, монда барысы да җайланган, аерым йортта яшибез, бакчабыз менә дигән. Мин дә институттагы эшемне яратам...— дип Чаллыярга күчәргә теләмәвен тагын бер кат белдерде. Айбулатов инде бу кадәресен дә уйлап куйган иде.

— Ярый... алайса, сишәмбегә кадәр көтәм... Килмисең... килмисең икән — үзеңә үпкәлә... Ике сөйли торган гадәтем юк. Чәршәмбе көнне кич белән өйләнәм, валлаһигазыйм, өйләнәм. Беренче очраган кызны алам да кайтам,— диде.

Кызулык белән әйтүен әйтте, ләкин киләчәктә шушы сүзләр Йолдызбану авызыннан никадәр зур үпкә булып үз башына явачагын уйламыйчарак әйтте...

Дүшәмбе көнне, кичкырын, аларның идарәсе урнашкан вагонга баштанаяк пычракка чумган бер хатын килеп керде. Айбулатов башта аны танымыйча торды, төзелешләргә агыла башлаган яшьләрнең берәрседер дип уйлады бугай. Ә танығач, бигрәк тә, мондагы ыгы-зыгы, билдән пычрак, казып-актарып ташланган җирләрне күреп һушын-акылын югалта язган Йолдызбануның мөлдерәмә яшь тулы күзләрен күргәч, аптырабрак калды.

— Я, мосафир, бердәнбер хатыныңны аерам дип куркытып җинүеңә шатлан инде. Килдем мин. Балаларны иртәгә үзең кайтып ал,— диде Йолдызбану, яулык астыннан томырылып чыккан озын куе чәчләрен нишләтергә белмәгәндәй дулкынландырып алды да өстәп куйды:— Кайсы бүлмәгә урнаштырасың? Югыйсә, теге «беренче очраган түтинкәң» килеп кермәгәе...

Айбулатовны төзүчеләр «хыялый Фазыл» диләр, ләкин ул үзен бу кадәр үк хыялга бирелеп, җитмәсә әле шәхси тормышын искә алып, үткәннәрне казынуга чумармын дип уйламаган иде. Берләшмәнең вестибюлендә чишенеп, дежур хатынга пальтосын тоттырганын, икенче катка күтәрелеп Дикопольцевның ал бүлмәсенә, Алексей Мирков янына барып кергәнен абайламыйча да калды.

Дикопольцев ишегенең эчкәресе ачык иде. Шуңамыдыр, эчтәге тавыш ярыйсы гына ачык ишетелә. Димәк, «Атакай»ның каефе бик үк шәптән түгел, дигән уй Айбулатовны чынбарлыкка кайтарды, кая, ни өчен килгәнен исенә төшерде.

Айбулатов кечкенә журнал өстәле янындагы биек артлы, тәбәнәгрәк креслога утырырга өлгермәде, ишектән килеп чыккан Мирков:

— Керегез, Вергилий Никифорович сезне чакыра,— диде.

Берләшмә җитәкчесе, көчәнебрәк кычкырудан булса кирәк, Айбулатов кергәндә, буыла-буыла йөткерә иде. Уң кул ягындагы селектор аппаратының бер күзе янып тора. Айбулатов тиз генә селекторга күз төшереп алды һәм ничә еллар буена шушы бүлмәдә булып, кайсы күзенең кем белән тоташтырасын белгәнгә күрә, теге баштагы кешенең кемлеген чамалады. Хәрби төзүчеләр командирының да тонык кына йөткергәләп алуы ишетелде. Дикопольцев йөткерүен басарга тырышып:

— Син миңа йөткеренмә, яме. Ярты сәгатьтән монда бул. Ни өчен безнең рөхсәттән башка дүрт йөз кешене читкә җибәрүең, атна-ун көннән тапшырылырга тиешле объектларны шәрәләндерүең турында аңлатма

да булсын,— диде. Кәрәк кадәрле кулын җәеп, Айбулатовны якынрак килергә чакырып изәде дә селекторга таба ымлап әйтте.— Башбаштаклык бу, иптәш... Уң кулың нәрсә эшләгәнне сулы белән чамаларга тиеш... Кәтәм. Бетте.

Дикопольцевның җыерчыклы йөзе, икешәр катлы булып салынып төшкән ияк аслары шома итеп кырылган иде. Аның шулай чиста кырынганын күргән саен, Айбулатов беркадәр гаҗәпләнеп ала. Ни әйтсәң дә, мондый йөз-битне, андагы җыерчыкларны киселми-нитми генә ефәк кебек тукыма өсте кебек чиста, шома тоту өчен гаять зур осталык кирәк бит. Төзүчеләр арасында Атакайның бу осталыгы турында бәләкәй генә бер легенда да йөри.

...Сугышта пулеметчылар отделениесе командиры Вергилий Дикопольцев каты яраланып әсирлеккә эләгә. Яшәү белән үлем арасында да үзенең кеше икәнлеген онытмый, мөмкин кадәр чиста йөрергә тырыша. Бу хакта ниндидер бер хәшәрәт чирек телем бәрабәренә аның өстеннән шикаять житкерә. Янәсе, аның кайдадыр яшереп саклый торган коралы — үткер хәнҗәре бар... Киләләр, тикшерәләр, әсирнең сәләмә-соламаларын капшап чыгалар. Юк, берни юк. Шуннан соң аның күкрәгенә автомат көбәсен терәп сорыйлар: я пычагыңны табып бирәсең, я... Фашистларның шаярмавын яхшы белә Дикопольцев. Чөнки ул аларның хәшәрәтлеген үз җилкәсендә бер генә тапкыр сынамаган инде. Акрын гына атлап, үзе ята торган сәке янына бара да астына җәйгән салам арасыннан төенчеген ала. Тегеләрнең күз алдында сүтеп җибәрә — кызгылт балчыктан ясалган бармак башы кадәр йомарлам һәм... гап-гади көзге китеге пәйда була. «Менә минем хәнҗәрем, шуның белән кырынам мин»,— ди. Ышанмыйлар! Нишләмәк кирәк, хаҗәт булмасенә кереп кырынып күрсәтә, үзенең һөнәрен аңлата хәшәрәтләргә...

Дикопольцев ул арада төзүчеләр командиры белән сүзен тәгәлләде. Бераз тынычланырга теләп булса кирәк, кулындагы карандашы белән өстәленә суккалап алды.

— Ни хәлләрең бар, Фазыл Артышевич? Кырык бишенче комплекска күчтегезме? Кырык жиденчегә теге йортларны кайчан тапшырабыз?— дип берьюлы әллә ничә сорау белән күмеп ташлады.

Айбулатов берләшмә житәкчесенең сирәгәйгән саргылт чәчләренә, әле генә булган киеренке сөйләшүдән бераз кызара төшкән маңгаена карап алды. «Боларны сорашыр өчен таң атар-атмас борын чакырмагансың бит инде, кадерле Атакай, ниндидер житдирәк сүзең бар, ахрысы»,— дип уйлап куйды ул. Шулай да Дикопольцев сорауларына мөмкин кадәр тулырак җавап кайтарды. Ахырдан гына:

— Агач эшкәртү комбинатында хәлләр тагын шәптән түгел, Вергилий Никифорович, тагын кирәк-ярак әйберләр җибәрүне өзәләр. Кырык жиденчедәге унсигез ишекле йорт бары тик алар «ярдәмендә» тоткарлана,— дип зарланды. Әлеге комбинаттагы хәлләр чынлап та мөшкелгә калып бара, соңгы ел ярым эчендә генә дә дүрт директор алмашынган иде.

Болар, барысы да, Дикопольцевка билгеле. Ул тагын бераз өстәлгә суккалап торды, ишектән башын тыгып караган Мирковка «кермичә тор» дигән ишарә ясады һәм:

— Менә нәрсә, Фазыл Артышевич, менә бит нәрсә...— дип бераз тотлыгып алды, бала башы кадәр йодрыгын иреннәренә табарак китереп, тоныкк тавыш белән йөткерде һәм дәвам итте:— Менә нәрсә, Айбулатов... син бит безнең бик күптәннән инде, кеше-кара тыгылмаган төшкә барып, «үз шәһәреңне» салмакчы идең... Әйе бит?

— Әйе, Вергилий Никифорович, дөрес... ләкин...

— Менә шулай, иптәш Айбулатов, Көмеш Алан дигән авыл тирәсендә эзләнүләр барганны син миннән ким белмисең инде. Шушы атом электр станциясен торгызуны безнең берләшмәгә тапшырдылар. Әйе... Билгеле инде, аның юлдашы — җыйнак кына каласы да булачак...

Айбулатов берләшмә җитәкчесенең бу сүзләрендәге тирән мәгънәне төшенмиме соң? Шатлыгыннан көлеп җибәрүен сизмичә дә калды. Дикопольцевка якынрак торган урындыкка күчеп утырды.

— Шәп бит бу, бик шәп бит бу, Вергилий Никифорович! Киле... Килешергә кирәк моның белән, югыйсә... «Химэнергострой»...

Дикопольцев тыныч кына сөйләргә кереште:

— Андый «куркыныч» та бар иде, ләкин кичәге киңәшмәдә автогигантны төзеп бетереп, икенче чиратын сафка тапшырган өчен безнең берләшмәнең Ленин орденына тәкъдим ителүен әйттеләр, Фазыл Артышевич... Шулай булгач, АЭСны һичшиксез безгә тапшырачаклар. Сезнең комбинатка беренче казыгыннан башлап атомчы энергетиклар каласын салуны тапшырып була, минемчә.

Айбулатов дәшмәде. Дикопольцев, урыныннан торып, өстәл артыннан әйләнеп чыкты да тәрәзә каршына килеп басты.

Мәһабәт корылмалар өстендәге томан таралган, кояш чыккан, ләкин кояш әллә нинди гаҗәеп бүрек кигән һәм аның озын колакчалары салынып-салынып төшкән иде. Димәк, тышта бабасы әйткән раштуа салкыннары...

Тарихи белешмә

«Кама елгасының сул як ярында, Чишмә елгасы тамагыннан якында гына, 2500 кешесе һәм принстаненнән 500 мең пот ашлык һәм утын озата торган Алан (Полянки) авылы ята. Авыл янында гына Камага Уратма елгасы килеп кушыла. Ул елга буенда, Алан авылыннан 5 чакрым чамасында, алпавыт Нератовның 6500 дисәтинә җире һәм Пановка авылы бар. Пановкадан 2 чакрым җир киткәч тагын бер Уратма, яки Ширәмәт, яки Богородское дип тә атала торган авыл бар. XVII гасырда бу җирләр татар морзасы Үркәев биләмәсе булган, ә инде XVIII гасыр урталарында граф Шереметьев тарафыннан сатып алынган. 5 мең кешелек Ширәмәт тирә-якта иң бай һәм промышленность белән шөгыльләнүче авылларыннан санала. Биредәге кешеләр, иген игүдән тыш, тире эшкәртү һөнәрен бик яхшы беләләр. 53 тире эшкәртү заводы һәм 70 сбруй әйберләре ясау мастерское, аяк киеме, олтан, кызыл һәм ак юфть (йомшак күн), бозау күне, бияләйләр, йөгәннәр һәм башкаларны ел саен 100 мең сумлык җитештерәләр. Авылда волость идарәсе, чиркәү, больница, ссуда бирү — саклык кассасы, базар, 20 мең сумга кадәр товар сата торган Ивановка ярминкәсе бар».

(«Очерки по родиноведению. Казанская губерния». Типография Казанского университета. 1912 год. Составитель — Н. Спасский.)

2

Гаяр үзләренең дерматин белән тышланган ишеген ачып керергә өлгермәде, хатынының:

— Бер туктарсыңмы соң син, тиле кеше кебек бушка йөрүеңнән туктарсыңмы, ходаем, ә?— дип, кухнясыннан аңа төбәп кычкырганын ишетте.

Ишетте һәм... кара коелып төште. Күңелендәге шатлыкның эзе дә калмады. Хатынына, кызы Карлыгачка үзенең хәзерге эшеннән яңадан төзелешкә күчәргә карар итүен әйтергә дип шатланып кайтуы канатсыз кош сыман теләр-теләмәс кенә талпына башлады.

«Тагын күпме шулай дәвам итәр икән бу хәл? Яшәп булмый бит, булмый бит болай булса. Нигә, нигә шулай начарланды соң әле аларның мөнәсәбәтләре, нигә?» — дигән уй аның төрле мәшәкатьләрдән ярыйсы гына талчыккан баш миен ярып узды.

Шулай да, күнегелгән, салмак хәрәкәтләр белән чишенә башлады. «Әллә чыгып китимме?» дигән фикер аны бер мәлгә туктатып та торды, ләкин Гаяр инде болай да ярыйсы гына арыган, үзендә каядыр барырлык көч-хәл тоймый иде. Ул арада хатыны Нурлыбикә — тулган ай сыман түм-түгәрәк йөзле, чем-кара чәчле, кара кашлы, кара керфекләренә сандугач басып сайрарлык, үзе бик заманча булырга тырышса да, озын толымнарын кистермәгән, Ык елгасы буенда үскән татар кызы — Гаяр чишенә торган коридорга чыгып, кулларын тастымалга сөртә-сөртә:

— Туктале, тукта, сарманыңның сарыларын чыгарырмын мин синнән... теге, теге вакыттагы кебек кенә булырмы? — дип янарга керешә. Тастымалын Гаярның күз алдында уйнатып-уйнатып алды.— Моның кадәр дә мәхлук булырсың икән... Ничекләр гейә бу мәхлуклыгың белән башларымны әйләндердең... Югыйсә, югыйсә Бәхтияр дә минем арттан сөйрәлеп йөргән иде... Белмәдем мин ул чагында синең шулай эшкә табынып та үзеңә тигән Геройны кешегә бирүче тиле көрҗә икәнлегеңне...

Гаяр башта хатынының «кисү кисүен» тыңламаган булды. Дөрес, баштарак аның сөйләнүләрен уен-көлкегә борырга, шаяртуга юрарга тырыша иде. Ләкин соңга таба, хатынының искәрмәстән тузынуларын чынлабрак аңлый башлагач, әлеге сөйләнүләрнең уен-көлке түгеллеген, аларда әлегә кадәр Гаяр аңламаган ниндидер мәгънәсе барлыгын чамалады:

Нәрсә: көнчелекме, мин-минлекме — нәрсә икән соң ул?

Ике арадагы мөнәсәбәтләр кайчандыр җил-яңгыр үтмәслек иде бит ул, соңгы бер-ике ел эчендә тартыла-киеренкеләнә барды. Кайсы чакларда ул киеренкелек шулкадәр тартыла иде ки, әгәр моңа кадәр шартлап, очкыннар чәчрәтеп өзелмәгән икән, бирedә бары тик Гаярның сабырлыгы, түземлеге, ә бәлки Нурлыбикәнең хыянәт юлына басмавы гына сәбәпче булгандыр.

Әлбәттә, теләсә нинди түземлекнең дә бер чиге була...

Ләкин Нурлыбикә аңлаудан узган, күптән узган иде шул инде...

Гаяр бүген дә тавыш чыгармаска булды. «Күпме түзгәнне, бүген дә түзәргә кирәк»,— дип уйлап куйды.

Ул акрын гына Нурлыбикә белән ике арадагы бушлыкны узды, көчле кулларын Нурлыбикәсенең тарту көче чиктән ашып торган тәненә-җилкәләренә куйды, салмак кына үзенә таба тарта башлады.

Элек мондый чакларда Нурлыбикә ирексездән тынып кала, йомшарып төшә, тавыш-тынсыз гына иренең көченә буйсына, аның киң күкрәгенә сыенып «дөньясын» югалта иде. Хәзер исә андый хәл торган саен сирәгәя, ни сәбәптәндер Нурлыбикә, Гаяр кочагына керсә дә, элеккечә онытылмый, аның күкрәгенә сеңми... Ләкин бит аларның да сөеп-сөелеп туймаган көннәре, дөресрәге төннәре бар иде, бар иде. Әмма борынгы греклар: гаилә бәхете — олы сәнгать ул, дип юкка гына әйтмәгәннәрдер шул.

...Нурлыбикә, үзенең бер карауда яндырып ала торган чем-кара күзләрен тутырып, аның каршына, комплекслы бригаданың буяучы-шомартучылар звеносына һөнәр училищесыннан тәгаенләү кәгазе тотып килеп басты. Басты да моңарчы кызларга туры гына карарга да вакыт тапмыйча йөргән Гаярны бөтенләй икенче кешегә әйләндерде.

Автогигант һәм аның янындагы яңа Чаллыярны кора башлаган яшьләр романтикасының иң күтәренке көннәре иде. Илнең төрле почмагыннан яшьләр килә дә килә. Дөрес, сирәк-мирәк булса да бригада-

дагы таләпләргә, андагы кырыс тәртипләргә буйсынырга теләмәүчеләр дә табыла. Төзелеш алар белән әллә ни кызгану хисләре кузгатмыйча гына аерылыша да иде.

Автогигант ыгы-зыгысы башланганчы ук, әле армия хезмәтен тутырып кайтып, шундагы төзү-монтаж идарәсендә эшли башлаган Гаярны «Син ярыйсы гына тәҗрибәле кеше — төзүче» дип, башта ташчылар, аннары комплекслы бригада җитәкчесе итеп куйдылар.

Алты-җиде ай үтмәде, әллә кайлардагы зур сынауларны үтеп, Хезмәт Батыры исемен алган төзүче Андрей Стародубов белән ярышка чыкты Гаяр. Мәскәү төзүчесе Злобинның атаклы алымын күтәреп алып, алга таба үстерүчегә әверелде.

Билгеле, Гаяр Сәфәров бары тик дулкын көче белән генә өскә күтәрелмәде. Аның характерында эшкә теше-тырнагы белән ябышып, теләсә нинди авырлыктан да курыкмау, нинди генә кискен хәлләрдә дә югалып калмау һәм, өстәвенә, крестьян атасыннан күчкән салкын канлылык, һәрбер эшкә йөрәк кайнарлыгын бирә белүе бар иде.

Озакламый аның бригадасы шәһәр төзүчеләр арасында иң алдынгыларның берсенә әверелде, хәтта Андрей Стародубовныкылар да аларның ничек эшләгәнен карарга килгәли башладылар...

Бәхетле, бик тә бәхетле көннәре иде Гаяр Сәфәровның. Юк, бригадасы алдынгы булу бер хәл, аның шәхси тормышында да бәхет дигән ефәк баулы былбыл кошның менә-менә куенына керәм дип торган чаклары иде.

Армия хезмәтен тутырып кайткан егет булуына карамастан, Гаярның әле күзе төшеп, күңеленә хуш килердәй кызны очратканы юк иде. Хәер, ул кызлар белән танышмады, аларны киного чакырмады, дип булмый, ләкин гомерлек юлдаш итәрлеген, «бәхет кошы» дип санарлыгын тапмады.

Автогигантны кузгаткан җилләр белән бергә, кайчандыр Гаяр Сәфәров дигән авыл егете белән ун ел буе бер мәктәптә йөргән Гөлфирә исемле мишәр кызы да Чаллыярга килеп төште. Кулындагы яшь ярым, күп булса ике яшь тирәләрендәге, сары чәчләренә тукранбаш чәчәген хәтерләткән бантиклар таккан кызын җитәкләгән хәлдә кран борыныннан салынып төшкән ыргакларга тимер-бетон плитә тагып маташучы эшче янына килеп, нәрсәдер сорашты. Тегесе башта «Вира!» дип кулын болгады, ыргакларга эләктерелгән плитәнең салмак кына чайкала-чайкала күтәрелеп китүкәнен карап торды, аннары гына, маңгаена төшкән шлемын бераз күтәребрәк, тугызынчы кат биеклегендә гаскәр башлыгыдай басып торган кешегә таба күрсәтте.

Гаяр Гөлфирәне күрде, ләкин танымады. Тагын берәр газетадан килгән корреспонденттыр инде, дип уйлады. Озакламый барыбер төшке ашка туктыйсы иде, теге ханымны төзелеш чүп-чары җыелмаган баскычлардан менгертеп йөртәсе килмичәме, әллә инде күңелендәге ниндидер җепләрнең тартуына буйсынып мы:

— Хәзееер төшәәәәм!— дип кычкырды.

Кояшлы, җылы көн иде. Кама ягыннан искән йомшак җил генә бүгенге бөркүлекне баса алмый. Шуңа күрә Гаяр тугызынчы каттан төшкәч тә, панель-стеналар өеменә җитәрәк бермәлгә туктап, башындагы каскасын кулына алды, кесәсеннән кулъяулыгын чыгарып битен-күзен сөрткәләргә керешә һәм... тир бөртекләрен сөртеп алган арада карашы аны көтеп торган хатынга төште.

Шул ук мизгелдә аның күз алдыннан мәктәп еллары, дәресрәге, тугызынчы класста укыган чакның кояшлы, иртә яздан ук шау чәчәкләргә күмелгән бер вакыты яшен яктысыдай йөгереп узып китте.

## 3

...Гаяр сирень чәчәкләрен үлеп ярата иде. Чөнки сирень чәчәге аның күңелендәге иң якты, иң матур хисләрне уятып җибәрде, кайда булуына карамастан, сирень чәчәкләренә күмелгән туган авылын хәтеренә төшерә. Беренче мәхәббәтенә сирень чәчәге бүләк иткәннән соң беренче тапкыр кыяр-кыймас кына сөю сүзләрен әйтергә тырышкан чагы яңара башлый иде. Хәзер шушы халәт тагын кабатланды...

Тугызынчы класска хәтле нишләптер кызның зәңгәр күзләренә, бераз гына көлемсерәп караган иреннәренә, әле кайчан гына чандырның чандыры булган гәүдәсенең бик килешле булуына, ягымлы, күз карашын иркәләп торучы җиткән кыз гәүдәсенә әверелгәненә юньләп игътибар итмәгән икән ул.

Яз җитеп, сиреньнәр чәчәк аткан көннәрдә, мәктәптән иптәшләре белән кайтып барганда күрде ул аларны. Күрде һәм... шул мизгелдә үк Гөлфирә белән икәүдән-икәү генә каласы, болыннарга, урманнарга барасы, аның өчен генә яшисе килә башлады. Атлап барган җиреннән баганага бәрелгән шикелле булды ул чак Гаяр. Бер мәлгә тыны кысып куйды, күз алларында сирень чәчәкләре түшендәге сыек томан пәрдәсе күтәрелгәндәй итте. Аннары, моңарчы бары тик сабантуйларында яисә мәктәп физругы Алексей Кузьмич оештырган ярышлардан соң гына кукрәгеннән чыгардай булып сикерә торган йөрәге җилкенергә, уйнап-уйнап тибенергә кереште.

Ул янәшәсендә диярлек барган яшьтәшләренә күз ноярмәс тизлек белән карап-карап алды: күрмәделәрме, сизмәделәрме?

Юк, берәү дә күрмәгән-сизмәгән иде. Хәтта Гаярның үзалдына туктап калуын да сизмәгәннәр, чөнки үз сүзләре — сүз, үз көлүләре көлү иде аларның.

Гаяр алар белән кайтты, тик Гөлфирәдән күзен бер генә секундка да алмады. Карады, карады, карады... Караган саен әлеге кызда яңадан-яңа өстенлекләр, берәүдә дә булмаган сыйфатларны ачты. Моңарчы күз алдында булган бу матурлыкны күрмәвенә исе китте...

Икеме-өчме көн шулай иләс-миләс йөрде ул. Өйдәгеләргә дә, укытучыларга да, хәтта үзенең иптәшләренә дә урынлы-урынсыз, ә кайчагында бөтенләй диярлек мәгънәсез, һичбер сорауга яки сүз агышына туры килми торган җаваплар бирә башлады. Тугыз ел укып та булмаганны, шушы ике-өч көн эчендә бер-бер артлы «икеле» эләктерде, контроль эшне бөтенләй ерып чыга алмады. Ә ничек соң ерып чыксын ул? Кемгә генә караса да, алдында бары тик бер Гөлфирәне күрде...

Ниһаять, игътибарсызлыгы, дәрестә «юк-бар хыялга чумып» утырганы өчен химия укытучысы аны — мәктәп газетасының баш редакторын дәрестән үк куып чыгарды.

Соңгы дәрес иде. Гаяр сумкасын селти-селти мәктәп урамын узды, уңга борылып, инеш буена төште. Ташулар киткәч, инешкә басма салалар, һәм барлык кеше бакча буйлатып сузылган сукмактан шушы басмага төшә, аннары теге яктагы әрәмәлек аша гына йөри иде.

Медпункт бакчасы буйлап төшеп барганда кинәт башына килгән уйдан шып туктады Гаяр: рәшәткәләр өстенә ябырылып үсеп утырган сиреньнәр, бөтен су буйларын бүтән беркайчан да кабатланмас хуш исләргә күмеп, шау чәчәктә утыра иде.

Гаяр «әһ» дигәнче сирень чәчәкләренең иң матур тәлгәшләреннән букет ясады һәм инеш аркылы салынган басмага таба йөгерде.

«Үзе генә, үзе генә кайтса ярар иде», дип теләде ул нәрсә эшләргә җыенганын үзе дә белеп бетермәстән.

Гөлфирә нигәдер күренмәде. Гаяр яшеренгән җиреннән бик җентекләп карап торды, кызның узып китүе мөмкин түгел иде. Аны, Гөлфирәне күрмичә уздырамы соң бүген Гаяр?

Гөлфирә әйләнеч юлдан киткәндер, дип өмете өзелергә җиткәндә генә сукмак буйлап килгән кызның җырлаганы ишетелде:

...Шомырт чәчәкләре ак кына,
сөюләрең булса...

Кыз басма янына җиткәндә, ниндидер бер сихри көчкә буйсынып, җир астыннан чыккан әкияттәге егет сыман Гөлфирә каршына басты.

— Аб-бауyу... Куркыттың ич, нәрсә дип монда торасыың?— диде Гөлфирә тавышын бераз иркәләндеребрәк. Егетнең күзләрендә гадәти булмаган очкыннарны күрепме, әллә болай гына, кызларга хас сизем беләнме — аңламассың.

Гаяр әле дә булса баягы билгесез көчкә буйсынуын дәвам итә иде.

— Менә... Сиңа бу, Гөлфирә...— диде ул, ниһаять, батыраеп. Ләкин аның тавышы батырларныкыча нык түгел, каушаудан беркадәр калтыравык иде. Шушы калтыравык тавыш сагайтты кызны.

— Син... син нишлисең монда, Гаяр?..

— Гөлфирә, ал менә бу чәчәкләрне... Мин... мин сине...— Егет: «Беткән баш беткән инде, нәрсә булса да булыр»,— дигән карарга килде. Тавышында ныклык, үз-үзенә ышаныч сизде, һәм бер тын белән сүзен тәгәлләде:— Яратам... мин сине... Гөлфирә... Әйдә... без дә синең белән... китаплардагы кебек... «Алтын йолдыз»дагы Галим белән Мөнирә кебек...

Кыз бераз кечерәебрәк калгандай булды, баскан җиренә чүгә төште. Ләкин икенче мизгелдә кызларга гына хас кыланчыклык белән инеш буйларын, сукмак һәм басма тирәләрен яңгыратып көлә башлады.

Гаяр шушы көлүдән үк үзенең күңел түрендәге хисләрнең җавапсыз калачагын аңлады. Аңлады гына түгел, ап-ачык чынбарлыкны күргәндәй булды хәтта. Акрын гына, аяклары белән капшый-капшый артка таба чигенеп басмага керде. Сул кулы белән күкрәгенә кысып токкан сиреньнәре башта басма такталарына, аннары берән-сәрән генә салынып инешнең әле чистарып бетмәгән болганчык суына коелдылар.

Чигәләрен кысып авырттыра башлаган кыршаудан котылырга теләгәндәй, Гаяр ачудан нишләргә белмичә, уңга-сулга карап алды. Аннары... аннары үзе әле генә атлап чыккан басма такталарын бар көче белән каерып-каерып суга томыра башлады.

Гөлфирәнең көлү тавышы ничек кинәт башланган булса, шулай кинәт туктап калды. Ләкин соң иде инде, басма такталары мәтәлчек ата-ата инеш суына төшеп кадалдылар да әйләнчек шикелле боргалана-боргалана су уңаена агып киттеләр.

— Ниш... нишлисең, тил-лллееее.

Гөлфирә теге яктагы куаклар арасына кереп барган Гаярның башындагы шакмаклы кепкасын ахыр тапкыр күргәндә... аның янына химия укытучысы килеп баскан иде.

— Кем... кем ул хулиган? Басманы кем сүтте?

Гөлфирә дәшмәде.

— Әле генә бик матур тавышлар чыгарып көлә идең бит... Кем ул, әйт!

Ай күрде, кояш алды Гөлфирәне — берни әйтми табаннарын гына ялтыратты.

Икенче көнне кызны дәрескә кертмәделәр, әтисе белән килергә куштылар.

Ул яңадан озын тәнәфес вакытында гына килде.

— Әти белән басманы төзәттек...— диде Гаяр янынннан узышлый һәм егетнең аяк астына кичә бакча буенда онытып калдырган сумкасын ташлады. Бары тик егеткә генә ишетелерлек итеп кенә әйтте:— Ә мин, Гаяр, сирень чәчәкләрен түгел, шом-мырт чәчәкләрен яратам...—

Аннары тагын өстәп куйды:— Көндәлекләреңне укыдым, матур язасың икән... Журналист булырсың...

Монысы инде Гаярның хисләреннән генә түгел, хыялыннан да көлү иде...

...Сәфәров күзен-битен сөртеп торган арада каршысына ук килеп баскан хатынга тагын бер тапкыр күз төшереп алды. Аның алдында, чыннан да, Гөлфирә үзе иде.

Кыштырдап торган эш киеме кигән, төзелеш тузаны буялып беткән бригадирның озаклап сөртенүенә бераз ачуы килә башлаган хатын:

— Мин бит, иптәш бригадир, әлегә сезне свиданиегә чакырмадым, ул кадәр үк сөртенмә... сә...гез... дә,— дия башлаган иде, ләкин соңгы иҗекләрне көчкә әйтеп бетерде.

Әйе, Гөлфирә иде бу! Тавышы бер генә дә үзгәрмәгән иде аның. Гаярның кулъяулыгы ничектер авыраеп, канаты сынган кош кебек, аска таба шуып төште.

Шулвакыт Гөлфирә дә аны таныды.

— Га-яр... Сәфәров...— диде күзләрен зур ачып.— Көтмәгән идем... Сине очратырмын димәгән идем бирәдә...

— Кайда булырга тиеш соң мин, Гөлфирә? Туган төбәгебездә шундый төзелеш барганда?— диде егет саф һәм туры карашын яшермичә.

Гөлфирә өчен, чынлап та, көтелмәгән очрашу иде бу, күрәсең.

— Белмим... Мин, мәсәлән, Ташкент дигән каланы торгызуда катнаштым,— диде һәм, ни әйтергә белмичә, кулындагы кәгазь кисәген Гаярга сузды.

* * *

Тыгыз җыргә — тана башы, дигәндәй, идарәнең кадрлар бүлегеннән Гөлфирәне, чакырып кайтарылган кеше буларак, элекке бригадирлыгына тәңгәл килә торган урынга, Нурлыбикәләр звеносына житәкче итеп билгеләгәннәр икән.

Тагын бер атнадан Нурлыбикә белән Гаярның туйлары булды, бөтен бригада яшьләре җыелган иде ул туйга...

Хәзер менә, ул көннәрдән соң ун елдан артык вакыт узгач, кайчандыр сөеп-сөелеп туймаслар сыман тоелган Гаяр белән Нурлыбикә, чибәрлеге белән әнисеннән дә болайрак кыз үсеруләренә дә карамастан, күңләп түгел, сагатьләп бер-берсеннән ерагая баралар.

Гаяр моның сәбәбен озак кына аңламыйча йөрде. Нәрсә, ни сәбәптән булыр соң бу, дип баш ватты. Бәлки тора башлаган елларында, Гөлфирә әле биредә чакта, алар үзара сөйләшкәннәрдер? Ләкин, яшүсмер чакта, мәктәп елларында кемнең, кайсы гына яшүсмернең мәхәббәттә беренче мавыгуы булмый? Аңа карап, хәзер инде нишләргә ди? Дөрес, Гаярның күңелендә кан савып торган җәрәхәт — аның йокысыз төннәре, сагышлары һәм моңнары Гөлфирә иде. Тик ул бит бүгенге көнгә кадәр бер генә мыскал да хыянәт итмәде Нурлыбикәгә, Гөлфирә турында ләм-мим бер сүз әйтмәде... Әйтмәде, ә нигә әйтмәде, нигә башта ук Нурлыбикәгә сөйләп бирмәде соң ул?

Чынлап та, һич көтмәгәндә, Нурлыбикә белән язылышырга йөргән көннәрдә алар бригадасына Гөлфирә килеп төшкәч, «Әллә сөйләп бирергәме?»— дип бу хакта уйлаган иде ул. Ләкин алар арасындагы элеккеге хәлләргә ым да булмады бит. Гаярның җавапсыз калган мәхәббәте булып яши бирде ул хисләр.

Сөйләмәскә булды, чөнки Нурлыбикәнең көнчелеге чамадан тыш икәнен сизгән иде. Анысын сизде, ләкин икенче нәрсәне: хатын-кыз үзара сөйләшеп аңлашмаса да, бер-берсенең күңелендәге яшерен хисләрне, ир-атлар бернигә дә санамаган вак-төяк шөгыль-фигыльләрдән, күз карашларыннан, теге яки бу сүзне ничек әйтүләреннән яхшы аңлауларын, кем әйтмешли, потенциаль көндәшләрен ерактан ук сизем-ләүләрен белмәде һәм белергә теләмәде дә.

Каманың теге ягында, бөек рәссам Шишкин сәнгатенә тәңгәллек өстәп торган нарат урманнары өстендә, күк йөзе тулы болытлар Айбулатовка да билгеле булмаган ниндидер ташпулатлар корып азапланалар. Ләкин ташпулатларның гомере озын түгел шул, унбиш-егерме минут үтми, кисәк-кисәк убылып юкка чыгалар, ерак-еракларга китеп таркалалар.

Ә биредә, йортлар төзү комбинатының тәрәзәсе каршында, төрле зурлыктагы тимер һәм бетон корылмалар, бетон һәм тимердән торгызылган баганалар башында хисапсыз-сансыз, кояшның җәйге нурларында ялтырап торган торбалар — су, җылы, газ, цемент һәм тагын әллә нәрсә үткәргечләре сузылып киткән.

Чаллыярның бу төшендә кайчандыр печәнле болыннар, кеше кирә алмаслык әрәмәлекләр җәйрәп ята иде. Ләкин инде аларның югалуына, менә шушы корылма-төзелешләр өчен искиткеч зур база барлыкка килгәнгә дә ун елдан артыграк вакыт узып китте. Шушы корылмалар, бер караганда әллә ни әһәмияте юк сыман тоелган, тузан һәм цемент, тагын әллә нинди төзелеш материалларына күмелеп яткан елга буендагы причал-складлар бу якларның тормышын, яшәү шартларын үзгәртүдә, биредә өр-яңа шәһәр һәм тиңдәшсез автогигант салуда төп рольне уйнадылар. Уйнадылар гынамы әле, хәзер дә аларның әһәмияте икелемикеле генә түгел. Хәзер дә әлеге корылма — база-складлар бу тирәне генә түгел,ерактарак башланып киткән төзелешләрнең дә таянычы...

Тик ул таянычның Көмеш Аландагы яңа төзелешкә ышанычлы сукмагы салындымы соң әле? Юк, юк шул...

Июнь башы. Иртә белән Фазыл Артышевичның кәефе бик әйбәт, хәл-әхвәле дә зарланырлык түгел иде. Сәбәбе дә бар: Йолдызбануның туган көне.

Кичтән кисәтеп куелганга күрә шоферы иртүк (гадәттә, Айбулатов эшкә җәяүләп бара иде) килеп житте, башка бер генә машинаның тавышы белән дә бутап булмый торган гудогын кычкыртты. Күлмәгенең бер җиңен кигән килеш, икенчесен табарга тырыша-тырыша, эчке бүлмәдә йоклап яткан Йолдызбануы чыга күрмәсен дия-дия, ишеккә барды да шофер күтәреп килгән өч данә ал һәм ике данә ак төстәге канәфер чәчәкләрен кулына алды.

Баштарак Айбулатов хатынын уятырга, кулына чәчәк бәйләмен тоттырырга уйлаган иде. Аннары, уятмаска, чәчәкләрне хатынының янәшәсенә куеп калдырырга дигән фикергә килде. Уянгач та көтелмәгән бер шатлык булсын әле!

Аяк очларына басып диярлек йокы бүлмәсеннән чыкты. Плащын һәм дипломатын алды.

Эш бүлмәсенең ишеген ачып керүгә күрде ул: селектор тартмасының иң өске рәтендәге кызгылт «күз» янып тора. Тиз генә барып астагы җәйпәк төймәгә басты.

— Әйе, тыңлыйм сезне, Вергилий Никифорович...

— Бик яхшы, әллә инде Айбулатов та сәгатькә карап йөри башладымы,— дип уйлый башлаган идем, югыйсә...

Берләшмә житәкчесенең тавышында ачулы чакларында гына була торган корыч чыңы төсмерләнә иде. Ул, күрәсең, ачуын көч-хәлгә тыеп сөйләшә.

— Эш сәгате башланырга әле, Вергилий Никифорович, тагын сәгать ярым бар, ялгышмасам...

— Ялгышмыйсың, ялгышмыйсың, Айбулатов... Тик менә, тик менә, Фазыл Артышевич, сиңа ихтирамымның шактый зур булуына карамастан, министрның кушуы һәм үземнең дә теләгем буенча бик каты шелтә бирергә туры килә бит әле...

Айбулатов чирек гасыр буе төзелешләрдә эшләгән кеше — шелтәләр алгалаганы бар аның, ләкин монысын бер генә дә көтмәгән иде. Гадәттә, нәрсә өчен шелтә алганыңны, дөресрәге, аласыңны алдан белеп торасың, ә бу юлы...

— Рәхмәт, Вергилий Никифорович, рәхмәт. Сезнең Алтын Йолдыз орденыннан соң минем исемгә әйтелгән беренче шелтә бит әле бу. Минемчә, моны әйбәтләп юмыйча ярамас...

Берләшмә җитәкчесе Айбулатовның тел төбендәге мәгънәне аңлый иде, шуңа күрә тиз бүлдерде:

— Юмор кешене бизәвен бизи, әмма, Фазыл Артышевич, соңгы вакытта андый нәрсәләр күбәебрәк бара шикелле. Синнән дә шундый сүз чыккач... Югыйсә, синең табын артында чәй яки «шифалы су» гына чөмереп утыруың Чаллыярда гына түгел, Мәскәүләргә дә мәгълүм... юуның сәбәбен син генә түгел, без дә беләбез аны. Йолдызбану Мансуровнаны без дә котладык анысы туган көне белән, Айбулатов...

Вергилий Никифоровичның андый эшләрдәге тәрбиялелеге бераүгә дә сер түгел иде, Фазыл Артышевич гаҗәпләнмәде. Ул арада бераз пауза барлыкка килде, берләшмә җитәкчесе икенче телефоннан сөйләшә башлады булса кирәк.

Айбулатов кичә авыллардагы төзелешләрне урап кайтты, шуңа күрә биредәге хәлләрнең иң соңгыларыннан хәбәрдар түгел иде.

«Тагын нәрсә килеп чыкты икән? Андый-мондый «ЧП»-фәлән булса, хәбәр итмичә калмаслар иде»,— дип уйлый-уйлый, Айбулатов, баш инженерны чакырып, төймәгә басты. Ләкин күрше бүлмәдән тавыш-тын ишетелмәде. Өлкән диспетчерга шалтыратмакчы иде, ул арада тагын Вергилий Никифоровичның юан тавышы ишетелде:

— Менә нәрсә, Айбулатов, үзең дә беләсең инде, Көмеш Аланга беренче десант төшерүебезгә төп-төгәл дүрт ай булды. Әйеме? Әйе. Пионер базасы һәм торак төзелешендә эшләребез шәптән түгел анда безнең. Кичә биредә министр һәм партия өлкә комитетының беренче секретаре катнашында киңәшмә булды. Без аңа кадәр Көмеш Аланга барып кайттык... Пионер базасы коручыларга, Алмазов белән Прохоровка урында эләкте. Бәхетең, кайнар чакта кул астында юк идең... Эшләр шәптән түгел анда. «Бүген үк барып кайт, үз күзләрең белән карап чык, чараларын күр. Минем янга кичкырын тугызга керерсең. Әзер тәкъдимнәр белән. Бетте...

Дикопольцевның сүзләрендә дөреслек ярылып ята иде.

«Теге вакытта Татарстанда АЭС төзү башланачагы турында беренче мәртәбә сөйләшкәндә, яңа объектның никадәр мәшәкать алып киләсен төгәл күз алдына китермәгән икәнбез»,— дип уйлады Айбулатов. Съезд трибунасыннан соң Көмеш Алан һәм аның тирәсендәге җирләрне тиешенчә тикшереп, атом электр станциясе төзергә ярыйммы-юкмы икәнлеген ачыклаганчы төп-төгәл бер ел үтте дә китте. Дөрес, барлык бәхәсләр дә монда, Чаллыярдагы төзүчеләр һәм бүтән оешмалар арасында гына бармады. Ерактарак, өстәге даирәләр арасында да барды ул. Шуның кайтавазлары бире дә килеп-килеп бәрелгәләде.

Кайтавазларны анализлаганнан соң Айбулатов нигездә ике төрле фикернең үзара көрәшүен аңлады. АЭСны Татарстан җирендә төзү инде хәл ителгән, анысы хакында бәхәс юк. Ләкин кайсы төштә торгызырга ул корылманы һәм аның янына салыначак энергетиклар шәһәрен? Бераүдән дә яшерен түгел, Чаллыяр тирәсендәге промышленность объектлары инде байтак җирне басып алды. Нибары ике йөз илле километр чамасы җирдә нефть промышленносте гигантлары, химия комбинатлары һәм иң соңгыларының берсе — автогигант калкып чыкты. Боларның кирәклеге зарури, ил экономикасына уңай йогынтысы ап-ачык. Ләкин бу яклардагы эшче көчләр, промышленность чималы, ниһаять,

табигать байлыклары белән әйләнә-тирә мохитның бу кадәр олы гигантларны кабул итеп үзләштерүе яки үзләштермәве дә бар бит әле...

Беренчеләр яклаган районда промышленность объектлары бөтенләй юк диярлек, анда әлегә кадәр иген игү һәм терлек асраучылык өстенлек итә. Ләкин бит анда тагын никадәр юллар, никадәр төзелеш индустриясе объектларын, телисеңме-юкмы, өр-яңадан торгызырга туры киләчәк. Алары әле аның, бер эшкә керешеп киткәч, төп объект — атом электр станциясе һәм анда эшләүчеләр өчен яңа шәһәр салу бәясенә генә төшмәячәк, икеләтә-өчләтә бәягә тартачак.

Көмеш Алан төбәгендә исә нибары кырык-илле чакрым бетон яки асфальт юл сузасы, тимер юл тартасы, кайчандыр Кама елгасының табигый култыгында торган причал янында яңасын, заманчасын торгызасы да — бетте-китте: яңа объект илдәге иң куәтлеләрдән саналган төзелеш индустриясе базасы белән тоташа да куя!

Озын-озак бәхәсләрдән соң шушы як өстенлек алды. Автогигант һәм Чаллыяр кебек заман шәһәрен торгызу сынавын кичкән төзүчеләргә тантаналы шартларда яңа бурыч тапшырылды...

Айбулатовның уйлары, хәтер йомгагын сүтеп барган шикелле, беренче төркем йорт төзүчеләр белән Көмеш Аланга барган көнгә күчте.

Февраль аеның чалт аяз көне иде. Берләшмә яныннан ике автобус һәм бернichә йөк машинасы кузгалып китте. Айбулатов исә Вергилий Никифорович белән журналистлар китеп байтак вакыт узгач кына юлга чыкты.

Көмеш Аланга аның беренче тапкыр баруы түгел түгелен, шулай да дулкынлана, шатлана иде ул. Соң инде дулкынланмыйча ничек түзәрсең: алар бит нindидер гадәти бер йорт салырга түгел, булачак шәһәрнең беренче йортына нигез салырга баралар...

Уйлар, уйлар... Нинди генә бетмәс-төкәнмәс уйлар уйламый кеше башы. Фазыл Артышевичны да бит әнә төзүчеләр «хыялый» дип атап йөртәләр икән. Башта бу сүзне ишеткәч Фазыл Артышевич көлеп кенә уздырган иде, ләкин тора-бара, бигрәк тә башында туган архитекторлык тәкъдимнәрен гаять кыюлык белән эшкә ашырып, моңарчы булмаган проектны булдырып, Чаллыярда йортлар төзүчеләр өчен спорт сарае, йөзү бассейны һәм яшь гаиләләр өчен махсус йортларны җитәкчеләр күзеннән яшереп диярлек салып куйгач, «Чынлап та, бар икән бит ул миндә хыял»— диебрәк йөрде.

Айбулатов урыныннан торып, сул яктагы стенаның бөтен буена һәм киңлегенә сузылган Чаллыяр схемасын гаять зур канәгатьләнү хисе белән карап чыкты. Әйе, монда шатланырлык, тарих булып калырлык эшләр бар иде барын. Менә ничә еллар инде Чаллыяр аның сәләтен, барлык уй-фикерләрен биләп тора. Ләкин бу көннәрдә Көмеш Алан шәһәрен торгызуга да гаять күп вакыт, энергия, оештыру осталыгын бүлеп бирергә кирәк.

Әнә ул Көмеш Алан шәһәренең әлегә расланмаган, проект институтында эшләнеп кенә ята торган төп нөсхәсенең күчермәсе. Ни әйтсәң, әле ана карынында, кешеләрнең башында яралып кына килә ул Калатау янындагы яңа шәһәр. Хәзергә ул — Чаллыяр схемасы сурәтендәге бер кисәк ватман кәгазе генә, анда да тулысы белән түгел, нибары алтыжиде йорты гына төшерелгән килеш. Алты-җиде йорт... Ул алты-җиде йорт — Айбулатовның иң кадерле балалары, бер уйласаң. Аның сәләте, җитәкчелек абруеның җиңүе, беләсегез килсә.

Әлеге алты-җиде йортны әнә шушы сызымда күрсәтелгән урынга сала башлау өчен нинди генә бәхәсләргә ташланырга туры килмәде аңа...

Секретарь кыз тавыш-тынсыз диярлек килеп керде дә стенадагы схемаларга карап үзалдына сөйләнеп йөргән Айбулатовны беренче

күргәндәге кебек гаҗәпләнеп, өстәлнең ачыграк төшенә бер кочак кәгазь, төрле-төрле папкалар һәм документлар куйды.

— Фазыл Артышевич,— диде ул нәрсәгәдер аптыраган кеше кебек.— Баядан бирле анда сезне Гаяр Сәфәров көтеп утыра. Мин аңа әллә ничә тапкыр: «кабул итми ул, кәефе начар», дип тә карадым, юк, китми...

— Әй син, чибәр кыз, минем кәефнең начарлыгын каян беләсең, ялтырап күренеп тормый бит...— диде Айбулатов, үз чиратында гаҗәпләнеп.

— Беләм инде, белмичә... мин бит сукыр да, чукрак та түгел...— дип, секретарь кыз кадак сыман үкчәләрендә зырылдап әйләнде дә, гәүдәсендәге барлык түмгәк-уентыларны, зифалыгын белгертеп торган вельвет чалбарының «Ну, погоди!» рәсемнәрен уйната-уйната йөзеп кенә чыгып китте.

Айбулатов танылган төзүче Гаяр Сәфәровның яраткан эшеннән китеп, күз алдыннан югалып йөрүенә болай да эче пошыбрак тора иде. Үзе килгәч бигрәк тә шәп булган, дип уйлады һәм ишектән чыгып барган секретарь кызга:

— Керсен, керсен әле Сәфәров!— диде, ашыгып-ашыгып кына киенә дә башлады...

Тагын берничә минуттан Айбулатовның аксыл «Волга»сы автогигантның беренче һәм икенче чиратларын тапшыру көннәре күрсәтеп язылган озын паннодан төшкән күләгәне урталай ярып узды да, олы юл буйлатып алга — Көмеш Алан ягына томырылды.

## Икенче бүлек

### I

Гөлфирәнең җанын мәче тырный иде. Кичә караңгы төшкәч кенә Көмеш Аланга кайтып житте ул. Кызы Таңсылу белән икесенә шәһәр читеннән бирелгән вакытлы куышына кереп утырды. Бераз тын алгач, өстен-башын чишенеп атты. Тиз генә йомырка кыздырып, тамак ялгап алырга уйлаган иде, электр плитәсен тапмады. Кызлар алып чыкканнар, күрәсең. Кызының тамагына тимәсен дип, суны графинага кайнатып сала иде, шуның белән генә әнисе тыгып җибәргән тавыкның яртысын ашап бетерә язды. Кызлар белән бергәләп сыйланырга иде исәбе. Болай булгач үзләренә үпкәләсеннәр инде, дип уйлады ул...

Вакыт соң инде, кызлар вагонына кереп, аларны уятып йөрисе килмәде. Урын җәяргә тотынган гына иде, тәрәзә пыяласына нәрсәдер бәрелгән кебек булды. Гөлфирә сискәнеп тәрәзә ягына таба борылды. Прораб вагоны өстендәге зур лампа-прожектор сүнгән, караңгыда берәү дә күренмәде.

Таңсылуын авылга кайтарганнан соң болай да бушанып, шәрәләнебрәк калган вагон бүлмәсе ничектер, күңелгә шом өстәп тора, Гөлфирәнең болай да бимазалы күңелен тагы да тырный төшә иде.

Утны сүндереп урын өстенә барып утырырга өлгермәде, вагон ишеге ачылгандай булды.

Саташам, ахрысы. Таңсылуны озатып өлгермәдем, ялгызлык дигән нәрсә җанны кимерә башлады, дип уйлап алды Гөлфирә ишек ягына колак салып. Чынлап та, вагонның кара ишеге аңа әллә нинди бер куркыныч нәрсә кебек тоелды. Бер уйласаң, бу минутта ул бит япа-ялгыз, әлегә төзелеш чынлап торып башланмаган да, киләчәктә шәһәр буласы урынның иң беренче йорты янындагы вагонда утыра. Дөрес, күршедәге вагоннарда аның шикелле үк җанына тынычлык таба алмаган, бер-берсенә охшамаган егерме язмышлы егерме хатын-кыз бар. Ләкин алар алдында җанының барлык серләрен ачып сала алмыйсың. Тик

кеше дигән затның бит кайчагында үзенең җанын үзенә якын икенче бер җанга ышандырасы да, аның белән иң яшерен серләрен уртаклашасы да килә.

Гөлфирә тик торганда гына акылын җуярлык курку биләп алганны тойды. Аның бер минут, хәтта бер мизгел дә монда калмыйча күз күрмәгән, колак ишетмәгән якларга олагасы килде. «Әгәр дә мәгәр үткәннәрдән ваз кичеп булса, язмыш дигән нәрсәне, бигрәк тә хатын-кыз башына төшә торганнарны, телевизордагы кадрларны җүрсәткән кебек кайтарып булса иде... Иң беренче башлап Гөлфирә үзе дә сизмәстән, ләкин бары тик үзе теләп ияләнгән нәрсәдән ваз кичәр һәм... шушы каһәр суккан тәмәке дигән нәрсәне авызына алу түгел, иренenә дә тидермәс иде. Башкаларга, бигрәк тә менә мондагыдай зур төзелешкә килгән яшь кызларга, иреннән аерылган яшь хатыннарга да: «Авызыгызга аласы булмагыз, кызлар!»— дияр иде. Кызганыч, бик тә кызганыч, үткәннәргә кире кайту мөмкин эш түгел икән шул...

Шушы уйлар белән халатын салып урындыкка ташлыйм... дигәндә генә Гөлфирә коридорга чыга торган кара ишекнең ниндидер илаһи бер көчкә буйсынып тавыш-тынсыз гына ачыла баруын тойды. Монысы инде ялгызлык саташуыннан ерак, чынбарлык үзе иде.

Ярым ялангач хатын, бөтен гәүдәсе белән бер йомарламга әверелеп, коточкыч бер нәрсәнең үзенә кагылганын көтте...

Гөлфирә, ике кулын күкрәк турысына кысып тоткан килеш, сул як җилкәсе аша артка, ишек ягына таба карады... Анда... бусага аркылы яткан берәүнең гәүдәсе тоныкына шәйләнә иде.

Гөлфирә ул кешене таныды, чөнки идәндә кубанка утыра иде, ә бирәдә үзләренең прорабы Зубровтан башка берәү дә кубанка киеп йөрми...

Тагы бер мәл Гөлфирә нишләргә белмичә, күзләрен шар ачкан килеш әле идәндә тәгәрәп яткан прорабка, әле аның кубанкасына карап торды. Шул кыска гына арада, төнге каравылда чөелгән фейрверк утлары шикелле, Гөлфирәнең хәтереннән Зубров белән булган беркөнге сөйләшүнең очкыннары ялтырап үтте.

...Өченче май иртәсе иде. Бер ай чамасы элек кенә Волгодонск шәһәрендәге эшен ташлап, туган ягында тагын бер зур төзелеш ачылганны ишетеп, бу юлы инде нинди генә каршылыкларга очраса да, Чаллыярдан киткәндәге шикелле китмәскә, ә бәлки Көмеш Аланда ныклап төпләнергә дигән ният белән кайткан Гөлфирә, күңеле ямансылаганга түзә алмыйча, салынача к шәһәрнең әйләнә-тирәсен карарга дип чыгып китте.

Арып-талып, аякларын авырттыра-авырттыра ерактагы сөзәк тауларны әйләнгән Гөлфирә Калатауның булачак шәһәргә таба кайтарылып торган кәрнизе өстенә менеп басты. Кама дәрьясын әллә кайлардан буйлап килгән аккоштай теплоходлар, сал йөртүчеләр кара төннәрдә юлдан язмасын, Калатауның шәрә күкрәгенә бәрелмәсен, хәвефле булмасын өчен куелган маяк, кояш инде төшлеккә якынлашкан булса да, сүндерелмәгән, әмма ул янәшәдә торучыга гына күренә иде.

Гөлфирә каршында еракларга сузылып киткән дәрья ачылды. Ул бирәдә аерата матур, аяз күктән үзенә таба төшкән кояш нурларыннан ялтырап, зәңгәрсуланып күренә икән. Ерактагы утрау лар, яшел урман һәм елга суы, җир белән күк йөзе арасындагы бушлык, әйтерсең лә, хуш исләр сибеп борыннарны кытыклап уйнаган йөзем суы сыман ташып, мөлдерәп тора иде.

Сокландыргыч күренешкә исе китеп басып торган Гөлфирә ирексездән бөтен гәүдәсе белән уңгарак борылып карады. Аста, упкыннан читтәрәк, бер оядан чыгып, төннең соргылт караңгылыгына чумган прожектор көлтәләре сыман өч үр сузылып китә. Алар арасындагы үзәннәр, арырак киткән саен күтәрелә барып, иген кырларына әйләнә һәм офыктагы карурманнарга барып тоташа.

Туган якларының иркенлеген очар кош биеклегеннән караган Гөлфирә, шатлыктан үзе дә канатлангандай булып, зәңгәрсу күк йөзенә күтәрелергә теләгәндәй берничә мәртәбә сикереп, кулларын өскә таба суза-суза күкрәгендәге бар тавышка кычкырып җибәрде:

— Эһ-һ-һей-һеееей!

Ләкин кеше табигать тарафыннан очар өчен яратылмаган. Гөлфирә дә кулларын өскә таба күтәреп йөгергән җиреннән әллә кая упкынга тәгәрәп төшкәндәй булды. Кулбашын авырттырып, тау башында яңарак кына тишелеп чыккан кыр чәчәкләре өстенә егылды. Ләкин торырга, аягына басарга ашыкмады, иркенлеккә бирелеп, кулларын янякка җәеп җибәрде...

Күзен ачып караса, күк йөзенең зәңгәрлеге күренми, аны берәүнең исерек күзләре, маңгаена ук төшеп торган кубанкасы каплаган иде.

Гөлфирә кычкырырга өлгерми калды, чөнки аның йөзенә аракы сасысы бөркелде. Хатын үзенең яңагын әлеге кешенең сакал-мыегы чәнчегәнне сизде. Һәм ул инде ничә еллар төзелешләрдә эшләп чыныккан мускулларын җыерды, бөтен тәнен бер йомарламга туплады да кискен хәрәкәт ясап өстенә төшкән авырлыкны әйләндереп җиргә салды. Шундук гәүдәсе белән артка таба ыргытылды һәм аякларына торып басты.

Бирегә килеп эшли башлаганнан бирле узган-барганда бәрелеп-сугылып китәргә яраткан прораблары Зубров иде бу.

— Сез... син... акылыңнан яздыңмы әллә, Зубров?— диде Гөлфирә, ни булганын аңлап та өлгермәгән исерек прорабны ачулы карашы белән бораулап.

— Син... ах син, урман пошие... Карале, нинди житез... Ах син, урман пошиеннан туган нәрсә... Мин бит сине... бәхетле итмәкче идем...

— Эх син, Зубров...

— Үзең дә әллә кем түгел әле... Әйдә, менә бу нәмәстәне икәү җиффәрәбез дә... Беләм бит мин, беләм юмартлыгыңны... Волгодонскидан да шуның аркасында качкансыңдыр әле...

Гөлфирә вагоннар арасындагы мәйданчыкка кайтып кергәндә, бәйрәм табынынnан торып саф һавага чыгучылар магнитофон ритмнарыннан да уздырырга тырышып биюләр иде...

Нишләргә? Кешеләр чакырыргамы, юкмы?

Бу исерек бәндә төн уртасында ачкыч ярагып аның түшәге янына килеп җитә язган икән, моның өчен «Ник керттең?» дип гаепләмәсләрме?

Аннары... үлеме, тереме соң ул?

Гөлфирә башында сварка чаткыларыдай кайнап торган сораулар-ның берсенә дә җавап таба алмады. Ләкин болай тераләп утырудан ни мәгънә? Ул инде төрле кешеләр арасында эшләгән, яхшысын да, кызганычка каршы, начарын да байтак күргән кеше. Бу хәлне болай гына калдырырга ярамаганлыгын белә, калдырса, киләчәктә Зубров аңа тынгылык бирмәячәген бик яхшы аңлый.

Кайчандыр авыл кызлары арасында усаллыгы, житезлеге һәм чаялыгы белән Ирдәүкә кушаматы алган Гөлфирә, куркуыннан тынычлана алмыйча, өстәл янындагы урындыкка кадәр ике адым атлады да баягынак үзе үк ыргытып бәргән сигарет кабын табып алды, калтыранган куллары белән көчкә шырпы эзләп тапты һәм сигаретына ут көйрәтеп җибәрде, күкрәгенә төтен агуы тутырды, шуннан соң гына Зубров янына иелде.

Үз хәле хәл булса да, исерек бәндәне шул килеш бүлмәсендә калдырып булмый бит инде. Ул кискен хәрәкәт белән, үзен мәҗбүр итеп, ишеккә таба атлады... һәм, Зубров кулындагы кыска ломны күргәч, тышка атылып чыкты.

Партоешма житәкчесе Зөлфәт Зәйнуллинны йокысыннан уятып кире кергәндә, ни хикмәттер, Зубровтан җилләр искән, вагон идәнендә аның киеменнән саркыган пычрак су гына каралып ята иде.

## 2

Күңелендәгеләрне уртаклашу, бәлки киңәш сорау нияте белән иртүк Айбулатов янына килгән Гаяр Сәфәров инде менә йомшак «Волга»ның арттагы креслосына сөялгән хәлдә юл буендагы хозурлыкларны күзәтеп бара.

Түбәньяргa кермичә генә, сулгарак борылып, биредәге төзелеш базалары яныннан үттеләр дә, Зәй елгасы аша салынган тимер күпернең аркалары астыннан чыгып, уң яктагы Иманлекне дә артта калдырдылар.

Гаяр бернichә тапкыр инде сүз кушарга җыенса да, дәшмәде, чөнки Фазыл Артышевич тирә-яктагы дөньяга исе китми генә үз уйларына чумып утыра иде.

Айбулатов, чыннан да, Көмеш Алан шәһәре сәхифәләренең әле бик күпләргә билгеле булмаган беренче битләрен күңеленнән генә барлап бара иде.

...Дикопольцев һәм аның белән бергә проектлаштыру институтыннан килгән вәкилләр, Көмеш Алан шәһәрен хәзерге авыл урынында түгел, ә бәлки шушы авылны ничә гасырлар буе Кама ягыннан искән салкын һәм усал җилләрдән саклап, горурлана мәгърур басып торган Калатау өстендә торгызырга кирәк, диделәр. Килер буыннар, Кама дәрьясы өстенә биектән карап, киләчәкне каршылаучы көмештәй ак шәһәрне күрсеннәр, янәсе. Күрсеннәр дә исләре китсен бабаларының кыюлыгына: замананың җитмеш җиде җилләреннән дә курыкмыйча, тарихның үзе булып калыккан борынгы Калатау башына шәһәр салганнар...

Айбулатов характерының бөтен кайнарлыгы, туган җиренә бирелгәнлеге, ихтыяр көченең бөтен барлыгы белән бу акылсыз фикергә каршы төште.

Әйе, ничәмә-ничә төзелешләрне беренче казыгыннан башлаган илебез төзүчеләре алдында какшамас абруй казанган данлыклы Атакайга каршы чыкты. Атакайның күз алдында әлеге фикерне дипломатик шомартуларга урын калдырмыйча «акылсыз» фикер дип, турыдан-туры әйтте дә салды.

— Киләчәкнең бу шәһәрендә, Вергилий Никифорович,— диде ул, житен сыман ак чәчләренең үҗәтләнеп җилдә җилфердәвенә игътибар итмичә,— кызганычка каршы, сез дә, мин дә, проект ясаучы иптәшләрнең берсе дә, аларның балалары да яшәмәячәк. Монысы — беренчедән, Вергилий Никифорович, ә икенчедән, без торгызган йортларга бүген-иртәгә күчәчәк үк сезнең дә, минем дә, проектлаучы иптәшләрнең дә ата-бабалары исеменә тозлы-борычлы «рәхмәтләрен» кичекмичә житкерәчәк. Мин, Вергилий Никифорович, әлеге фикерне «акылсыз» дим, чөнки бу чынлап та шулай. Киләчәк буыннар исәбенә экономия ясарга, аларның җан азыгын урлау исәбенә файда кылырга хакыбыз юк безнең, юк!

Экономика серләреннән яхшы хәбәрдар булган Айбулатов берләшмә житәкчесенең, проект ясаучы белгечләрнең үзләренә бирелгән заданиене тизрәк һәм мөмкин кадәр арзанрак юл белән башкарып чыгарга теләвен күздә тотып әйтте, әлбәттә.

— Син, Айбулатов, соңгы вакытта үзбелдегеңчә эшләү белән артыграк мавыга башладың бугай. Спорткомплекс торгызудагы үҗәтлегең китергән бәла-казадан ярыйсы гына шома чыгуыңны хәтерлә. Шул үҗәтлегең белән бик күпләрнең тамагына кадалуың, шуның өчен

Чаллыяр һәм автогигантның икенче чиратын салуда катнашучыларны Хезмәт Батыры исеменә тәкъдим итүчеләр исемлегеннән төшеп калуыңны белмисеңме? Өстеңә тагын нинди мәшәкать алмакчы буласың? — диде берләшмә житәкчесе, йөзенә чыккан канәгатьсезлекне яшермичә.

— Без — ил кушкан урында төзергә күнеккән кешеләр, Фазыл Артышевич, һәм, ничек кенә булмасын, шушы максатка омтылабыз. Без аласы миллионнар, хөрмәтлем, ил экономикасына файдадан битәр бернинди зыян-зарар китермәячәк бит...

— Вергилий Никифорович, билгеле, Калатау башында шәһәр күтәрү безгә жиңелрәккә төшәчәк, чыгымнар да азрак, мәшәкатьләр дә кимрәк булыр иде. Ләкин, минемчә, сез үзегез дә тау башына шәһәр хәтле шәһәрне куярга ярамаганлыгын беләсез. Мин үзем, мәсәлән, хыял шәһәренең нигез ташы янына килер буыннар, үз жиремнең балалары ризасызлыгын салып калдыра алмыйм. Үгетләмәгез дә. Ә инде балаказа, борчуларга килгәндә... без бит Вергилий Никифорович, сездән үрнәк алабыз...

Шулай да Дикопольцев, үзе әйтмешли, «үҗәт татар»га бирешергә теләмәде. Дөрес, ул аның оештыру сәләтен, авторитетларга баш иеп калтырамавын ярата, шуңа күрә үз итә дә, шуңа күрә алар менә ничә еллар инде жанга-жан куеп эшлиләр. Ләкин кеше характерындагы шушы сыйфатның үзеңдә булуы бер хәл, ә менә сиңа буйсынган кешенең үзеңә каршы хәрәкәт иткәнен күрү бөтенләй икенче нәрсә...

— Ярый, ярый, киңәшербез, сөйләшербез әле, Фазыл Артышевич. Бер утыру-тотынуда хәл иттек түгел бит.— Дикопольцев тагын нәрсәдер әйтеп каршы төшәргә маташкан Айбулатовның кайнарлануын басарга тырышты. Аңа карап проект ясаучылар да тынды.

Әмма бу тынычлануның вакытлы икәнлеген Айбулатов сизде һәм кичекмәстән үзенчә чара күрә башларга булды.

Шушы сөйләшүдән соң бер ай чамасы үттеме-юкмы, Чаллыярга проектлаштыру институты житәкчесе академик Губаненко килде. Чаллыярның яңа өлешендә Айбулатов тәкъдиме белән житкерелгән алтмыш ике ишекле торак йорт бинасын карарга бардылар. Олы юлга чыгып, Мәләкәс елгасын үтүгә, архитектура корылышы, тышкы эшләнеше белән аерылып торган өч йортка күз дә салмаган сыман узып киттеләр, югыйсә. Әмма яңа шәһәрне карап, алар турында озаклап фикер алышканнан соң кунакханәгә кайткач та академик әйтеп куйды:

— Фазыл Артышевич, теге өч йортның проектын әллә башка шәһәрләргә дә бирәбезме? Чөнки аларны чынлыкта күрү күңелгә бигрәк тә ятышлы булды...

Айбулатов, билгеле инде шул секундта ук академикның кайсы йортлар турында сүз кузгатканын аңлады.

— Без бөтенләй үк каршы түгел түгелен, Василий Михайлович, ләкин бит әле сез житәкләгән институтның ул проектны, кызганычка каршы, раслаганы юк...

Академик Губаненко зирәк акыллы кеше, шуның өстәвенә ни өчендер шушы үзсүзле Айбулатов дигән егетне якын күрә, ләкин бу юлы аның чәнечкеле сүзләрен тыныч кына уздырып жибәрә алмады.

— Беләсезме, Фазыл Артышевич, сез, минемчә, үзегезнең хезмәт карьерагызны хәзергедәй югары урында тәгаллиң алмассыздыр. Минемчә, сезне бервакыт килеп СМУ начальнигы да итмәсләр, прораб-фәләнгә генә калдырырлар...

Айбулатов академиктан шулай ук усал сүзләр көтмәгән иде.

— Рәхмәт, Василий Михайлович, рәхмәт сезгә...

— Рәхмәтегезне, Айбулатов иптәш, прораб урынына куйсалар гына әйтерсез... Әлегә минем үземне беркем белмәгән проект, тиешле урыннарда расланмаган проект...

Академик шул урында туктап Айбулатовның күз алдында диярлек имән бармагын уйнатып алды. Беркадәр тын торганнан соң сүзен дәвам итте:

— ...Проект буенча тугызар катлы өч йорт торгызып куйган кешенең әлегә кадәр шундый куәтле комбинатны җитәкләве гаҗәпләндерә... Ни хәл соң бу, ә?

— Соң бит, Василий Михайлович, күпме талаштым мин иптәш Сова бүлеге белән... Аларга эш күрсәтү, соавтор булу кирәк...

— Ә бит, иптәш Айбулатов, бүген иртән сезнең кабинетта мин күргән ватман кәгазендәге схемада Көмеш Алан шәһәре дә үз урынында түгел... Ах, иптәш Айбулатов, Айбулатов, инициатива — яхшы нәрсә, тик аның да бер чиге була, ай-яй, ничек кенә була әле...— диде Губаненко, баягы сүзнең очын югалткан кеше сыманрак, күзләрен хәйләкәр кысып. Шундук Айбулатовны тагын бер кат гаҗәпләндерде:

— Теге йортлар кирәк иде миңа, Фазыл, Волгодонск шәһәрендәге яшь гаиләләргә кирәк. Проект авторы буларак, бәлки безгә аны «Атоммаш»ка да куярга рөхсәт итәрсез, туганкай, ә?

Айбулатов соңгы вакытларда ут йотып йөргән теге йортларның давылы үзе өчен бәла-казасыз гына үтәчәген анлады.

Ә икенче көнне, Көмеш Аландагы рельеф мәгълүматлары, эзләнүчеләрнең анализлары белән танышкач та, самолетка озатучы кызны көтеп торган арада, Василий Михайлович янәшәсендәге иптәшләр арасыннан Айбулатовны аерып алды.

— Менә нәрсә, күгәрченкәем, проект институты җитәкчесе буларак, мин коллегиядә Көмеш Алан проекты турында сөйләгәндә ике вариантны да — безнең инженерлар белән Дикопольцев сайлаганын һәм шул ук вакытта сезнекен дә, миңа калса, иң кулай, ләкин шактый чыгымнар таләп итә торганын да хәбәр итәргә тиешмен... Әгәр үзегезнең фикерегездән кире кайтмаган булсагыз, ул вакытка кадәр дип әйтүем, коллегиягә сезне дә чакырырбыз, яклашырсыз, якалашырсыз... Кызмагыз, кайнарланмагыз, Айбулатов... Москва слезам не верит, диләрме әле? Шулай булгач, дәлилләрегез уйланган, нык уйланган булырга тиеш.

Айбулатов нечкә күңелле кешеләрдән булмаса да, танылган галим, илдәге архитекторлар союзының башлыгы тарафыннан әйтелгән мондый сүзләрдән йомшарып китте, тамагына төер килеп тыгылды.

— Рәхмәт, рәхмәт сезгә, Василий Михайлович... көтмәгән идем...

Академик та саубуллашу алдыннан ярыйсы гына хисләнгән иде. Кичәге сөйләшүләрне, «Улым сиңа әйтәм, килен син тыңла» дигәндәй, тагын бер кат Айбулатовның исенә төшерде.

— Рәхмәтегезне, туганкай, урыныгыздан төшереп прорабლыкка куйсалар әйтерсез...

Икесе дә — тормышның төрле агышларын, кешеләрнең тагын да күбрәк язмышларын-күтәрелешләрен һәм упкыннарга ташлангандай түбәнгә тәгәрәүләрен күргән академик һәм бөтен җаны-тәне белән туган ягында торгызыла торган йортларга бирелгән яшь шәһәрләрнең һәркайсы мөмкин кадәр матуррак, кешеләрнең рухына тәңгәл килерлек итеп төзетергә тырышучы җитәкче инженер — сөйләшенгән сүзләрнең төбендә яткан мәгънәсеннән рәхәтләнеп көлеп җибәрделәр.

...Академикның кисәтүенә дә карамастан, коллегиядәге сөйләшү гаять бәхәсле булды. Андагы кешеләрнең күбесе башта Дикопольцев һәм инженерлар төркеме керткән тәкъдимне раслау ягынарак авышты. Айбулатов өстенә әле салкын, әле эссе су сипкәндәй булдылар.

Ниһаять, академик Губаненко сүз алды, ике тәкъдимнең дә нинди уй-фикерләрдән чыгып кертелгәнлеген коллегиядәге, үзләре белгеч булмаган кайбер агайларга да барып җитәрлек итеп аңлатты һәм... ахырдан бөтен эшне бозып куя язды.

— Чаллыяр йортлар төзү комбинаты Көмеш Аландагы беренче йортларны, иптәшләр,— диде ул,— нәкъ менә икенче тәкъдимдәгечә, Калатау башына түгел, ә бәлки аның итәгендәге түбәнлектән сузылып-сузылып чыккан, табигатьнең үзе тарафыннан, «Шәһәр салыгыз монда, сокланып туялмассыз» дигәндәй, яратылган үргә сала башлаган да...

Коллегиядән чыккач та Дикопольцев, гәүдәсенең центнерлы авырлыгын онытып җибәргәндәй, машинаны чайкалдырып утырды. Айбулатов белән бергә килүләренә карамастан, аңа бер сүз дәшмичә аэропортка китеп барды...

### 3

Көмеш Алан уртасындагы бер төштә, кайчандыр чиркәү булган таш бина янында берничә трактор, автомашина һәм автокран басып тора иде. Шофер машинасын туктаткан арада Айбулатов белән Гаяр Сәфәров икенче бер озынчарак агач бина янына тупланган төзүчеләрне, алар арасында катнашкан авыл кешеләрен күрделәр.

— Нindидер җыен буласы, ахрысы, биредә, Фазыл Артышевич,— диде Сәфәров, юл буе диярлек сөйләшми килүдән йотылган тавышына ирек биреп.

— Җыен ук булырга тиеш түгел, Сәфәров, әмма мәктәпне сүтә башлаучыларны тоткарларга тырышучылар бар бугай. Күңелем шуны сизә.

Айбулатовның күңеле ялгышмаган икән. Чынлап та, төзүчеләр янына тупланган кешеләр мәктәпне тик торганда сүтеп ташлауга риза түгелләр иде.

— Мин бу мәктәптә утыз ел буе балалар укыттым, иптәшләр,— диде өстенә ятышлы гына костюм кигән, муенына галстук таккан, чигәсендәге чәчләренә чал суккан озын буйлы чандыр ир-ат.— Уку елы әле тәгәлләнеп кенә килә, сигезенчеләрнең имтихан бирәсе бар. Аңысы ярый, имтиханнарны авыл Советы бинасында яки клубта да уздырырбыз. Проблема түгел, ләкин сез, иптәшләр, монда килгәнегезгә озаклямый биш ай була, әлегә кадәр берничә бинаның нигезен салудан узмадыгыз. Төзелеш үзенең көченә кермәгән әле дип әйтүем. Шулай булгач, мәктәпне сүтеп ташлаудан ни файда? Безнең бит яңа уку елына хәстәрләнәсебез бар. Аннары, без бит яңа уку елын урамда башлап җибәрә алмыйбыз...

Айбулатов төркемдәге хатын-кызлар, төзүчеләр һәм малай-шалай арасыннан узып, чүмече урынына очлаеп торган тимер болванка таккан, мәктәп бинасын ишәргә әзерләнгән экскаватор янәшәсендәге аксыл плитәләр өстенә менде, ике кулын берьюлы югары күтәрде һәм: «Тынычланыгыз, тынычланыгыз әле, иптәшләр»,— дигән сыман ишарә ясады. Нәрсәдер әйтте, тик төркемнән килгән шау-шуда аның тавышы югалып калды, алдагы рәтләргә дә ишетелмәде. Ниһаять, Айбулатовның кул хәрәкәтләрен күргән кешеләр тынычланды, «нәрсә әйтер бу» дигән сыман көтә башлады.

— Иптәшләр! Хөрмәтле көмеш-аланлылар!— диде ул тавышындагы сизелер-сизелмәс акцент белән.— Мин — Айбулатов дигән кеше, йортлар төзү комбинаты начальнигы. Биредә яңа шәһәрне кору безгә тапшырылды, һәм без аны башкарып чыгарбыз да. Көмеш Алан дигән борынгы авыл нигезеннән күтәрелгән беренче зур бина, безнеңчә, мәктәп бинасы булырга тиеш. Без аны быелгы беренче сентябрьгә, һичшиксез, тапшырачакбыз...

Баягы ир-ат ашыкмыйча гына Айбулатов янына таба атлады, аннары плитәләр өстенә күтәрелде дә:

— Исәнмесез, иптәш Айбулатов,— диде.— Без, билгеле, авылыбыз нигезеннән өр-яңа шәһәр калкып чыгуга каршы түгел. Ләкин, карап

карап торабыз да, иптәш Айбулатов, төзүчеләрнең үз эшләренә салкын каравын сизәбез. Төзелеш чын-чынлап башланмаган әле, аның беренче адымнары гына. Ләкин бит, иптәш Айбулатов, мәктәпне сүтмичә дә була торгандыр. Турысын әйткәндә, без әлегә сезнең «Беренче сентябрьгә өлгертәбез» дигән сүзегезгә ышанып бетмибез...

Бу укытучы агай Чаллыяр дигән шәһәрнең көнләп түгел, сәгатьләп күтәрелгәнен, андагы йортларны гына түгел, икешәр-өчәр мең бала укырлык мәктәпләрне дә Айбулатов төзүчеләре торгызганны, ике-өч ай арасында юктан бар ясаганнарын ныклап белми иде бугай.

Шул вакыт төзүчеләр арасыннан өстенә зәңгәрсу комбинезон кигән, башына яулыгын муеныннан урап бәйләгән хатын-кыз чыкты. Гаяр әлеге хатын-кызның йөреш-килбәтендә ниндидер таныш чалымнар барлыгын чамалап өлгермәде, әлеге хатын плитәләрнең теге ягындагы баскычыннан менеп тә житте.

Сәфәров аның беренче сүзен ишетүгә таныды һәм өскә таба каерылып йөзенә карады. Әйе, Гөлфирә иде ул.

— Иптәшләр, Көмеш Аланның хөрмәтле кешеләре! Сезнең күңелдәге шик-шөбһә безне, төзүчеләрне, турысын гына әйткәндә, беркадәр гарьләндерә. Ләкин, иптәшләр, без бит әле тупланып кына киләбез. Мин — Ташкентны хәрабәләрдән торгызышкан, Чаллыярдагы яңа шәһәрне һәм «Атоммаш» янындагы каланы салучылар арасында эшләгән кеше. Мин иптәш Айбулатов сүзләренә ышанам. Әгәр ул әйткән икән инде, мәктәп көне-сәгатенә әзер булыр. Ә без, төзүчеләр, тырышлыкны җәлләмәбез.

Айбулатов Чаллыярдагы төзелештә кайчандыр буяучы-штукатурчылар звеносын җитәкләгән бу хатынны шулай ук таныды. Дөрес, аның моннан ике-өч ел элек көтмәгәндә Чаллыярдан ни өчен китүе белән кызыксынып өлгермәде ул чакта.

Гаяр Сәфәров исә Гөлфирәне кыз чагыннан ук белә. Чаллыярда эшләгән чакта ул аның белән мөмкин кадәр азрак очрашырга тырышты. Ни әйтсәң дә, Гаярның ул чакларда бөтен илгә шаулаган чагы, илнең иң югары органына депутат булып сайланган көннәре иде. Хезмәте, хезмәте китергән данның тәме, күптән түгел генә тапкан бәхете — Нурлыбикәсе белән корган тормышның кадерен белеп кенә йөргән вакыты иде Гаяр Сәфәровның. Төрле планеркалар вакытында да Гөлфирәнең сәер бер гадәтен — ир-атлар белән бергәләшеп тәмәке тартуын да күрмәде.

Плитәләр өстенә баскан Гөлфирә, сөйләвеннән туктап, як-ягына карап алды, танып өлгермәдеме, әллә танып та сиздерергә теләмәдеме, аның карашы Гаярьгә туктамыйча узып китте.

Көмеш Аландагы төзүчеләрнең эшләре шәптән түгел иде. Моны бер карауда чамалап алган Айбулатов, прораб Зубровның кичкырын монда булып та, таң атканчы каядыр китеп югалуын белеп алгач, бөтен эшне туктатырга, кешеләрне вагоннар уртасындагы мәйданга, «кызыл почмак»та тупларга кушты.

Аның гадәттә бераз елмаебрак торган, мөлаем йөзендәге ачу төсмерләре чагылып китте, тыгыз ябылган иреннәре сирәк кенә тартышып, нәрсәдер әйтергә теләгәндәй селкенеп куялар иде.

Мондый хәлдә төзүчеләр алдына чыгып булмасын аңлаганга күрә, Сәфәровны төзелеш мәйданы белән таныштыруны сәбәп итеп, машинасына кереп утырды да шоферына:

— Әйдәле, Рәсим туган, безне Калатауга алып мен. Сәфәров абыеңның төзелеш мәйданын очар кош биеклегеннән карыйсы килә бугай,— диде.

Сәфәров Айбулатовның аны бер дә юкка гына Көмеш Аланга алып килмәвен сизенә иде. Шулай да аптыраганын белдермәде. Монда килеп көтмәгәндә оешкан «митинг»та Гөлфирәне, күңеленә якын тоелган яңа төзелеш ыгы-зыгысын, тәртипсезлек һәм оешмаганлыкны белгәч, ни-

чектер икеләнебрәк калды. Иртә белән ул Айбулатов янына тиктомалдан килмәгән иде. Соңгы вакытта күңелендә тупланган юшкыннан арынырга, Чаллыярны коруның иң шаулы көннәрендә ярыйсы гына дуслашып, якынаеп та, аннары сәбәпсез-нисез аралары ерагайган өлкән житәкче янына киңәшкә килүе иде.

Аны, танылган төзүче Гаяр Сәфәровны, югары партия мәктәбен тәмамлый дип, берләшмәнең резерв исемлегенә кертәннәр иде. Моннан ел ярым элек, һич көтмәгәндә, эш урыныннан алып, икенче бер төзү-монтаж идарәсенә партия оешмасы секретаре итеп күчерделәр.

Гаяр аңлый: партия оешмасы секретаре булу гаять җаваплы, кешеләр белән эшли белүне сорый торган эш, әлбәттә. Ләкин йөздән артык кешене туплаган комплекслы бригада белән идарә итү бер, ә партия оешмасын җитәкләү, идарә коммунистларын туплау бөтенләй башка нәрсә. Монда инде, эшләрне оештыра белү сәләтеннән тыш, коммунистларга күрсәтеп бара белү һәм тагын элек Сәфәров уйлап та карамаган бик күп сыйфатлар кирәк булып чыкты. Дөрес, ул үз иптәшләреннән аерылырга теләмәгән иде, ләкин берләшмәнең партия комитетына чакырып сөйләшкәннән соң, карышмаска, эшләп карарга булды.

Карышырга, үзе яраткан эштән, иптәшләреннән аерылмаска булган икән аңарга. Ә ул...

Көмеш Алан авылы урынында салыначак шәһәрнең нинди булачагын, аның үзенчәлекләрен тәфсилләп сөйләп килүче Айбулатов беразга тынып калды. Аннары Гаярга аңлашылмас ачу белән:

— Менә, күрәсезме, Сәфәров, безнең Атакай белән әлегешә башлавыбызның кучәре менә шушында, Калатау итәгендәге карьерда ята,— диде ул эчке бер әрнү сиздереп.— Кайчагында безнең Атакай кебек акыл иясе, тәҗрибәле җитәкче дә ялгыша. Кемнәрнеңдер «иясенә киткәнче» дип үгетләвенә бирешә бит.

— Күз өстендә кара каш сыман торган тау итәгеннән ташлы җир алуны әйтәсезме, Фазыл Артышевич?

Гаярның бу соравы урынсызрак иде, чөнки биредә шушы карьердан башка нәрсә юк. Әмма Гаярның да башында үз уйлары актарыла, үзенеке үзәктә...

Айбулатов мәгънәсез сорауга җавап бирүне кирәк тапмады, җилкәсе аша артка борыла төшеп, Гаяр ягына күз ташлап кына алды.

Ул арада чайкала-чайкала баручы «Волга» Калатау башына менеп тә җитте.

Калатау чирәмлегендә, кай арада күтәрелеп өлгергәннәрдер, сарыбаш, ромашка сабаклары кояшланеп утыра.

Озакламый шәһәр калкып чыгасы урын моннан уч төбендәгедәй күренеп тора. Ләкин биредә Чаллыярны төзи башлагандагы кебек зур көчләр, аңдагыдай шау-шу, мәхшәр сизелми. Нибары өч-дүрт кран, борыннарын Калатау башына таба сузып, кемнәрнедер көтә шикелле иде.

Күкрәкләрне кытыклаган саф һава, тирә-яктагы борынгы тынлык, каршыларында ачылган күренеш үзенекен итте, Айбулатов белән Сәфәровның күңелләрен шәһәр ыгы-зыгысыннан арындырды.

— Син, гафу ит мине, парин,— дип башлады Айбулатов машинадан унбиш-егерме адым атлагач та.— Күңелеңдә кара болытлар йөзгәнне әлегрәк тә сизеп йөри идем мин, Гаяр. Ләкин сүз кушарга өлгерә алмадыммы шунда, әллә көндәлек ыгы-зыгы йотты, әллә теге вакытта, депутат чагында, беркадәр масаебрак йөрүеңнән күңелдә юшкын утырып калганмы — төгәл генә белмим. Шулай да синең ниндидер авыр кичерешләр белән яшәгәнеңне сизәм... Мин сине монда юкка гына алып килмәдем... Анысы соңыннан... Ә хәзер, әйдә, Гаяр, нинди таш бар күңелеңдә, җаныңны нинди уйлар кимерә — чыгар да сал...

Сәфәров мондый сөйләшүгә әзерләнеп, үзе теләп килгән иде, ләкин хәзер үзалдына дулкынлану тойды. Юлда килгәндәге кичерешләр-

ме, әллә нинди көтмәгән-уйламаган җирдән Гөлфирәне очрату, әллә Калатауның саф һавасы биргән рәхәтлектәнме — зиһенендә күптән әзер сүзләре түгел, бәлки тормышының аерым-аерым сәхифәләре бүгенгедәй ялтырап-ялтырап хәтереннән узды.

...Иң югары органга депутатлыкка сайланып, башкаладагы күп санлы очрашуларда, төрле-төрле газета һәм журналлардан килгән иптәшләр каршында чыгыш ясап, үзе кебек депутатлар белән телевидениедән күренгәли торгач, аның характерында тәкәбберлек, мин-минлек сыйфатлары чагылгалый башлады шул. Бер айга якын аның өчен дә эшләгән иптәшләре инде аңа тиңдәш сыман түгел, ничектер бүтәнрәк кешеләр шикелле иде.

Моны бик озак аңлый алмыйча йөрде Гаяр, бик озак...

Шундый көннәрнең берсендә алар эшли торган мәйданга Айбулатов килеп чыкты. Торак йортларны яхшырту, үзгәреш кертү нияте белән йөрүе икән. Айбулатов сызымнары белән эшләнәчәк бизәкле стеналар китергәнне көтәргә туры киләчәк, диде житәкче. Плитәләр бер-ике көннән килер, бүтән эшләрне башкара торсагыз иде, дип үтенде Айбулатов. Билгеле инде, Сәфәров егетләре тоткарлык буласын бик тиз чамаладылар, Бәхтияр Харрасов егетләре белән җан-фәрманга ярышкан чаклары иде аларның. Бөтенсоюз журналы «Огонек» призына ярышта беренчелекне алу-алмау бәхәсенең иң кызу вакыты. Гаяр тегеләй итте, болай итте һәм икенче көнне, яңа плитәләр килмәгәнне сәбәп ясап, искеләрен куярга кушты. Тынычлык проспектына кыры белән баскан мәһабәт йорт шулай итеп бертөсле гадәти плитәләр белән торгызылды. Айбулатов аларны милли бизәкләр төшерелгән нәкышлы плитәләр белән бизәмәкче иде. Бәхтияр Харрасов егетләре: «Янабыз,«Огонек» призыннан коры калабыз»,— димәгән, яңа плитәләр килгәнне көтеп, өч көнгә соңга калса калганнар, проспектка гына түгел, шәһәрнең үзенә дә ямь өстәп торучы плитә-нәкышлы йорт торгызганнар. Дөрес, алар социалистик ярышта ел саен диярлек алып килгән күчмә призданколак кактылар. Приз Сәфәров егетләренә дан өстәде. «Огонек»та рәсемнәрен басып чыгардылар, җыелышларда мактадылар. Хәер, Бәхтияр Харрасов егетләренә дә мактау сүзләре аз тимәде, чөнки алар да билгеләгән чиктән күпкә алда бара иделәр.

Анысы әле аның бәлки эзсез генә узган да булыр иде, әмма приз алган көннәрнең берсендәге актив җыелышында Сәфәров, һич уйлапнитеп тормастан, тотты да: «Без тагын да күбрәк эшләр башкара алыр идек, тик менә безнең эшкә кайвакыт житәкче иптәшләр комачаулый. Нинди дер тәҗрибә ясау нияте белән, башта ук уйламыйча, кызу эшне тоткарлыйлар. Детальләрне алмаштыралар. Мондый хәлләр булмасын иде»,— дип бик «ачы» чыгыш ясады. Активта утыручы җитәкчеләр бу сүзләрнең кем исеменә әйтелүен аңладылар, әлбәттә. Айбулатов ягына таба борылып кайсы күз кысып, кайсы ияк кагып «Во, бирә, күрдеңме?» дигән сыман иттеләр. Айбулатов күңелендә ачу саклый торган кеше түгел. Ләкин инде ул бүтән беркайчан да үзенең яңа тәкъдимнәрен Сәфәров бригадасында сынап карамады...

Сәфәров янәшәсендәге Айбулатовның баягы сорауга җавап көтеп атлавын белеп-күреп бара. Ләкин ул тау түбәсеннән түгел, ә бәлки инеш аркылы салынган басманың сыгылмалы такталарында тирбәлгәндәй хис итә иде үзен. Уйлар тагын ялтыраштылар, хәтер йомгагыннан тагын бер мизгелне сүтеп чыгардылар.

...Гөлфирә теге чакта звено житәкчесе булып эшли башлагач та Нурлыбикә, үзенә генә мәгълүм юллар белән, Гаярның Гөлфирәгә «үлеп» гашыйк булып йөргәнен белеп алган. Башта ул Гаярга: «Үзең чакыртып китергәнсеңдер әле»,— дип бәйләнеп йөрде. Аннары, үзләре бергә-бергә эшләп тә аны-моны сизмәгәч, тынып торды. Икенче мәртәбә тавышны

Мәскәүгә алдынгылар слетына бер төркемдә барган өчен чыгарды. «Соң, Нурлыбикә, мин бил.ләмәдем бит делегатларны. Аны тырыш хезмәте өчен яраталар, үзен күреп торасың, сезнең кебекләрне бер йодрыкка туплап эшләтә»,— дип ычкындырды Гаяр.

Шул гына җитмәгән икән... Нурлыбикә, эшләгән җиренә барып, Гөлфирәгә: «Син иремне миңа каршы котыртасың»,— дип тавыш чыгарды... Ничек җитте шулай җайладылар.

Автогигант һәм Чаллыярның беренче чиратын сафка тапшырган өчен алдынгыларны хөкүмәт бүләгенә тәкъдим итә башлагач та Гаяр алдына катгый таләп куелды: әгәр дә мәгәр Гөлфирәне бүләкләнүчеләр исемлегенә кертеп, аңа орден алып бирсәң — горкомга гына түгел, сезнең депутатыгыз фәлән-төгән дип Верховный Советка язам, диде Нурлыбикә.

Озак, берничә көн уйланып йөрде Гаяр һәм Нурлыбикәсенең таләбенә каршы тора алмады. Идарәгә барып үзе язган исемлекне «Тагын бер тапкыр карап чыгыйм әле» дип алды да... Гөлфирәнең фамилиясен төшереп калдырып яңага күчерде... Кәгазьләр югары урынга киткәч, идарә җитәкчеләренең күзенә иң алдынгы звено җитәкчесенең исемлектә булмавы чалына. Гаярны чакырып, «Нигә болай?»— дип сорадылар.

Сәфәров колак очларына кадәр кызарып, оят булса да, ялганларга мәҗбүр булды:

— Теге исемлектә бар иде, күчереп язганда... ялгыш төшереп калдыргачнардыр.

Аннары мәрмәргә төренгән культура сараенда тантаналы җыелыш булды. Ару-талуны белми эшләгән кешеләр берәм-берәм сәхнәгә күтәрелде, хөкүмәт бүләкләрен алды. Алар хөрмәтенә оркестр уйнады, милли киемнәр кигән гүзәл кызлар чәчәк бирде аларга...

Президиумда утырган Сәфәров концерт башланыр алдыннан зур залга кереп барганда Гөлфирә белән бәрелеште. Халык арасында берсенберсе күрмичә бәрелештеләр, әлбәттә. Шушы мизгелдә Гаяр үзенең никадәр мәгънәсез, никадәр намуссызлык кылганын бөтен ачылыгы белән күрде. Гөлфирәнең күзләреннән күрде. Андагы мөлдерәмә тулы яшьләрнең ачысын тойгандай булды...

Икенче көнне иртә белән звено җитәкчесе эшкә чыкмады. Ә тагын бер көннән комсомолның шәһәр комитеты секретаре пленумда Гөлфирә Шәйхетдинова һәм аның кебек бер төркем алдынгыларга «Атоммаш» төзелешенә путевкалар тапшырды...

— Беләсезме, Фазыл Артышевич... мин инде күптән сезнең белән сөйләшергә теләп йөри идем,— диде, ниһаять, Сәфәров Калатауның биек төшендәге маяк янына җитәрәк телгә килеп.— Соңгы елларда мин бергә эшләгән иптәшләрем, алар башкарган эшләр турында күп уйландым үзем һәм үземнең күңелдә йөргән байтак вакыйгаларны тыгыз иләктән иләдем, йөрәк аша уздырдым...

Сәфәров шулай диде дә кулындагы чыбык белән җиргә суккалап торган Айбулатовка карады. Ул башын аска иебрәк, чыбыгы белән «фиит, фи-ит» иттергәләп тора бирде. Гаярга таба күтәрелеп карамады, дәшмәде.

— ...Минем әле кырыкка да җитмәгән гомеремдә, Фазыл Артышевич, байтак вакыйга булды. Авылда туып үскән, армиягә китеп кенә бераз олы дөнья белән танышкан егет, Чаллыярга килгән идем. Ул чагында тормыш тәгәрмәче шулай әйләнеп китәр дә мине үзе белән ияртеп алып менеп, күкләргә таба чөяр дип кем уйлаган аны, Фазыл абый... «Автогигант булачак монда!» дигәч тә без ышанып бетмәдек... Нишләп монда корсыннар аны, илдә җир беткәнме әллә диешеп йөрдек. Тоттылар да кора башладылар. Олау-олау материал, вагон-вагон кеше килә башлады... Без, билгеле, аптырашта калдык... Шундый берчакны сез килеп

чыктыгыз... Егетләр, әйбәт кенә бер бригада оештырыйк та яңа Чаллыярны корырга керешик әле, дидегез... Аннары... аннары инде үзегез беләсез...

Без эшләдек, вагоннарда яшәп, резин итекләр киеп, бот төбенә кадәр пычракка чумып эшләдек... Ярышка чыктык... сынатмадык. Хәер, Фазыл абый, мин бу хакта сөйләргә җыенмаган идем, телгә килгәнгә генә әйтүем... Мин... үзем турында... Нишләргә миңа хәзер, Фазыл Артышевич, нишләргә? Яраткан эшемнән аерылдым... Мин үзем турында, чыннан да, ай-һай зур фикергә килдем бер чакны... Иптәшләремне санга сукмый башладым. Телгә алып сөйләргә дә оят, янәсе, югары сфераларга күтәрелдем... Ил җитәкчеләре белән кул кысышып йөри башладым... Мине президиумнарда гына йөрттеләр... Озакламый... озакламый Герой буласың дип аркама сугып кына сөйләштеләр... «Без шулай эшлибез, без фәлән хәтлене үтибез»,— дип күкрәк киереп сөйләшергә өйрәндем...

Аннары Чаллыярдагы сынауларны бергә узган иптәшләрем берәнсәрән генә башка бригадаларга күчә яисә үзләре салган шәһәрне калдырып бөтенләйгә китә, яңа кешеләр туплагач та эшләрем алай ук тернәкләнмәгәч... Минем дә башка уй төште. Ләкин соң иде инде. Мин күп дусларымны югалткан идем, күп нәрсә шулай җиңел генә, алтын балык кушканча гына эшләнер дигән фикердән арына башладым...

Минем җаныма суккан беренче нәрсә, Фазыл абый, иптәшләремнең, сыналган дусларымның китүе, очрашкан чакларда күрмәмешкә салышулары, ниһаять, бригаданың акрынлап алдынгылыктан төшеп калуы булгандыр, билгеле. Ләкин... мине иң борчыган нәрсә — кайчандыр берәүне җәберләү, аның җан җылысын куеп эшләгән эшләрен күрсәтмичә, югары бүләктән мәхрүм итү булды... Бәлки, ул беркайчан да орден-медаль өчен эшләмәгәндер... Ләкин... Күпләрнең күкрәк киереп орден тагып йөрүләрен күргән саен минем күз алдыма шушы кешенең мөлдерәмә яшь тулган күзләре килеп баса...

Иң соңгысы, Фазыл абый, оят булса да әйтим, ул чагында мин бит үземне Чаллыярның кендеге итеп саный идем... Автогигантны төзеп бетереп, Чаллыярны иң матур шәһәрләрнең берсе итеп күтәргән көннәрдә, сез инде аны беләсез, мин көтеп, ышанып йөргән нәрсәгә... Хезмәт Герое дигән исемгә мин түгел, Бәхтияр Харрасов лаек булды...

Сез, Фазыл абый, мине дөрес аңларга тырышыгыз, мин хәзер генә бу хакта шулай сөйли алам, чөнки хәзер инде үземнең никадәр оятсызлануымны аңладым... Гомерлек сабак алдым...

Беләсеңме, бездә әле кайвакыт җитәкчеләрнең, кирәкле кешеләрнең күзенә туп-туры төбәп, намуслы кеше күзләре белән карап ялганласаң, икейөзлеләнсәң, сиңа күбрәк ышаналар, сине... сине хәтта ихтирам итәләр... Ләкин кеше дөреслекне күзгә бәреп әйтә башласа, аңа ышанмыйлар, алай гына да түгел, аңардан йөз чөерә башлыйлар...

Шулвакыт Кама өсләтеп бу якка таба очып килгән самолет күләгәсе Сәфәров белән Айбулатов басып торган җирне кисеп китте. Аннары самолет үзе дә Калатаудагы маякка турыланган шикелле килде-килде дә кинәт Кама ягына таба янтаеп тау ышыгына кереп югалды. Гаяр, самолет тау артына кереп югалгач та, нәрсәнедер исенә төшергәндәй иреннәренең чите белән генә елмаеп алды, сүзен дәвам итә алмый торды.

Сәфәров сөйләгәндә чыбыгы белән җиргә суккалап, әле теше сызлаган кеше кебек сул кулы белән яңагын тоткалап, ләкин бары тик бер җиргә — аска, Калатау ышыгыннан калкып чыгачак шәһәр ягына таба кысынкырак күзләрен тагы да кыса төшеп карап торган Айбулатов башын югары күтәрде, самолетны күз карашы белән озатып калды. Сәфәров сүзен дәвам итмәсме дип тагын беркадәр көтте, ак чәчләре белән уйнаган салкынча һаваны күкрәк тутырып сулады.

— Нәрсә дип әйтим сиңа, парин. Син бәлки мине киңәш бирер, болай эшлә, менә тегеләй эшләмә, дип әйтер дип уйлыйсыңдыр? Турысын әйткәндә, Гаяр, син минем өчен яңалык ачмыйсың. Мин генә түгел, безнең йортлар комбинатындагы күпләр синең шөһрәт сынавын уза алмавыңны күреп килде. Ләкин бит ул чагында синең кеше әйткән сүзне дөрес аңламавың бар иде,— диде Айбулатов карашын Сәфәровның йөзенә күчереп.— Иң яхшысы, Гаяр, шушы хакыйкатьне синең үз башың белән аңлавың, минемчә. Ә бит дөреслекне аны, татып карамыйча, кеше сөйләгәннәрдән генә белеп булмый...

Күп еллар элек, тугыз-ун яшьлек малай чагымда, әни мине бәрәңге бакчасына бәрәңге төбе өяргә, чүп үләннәрдән чистартырга чыгара иде... Рәтләрне менә шушында хәтле дип күрсәтеп, билге куеп китә. Мин бу хәлне җиңел генә хәл итәргә өйрәндем. Барам да ул куеп киткән таш кисәген яки җиргә кадап калдырылган чыбыкны берничә рәткә бирерәк күчереп куям. Чөнки эшлисем килми, су буена йөгерәсе, кояшның кайнар нурларыннан качасы килә... Су буеннан исә тиз генә кайтырмын димә... Бераз эшлим дә карыйм — билге тагын да ерагайган шикелле... Барам да тагын бер-ике рәткә... Шулай итә-итә әни куйган билгене байтакка якынайтканмын бит, парин. Әни, билгеле инде, сизеп алды. Әрләде-әрләде дә икенче көнне мин сиңа тагын күбрәк бирермен, эшләмәсәң бабаңа әйтермен, дип йокларга яткырды...

Икенче көнне тагын бакчага чыктык. Әни рәтләрне санады да кулындагы таягын җиргә кадап куйды. Миңа күренеп торсын өчен таякның башына ак чүпрәк бәйләде дә... уракка китеп барды. Кәптең, брамат, болай булгач, минәйтәм. Су керү, малайлар белән уйнауның нәрсә икәнлеген оныт, парин... Эшкә керештем. Бәрәңге төбе саен өч йөз алтмыш градуслы әйләнеш ясап кара әле син! Кул-аягың атламас, аркаларың тураймый башласа, башыңдагы шарикларың селкенә икән ул... Туктале, минәйтәм, нишләп соң мин болай эсседә миңгерәгән сарык шикелле бәрәңге төбе саен әйләнеп, рәт буйлап барып, бәрәңгенең башта бер ягын, аннары китмәнне икенче кулга ташлап ул ягын да өеп була, ләбаса... Шулай итеп, эш җиңеләйде, малай... Тормыш бабай, зар-урри-лык үзе өйрәтте, башны эшләтергә мәҗбүр итте...

Айбулатов Сәфәровның яшьтән үк эшкә чыныгып үскән киң җилкәсенә шапылдатып сугып куйды.

— О-о-о, Гаяр, без синең белән ярыйсы гына серләшкәнбез бирегә, җыелыш башланырга нибары ун минут калып бара түгелме соң? Әйдә, тизрәк,— диде һәм шоферына кулын изи-изи, Сәфәровны көтеп тә тормастан, машина калган урынга таба атлап китте...

Гаяр Сәфәров аның артыннан, аякларын диңгезчеләрчә нык басып атлады. Калатау өстендә бу минутларда күк йөзе ачык, ул җанга рәхәтлек бирә торган зәңгәрлек белән томаланган. Дөрес, Каманың теге ягындагы карурманнарга тия язып берән-сәрән аксыл болытлар йөзә, июнь кояшының җылы нурында коена, кеше хыялындагы бәхет булып салмак кына тирбәлә иде.

## Өченче бүлек

### I

Нурлыбикә, төшке аштан соң ял итеп алырга яткан җиреннән торды да, зур-зур чәчәкләр төшерелгән, итәкләре үкчәсенә тиеп торган халатын төймәләмичә генә бәләкәй өстәл янындагы креслоның йомшак аркасына ауды. Кулларын креслоның ике ягыннан идәнгә кадәр сузып, башын артка чөеп җибәрде, аякларын күтәреп, велосипедта барган шикелле селкеткәләде. Аннары төзелештән киткәч ярыйсы гына йомшарган бармакларын йөгертеп, тагын да түгәрәкләнә төшкән, ләкин яшь-

леккә хас тыгызлыгын саклаган бит алмаларына җиңелчә генә массаж ясап алды. Тагын кресло аркасына ятып, башын артка чөйде, зур, тулы күкрәкләрен киереп тирән сулыш алды. Торшер өстәлендәге телефонга карый-карый, сул яктагы бүлмәгә борылып кычкырды:

— Карлыгач... Карлыгач дим!..

Тавыш-тын ишетелмәде, хәрәкәт сизелмәде.

«Менә бит, атасы кебек үк кире беткән нәрсәкәй» дип уйлап алды Нурлыбикә кызы турында һәм:

— Катя... Катюша!— дип ярыйсы ук каты кычкырды.

Бу юлы бүлмә ягыннан өстәлгә китап ташлаган тавыш ишетелде, аннары бүлмә ишеге теләр-теләмәс кенә ачыла башлады.

— Мин монда бит инде, әни, нигә кычкырасың?

— Нигә дәшмисең? Анаң чакыргач тавыш бирергә, чабып килергә кирәк түгелме соң?

Бүлмә ишеге бөтенләй ачылды, анда балаларга хас очлаебрак киткән ияк һәм әнисенә караганда сузынкырак йөзле Карлыгач күренде. Аның маңгаендагы чәчләре каш өстеннән киселгән һәм бәләкәй-бәләкәй бөҗраларга уралган. Күзләрендә кырыслык чаткылары күренә иде.

— Син бит, әни, мине түгел, нindидер Катюшаны чакырасың... Телефоннан сөйләшәсең дип торам...

Нурлыбикәнең кара күзләрендә усаллык очкыннары уйнап алды, бит алмалары сизелерлек алсуланды, иреннәре ирексездән кысылды.

— Чәнечкеләреңне калдырып тор әле, яме. Күрше кызлары, я булмаса класстагы малайларың белән сөйләшмисең... Бу кадәр атаңа охшасаң да охшарсың икән. Бүре башын табакка салсаң да, урманга таба тәгәрәп төшә диләр иде шул... Ак кала төзим дип, атаң шикелле тиләләргә ияреп йөрмәгән булсам, сине җиде ай ярымнан ук бакчага илтеп ташламаган булсам, тугыз яшеңнән түгел, сөйләшә башлауга акыл укыта башлаган булсам...

Соңгы вакытларда кызын «яшәргә өйрәтә» башлавының бер-берсенә ике тамчы су кебек охшаган чираттагы нотыгы иде бу Нурлыбикәнең.

— Әни, минем әле иртәгә булачак походыбызда сөйләргә шигырь өйрәнәсем бар. Сүзеңне әйт...

— Карале моңа, анасы янында торырга да вакыты юк... Тагын нинди поход? Әле син әниеңнән сорадыңмы, әниең җибәрәме соң сине ул походка?— диде Нурлыбикә керфекләре арасыннан гына кызына сөзеп караган килеш.

— Әтием киткәнче үк сораган идем инде. Ул: «Барырсың»,— диде.

Әнисенең бенгаль утыдай чытырдарга тотынуын белгәнгә күрә, кыз, борылып, бүлмәсенә кереп китмәкче иде...

— Туктале, тукта, кызым... Ну, Катюшенька...— диде Нурлыбикә, бер тәкәбберләнә башласа әйткәнне тыңламаячагын алдан ук сизеп.— Туктале, менә монда, минем яныма кил әле, кил, Катюша...

Кыз, ишек төбендә басып торган җиреннән кинәт кенә кубып, ияген югарырак күтәрде һәм роза чәчәкләре төшерелгән күлмәк итәген җилләндереп янәшәдәге креслога чумды.

— Беренчедән, әни, мин — Катюша түгел. Минем исемемне әти белән бергә син үзең куйгансың, минем исемем — Карлыгач... русчага әйләндерсәң дә, Катюша түгел, Ласточка дигән сүз...

— Хәзер бөтенесе шулай дип йөри. Кем сине Карлыгач дисен? Атаң сүзе белән шул татар мәктәбенә биргән мин юләр... Хәзерге заманда нәрсәгә, әйт әле, нәрсәгә ярый ул татарча укуың?

Кыз, яшьлегенә карамастан, гаять җитдилек белән әнисенә таба борылды.

— Әни, бу хакта без бер сөйләштек бит инде. Нигә тагын шуны кузгатасың. Мин — татар кызы һәм... үз телемне яратам. Ул миңа аңлаеш-

лы. Ул—безнең илебезгә Муса Җәлил кебек батырны биргән халыкның теле. Мин аны белергә, оригиналда укырга телим. Нигә мине тыясың? Үзең әнә русчаны бик яраткан кебек кыланасың, ә сөйләвең... Ә мин русчаны да дус кызларымнан ким белмим, әле мин рус теленнән бер генә «дүртле» дә алганым юк...

Кызының бик күптән инде болай ярсып, озак итеп сөйләгәне, әнисе белән аңлашканы юк иде. Әнисенең «акыл өйрәтүләре»ннән туйган Карлыгач еш кына дәшми, я кырт борыла да бүлмәсенә кереп китә башлый һәм шуның белән әнисенең нәфрәтенә очрый иде.

Нурлыбикәнең дә бүген, гадәтенчә, кызына кычкырып, «син тегеләй, син болай» дип орышырга исәбе юк иде, шуңа күрә:

— Ярый, ярый, кызым... Карлыгач бул... Ярый...— диде ашыгыбрак. Ул, сизелеп тора — башка көннәрдәгедән үзгә, нидер әйтергә теләгән, әмма сүзен башларга җай табалмыйча йөргән кеше шикеллерәк иде. Ләкин характерындагы ярыйсы гына ялтырап чыккан сыйфат тора-бара үзенекен итте.— Син минә, кызым, әниеңне гаеплисең, нигә дип моның кадәр чүпрәк туплыйсың дип үзәккә үтәсең... Тирә-күршеләр, таныш-белешләрнең тормышын күрмисеңме син, кызым? Аларның нәрсәләре юк? Әнә, Бәхтияр Харрасовларны кара син: дубленкалар чыгып өлгермәде, өчесенә дә алдылар. Менә дигән мебельләре бар иде, Герой булган айда ук яңаны — Эфэргедә чыкканын кайтардылар. «Жигули»лары бар иде, ноль пятый чыгып өлгермәде — алыштырдылар... Менә... ә синең яраткан атаң депутат булып күпме йөрде... Әгәр үзем колагына тукып тормаган булсам, әле бердәнбер хатынына һәм кызына дубленка сорап, сәүдә оешмасына кергән булыр идеме ул... Анда да... кергәч тә юньләп сөйләшә алмады бит ичмасам, бер-ике сүз әйтте дә колакларына кадәр кызарынды...

Карлыгач этисенең ул вакытта оятыннан нишләргә белмичә йөргән көннәрен әле дә онытa алмый әле. Шуңа күрә әнисенең чыгышын бүлдермичә түзә алмады:

— Әти, әти... чын төзүче ул... Ул кешеләргә ядкяр-шәһәр хәтле шәһәр төзеп калдыра...

Кыз шулай диде дә әнисенә карап куйды, торып китәргә җыенгандай итте.

— Фиии... Ә мин... мин кем идем синеңчә? Мин... мин соң бу каланы сигез ел ярым буена менә шушы, сине баккан кулларым белән төземәдеммени? Беләсең килсә, ничек кенә төзедем әле! Синең тымызык атаң кадәр генә мин дә эшләдем... Тик ул эшнең кемгә кирәге бар? Кем күрә ул эшне? Әнә атаңны мактадылар, күкләргә чөйделәр, ул гына күз өстендәге кара каш иде, депутат ясадылар... Ә аннан ни файда алды соң ул? Ни файда? Синең дубленкаң бар, вельвет джинсы, чалбарларың әллә ничәү... Аларның берәрсен сиңа атаң алып кайттымы соң? Акча кайтарды? Кайтарса соң, ул аны кемгә кайтарырга тиеш? Әллә...

Кинәт теленә килгән, аңына суккан бу уйдан Нурлыбикә тынып калды, кызына карады, башын кресло аркасына салып уйланып алды, аннары шулай түшәмгә караган килеш дәвам итте:

— Менә мин сигез ел буена кулларымны төрле буяу-измә эченнән алмадым... Нииндидер романтикага бирелеп, юләр шикелле көн саен эшкә йөгердем... Кешеләргәәәә... яңа йортлар булсын, дидем... Ә мине... мине күрделәрме? Миңа бер медаль бирделәр. Шул... Ник бер тапкыр депутат итеп сайласыннар! Мин белгән булыр идем... нәрсә эшләргә икәнлеген... Атаң шикелле үҗым бозавы булып йөрмәгән булыр идем...

Шулвакыт аның сүзен бүлдереп телефон шалтырый башлады. Карлыгач якынрак иде, үрелеп алды да колагын куйды.

— Әйе... тыңлыйм... Әйе... Өйдә юк ул... белмим...

Нурлыбикә урыныннан бу яккарак күчеп:

— Кем ул, кемне сорыйлар?— диде, телефон трубкасын алырга кулын сузып. Ләкин Карлыгач аның сузылган кулын күрмәмешкә салышты. Тагын:

— Әйттем бит инде... өйдә юк ул,— диде дә, сүзне бетергәнгә санап, трубканы урынына куйды. Нурлыбикә түземсезләнеп сорады:

— Кем, кем иде ул?

— Кем булсын инде? Шул... Дядя Эд-дик,— диде Карлыгач, соңгы сүзләренә аерата басым ясап.

Нурлыбикәнең күзләре зур ачылып китте.

— Ә син... Син аны каян беләсең?

Карлыгач әнисенә карап алды, авызы янына төшкән чәч бәйләмен өреп җибәрде һәм иреннәре белән генә мыскыллабрак елмайды да:

— Син юк чакта шалтыратмый дип уйлама син аны...— дип куйды. Аның карашы ук әнисенең кыланышы андый ук яшерен сер түгеллеген әйтеп тора иде. Шуңа да Карлыгач соңгы сүзләрен ярыйсы гына ачу белән әйтеп, бүлмәсенә кереп киткәнгә сүз әйтмәде Нурлыбикә. Эх, бу юлы да башлаган сүзен очларга, иң кирәклесен әйтергә — кызын үзе белән Эдик яшәгән якларга китәргә күндерә алу гына түгел, ул хакта сүз башларга да өлгермәде.

Эдик... Эдик. Менә кем ул Нурлыбикә омтылган тормышның бөтен тирәнлеген белүче... мондый тормышны бирүче кеше... Нурлыбикә аның белән моннан ике ел элек танышты. Танышты... Сәфәров бригадасындагы прораб Камил Мөхәррәмовның хатыны Бәрия туган көнен уздыра икән, Нурлыбикәне шунда чакырды. Дөрес, анда ул чагындагы Нурлыбикә белгән кешеләр бик аз булып чыкты.

Мәҗлес зур түгел, дүрт пар, Нурлыбикә һәм тагын бер ир-ат иде. Бәрия, табынга утырыр алдыннан, аны Эдик янына алып килде, таныштырды.

Нурлыбикә инде ул вакытта Гаяр белән мәҗлесләрдә булгалаган, дөнья гадәтләре белән танышкан, кайчандыр туган авылыннан чыгып киткән ябай кыз түгел иде инде. Яңа танышы Эдикның Нурлыбикә әлегә кадәр күргән барлык ир-атлардан үзенең нәфислеге, игътибарлылыгы, җылылыгы белән аерылып торулары!.. Шундый игътибарны хатын-кыз күңеле сизмиме соң? Иркәләп сөйләшүләре, һәр теләгәнне ярты сүздән аңлавы һәм шуларны үзенә күрә бер осталык белән башкара белгән кешене кем якын итмәс тә кем аның белән танышлыкны икенче көнне үк онытыр икән?

Хәер, аларның танышуы, мәҗлеснең җанлылыгы шулкадәр вакытлы булды ки, аның ахырында инде янәшә утырган икәүнең бик күп уртак теләкләре барлыгы ачыкланган иде.

Моңарчы, Сәфәров белән барган мәҗлесләрдә Нурлыбикә татлы ширбәтләрне капмый түгел, капкалый иде. Ләкин һәрвакыт үзен-үзе тыеп, андый-мондый ялгыш сүз әйтмәсәм, кеше арасында көлкегә калмасам ярый дип утыра иде. Күрәсең, Нурлыбикәнең мәҗлесләргә йөреп тупланган тәҗрибәсе, аларгаияләшүе нәкъ менә Бәриянең туган көненә туры килгәндер. Ул үзен бу мәҗлестә моңарчы бер тапкыр да тотмаганча тота белде. Ачык та, заманча да һәм шул ук вакытта күп төрле мәҗлесләргә йөреп тапталмаганча да тота белде. Кем белә, бәлки аңа гына шулай тоелгандыр, бәлки аңа гына: «Мин бу мәҗлеснең тоткасы, алыштырып булмый торган бизәге»,— дигән фикер килгәндер... Ничек булса да булды. Эдик дигән затлы җан, җаен белеп кенә «патша кызы»ның кеше арасында ничек булса да үзенә иң өстәге урынны алырга омтылган күңелен әйләндерде дә салды.

Нурлыбикә «яши белеп яшәү»нең иң беренче тәмен шунда, шушы кичәдә, Эдик дигән затлы җан янында татыды.

Мәҗлес ярыйсы гына кызды, шуның белән бергә Нурлыбикәнең күңелен кытыклый-кытыклый, аны ниндидер рәхәт томаннар артына алып киткән ширбәт тәме дә артканнан-артты.

Инде «тегендә-монда гына ишеткәләгән» музыка, шөһрәтле артистның карлыккан тавыш белән җырлавына кушылып биешүләр башлангач... Эдикның никадәр заманча, никадәр мавыктыргыч кеше икәнлеге тагын да ачыкланды. Шулвакыт Нурлыбикәнең миен бораулап бер уй узды. Ул ирексездән Эдикны үзенең ире Сәфәров белән чагыштыра башлады. «Никадәр эчпошыргыч бит ул,— дип уйлап алды Нурлыбикә,— аның бит башында эштә дә, өйдә дә үзәкләргә үтеп беткән нәмәрсәләр — план һәм социалистик ярыш, әллә нинди, кеше укымый торган китаплар, имтихан-зачетлар, тегендә дә монда булачак чыгышлар гына. Анда мин юк...»

Дөрес, Нурлыбикә Сәфәровны ир буларак яманлый алмый. Танышкан көннәреннән үк Гаярның көчле куллары үз тәненә килеп тиюгә, Нурлыбикә ирексездән тынып кала, йомшарып төшә, тавыш-тынсыз гына аның көченә буйсына, аның киң күкрәкләренә сыенып «дөньясын» онытa иде. Соңгы вакытларда Гаяр диплом эше белән аның барлыгын да белмичә йөри башлады. Ә аңа, Нурлыбикәгә, бөтен җирдә макталып йөргән, көчле һәм әллә нигә бер назлы да була белгән ир түгел, аңа көн саен шундый тормыш кирәк. Аңа, Нурлыбикәгә, кешеләр кия торган затлы нәрсәләр модасы чыгып беткәч кенә түгел, шәһәрдә беренчеләрдән булмаса да, беренче дистәдәгеләр рәтеннән кирәк. Бәриянең сөйләүләренә караганда, Эдик шундыйларны таба, заманның иң нечкә хисләрен белә торган кеше иде.

Биюләр туктап торган арада әллә ничек кенә икәүдән-икәү лоджида булып чыктылар. Татлы ширбәтнең хисләрне тагын да ныграк исертә торганы — тәрбияле ир-егет белән икәүдән-икәү генә калу, аның таләпчән, тыгыз тәнен тою Нурлыбикәне бөтенләй йомшартты һәм ул Эдикның кочагына кереп чумганын, аннары иреннәренең бергә кушылганын тоймыйча да калды.

Ул кичне Нурлыбикә үзенең гаиләсе барлыгын, кызы һәм ире көтеп торуын бөтенләй истән дә чыгарган иде. Бәлки Бәриянең кыставына бирелеп, аларда куна калган булыр иде, ләкин алар белән бергә утыручы пар Нурлыбикәләр ягына кайта икән. Алар такси чакырткач, Нурлыбикә калмады, кайтып китте. Икенче көнне Эдик белән телефоннан сөйләштеләр.

Карлыгач инде күптән йоклаган, Гаяр, тагын үзенең китапларына күмелеп, имтиханнарга әзерләнә иде.

— Кайда булдың, Нурлыбикә, нигә шалтыратмадың?— диде ул шелтәле тавышын тыярга тырышып. Аның ачуы килгән чакларда икесе бергә кушыла язган калын кашлары сикереп куя. Нурлыбикә бер-ике минуттан Гаярның ачуы ярсып чыгасын аңлады һәм... аны уздырырга, аңардан алданрак дуларга исәп итте.

— Ни эшләргә кушасың миңа борынгы заманнан калган тәртипләрең белән?— диде ул бер генә дә ярсырга исәбе юк кеше сыман.— Нәрсә эшләргә кушасың? Әллә инде иптәш кызларымда утырырга да ярамыймы? Нинди кыргыйлык инде бу? Үзең дә йөрмә, хатыныңны да йөртмә.

— Мин сиңа ачуланмыйм, теләсәң концертына, теләсәң, иптәшләреңә бар, Нурлыбикә... Ләкин бит инде хәзер сәгать төнге бер... Бу вакытта нинди иптәшләр инде ул?.. Шалтыратып кисәтер идең, барып алган булыр идем...

«Тагын шул гына җитмәгән иде, килеп аласың гына калган иде»,— дип уйлап алды Нурлыбикә һәм... шул мизгелдә моңарчы яратып яшәгән иренең искиткеч ерагайганын тоеп, котлары очып куйды. Ләкин бу хәл мизгелнең мизгелен генә билэп торды һәм, Эдик исенә төшүгә, әллә кая китеп югалды.

...Икенче көнне, көтеп-көтеп тә, Эдиктан звонок булмагач, китәргә дип кузгалган гына иде... сискәндереп телефон шалтырый башлады.

Нурлыбикә йөгереп диярлек барды. «Ул, ул, бары тик ул гына»,— дип ашкынган иде, дөрес булган икән.

— Эшләр ничек, Норхен, барамы, баш авыртмыймы?— дип әллә кайчангы әшнәләрчә башлады Эдик. Шундук үзе тезеп китте:— Минем баш, нишләптер, чатнап тора... Әллә... әллә, мәйтәм, Норхен, минем янга киләсеңме? Ерак түгел. Әйе, әйе. Яңа кунакханәгә... Мин төшеп алырмын...

Турысын әйткәндә, беренче минутларда Нурлыбикә, Эдикның кая чакырганын төшенеп тә өлгермәде. Ул инде күңеленнән Эдик кая чакырса да барырга әзер иде. Шуңа күрә ялындырып тормады, кая икәнлеге баш миенә житкәнче үк:

— Барыйммы соң?— дип сораулы ризалыгын бирде.

Ярты сәгатьтән кунакханә каршындагы мәйданның шакмаклы плитәләреннән атлый иде Нурлыбикә. Ләкин туп-туры гына кереп китә алмады ул. Ни генә әйтсәң дә гомерендә беренче тапкыр кунакханәгә... чит кеше янына бара иде ул. Элегрәк кунакханәләргә йөрүче хатын-кызлар турында ишеткәләгәне булды булуын. Ләкин үзен алар урынына куеп карарга башына килмәде. Хәзер исә... Ашык-пошык киенгәч тә өеннән чыгып урам буйлап атлый башлауга аның өстенә салкын су сипкәндәй булды. «Ничек, ничек инде мин туп-туры, тәүге чакыруны ишетүгә таныш түгел ир янына барам?»— дигән уй аны туктап калырга, аннары өй ягына таба атларга мәҗбүр итте. Ләкин... ләкин ниндидер икенче бер көч аның миендә:«Барсаң соң, нәрсә була? Синең анда нәрсә өчен барганыңны кем белә?»— дип кыстап торды.

«Нәрсә эшләргә? Барыргамы-юкмы? Барсаң... бик үк яхшы булмаячак, билгеле. Ни әйтсәң дә ир хатыны бит. Житмәсә, Чаллыярда мәгълүм кешенең хатыны... Бармасаң... Эдик кебек кеше, аның үзенә тартып торган ир-егетнең гомерендә бер генә тапкыр туры килүе ихтимал. Ә бәлки безнең җаннарыбыз шуны тели, бәлки безнең инде бер-беребезне сөюебез шушыдыр?— дигән уй килеп коткарды Нурлыбикәне шикләнүләреннән.— Чынлап та, әгәр дә алар арасында мәхәббәт хисләре туган икән, димәк, бу мәхәббәтнең җавапсыз калмавына, икесенең дә йөрәктәге тойгыларын бер-берсенә бүләк итәргә хаклары бар... бар...

Шундый уйлар белән вөҗданын аклый-аклый килеп керде Нурлыбикә кунакханәгә.

Әмма барысы да искитәрлек гади булып чыкты.

Беренче каттагы вестибюльдә аны Эдик каршы алды. Сул яктагы өстәл янында ике хатын серләшеп торалар иде. Аларның ирен чите белән генә елмаеп калуларын Нурлыбикә күрмәде.

Хәер, никадәр генә тыныч, битараф булырга тырышмасын, энәләргә баса-баса керде Нурлыбикә. Шуңа күрә ул каршысында җиңел автомобиль сыярлык лифт ачылгач та «Ябылмаса гына иде» дигән шикеллерәк эчкә узды. Эдик аның артыннан ук керде.

Ишекләр шыгырдап ябылгач та иркен сулыш алды Нурлыбикә. Эдик лифт өскә менгән көйгә Нурлыбикәне үзенә тартып китерде дә күкрәгенә кысты, алсуланган бит алмасыннан үбеп алды.

Люксның урта оүлмәсендә менә дигән өстәл әзер икән. Нурлыбикә плащын салып ванна ягында битен-күзен караштыргалап чыккач та өстәл янына утырдылар. Бик күптәнге танышлар яки каядыр еракка китеп торган һәм әле генә очрашкан кешеләр кебек бер-берсенә сыенышып утырдылар.

Ширбәте әллә нинди иде Эдикның. Беренче рюмкадан ук Нурлыбикәнең күз алларын сыек яшькелткә томан урый башлады. Ә инде Эдик аны үзенең тезләре аша сул кулына аударгач та... Нурлыбикә карышып торуны кирәк дип тапмады. «Хәзер яки беркайчан да...»— дигән сы-

манрак урыныннан күтәрелде, арттагы бүлмәгә узды һәм Эдикның елмаюлы карашы астында киемнәрен салырга кереште...

Бераздан инде аның ширбәт тәменә күмелгән, хәлнең киеренкелеген уттай янган иреннәре:

— Син... син... нинди кайнар, Эдик... син нинди... рәхәт... Син... Син...— дип пышылдыйлар иде...

Креслоның йомшак аркасына ятып, моннан ике ел элек булган, ләкин искә төшергәндә дә бүген дә кайнарлыктан хәтерне пешереп-пешереп алган хисләреннән тиз генә арына алмады Нурлыбикә. Ни әйтсәң дә, вөҗдан белән хыянәт арасындагы киртәне бер тапкыр узганнан соң, аның кичерешләре, кайнарлыкка һәрвакыт кайнар булса да, барыбер ул чагындагы кебек өтеп-өтеп алмыйлар иде инде. Бәлки аның ул хисләре инде тупасланган да булыр иде, ләкин Эдикны ай күрде, кояш алды, Чаллыярга килә, эшен эшли, Нурлыбикәсе белән үзенә бирелгән вакыттан бик яхшы гына файдалана да тагын килгән ягына таба китеп югала. Дөрес, ...... ни озакка югалмый ул, ике-өч айдан тагын килеп чыга бу якларга. Нурлыбикәнең рәхәтлектә үткән көннәрен-сәгатьләрен сагынып җиткән чагы гына була...

Соңгы очрашуда Эдик сөекле Нурлыбикәсенең өйдәге хәлләре турында сөйләгәннәрен, кайчаннан бирле алып китәм дә алып китәм дип өметләндерәсең, дип үпкәләүләрен тыңлаганнан соң әйтте:

— Мин, билгеле, Норхен, сине алып китәргә, җир читенә олагырга да әзер. Син моны беләсең. Ләкин бит үзең моңа кадәр төрле сәбәпләр таба килдең. Әле кызымны калдырып китә алмыйм дидең, әле тагын нәрсә дә булса чыгарып тордың.

Нурлыбикә инде хәзер Эдикны түргә куеп инаныр халдән узган, аның характерын, нинди уйлар белән, ничек яшәгәнен ярыйсы гына төсмерли. Шуның өстенә Эдикның башка шәһәрләрдә дә тик кенә йөрмәгәнлеген чамалый иде. Әгәр дә алар ир-хатын булып яши башласалар, аңа булган таләпләр дә үзгәрәчәк. Нурлыбикә сөйкемле сөяк Эдикның йомшак якларын белә, шулар ярдәмендә үзенә генә борырга исәпли иде.

Ниһаять, барысы да хәл ителгән. Нурлыбикә иреннән аерылып китүне хәл ителгәнгә саный. Ләкин мондагы квартираны, мебельләрне, аерата соңгы ике елда тупланган туннар, күп төрле затлы әйберләрне, тик торганда калдырып китәсе килми иде аның. Җитмәсә, кызы да тәмам кулдан ычкынды, атасы ягына ауды. Ул зирәк күңелле кыз, әнисенең яхшы юлда йөрмәгәнлеген, Эдик дигән кешенең кемлеген чамалый гына түгел, ярыйсы гына төгәл белә дә иде. Хәзергә кадәр ниндидер бер көч тотып торды аны, әтисенә аны-моны сиздермәде. Тик соңгы вакытларда кызның позициясе ачыклана төште. Ул атасы ягына ава, беркая да китмәячәген төрлечә сиздерә башлады...

Нурлыбикә үзе дә әллә кайдагы, таныш булмаган якларга китүдән ярыйсы гына шүрли, шул ук вакытта Эдик белән ике араны өзәргә хәленнән килми иде...

2

Вергилий Никифорович Дикопольцев зур төзелешләрдә эшләп һәм яшәп, кем әйтмешли, энә күзеннән кереп, җепнең очыннан чыккан кеше. Аны инде берниндн кыенлык, төзелешләрдәге көтелмәгән ыгы-зыгы, иң югарыдагы җитәкчеләрнең килүе белән дә каушата алмыйсың. Аның теләсә нинди эшне мөгезеннән тотып җайлап кына сыртына сала торган каты кулы бар. Ләкин Калатаудагы төзелеш, аның өстенә көнбатышка таба сузыла торган магистраль объектлары да кушылгач, аның тамагына да төер тыгылды.

Дөрес, хәзер инде көннәр буе төзелеш мәйданнарыннан кайтмыйча, төн уртасында да күп төрле киңәшмәләр уздырган чаклар ерагайды. Элек бары тик Чаллыярда һәм якын-тирәләрдә генә тамырланган Кама буе төзелеш берләшмәсе хәзер инде үзенең тамырларын тирәнлеккә генә түгел, ерак-еракларга да җибәрде. Аның бүлекчәләре хәзер «Атоммаш» һәм Башкортстан җирендә, Кама буйларында һәм аннан да еракларда эшлиләр, миллионнар гына түгел, миллиардлар белән исәп-хисап йөртәләр. Автогигантның икенче чиратын тапшырдылар, ләкин әле барыбер эш җитәрлек. Чаллыярда, промышленность төзелешләрен исәпләмәгәндә дә, ел саен 400 мең квадрат метр торак төзелә. Бу, билгеле, аңлаган кешегә, кем әйтмешли, догасын кылмыйча да туярлык.

Кичә һәм бүген Вергилий Никифорович үзен автогигант төзелешенең иң кызган чакларындагыча хис итте. Эш тыгызлыгы һәм вакыйгаларның күплеге искитәрлек әле. Хәер, Вергилий Никифорович башкача эшли белми, аның җаны, характерының корылышы бары тик киеренкелектән киеренкелеккә күчеп кенә яши ала торгандыр.

Бу араларда мондагы төзелешләрдән тыш Калатау һәм... тагын бер яңа, гаять үзенчәлекле, шулай ук төп базалардан ерактагы объектны үзләштерү, андагы эшләрне оештыру белән мәшгуль булды Вергилий Никифорович.

— Алеша... Мирков...— диде ул селектор төймәсенә баскалап.— Алексей...

— Әйе, тыңлыйм сезне, Вергилий Никифорович.

Үзенең мәшәкатьле вазифаларыннан беркайчан да туймый торган ярдәмче һәрвакыттагыча урынында иде.

— Айбулатов күренмиме әле?

— Юк, ләкин озакламас ул, Вергилий Никифорович, кайткан инде. Баярак кына сөйләштек без аның белән.

— Ярый алайса, килү белән керсен, көтеп утырмасын, ярыймы?

— Ярый, кер, Вергилий Никифорович...

Берләшмә аппаратындагы хезмәткәрләр, эш сәгате чыгу белән тизрәк шәһәр тирәсендә ике-өч ел эчендә яңгырдан соң үсеп чыккан гөмбәләр шикелле күтәрелгән бакча-дачаларына ашкыналар. Аларны, билгеле, гаепләп тә булмый. Эштән соң һәркем үзе теләгәнчә ял итәргә хокуклы... Хокуклы... Вергилий Никифорович моны бик яхшы белә, ләкин моннан илле елга якын башланып киткән хезмәт юлында шушы хокуктан ничә генә тапкыр файдаланды ул?

Менә бүген дә иртәдән кичкә кадәр Вергилий Никифорович, кул астындагы кешеләр әйтмешли, «шашкан темп»ны югалтмыйча эшләде.

Иртәдән үк, бер генә минутка да тынмыйча диярлек, селектор аппараты төрле төстәге күзләрен мелт-мелт иттереп утырды. Һәркайсы берничә трестка торырлык идарәләрдәге җитәкчеләр әледән-әле аны эзләделәр. Берләшмә аппаратындагы идарә һәм бүлек җитәкчеләре әледән-әле кергәләп тордылар. Өч тапкыр төрле мәсьәләләрнең торышын тикшергән киңәшмә үткәрелде. Авыл җирендәге төзелешләрдә тар урыннар шактый гына җыелган, шуларны бетерү турында сөйләшенде. Агач эшкәртү комбинатындагы хәлләр, анда җитәкче алмаштыру турында тагын бер тапкыр ярыйсы гына кискен утырыш булды. Аннан соң Үзәк Комитеттан килгән иптәш катнашында магистраль газүткәргеч объектлардагы эшләр торышы хакында озаклап сөйләштеләр, баш миләре кысага кысылганчы уйлаштылар. Бу мөһим төзелешкә Кама буе төзүчеләре үзләренең өлешен кертергә, океан артындагы агайларның мин-минлегенә тагын да бер тапкыр сугарга кирәк, дигән карар кабул иткән иде.

«Нишләп шул агайларга дөнья тар соң?— дип уйлап куйды Вергилий Никифорович.— Инде ничәмә-ничә тапкыр аларның аяк чалуларына карамыйча зур гигантларны торгыздык. Инде ничәнче тапкыр иң җаваплы чорда безнең тыныч эшләребезне өзәргә, дөнья каршында

безне көлкегә калдырырга тырышты алар. Ничәмә-ничә кат инде үзләре тишек тагарак янында утырып калдылар. Бу көрәшнең ахыры булырмы? Бу агайлар беркайчан да безнең эшләребез, алай гынамы, җирдә яшәвебез белән килешә алмаслардыр, ахры... Ә без унҗиденче елдан бирле автогигант төзелешендәге бер бригадир әйтмешли, океан артындагы агайлар ачуларыннан... ачып тешләсәләр дә, яшибез, яшәрбез...»

Вергилий Никифорович, әйләнмәле креслосына бөтен авырлыгын салып, тәрәзә ягына таба борылды. Кама аркылы салынган мәһабәт корылма — ГЭС плотинасы һәм аның өстендәге бетмәс-төкәнмәс краннар һәм тагын бик күп төрле корылмалар, үз гомерендә төрлесен күргән Дикопольцевның сүзләрен, уйларын раслагандай, аның гомерендә булган барлык көрәшләрнең, йокысыз төннәр һәм кеше ышанмаслык киеренкелекләрнең нәтиҗәсе булып мәңгелеккә утыралар иде. Ә бит, ә бит Вергилий Никифоровичның бу төзелешләрнен тамчысын да күрми калуы бик мөмкин иде.

...Сугыш башланганда яшь инженер Дикопольцев Урал якларындагы бер төзелештә эшли башлаган иде. Ләкин аңа, теләкләре һәм энергиясе ташып торган тау инженерына, хыялларын тормышка ашырырга ирек бирмәделәр... Вергилий Көнбатышка таба кузгалган беренче эшелонда булып чыкты. Ләкин башка иптәшләре кебек сугышка тиз генә кереп китәргә туры килмәде аңа. Эшелонны алып баручы хәрбиләрнең берсе — батальон комиссары Рашат Ганиев дигән үтә житди кешенең ихтыяры Дикопольцевны Идел ярындагы Куйбышев шәһәрендә калдырды.

— Син инженер кеше, югары белемең бар, сугыш хәтле сугыш чыккан икән инде, анда синең кебек белемле командирлар да кирәк. Сугышырга өлгерерсең, әйдәле, егет, командирлык серләрен дә үзләштер,— диде аңа зәңгәр күзле, ачык йөзле, чандыр гәүдәле Ганиев.

Дошман яулары Мәскәүгә якынлашканнан-якынлаша бара иде. Булачак командирлар телдән булмаса да күңелләреннән: «Без бармыйча фашист яуларын туктата алмаячаклар, без генә аларның әҗәлчесе»,— дип уйладылар. Һәм шуңа күрә ике көннең берендә командирларына: «Безне фронтка җибәрегез»— дип ялвардылар. Хәтта... янаучылар да табылды. Бер акыллы башлы иптәш, мәсәлән, командирларына ачыктан-ачык:

— Сез фашистларга ярдәм итәсез, безне, югары белемле кешеләрне, юк-бар белән йөртеп фронтка җибәрмичә тоткарлыйсыз. Шушы атнада җибәрмәсәгез — күрегез дә торыгыз, иптәш Сталинга хәбәр итәчәкбез!— диде.

Шушы сүзләрдән соң ачуланырга, чиктән тыш тәртипсезлек күрсәткән курсантны аз дигәндә гауптвахтага ябарга тиешле командир салмак адымнары белән, берәз аксый-аксый (соңыннан белделәр — фин сугышындагы яралары төзәлеп бетмәгән икән әле) сафтагы курсантларның йөзенә карап арлы-бирле үтте һәм әлеге «акыллы баш» янына туктап аның җилкәсенә суккалады. Аннары сүзсез генә иңенә аскан кыр сумкасыннан дүрткә бөкләнгән кәгазьләр чыгарды.

— Укы!— диде.

«Акыллы баш» командирга кырын карый-карый бармак очлары белән генә диярлек әлеге кәгазьләрне актара башлады. Аларны кулдан кулга җибәрделәр. Һәркайсының почмагына: «Отказать! Вы нужны здесь!»— дип язылган иде.

Шул көннән соң командирны «хыянәт»тә гаепләүче булмады. Хәер, тагын атна-ун көннән курсантларны төн уртасында тревога белән күтәреп алдылар да, рота-рота сафка бастырып:

— Шагом-марш!— дип боердылар.

Әле кайчан гына «сугышка җибәрмисез» дип җикеренеп йөргән «акыллы баш»лар, дөресрәге, такыр башлар, аны-моны аңышып өлгер-

гән арада алар инде башкалага таба ыргылган фашист яуларын тоткарларга өстәмә көч булып баралар иде.

Командир булды егетләр. Ләкин кече командирларга житәрлек хәрби белемнәрен генә үзләштереп өлгерде алар. Вакыты шундый иде, кул астындагы көчләрне ут һәм броняга каршы куярга, төп көчләрне туплап китергәнче ничек кенә булса да илнең йөрәге — башкалага фашист илбасарларны җибәрмәскә кирәк иде...

Дикопольцев пулеметчылар отделениесенә җибәрелде.

Бер ай эчендә ике тапкыр чолганышта булдылар. Кулларына кара автомат тоткан фашист тәреләре белән йөзгә-йөз, якага-яка, тешкә-теш, бугазга-бугаз килделәр. Меңнәр ятып калды. Сафлар сирәгәйде. Кешеләрнең рухы барыбер сынмады. Үзләрен җиңелгәнгә санамадылар. Канлы яраларын ничек җитте шулай бәйләделәр дә, атлап булмаса үрмәләп, үрмәләп булмаса шуышып үзебезнекеләр ягына чыктылар, кулларындагы коралны ташламадылар. Илнең шифалы чишмә-инеш, елга һәм күлләрендәге су белән битләрен-яраларын юдылар да яңадан фашистларга каршы бастылар.

Өченче чолганыштан чыгу насыйп булмаган икән...

Ул иртәне Дикопольцев җирдә күпме яшәсә, тәнендә җаны күпме торса — шуңынчы исеннән чыгармаячак, бер генә мизгелен дә онытмаячак.

Көзге төннең төпсез караңгылыгын ярып, алтынсу төскә кергән яфракларны тагын да ныграк кызартып, йөзьяшәр агач ботаклары арасыннан сизелер-сизелмәс кенә кояш күтәрелеп килә иде. Кайдадыр еракта, хәлдән тайган сугышчылар тупланган төштән төньяктарак, үз кодрәтенең илаһилыгын белдертеп күк күкрәп алды. Сугышчылар шундук югарыга текәлделәр. Ул карашларда, бәлки, бу иртә безне эсселектән, сусаулардан, ниһаять, соңгы һөҗүм вакытында дошман пуляларыннан коткара торган яңгыр алып килер, дигән өмет уты яна иде.

Дикопольцев үзенә ярдәмгә бирелгән өч сугышчы белән таң атканчы безнекеләр тупланган урман алдындагы болынны, болын артындагы елгага чыга торган бердәнбер юлның текә борылышын арканлап алган иде. Кузгалдылар. Тылсымлы бер көч аны ирексездән артына борылырга, урман авызына таба карарга мәҗбүр итте. Әйе, дошман күзеннән яшерен чокырларда тупланган, үзебезнекеләр ягына тизрәк чыгарга уйлаган кешеләр болындагы биек үләннәрне ярып елгага таба йөгерәләр иде. Менә алар, болынның уртасын узып, ялгыз кушкаен янына җиттеләр.

Шулвакыт, баягы күк күкрәү авазларын томалап, бөтен тирә-як яңгырсалдәүләргә күмелде. Ул да түгел, кушкаен, үсеп утырган җирдән төбе-тамыры белән кубып, күк йөзендәге болытларга таба күтәрелә башлады...

Дикопольцев күзләрен ачкач та гәүдәсенең барлыгын сизмичә байтак ятты. Әйтерсең, аның куллары да, аяклары да юк, әйтерсең, урманлысулы дөнья, күгелҗем болытлардан һәм төннән арынган күк йөзе төн буена, җанны өшетеп чыккан юеш салкынлык та юк. Әйтерсең, ул, Дикопольцев, әллә кайдагы бер җисемнән аерылып, япа-ялгызы гына очып йөргән сыңар бөртек, аңсыз-зиһенсез тузан бөртеге иде.

Шулай да беравыктан Дикопольцев колакларында иләмсез шау-шу ишетте, күкрәк астындагы ниндидер әгъзаларның үзәкләргә үтеп әрнүен тойгандай булды.

Аң тупларга өлгермәде, үзе яткан җирдәге баягы кушкаен шикелле кубарылып, күккә таба күтәрелә башлады. Күзен ачмакчы булды, ләкин дөнья аллы-кызыллы чаршау булып кына күренде.

Аннары... аннары өч ел ярымга сузылган әсирлек.

Үзебезнекеләр килеп азат иткәннән соң, Дикопольцевка язмышының тагын да ачырагын татырга туры килде.

Үлем лагеренда бер чеметемлек җанын сатып, әсирләрне крематорийга озаттырып йөргән бер бәндә безнең тикшерүчеләр алдында да

боргаланырга, юха елан шикелле агуын сибәргә, үлем лагеренда көрәш оештырган кешеләрне пычрак белән бутарга керешкән икән.

Тикшерүләрне узган Дикопольцевны тагын чакыртып алдылар.

— Синең өстән, Дикопольцев, менә шундый сүз керде. Үзеңне аклар-лык нинди дәлил китерә аласың? Каршылык төркемен житәкләвеңне кем-нәр раслый ала?— дип сорадылар аңардан.

Әсирлекнең хурлыклы юлларын үткән, биш мәртәбә каравылчы эт-ләрен алдап качу бәхетенә ирешкән, ләкин бишесендә дә яңадан фашист-лар кулына эләгеп, күпме өстәмә кыен, мыскыллаулар кичергән, шуңа карамастан үзенең рухи ныклыгын саклаган һәм каршылык төркемен туплаган кешегә моны ишетүе, әлбәттә, жиңел түгел иде.

— Ярый, иптәшләр,— диде ул, бераз уйлап торганнан соң.— Менә сезнең алдыгызда безнең төркем чыгарган листовка ята. Аны чыгаруда минем дә өлешем барлыгын раслаучы кешеләр, кызганычка каршы, фашистлар белән соңгы бәрелеш вакытында һәлак булды. Ләкин, зинһар, шикаятьчене чакырыгыз, мин аңа бер генә сорау бирәм. Әгәр дә шул сорауга төгәл жавап бирә алса, димәк...

Теге бәндәне Вергилий Дикопольцев ишектән керүгә таныды. Аның намусында байтак кына иптәшләрнең жаны ята иде. Каршылык төркеме чыгарган «Юк итәргә!»— дигән карарның үтәлми калуы бик кызганыч иде.

— Ярый, сез әйткәнчә, Каршылык төркеменә минем катнашым юк икән, соңгы баш күтәрүне оештыруда мин катнашмаганмын икән... Син... сез... бер сорауга жавап бирегез әле.

Дикопольцев тикшерүченең өстәленнән, үрелеп, саргылт кәгазь битен алды. Каршылык төркеме чыгарган листовка иде ул.

— Менә монда, листовка текстының астында,— диде ул теге бән-дәгә якын килергә жирәнеп,— күп урынлы саннар сугылган — алар нәр-сәне аңлата?

Сатлык жан утырган жирендә селкенгәләп куйды, аннары аягүрә ба-сып әсирләр канына манчылган кулын сузды. Янәшәдә торган сугыш-чы листовканы аңа алып бирде.

— Болармы?.. Болар...— диде хаин күзен дә йоммыйча.— Болар, бе-ләсегез килсә... безнең... безнең төркемнең күктән алган шартлы саннары... Соң, билгеле бит инде, без үзебезнең фамилияләребезне, яки лагерьдагы номерларыбызны куя алмый идек...

Дикопольцевның йөрәге киеренкелектән ашыгып-ашыгып тибә иде.

— Ярый алайса, тикшерүче иптәшләр. Бу бәндә Каршылык төрке-мендә катнашкан икән, әйтсен: листовка тексты астындагы саннар, аның-ча, шартлы саннар икән... Ул чагында ничек итеп алар минем партби-летымның номерына тәңгәл килә?

Тагын ике көннән Дикопольцевны хәрби хезмәтен дәвам итәргә озаттылар, ә теге бәндә «макар көтү көтмәгән жиргә» ил һәм һәлак бул-ган әсирләр алдындагы мәңге юылмас гаебен юарга озатылды...

Айбулатов берләшмә житәкчесенең ишеген ачып керде һәм туктап калды. Вергилий Никифорович урынында юк иде.

«Ял бүлмәсендә микәнни?»— дип уйлап алды ул һәм кабул итү бүлмәсенә чыгып торырга исәпләде. Шулвакыт ишектән кергәч тә күренми, күп төрле киңәшмәләр дәвамында һәрвакыт ачык куела торган тәрәзә ягыннан:

— Кер, кер, Айбулатов, әйдә уз,— дигән тавыш килде. Вергилий Никифорович ачык тәрәзә каршына баскан да ГЭСның кичке күренеше-нә карап тора иде.

— Исәнмесез, Вергилий Никифорович!

Дикопольцев гәүдәсенең бөтен мәһабәтлеге белән Айбулатов ягына таба борылды.

— Безнең монда АЭСтагы эшләрне төп башкаручы Алмазов һәм аның белгечләре катнашында киңәшмә булып узды бит әле, Фазыл Артышевич. Сезнең исемгә әйтелгән нәрсә барыбызга да мәгълүм: торак йортларны тизрәк өлгертә башларга кирәк.

— Анысы шулай, Вергилий Никифорович, ләкин бит әле Алмазов идарәсе дә ашкынып эшләми. Өч агрегаттан торган измә-бетон узелын файдалануга тапшырдык дип шауладылар, ә безнең төзүчеләрнең аннан бер тагарак измә алганнары юк. Читтән ташырга мәҗбүрбез... Без сүзебездә торырбыз: беренче сентябрьгә мәктәп бинасын, яңа елга бишәр катлы йортны өлгертербез. Тик... Алмазов агайның егетләре котельный дигән нәрсәнең нигезен дә салмый бит әле...

— Фазыл Артышевич, Фазыл Артышевич...— диде сузыбрак Дикопольцев.— Сезгә хас сүзләр түгел бу. Нишләп әле зарланудан башладыгыз?..

— Юк, Вергилий Никифорович, зарлану түгел бу. Обстановканы житкерү... Рөхсәт итсәгез, мин сезне, Вергилий Никифорович, Көмеш Аландагы хәлләр белән конкретрак таныштырыр идем,— диде Айбулатов һәм беразга тынып калды. Ул арада Дикопольцев шәһәрара телефоннан сөйләшеп алды.

— Дәвам итегез, Фазыл Артышевич...

— Мин, Вергилий Никифорович, Көмеш Аландагы комплекслы бригаданы махсус участок итеп үзгәртеп тупларга булдым. Алай гына да түгел, киләчәктә ул участокны мөстәкыйль төзү-монтаж идарәсе иткәндә дә яхшы булыр иде. Сез каршы килмәссез дип уйлыйм.

Дикопольцев аны креслосында утырган килеш сул кулының бармаклары белән чигәсен уа-уа тыңлады.

— ...Участокны, аннары бәлки идарәне дә элекке бригадир, Чаллыярны төзүгә күп өлеш керткән Гаяр Сәфәров житәкләр. Мин инде аны Көмеш Аланда калдырып та кайттым... Менә тагын шул балык башы диярсең инде, Вергилий Никифорович... Әйдәгез, Көмеш Аланны төзүдә болай итик әле: йортларның нигезен салуны «Спецстрой»дан алып безгә бирик. Моның өчен Көмеш Аландагы участокларын тәҗрибә йөзеннән безгә буйсындырыйк.

Бу хакта Дикопольцев белә. Йорт төзүчеләр белән нигез салучылар арасындагы күп еллык бәхәс әлегә кадәр хәл ителмәгән. Шуның аркасында кайсыбер айларда торак салу заданиесе үтәлмичә дә кала...

— Кызык тәкъдим бу, Фазыл Артышевич, мин моны күптән уйлап йөри идем йөрүен, нишләптер җае чыкмады. Ярый. Мин риза.

Вергилий Никифорович ишектә күренгән ярдәмчесе Мирковка: «Баш инженер, Андрей Моисеевичны тап әле»,— диде дә алдындагы блокнотына бер-ике сүз язып куйды.

— Бусы бер нәрсә, Вергилий Никифорович, ләкин бит Көмеш Аланга, иртәме-соңмы, кешеләрне күбрәк җибәрә башларга кирәк булачак. Кайда яшәрләр дисезме? Чаллыярда бик күп вагоннар бушый, аларны тиктомалга җимерәләр яки шәхси дачаларга тарттыралар. Барысын булмаса да, бик күбесен файдаланып булыр иде аларның. Көмеш Аланда вакытлы шәһәрчек булдырмыйча булмастыр...

— Ничәнче төзелешне «вакытлы» торактан башка башларга җыенабыз, ләкин шуңа ирешкәнебез юк әле. Ярый, Фазыл Артышевич, эшләгез. Бу ел ахырында кимендә биш-алты йорт сафка кертелергә тиеш... Үзегез шәһәрнең урынын үзгәрттегез, инде хәзер үзегез үк өстәмә средстволарны кайдан табу турында да уйлагыз.

Айбулатов аңлады: ничә елдан бирле бергә эшләп тә күңелендә үпкә сакламаган Дикопольцев коллегия киңәшмәсен онытмаган иде. Шулай да әйтергә җыенып килгәнен әйтергә, тагын бер тапкыр Вергилий Никифоровичның кәефен «бозарга» булды!

— Сез мине кичерегез, Вергилий Никифорович,— дип ерактан әйләнеебрәк башлады ул.— Ләкин... минемчә, Көмеш Алан причалына

Калатау итәгеннән ташлы җир алуны кичекмәстән туктатырга кирәк... Ни өченме? Хәзер үк инде, Вергилий Никифорович, шәһәр ягыннан караганда ярыйсы гына шыксызлык ачыла. Ничәмә гасырлар буена табигать тарафыннан нигытылган ярны ишү, күренешне шыксызлау безгә бик кыйммәткә төшәчәк. Матурлыкны бозуны безнең халыкның килер буыннары кичермәс. Әнә минем төзелеш институтында укучы өлкән улым Көмеш Аланга кайтырга җыена. Ул — минем улым — бабалары җирендә атасы корган шәһәрдә яшәячәк. Мин аңа ни җавап бирермен.

Айбулатов сөйли башлауга Дикопольцев йөзен чытып куйды. Бу аның авырткан чуаны иде. Чынлап та, ниндидер бер тискәрелек, кемгәдер үпкәләү дип әйтергәме, әллә «бу инде минем төзелеш булмас» дигән уймы үз вакытында Вергилий Никифоровичка комачаулады. Ул, Айбулатовның кисәтүләренә карамыйча, Калатауның олтанын казып, причалга дамба салырга рөхсәт бирде. Билгеле, ташлы җирне якыннан алу эшне ярыйсы гына тизләтә иде. Ләкин... бу эш балакны кисеп җиңне ямап кую белән бер булып чыкты...

Айбулатов берләшмә җитәкчесенә күтәрелеп карамыйча гына алдындагы кәгазьгә сызыклар сыза-сыза дәвам итте:

— Хәзер үк, иртәгәдән үк туктатырга кирәк, Вергилий Никифорович. Калатауны рәнҗетүне. Болай да инде безгә, сезнең белән, казыган җиребезне нигыта башларга кирәк дип уйлыйм...

Бүлмәдә гаять тирән тынлык урнашты.

## Дүртенче бүлек

### I

Гаяр йокысыннан кинәт уянып китте, шундук торып утырды.

Вагонның тимер рәшәткәле ачык тәрәзәсеннән иртәнге саф һава агыла, майкасыз тәндә бөрчек-бөрчек чирканчыклар хасил итә иде.

Ике-өч тапкыр Гаяр кулларын ян-якка сузгалап, идәнгә таба чүгәләштергәләп, тән язгыч хәрәкәтләр ясап алды да трикодан килеш ишегалдына чыкты.

Яктырган, Кама ягыннан кояшның иң өске өлеше генә ураксыман булып күренә. Әлегә кул тимәгән, ләкин инде озакламый беренчеләрдән булып сүтеләчәк авылның кайсыдыр йортыннан әтәч кычкырган тавыш ишетелде. Шунда ук сыер мөгрәп куйды.

«Тормыш үзенекен итә, тирә-юнь төнге йокыдан уяна,— дип уйлады Гаяр, шәһәр ыгы-зыгысына да кереп өлгермәгән Көмеш Алан өстенә карап.— Һәр яңа көн үзе белән бирегә нинди дә булса яңалык алып килә, җиләк-җимеш, чия бакчаларына күмелгән Көмеш Аланны үзгәртә. Дөрес, әлегә искитәрлек матурлык күренми, киресенчә, хәтта, бар эшебез — әлегә ишү, җимерү, сүтү, казу, җир актару. Тик, барыбер, Көмеш Алан инде үзенең элеккеге тормышына кайтмаячак. Бәлки, Көмеш Алан дигән авылның исеме, шәһәр исеме булып, тарихка языла башлар».

Һәр яңа көн үзенә генә хас матурлык белән килә. Гаяр моны бик күптәннән күреп белә. Тик бүгенгесе аерата матур, кичә кичкырын гына тирә-яктагы тузаннарны бастырып җылы яңгыр явып узган иде. Шуның галәмәте күрәсең, бүгенге иртә аерата саф, салкынча һәм чисталык бөркеп тора. Өлгергән шомырт һәм... әллә шулай тоела гынамы, инде август ае булуга карамастан, сирень чәчәкләренең исе килә.

Шундый ләззәтле иртәләрне бигрәк тә ярата Гаяр. Чаллыярда яшәгәндә мондый иртәләрне күрмисең, чөнки шәһәр зурайды. Кайчандыр аның да иске өлешендәге бакчаларыннан хуш исләр бөркелә иде, ләкин бу хәл озакка бармады, олы төзелеш алып килгән машиналар шау-шуы, күкләргә ашкан ташпулатлар ул исләрне үзенә йотты, сеңдереп алды.

Әмма биредә — Көмеш Аланда төзелеш яңа башлана гына, иң беренче йорт...

Гаярның уйлары әнә шуларга, беренче йортларга, аларны салучыларга, алар кузгаткан ыгы-зыгы, бер караганда һичберкем хәл ителмәслек булып тоелган мәшәкатьләргә күчте.

Шушы уйлар белән күмәк юынгыч янына барып, бил тиңентен чишенде, кичә кич дежур кызлар тутырып калдырган, төн эчендә ярыйсы гына салкынайган суны чәчрәтә-чәчрәтә юынды. Озын, йомшак сөлгесе белән сөртенә-сөртенә вагондагы бүлмәсенә керде.

Ял көне булганга күрә вагоннарда яшәүчеләрнең торырга, көндәгечә эшкә җыену ыгы-зыгысы белән булашырга уйларында да юк. Хәер, кичә монда яшәүчеләрнең дә күбесе Чаллыярдагылар белән кайтып китте. Гаяр да бүген ял итеп алырга, соңгы ике айдагы мәшәкатьләрдән бераз бушанырга, алдагы көннәрдә башкарыласы эшләрне барларга исәпләде.

Чәй кайнап чыкканчы дип, өстәл тартмасыннан каты тышлы, монда килгән көннәрдә үк яза башлаган калын дәфтәрен алды.

Турысын әйткәндә, көндәлек язу Гаярның бик күптәнге, бишенче класста ук «чирләгән» һәм арына алмаган гадәте иде. Дөрес, ул аны берәүгә дә күрсәтмәскә, белгертмәскә тырышты, ләкин бер авылда яшәп, бер мәктәпнең бер классында укыган иптәшләреңнән сер яшереп була димени?

Белделәр.

Алай гынамы, көндәлек язуның ниндидер серле ягын күреп, Гаярны үз араларында тылсым көченә ия булганрак кешегә санадылар, «журналист» дип йөртә башладылар. Аның барлык язу эшләрен аерата пөхтәлек белән башкарып, сочинениеләрне әйбәт язуын әнә шушы көчтән күрделәр. Аннары... аннары ике дә уйламыйча, Гаярны мәктәп газетасының редакторы итеп билгеләделәр.

Гаярдагы журналист булу теләгенең яшерен көче, бер башлаган эшкә үҗәтлек белән ябышып ятуы, кешедән яшереп дәфтәр-дәфтәр көндәлек язуы, район газеталарына мәкаләләр җибәргәләве җиңгәнме, әллә кем әйтмешли, чынлап та авылда туып, табигатькә гашыйк булып үсүме — кайсы да булса булгандыр, билгеле, Сәфәров дигән егет тугызынчы-унынчы классларда республиканың яшьләр газетасында да басылгалап торды. Ләкин шунысы гаҗәп, журналист булу теләге Гаяр Сәфәровның зур хыялына әверелеп китмәде. Әмма каләм шомартулары, аннан соң да шушы гадәтен онытып бетермәве, җае килгәндә газеталарга язгалавы, бигрәк тә ихласлык белән тулы көндәлекләрне дәвам итәргә тырышуы эзсез генә югалмады. Чаллыярдагы ыгы-зыгы шул кадәр көчле булды, язмыш Гаярны дулкыннарның шундый биек өркәчләренә утыртып йөздерде ки, вакыйгаларны көндәлек дәфтәре битләренә күчереп барырга вакытны бөтенләй диярлек калдырмады. Хәер, бик нык теләгән очракта моңа вакыт таба алган да булыр иде, бәлки... Әнә шушы «бәлки», дөресрәге, өйләнешкәннән соң Нурлыбикәнең ул көндәлекләрне сораусыз-нисез алып укулары һәм язылганнардан үзенчә нәтиҗә чыгаруы, җай чыккан саен, чәнчеп-чәнчеп алулары, ахыр чиктә бөтенләй кул селтәвенә китерде дә. «Көндәлек ул — вөҗдан көзгесе,— дип уйлый иде Гаяр,— аны көчәнеп язуга караганда бөтенләй язмавың артыграк».

Бирегә — Көмеш Аланга килгәч тә ниндидер эчке бер тойгы Гаярның күңелен җилкендереп җибәрде, төзелешнең тарихына керердәй вакыйгаларны язгаларга мәҗбүр иткән иде...

Хәзер дә Гаяр, шушы минуттагы халәтенә буйсынып, өстәлдәге дәфтәрен яңадан алды, кадерләп кенә ачты һәм ашыгыч язылганга күрә бигүк пөхтә тоелмаган юлларны укый башлады.

9 июнь, Көмеш Алан.

Монда килеп эшли башлавыма биш көн тулды. Бу шул кадәр көтелмәгән, башыма да килмәгән бер вакытта булды ки, Айбулатов мине машинасына утыртып, төзелештәге хәлләр белән таныштырганда, Калатау башына менеп, эч серләрен бушатканда да Көмеш Аланның минем төзелешкә әвереләсен уйлап та карамадым. Чөнки, турысын гына әйткәндә үз кайгым үземә бик житкән, нишләргә, кая барып бәрелергә белмичә аптырап йөргән чагым иде.

Ике ел чамасы элек, кемнеңдер изге теләге белән мине, ничә еллар буена житәкләгән комплекслы бригадада эшләгән жиремнән алып, төзү-монтаж идарәсенең партия оешмасы секретаре итеп сайлаганн иделәр.
Билгеле, әгәр дә мине бригададагы иптәшләремнән, андагы мәшәкатьләрдән аермаган булсалар, бәлки, Чаллыярдагы төзелеш башланганнан бирле узган тормышымны бу кадәр үк бирелеп энәсеннән жебенә хәтле төпченеп тикшермәгән дә булыр идем. Ул бригадада эшләгәндә үткәннәремне барлау белән шөгыльләнергә вакытым бөтенләй диярлек калмый иде.

Шуның өстенә өйдә дә әллә нинди тормыш башланды. Кайтып керәсе килмәде, кайтсам, тизрәк чыгып китү ягын карадым. Бусы соңрак, Нурлыбикәнең кем икәнлеген ачыклагач, аның нәрсә һәм кемнәр белән яшәвен күрә башлагач булды. Шуны аңлагач та жанны миңа билгеле булмаган ниндидер бер көч актарып салды, пыран-заран китерде.
Шундый көннәрнең берсендә Айбулатов янына киңәшергә, сөйләшергә дип килүем иде. Ул минем хәлләтемне миннән яхшырак аңлаган, күрәсең...

Көмеш Аландагы төзүчеләр киңәшмәсендә катнашырга туры килгәч, прораб Зубровның башбаштаклыкларын ишеткәч, яңа шәһәрне төзүчеләрнең эшләре бигүк шәп бармавы, билгеләнгән эшләрнең үтәлмәве ачыклангач, үзем дә сизмәстән, сүзгә кушылып киткәнмен.
Шунда Айбулатов әйтте:
— Син, Гаяр, менә болай ит әле. Мондагы участокны үзеңә ал әле, яме. Тәжрибәң бар — Чаллыярдагы йортларның яртысын ук булмаса да, өчтән берен син күтәрештең. Югары партия мәктәбен бетердең... Дөрес, теге вакытта мин әйткәч тә төзүче-инженерлар институтына бармадың баруын. Ярый инде, узган эшкә салават... Жаның-тәнең белән төзүче син. Барыбер партия работнигы чыкмас ахры синнән. Я, ничек, ризамы, каласыңмы?
Мин моны көтмәгән идем. Күрәсең, Айбулатов агайга сәеррәк күзләр белән карап куйганмын. Ул тагын:
— Я, нишлибез? Әллә синең Калатауда әйтелгән баягы сүзләрең болай гына, кызыл сүз генәме?— дип, мине стенага терәде.
Билгеле инде, мондый очракның тиз генә булмасын аңлый идем. Соңгы елларда кичергәннәрнең дөреслеген менә шушындагы мәйданда сынарга, киләчәктәге тормышымның аерым мизгелләре өчен кызармаслык итеп корырга, бәлки, бердәнбер мөмкинлек иде бу.
Мин ризалык бирдем.
Китәр алдыннан, башкарасы эшләрне билгеләгәндә, Фазыл Артышевич әйтте:
— Гаяр, сиңа инде сөйләп торасы юк, ләкин тагын бер тапкыр исеңә төшерүне кирәк санадым: һәр эшне башлаганда иң кыеннарның кыены — ышанычлы кешеләрне туплау. Арага чит-ят нәрсә кертмәү. Күргәнең бардыр: кайбер ипинең урта бер жирендә он яки камыр кисәге укмашып калган була. Кемгә ничектер, белмим, әмма минем үземә бу бер генә дә ошамый. Ипинең гаебе юк, ул менә диген камырдан тора, тик барыбер күңелне нәрсәдер тырный. Монда да шуның кебек: әгәр дә син туплый торган кешеләр арасына ят кушымталар кереп оялаca, ахыр-

дан аларны аралап алу гаять кыен булачак... Шуңа күрә башта ук кешеләрне дуслаштырырга, ихтыяры бер көчкә буйсындырырга кирәк. Шулай итә алсаң, эшләрнең яртысын башкардың дигән сүз...

Һичшиксез, Фазыл абый, болар барысы да дөрес. Ләкин аларны ничек итеп, нинди юллар белән тормышка ашырырга соң? Ничек ялгышмыйча тупларга ул кешеләрне?..

11 июнь, Көмеш Алан.

Кешеләрне туплау турында яза башлаган идем. Чынлап та, бик четерекле мәсьәлә булып чыкты бит әле яңа кешеләрне туплау. Хәзер безнең вагоннарда алтмышка якын кеше яши. Күпчелеге — хатын-кыз. Аларның да яртысыннан артыграгы балалы хатын. Төрлесе төрле җирдән килгән. Ләкин, ни хикмәттер, аларның күбесенә уртак бер сыйфат бар: утызны, хәтта егерме бишне дә тутырмаганнар. Ирләреннән я аерылган, я аерылмыйча гына китеп баручылар...

Шулар белән сөйләшеп чыккан идем: чәчләрем үрә торды. Хәзер безнең вагоннарда аз да түгел, күп тә түгел — мәктәп яшенә җитмәгән егерме өч бала яши булып чыкты. Бу нигә болай килеп чыкканмы? Беренчедән, кешеләрне Чаллыярдагы кадрлар бүлеге җибәрә. Андагы тулай торакларда балаларга урын юк, ә Көмеш Аланда, янәсе, әлегә барыбер прописка-фәләнне тикшермиләр. Бер уйлаганда яхшы нияттер инде бу. Чөнки авылыннан баласын күтәреп чыгып киткән яки иреннән аерылган хатынга нинди дә булса торак табалар, ярдәм күрсәтәләр. Ләкин андагы хөрмәтле кадровикларның монда килеп караганнары юк бит. Икенчедән, кискен төстә әйтелде: бу тирәләрдә яшәүчеләрне әлегә эшкә алырга ярамый. Эшче куллар якындагы шәһәрләргә китеп беткән, авылда эшләргә кеше җитми. Бу да дөрес. Димәк, бердәнбер юл кала: яңа төзелешкә килергә теләүчеләрне читтән туплау. Монда инде, хөрмәтле Фазыл абый, сайланырга, бигрәк тә ерак-ераклардан килгән кешеләрне кире борып җибәрергә мөмкинлек аз... Хәер, ерак җирләрдән китүчеләр дә авылларын калдырып китәләр бит.

Нишләргә?

Кичекмәстән балалар бакчасы оештыруны кайгыртырга. Моның өчен Чаллыярдан алып килгән берничә вагонны аерып куярга кирәк булыр.

Хатыннар белән шул хакта сөйләшкән идем... Чүт күтәреп алмадылар. Менә бит ничек! Эшлибез, Гаяр, җимертеп эшлибез, диләр.

Әйтүен әйттем, телефоннан шалтыратып, Фазыл Артышевичның көнкүреш мәсьәләләре буенча урынбасары белән сөйләшкәч тә...

Уйладым-уйладым да тагын хатыннар янына бардым. Менә шулай, кызлар, бакча оештырып булмый икән ләбаса, дим... Күрсәгез икән аларның кыяфәтен! Ник әйткәнемә үкендем! Мин әйтәм, ул менә шундыйшундый нәрсәләргә терәлә дим... Һәм... шул ук минутта башыма сукты. Ни дә эшләп булмый, сүксәләр сүгәрләр: әлегә хатыннар арасыннан бала карарга яратучы берәвен сайлап алырга, ә башкалары тыныч күңел белән эшли бирсеннәр.

Икенче көнне үк вагоннарны чирәмлерәк җиргә күчереп куйдык һәм, рәсмиләштерелмәгән булса да, Көмеш Аланда беренче балалар бакчасы эшли башлады!

13 июнь, Көмеш Алан.

Бригадаларны яңабаштан оештырдык. Звеноларны барладык, яңа җитәкчеләр билгеләдек. Беренче монтажчылар бригадасын Саша Кислов, икенчене Зөлфәт Зәйнуллин, өченчесен — штукатурчы-буяучыларны Гөлфирә Шәйхетдинова җитәкләде.

Мәктәп бинасына панельләр килми. Торак йортларга килгәннәрнең дә очы-тәртибе юк. Кичә дүрт машинага төяп гамәлгә ярамаслык санузеллар җибәргәннәр. Кире бордым. Бу мәсьәләне төзү-монтаж идарәсендә

хәл итмиләр. Чаллыярга барып Фазыл Артышевич янына керергә, нинди дә булса бер юлын табарга кирәк булыр моның.

Кичә коммунистларны һәм комсомолларны тагын бер кат барладык. Коммунистлар барысы да исәптә икән. Моңа чик куярга, бер-ике көннән комсомолларның җыелышын уздырырга, комсорг сайларга, яшь төзүчеләр белән эшне җанландырып җибәрергә булдык.

15 июнь, Көмеш Алан

Иртүк яңгыр сибәли башлады. Салмак кына, җайлап кына җирне юешләтә дә юешләтә. Мондагы эшләрне бераз көйгә салгач, җайлап җибәргәч тә Чаллыярга кузгалдык. Һәм... Көмеш Аланнан өч чакрымга якын җирне, ягъни олы юлга кадәр араны ике сәгать чыктык. Бу юлсызлык безнең эшләрнең бугазына төер булып тыгылыр ахрысы. Узган ел да, бигрәк тә язын, юлсызлыктан интеккәннәр: детальләр төялгән машиналар, килеп җитә алмыйча, кире борылып-борылып киткәннәр. Бетон юл салучылар ярыйсы гына эшли үзләре, ләкин ике арада тагын өч мең метр җир ята — күтәрәсе, ныгытасы, тыгызлыйсы һәм бетон түшисе бар.

Чаллыярга төшке аш вакыты узгач кына барып җиттек. Юл уңаеннан ук Фазыл Артышевич янына кердем. Кәефсезрәк чагы икән... Соңыннан ишеттем: берләшмә җитәкчесе Дикопольцев белән бәрелешкәннәр дип. Үзеннән сорап булмый, кирәк булса әйтер иде. Әйтмәде.

Идарә җитәкчесе минем көтмәгәндә генә Көмеш Аланга китеп баруымны дөрес аңлап бетермәгән.

— Син инде, Сафаров, яңа төзелештә шауларга, монда ирешә алмаганга анда ирешергә уйлагансың. Белмим, барып чыгармы икән? — ди.

Кайберәүләрнең шулай уйлавы бар, әлбәттә. Ләкин бит очраган бер кешенең соравына үзеннең күңелендәгеләрне аңлатып тора алмыйсың.

Эре панельләр ясаучы завод директоры белән безгә җибәрелергә тиешле детальләрне озату графигын килештек. Айбулатов графикны раслады. Транспортчылар гына сынатмасын. Мәктәпне беренче сентябрьгә өлгертеп, Октябрь бәйрәменә кимендә ике йортны эчтән җиһазлауга керешербез дип уйлыйм...

Көндәлекләргә язма шушы урында өзелгән, туктап калган... «Бүген бишенче август, димәк, аз да түгел, күп тә түгел, ике айга якын вакыт узган»,— дип уйлап куйды Гаяр, дәфтәрен бер читкәрәк куеп.

Ике ай гомер... Югыйсә нибары алтмыш көн һәм төн узган, ләкин шул вакыт эчендә байтак кына вакыйгалар булды, ярыйсы гына хәлләр кичерелде.

## 2

Гаяр ул көнне Чаллыярдагы эшләрен соң бетерде. Идарәдә булды, андагылар белән сөйләште, бүлмәсенә кереп, элекке кәгазьләрен тәртипкә китерде, тапшырды. Аннары бүлекләрдә Көмеш Аландагы участокның бетмәс-төкәнмәс мәшәкатьләрен кайгыртты. Бүлек җитәкчеләренең артык исе китмәде, чөнки алар арасында «Участокны үзенә бер мөстәкыйль идарә итеп үстерәләр, аның җитәкчесе Сафаров булачак», дигән сүзләр колактан-колакка йөри башлаган икән. Турыдан-туры килеп, шул хакта сораучылар да булды, хәтта Көмеш Аланга күчәргә теләк белдерүчеләр дә табылды. Техник инспекциядә берничә ел эшләп, инженерлык дәрәҗәсенә ярыйсы гына күнегеп өлгергән Андрей Волгин хәтта Сафаровтан үзе белән алып китүне үк таләп итә башлады.

— Гаяр,— диде ул,— әгәр дә син кайчандыр бер бригадада үзең белән бергә «Лаеш шулпасы» эчкән иптәшеңне дә алмыйсың икән, белмим, кемнәрне генә туплarsың анда. Ал мине, үкенмәссең...

Андрей ышанычлы егет иде. Чаллыяр төзелеше башланган көннәрдә комсомол путевкалары белән килде, армиядән кайтышлый турыдан-туры юл тотуы икән. Сәфәров белән бик күп юлларны бергә узды, институт бетерде. Нигә алмаска аны?

Алырга булды Гаяр. Әлегә звено җитәкчесе булып башлыйсың, аннары күз күрер, диде. Килештеләр.

Тагын ике тапкыр комбинатка, Айбулатов янына барырга туры килде. Шулай итеп, ул өенә кайтырга чыкканда, җәйге Чаллыярның урамнарында инде неон утлары кабынган иде.

Көндезге яңгырдан соң бөтен тирә-якны саф һава ураган, сулыш алуы җиңел, җан рәхәтләнә.

Иң күңеллесе — Чаллыярда хәл ителергә тиешле күп нәрсәләр уңай якка каралды. Берләшмә җитәкчеләре, комбинат һәм төзү-монтаж идарәсе вәкилләре Көмеш Аландагы төзелешнең мөһимлеген аңлыйлар, аны инде үзләренең бер өлеше, гаиләдәге тулы хокуклы бер әгъза буларак таный башлаган иделәр.

Гаяр комбинат идарәсе ягыннан берләшмә бинасы янына таба күтәрелде. Менә бик күпне күргән, Чаллыяр башланганда беренчеләрдән салынган кунакханә. Ресторанның ачык тәрәзәләреннән барабан гөпелдәткән, җиз тәлинкәләрне бәреп чыңлаткан авазлар атылып-атылып чыга да, кичке тынлыкны ярып, борынгы елга буйлап еракларга тарала.

Гаяр үзе яши торган урамга килеп чыкты. Менә Чаллыярдагы иң беренче зур кибет, менә эре панельле, биш катлы, хәзер инде борынгы заманнардан килгән сыман моңаеп утыручы иң беренче йорт. Әнә тегендәрәк, Чаллыярның барлык тантаналы бәйрәмнәренең шаһите, төзүчеләр горурланып атаган «Кызыл мәйдан». Аның каршындагы панно — Мактау тактасында алдынгы кешеләрнең рәсемнәре. Төзүчеләр каскасы кигән яки рәсемгә төшерү уңае белән киенгән-ясанган, галстуклар таккан шат һәм көләч йөзләр узып баручыларга карый...

Урамның икенче ягына чыгып, хәзергә кадәр биредә сакланып калган, пыяла тәрәзәләренең кайбер күзләрен катыргы белән каплаган павильон яныннан узып, үзләренең йортына таба атлый башлагач та Гаяр, нишләптер, борчыла, дулкынлана башлады.

«Нәрсәгә булыр икән бу?» — дип уйлады ул һәм... соңгы вакыттагы күп кенә нәрсәләрне Көмеш Аландагы бетмәс-төкәнмәс эшләр-мәшәкатьләр белән онытыла язган вакыйгаларны барысын берьюлы исенә төшерде.

Ашыгыбрак атлады Гаяр. Үзләренең өен каплап торган биш катлы йортны, бер-берсенә ике тамчы кебек охшаш биналарны узды һәм үз куллары белән зәңгәрсу төскә буяган балконга караш ташлады.

Бүлмәдә ут яна, ләкин анда элеккечә яшькелт төстәге люстра түгел, ә яп-якты бер лампочка гына асылынып тора. Житмәсә, тәрәзәдәге пәрдәләр дә юк, шуңа күрә әлеге сыңар лампочкадан төшкән яктылык аеруча бөркелеп күренә иде.

Гаяр ишегалды ягыннан әйләнеп, үзләренең турына килде. Анда, ишегалдының урта бер җирендәге эскәмияләрдә, гадәттәгечә яшь-кыркын тупланган, кулларында көйсез гитара зеңгелди. Бер-ике яшүсмернең танылган җырчыга охшатыбрак, ни татарча, ни русча дигәндәй, үзләре дә аңламаган авазлар чыгарып җырларга тырышканы ишетелә иде.

Гаяр ишек төбендәге эскәмиядә кара-каршы утырган карчыкларны иң соңгы мизгелдә генә абайлап алды.

— Исәнмесез! — диде ул. Чөнки авылдан килеп, шушы баскыч төбендәге эскәмияләргә чыгып утырудан бүтән барыр җирләре булмаган, шуңа күрә ни бар затлы киемнәрен — яулык-күлмәкләрен киеп чыккан өлкән яшьтәге апаларга дәшмичә узганы юк аның. «Әни дә алар янына чыгып утыра иде, мәрхүмә» дигән уй күңеленнән узды.

— Исәннәр әле, аллага шөкер...— диешкәннәре ишетелде.

Подъезд ишеген ача башлаган иде инде Гаяр, артыннан пышылдап әйтелгән, әмма бомба шартлагандай тәэсир иткән берничә сүз куып житте аны:

— Хатыным янына кайтам дип ашыга инде бу бичара...

Эсселе-суыклы булып китте. Берничә секундка ишекне ачкан килеш туктап калды Гаяр, эчке якка атларга да, тышка борылып чыгарга да белмәде. Шулай да ниндидер бер усал көч аны эчке якка ташлады. Ул үзләре яшәгән өченче катка ничек менеп житкәнен сизмичә дә калды. Артыннан куып житкән сүзләрдән түгел, ул сүзләргә салынган мәгънәнең чынлыгыннан курыкты Гаяр...

Бүлмә эче, тәрәзәдән күренгәнчә, ап-якты һәм шып-шыр иде! Аргы почмакта ниндидер әйберләр өелеп тора, өстенә япкан газеталар астыннан китаплар икәнлеге күренде. Ләкин алар гына шыксыз бүлмәгә жан бөркеми иде.

Гаяр бер адым артка чигенде, кием шкафына килеп сөялде.

Нәрсә? Ни хәл соң бу? Киткәннәр... Аңа бер сүз дә әйтмичә китеп барганнармы?..

Шулвакыт Карлыгач бүлмәсеннән тавыш ишетелде. Гаяр үз-үзен белештермичә диярлек алга атлады һәм бүлмә ишегенә йодрыгы белән төртте. Ишек ачылып та китте, аннары стенага тоткасы белән бәрелеп кире килә башлады.

Диванда утырган ике кыз сикерешеп тордылар.

Гаяр йөрәгенең шатланып сикергәнен ишетте.

Карлыгач иптәш кызы белән иде. Ләкин Гаяр бары тик Карлыгачның, аның шундый таныш, шундый якын, очлаебрак торган йөзен, үтәдән-үтә ап-аяз күзләрен генә күрде.

— Әти... Әти-еем!— диде кыз урыныннан кубып әтисенең күкрәгенә сыенды.— Әт-тиееем!

Гаяр кызын кочаклаган килеш бүлмәгә күз йөгертеп чыкты, биредә затлы сервант, стенадагы келәмнән кала башка нәрсәләр үз урынында иде.

Ата белән кыз шулай бер-берсенә сыенган килеш шактый басып тордылар. Күрше кызы кайчан, ничек чыгып киткәнен дә сизмәделәр.

Ниһаять, Гаяр кызының жилкәләреннән тотып арткарак этәрде, аның яшь тулы күзләренә карарга тырышты. Ләкин кыз күзләрен, ике битен учлары белән томалады.

Бераздан Гаяр, борылып, ал бүлмәгә чыкты, аягындагы туфлиләрен салды, курткасын идәнгә ташлады. Кабат кызы янына әйләнеп керде.

Карлыгач һаман да идән уртасында басып тора иде.

Ул Гаярга гади дә, бик-бик якын да, дөньядагы бар кешедән кадерле дә булып, бердәнбер ышанычлы кеше булып күренде.

Бер караганда кызының һәр хәрәкәте, буй-сыны, чәчләренең жилкәләренә таралып төшүе — һәммәсе, һәммәсе дә таныш, шул ук вакытта таныш та түгел кебек иде. Чынлап та, үсмерлек чандырлыгы чыкмаган, буе инеш буендагы талның бер жәйдә үскән, әлегә ныгып бетмәгән ботагы сыман нечкә генә гәүдәле кызның йөзендә ниндидер яңа төсмерләр бар иде инде.

Гаяр тагын кызы янына килде, хәлнең аянычлыгына карамыйча, бөтен күңелен биләп алган тойгылар белән аны үзенә тартып китерде, аркасыннан суккалап сөйде.

Аннары алар бушап калган бүлмәдә сөйләшмичә диярлек озак утырдылар.

Гаяр кызыннан бернәрсә дә сорамады, ә кызы шулай ук дәшмәде. Әллә үзенең күңелендәге яраны күзгатмыйм дипме, әллә тумыштан ук күңеленә табигать тарафыннан салынган хатын-кызларга хас сизгерлек белән әтисенең халәтен тоемладымы — ничек кенә булмасын, дәшмәде, кичәле-бүгенле булган вакыйгаларны күзгатмады, әтисе ванна әзерли башлаганчы, янындан бер генә минутка да китмәде...

Иң гаҗәбе шунда иде: Гаяр күңелендә нindидер җан әрнеткеч, мондый очракларда була торган ачы кичерешләрне тоймады. Билгеле, беренче минутларда аның күңелен моңарча кичермәгән нәрсәләр тырнап-тырнап үтте, ләкин бу хәл озакка бармады. Иртәме-соңмы бер булырга тиеш иде бит. Ләкин Гаяр үзен гаепле санамады. Ул хатыны мул тормыш белән яшәсен өчен барысын да эшләде. Әгәр инде Гаярның күңелендә «ничек кенә булса да кешеләрдән уздыру» теләге калкып чыкмаган икән, монда аны гаепләп булмый. Шундый холыклы булып туган, шундый сыйфатлар белән яши инде ул. Аның өчен шушындый тормыштан башкасы юк һәм ул аны бүтән төрлегә алыштырмый да.

Карлыгач — уңган кыз, әтисе ваннадан чыккан шәпкә мәтрүшкәле чәй өлгерткән, йомырка кыздырып куйган. Икәүләшеп кухня өстәле янына утырдылар. Гаяр бик тәмләп кенә чәй эчә башлаган иде, Карлыгач:

— Әти, ә, әти? Без инде синең белән бәхетсезләрме?— дип сораганын ишетеп, авызын кайнар чәйгә пешерә язды.

— Ничек, нигә алай уйлыйсың, кызым?

Сорауга каршы сорау бирсә дә, Гаярның күкрәгендә әллә нәрсә «дерт» итеп алды. Чынлап та, бәхетлеме-юкмы соң алар? Элек Гаяр бу хакта ничектер сирәк уйлана иде. Дөресрәге, бөтенләй диярлек уйламый иде. Чөнки ул үзен, үзе кебекләрне бәхетсез кешеләрдер дип башына да китерми иде.

...Гаяр сугыш беткән елны дөньяга килде. Сугыштан бер аягын калдырып кайткан әтисе гаиләнең иң олы таянычы иде. Гаяр һәм аның кебек авыл малайлары аш талымлый торганнардан түгел. Аларга нәрсә булса, шул ярады. Әниләре чөгендер яфраклары яки балтырган җыеп аш пешерсә, бәрәңге кумәче ясаса, берничә бөртек ярмасы йөзеп йөри торган аш пешерсә — шулай тиештер дип санарга күнеккән иде алар. Кием дигәндә дә әтиләреннән калганны таманлап тегеп бирсәләр, шул житкән иде.

Шулай үстеләр. Шукланып кына бакчасын да бастылар, күрше-күлән тәрәзәсенә шыгылдавыгын да куйдылар. Тотсалар — «кыен» ашадылар, тотмасалар — шатландылар. Юк кына сәбәптән кайчак үзара сугышып та алгаладылар. Колхоз эшеннән дә йөз чөермәделәр, өмәләрдән калмыйча авылдашларына утын китерделәр, кистеләр... Ләкин «без бәхетсез» дигән уй берсенең дә башына кереп карамады. Аларга шушы тормыш бәхетле, шушы кешеләр — ана сөте белән кергән телдә сөйләшүче авылдашлар, күршедәге чувашлар, урманның теге ягындагы урыслар, алардан да тегендәрәк урнашкан мукшылар белән сабан туйларындагы бәйге-ярышлар, көрәш-алышлардан да бүтән тормыш, шуннан гайре башкача бәхет юк иде.

Әгәр инде аларның авызына шоколад-кәнфит, мороженое яки татлы лимонад, кыздырган яки кыздырмаган колбаса, шәһәрчә ашлар эләкмәгән икән, аларның нинди гаебе бар? Аның каравы шәһәр малайларының кайсысы мичкә тәгәрәткән яки атлар саклаганда учак көлендә пешкән бәрәңгене, кычыткан һәм алабута, балтырган һәм чөгендер яфрагыннан пешерелгән, катык катып ашасаң, кикертеп тә җибәрә торган ашларны туйганчы ашавы белән мактана ала?

Хәер, вакыты җиткәч тә аның кебекләрдән нәрсә ашап үстең, нәрсә киеп йөрдең дип сорап тормадылар. Кирәк булгач, буй-сыннарындагы ташып торган көчне күргәч — алдылар да киттеләр, соры шинель киделәр, кулга автоматын да, ялтырап торган штык-ханҗәрен дә, күкләргә ашкан ракеталарын да, кузгалса — бөтен киртәләрне җимереп бара торган танкларын да ышанып тапшырдылар.

Аннары автогигант кору, Чаллыяр каласын салу башланды... Андагы шау-шу авазлары илләрне үтеп-үтеп китте, төзелешнең зурлыгы исләрне китәрде, океан артындагыларның мин-минлеген кузгатты. Әмма, Гаяр кебек үк, авылда бәрәңге ашап үскән егетләр килделәр дә, Ватан кушуын тыңлап, барлык кыенлыкларны җиңеп чыктылар.

Карлыгач әтисеннән җавап көтә. Нигә сорадым, дип уйламаса да, өйләрендә булган хәлнең четереклелеген чамалый иде замана кызы. Ул инде соңгы вакытларда әнисенең «Эдик абый»сыннан башкаларга түбәнсетеп каравын, тора-бара әтисе белән әнисенең арасында беркайчан да төзәлмәслек упкын хасил булачагын да яхшы аңлаган иде. Дөрес, әтисе аның турында «мондый нәрсәләрне аңлый торгандыр» дип уйларга да кыймыйдыр. Шулай да...

— Әлбәттә, кызым, әниеңнең безне шундый хәлдә калдырып китүе яхшы нәрсә түгел. Ләкин моны бәхетсезлек дип санарга ашыкмыйк. Бәхет ул, кызым, мондый ваклыклардан югарырак төшенчә. Тик без, бүгенге хәлгә карап кына, дөньяда безнең өчен кызык бетте дип, башны түбән иеп йөрергә тиеш түгел. Безнең бит бер тамчы да гаебебез юк аның алдында... Ләкин без аны гына гаепләп яшәмәскә тиешбез, кызым. Монда минем дә гаеп бардыр. Чөнки аның шушы тайгак юлга кереп барганын сизмәдек түгел, сиздек. Әмма шушы юлдан тартып алырга көчебез җитмәде...

Карлыгач озак кына дәшмичә утырды. Ул әтисеннән ишеткән сүзләрне үз аңы аша уздыра иде бугай.

Гаяр урыныннан торып, чәй яңарта башлады.

— Ә син, син, әти, тагын... тагын өйләнерсеңме соң?— диде Карлыгач ишетелер-ишетелмәс кенә, үзенә хас булмаган сүлпән тавыш белән, тагын бераздан өстәп куйды.— Анда, анда бит синең яшьлек мәхәббәтең... Гөлфирә апа.

Нурлыбикә сүзләре иде болар! Димәк, үзе китү генә җитмәгән, Карлыгачның күңелен дә агуларга тырышкан.

Гаяр чәйнекнең үз урынында нык утыруын тагын бер кат тикшереп тотып карады, кулындагы тастымалын кая куярга белмәгән кеше кебек тирә-ягына караштырып алды, аннары гына килеп кызының аркасына кулын куйды. Кыз исә күзен дә йоммыйча җавап көтә иде.

Башта ул өздереп кенә: «Юк, аның кайгысы түгел әле»,— дип әйтмәкче булып авызын ача башлаган иде, ләкин үзендә нindидер бер икеләнү тойды.

— Беләсеңме, кызым, бик авыр сорау бирдең син миңа. Алдан ук кырт кисеп: «Әйе» яки «юк» дип әйтәсем килми. Мин — әле кырыкка да җитмәгән кеше. Бераздан үзең дә аңларсың — күпме тырышсам да, мин сиңа сердәш була алмам. Чөнки тормыш шундый нәрсә инде ул. Күрәсең бит әнә, сыерчыклар — үз эше, күгәрченнәр үз эше белән үз эше, күгәрченнәр үз эше белән сайраша-гөрелдәшә, без — кешеләр дә шулар кебек. Безгә үзебезнең иш — сердәшебез кирәк... Мин Гөлфирә апаңны яшь чагымда бик нык яратып йөрдем, яшермим. Минем аңа булган хисләрем яшьлегемдә ничек саф килеш яралган булса, шул килеш җавапсыз калды да. Әйе, Гөлфирә апаң анда. Аның да синең шикелле үк кызы бар. Ләкин минем әлегә кадәр аның белән, Гөлфирә апаң белән, андый нәрсәләр турында сөйләшкәнем юк. Дөрес, мин аны күргән саен күңелемдә ниндидер хисләрнең исәнлеген сизәм. Ләкин бит... бу гына бик аз бит әле, кызым. Минемчә, без әле синең белән бу хакта уйлашырбыз, яме?

Карлыгач әтисенең тиң күреп сөйләшүеннәнме, әллә ишеткән җавапның дөреслеген тоепмы, утырган җиреннән әтисенә сыенды.

Ул төнне ата белән кыз бик озак сөйләштеләр. Бүгенгеләрен генә түгел, киләчәк тормышлары турында да хыялландылар. Гаяр инде йокыга китә башлаган иде, Карлыгач тагы:

— Әти, беләсеңме, әтием, әйдә син мине дә Көмеш Аланга алып кит. Хәзер барыбер җәй көне. Пионерлар лагерена бармасам да үкенмим, анда әллә ничә тапкыр булганым бар. Алып барасыңмы, әтием, ә? Минем дә бит яңа төзелешне күрәсем, синең ничек эшләгәнеңне карап торасым килә.

— Мин каршы түгел, барыбер авылга — абыйларга кайтасың бар. Шулай да, кызым, әйдәле, без бу мәсьәләне иртәгә калдырыйк. Кем әйтмешли, кичке уй иртәнгә ярамый,— диде дә күзләрен түшәмдәге яктылык утрауларына текәп тынып калды.

Чынлап та, кичтән уйлаган иртәнгә түгел, шушы төнгә дә ярамады. Дүртләр тирәсендә буылып-буылып телефон шалтырый башлады. Күптән түгел генә уйларыннан арынып йокыга киткән Гаяр торыргамы-юкмы дигәндәй икеләнебрәк ятты. Аннары юрганын читкә атып җибәрде, сикереп торды да трубканы алды.

— Әйе, тыңлыйм...

Телефон трубкасындагы тавыш карлыгып, калтыраныбрак килә иде.

— Сәфәров... Гаяр...

Гаяр таныды: икенче бригада җитәкчесе, парторг Зөлфәт Зәйнуллин иде бу.

— Тыңлыйм, Зөлфәт.

— Гаяр, тизрәк... Кил, давай... Бездә... «ЧП», бәхетсезлек булып куйды. Кил тизрәк...

Сәфәровның бөтен тәне бер йодрык шикелле йомарланып килде. Ул трубкадагы шытырдауларны көтеп уздырды да:

— Зөлфәт, Зөлфәт дим, нәрсә... нәрсә булды? Нинди бәхетсезлек? Ачыграк әйтәласыңмы?— дип кычкыра ук башлады.

— Ширәмәт клубына киногa барган идек. Вахта автобусы белән. Ике сериядән соң танцыга калдык. Кайтканда... юл тайгак бит... Көмеш Аланга җитәрәк... туры юлдан кайтабыз дип кергән идек... текә тау артындагы Коры чокырга...

Сәфәров нәрсә булганын аңлап, Коры чокырның юлга таба ишелеп кергән җирен күз алдына китерде. Әгәр дә машина бөтенләе белән төшеп киткән булса... Тирәнлеге унбиш метрлап бар бугай...

— Имгәнүчеләр, һәлак... булучылар юкмы?— диде ул тәненә салкын чирканчыклары бәреп чыкканны сизеп.

— Үлүчеләр... әлегә юк, Гаяр. Имгәнүчеләр шактый. Каты имгәнүчеләре икәү... Ширәмәткә... больницага озаттык...

Шулвакыт телефон трубкасында кыска-кыска гудоклар гына ишетелә башлады. Берничә мәртәбә шалтыратырга тырышып караса да, Сәфәров берәүгә дә чыга алмады — трубкада кыска «пип-пип-пип»тән башка нәрсә юк иде.

Карлыгач нәрсә булганын сорамады, чөнки әтисенең сөйләшүеннән үк барысын да аңлаган иде.

— Менә шулай, кызым. Хәзергә син дус кызың белән торып тор, яме. Бу хәлләрдән бераз арынуга, мин сине кайтып алырмын,— диде һәм шунда гына Карлыгачны Көмеш Аланга алып китәргә ризалык бирүен сизде.

Комбинатның баш диспетчерлыгы янында Сәфәровны автобус көтеп тора иде инде. Сәфәров машинаны озатырга чыккан баш диспетчерга таба борылып: «Айбулатов беләме?»— дип кенә сорады. Тегесе: «Белә», — дип баш какты.

Юлда барганда Сәфәров ләм-мим бер сүз сөйләшмәде. Иртәнге табигать, салкынча һава, кичәге яңгырдан соң аерата яшелләнеп киткән урман, җиләк-җимеш бакчалары, Түбәнярның нефть химиясе корылмалары, Зәй күпере тирәсендәге камышлар да аның игътибарын били алмады. Сәфәров өчен әллә бар алар, әллә юк иде.

Көмеш Аланга якынлашкан саен, уйлар өере ерагая барды. Күңелдә: «Ничек булган, кемнәр... кемнәр бәхетсезлеккә юлыкты икән?»— дигән уй гына утырып калды.

Ширәмәт тавын төшкәндә, үзеннән зур тавышы белән автобустагыларны сискәндереп, «Волга» кычкыртып узды. Сәфәров машина тавышын-

нан ук таныды. «Айбулатов»— дигән уй күңелдәге борчуларны тагы да көчәйтебрәк җибәрде.

Больница ишеге төбендә бер төркем кеше җыелып тора, Айбулатов инде эчкә кереп киткән иде.

Сәфәров башта Зөлфәт, аннары башкалар белән исәнләште. Арада куллары бинт белән бәйләп муеннарына аскан һәм башларын марля белән ураганнары да бар иде. Сәфәров алар алдында үзен гаепле сыман тойды, больницага таба ымлады да:

— Кемнәр?.. Ни хәлдә?— диде.

Төркемдәгеләр дәшмәде. Тынлык озаккарак сузыла башлагач, Зөлфәт Зәйнуллин алга чыгыбрак әйтте:

— Гөл... Гөлфирә белән Варя Колобовадан башкалары, баярак кына белештек, куркыныч түгел. Хәзер Гөлфирәгә кан өстиләр. Ә менә Варяга ярый торган кан безнең арадагыларда юк икән. Аэропортка киттеләр китүен, Казаннан җибәрергә тиешләр...

— Варяга ничәнче группа кирәк?

— Уңай резуслы беренче группа,— диде берьюлы бернечә кеше. Сәфәровтагы канның нәкъ шушы группа икәнлеген белеп тә, ул аны бирмәс дигән шикеллерәк килеп чыкты бу.

Сәфәров, аны-моны әйтмичә генә төркем уртасын ярып чыкты да, больница болдырына менеп китте.

## 3

...Март ае, имеш. Гөлфирә кызлар белән Калатау башында йөри. Янәшәсендә язгы каникул вакытында гына түгел, бөтенләйгә әнисе янына килгән Таңсылу күлә. Шундый рәхәт, тынга шундый иркен, имеш. Зәңгәр күк гөмбәзенә аксыл тасма юллар сузучы очкычлар гөрелтесе ишетелә. Гөлфирә бик күптәннән инде әнә шушы аксыл тасмаларны зәңгәр күкнең иксез-чиксез киңлегендәге чып-чын басмалар итеп күз алдына китерә. «Эх!— дип уйлый ул.— Менеп китәсе иде кулларны пар канат шикелле як-якка җәеп шушы басма буйлап зәңгәр күккә таба»...

Җир йөзе язгы нурда коена. Дөрес, Көмеш Аланның теге ягындагы басуларда әле кар ята. Ә монда, Калатауның кояш нурлары җылытып карның юка катлавын күптән инде күкләргә очырган җирендә, яп-яшь үләннәр борын төртеп маташа. Алар да күк зәңгәрлегенә таба күтәрелмәкче...

Гөлфирә, хатын-кызларча, ике тезен берьякка таба авыштырыбрак баскан урынында чүгәли дә эштә чыныккан, кытыршыланган куллары белән шушы яңа гына борын төрткән үләннәрне сыйпап-сыйпап карый, имеш. Алар шундый йомшак, шундый матур... Гөлфирәнең ирексездән яланаяк шулар өстеннән йөгереп китәсе килә башлый...

Ул да түгел, Гөлфирәнең беренче тапкыр Чаллыярга Ташкент якларыннан кайткан чагы, имеш. Таңсылуын больницага салганнар, ул кызы янына барган, ләкин аны эчке якка кертмиләр, шуңа күрә Гөлфирә үзенең йөрәк парәсен тәрәзә аша күрергә йөри, имеш. Ул кемнәрдер күтәреп нигез ташына сөяп куйган ватык эскәмиягә басып күтәрелмәкче була, тик әле аягы таеп, әле ватык эскәмиянең янтаюыннан җиргә сикереп-сикереп төшә. Ә теге яктагы Таңсылу аның шулай кинәт кенә югалып-югалып алуыннан кызык табып, качышлы уйный диптер инде, көлә дә көлә,имеш. Гөлфирә кызының көлгәнен күреп чынлап та уйнарга керешә. Бер күтәрелә, бер югала, күзләрен зур ачып, кашларын әле генә куак астыннан чыккан куркак куян шикелле сикертеп, я булмаса телен чыгарып кыланчыклана. Әнисеннән күрмәкче, Таңсылу да уйнарга керешә. Икесенә дә рәхәт, икесе дә дөньяларын онытканнар...

Шулвакыт каяндыр килеп чыккан бүрек кадәрле генә болыттан яңгыр сибәли башлый. Яңгыр тамчылары чынбарлыкның үзе булып Таңсылуның тәрәзәсенә барып-барып ябышалар һәм зигзагсыман әле тегендә, әле монда таба тәгәрәшәләр. Шул сызыклар арасыннан Таңсылуның «Сау бул, әнием» дип изәгән бәләкәй бармаклары күренеп китә, аның артында ак халатлы гәүдә барлыкка килә. Врач яки шәфкать туташы керде бугай, дип уйлый Гөлфирә, кинәт кенә артына борыла һәм нәрсәгәдер абынгандай егылып китә башлый...

Гөлфирә ишек ачылган авазлан уянып китте һәм әле генә күргән төшеннән аерылырга курыккан кебек күзләрен ачарга, тирә-юньдәгеләргә карарга кыймыйча ята. Ләкин янәшә генә сөйләшкән тавышлар аны төшендәге матурлыктан аерып чынбарлыкка кайтардылар.

— Без озакка түгел, зинһар өчен, борчылмагыз. Өч-дүрт минут сөйләшәбез дә китәбез, юл кешеләре бит без,— ди тамагына салкын тиюдән бераз карлыккан ир-ат тавышы.

Гөлфирә бу тавышның иясен шул мизгелдә үк таныды: «Гаяр!»— дигән уй ярылып-ялтырап узды.

— Соң бит әле авыру йокысыннан да уянмаган,— ди шушы больницада шәфкать туташы булып пенсиягә чыккан, ләкин няня вазифасын үз өстенә алган керәшен хатыны Лаксандра — Санук апа. Ләкин тегеләр бирешергә, палата янына килеп җиткәч кенә борылып китәргә теләмиләр иде.

— Ярый инде, без бит көн аралаш диярлек килә-килә үз кешеләр булып беттек, Санук апа,— дигән булды арадан тагын берсе.

Гөлфирә, аның үзен күрмәсә дә, Зөлфәтне анык таныды һәм күзләрен ачып:

— Керсеннәр инде, мин аларны озак тотмам,Санук апа,— дип үтенде.— Барыбер палатада миннән башка кеше юк, бакчада йөриләр...

— Шулаен шулай да бит, Гөлфирә, баш врач күрсә — ни әйтер?— Аннары, бераз уйлап торгач:— Ярый инде алайса, эләксә әләгер, керегез берегез,— диде Санук апа кин күңеллелек күрсәтеп.— Менә... начальнигыгыз керсен...

Бу ярыйсы гына үзсүзле, ләкин асылында киң күңелле, больницага ятарга дучар булучыларның һәркайсына игелектән башканы күрсәтмәгән керәшен хатынын барыбер җиңеп булмас, ахры, дигәндәй, Сәфәров белән Зөлфәт бер-берсенә карашып алдылар.

— Син кер, Гаяр... мин машина янында көтеп торырмын, мондагы кырыс тәртипне бөтенләй үк җиңеп булмас, ахрысы,— диде Зөлфәт, бүлмә бусагасына аркылы баскан Санук апаның җилкәсе аша үрелеп.— Кер, кер...

Гөлфирә ак җәймә киертелгән одеалын үзенең ачылыбрак торган күкрәгенә таба тартты, аяк астына ук китерде һәм карават янына ук килеп баскан Сәфәровка таба күтәрелеп карады.

Бүлмәдә тынлык урнашты. Гаярның карашы Гөлфирәнең куллары, күкрәге өстеннән йөгертеп үтте дә, кысылыбрак, ләкин ниндидер әйтелмәгән якынлык иңдереп караган күзләр белән очрашкач, караңгы төндә атлап барганда таш диварга төртелгән кеше шикелле, туктап калды, аннары ике якка да ачып куелган тәрәзәдән урамга сирпелде.

Соңгы ике атна эчендә берничә тапкыр үлем белән яшәү арасындагы чик сызыгына басып, теге якка атларгамы, әллә бу якта калыргамы дигән икеләнүле кичергәннәрне узган Гөлфирәнең болай да агарыбрак калган йөзе тагын да бүзләнә төште. Дөрес, ул инде хәзер олы-олы адымнар белән бөтәю ягына таба бара иде, әмма кискен минутта әлеге кичерешләр үзләрен сиздермичә калмадылар.

Ачык тәрәзәдән томырылып диярлек бер-бер артлы ике ак күбәләк килеп керделәр дә бүлмә эченнән берничә әйләнгәч тә чыгу ягына таба омтылдылар, тик ашкынулары аркасындамы, ачык тәрәзәгә түгел,

икенчесенең кояш яктысында көмешләнгән пыяласына бәрелделәр, тыпырчына-фырылдый башладылар.

Сәфәровның дәшмичә торуыннан уңайсызлана башлаган Гөлфирә, икесенә дә бер төслерәк уйлар килгәнне тойган һәм шулардан качарга җыенгандай, тынлыкны бозып:

— Нихәлләрсез анда, Гаяр, эшләр барамы? Мәктәпне бетерәсезме әле?— дип куйды, ике карават арасындагы тумбочка янәшәсенә куелган урындыкка күрсәтеп:— Минә бирегә утыр, Га-а-яр...— диде көтмәгәндә тотлыгып.

Авыртулардан интегеп, Гаяр алдында бераз аптырабрак калган килеш акбүз тышлы мендәр өстендә ятучы, бу минутларда гадилекнең үзенә тиңләшердәй Гөлфирә, кайчандыр дөньяда тормыш булса бары тик шушы Гөлфирәне яратуга гына корылган дип уйлаган, шушы яратуы аркасында күпме газаплар кичергән, аннары инде «тиң итмәде» дип онытырга тырышып-тырышып та оныта алмаган, ләкин барыбер үзенең күңелендәгене сиздермәскә күнеккән Гаяр бу юлы тыелып кала алмады. Ул бераз гына аптыраште калган, ләкин үзенең шушы аптырашта калуы белән дә бик якын, искиткеч якын һәм кадерле күренгән, үзенең тормышында күпме борчуларның аерылмас бер өлеше булып яшәгән Гөлфирәнең күзләрендә, аптыраулы йөзендә ничәмә-ничә еллардан бирле үзе күрергә, чамаларга теләгән җавап төсмерләрен күрде. Күрде һәм шушы минуттагы бөтен киеренкелеге белән аңлады: әгәр дә хәзерге мизгелдә шушы киребеткән Гөлфирәнең күкрәгенә башыңны куеп, аның кайнар сулышын үзеңнеке белән бергә кушып, тыннар беткәнче үбешмәсәң, әлегә чагылып-чагылып кына киткән якынлык, тумыштан диярлек бер-береңне белеп, бер-береңнең характер үзенчәлекләрен күреп-сизеп, ничәмә-ничә еллар буена битараф сыманнарга саналышып йөрү аркасында туган ялгышлар тагын бер тапкыр кабатлану гына түгел, бәлки тагын да катлауланыбрак, тискәреләнебрәк, буталчыкланыбрак китәчәк иде.

Әле больницага килгәндә дә үзе өчен бик күптәннән югалганга санап йөргән һәм үзе дә аңлап бетермәстән Чаллыярда, аннары инде биредә очрашканнан соң Гөлфирәгә ярыйсы гына борчулар тудыргалаган Гаярның уенда яшьлек мәхәббәте белән аңлашыр мизгел килер дигән өмет кисәге дә юк иде. Хәер, мәхәббәт ул моңарчы берәүне дә: «Шушы көннең шушы сәгатьләрендә һәм минутларында киләм, көтеп, хәстәрләнеп тор»,— дип кисәтмәгәндер...

Гаяр, күңелендәге хисләрнең дулкынына каршы тора алмыйча, башын Гөлфирәнең күкрәгенә салды.

Гөлфирә дә шушы мизгелләрнең кадерен белеп кенә, хәленең кискенләгән бөтенләй диярлек онытып, әлеге горур башны ныгып өлгермәгән кулы белән сыйпап-сыйпап алды, аннары үзенең күкрәгенә таба кысты, күзләреннән берәмләп кенә чыккан борчак-борчак яшь бөртекләренең бит алмасы буйлап тәгәрәгәнлеген дә тоймады...

— Гаяр... Гаяр, кадерлем... Кичер... булдыра алсаң. Мин... мин... ул чакларда да сине ярата идем... Ләкин әллә ничек, үз итеп, якын итеп ярата идем... Сине беркая да китмәссең, минем кылануларыма карамассың, артымнан... йөрерсең дигән идем... Синең җаныңа тиим, сынап-сынап карыйм дия идем... Тик... әнә ничек кенә килеп чыкты бит...

Гаяр әлеге сүзләрне ишетте дә, ишетмәде дә. Ишетте — чөнки ул бу сүзләрне бик күптәннән көтә иде, Гөлфирә авызыннан шушы сүзләрне ишетер өчен ул яшьлектә калган ерак еллар өчен җанын фида кылырга да әзер иде. Ишетмәде — чөнки бу сүзләр ике йөрәк, ике янар тауның актарылган чагында яңгырадылар.

Гаяр бу минутларда нинди дә булса сүз әйтерлек хәлдә түгел иде. Ул шуңа дәшмәде. Гөлфирәнең кабарынкы тыгыз күкрәкләренә ныграк кысыла гына төште.

Житез канатлы күбәләкләр, ниһаять, ачык калган тәрәзәгә турылап килделәр дә тышкы якка чыгып, шатлыкларыннан тагын да югарырак очыш үрнәкләре күрсәтеп кояшка таба очып киттеләр.

## Бишенче бүлек

### 1

Җәйге көннәр тәмам кызды. Бүлмәдә эшләү үзе бер җәфага әверелде. Кама яры да ерак түгел, тәрәзәләр шар ачык, барыбер эссе. Гомер-гомергә Чаллыярны җиде җил үзәне дип йөртәләр иде, тик быел моның дөрес үк булмавы расланды, җилнең әсәре дә күренмәде. Дөрес, күз күреме җиткән киңлектәге олы елга өстендә җил югында да вак-вак кына дулкыннар әрле-бирле тәгәрәшәләр.

Айбулатов өстәлендә яткан кәгазьләр арасыннан урта бер җиргәрәк алып куелган бер биткә һәм аның янындагы гадәти дәфтәр битенә эреле-ваклы хәрефләр белән язылган юлларга карап-карап алды да, үзе дә сизмәстән көрсенеп куйды.

Бу минутларда Фазыл Артышевич башында бөтерелгән уйларны төгәл бер тәртипкә китерә алмыйчарак интегә иде.

— Кем эше бу? Кемнең кулы барган мондый шикаятьне язарга?— диде Айбулатов үзенә-үзе тамак төбеннән чыккан тоныграк, ачуы бик нык чыккан чакларда гына сөйләшә торган тавышы белән.— Хәер, хикмәт кем эше булудамыни? Кешеләр имгәндеме? Имгәнде. Шулай икән, Сәфәровның гаебе бармы? Әллә бу очракта аның участок мәшәкатьләре белән Чаллыярга китүе аклана торгандыр? Ул участоктагы барлык кеше артыннан йөри алмый, балалар бакчасы түгел монда...

Айбулатов шикаятьтә язылганнарны йөгереп кенә тагын бер кат укып чыкты...

«Сәфәров — карьерист, иң кыен чакларда үзенә дан китергән, күп еллар буена шаулаткан бригадасын ташлап, идарәдәге җылы урынга кереп оялады. Ә хәзер, яңа төзелешнең каймагын ялап, автогигант төзелешендә үзенә тәтемәгән герой исемен алырга килде. Шуңа күрә аның бирелә кешеләрдә гаме юк. Үз хатынын ташлап, куып җибәргән кешедә нишләп башкалар гаме булсын? Хәер, хатын юк дип аптырамый ла ул. Монда килгәч тә, бәхетсезлек булды дип тормады, больницада чагында ук әллә кайчангы сөяркәсе янына көненә икешәр-өчәр тапкыр чаба башлады... Чаллыярда өч катлы дача йорты бар иде, хәзер моннан эшчеләр җибәреп икенчене, тагын да зурракны салдыра. Дәүләт материалларыннан, билгеле. «ЧП» булып кешеләр бәхетсезлеккә очраган көннәрдә ул Чаллыярга, үзбушаткыч тутырып, кирпеч, цемент һәм кыйммәтле плитәләр төяп киткән иде. Икенче дачасы кайда дисәгез — Акмыек авылына барып, карагыз. Андагы мунчага Сәфәров үз ишләрен генә түгел, Чаллыярдагы сөяркәләрен алып бара да шәрә килеш сукыр тәкә уйнашалар. Шулмы инде коммунистларга хас сыйфат? Әгәр дә чара күрелмәсә, иптәш Айбулатов, без кемгә һәм ничек язарга икәнлеген үзебез белербез. Үпкәләштән булмасын...»

Айбулатов, әлеге җирәнгеч кәгазьне чирканып тоткан килеш, уртадагы өстәлне тиз-тиз әйләнеп узды, урынына кереп утырды һәм бая машинкада басылган юллар өстенә язган текстын аркылы-торкылы сызгалап ташлады да аскарак, эре-эре хәрефләр белән кәгазен сыта-сыта, өр-яңа приказның беренче параграфын язарга тотынды.

«Юк, Сәфәров белән уйнамагыз. Мин аның кем икәнлеген Чаллыяр хәтле Чаллыярны төзегән елларда сынап белдем. Холкының кискенлеге бар барын, әмма хәзерге киеренке вакытта Көмеш Аландагы коллективны тупларга нәкъ менә шундый куллы кеше кирәк. Бәхетсезлек очрагында аның гаебе юк диярлек. Шуңа күрә без аны кисәтү белән чикләнәбез,

ә гаилә... Гаилә хәленә килгәндә, ач күзле шикаятьче бәндә, бик нык ялгышасың, ул түгел, хатыны ташлап китте иптәш Сәфәровны... Бәхеткә каршы, ярый әле ташлап китте, югыйсә егетне өзгәләр-телгәләр, күрмәгәнен күрсәтер иде ул хатын. Ә болай нәрсә, аның кайгысы тартылырвакланыр да он булып таралыр,— дип эченнән ярсып бәхәсләшә-бәхәсләшә язды ул әлеге приказны.— Сезгә, шикаятьче бәндә, минем кул белән үч алу бәхете тәтемәс, Сәфәровның кем икәнлеген беләбез, кирәк икән, вакыты житкәч, үзебез кыйнарбыз без аны. Һәм сездән ким кыйнамабыз. Хәзергә без аны, Көмеш Аланга барып, «мунча» кертеп алу белән канәгатьләнербез...»

Шулвакыт, секретарена берәүне дә кертмәскә дип, кат-кат кисәтүенә дә карамастан, бүлмә ишегенең тышкы яктагысы ачылган тавыш, аның артыннан ук кемнәрнеңдер кычкырып көлешкәне, нәрсә турындадыр сөйләшкәннәре ишетелде. Ул да түгел, ишектә шәһәр партия комитетының беренче секретаре күренде. Аның артыннан тагын кемнәрдер кереп килә иде.

Айбулатов өчен яңалык иде бу, чөнки Мирас Гайнанович Борнашевның биредә идарәнең вакытлы бинасы салынганнан бирле бер тапкыр да булганы юк иде. Гадәттә, барлык мәсьәләләр дә шәһәр комитетында яисә берләшмәдә, Дикопольцев катнашында хәл ителгәнгә күрә, беренче секретарьга берләшмә, баш идарә яки трест кебек оешмаларга барып йөрүнең кирәге дә юк. Болай да көн аралаш диярлек очрашып тора Мирас Гайнанович, шәһәр төзелеше белән бигрәк тә нык кызыксына иде...

— Менә, иптәш Айбулатов, ничек диләр әле, Мөхәммәт тау янына бармаса, тау үзе аның янына килә... Ничә еллар буена бергә эшләп, шәһәр хәтле шәһәр салып та үзегезгә чакырмаган идегез, килеп чыгарга булдык бит әле,— диде Мирас Гайнанович, куллары жәлеп итә торган көлү-елмаюы белән Айбулатовка таба килә-килә. Аннары гәүдәсенә карата ярыйсы гына житез хәрәкәт ясап артка таба борылды да «Рәхим ит, каршыла кунакларны» дигәндәй кереп килүчеләргә таба уң кулы белән ишарәләде.

Айбулатов көтмәгәндә килеп кергән кунакларны, житмәсә Мирас Гайнановичның бераз кинаяле сүзләрен дә ишеткәч, бермәлгә аптырабрак калды. «Шикаять... Шикаятьче, күрәсең, минем исемгә генә түгел, Мирас Гайнановичка, ә бәлки әле югарырак оешмаларга да язгандыр»,— дигән уй телеэкрандагы импульслар тизлеге белән үтте. Әмма Мирас Гайнановичның шалтыратмый-нитми генә кунаклар белән килеп керүе бу визитның житдилеген аңлата иде.

Ул арада ишектән керүчеләр берәм-берәм күрешеп чыктылар. Айбулатов аларның бер ишесен таныды. Казан шәһәр советы башкарма комитеты председателенең төзелеш буенча урынбасары белән күп тапкырлар очрашканы бар иде, аның белән ике куллап күреште. Иң аъзактан кереп, бүтәннәр артына посыбрак торган тәбәнәк буйлы, ялтыр башлы кешене Айбулатов бик яхшы белә, чөнки ул башкаладагы йортлар төзү комбинатының беренчесен житәкли һәм аларның байтак кына киңәшмәләрдә бергә-бергә утырганнары, уртак мәсьәләләрне тегеләй һәм болай хәл иткәннәре бар. Моннан ел ярым чамасы әлек әлеге иптәш житәкләгән комбинат ялгышлык белән жибәрелгән берничә вагон агач материалларын Чаллыярга юллап озатмады, үзләштереп калды. Шуның өчен өлкә комитетында кырыс сөйләшү булган иде. Шуннан бирле Айбулатов ул комбинат белән алыш-бирешне өзгән иде. Шулай да үзенең бүлмәсенә кунак булып кергән иптәшкә Айбулатов моны сиздермәскә тырышты, ачык йөз белән күреште.

Барысы да утырышып беткәч, Айбулатов тәкъдим иткән урынга кереп утырган Мирас Гайнанович баягыча елмаймаган килеш, Чаллыярның схемасы өстенә кадакланган Көмеш Алан сызымына карап алды да:

— Шулааай,— диде бераз сузыбрак, стенага таба ымлап.— Чаллыяр мәшәкатьләре, Фазыл Артышевич, арткарак кала башлаган түгелме?

Айбулатов шулай ук стенадагы схемаларга күз ташлап алды. Борнашев сүзләрендәге кинаяне чамалап өлгерде, әмма тыныч, беркадәр басынкырак тавыш белән сорауга җавап кайтарды.

— Безнең комбинат, Мирас Гайнанович, белгәнегезчә, Башкортстан һәм Татарстан АЭСларындагы яңа калаларны хыялдан чынбарлыкка ашыруны намус эше итеп саный. Эш күләме, әлегә, Чаллыярдагы белән чагыштырганда, гел юк тирәсендә. Мәгълүмчә, без быел гына да Чаллыярда биш йөз мең квадрат метрга якын торак мәйдан төзеп тапшырачакбыз, тегеләрнең икесендә нибары кырык мең чамасы...

Айбулатов сөйләгәндә кунакларга «күрдегезме» дигәндәй күз кысып алган Борнашев аны бүлдереп:

— Ярый, ярый, Фазыл Артышевич, телгә килгәнгә генә әйтүем. Бәхәсләшергә яисә сезгә нинди дә канәгатьсезлек белдерергә теләвем түгел...— диде елмаебрак торган күзләрен кыса төшеп, хәйләкәррәк карап. Аннары кинәт җитдиләнеп, өстәде:— Көмеш Алан төзүчеләре хәзер — сезнең генә түгел, безнең дә кайгы. Өлкә комитеты, йорт төзүчеләр белән бергә АЭС коручыларны да Чаллыяр партия оешмасында торсалар яхшырак булыр, дигән карар кабул итте.

Ул арада Мирас Гайнанович инде икенче темага күчәргә, башкала кунакларының ни өчен килүләрен сөйләргә җыена иде.

— Менә, иптәш Айбулатов, тугыз ел чамасы элек, хәтеремдә, сез йортлар төзү комбинаты оештыру уе белән янып кайларга гына барып йөрмәдегез. Турысын әйтик, тырыштыгыз, көчле-куәтле, эшләрнең иң олыларын башкарырга сәләтле коллектив тупладыгыз. Нәтиҗәсе күз алдында: сезнең комбинат хәзер эш күләме һәм башкару сәләте ягыннан илдәгеләрнең беренче дистәсенә керде. Бу безнең дә тырышлык, безнең дә шатлык...

Мирас Гайнанович тагын баягы сыман кинаяле караш ташлады. Айбулатов игътибарын нәкъ менә шушы кинаягә юнәлтте, әмма беренче секретарь кинаяне телдән белдерергә ашыкмадымы, әллә инде билгән урыны андый сүзне әйтергә килештермәдеме — кунаклар ягына ымлабрак сүзен дәвам итте:

— Менә, иптәш Айбулатов, башкалада торак төзү мәсьәләсе катлауланып киткән. Анда база бар. Ләкин төзелеш тизлеге, аның сыйфаты шәптән түгел. Син, иптәш Ай-бу-латов, осталык серләрен яшермичә, кирәген-кирәкмәсен дигәндәй, килгән иптәшләргә күрсәт, тәҗрибәгез белән таныштыр, уртаклаш, яме.

Айбулатов монысына бик риза, беренче тапкыр түгел, тик Мирас Гайнановичның нәрсәнедер әйтеп бетермәве барыбер сизелә иде.

— Ярый, Мирас Гайнанович, эшләрбез. Казан — кадерле кала, андагы төзелешнең яхшы булуы, архитектура стиленең кабатланмас матурлыгы безнең өчен шатлыклы хәл. Булганны күрсәтербез, уртаклашырбыз...— диде Айбулатов, төгәл булырга тырышып.

Борнашев шул төштә үзенең вазифасын төгәлләнгәнгә санап булса кирәк, урыныннан торып басты. Соңгы елларда базыга башлаган гәүдәсендә көч-житезлек бар иде әле. Айбулатов беренче секретарьның яшьтәш икәнлеген исенә төшерде һәм... характерының бер кимчелеге — байтак кына җитәкчеләрнең туган көннәрен исендә тотмавы, шуның аркасында аларны тәбрикләргә онытуын хәтерләп алды. Әнә бит, Борнашевның илле яшьлек юбилее җиткәнен газеталардан укып кына белде... Чынлап та, Василий Михайлович Губаненконың:

— Минемчә, Фазыл Артышевич, вакыт килер — сезне СМУ начальниг ы да итмәсләр, прораб-фәләнгә генә калдырырлар,— дигән сүзләре дөрескә чыгар, ахрысы...

Мирас Гайнанович җае килгәндә, бигрәк тә кунаклар арасында сөйләшеп утырганда, ачык йөзлелек күрсәтергә һәм, автогигант төзелешләрендәге киеренке чорларны искә төшереп, «Менә бит без нинди!»—

дигән шикелләрәк бераз мактанып алырга да тартынмый торган кеше иде. Ул, китәргә җыенуын белдереп, аягүрә баскач та, Айбулатов аның карашындагы баягы кинаяләрне кабат исенә төшерде.

«Нишләп болай тиз генә чыга соң әле бу?»— дигән уй Айбулатовны да урыныннан кузгатты.— Бер дә юкка гына кәефе кырылмаган монын. Безгә кагылышлы нәрсә дә булса булырга тиеш».

Кунакларга: «Очрашырбыз әле!»— дип, өстәл артындагы креслосыннан чыгып, ишек төбенә барып җиткәч Мирас Гайнанович, чынлап та, тагын бер кат борылып Айбулатовка таба карап куйды. Гадәттә, ул беркайчан да ишек катында туктап калмый, борылып карамый торган иде.

«Нигә?.. Ни өчен борылып карады ул?— дип анализлады Фазыл Айбулатов.— Тикмәгә генә түгел бу. Димәк, Мирас Гайнановичның аңа, бары тик аңа гына әйтер сүзе бар иде. Кунаклар алдында кузгатуны кирәк тапмады. Шулай да мине кисәтеп китте...»

Айбулатов хаклы иде.

## 2

Болай да тиктормас Таңсылу бүген иртәдән үк иләс-миләс иде. Тик торганда, юк кына нәрсәдән кызык табып көлеп җибәрә, я булмаса, кабыгына бикләнә дә дәшмәс була. Берничә минут элек кенә ул әнә шундый иде, ә хәзер исә һич көтмәгәндә:

— Мин бит, Карлыгачкай, яланаяк йөрергә яратам, шундый яратам, шундый яратам...— диде, Ширәмәтне чыгып, бетон юл белән бераз баргач та туфлиләрен берәм-берәм кулларына ала-ала.— Әйдә, Карлыгач, йөгерәбез...

Әле генә больницадан, Таңсылуның әнисе яныннан чыкканга күрәдерме, Карлыгач бу омтылышны тиз чамалап өлгерде. Бераз соңгарак калып булса да, дус кызыннан күрмәкче, аяк киемнәрен, салып, кулына тотта, җылынган бетон өстенә баса-баса утыз-кырык метр йөгереп өлгергән Таңсылу артыннан ыргылды.

Юлның уң ягында, беркадәр арырак, бөтен күкрәге мәңге яшел нарат урман белән томаланган Ширәмәт тавы сузылып киткән. Аның өстеннән диярлек искиткеч зур җилкәннәр сыман кабарынкы болытлар Көмеш Алан ягына таба агылалар иде. Каян гына килеп чыккандыр, һич көтмәгәндә, бүрек кадәрле генә бер болыттан кыйгачлап яңгыр ява башлады. Кызлар йөгерә бирделәр.

Дүрт-биш минут үттеме-юкмы, кызлар өстендәге җәйге җиңел күлмәк йөгергән уңайга җилдә сизелер-сизелмәс тибрәнүдән туктап, лычма суга әйләнде, кайнар тәннәренә ябышты.

Таңсылу, гаҗәпләнүдән күзләрен зур ачып, юлның кыл уртасында туктап калды, Карлыгачны көтеп алды һәм:

— Карале, яңгыр... яңгыр ява түгелме соң, Карлыгачкай,— диде, ике кулын пар канат шикелле ян-якка сузып баскан җирендә бөтерелә-әйләнә башлады.

Аның яңгырда чыланган чәчләре салынып-салынып төшеп битенә ябышкан, ләкин ул аларны сизми, бары тик ара-тирә генә авызына керә башлаганнарын, иреннәрендәге яңгыр тамчылары белән бергә өреп, очыртып-очыртып җибәрә иде.

Карлыгач та көтмәгәндә килеп туган күтәренкелек көченә бирелмичә булдыра алмады, яңгыр шыбырдаган тавышка кушылып, көмеш тавышы белән тирә-янны яңгыратып көлеп җибәрде. Тагын бераздан инде шәһәрдәге житдилегенең, бүген иртәдән бирле күңелен биләгән, «әйт инде, әйт» дип кытыклап торган сорауның эзе дә калмаган иде.

Җитмәсә тиктормас Таңсылу тагын уйлап тапты: ул уң кулындагы туфлие-ние белән Карлыгачның чыланган аркасына җиңелчә генә сугып алды:

— Әйдә, әбәкү тот мине!— дип, җил тизлеге белән ярыша-ярыша, тагын йөгерә башлады.

Юл түбән таба төшә, тыгыз, салкынча тамчыларга каршы йөгерүе рәхәт, җиңел иде. Тырыша торгач, тән-хәрәкәткә җиңел Карлыгач Таңсылуны тагын куып җитте.

Ул арада җәйге яңгыр ничек башланган булса, шулай туктап калды, ялтырап кояш чыкты. Дөрес, көтмәгәндә килеп чыккан бүрек кадәрле болыттан актарылган су җиргә сеңеп өлгермичә бетон читендәге елгалакларга агып-агып төшә, юл салганда күтәрелгән кызыл балчык һәм ком өемнәрен юып ала, хәтта ни булганын аңламыйча калган вак-төяк чыбыкларны, аларга кунган күбәләкләрне һәм башка бөҗәкләрне дә тәгәрәтә иде.

Карлыгач күңелендә яралган, тел очында бөтерелгән сораудан хисләнеп, Көмеш Алан ягына таба бер-берсен ашкынып узган зур җилкәннәр шикелле кабарынкы болытларга карап әйтте:

— Шагыйрьләр хаклы, хаклы бит, Таңсылу, җәйге яңгыр тамчыларында коену рәхәт, искиткеч рәхәт. Ул, беләсең килсә... мәхәббәт шикелле, килеп җиттеме — бөтен күңелне рәхәтләндерә, яшисене, озак-озак яшисене китерә!

Баштарак Карлыгачның сәерлегенә, килде-киттелерәк сүзләренә игътибар бирмичә йөргән Таңсылу, юеш чәчләреннән саркып керфекләренә кунаклаган яңгыр тамчысын төшерергә теләп, күзләрен мелт-мелт иттереп алды, аннары:

— Ә син, син соң, Карлыгач,.. мәхәббәтнең... нәрсә икәнлеген... яшисене китергәнен каян беләсең?— диде, гаҗәпләнүдән авызын ябарга онытып.

Карлыгач дәшмәде, башын аска табарак иеп, ләкин ник әйткәненә мыскал да үкенмәгән кыяфәт белән торба алдына тупланган күбекле ерганак өстендә бөтерелгән печән өемнәре, чыбык-чабыкларга карап тора башлады.

Таңсылу да шунда карады.

Торба авызы алдында тупланган су басымыннанмы, әллә берәр авыр әйбер тәгәрәп килепме шунда — су күзгә күренеп кими башлады, печән учмалары, чыбык-чабыклар барысы бергә бөтерелә-бөтерелә эчкә кереп югалдылар.

Карлыгач Таңсылуның гаҗәпләнүдән исе китеп биргән сәер соравын онытмаган икән. Ул дустының үзенә таба борылганын көтеп алды да, малайлар урам буйлап кочакланышып йөргәндәге кебек итеп кенә туфли тоткан уң кулын аның җилкәсенә салды.

— Ә син... син беләсеңме, Таңсылу?..

— Нәрсәне, Карлыгач?

— Нәрсәнеме? Минем әтинең... Гөлфирә апаны... яратканын?— диде кинәт тавышы калтыранып киткән Карлыгач.— Алар... алар бит... мәктәптә укыганда ук... Минем әти бит синең әниеңә гашыйк булып, башкаларын «югалтып» йөргән...

— Кит аннан...

Таңсылу шуннан артыкны әйтә алмады. Күкрәгендә әллә нинди бер кыл тартылып куйгандай булды. Аннары аңында әллә нинди бер чагылыш ялтырады һәм ул күптәннән акылына барып ирешә алмаган бер нәрсәне аңлады.

— Әйт... әйтәм җирле... әни больницага кергәннән бирле, һәркөн килеп йөри... Ә мин... мин аны мондагыларның начальнигы булганга гына шулайдыр дигән идем. Әйт-тәм җирле...

Бетон юл хәзер инде үргә таба күтәрелә, яңгырдан соң кабат ялтырап кояш чыккан, һава сафланган — салкынчаланып киткән иде. Юл буендагы арыш, арпа һәм бодай басулары, урылмаган килеш сизелерсизелмәс кенә чайкалып, кояш нурында җемелдиләр.

Карлыгач белән Таңсылу бер-берсенә сүз әйтү түгел, күтәрелеп карарга да кыймыйча юлның юеш бетонына ялан тәпи баса-баса атлыйлар.

Аларның адымыннан, гәүдә тотышыннан, башларын унөч-ундүрт яшьтәгеләргә хас горурлык белән тотуларыннан беленә: икесе дә Дулкынлана, икесенең дә күңелендә көрәш бара, моңарчы сиздермәгән нинди-дер хис бөреләре ачылырга җыена иде.

Таңсылу күз кырые белән генә Карлыгачка карап алды. Аның йөзе кырыс, иреннәре кысылган, карашы әллә кая югарыга төбәлгән.

Дулкынлана! Димәк, аның күңелендә дә ыгы-зыгы.

Таңсылу дустының күңелендәге ыгы-зыгының инде күптән, әнисе белән Эдик абыйсы очрашкан көннәрдә үк башланганын белми иде әле.

Таңсылуның күкрәгендә нәрсәдер калтыранып куйды. Нәрсә булды, дип сорасаң, ул, әлбәттә, анык кына җавап бирмәс тә иде, әмма житлегеп килә торган кыз күңеле килер кичерешләрне көтә башлаган иде инде.

— Карлыгач җаным, Карлыгачкай!— диде Таңсылу, артык түзә алмыйча, елап җибәрмәс өчен сүз кузгатып.— Ә синең, синең әниең кайда соң? Ул сезнең белән Чаллыярда яшәмимени соң?

Әй, Таңсылу, Таңсылу, белсәң иде син бу сорауның Карлыгач күңелен никадәр авыр, никадәр очлы ук булып кадалганын!

Ләкин моннан ике атна чамасы гына язмышның күзгә күренмәс җепләре Көмеш Аланга тартып китергән һәм бер-берсе белән очраштырган, әлегә балачактан чыгуның беренче адымнарын гына ясаган Таңсылу моны белми, күз алдына китереп житкерми иде әле.

Карлыгач инде Таңсылуга караганда күбрәкне кичергән, мавыгучан җанлы әнисенең бик күп хәйләләрен аңларга өйрәнә төшкән, шуңа күрә бу юлы артык каушамады, әлеге сорауга каршы:

— Беләсеңме, Таңсылу, әйдә без синең белән болай килешик: син беркайчан да әнием турында сорама, яме. Ул... ул безне... минем әтиемне кеше көлкесенә калдырды. Ул, ул...— диде, күзләренә тулган яшь тамчылары аша дустына таба карады.

Таңсылу инде урынсыз сорау биргәнен аңлап өлгергән, ләкин, әбисе әйтмешли, авызыңнан бер чыккан сүзне кире җыеп булмаслыгын белә иде. Ул, шулай ук яшьле күзләрен тутырып, Карлыгач ягына таба борылды:

— Син... син мине, Карлыгач, гафу ит, яме?— дип үтенде.— Мин беркайчан да... беркайчан да...

Бервакыт тавыш-тынсыз атладылар.

— Мин сиңа сөйләрмен, сөйләрмен әле, яме, Таңсылу...

Икесе берьюлы якынаеп кул тотыштылар.

— Ярый, Карлыгач...

Карлыгач сүзне икенче якка борып җибәрде:

— Тагын өч-дүрт көннән Гөлфирә апа больницадан чыгар. Көмеш Аланга кайтып яши башлар.

— Ә син, Карлыгач, ничек уйлыйсың? Синеңчә, минем әнием яхшы кешеме?— дип сорады Таңсылу аптыраулы караш белән. Ул тагын: «Синең әтиең, Гаяр абый, аны яратырмы соң?»— дип тә өстәмәкче иде, тыелып калды.

— Минемчә, Гөлфирә апа, Гөлфирә апа...

Ул борылып караганда... Таңсылу юлның уң ягына килеп тоташа язган, як-ягында куак-агачлар үсеп утырган ерганакка таба йөгерә иде.

Шулвакыт көчле итеп автомашина кычкыртты. «КамАЗ!»— дип уйлап алды Карлыгач, чөнки бары тик ул гына шулай кычкырта. Уйлавын уйлады, әмма аның кемгә кычкыртуы аңына килеп житмәде. Ул арада филдәй олы машина кызга килеп бәрелә язган иде.

Карлыгач, сыртына камчы төшкән юрга кебек, урыныннан кубып юл читенә сикерде, биек үләннәргә тез башларын бәрә-бәрә Таңсылу ягына таба атылды.

Кабинасыннан башын чыгарып, авызын ерган шофер егет бу юлы инде машинасының тавышы ертылганчы бар көчкә сузып-сузып кычкырт-

ты, аннары гына дрык-дрык иттереп урыныннан кузгалды да «ТатАЭС» дип язылган эре-эре хәрефләрне сулда калдырып, Көмеш Аланга, булачак шәһәрнең панельләрен илтергә китте.

— Таңсылу, Таңсылу, дим, бу ни эшең инде? Бер сүз әйтмичә, агачлар арасына томырылдың?— диде Карлыгач, агачлар арасындагы ачыклыкка, җиләк сабаклары өстенә йөзтүбән яткан дустының иңбашларына кагылып.

Таңсылу исә бу вакытта үксеп-үксеп елый иде.

Карлыгач дустына кагылмаска, елавыннан туктаганын көтеп торырга булды, аның янәшәсенә, хуш исләре белән борыннарны кытыклап алган үләннәргә чалкан ятып зәңгәр биеклеккә карады...

Алар, икесе берьюлы, баш очында гына гөрселдәгән тавышка уянып, күзләрен ачып җибәрделәр. Шул ук мизгелдә, икесенең дә күз алдында диярлек агачлар арасыннан әллә ниткән озынча җирән бер кош пырхылдап чыкты да күк йөзен кыл урталайга ярып югарыга таба менеп китте. Ул сүнеп бетәргә өлгермәде, биектә-биектә тагын бер, аның артыннан икенчесе, өченчесе ялтырап-ялтырап китте.

Җир өсте караңгыланган. Баярак аз гына да кымшанмый утырган агачлар үзләренә искиткеч куәт белән ябырылган җилгә каршы торырга азапланалар, булдыра алмыйча, ерганак тирәнлегенә ышыкланырга теләгәндәй сыгылалар, аннары тагын, буйсынмыйбыз, барыбер башыбызны имәячәкбез, дигәндәй, һаваның тыгыз катлавын ярып янә күтәреләләр иде.

Кызлар, тагын икесе берьюлы диярлек, торып утырдылар. Көчле җил: «Болары кемнәр тагын, ни кирәк?»— дигән сыман алар өстенә ябырылды, тән җылысы белән баягы яңгырдан кипшенергә дә өлгермәгән күлмәк итәкләрен билләргә кадәр күтәреп-күтәреп карады.

Күк йөзендәге электр көчләре атылып-таралышып, тагын да күбрәк сибелергә көч туплаган арада юл ягыннан йөк төягән машиналарның гүләве ишетелеп-ишетелеп куйды. Бу озак дәвам итмәде, чөнки куе болытлар томалаган күк гөмбәзенең төрле җирендәге утлар тагын ялтйолт итәргә кереште.

Табигать көчләренең хис-кичерешләр киеренкелегендә тарткалашкан кеше күңеленә охшарга тырышып дулавы иде бу, күрәсең. Кем белә, бәлки алар дөньяның иксез-чиксез күкрәгенә сыймаганга шулай ялтырый-гөрселди торгандыр. Бәлки ул ярылу-ялтырау гөрселдәү табигатьнең елавы, хис-кичерешләрдән үзәкләре өзелгәнгә, авыртуларының зурлыгыннан шулайдыр?

Карлыгач бу минутларда да Таңсылуның күңелен телем-телем телгәләгән, аны көтмәгәндә юлдан кубарып, агачлар арасына, үләннәр өстенә ташлаган ни икәнлеген белми, башына да китерми иде.

Алар икесе дә, үз уйларына чумып, озак утырдылар.

## 3

Алексей Мирков берләшмә житәкчесе Дикопольцев каршына җиңел, тавыш-тынсыз диярлек адымнар белән килде дә өске өлешендә «правительственная» дип сугылган телеграмма кәгазен куйды, үзе бер адымга чигенә төшеп көтеп тора башлады.

Мондый телеграммалар ил күләмендә эш йөртүче эре берләшмә өчен яңалык, искитмәле нәрсә түгел, алар көн саен дистәләп килә, шуңа күрә ярдәмчесенең әлеге кәгазьгә җавап көтеп басып торуы Дикопольцевны нәрсәдер язып утырган җиреннән аерылырга, башын күтәреп карарга мәҗбүр итте.

— Я, ни булды, Алексей? «Правительственная» телеграмманы беренче тапкыр күрүеңме?— диде ул, куе кашларын үр куяны сыман сикертеп,

эшеннән бүлдергәнгә канәгатьсезлек белдергән шикелле.— Нәрсә терәлеп торасың дим?

— Бу телеграммага кичекмәстән җавап бирүне сорыйлар, Вергилий Никифорович, шуны көтәм.

Дикопольцев, «Тагын нинди телеграмма инде ул» дигәндәй, ашыкмыйча гына сузылып алды ул кәгазь кисәген. Битендә тормыш салган җыерчыкларның берсе дә селкенмәде, күңелендәге кылларның берсе дә тартылмады. Чөнки эш дәвамында аңа: «Ашыгыч», «Бик ашыгыч» дигән грифлар сугылган телеграммаларны бик күп күрергә туры килде. Бу юлы да шуларның берседер дип уйлады бугай.

Ләкин бусы, әле генә ярдәмчесе кертеп биргән телеграмма андыйлардан түгел иде.

Вергилий Никифорович, житмеш яше тулып килүенә карамастан, күзлексез дә әйбәт кенә укый ала иде.

Т е л е г р а м м а

*Иптәш Дикопольцев зпт СССРның тынычлыкны яклау комитеты Сезне фашизмның элеккеге әсирләренең Освенцимда булачак халыкара очрашуына чакырачак тчк Барубармавыгыз турында хәбәрне кичекмәстән Мәскәүгә тынычлыкны яклау комитетына җибәрүегез сорала тчк*

Бүлмәдә авыр тынлык урнашты. Дикопольцев үзе дә, ярдәмчесе Мирков та, хәтта сәгатьләр буена тынгы белмәгән селектор зуммеры да, бу тынлыкны ялгыш хәрәкәт белән бозмыйк, диделәр бугай.

Вергилий Никифорович кулында бераз калтырабрак торган телеграмманы берничә тапкыр укып чыгарга өлгерде. Аның зур, кие һәм саргылт төстәге кашлары да куерыбрак, тыгызланыбрак килделәр.

Дикопольцев чигәләрендәге чәч бөртекләренең берәм-берәм салкынаюын, тимерчыбык шикелле катып торая башлауларын тойды. Колагында башта ишетелер-ишетелмәс кенә, аннары көчәя барган җан өзгеч чинау башланды... Ул чинау якынайганнан-якыная барып, колак пәрдәләрен ертырдый булып үсте-үсте дә бөтенләй булмагандай кинәт юкка чыкты.

Үзенең акыл сәләте, ихтыярының көчлелеге, искиткеч чыдамлылыгы, язмышының катлаулылыгы белән озын һәм куәтле тамырларын җир куенына таратып, җил-давылларга карамыйча зәңгәрсу күкнең гөмбәзенә таба туктаусыз күтәрелгән, янәшәсендә бик күп башка төр агачларны да үстергән йөзьяшәр имән шикелле нык кешенең күңеленә бу мизгелдә узгандагы сынау-кичергәннәрнең ябырылуы аермачык күренеп тора иде.

«Телисеңме, иптәш Дикопольцев, теләмисеңме, син — ветеран, күптән ветеран инде. Бу — бәхәссез. Бу тормышның ачы, ләкин бердәнбер хаклыгы. Кайчандыр син, иптәш Дикопольцев, икеләнү-шөбһәләнүләрне бар дип тә белми идең. Синең күкрәгеңдә, әйтерсең, бер түгел, берьюлы ике йөрәк типкән сыман иде. Син тормыш дигән иң текә, иң биек кыяның иң куркыныч һәм дәһшәтле биеклегеннән ташланып та саусәламәт чыга ала идең. Алай гынамы, син ул упкыннардан тагын да ныграк, тагын да батыррак булып, чыныгыбрак чыга идең. Ләкин... ул вакытлар үтте. Синең дә ветеран булып, әле тормышның андый кыяларын яшьрәкләргә калдырыр чакларың житте, житте, иптәш Дикопольцев»,— диде күңел түренә кереп урнашкан һәм шунда бертуктаусыз үсә, зурая барган хыянәтчел бер тавыш.

«Юк, ветеран булсам да, минем җырлыйсы җырым җырланмаган әле,— диде Вергилий Дикопольцевны тормыш сикәлтәле юллары буйлап куркусыз атлатып, әйдәп йөргән үз тавышы.— Минем әле җир йөзендә дәһшәтлелеге белән тиңдәше булмаган канкойгыч сугыш кырында егермесен дә тутырмыйча мәңгелеккә чумган иптәшләрем, үлем лагерьларында көлгә әверелеп, фашистлар кулы белән Европа илләрендәге басуларга сибелгән көрәштәшләрем эшләргә тиеш булган эшләрне башкарасым,

алар төзергә тиеш булган заводларны, яңа калаларны, ниһаять, инде нигезе салынган атом электр станциясен хыялдан чынбарлык итәсем бар...»

«Тынычлан, ветеран, тынычлана күр һәм каушама: ләкин син, Дикопольцев, бик күпләр гомер буена, хәтта йөз еллар дәвамында хыялланырга да базмаган эшләрне эшләдең, яңа калалар һәм электр станцияләрен, алмаз рудникларын булдырдың. Сиңа җитмәгәнмени эшләгәннәрең? Бик җиткән. Хәзер син, ветеран, яшьләргә юл бир, алар, һичшиксез, кыюрак. Шулай булгач, алга таба алар омтылсын. Ә син ветеран кордашларың янына ашык, аларны күр, алар кебек үк хатирәләр белән яшә»,— диде тагын баягы хыянәтчел тавыш.

«Әллә соң, әллә соң чынлап та шулаймы? Чынлап та миңа ветеран булып йөрер вакыт җиткәнме? Алайса, нишләп соң мин моңарчы сугыш ветераннары янына очрашуларга йөрмәдем?— диде тагын Дикопольцевның үз тавышы.— Мине бит чакырмадылар түгел, чакыргалап тордылар. Дөрес, бер тапкыр Вилюйга бардым. Ләкин мин анда ветеран булып түгел, ә шушы якларга тормыш сулышы илткән төзүчеләрнең беренче җитәкчесе буларак бардым... Хәзер мине Ветераннар советы чакыра... Димәк, минем яшем дә, эшләрем дә ветераннарныкыча. Димәк, мин күпме генә таныpга тырышсам да, тормыш хаклыгы барыбер үзенекен итә...

Алексей Мирков берләшмә җитәкчесе күңелендәге кичерешләрнең мыскалын да күз алдына китерә алмый иде. Әмма барыбер ниндидер эчке бер тойгыга буйсынып, ничек кергән булса — шулай тавыш-тынсыз адымнар белән кабул итү бүлмәсенә чыгып китте.

«СССР Верховный Советы депутаты, Социалистик Хезмәт Герое Вергилий Никифорович Дикопольцев»,— дип кызыл хәрефләр белән язылган ишекне тыгызлап ябуына карамастан, тагын ачылмасын дигәндәй аркасы белән күпмедер тотып торды.

Төп-төгәл унбиш сәгатьтә Татарстан атом электр станциясе, аның юлдашы Көмеш Алан төзелешенә багышланган атналык киңәшмә ачылырга тиеш, шуңа күрә кабул итү бүлмәсенә төрле идарә һәм оешма җитәкчеләре, тәэминатчылар, проект ясаучылар һәм бүтән вәкилләр тупланган иде. Алар ишек ачыла башлауга «Безне чакыра»— дип уйлап алдылар булса кирәк, берьюлы аягүрә бастылар. Мирковның дәшмитынмый чыгып ишекне терәтеп торуын башта үзләренчә — гадәттәге «мунча»дан чыгу дип аңладылар бугай, бердәм рәвештә көлешеп куйдылар. Арадан берсе хәтта:

— Нәрсә, Алеша, сиңа да «мунча» кергәләргә туры киләмени? Безне генә кертеп җибәрәсең дип торам тагы?— дип чәнчеп алырга да өлгерде.

Бирелә күпне күргән, тагын да күбрәкне ишеткән, утлар-сулар ның теләсә ниндиен кичергән кешеләр, күпчелек очракта оптимистларның да оптимистлары җыелган иде.

— Ничава, Алексей, әйдә, күтәр прицибыңны. Беренче тапкыр түгелдер әле...

Мирков бу кешеләрнең — җилкәләренә искиткеч җаваплылык йөген салган җитәкчеләрнең — һәммәсен дә белә, хәтта алар үзләре белмәгән күп нәрсәләрне дә белә. Кайсы чакларда тегеләрнең ачы тормадай телләренә каршы үзләреннән дә уздырыбрак җавап биргәли иде. Бу юлы дәшмәде, телефон аппаратлары, селектор тартмасы куелган өстәле артына кереп утырды. Кулларын учын-учка куеп өстәл өстенә салгач кына:

— Бераз сабыр итегез,— диде.

Әмма шундук ишек ачылып китте, Дикопольцев күренде. Аның кашлары баягыча җыерылган, кабарынкы иреннәре тыгыз кысылган, күзләрендә кырыс очкын ялтырап-ялтырап китә иде.

— Иптәшләр, нигә кермисез? Билгеләнгән вакыт узып китте түгелме соң?

Дикопольцевның тавышы да гадәттәгедән кырысрак иде.

* * *

Житәкчеләр үзләре яратып сайлаган урыннарга кереп утырыштылар. Дикопольцевның сул ягындагы почмакка махсус куелган кечерәк өстәл янына стенографистка кереп утырды, кәгазьләрен җәеп салды һәм язарга хәстәрләнде. Алексей Мирков ниндидер йомыш белән бер-ике тапкыр кереп чыкты.

Элегрәк Дикопольцевның теләсә нинди хәлләрдә дә йөзенә чыкмый торган борчылу билгеләре бүген юк-юк та чагылып-чагылып китә, куе саргылт кашлары әледән-әле икесе бергә кушылып-кушылып куя иде.

— Я нәрсәдән, кемнән башлыйбыз?— диде өстәл тирәсендәгеләргә игътибар белән карарга тырышып, ләкин читтән караучыга аның карашының кешеләргә түгел, ә бәлки каядыр, алардан югарырак бер ноктага тупланганын сизүе кыен түгел иде.— Сезме, иптәш Алмазов? Хәрби төзүчеләр өчен казармаларның нигезен кайчан салып бетерәбез! Причалга бара торган дамбаны тагын бер метрга күтәрергә сөйләшкән идек, бетердегезме?

Марк Львович Алмазов Көмеш Аланда төзелеш башланганда республикада гына түгел, федерациядә иң эреләрдән саналган Зәй ГРЭСын төзегән идарә җитәкчесе иде. Идарә кешеләре автогигантны торгызышуда, башка объектларны коруда уңышлы гына эшләделәр. Шуңа карамастан, ул идарә барыбер берләшмә җитәкчеләренең күзеннән читтәрәк, һәм башкара торган заданиеләре дә шау-шу куптара торганнардан ук түгел иде. Көмеш Аланда төзелеш кузгалгач та, Дикопольцевның боерыгы белән идарә барлык эшләрне төп башкаручыларның берсе итеп билгеләнгәннән соң, Алмазов, һич көтмәгәндә, күз өстендәге кашның берсенә әйләнде дә куйды. Шунысы кызык, әлек үзе кебек идарә җитәкчеләре янына һәрвакыт диярлек нәрсә дә булса сорарга килүче Алмазов, һәркайсына нинди дә булса дәгъва белдерүчегә әверелеп куймасынмы?

Бу юлы да, «уттан-ялкынга» дигән кебек, урыныннан торып басуга:

— Вергилий Никифорович, чистарту корылмасына кирәкле бетон конструкцияләрне китерү кичектерелә, шуңа күрә безнең эш тоткарлану ихтималы бар. Аннары, торак төзүчеләр хәзергә кадәр мәктәп бинасында кайнашалар, ә бит безнең монтажчыларга, АЭС коручыларга, үзегез беләсез, кышка кадәр торак кирәк...— дип тезә башлады. Ләкин Дикопольцев аны уң кулы белән ишарә ясап туктатты.

— Туктале Алмазов, кадерлем, куелган сорауга җавап бир син,— диде ул кинәт, үзе дә сизмичә төче телләнеп.— Аларга өстәп тагы измә-бетон узелларын сафка кертүне ник сузуыгыз турында да әйт...

Алмазовның иң авырткан төше иде бу. Төзелеш башланып, ул җитәкләгән идарә Көмеш Аланга күчерелгәч тә бик һаваланып:

— Күп булса ике ай тулганчы ике измә-бетон узелын куярбыз. Без измә-бетонны Чаллыярдан яки Түбәньярдан ташудан туйдык инде,— дип вәгъдә биргән иде. Шактый вакыт узды, әмма Алмазов идарәсе төзүчеләре, Айбулатов егетләре һәм юл салучылар измә житмәүдән интегәләр. Һәм, чынлап та, соңгы көннәрдә измә-бетон узелы сафка кертелмәсә, барлык эшләрнең тәрәлеп калуы бик мөмкин. Озакламый причалга юл түшәү, аннары причалның үзен бетонга төрү башланачак һәм, билгеле инде, башкаларның Алмазовка дәгъвалары бермә-бер артачак иде.

Алмазов моны яхшы аңлый һәм Дикопольцевның ачуын китермәс өчен бик җайлы гына юл тапкан иде: әлегә кадәр җиңел генә төгәл вакыты күрсәтелгән вәгъдә бирен котыла килде.

Хәзер дә ул гадәтенчә:

— Беренче сентябрьгә, Вергилий Никифорович, узелларның икесе дә дөбердәшеп эшкә керешер,— диде.

Киңәшмәдә катнашучыларның урындагы хәлләрне белүчеләре сизелер-сизелмәс кенә, ирен читләре белән генә елмаешып куйдылар. Дикопольцев моның сәбәбен беләме-юкмы, әмма идарә җитәкчеләренең һәркайсына диярлек Алмазов вәгъдәләре суга язылганлыгы мәгълүм иде.

Яз көне Алмазов куйган вакыт узып китеп, узелларның берсе дә сафка кертелмәгәч, Айбулатов белән Алмазов арасында бәхәс купкан иде. Алмазов исе китмәгән кыяфәт белән күзен дә йоммыйча: «Беренче майга, һичсүзсез өлгертәм!»— дигәч, Айбулатов аңа:—«Булмый, Марк Львович, булмый беренче майга»,— дип каршы төште.

Алмазов исә кызып ук китте: «Нишләп булмасын? Анда бит инде эш бетеп килә диярлек... Әйдә бәхәсләшәбез... Әгәр дә беренче майга измә узеллары эшли башламаса... миннән бер... юк, өч шешә коньяк булыр!»— дип әйтеп ташлады. Айбулатов — бәхәсләрдән курка торган кеше түгел, күзе дә күбрәкне күргән, автогигант кебек зур төзелештә эшләрнең дә төрлесен күбрәк башкарган: «Әйдә, карап карыйк»,— диде. Шуны гына көтеп торган, җае килгәндә уен-көлкегә һәвәс җитәкче иптәшләр шаһитлыкка алындылар, Айбулатов белән Алмазовның кулларын сугып аердылар.

Билгеләнгән көн үтте дә китте, узеллар эшкә керешүдән ерак, бик ерак иде.

Бәхәсне белүчеләр еш очрашып торалар, һәрхәлдә атнага бер-ике тапкыр Дикопольцев бүлмәсендәге киңәшмәдә булмыйча калмыйлар. Киңәшмәдән кабул итү бүлмәсенә чыгып, тәмәке тартып торган арада кайсыдыр берсе:

— Син, Марк, узелларны беренче майга бирәм дип пари тоткан идең, оныттың бугай,— дип исенә төшерде.

Алмазов күзен дә йоммыйча:

— Бусында точно июль башында була!— диде һәм тагын, бу юлы инде ун шешә коньяктан бәхәсләште.

Июльнең башы да, ахыры да узды, август тәгәлләнеп килә, ләкин Алмазов сүзендә тора алмый иде...

Дикопольцев стенографисткага таба борылмыйча гына:— Языгыз: беренче сентябрьгә измә-бетон узелларын сафка кертергә, боерык үтәлмәгән очракта иптәш Алмазовка кисәтүсез-нисез каты шелтә язарга!— дип мәсьәләгә «нокта» куйды.

Вергилий Никифорович берләшмә бинасыннан кәефе кырылып чыкты. Өенә кайтасы, гомумән, бер кеше белән дә күрешәсе, сөйләшәсе килми иде аның.

— Әйдәле, дус кеше, КамАЗ тирәләреннән әйләндереп кайт бер,— диде ул шоферын гаҗәпләндереп. Чөнки берләшмә җитәкчесенең бу вакытта больницага барырга, врачлар билгеләгән тиешле дәваны алырга тиешлеген белә иде ул.

— Вергилий Никифорович, ә больницага... анда барыр вакыт җиткән бит инде.

Вергилий Никифорович шоферына яннан карар-карамас кына:

— Әйткәнне тыңлый беләсеңме син, Ренат, әллә мәктәптә андый нәрсәләрне әйтмәделәрме?— диде, үзе турында туктаусыз кайгыртырга күнеккән, алтын куллы, киң күңелле шоферына бераз канәгатьсезлек белдереп.— К черту дәваларын...

Шофер егет хуҗасының кәефсез чагы икәнлеген чамалап алды һәм бүтән бер генә сүз яки хәрәкәт белән дә аңа комачауламаска булды.

Куәтле «Волга» урыныннан салмак кына кузгалды, тизлекне секундлап диярлек арттыра барып, урамга чыкты, аннары, шәһәргә кермичә,

сул якка борылды. Тимер-бетон күперләр астыннан чыгып, бишәр, тугызар катлы жыйнак, елмаеп торган йортларны карап уздылар. Мәләкәс елгасының теге ягындагы Айбулатов үҗәтнең яшь гаиләләр өчен махсус проект ясап салдырган биналары күязләнеп калды. Ул йортлар күренүгә, Дикопольцев, күпме генә теләмәсә дә, күңеле белән баягы киңәшмәгә кайтты.

Әйе, Дикопольцев турында артында да әйтергә ярамаган нәрсәләрне үз күз алдында, ачыктан-ачык әйтә дә сала бит шул Айбулатов. Билгеле, Вергилий Никифорович аны бер сүз белән туктата алыр, бүтән сөйләмәслек итәр иде. Ана, берләшмә житәкчесенә, андый гына хокук бирелгән. Әмма эш турында сүз барганда, алай туктату — Дикопольцевка хас нәрсә түгел. Вергилий Никифорович күңеленең кайсыдыр бер төше белән намалый иде: Айбулатов хаклы, хаклы бит. Башта ук Айбулатов белән килешәсе булган да, әллә нинди бер тискәрелек комачаулады. Калатау итәгендә карьер ясап, дамба ясар өчен ташлы жир алу,— бер уйлаганда, Дикопольцев фикере дә түгел. Ул уйны Алмазов салды аңа. Әмма берләшмә житәкчесе раслап, жирне шуннан алу турында тиешле боерыкларны биргәннән соң ул: «Дикопольцев кушты...»га әйләнгән иде. Ә хәзер Көмеш Аландагы барлык төзүчеләр, бигрәк тә башкаладан яки югарыдагы оешмалардан килгән кешеләрнең барысы да беравыздан:«Булачак каланың күз өстендәге каш шикелле нигезен иштерергә кемнең башы житте икән»,— дип мыскыллы көлү сүзләрен кабатлыйлар. Югыйсә, Айбулатов кына түгел, башкалар да кисәтте бит аны: «Ярамый, Вергилий Никифорович, ярамый бу тауның итәгеннән жир алырга. Адәм күрке — баш, тау күрке — таш дигәндәй, тавы-ташы ишелә башламагае»,— диделәр.

Дикопольцев шуннан соң исәп-хисап ясарга кушкан иде, күрәсең, исәп-хисапчысының намусы шуның кадәр генә булгандыр. «Ярый. Нәрсә булсын соң ул тауга, Вергилий Никифорович»,— дигән нәтиҗә ясап бирделәр. Әллә барганнар, әллә юк? Әнә бит, Айбулатовны әйтер идем, киңәшмәгә коры кул белән түгел, Калатауның, Дикопольцев боерыгы буенча нигезе иштерелгән, хәзер инде шәһәргә караган ягы да ишелә башлаган тауның өстәл хәтле рәсемнәрен алып килгән... Теге вакытта, шәһәрнең урыны өчен бәхәс барган чакта, Дикопольцев фикере алга чыкса, билгеле, тауның бу ягы ул кадәр үк күз өстендәге кара кашка әверелмәгән булыр иде...

Дикопольцев акылының ниндидер яшерен күзәнәкләре аермачык төшенә: теләсә нинди, хәтта әллә ни олы булмаган төзелешне җәелдереп жибәрү — гади нәрсә түгел, һәм анда кемнәрнеңдер ихтыяры кушканча эшләп, ахырда гаять четерекле нәтиҗәләр чыгарырга мөмкин. Мондый хәлләр Вергилий Никифоровичның эш дәверендә булмады түгел, булгалады. Кемнеңдер ихтыяры кушканга гына урынлы-урынсыз салынган заводлар, хәтта тулы шәһәрләр дә бар, кызганычка каршы. Әйтик, ерак барасы юк, кемнеңдер ихтыяры Татарстанның сусыз-нисез, житмеш жиде жил үзәне булган шыр ачык урынында Жәлил шәһәрчеген сала башлаган һәм, ялгышу төзәтүдән узгач, аны, эшчеләр поселогы дип, үз язмышына тапшырып киткән. Яисә, ихтыяри кушуның классик үрнәге: егерме-егерме биш еллар элек Дикопольцевның үзен дә Обь елгасының түбән агымында зур электр станциясе корылышына кодалый башлаганнар иде. Галимнәр арасында:«Ярамый анда электр станциясе корырга, Обь һәм Иртыш күтәрелеп искиткеч күп мәйданнар, Төмән сазлыкларь су астында калачак»,— дигән аргумент күпләрне ышандырмады. Ярый әле язучы халкы арасында кыю йөрәкле ир-егетләр, дәлилләп яза белүчеләр бар. Озаклаймый төзелешне башлыйбыз дип директивалар корып житкергәндә генә мәсьәлә хәл ителде. Тагын бер-ике елдан Төмән якларында миллионнар белән хисаплана торган «кара алтын», «зәңгәр алтын»нар бәреп чыкты. Хәзер әнә илебез хуҗалыгы гына түгел, Көнбатыш Европа илләре дә шуннан ягулык ала. Ә бит берәүнең ихтыяры белән шушы байлык су астында күмелеп калырга бик мөмкин иде...

Дикопольцев үзе дә үгезне мөгезеннән эләктереп сыртына салырга ярата иде, тоткан җирдән өзмичә, әйткән сүзен тормышка ашырмыйча калдырмый иде.

Бәлки, бәлки аның да ихтыяри кушулары, кемнәрнеңдер фикерен таптап киткән чаклары булгандыр. Бәлки, ул да һәрвакыт дөрес фикер йөртмәгән, кемнәрнедер басылырга мәҗбүр иткәндер...

Теләсә нинди төзелеш мәйданындагы эш барлык куәтенә башланып китсен, тәгәл автомашиналар кебек көйләнгән, җайга салынган организм булсын өчен, кимендә, бер-ике ел кирәк. Ул чагында инде аны тәгәрмәч астына таяк тыгып кына туктата алмыйсың, андыйларны ул үзе дә таптап изеп китә.

Вергилий Никифорович үзенең Чаллыярдагы төзелешкә, автогигантка килгән көннәрен искә төшереп алды. Аны, тәҗрибәле төзүче-инженер, булдыклы җитәкче бит син, Дикопольцев, дип, бирелдәге эшләрне җайга салырга, артта калуларны бетерергә, эшләрне билгеләнгән вакытка башкарып чыгуны оештырырга, үзе тормышка ашыра башлаган кыю идеяләрне сынарга җибәрделәр.

Җиңел генә бирелдеме...

Хәтта бервакыт килеп, Дикопольцевның эшеннән канәгатьсезлек белдерүчеләр табылды, аны төзелеш начальнигының урынбасары итеп күчерделәр...

Бер уйлаганда, артык бимазаланырга урын да юк. Көмеш Алан КамАЗ кебек ил-җир күзе өстендәге кара каш түгел, шулай да эш башланганнан бирле тиешеннән шактый артык миллионнар салынды инде. Ләкин нилектәндер андагы эшләр җайланып, Чаллыярда күнегелгән эзгә, андагы темпларга керми, иң мөһиме — шау-шу кубара алмый иде әле.

Беренчедән, дип уйлап алды Дикопольцев, торак төзүне көчәйтергә, шул ук вакытта Чаллыярдагы тәҗрибәне кулланырга, мөмкин кадәр күбрәк вагоннар куярга кирәк. Икенчедән, иптәш Дикопольцев, нихәтле генә кыен булмасын, чынлап та, бу очракта Айбулатов сүзе дөрес иң. Калатауны иштерүдән туктатырга кирәк, чөнки аны яңадан үз хәленә кайтару өчен күпме көч кирәк булачак...

Дикопольцев «Волга»сының уң як тәрәзәсен төшерде дә, тынычланырга тырышып, юл буендагы панноларга карап бара башлады. Пропагандистлар бу панноларны уйлап чыгарып, аларны олы юл буена бастырып бик дөрес эшләделәр, әнә бит андагы язу-рәсемнәргә карыйсың да үзеңнең үткән гомереңнең сәхифәләрен теркәп барасың...

## 5

«...Җирдә яшәгән һәр кеше мәхәббәт җәзасын татырга тиеш», дигәнне укыды да кулындагы зәңгәрсу тышлы китабын янәшәсенә, диван өстендәге мендәргә ташлады Нурлыбикә. Бу сүзләр һич көтмәгәндә аның йөрәгенә ук булып барып кадалды.

— Чынлапмы икән бу, белеп язганнармы икән?— диде ул үз-үзенә.

Чаллыярдагы квартирында кызы Карлыгачны япа-ялгыз калдырып, Эдик белән Акнаратына — әниләре янына, аннары бирегә, Ереван читендәге курчак йортына охшаган дачага килеп кергәннән бирле аның бу хакта уйлап караганы юк иде әле. Әмма соңгы бер-ике көндә, сөекле Эдигы чираттагы «командировка»га китеп, бу йортта ялгызы гына калгач та Нурлыбикәнең башына торып-торып шомлы уйлар кергәли башлады.

Җитмәсә кичә кичкырын, күрше йорттагы бер оятсыз бәндә, аның Эдик хатыны икәнлеген бөтенләй белмәгәнгә салынып:

— Бу кәнтәйне Эдик алып кайтканмы әллә? Ничә көнгә икән? Үзе туйгач булса да миңа биреп тормасмы?— дип кычытмаган телен кашыган була.

— Менә Эдик кайтсын, кәнтәеңне күрсәтер,— дип уйлады Нурлыбикә ярсып-ярсып.

Өстәвенә әле бит Акнаратка кайткач, этисе дә беренче күрүдән үк яратмады Эдикны, кулын биреп, юньләп исәнләшмәде, өр-яңа «КамАЗ»-га дыңгычлап төягән затлы әйберләрне дә бушатышмады. Аннары өч көн буена бәрелеп-сугылып йөрде, ачудан бер гөнаһсыз Актырнакның сыртына «кит моннан», дип сәнәк сабы белән сукты... Соңгы кичне, ничек җитте шулай утырттылар табынга, әмма анда да Нурлыбикәнең кәефен җибәрде. Ничек диде соң әле ул?

— Син, кызым, күрми күргән көндез чыра яндырган, дигәндәй, бәхетеңә чыдый алмадың. Хәерлегә генә булсын. Минемчә, син озакламый үкенерсең, тик бер киткән болытны куып тотып булмай, булмай аны, кызым,— диде ачулы күзләрен гомердә булмаганча ялтыратып, Эдик күрсен диптер инде, бик озак кына кул күтәреп дога кылды һәм урманга — умарталыгына китеп барды.

Ярый инде, бәхеткә каршы, Эдик аның нәрсә әйткәнен ишетеп өлгермәде.

Ә этисенең күршедә генә яшәгән туганнан-туган апасы инде бөтенләй тузга язмаганны әйтеп куйды:

— Син, Нурлыбикә кызым, үз тормышын үзе ашап махмырлаган кеше икән... Кара мунчада торып-торып якты күргәч тә шулай була инде, шулай була,— дип үзәккә үтте.

Әнисе онытгы Карлыгачны алып кайтмаганына әрнеп, өч көн һәм өч төн буена кешегә сиздермәскә, бигрәк тә яшь киявенә күрсәтмәскә тырышып, пышын-пышын елады.

Тик Нурлыбикәнең әлеге сүзләрне күңеленә алырлык вакыты түгел иде шул. Эзләп тапкан мәхәббәтенең иң кайнар, татлы көннәре иде әле.

— Моңа кадәр күпме вакыт сүнмичә-сүрелмичә янган мәхәббәт уен буламы соң инде? Эдик мине чын күңелдән ярата ул, миннән башка җир йөзендә яши алмый. Нигә соң мин үземә килгән, үземә тигән мәхәббәт өлешеннән тыелырга, ваз кичәргә тиеш? Юк, юк, мин — Эдикны, Эдик мине гомерлеккә яратабыз. Безнең мул, бай тормышта яшисебез килә. Ә теге ужым бозавы андый тормышны аңлыймы соң ул? Минем ике уртада яшисем килми, туйдым мин андый тормыштан, кем әйтмешли, я уңам, я туңам,—дип, үзен-үзе юатты Нурлыбикә ул чагында.

Ул чагында әйтүен әйтте, ләкин бит мәхәббәтне аны кем кулына тотып караган да кем бизмәнгә салып үлчәгән! Әгәр дә хәзер аның уты сүнә, кызуы бетә башласа, нишләрсең? Нурлыбикә, күңелендәге каршылыклы уйлар белән бәхәсләшә-бәхәсләшә, укый торган китабын читкәрәк ташлап, урыныннан сикереп торды, ике якка ачылмалы җиңел ишекләрне куллары белән төртеп җибәреп, киң һәм иркен балконга чыкты.

Тышта август аеның җылы, тыныч бер иртәсе иде. Ерактагы таулар өстеннән ярыйсы ук күтәрелгән кояш сокландыргыч зәңгәрлектә күк гөмбәзендә йөзә. Яшеллеккә күмелгән тау үзәнлекләреннән хуш исле сафлык бөркелә. Офык читен кыя-тау башында хәзергә кадәр эреп бетмәгән кар япмасы кояш нурларына салкынлык өсти иде кебек.

### 6

26 август, Көмеш Алан

Бүген иртә белән шәһәргә барган чагында Гөлфирә янына кереп чыккан идем. Ул миңа:

— Синең инде борының гына утырып калды, шулкадәр ябыктың, Гаяр,— дип куйды.

Белмим, бәлки чынлап та шулайдыр, әмма төс-кыяфәткә карап торырга вакыт юк. Бирелгән эшләр мин күз алдына китергәндәгедән

күп тапкырга артыграк булып чыкты. Шунысы бар: бирелә миңа төзелеш белән генә түгел, тагын күп төрле мәсьәләләр белән дә шөгыльләнергә туры килә. Әле беркөннәрдә генә Фазыл Артышевич:

— Көмеш Аланга күчеп яшәргә кирәк сиңа, югыйсә күңелеңнең яртысы анда, яртысы монда,— дигән иде... Үзеннән-үзе шулай килеп чыкты: иртәдән кичкә кадәр генә түгел, кичләрен һәм хәтта төннәрен дә, ял көннәрендә дә эшләргә туры килә. Анысы, билгеле, куркытмый, ләкин икенче бер нәрсә бар: мондагы эшләрнең барысын да үзем генә башкарып чыга алырмынмы, юкмы? Бервакыт килеп «Син, Сәфәров, мондагы эшләрне оештыра алмадың, коллектив туларга көчең җитмәде»,— дип адәм мәсхәрәсенә калдырмаслармы? Шуңа күрә бригада советына, мондагы коммунистларга, тәҗрибәле кешеләргә күбрәк ышандырырга, аларның да инициатива күрсәтүләренә ирешергә кирәктер, бәлки? Бер баш әйбәт, ике баш тагы да яхшы, диләр бит.

Чаллыярдан китүемә байтак вакыт узды инде, ләкин әле ниндидер бер тойгы һаман да андагы эшләр, анда кичергәннәр белән яшәргә мәҗбүр итә. Бу, бәлки, табигыйдер, чөнки, ни генә әйтсәң дә, минем аңлы тормышымның иң күп өлеше, тулысы белән булмаса да, шушы шәһәр һәм андагы төзелешләр белән бәйләнгән. Юклы-барлы ун ел эчендә бөтен дөньяга шау-шу күтәргән автогигант үсеп чыкты, аның янындагы Ак шәһәр инде минем дә хыялымдагы Ак шәһәр иде. Аның күккә ашкан ак йортлары, моңарчы илдәге бер генә шәһәрдә дә булмаганча киң, дүртәр юллы урамнары-проспектлары — һәммәсе дә хәтердә.

Шуңа күрәдер инде, Көмеш аланга килергә булгач, хәтта монда килеп эшләр өермәсенә кереп киткәч тә мин әле кайда яшисемне тиз генә билгели алмадым. Айбулатов күргән саен ул хакта сүз кузгатмыйча калмый, ләкин мин һаман да кичектереп килү сәбәбен табам... Башта, хатын килергә теләми, дидем. Аннары инде, ул киткәч, мондагы хәлләр бөтерелеп-дулап алды. Бәхетсезлек очрагыннан соң Айбулатовның да ул хакта сүз кузгатканы юк. Хәер, кузгатырга җае да чыкмый, чөнки минем инде Чаллыярда булмаганыма да байтак көннәр узды. Карлыгач та монда. Дөрес, аны мондагы мәктәптә укытып булмый. Димәк, Чаллыяр кешеләре булып, андагы квартираны тапшырмыйча яшәргә туры килә дигән сүз. Менә тагын өч-дүрт көннән беренче мәктәпне тапшырабыз, аның артыннан ук беренче биш катлы йортны җиткерербез...

Сәфәров шул урында каләмен дәфтәр өстенә ташлады да ишек ягына таба карап нидер көтә башлады. Ул да түгел, ишектә Зөлфәт Зәйнуллинның таза гәүдәсе пәйда булды, аның артыннан кемнендер тавышы ишетелде, ләкин кешесе күренмәде.

Ачудан тыны буылырга җиткән Зөлфәтнең күзләре атылып чыгардай булып зурайган иде. Ул эш киемен кыштырдатып бусагадан узды да «Нәрсә әйтер бу?» дип көтеп торган Гаярга карамыйча, карлыга төшкән тавыш белән кычкырды:

— Менә, иптәш Сәфәров, менә,— диде ул тотлыга төшеп, әйтергә сүз табалмыйча.— Менә, менә...

— Нәрсә булды, Зөлфәт, я әйт инде кешечә...

Зөлфәт исә дулкынланудан арына алмый иде.

— Китәләр, китәләр әнә...

— Кемнәр китә, кая китә?— Сәфәров парторгның тел төбен аңламый тора иде.— Кемнәр китә дим мин сиңа?— диде ул Зөлфәтнең янына ук килеп һәм ачык калган ишектән кемнәрнедер күрергә тырышып.

— Хатын-кызлар китә,— диде, ниһаять, Зөлфәт өздереп.

Барысы да аңлашылды. Теге атна арасында отделкалаучы хатын-кызлар һәм балта осталары Чаллыярга кайтмаганнар иде. Кичә кичкырын киңәшмәдә бу юлы да кешеләрне кайтармау турында сүз булды.

Шулай эшләмәгәндә, мәктәп бинасын беренче сентябрьгә тапшырып булмаячак. Югыйсә төзүчеләрнең барысы да эшнең мөһимлеген аңлыйлар иде кебек. Дөрес, соңгы вакытта Гөлфирә больницада чакта бригада икеләтә зурайды, автозавод сынавын узмаган, хәтта кем икәнлекләре дә яхшылап беленмәгән кешеләр килде.

— Ничек китәләр, нәрсә белән, автобус урынында тора бит,— дип тәрәзәгә ымлады Гаяр, Зөлфәт әйткән хәбәргә ышанырга теләмичәрәк.

— Алар рейс автобусы белән китәргә җыеналар. Дөрес, мин автобус йөртүченең кулыннан ачкычын тартып алдым.

— Яхшы иткәнсең...— диде Гаяр һәм әле булса ишекне томалап торган Зөлфәтне бер читкәрәк этәрде дә, коридордагы резин итекләрен киде, күлмәктән килеш урамга чыга башлаган җиреннән: «Туктале, сүз җитди булыр, ахрысы»,— дип кире борылды, галстугын такты, пинжәген киде һәм узып барышлый гына көзгегә күз салырга да онытмады.

«ЛАЗ» автобусы, чынлап та, халык белән шыгрым тулы иде. Сафәров барган уңайга ук автобусның ачык калган ал ишегеннән керде һәм тыныч булырга тырышып, шулай ук автобустагылар ишетелерлек итеп кычкырды:

— Иптәшләр, бу ни хәл? Кая җыендыгыз?

Автобус салонындагы шау-шу туктап калды. Ләкин бу кыска вакытка гына шулай булган икән. Икенче секундта инде арттагы рәтләрнең берсеннән:

— Кая булсын — каймаклыга,— диде усал тавыш. Гаярны үчекләп, һәм шундук өстәп куйды:— Син, Сафәров, монда килеп безне ишәк урынына эшләтмәкчесең икән, ә?! Хәлеңнән килсә, үзең эшлә. Безне җибәр хәзер үк, Сафәров. Яхшы чакта җибәр, югыйсә...

Югыйсә нәрсә буласын кресло аркасына яшеренгән коткычы (Сафәров аның кем икәнлеген танымады, димәк, яңа килүчеләрдер, дип уйлап алды) әйтеп бетерә алмады, автобус салонында баягыдан да битәррәк шау-шу купты.

— Нигә син безнең исемнән сөйлисең?

— Мондый сүз өчен беләсеңме... беләсеңме нишләтәләр?

— Без мунча керергә, өс-баш алыштырырга тиешме-юкмы?

— Хатын-кызлармы без, юкмы? Безнең хакта кайгырту кирәкме-кирәкмиме?

Сафәров уртадагы урыннарның берсендә бригадир вазифаларын вакытлыча башкаручы Әнүрә Әмированы күреп алды, аңа әр тулы караш ташлады.

Әнүрә дәшми генә тәрәзәгә карап утыра бирде.

Ни хикмәт, аның баярак кына теленә килгән тупас сүзләр әллә кая китеп югалдылар. Ни генә әйтсәң дә, хатын-кызлар хаклы бит. Ул тактиканы үзгәртергә, хатын-кызларга төчеләнеп «кызлар-йолдызлар» дип дәшәргә уйлаган иде, әмма үзе дә сизмәстән теленә башка сүзләр килде.

— Чаллыяр һәм КамАЗ төзелешендә булучылар хәзер үк эшкә тотына. Калганнар, иртәгә үк хезмәт кенәгәләрен алып, теләсәләр генә кайсы якка китә ала. Безгә иң авыр чакта сыгылып төшеп хыянәт итүчеләр кирәкми,— диде дә артына борылып карамыйча автобус бусагасыннан юеш җиргә сикерде, салмак, ләкин ышанычлы адымнар белән мәктәп бинасына таба атлап китте.

Чынлабрак караган кеше Сафәровның аркасы бөгеләрәк төшкәнен, җилкәләре дә урынында түгел, беркадәр салынып торганын чамалар иде. Ләкин Сафәров артына борылып карамыйча атлавын дәвам итте. Башта аның башыннан: «Эх, болай кискен бәйләнмәскә иде, җайлабрак сөйләшергә иде. Яңа килгән кешеләр күбрәк бит»,— диган уй ялтырап узган иде. Шулай да күңелендәге ниндидер бер үзсүзлелек кире борылырга, бүтәнчә сөйләшергә ирек бирмәде...

Ниһаять, берәүнең, җыелган суны чупылдатып, автобустан сикереп төшкәне, аның артыннан тагын берничә кешенең сөйләшкәне ишетелде. Шунда гына Сәфәров үзенең биредә калу-калмавы хәл ителгәнлекне, гигант төзелеш сынавын узган төзүчеләрнең аның белән санашуларын төшенде. Барыбер, мәктәп бинасының ишеге төбенә җиткәнче артына борылып карамады, ничек атлаган булса шулай баруын белде.

Хатын-кызларның барысы да диярлек кире килгән иде. Алар, баягы кебек үк бер сүз әйтмичә, хәтта үзара да сөйләшмичә, вакытлыча кием бүлмәсенә керделәр, өс-башларын алыштырып эш урыннарына таралдылар.

Шулвакыт, Сәфәровның артыннан калмыйча диярлек йөргән Зөлфәт:

— Ну, Гаяр Бариевич, бу чыгышың, мин сиңа әйтим, каты булды. Беттек дигән идем...— дип маңгаеннан әллә яңгыр, әллә тир тамчыларын кулъяулыгы белән сөртеп-сөртеп алды. Бу аның Гаярга беренче тапкыр әтисенең исеме белән кушып дәшүе иде.

— Катысы аның соңрак булыр әле, Зөлфәт Рәшитович,— диде Сәфәров, соңгы сүзләрне беркадәр суза төшебрәк һәм сорап куйды.— Автобуста ничә кеше калды?

Зөлфәт шатлыгын яшермичә, шуны гына көтеп торган шикелле әйтте:

— Нибары өч кеше, яңарак килүчеләр...

— Өч кеше, Зөлфәт туган, күп ул. Безгә кешеләргә карата йомшаграк, кайгыртучанрак булырга кирәк иде дә бит...

Әле генә Сәфәровның «йомшаклыгын» күргән Зөлфәт дәшмичә калуны артыграк санады. Сәфәров дәвам итте: «Менә нәрсә, иптәш парторг, хәзер үк партбюро членнарын җый әле син, моны болай гына калдырырга ярамас». Вагон ишеген саклык белән генә ачып керде, икенче бүлмәдә кочаклашып йоклап ятучы Карлыгач белән Таңсылуның йокы аралаш нәрсәдер мыгырданып алуларын ишетеп, ирексездән елмаеп куйды.

«Гөлфирә генә җитми», дигән уй миең урталай ярып узды һәм Гаяр үзенең караңгы бүлмәсенә кереп утырды.

«Ни гаҗәп,— дип уйлады ул,— теге көнне Гөлфирә белән аңлашканнан соң Нурлыбикә йөрәккә салган яраның сызлавы кимегәннән кими бара. Хәзер инде бөтенләй онытылды дисәң дә ярый. Тик әллә нигә бер искә төшеп-төшеп ала да, язмышыма бөтенләй бәйләнеше булмаган вакыйга сыман, гадәти бер хатирә шикелле салкын гына үтә дә китә. Ә бит аның белән ни генә әйтсәң дә, аз да түгел, күп тә түгел, — ундүрт елга якын бергә яшәделәр»...

Теге көнне нинди дә аңлашылмас һәм күзгә күренмәс бер көч Гаярның үзсүзле башын һич көтмәгәндә Гөлфирәнең күкрәгенә салырга мәҗбүр итте. Ул йөрәгендә ничәмә-ничә еллар буена сүнмичә-сүрелмичә йөргән яшьлек мәхәббәтенең исәнлеген һәм тәтенсез дары кебек кабынып китәргә әзерлеген аңлады. Төзелештәге эшләрнең барыр-бармас, җайланыр-җайланмас булуына карамастан, искиткеч зур өмет һәм хыяллар белән яши башлады Гаяр. Мондагы күңелсезлекләр, йөрәккә никадәр генә якын булмасын, вакытлыча гына туган күңелсезлекләр иде. Алар күпмедер вакыттан соң — яңа төзелешнең олы тәгәрмәче бар куәткә әйләнә башлагач та югалачак, ә күңелнең иң ерак түрендә озак еллар буена яшеренеп яткан беренче мәхәббәтнең ирек татымаган тойгылары Гаяр Сәфәровны тормышның тәмен белеп яшәргә мәҗбүр итәчәк иде.

## 7

Казаннан килгән кунаклар ярыйсы гына талымлы кешеләр булып чыкты. Айбулатов аларга үзе җитәкләгән комбинатка караган оешма-

ларны күрсәтте, объектларга алып барды. Чаллыярдагы төзелеш темпларына ничек-ничек ирешү серләрен бәйнә-бәйнә сөйләде. Башкаланың шәһәр башкарма Советы председателе урынбасары, төзелеш эшләре белән турыдан-туры шөгыльләнүче Аксурин сорау биреп, комбинатның эчке серләрен, теге яки бу эшне, мәсьәләне нинди юллар белән әйләндереп чыгарулары турында бигрәк тә төпченеп, кат-кат сорашты. Яңа шәһәрнең шушы араларда кешеләр кертергә дип әзерләнгән кияү егете сыман көяз, аның кәләшедәй саф һәм җыйнак комплексларын карап, торак йортларга кереп аларның эчке әзерлеген тикшереп чыккач әлеге Аксурин:

— Әйтегез әле, иптәш Айбулатов, гадәттә тапшырыла торган йортларда бик күп җитешсезлекләр табып була. Я тегесе җитми, я бусы эшләнмәгән була. Ә сез хәтта су краннарын, газ плитәләрен дә көйләп куйгансыз. Бу бөтен йортларда да шулаймы? Әллә, минәйтәм, начар нәрсә күрсәтәсегез килмәгәнгә, боларын гына шулай җыйнакладыгызмы?— дип төрттереп куйды.

Айбулатов кунакның мондый тыйнаксызлыгын ишетмәгәнгә салышып караган иде, тегесе үзсүзләнеп, соравын тагы кабатлагач, түзмәде, күзләрен ачулы кыса төшеп ярып салды:

— Без бит, иптәш Аксурин, сезне ирексезләп чакырмадык, үзегез күрергә килдегез. Без күрсәткәннәргә ышанасы булмагач, нигә килдегез? Минем, бәхеткә каршы, сез шикләнгән нәрсәләрне берәмтекләп күрсәтеп йөрергә, шуның белән үзебезнең төзүчеләр хезмәтенең зурлыгына, аларның тырышлыгына тап ташларга вакытым кысанрак. Ышанмыйсыз икән, менә бу комплекста әзерләнгән меңнәрчә квадрат метр торак мәйданны тәшкил иткән йортларның һәр подъездын үзегез әйләнеп чыгыгыз, ярыймы?— дип, ярыйсы гына тупас җавап кайтарды.

Сүз шуның белән тәгәлләнде, бәхәс куерып җитмәде. Кайтырга кузгалдылар. Машиналар янына җиткәч, әлеге дә баягы Аксурин иптәш берәүгә дә атамыйча гына:

— Безнең разведка мәгълүматларына караганда, биредәге кайбер иптәшләр йорт нигезен субайлар кагып салуны алдынгы алым дип күршеләренә күрсәтәләр күрсәтүен, әмма үзләре... Үзләре яшерен мастерской оештырып, тагын ниндидер яңалык чыгарып, кирәк булган җиһазларны ясап яталар, имеш... Субай урынына измә салып катыру юлын сайлаучылар, зурдан кубып сөйлиләр, тик нишләптер, ул яңалыкны башкаларга күрсәтергә ашыкмыйлар,— дип эчпошыргыч тавыш белән тезеп китте.

Айбулатов бакчасына атылган таш иде бу.

Нихәл итмәк кирәк, кунак булсаң, тыйнак бул, дигән акыллы сүзне оныткан кешегә һаман саен тупаслык күрсәтеп булмый...

Фазыл Артышевич бераз уйланып торгач та машиналарны кырык икенче комплекста тәҗрибә рәвешендә, әлегә бик аз кеше генә хәбәрдар булган йорт нигезе салына торган төшкә борырга кушты.

Бу алымны автогигант төзүчеләре әлегә уйлап-сынап кына карыйлар иде. Әмма аның никадәр файдалы, никадәр вакытны киметәчәген Казан кунаклары тиз чамалап алдылар.

— Кирәкле җиһазларны, техниканы каян алдыгыз?— дип кызыксынды Аксурин.

Айбулатовка кунакларны «яшерен» тәҗрибә участогына алып барудан башка чара калмады.

«Казан төзүчеләре дә белгәч,— дип уйлады ул,—«яшерен» участокның сере ачылган булып чыга, димәк, озакламый тагын бер бәхәс кубачак, тагын Айбулатов үз белдеге белән проектны үзгәрткән. Ни хакы бар?— дигән сорауга җавап бирергә туры киләчәк...»

Соңыннан Айбулатов идарәдәге үз бүлмәсенә юнәлде. Үзәк почта һәм телеграф почмагын борылганда алар артыннан килгән «Волга» калтыравык тавыш белән кычкыртып куйды. Айбулатов сулга каерылып

караса — Мирас Гайнанович икән. Ул, машинасының ачык тәрәзәсеннән уң кулын сузып, «Минем арттан барыгыз» дигән ишарә ясады һәм, туктап-нитеп тә тормыйча, борылышка керде, шәһәр комитеты каршына барып туктады.

Көннең эсселеге аз гына да сүрелмәгән иде әле. Мирас Гайнанович кыска җиңле күлмәгенә галстук та бәйләгән, шуңадырмы бераз тирләгән, битен-күзен кулъяулыгы белән сөртә-сөртә, Айбулатовны бүлмәсенә алып керде.

Кереп утыргач, тагын байтак кына дәшмичә, тегесен-монысын эшләде, телефоннан сөйләшеп алырга өлгерде. Ул арада уңган секретарь чәй әзерләп кертте.

— Әйдәле, Айбулатов... сусауны басып алыйк әле. Бәлки, кем белә, соң...гы тапкырдыр.— Ул суза төшебрәк әйтеп куйды һәм әйткән сүзенә үзе дә игътибар биреп житкермәгән кеше сыман тамак кыргалады.

Айбулатов мондый хәлнең тиктомалга түгеллеген, ниндидер житди сөйләшү булырга тиешлеген чамалый иде чамалавын, әмма тәгаен түгел һәм шуңа күрә ни уйларга белмичәрәк утыра иде.

Ниһаять, ул телгә килде.

— Бүген, Мирас Гайнанович, иртәдән бирле ниндидер киная белән сөйләшәсез әле. Нишләптер минем зирәклек житеп бетми. Орышыргамы-мактаргамы дигәндәй ни әйтергә теләвегезне аңлап бетермим бит әле.

— Турысын әйтергә дә мөмкин, Фазыл Артышевич, ләкин бит сез үзегез шәһәр комитетының беренче секретаре белән турысын әйтеп сөйләшергә бик үк ашыкмыйсыз...

Айбулатовка бу сүзләр сәеррәк тоелды.

— Нигә алай дисез, Мирас Гайнанович. Әгәр дә кирәге чыга икән, үзегез беләсез, сезгә килмичә калганыбыз юк бит.

— Шулаен шулай... Тик «кирәге чыкканда» бит ул. Әгәр кирәге чыкмаса... Мин, билгеле, иптәш Айбулатов, турысын да әйтә алам: Казан кунакларының тел төбеннән аңлавымча, беркөнне өлкә комитетында торак төзү мәсьәләләренә багышланган киңәшмәдән соң сезне Беренче аерым алып калып сөйләшкән...

Аңлашылды, барысы да аңлашылды Айбулатовка.

— Күптәнге мәсьәлә бит инде бу, Мирас Гайнанович,— диде ул жиңел сулап.— Миңа калса, сез минем фикерне беләсездер дип уйлаган идем.

— Белүен беләм, иптәш Айбулатов, әмма биредәге йортлар комбинаты житәкчесе булуга караганда башкаладагы шундый берничә комбинатны берләштергән шәһәр төзүче Баш идарәне житәкләү сезнең өчен хәлдән килми торган эш түгел, минемчә...

Чәйләр суынып өлгергән иде инде, Мирас Борнашев яңартып кертүләрен үтенде. Ул да түгел, телефон шалтырап куйды — өлкә комитетының беренче секретаре белән сөйләшә башлады. Сүзнең ахырында гына Казаннан килгән кунаклар турында сорашты бугай, ул:

— Айбулатов аларга барлык серләрен сөйләп бетерде инде, бездән битәррәк эшли башламагайлары,— диде каршысындагы әңгәмәдәшенә күз кысып.

Фазыл Артышевич сизде: Борнашевның кармак салып каравы иде бу. Һәм чирттерде дә. Чөнки өлкә комитетының беренче секретаре беркөнге сөйләшүдә кузгатылган мәсьәләне Борнашевка житкерде. Ул исә моны: «Шулай... әйе... үзе нәрсә әйтер бит әле»,— дигән кыска гына җөмләләр белән тыңлап торды. Аннары гына:

— Мин бу эшне, иптәш секретарь, бик үк уңышлы сайланган, уйланылган дип әйтмәс идем. Чөнки, үзегез беләсез, Айбулатов-автогигант төзүдә беренче көннәрдән катнашкан кеше. Хәзер әнә үз шәһәремне салам дип Көмеш Алан белән җенләнә. Мондагы төзелешнең зурлыгын

беләсез. Хөкүмәтнең Чаллыярны үстерүгә өстәмә средстволар куюы җаваплылыкны арттырды гына. Аннары бит әле үзебездә дә андагы баш идарәдән зуррак берләшмә бар... Озакламый аңа да үзебездә үскән кеше кирәк булмагае... Ярый... Ярый, сөйләшермен.

Секретарь кыз чәй яңартып китерде. Мирас Гайнанович өлкә комитеты секретаре белән сөйләшкән тәэсирдән арынып бетә алмый иде әле. Шуңа күрә секретарьның ярым пышылдап соравына каршы җавап бирергә онытты. Аннары авызын пешерә-пешерә бер-ике йотым чәй капты да Айбулатовка таба борылып карап торды.

— Менә шулай бит без, Фазыл кордаш, үзебезне үстергән, тауларга күтәргән якларга рәхмәтне шулайрак әйтәбез кайчакта. Шуның өчен дә безнең алты миллионлы халыкның иң талантлы кешеләре — белгечләре, оештыруга сәләтлеләре, гомумән, талант ияләре бөтен илгә таралган. Элек-электән шулай булган бу. Әйтерсең, безнең республикада аларга колач юк. Мин исә сездән моны көтмәгән идем. Ничек инде шулай, җиңел генә, Чаллыярны — үз кулларыгыз белән торгызышкан, күпме өлешегез кергән, йокысыз төннәр, күпме шатлыклар кичергән шәһәрне, ахыр чиге үзегезнең яшьлегегез үткән җирне ташлап китәргә мөмкин? Аңламыйм...

Айбулатов шәһәр комитеты секретаре сөйләгән арада берничә тапкыр бүлдерергә, нәрсәдер әйтергә теләп караса да, тукталып калырга мәҗбүр булды. Ниһаять:

— Мин, Мирас Гайнанович, Казанда чакта ук тәкъдим ителгән урыннан баш тарттым. Мин анда күчәргә ризалык биреп кайтмадым бит. Мине Чаллыярда гади инженер итеп булса да калдырыгыз, дидем. Баш идарә җитәкчесе булу мине кызыктырмый.

Борнашевның йөзе әлеге сүзләрдән яктырып китте. Ул урынында утырып кала алмыйча сикереп торды, озынча бүлмәсенең аргы башына урап килде.

— Соң бит күптән шулай диләр аны, Айбулатов... баш катырып утырасың монда,— диде әңгәмәдәшенең җилкәсенә сул кулын куйган килеш.— Күптән шулай диләр аны, дускай.— Борнашев соңгы сүзгә басым ясап әйтте.

— Соң сез бит миннән, Мирас Гайнанович, турыдан-туры әйтеп: китәсеңме Казанга күчеп, әллә юкмы?— дип сорамадыгыз. Ничек инде мин үзем башлап әйтим... Чаллыярыбызны ничек ташлап китәсең дә, аннан башка ничек яшисең ди?

Тагын телефон шалтырады. Борнашев урынына барып утырды, трубканы алды һәм бераз тыңлап торганнан соң Айбулатовка борылып, учы белән микрофонны томалаган килеш:

— Әнә, Казан кунаклары сине югалтканнар, монда килмәкчеләр,— диде һәм яңадан трубкага:— Килегез, хәзер үк килегез, иптәшләр,— дип өстәде.

Бер минут чамасы тын тордылар. Борнашев тагын нәрсәдер әйтергә теләгән иде, шуңа күрә Айбулатов урыныннан кузгалмыйча көтеп торды.

— Беләсегез килсә, Фазыл Артышевич, минем үземнең дә борынгыдан килгән тарихи башкалабызның алама йортларын сүтеп алар урынына Ташкент, Алма-Аталардагы кебек күз явын алырдай йортлар, архитектура ансамбльләре торгызасы бик килә дә бит, бу эшләрне киләчәккә калдырып торырга туры килә, чөнки халыкны торак белән тәэмин итәсе бар. Күп төзелешләрне, яңа калаларны күтәрәселәр бар. Минемчә, Фазыл, килер шундый бер вакыт, без Казанның тарихи үзәген саклаган килеш, аның барлык матур сыйфатларын чагылдырган мемориал булдырырбыз әле. Тар урамнар, елның-елында ремонтланып та, елның-елында аламалана торган иске йортлар сакланса да, фәкать шушы мемориал эчендә генә сакланып калыр. Ә хәзергә... ә хәзергә без килер буыннар өчен Чаллыярны, Көмеш Аланнарны салыйк, Фазыл...

## Алтынчы бүлек

### I

Җәйнең җылы киче. Кояш инде сүнеп, Көмеш Алан ягындагы урман артына төшеп бара. Аксыл болытлар күк гөмбәзенең ерактагы читенә таба актарыла, ә Ширәмәт тавының текә битендәге агачлар сүнеп баручы кояшның иң соңгы нурларында коеналар.

Гаяр больницага барышлый кызгылт, миләүшә һәм ак төстәге өч данә роза чәчәге сатып алган иде, Гөлфирә бүлмәсенә шуларны тотып, елмаеп килеп керде.

Ни хикмәттер, Гөлфирә ак халатка төренгән Гаярның үзен таныганчы үк чәчәк исен сизеп алды. Ул ирексездән:— Ой, нинди тәмле, нинди хуш ис...— дип куйды һәм, соңгы көннәрдә ярыйсы гына җанланган күзләрен тутырып, Гаярга карады. Аның озын, матур керфекләренә яшь бөртекләре саркып чыкты.

Каршылыклы, бик каршылыклы тойгылар кичерә иде бу минутларда Гөлфирә. Аның һәркайда кыю, туры барырга яраткан табигатенә Гаярның ничә еллар буена беренче мәхәббәт хисләрен саклавы, әле хәзер дә теге чакта, басма янындагы кебек дулкынлануы, шушы дулкынлануы хисләренең чынлыгын белгертә, шул ук вакытта Гөлфирәдән җавап көтүе сәер, бик сәер сыман иде.

Кем белә, бәлки Гаяр теге вакытта үзенең хисләрен җавапсыз калдырган кешедән үч алырга — аннан көләргә, үзенеке итәргә һәм...

«Юк, юк, мондый әшәке уй белән йөри торган кеше түгел бит Гаяр. Мин ул, мин гөнаһлы җан, нигә мондый уйлар белән аның керсез сакланган хисләрен буярга тырышам соң әле»,—дип уйлый иде Гөлфирә ялгыз калган минутларында. Ләкин андый чакларда Гөлфирәнең күз алдында теге вакыттагы Гаяр: басма төбендә кочагына ап-ак шомырт чәчәкләре күтәреп, күзләрен ялтыратып торган, аннары малайларча кызуланып басма такталарыннан үч алучы егет килеп баса. Шулай итеп, Гөлфирәнең уйлары буталып кала, һәм ул төгәл бер карарга килә алмыйча бимазалана иде.

Гаяр да Гөлфирәнең дулкынлануын, күңелендәге кичерешләрнең каршылыклы икәнлеген чамалый. Эчке бер сиземләү аңа Гөлфирәнең нәрсәдер әйтергә, ләкин әйтә алмыйча үз-үзе белән көрәшүен пышылдап тора шикелле.

Гөлфирә Гаярны күрүгә хәстәрләп куйган сүзләрен оныттымы, әллә онытмыйча, бары тик кыюлыгы җитенкерәмичәме:

— Килдеңме... Гаяр?— дию белән тынып калды.

Гаяр Гөлфирә янына барырга, аның кулларыннан тотып бит алмасыннан үбеп алырга кирәк булыр, дип уйлаган иде — булдыра алмады.

— Килдем шул... Гөлфирә,— дип чикләнде.

Бүлмәдә көтелмәгән, урынсыз тынлык урнашты.

Гаяр шунда гына халат астында яшереп тоткан күчтәнәчне — алмалар салган полиэтилен капчыкны исенә төшерде.

— Менә, Гөлфирә, сиңа бригада кызлары җибәрде.

Ләкин бригада кызларында күбесенә бөтенләй таныш булмаган «Гөлфирә апа» кайгысы юк иде ул көнне.

— Алмакайлар...

Гөлфирә әллә кызларны, әллә, чынлап та, берсеннән-берсе ныграк алсуланып торган Болгариядән килгән алмаларны шулай назлап атады — Гаяр аңлап бетермәде, ләкин ул Гөлфирәнең моңарчы килгәндәге халәтеннән ерак, бик ерак булуын чамалап алды.

Дөрес чамалаган иде ул.

Теге көннән соң Гөлфирә, башындагы чәчләре үрә торып, чигә тамырлары кыса башлаганчы, Гаяр белән үз-үзен ничек тотасын, нәрсәләр

сөйләшәсен уйлады. Уйлаган саен тирәнгәрәк керде, фикерләр каршылыгы көчәйде, узгандагы вакыйгалар бүтәнчәрәк төсмерләре, астыртынрак яклары белән ачылдылар.

Ул Гаяр күзләренең төсен, карашының яшертен мәгънәләрен хәтерләргә тырышты. «Минем хәлләрне, бигрәк тә соңгыларын беләмеюкмы? Белсә, мине кызганып, үткәннәрдән йолып алыйм, начарлыгына каршы яхшылык эшләп, үземнең көчлелегемне күрсәтим,— дип кенә йөремиме икән соң ул»,— дип иза чикте.

Әмма шундук кемдер аның колагына:

— Болай итеп, япа-ялгызың күпме яшәргә була, син дә тере кеше бит. Багалмасыдай яшь чакларың, гомерең шулай үтәрме, сугыш арты түгел бит, теләсә нинди талымлы ир-атны да бәхетле итәрдәй кайнар тәнең шулай кадерсезләнер дә пыскып сүнәрме?— дип пышылдый иде.

Ничек булса булгандыр, беркөнне Гөлфирә әлеге очсыз-кырыйсыз уйларны, күңелсезлекләрне, бигрәк тә үзе күргән-кичергәннәрнең мыскалын да яшермичә сөйләп бирергә дигән карарга килде.

Хәзер бүлмәсенә Гаяр килеп кергәч тә, Гөлфирә әнә шушы сүзләрне чишмә оясында тулыһ улактан ташыган су сыман актарып салырга әзер, ләкин ниндидер көч аның телен бәйләп куйган шикелле тотып тора, башлап китәргә ирек бирми.

Хәер, бүтән вакытта, җыелышларда яки киңәшмәләрдә, ир-атлар арасында, бигрәк тә участоктагы эш мәйданнарында теле-телгә йокмаган Гаяр да шундыйрак хәлдә иде бугай. Дөрес, ул инде ишек төбеннән Гөлфирә яткан карават янына килгән, урындык алып аның каршысына утырган иде утыруын.

— Ник, ник дәшмисең, Гаяр, нигә сөйләшмисең?— диде, ниһаять, Гөлфирә.

— Син үзең дә бүген әллә нинди бит, Гөлфирә. Күзләрең дә моңсу. Нәрсә булды, дип сорамакчы гына идем.

— Беләсеңме, Гаяр,— диде Гөлфирә, тәрәзә аша кичке караңгылыкка таба төбәлгән килеш.— Теге вакытта... басма буенда, аннары мәктәптә дә синең күңелдәгеләрне аңлаган идем бит мин. Әйе, әйе, беләсең килсә, синең кебек уңган, чибәр егетнең үземә гашыйк булып йөрүенә бик нык горурлана идем. Кызганычка каршы, ул чагында минем чая матурлыгыма кызыгып йөрүчеләр мәктәптә дә, мәктәпне бетереп чыккан авыл егетләре арасында да син генә түгел идең. Мин, хатын-кызга гына хас сыйфат — үзенә күрә бер усаллык белән аларның башын әйләндерүдән кызык таба идем...

Гөлфирә, сөйләвеннән туктап, ак кәгазь белән каплап куелган стаканнан бер йотым чәй эчте, иреннәрен тастымалга сөртте, күзләрен тутырып, Гаярга карады, аннары, көрсенеп, тирән сулыш алды да өзелгән төшеннән ялгап китте.— Иң кызганычы, синнән кала бүтәннәрнең берсе дә миңа ошамый, ләкин мин аларга карата игътибарлырак та, йомшаграк та, сүзчәнрәк тә идем... Ә син, син бит тыйнак идең, күңелеңдәге хисләрне әйтергә яхшысынмый идең. Бәлки, аларны чын хисләр булганга күрә әйтүе, күкрәгеңнән чыгарып салуы кыен булгандыр. Тик мин андый нечкәлекләрне аңлардай дәрәҗәдә түгел идем әле. Минем өчен бүгенге кыюлык — чынмы ул, әллә ялганмы — мөһимрәк иде. Мин синең чибәрлегеңне, миңа карата ниндидер, башкаларныкына бер ягы белән дә охшамаган хисләр кичерүеңне күрә идем. Әмма, кем әйтмешли, күңел күзе күрмәсә, маңгай күзе ботак тишеге икән...

Гөлфирә тотлыгып-тотлыгып калды. Гаяр аны тынычландырырга ашыкты:

— Сөйлә, сөйлә, Гөлфирә!

— Кая калган идем әле? Әйе. Мәктәптән чыккач та мин башта Казанга киттем. Анда инде, дустым, синең ише авыл малайлары, билгеле, искә дә кереп чыкмый башлады. Минем өчен тормышның, яңасе,

нәкъ үзе, нинди булырга тиешлесе башланды. Бер уйласаң, кызык инде, үзең бер нәрсә дә югалтмагансың, ләкин үзең эзлисең дә эзлисең. Мин дә шулай, бер егет белән мавыгып өлгермим, аннан битәррәге килеп чыга. Язганым нәкъ шушыдыр сыман тоела... Дөрес, ул вакытларда үземә тиңне мин үзем генә сайлыйм дип уйлыйдыр идем, минем исә үземне дә сайлаулары башыма да килмәгән шул.

Гөлфирә озак кына дәшмичә торды, Гаяр аны ашыктырмады.

— Хәтерлисеңме син, юкмы — белмим. Хәер, хәтерләмисеңдер. Мин бит сине мәктәптән чыкканның икенче җәендә, дөресрәге көзендә күрдем... Чаллыяр пристаненда... Син кемнедер көтеп тора идең. Мин, пароходтан чыгып, баскыч төбенә җитүгә, өскә таба күтәрелеп караган идем — син басып торасың... Шулчак янымдагы кызларга:

Тегермән тирәләрендә...
Минем сиңа буласым юк,
Йөремә тирәләремдә,

— дип җырлап-такмаклап та күрсәттем. Ләкин без менеп җиткәндә, син урыныңда юк идең. Мин ашханәгә дә кереп чыктым, мәйдан тирәсен дә караштырдым, ләкин син юк идең... Шуннан соң инде сине бик озак, ай-һай, озак күрмәдем... Мин синең турыда Үзбәкстан ягында яшәгәндә радиодан ишеттем, Гаяр. Ул чагында инде мин туган ягыбызда төзелеш башланганны белә идем, әллә кайтыргамы диебрәк тә уйланып йөридер идем... Ләкин... юлымда бер кеше һәрбер адымымны белеп, күзәтеп тора иде...

Гаяр, урыныннан торып, тәрәзә янына барып басты. Аның күзләре кысылган, иреннәре бер-берсенә тыгыз ябышкан иде.

— Мин аны беренче күрүдән үк яраттым сыман булды. Аның серле күңеле, башбаштаклык чигенә җиткән кыюлыгы, тоткан җирдән өзәргә яратуы,— дип дәвам итте Гөлфирә, түшәмгә карап.— Шундый ирләргә генә хас таләпчәнлеге, ирләрчә үзенә тарту көче мине әсир итте... Бергә үткәргән беренче кичтән үк, ышанасыңмы-юкмы, мин аның хатыны булырга ризалык бирдем. Чөнки мин инде, егетләрне күргәләгән кеше булсам да, андыйны беренче тапкыр очратуым иде.

Баштагы атнада ул минем янга, тулай торакка килеп йөрде. Бер килүендә дә буш килми иде... Күп очракта аның кулында берәр кыйммәтле әйбер, кесәсендә Ташкентның иң атаклы рестораннарына чакыру билеты була торган иде...

Гөлфирә иреннәре кипкәнне тоеп туктап калды, башта теленең очы белән генә ялап алды, аннары ирен читенә тидереп стаканнан бер-ике тапкыр чәй йотты. Аның күзләрендәге яшь бөртекләре күптән кибеп, карашы кырысланган иде. Күңелен биләгән хисләре каядыр арткарак, ераккарак чигенгәндәй булды. Кинәт аңа ямансу, искиткеч ямансу булып китте. Үзенең бу сүзләре белән Гаяр күңеленә яңа яралар салуын чамалый иде ул. Тик барыбер тыела алмады. Берничә минут дәшмичә ятты һәм барыберлек чаткылары кабынганны белгән килеш дәвам итте:

— Озакламый без шәһәрнең җир тетрәүдән исән калган иске өлешендә аерым бер куыш таптык — күчендек. Эч серләрен уртаклашып яшәгән дус кызларымнан шулай итеп җиңел генә аерылдым, бөтен барлыгым белән бары тик аныкы, аныкы гына булып яши башладым... Күкрәк астымда җиденче ай инде Таңсылуымның тибешен тоеп йөри идем. Әти буласы кеше язылышу турында ник бер сүз кузгатсын. Баштарак берничә тапкыр әйтеп карадым каравын, ләкин аның көчле ихтыярына буйсынып, ул сүзләремне оныта килдем... Ул чагында инде аның ниндидер караңгы эшләр белән яшәвен, берсеннән-берсе шиклерәк кешеләр белән аралашуын аңлаган идем. Кызганычка каршы, күзем ачылмаган иде әле. Минем «бердәнберем»нең кыргый җанвар икәнлеген, аның кансызлыгын соңрак аңладым...

«Мин урамда бала күтәреп йөрергә, аның һәм синең капризларына карап яшәргә җыенмыйм. Син миңа башкаларга караганда җылырак һәм темпераментлырак хатын булганың өчен кирәк. Син баланны юк итәргә тиешсең. Югыйсә...» — дип янады ул көннәрнең берендә.

Бу минутларда Гаяр хәрәкәтсез калып, җансыз күзләрен бакчадагы карагайларга төбәп торды. Аның күңелен әллә нәрсә телгәли, җанын үлем суыгыдай салкынлык өшетеп тора иде. Гөлфирәнең сүзләре аның тәненә көтмәгәндә яуган бозлы яңгыр булып бәрелә, ләкин ул боларны тоймый, бөтенләй тоймый иде. Кайсыдыр бер мизгелдә аның башында: «Китәргә, хәзер үк чыгып китәргә моннан!» — дигән уй чаткысы да күренде. Шул мизгелдә Гаяр инде урыныннан кузгала да башлаган иде, әмма икенче мизгел Гөлфирәнең әрнүле сүзләрен аермачык ишеттерде һәм аны баскан урынына кадаклап куйгандай итте. Ул тораташ хәленнән айнырга тырышып, ләкин ихтыярының иң соңгы яшерен көчләрен җыеп:

— Әйе, Гөлфирә, мин тыңлыйм, тыңлыйм мин сине... — диде.

Гөлфирә сүзен дәвам итте:

— Минем Ташкентларга барып тапкан бәхет кошым, шулай итеп, кара карга баласы булып чыкты, Гаяр... Яшәгән куышыбызга тентү белән кергәч, аннары мине тиешле урынга чакыртып сорау ала башлагач кына белдем: минем «бердәнберем» кеше йортларын басучы караклар арасында булган икән...

Аны, ун елга ябарга хөкем итеп, ерак җирләргә җибәрделәр. Ләкин мин аңа инде, бер күрешүебез вакытында, беркайчан да бергә яшәмәячәгебезне, аны күрергә дә теләмәвем турында әйтеп өлгердем... Озакламый Таңсылуым туды. Ул бераз тернәкләнгәч, аягына баса башлагач, Чаллыярга кайтып төштем, синең буяучылар звеносына җибәрүләрен сорадым... Калганы сиңа беркадәр билгеле инде...

Шулай дип әйтеп бетерә алмады, әлегә кадәр бар түземлеген туплап эчендәгеләрне бушаткан Гөлфирә сулкылдап-сулкылдап елый башлады.

Тораташтай утырган Гаяр аны юатырга уйламады. Хәер, каршында яшьлек кайнарлыгын шулай әрәм иткән, яратып, хыялында йөрткән Гөлфирә булуга карамастан, нәрсә әйтә, аны нинди сүзләр белән юата ала иде соң ул?

Алар караңгы бүлмәдә озак утырдылар. Гөлфирә сулкылдавыннан туктады. Гаярның да җаны баягы боз яңгырыннан арына башлаган иде.

Ниһаять, Гөлфирә телгә килде.

— Бар инде, Гаяр, кайт... — диде ул. — Сиңа бары тик бер үтенечем бар: Таңсылуымны күзеңнән югалтма, ярме? Минем әнкәйнең үз хәле хәл... Озак яшәмәс дип куркам.

Гөлфирә теләгенә сүзсез буйсынып, Гаяр урыныннан күтәрелде, сул як җилкәсеннән шуып төшкән ак халатны челеп алырга кирәклеген дә онытып, ишеккә таба кузгалды...

## 2

Нурлыбикә курчак өе сыман бәләкәй, ләкин ярыйсы гына зур мансардлы өйнең киң, аскы өлеше челтәрләп-челтәрләп эшләнгән балконына чыгып басты, тирә-якны колак салып тыңлап карады.

Магнитофон янсә радиоприемниктанмы, карлыга төшкән тавыш белән чит ил җырчысының җырлавы ишетелә. Ул тынып торган арада кызларның ачы тавыш белән чырылдаганы кичке тынлыкны урталай ергандай итә.

Нурлыбикә табигатьнең бирелгән сәерлекләренә иялашеп бетмәгән иде, шуңа күрә урамнан ишетелгән тавышларга шикләнебрәк балкон

киртәсе янына барыйммы-юкмы дигән төсле генә атлап барды. Култыксаларга тотынгач, башын тышкы якка таба сузып, бакчадагы агачлардан килгән саф һаваны күкрәге тулганчы сулап куйды. Кичке салкынча һава шундый рәхәт, шундый татлы иде ки, Нурлыбикә ирексездән күзләрен йомып озак кына ачмыйча торды һәм, тагын бер сәерлек — караңгылыкны ярып, таулар артыннан ялтырап ай чыкканны, таулар итәгендәге бакчаларны берьюлы яктыртып җибәргәнне күрмичә калды.

Күзләрен ачып, бакчадагы агачлар арасыннан килгән сукмакка таба карася, Нурлыбикә ни әйтергә белмичә катты да калды. Шик юк, бакчадан ишегалдына — верандага таба кызыл кырпулы фуражка кигән ике кеше һәм тагын берничә штатский костюмлы якынлашып килә иде.

Ерактагы музыка, артистның карлыккан тавышы, хәтта кызларның чырылдашуы да көтмәгәндә тынып, югалып калгандай булды. Нишләптер Нурлыбикәнең әле генә саф, салкынча, хуш исле һава тулган күкрәкләрен тимер кыршау ураган шикелле булды, тыны кысылды, йөрәге сыкрап-сыкрап үзалдына дуларга, читлеген җимереп чыгарга теләгәндәй бәргәләнергә кереште.

Нурлыбикә балкон пәрдәсе артына яшеренә төште. Ул арада керүчеләр инде веранда болдырына менеп тупланганнар иде. Нурлыбикә яшеренгән җиреннән чыга төшебрәк, җентекләбрәк карады да, инстинктның ниндидер бер кылы тартылып куйганга күрәдер инде, куллары белән балкон кырыннан этелеп артка чигенде.

Ләкин аны күреп алганнар иде инде. Болдырдагылар арасыннан берәү тәбәнәк рәшәткәләр аша атлап чыкты да балкон турынарак килеп:

— Кем бар анда, хәзер үк ачыгыз, ишетәсезме?— диде.

Нурлыбикә артка чигенеп барган җиреннән балконның кыл урта бер төшендә басып калды. Тыны бетте — аны сизмәде, чигәләренә ниндер кадалгандай булды — кымшанмады: ничек туктап калса, шул халәтендә тора бирде.

— Ачыгыз. Без бит күрдек сезне, ачыгыз — милиция!

Нурлыбикә нишләргә белмичә аптырап торуын дәвам итте. Күпме шулай торган булыр иде, баш очындагы кыңгырау зеңгелдәве аны чынбарлыкка кайтарды. «Ачарга кирәк, алар барыбер керәләр бит инде... Я ходаем, нәрсәдән генә бу кадәр куркам соң әле мин? Минем нинди гаебем бар? Бер гаебем дә юк ләбаса».

Килүчеләр алтау иде. Алдан кергәне, милиция киемендәгеләрнең берсе, башкаларны берәм-берәм уздырып җибәрде, Нурлыбикәнең затлы халаты астыннан бер күтәрелеп, бер төшеп торган күкрәгенә, сылулыгын югалтмаган гәүдәсенә карап алганнан соң, үзе дә сизмичә билендәге каешын төзәтеп куйды, фуражкасын арткарак җибәрде һәм, ниһаять, ни өчен кергәнен исенә төшереп булса кирәк:

— Сез кем буласыз, матурым? Монда ничек килеп эләктегез?— диде.

Ул арада килүчеләр бүлмәгә кереп беткәннәр иде инде. Нурлыбикә дә милиционерның сорауларына җавап биреп тормыйча, җай гына борылып, өй эченә кереп китте.

Бүлмәдәгеләрнең барысы берьюлы аңа таба карады. Ул исә дәшмитынмый гына түргә узды, зур көзге өстәлендәге затлы сумкасын ачып, үзенең паспортын алды.

Милиционер паспортның беренче битен ачып карады, Нурлыбикәгә күз йөгертеп узды.

— Аңлашылды, сез Нурлыбикә Сәфәрова буласыз икән?

— Моннан берничә ай элек Сәфәрова идем, хәзер Атнабаева мин,— диде Нурлыбикә.

— Ләкин бу йортка сез ничек килеп эләктегез? Хуҗа кеше үзе кая югалды әле?

Нурлыбикә ни өчендер тәнендә жиңелчә калтырау тойды, әйтерсең, ул бирегә ярамаган эш эшләргә кергән дә шул эш вакытында аның кулыннан тотып алганнар иде.

— Мин... мин... йорт хужасының... Эдикның хатыны булам, шуңа күрә монда торам...

Милиционер һәм аның белән керүчеләрнең дә моңа исе китмәде, чөнки алар өчен бу инде яңалык түгел.

— Сез аны иптәшегез буларак беләсездер, ләкин аның бүтән паспортлары һәм фамилияләре бар. Балаян бу көннәрдә сезнең янда булдымы-юкмы?

Башкалар тавыш-тынсыз гына өй эчендәге әйберләрне күзәтәләр иде. Арадан берсе, тәрәзәгә якынрагы, урыныннан торып, беркадәр ачык калган пәрдәне яхшылап томалап килде, кабат үз урынына утырды.

— Эдикның командировкага киткәненә ике атна инде. Ничек итеп ул өйдә булсын икән?— диде сорауга сорау белән Нурлыбикә.

Тегеләрнең йөзеннән сизелер-сизелмәс кенә елмаю әсәре чагылып үтте.

Нурлыбикә чит кешеләрнең үз өенә кереп килделе-киттеле, мыскыллы сораулар бирүенә бөтен тәне-жаны белән каршы иде. Тегеләрне пырылдатып чыгарасы килде аның, ләкин баскан жиреннән селкенми, нидер көтә, кыюлыгын жыя алмый иде. Дөрес анысы, әгәр дә мәгәр аның Чаллыярдагы квартирасына шулай килеп керсәләр... ул бөтен шәһәрнең астын өскә әйләндерер, ни хакыгыз бар, тиешле кәгазьләрегез кая, күрсәтегез, дияр иде.

Ниһаять, штатский киемнән утырганы торып басты һәм Нурлыбикәгә ниндидер кәгазь кисәген сузды.

— Менә бу, гражданка Атнабаева, алып-сатар [1] Эдик Гайниев-Балаянның дача йортында тентү ясарга рөхсәт кәгазе. Сез каршы килмәсәгез, бүлмәләрне карый башлар идек,— диде, үзенә күрә бер ләззәт белән Нурлыбикәнең күзләренә төбәлеп.

Бу хәбәр Нурлыбикәнең яңагына суккан сыманрак ишетелде. Ул инде бу кешеләрнең бер дә юкка гына килмәгәнлекләрен аңлый, ләкин мондый хәл белән килешеп бетә алмый, килешергә, шундый көннең киләсенә ышанырга теләми иде.

— Ярый, алайса, тентегез, кирәк булгач,— диде ул, үз-үзен көчкә хәлгә тыеп.— Тентегез соң, нәмәрсә табарсыз икән, һәммәсе дә күз алдыгызда.

Нурлыбикә бу урында ниндидер өстенлек, канәгатьләнү тойгысы белән әйтте, кулларын бүлмә эченә таба ишарәләп алды.

— Ярый, башлыйбыз, иптәшләр. Караян, Саркисян иптәш, пүнәтәйне алыгыз да икенче катны карап чыгыгыз...

Шул чагында гына Нурлыбикәнең аңын ярып бер уй узды, һәм ул тавышын югалткан кеше шикелле пышылдабрак сорады.

— Ә минем ир... ирем... кайда соң? Сездәме ул? Сез аны кулга алдыгызмы әллә? Ни өчен? Ни хак...

Соңгы сүз ярты юлда тамак төбенә тыгылып калды. Икенче катны тентергә менүчеләрнең берсе:

— Иптәш капитан, бире килегез әле, пожалуйста,— диде.

Өстәл янында боерык биреп утырган кеше урыннан күтәрелде, икенче катка алып менә торган баскыч янына килде. Өстән такта каерганнары ишетелде. Нурлыбикә сискәнеп китте, тизрәк икенче катка алып менә торган баскычка ашыкты.

Башта берни күрмәде, аңламады ул, әмма якынрак килеп, тентүчеләр чүгәләгән төшкә карасә... Үз күзләренә үзе ышанмады: суыткыч тора торган урынның идән паркеты куптарып ташланган, анда тигез

[1] Алып-сатар — спекулянт.



*Тавил Хаҗиәхмәтов рәсеме*

рәтләргә тезелгән акча бәйләмнәре ята иде! Нурлыбикә күзләрен тагы да ачыбрак, текәлебрәк карады: юк, ялгышу һич мөмкин түгел.

Ул арада пүнәтәйләр әлеге акчаларны берәм-берәм алып санарга керештеләр. Идәндә егерме биш, илле һәм ун сумлык купюр төргәкләре аралашып, тәгәрәшеп ята башладылар. Ләкин көтелмәгән ачышлар моның белән генә бетәсе булмаган икән әле.

Тентүчеләрнең берсе ике тәрәзә арасына куелган китап киштәсен тегеләй-болай төрткәләп караганнан соң әллә кай төшенә генә баскан иде... Китап киштәсе салмак кына, тавыш-тынсыз гына ачылып китте. Һәм... стенадагы җыйнак киштәләргә тезеп-тезеп куелган затлы нәрсәләр: алтын алкалар, балдаклар һәм тагын Нурлыбикә үз гомерендә дә күрмәгән бизәнү әйберләре, иң астагы киштәдә озынчарак китап сыман тартмачыклар күренде.

«Алтын» дигән сүз Нурлыбикәнең колак төбендә генә ишетелеп китте. Ләкин ул инде аның чын мәгънәсен төшенеп өлгерә алмады, күз аллары тик торганда сыек томанга уралды. Ул да түгел, аның гәүдәсе каядыр еракка-еракка, билгесез сәер чокырга таба салмак кына очарга кереште.

Күзләрен ачып җибәргәндә, тентүчеләр барысы да икенче катка тупланганнар, табылган әйберләрне тәртипләп кенә чемоданнарга тутыралар иде инде. Өлкәннәре, капитан дигәннәре, чемоданнарга сургыч салды, өстенә бәләкәй генә тимер пичәтен басты, иптәшләренә бүлмәләрне тиешле тәртипкә китерергә кушты, үзе китап киштәсен ябып, электерәсе җирен электереп куйды, урындыкларны ничек торган булса шул урыннарына тезеп чыкты. Нурлыбикәнең күзләрен ачып күзәтеп ятканын күргәч тә:

— Менә әйбәт, гражданка Атнабаева, хәлегез җиңеләйде бугай?— диде.

— Кайгыртуыгыз өчен рәхмәт...

— Алай булса, хәлегез җиңеләйсә дип әйтүем, җыеныгыз, бераздан китәрбез.

— Китәбез? Ничек китәбез? Кая?

— Юк, без сезне кулга алмыйбыз, гражданка Атнабаева, кайбер рәсми кәгазьләрне тиешле урынга барып тутыру һәм сезнең белән мөмкин кадәр ачыграк сөйләшеп алырга кирәк безгә.

— Ничек? Ничек инде китәбез? Кәгазьләрне биредә генә тутырып, монда гына сөйләшеп булмыймыни соң? Эдикның да кайтып керүе ихтимал...— дип куйды Нурлыбикә, үз сүзләренә үзе дә ышанмыйча, бары тик нәрсә дә булса әйтү теләге белән генә.

Бу юлы инде капитан ирен читләре белән генә елмаймыйча булдыра алмады бугай, Нурлыбикә дә моны күреп алды.

— Эдик Балаян-Гайниев инде бу куышка тиз генә кайта алмас, гражданка Атнабаева, һәм сезнең дә кайтуыгыз икеле. Чөнки бу дача бүгеннән соң инде алып-сатар гражданин Балаянныкы булмаячак,— диде капитан, җитди итеп.— Без сезне, һичшиксез, очраштырырбыз, бер дә шикләнмәгез...

Капитан үзенең ак төймәләр шикелле тезелеп киткән таза тешләрен күрсәтеп, гаепле кеше сыманрак елмаеп җибәрде.

Нурлыбикә, һушына килеп, диванга ничек торып утырган булса, шул хәлендә ни үле, ни тере бер халәттә утыра бирде. Аның күкрәген аңлашылып та бетмәгән ачулы бер үкенү хисе кысып-кысып алды.

«Ахмак, чеп-чи ахмак мин!»— дигән искиткеч бер чынлык хәзер инде аның өчен әллә кайдагы хакыйкать түгел иде.

Нурлыбикә, куллары белән диванга тотынып, кискен генә күтәрелде, әмма хәзерге минутта нәрсә эшләргә тиеш икәнлеген исенә төшерә алмыйча басып тора бирде. Акча һәм зиннәтле нәрсәләр тутырылган

чемоданны тоткан яшь милиционер идән паркетын шыгырдатып беренче катка төшә башлады.

«Нишләп торам соң мин? Нәрсә эшләргә куштылар соң әле миңа? Ходаем, башыма берәр нәрсә булмагае... Әйе, киенергә куштылар бугай...— Шушы уйлар белән Нурлыбикә кинәт бер карарга килгән кеше кебек баскычка таба ике-өч адым атлады.— Һай, ахмак, һай юләр, һай чүпрәк баш бит мин...»

Баскычның беренче басмасына аягын куйган мизгелдә урамдагы музыка авазлары аермачык булып ишетелә башлады. Алар белән бергә, күңеленең кайсы гына бер тартмасында яшеренеп яткан булгандыр, Нурлыбикәнең күз алдын Чаллыярдагы төзелешнең иң кызу көннәрендә кызлар белән көлешә-көлешә эшләп йөргән чаклары, аның да ни өчендер моңарчы бер генә тапкыр да үзен белгертмәгән бер чагы томалап алды.

...Чаллыярдагы төзелешкә Нурлыбикә теләр-теләмәс кенә диярлек, авылдаш кызларына ияреп килде. Әмма барыбер аның күңелендә әйтелмәгән, әлегәчә сизелмәгән ниндидер бер тойгы бар иде. Аларны техник училищега укырга җибәрделәр. Хәер, алар ул чакларда укудан битәр эш мәйданнарында күбрәк булдылар. Яшьләрнең дистәләп кенә түгел, йөзәрләп-йөзәрләп килгән көннәре булса да, кеше җитми иде.

Басу уртасында салына башлаган шәһәр көнләп түгел, сәгатьләп үсә. Тирә-юньдә ямь-яшел басу, сирәк-мирәк утырган агачлар арасында сансыз-хисапсыз машиналар ыгы-зыгы килә. Кешеләр бөтенләй юк сыман. Өстән, Нурлыбикәләр эшли торган яңа йортның тугызынчы кат тәрәзәләреннән аска карасаң, төзелештә нишләптер бары тик машиналар да төрле-төрле тракторлар гына арлы-бирле йөри һәм борынгы даланы шәфкатьсез кыздыручы кояш кына күк йөзенең иксез-чиксез зәңгәрлегендә йөзә шикелле иде.

Шундый гадәти көннәрнең берсендә бригадирлары Мәрфуга апа Нурлыбикә белән Люция исемле кызны монтажчылар бригадасы ял итә торган вагонның эчендәге обойны алыштырырга җибәрде.

Алар барып кергәндә, вагонда кеше-кара юк, бөтен нәрсә ишегалдына чыгарылган һәм ачык һавадагы өстәлләр янында монтажчылар бригадасының планерка кебегрәк утырышы бара иде. Кызлар озын-озак мавыгып тормастан, үзләре алып килгән обойны ябыштырырга хәстәрләнә дә башладылар. Дөрес, ул арада планерка тәмамланды, монтажчылар бригадиры белән Мәрфуга апалары кереп обойларны караштырып киттеләр. Бригадир аны-моны әйтмәде, Мәрфуга апа кызларына:

— Ябыштырыгыз,— дип әмер бирде дә китеп барды. Кызлар эшкә керештеләр.

Бригадир, каратутрак йөзле, башкалардагы шикелле үк киҗемамык эш киеме, башына озынчарак каска кигән егет, алар эшләгән арада шулай да бернichә тапкыр вагон янына килеп китте. Ләкин кызлар эшенә илтифат итмәгән сыман уза бирде. Нурлыбикә:

— Ай-һай, җитди егет бу, уйнап-көлеп бер-ике сүз әйтсә, ни була?— дип төрттереп куйды.

Эшләре төгәлләнеп килә иде инде, иң соңгы буйга ябыштырырга дигән обой бернichә төштән ертылган булып чыкты. Җыйнак, озынча вагонның матурлыгын бетереп ертык обой ябыштырмассың бит инде. Нурлыбикә иптәш кызы Люцияне (ул чагында ук инде иптәшләренә боерык бирергә, тегесен-монысын кушарга ярата иде ул) үзләре эшли торган подъезддагы вакытлы складка обой алырга җибәрде. Ә үзе соңгы буйның өске өлешенә ябышкан известь кисәкләрен кырып, чистартырга керешә. Һәм, югарыга үрелеп эшләү белән мавыгып, үзе баскан буяу мичкәсенең янтаеп китканен сизеп өлгерә алмыйча вагон идәненә егылып төште. Тиз генә сикереп тормакчы, яңадан эшкә тотынмакчы иде ул. Кулларына таянып, идәннән күтәрелә дә башлады, аягына басам

дигәндә авыртуга түзә алмыйча кычкырып ук җибәрде, тагын идәнгә ауды.

Шулвакыт, нинди йомышы төшкәндер, вагонга монтажчылар бригадиры Сәфәров килеп керде. Нурлыбикә идәндә утырган килеш астан өскә таба аңа карады. Сәер, ләкин нәкъ шушы ноктадан карау кирәк булган икән бу егеткә. Аның җилбәгәй җибәргән пиджаге ачылган, киң күкрәгенә, каска астыннан чыгып, беркадәр бөдрәләнеп чәбәләнгән кара чәчләренә, зирәк, әмма тыныч, ышандыргыч күзләренә карап торган Нурлыбикә шул мизгелдә очып китәргә әзерләнгән бөркеткә охшаш егетне күрде. «Моңарчы сине ничек күрмәдем соң мин?» дигән уй тиз генә ялтырап алды.

— Нәрсә, нәрсә булды сиңа, нишләдең?— диде егет, бу хәлгә беразаптырап.

— Егылдым...

Егет тә ирексездән Нурлыбикә кебек сузыбрак:

— Егылдың?..— диде.— Имгәнмәгәнсең бит?

— Белмим.

— Нишләп тормыйсың?

— Аяк... аягым...— диде кыз һәм торырга омтылыш ясап карады, көчле авыртудан ыңгырашып, яңадан идәнгә сыгылып төште.

Егет шундук Нурлыбикә янына килде, иелеп аның кулыннан тотып торырга булыша башлады.

— Әйдәле, әйдә акрын гына кузгалабыз.

Нурлыбикә торып баса алмады, аһ та ваһ килде.

Бригадир беркадәр бөгелә төште һәм, көтмәгәндә, Нурлыбикә каядыр югарыга менеп китте. Ул да түгел, аның маңгае егетнең чәнечкеле иягенә тиеп-тиеп алды.

— Кирәкми, кирәкми... төшерегез... үзем,— диде кыз пешкән алмадай кызарып, ләкин килешүчән йомшак тавыш белән.

Тагын беравыктан инде кыз егетнең көчле кулларында салмак кына тирбәлеп бара, аягының авыртуы да бөтенләй диярлек онытылган, бары тик күңеленең әллә кайдагы кылларын рәхәт бер нәрсә кытыклап-кытыклап ала иде.

Дача йортының беренче катында Нурлыбикәне тагын да гаҗәбрәк хәл көткән икән: биредәге өсталдә, урындыклар өстендә тау-тау булып пөхтә өемнәргә өелгән джинсы костюмнар, төрле рәсемнәр төшерелгән футболка-күлмәкләр һәм тагын шуның ише әйберләр ята иде. Нурлыбикә исе китеп басып калды. Бу шулкадәр көтелмәгәндә булды ки, аның артыннан төшеп килүче капитан, туктап өлгерә алмыйча, хатынның аркасына килеп төртелде. Әмма югалып калмады, тиз генә:

— Гафу итегез, гражданка Атнабаева,— диде.— Сезнең бу әйберләрне күргәнегез, аларның кай төштә сакланганнарын дип әйтүем, бар идеме?

Нурлыбикә өсте-өстенә ябырылган хәлләрдән айнырга өлгермәгән иде әле, шуңа күрә баштарак әлеге сүзләрнең мәгънәсе аңа барып та җитмәде. Ул ирексездән диярлек:

— Белмим, минем бу кадәр нәрсәләрне беренче тапкыр күрүем,— дип әйтерлек көч тапты, аякларының хәле беткәнне, йөрәге каушап, еш-еш тибә башлаганны сизгән Нурлыбикә өстәл янындагы бер урындыкта өелеп яткан джинсыларны шудырып төшерде дә «лып» итеп шунда утырды.

## 3

Гөлфирә соңгы атнаны тоташ саташу эчендә диярлек яшәде. Кызганычка каршы, эчендәге серләрен актарып салгач та ул көткән бушану килмәде, киресенчә, аңа көнләп түгел, сәгатьләп кыенлаша барды. Күк-

рәгенә тулган үкенү тормышын үзе теләгәнчә матур итеп уздыра алмаудан түгел, бәлки Гаярның үзенә карата шундый матур, еллар буена сүнмичә-сүрелмичә саклаган хисләрен кайчандыр аяк астына салып таптавыннан иде. Ул тойгы кимемәде, Чаллыярдагы ГЭС буасына бәрелеп тулган агымсу шикелле һаман тула бирде. Үзенең дә Гаяр күңелендәге тыйнак мәхәббәткә битараф булмавын, ничә еллар буе аны кайтып-кайтып уйлавын, аерата кыен минутларда, аны сагынып яшәвен, ләкин язмыш шаяруының аны гел «кара көнгә» саклап килүең аңлады ул.

Шушы бер атна эчендә кичергән кичерешләрдәнме, әллә бүтәнчәме, әмма Гөлфирә күзгә күренеп үзгәрә башлады. Ярыйсы гына ябыгуы, чандырлануы өстенә, аның карашы элеккегечә яндырып-яндырып ала торганнан салмак, ләкин үтәдән-үтә күрә торганга әверелде.

Гөлфирә инде больницадан чыгасы көнен түземсезләнеп көтә иде. Аның өчен иң шатлыклысы, тәнендәге яралар төзәлүдән битәр, «йөрәк янганны бастыра торган» тәмәке исен өнәми башлавы иде.

Бу көннәрдә сөекле Таңсылуы һәм Көмеш Аланга килгәч тә дуслашып киткән Карлыгач аның янында берничә тапкыр булып, Калатаудагы хәлләрне бәйнә-бәйнә сөйләп киттеләр.

Бу көннәрдә кояш бик сирәк күренде һәм ул әледән-әле килеп яуган яңгыр болытлары арасыннан әллә нигә бер тапкыр, тансыкка гына чыгып алгалады.

Шушы көннәрдә Гөлфирә үзенә җан сердәше тапты. Ул — Санук апа иде. Баштарак, тормышка ярыйсы гына ачуы кабарган, җитмәсә күнегелгән гадәтеннән аерылырга дучар булган Гөлфирә кырыс йөзле керәшен хатынын яратып бетермәде. Кашларын кызык сикертеп алучы, өлкән яшьтә булуга карамастан, өч кешегә җитәрлек өлгерлеге, эшкә атлыгып торуы белән больницадагы барлык нянялардан да аерылып торган Санук апа үзенә беркетелгән әле бер, әле икенче палатага барып керә, авыруларның йомышларын үти, шуның өстенә кичә генә бер бөртек тузан калдырмыйча юып-сөртеп чыккан стеналарны, тәрәзә пыялаларын тагын бер кат сөртә, авырулар соравы буенча кибетләргә чыга, кыскасы, көне буена ярты минут та утырып тормый иде.

Тормышның түмен белеп, җаена төшенеп, җил-яңгырларына әлекмичә генә яши сыман тоелды Гөлфирәгә Санук апа. Шуңадырмы, палатадагыларның «Санук апа» да «Санук апа» дип өзгәләнүләре аның ачуын китерде һәм ул аңа вак-төяк сәбәп табып бәйләнергә, аның белән әрепләшергә, әрләшергә җай эзли башлады. Бервакыт карават һәм тумбочка астындагы тузаннарны сөрткәндә Санук апа җайсызрак борылды бугай, Гөлфирәнең чәй тулы стаканы авып китте, түгелде.

— Йөрисең шунда буталып, пенсияң генә җитмимени сиңа,— дип ярсып ук китте Гөлфирә, юк сәбәпне бар итеп.

Сынган җирләрен ялгап-ябыштырып, канга баткан өс-башын да алыштырмыйча палатага кертеп салганнан бирле аңа үзенең җан жылысын биреп, һәр теләген үтәп, сызлану-сыкрауларны үзенә алырдай булып, баласыдай якын күреп караган кешедән шундый сүзләрне ишеткән Санук апа бермәлгә катты да калды, ни әйтергә белмәде. Билгеле, әгәр дә ул моңарчы хаксызга кыерсыту-җәберләүләрне кичермәгән, кыен чакта кеше күңеленең агачка әверелеп калганын белмәсә, бәлки, Гөлфирәнең әлеге усал сүзләренә рәнҗегән, кирәген әйтеп чыгып та киткән булыр иде. Ләкин... Санук апа — башыннан үткәннәрне, үзе кичергәннәрне «Ходаем, дошманыма да күрсәтмәсен!»— дип яшәүче кеше, аның күңеле киң... Бу юлы да дәшмәде, бары тик ирексез чыга башлаган күз яшьләрен акбүз яулыгы читенә сөртеп-сөртеп алды да ишеккә юнәлде.

Берничә минуттан Гөлфирәнең күңелендә кабарган нәфрәт сүрелә төште һәм ул Санук апаны хаксызга рәнҗетүен җаны-тәне белән сиз-

де. Шулай булса да, ниндидер тискәрелек аның телен бәйләде, гафу үтенергә кушмады.

Аңа карап кына Санук апа үз вазифаларына карашын үзгәртмәде, тиешле вакытта идәннәрне юды, тәрәзәләрне сөртте. Гөлфирәгә «йомыш» төшсә, минуты белән янына килеп басты. Тик хәзер инде аның телендәге ягымлы сүзләр юкка чыкты, күзләре элеккечә җылылык, аналарда гына була торган нур сибеп карамады. Гөлфирә янына килүчеләргә, бигрәк тә Таңсылу белән Карлыгачка, аннары Гаяргә да ягымлы булды, яңалыкларны житкерде, вакыты туры килү-килмәүгә карамыйча палатага кертте, кычкырмады. «Ул шундый!»— дип авызын да ачмады. Гөлфирәнең ярыйсы гына ачы язмыш кешесе икәнлеген йөрәгенең сизгер тамырлары аша ачыклап белгән иде инде ул.

Гөлфирәнең, үзе килеп керүгә, кызарып сүзсез калуын, ул теге көнне әйткән сүзләрнең ирексез генә ычкынуын да күреп йөрде Санук апа.

Беркөнне Санук апа Гөлфирә бүлмәсендә ничектер аерата озак кайнашты. Юган тәрәзәләрне кабат сөртте, караватт тимерләрендәге юк тузаннарны алды, идәннәрне югач, тумбочка эчен тәртипкә китерергә тотынды.

— Житәр инде сиңа, Санук апа, күпме эшләргә була? Нигә соң шулкадәр ватыласың? Сиңа гына бөтен эшне эшләп бетерергә димәгәндер бит,— диде Гөлфирә, Санук апаны кызганып. Бу аның теге тупаслыгы өчен үзенчә гафу үтенүе иде.

— Нишлим соң, матурым, Гөлфирә? Пенсиядәге кеше булсам да, кулымда көчем, күкрәгемдә жаным бар чакта кешеләргә яхшылык кыласым килә. Сугыш... сугыш вакытында шундый нәзер әйткән идем...— диде Санук апа Гөлфирә белән ике арада берни булмагандай.

— Соң бит, Санук апа, сугыш вакытында да ялсыз-нисез көне-төне эшләмәгәннәрдер инде.— Гөлфирә Санук апага туры карарга кыймый иде.

— Эшләгән кешегә, бигрәк тә хатын-кызга, кызым, эш һәрвакыт житәрлек. Мин сугыш вакытында... матурым... нәзер...

Санук апа башлаган жөмләсен дәвам итә алмыйча тотлыгып-тотлыгып алды һәм һич көтмәгәндә елап жибәрде.

— Ходаем күрсәтмәсен генә, без күргәннәрне күрсәтмәсен генә, күрсәтмәсен генә...— дип кабатларга керешге ул, ак яулыгын башыннан алып күзләрен сөртә-сөртә.

Гөлфирә Санук апаны бу халдә күреп аптырап калды. Гадәттә Санук апа үзе авырту-сызлаулардан әрнеп елаучыларны юата, алар күңеленә өмет чаткылары сибә иде. Гөлфирә хатын-кызларга хас тапкырлык белән шушы очракта гына әйтелергә тиешле сүзләрне эзләп карады. Тапмады. Күрәсең, кешене сүз белән юатып булмый торган вакытлар да була торгандыр. Гөлфирә сау кулы белән үрелеп, Санук апаны кочаклап алды һәм... үзе дә аңа кушылып елап жибәрде. Ахрысы, сүзләр түгел, әнә шушы күз яшьләре Гөлфирә әйтергә теләгәннәрне Санук апа йөрәгенә житкергән дә, алар арасындагы кылларны тибрәткәндер...

## 4

31 август, Көмеш Алан,
иртәнге 6 сәг. 30 мин.

Быелгы жәйнең соңгы көне житте. Кама өстеннән акрын гына аксыл томан күтәрелеп килә. Калатауның түбәсенә таба үрмәли-үрмәли дә, менеп житә алмасына ышангач, кинәт борылып, безнең төзелеш өстенә ябырыла һәм ерактагы урман ягына таба китеп бара.

Ура! Бүген без беренче жиңүне бәйрәм итәбез. Дөрес, ул Чаллылардагы жиңүләр белән чагыштырганда, бәлки, алла ни зур да түгелдер. Нибары өч катлы бер бинаны, мәктәп һәм авыл советы, медпункт, почта

урнашкан бинаны файдалануга тапшырабыз. Бүген мәктәпне ачу тантанасы була.

Болар әле беренче карлыгач кына. Озакламый бирелә үзенең ак йортлары, төз һәм иркен урамнары, культура сарае һәм башка корылмалары белән тулы бер шәһәр калкып чыгар. Әнә тегендәге үрләр артында Татарстан атом электр станциясенең реакторлары — тынычлыкка, халыкка хезмәт итә башлар!

Турысын әйткәндә, моннан нибары алты көн элек кенә минем күңелдә: «Өлгертә алмабыз»,— дигән шөбһәле уй ярала башлаган иде. Ул теге көнне, хатын-кызлар бригадасы Чаллыярга китәбез дип автобуска кереп утырганны күргәч тә булды. Бәхеткә каршы, шикләнүем берничә минут кына дәвам итте.

Берничә минут кына... Шулаен шулай, әмма минем өчен ул минутларның һәркайсы тулы бер көнгә торырлык булды. Ул вакыйга миңа кешеләргә карата, бигрәк тә хатын-кызларга карата, мөнәсәбәтемне үзгәртергә кирәклеген аңлатты. Гомумән, әгәр дә мәгәр шушы төзелешне уңышлы башлап җибәрергә һәм үземә күрсәтелгән ышанычны акларга телим, куелган бурычны җиренә җиткереп, үзебезнең Көмеш Аланны хыялдан чынбарлыкка әверелдерәсем килә икән, кешеләр турында, бигрәк тә хатын-кызлар турында күбрәк кайгыртырга кирәк. Бу — закон.

Төзелешкә килә торган хатыннарның һәркайсы — үзе бер язмыш. Әле кичә генә мәктәп бинасы янында мине унсигез-егерме яшьләрдәге бер хатын-кыз:

— Сәфәров сез буласызмы?— дип, каршыма чыгып туктатты.

— Әйе, ачуланмасагыз, мин булам,— дип шаяртып дәшкән идем, шул ук минутта үзгәрергә туры килде. Әлеге хатын-кызның чырае шундый чытылган, шундый әрнүле иде ки, мин ирексездән хәлне төзәтергә:

— Әйе, мин Сәфәров,— дияргә мәҗбүр булдым.

— Мине, иптәш Сәфәров абый, эшкә алыгыз әле. Мин бишенче разрядлы буяучы-штукатур,— диде ул кәгазьләрен сузып.— Андый кешеләр сезгә бик кирәк икән бит...

— Әйе, безгә андый кешеләр бик кирәк,— дидем мин.— Ә сез ни өчен соң эшкә алмабыз дип уйлыйсыз? Сәбәбен әйтегез әле, ни өчен?

Хатынның күзләрендә усал чаткылар уйнап алды, йөзе кырысланды, шуңа да карамастан, аның йөзендә тартыну билгеләре бетмәгән иде әле. Әмма ул үзен бик тиз кулга алды һәм әйтте:

— Мине эшкә алыгыз, иптәш Сәфәров абый. Мин эшләргә, яңа шәһәр төзешергә телим. Мин инде Усть-Илимда эшләдем һәм начар эшләмәдем. Алыгыз — үкенмәссез.

Миңа бу хатынның сүзләре сәер тоелды.

— Без үзебез әлегә бик аз кешене алабыз, матурым. Төп көчләрне безгә Чаллыярдагы идарәдән җибәрәләр...

Ул солы көлтәсе төсле чәчләрен селкеп җибәрде дә, мине бүлдерде:

— Беренчедән, мин сезгә, иптәш Сәфәров абый, «матурым» түгел. Сезнең матурыгызның кем икәнлеген беләбез. Икенчедән, мин инде Чаллыярда булдым. Анда мине алмадылар...

Баштагы сүзләре белән чәнчеп, бу хатын миндә усалрак бер тойгы уята башлаган иде, әмма аның соңгы сүзләре, аларның беркадәр калтыраныбрак һәм шул ук вакытта өметсезләнебрәк чыгуы мине сагаерта мәҗбүр итте.

— Ярты сәгатьтән участок конторасына керегез,— дидем үзем дә сизмәстән. Минем өчен инде бу хатынның нинди дер кыен хәлгә төшүе аңлашыла иде. «Мөгаен, бала беләндер, иреннән аерылгандыр»,— дип уйлап алдым мин. Дөрестән дә, андыйлар байтак килә иде безгә соңгы вакытта...

Шулай булып чыкты да. Ярты сәгатьтән әлеге хатын минем алда утыра иде инде.

— Исемем Фәния була минем, Гаяр абый,— диде ул, котмәгәндә үз итеп, күкрәк түреннән чыккан йомшак тавыш белән туп-туры карап.— Мине Чаллыярдагылар эшкә алмады. Баланны куярга урын юк, диделәр. Ләкин мин аны кая куйыйм соң, Гаяр абый? Авылга алып кайткан идем, әнкәй өйгә көч-хәл белән кертте, ләкин «Каян табып алсаң, шунда илтеп куй бу баланны»,—диде. Ярый, мин анысы өчен үпкәләмим, чөнки үз ялгышым, әнкәй белән киңәшмичә-нитмичә чыктым мин ул кешегә. Хәер, чыктым дигәч тә... тулай торакта яшәдек, башкалар кебек язылышмыйча гына яшәдек. Мин аның мәхәббәтенә ышанган идем...

Яңарак кына егерме яшен тутырып өлгергән, бая гына аннан да яшьрәк сыман күренгән бу хатынның язмышы, кыска гына вакыт эчендә кичергәннәре мине, турысын әйткәндә, ярыйсы гына дулкынландырды. Мин аны тизрәк тынычландырырга теләп:

— Ярый, Фәния, ярый, болай ук булганын белмәдем бит. Мин сиңа рөхсәт кәгазе язып бирәм, алтынчы вагонның бер бүлмәсе буш булырга тиеш, шунда урнашырсың,— дидем.

Димәк, безгә ашыгыч рәвештә балалар бакчасы төзи башларга, бу мәсьәләне вакытлыча гына түгел, ә төптән уйлап хәл итәргә кирәк булачак.

Кичә Гөлфирә янына кереп чыккан идем. Кәефе болай әйбәт кебек күренә, ләкин аның да күзләрендә теге вакыйгадан соң вакыты белән яндырып-яндырып ала торган моңаю, әрнү бар.

Дөрес, Тансылуны минем Карлыгач белән бергә Чаллыярга озатуымны, анда бер үк мәктәптә укыйсыларын әйткәч тә шөбһәле билгеләр югалгандай булды. Тик бераздан алар кабат әйләнеп кайтты. Ул инде үзе дә моны сиздe бугай.

Озакламый аны больницадан чыгарачаклар, дәвалануы тәгәлләнеп килә...

Нишләргә?

Гөлфирәгә булган тәүге хисләремнең вакытлыча гына көчәюе, төрле сәбәпләр аркасында, ниһаять, үзем кичергән ямьсез хәлнең тәэсиреннән генә түгелме икән?

Юк, алай гына булырга тиеш түгел...

О-оха! Көндәлек белән мавыгып утыра-утыра байтак вакыт узган түгелме соң? Татарча концерт башланды, димәк, сигезенче ярты булган.

Бүген безнең беренче бәйрәмебез. Көмеш Алан өстенә якты, жылы көн килә. Әнә күк йөзе нинди матур, үзе зәңгәр, үзе аяз, кояшлы. Бәлки... безнең беренче бәйрәмебез булганга шулайдыр ул?!

## Жиденче бүлек

### I

Җәйнең соңгы атнасында көннәр бозылыбрак торган иде, сентябрь керү белән һава кинәт алмашынды да куйды. Кояш шундый жылытты, шундый нурлы булып китте ки, сабан туйлары тирәләрендә дә мондый көннәр сирәк күренгән иде. Игеннәрдән арынгач та көзне жилнең юка иреннәре кебек кипшенеп ярғаланган басулар рәшәле үрмәкүч жепләре белән ялтырап тора башлады. Тынычланып калган агачлар, табигатьнең мең еллар буена килгән таләбенә буйсынып, саргайган яфракларын жиргә коярга керештеләр.

Озак еллар дәвамында искиткеч күп төрле һәм катлаулы проблемаларны үз жилкәсенә йөкләп барган кеше, табигый ки, тормыш мәшәкатьләренә күмелә дә вакыт агышын тоймый башлый.

Вергилий Никифорович әнә шундыйларның берсе иде. Ул иртә таңнан алып кара төнгә кадәр эш мәшәкатьләренә чумып, шуларны хәл

итәргә тиешлеләр арасында, аларның эреле-ваклы кайгы-шатлыкларын бергә кичерешеп яшәде. Алай гынамы, Вергилий Никифоровичның куәтле тәне, кайнар каны, тирән акылы аша илебездәге иң эре төзелеш мәйданнары, иксез-чиксез Ватанның хуҗалык һәм политик тормышы акты, актарылды. Чөнки Вергилий Никифорович, ашкын йөрәкле кеше буларак, үз янында эшләүчеләрне дә шушы ашкынлык белән агулый һәм шуны таләп итә дә иде.

Вергилий Никифоровичның ашкын йөрәге, зирәк акылы аша бер генә мәсьәлә дә, ул кызыксынырга тиеш булган бер генә вак-төяк тә эзсез генә үтмәде, үзенә хас чишелешен таба барды.

Ләкин еллар үтә торды һәм табигать, үзенең яңаны тудыргандагы кичектерелмәс көч-ихтыяры булган кебек, үзе тудырганны саклап-кадерләп үстергән шикелле, үзе үк билгеләгән чиккә, иң соңгы сызыкка таба да, бернинди кичектерү-соңарусыз китереп җиткерә белә.

Кеше тормышында ул сызык — картлык, берәүнең дә ихтыярына буйсынмый торган картлык. Халык «Картлык — кемгә шатлык?» дип белмичә генә әйткәнмени соң? Кешенең иң зур, иң ышанычлы һәм иң кыйммәтле байлыгы — акыл һәм аны хәрәкәткә китерүче йөрәк дигән нәрсә гомер сукмагын арырак барган саен, тынычрак, аеграк була бара. Шуның аркасында кеше үзенең гомер юлының аргы башын яктырак, ачыграк күрә башлый. Дөрес, әгәр дә кеше үзенең тормышын ил зурлыгындагы мәсьәләләрне хәл итүгә багышлаган, аларны чынбарлыкка ашыру юлыннан тайпылмыйча атлаган икән, ул инде үзенә билгеләнгән вакытның азая баруына карамастан, нинди дер үкенүләргә, аһ та ваһ килүләргә бирелми, ә бәлки зур эшләргә катнашы булуын тоеп, файдалы икәнлеген белеп яши.

Вергилий Никифорович моннан ун ел элек үк инде кешеләргә билгеләнгән бер сызыкны — «лаеклы ялга чыгу» вакытын узып китте. Чаллыярдагы төзелешнең яңа гына шаулый, ярсый башлаган чагы иде, һәм «пенсиягә чыгу» мөмкинлеге Вергилий Никифоровичның башына да килмәде. Чөнки әле аңардагы көч-куәт, йөрәгендәге гайрәт, акылның ачыклыгы шундый дәрәҗәдә иде ки, аңа карап берәүнең дә: «Житте сиңа, иптәш Дикопольцев, калдыр эшеңне, яшьләргә бир тоткан дилбегәңне»,— дип әйтергә батырчылык итмәде.

Әмма табигать дигән нәрсә, мәңге җиңелмәс көч үз дигәненә ирешә белә икән. Кайсыдыр фикер иясе: «Кешенең тууы очраклы, үлеме — закон» дип юкка гына әйтмәгәндер, билгеле.

Дәүләт комиссиясе Чаллыярдагы автогигантның икенче чиратын сафка кертү актына кул куеп, Дикопольцевның күпьеллык хезмәтенә, ниһаять, тиешле бәя — Социалистик Хезмәт Герое дигән исем бирелгән көннәрнең берсендә, һич уйламаган-көтмәгән бер минутта Вергилий Никифоровичның катлаулы уйларга күнеккән мие әллә кайдан гына: «Картаям!» дигән гап-гади бер нәрсәне тартып чыгарды һәм шушы мизгелдән соң инде хәтернең иң өске киштәсеннән төшермәде. Ул уй башта сирәк кенә һәм җәйге җылы кичләрдәге чикләвек яшене сыманрак кына ялтырап-ялтырап алды. Тик көннәр узган саен ул уйның яктылыгы артты һәм, ниһаять, куәтле прожектор нурлары булып әверелде.

Ләкин Вергилий Никифорович кайберәүләр кебек:

— Ах, гомер үтеп тә киткән, бернәрсә дә эшли алмадым,— дип үкенүчеләрдән түгел иде. Аның эшләгән эшләре килер буыннарның күз алдында торып, ерак елларга кадәр барып җитәчәк. Ул салган электр станцияләре Кара диңгез буендагы шәһәр-авылларны яктыртачак, Байкал тирәсендәге кыяларга җан өреп, мәңгелек туң җирләрне җылытып торачак. Ул салган йортларда, бәлки, Вергилий Никифорович күзләрен йомган минутта, меңләгән яңа гомер дөньяга килеп күзен ачып җибәрәчәк һәм ул әнә шушы яңа тормышка килүчеләрнең күзендә сүнмәс

чаткылар булып кабыначак. Аның артыннан җирдә бик күп, бик күп нәрсәләр калачак...

Вергилий Никифорович үзенең житмеш еллык дәверендә байтак нәрсәләрне — яхшысын да, начарын да күрде. Алар кайберәүнең үн гомеренә торырлык, житәрлек булыр иде. Ләкин ул бервакытта да, хәтта гаепсезгә кимсетелгән, яраткан эшеннән, кешеләр арасында яшәүдән мәхрүм ителгән минутларда да үзен бәхетсез итеп санамады. Андый уй аның башына да килмәде. Әгәр инде дөньяга яратылгансың икән, димәк, сиңа табигать тарафыннан гаять олы нәрсә — бәхет бирелгән. Бары тик шушы бәхетне бөтен гомер буена югалтмыйча, аның сафлыгына кер кундырмыйча уздыра белергә генә кирәк. Аны сакларга, яңадан-яңа сыйфатлар өстәп яшәргә генә кирәк.

Вергилий Никифоровичның еш кына, бигрәк тә мәктәп укучылары белән очрашканда:

«Бәхет... нәрсә соң ул бәхет?»— дигән сорауны ишеткәне бар.

Бу сорауга төрлечә җавап бирергә тырышкан чаклары булды аның. Әмма күп вакыт ни өчендер үзенә кагылмаган, бөтенесенә дә аңлаешлы, барысына да мәгълүм җавапларны бирде бугай ул. Ә бит бер уйласаң, аның тормышын бәрлап караган кеше: «Юк, Вергилий Дикопольцев гаять авыр, катлаулы гомер кичергән»,— дип әйтүе мөмкин.

Теләгән очракта Вергилий Никифорович аларга җиңел генә җавап бирә алыр иде, тик аның өчен бәхәскә керергә, үзенең теге гасырда эшләнгән винтовканы тотып, фашист автоматчыларына каршы атакага күтәрелүен, канга манчылып яраланган, аңын югалткан килеш дошман кулына әсирлеккә эләгүен, ләкин анда да иленә, халкына булган мәхәббәтне югалтмавын, тугрылыклы булып калуын әйтергә, әнә шулар белән дә үзенең бәхетсез түгел икәнлеген исбатларга туры килер иде.

Тирән уйга чумып, тәрәзәдән Чаллыяр гидроэлектростанциясенең мәгърур корылмаларына карап утыручы Вергилий Никифорович селектор зуммерының берничә тапкыр кабатланган чакыруын да, ниһаять, җавап булмаганга аптырап, гаҗәпләнгән Алексей Мирковның бүлмәгә керүен сизмәде.

— Вергилий Никифорович...— диде Алексей, житәкчесенең уйларын бүлдерүдән куркыбрак һәм шул ук вакытта аны чынбарлыкка кайтарырга тырышып.— Вергилий Никифорович...

Дикопольцев ярдәмчесенең тавышыннан битәр, янәшәсендәге яшькелт абажурлы өстәл лампасының бер дә юкка янып торуын күреп үзен биләгән уйлардан арынып китте.

— Ну, Алексей, нәрсә булган дөньяга? Кояш тотылып, күк гөмбәзе җиргә ишелеп төшмәгәндер ич...— диде Вергилий Никифорович канәгатьсезлек белдереп.— Бертоташ шалтыратасың да шалтыратасың, иркенләп уйларга мөмкинме миңа, әлле юкмы? Я, нәрсә булды, әйт сүзеңне...

«Менә сиңа мә!» дип уйлап алды Алексей, исе китеп.

— Гафу итегез, Вергилий Никифорович, ләкин бит сез Көмеш Аланга китәргә тиешсез, катер әзер, Айбулатов сезне причалда көтә...

Дикопольцев сәгатенә күз сирпеп алды, чынлап та, үзе билгеләгән вакыт җитеп килә икән.

*Ахыры киләсе санда*

БАТЫРЛЫК ДӘВАМ ИТӘ

# Мәгъсүм Хуҗин

# БӘХЕТ ҖИРЕ

хикәя



Габделнур миннән дүрт яшькә өлкәнрәк, шулай да балачактан ук үзенә тиң күрде ул мине. Моның сәбәбе гади иде кебек — Әрәмә урамында без ике генә малай, бүтән гаиләләрдә гел кызлар үсте. Безнең йортларыбыз әрәмәлек башында, кара-каршы. Елмаешып карый сыман иде алар бер-берсенә — күршелек күңелгә шулай сеңеп калган.

Болын-кыр үләннәренең ашарга яраклыларын мин Габделнур күрсәткәч таный башладым, шаракәшә уенына, йөзәргә һәм атка атланып чабарга да ул өйрәтте, урманга сагыз җыярга, соңрак агач төбе чыгарырга аңа ияреп бара идем. Әйе, авыл табигатенең, авыл хезмәтенең кайбер серләрен күпмедер белүем белән иң башлап өлкән дустым Габделнурга бурычлы мин.

Әмма яшь аермасы безнең ихтыярдан башка өскә бәреп чыкты — кырык дүртенче ел башында, төнлә явып узган йомшак карлар кояшта җемелдәгән көндә, Габделнурны сугышка озаттык. Авыл иң авыр эшләргә җигелүче, заманы кушканга инде байтак акыл утырткан иргетсез калды.

Сугыш бетеп, ике ел узгач та кайтты Габделнур. Кыен чаклар иде, укуын дәвам итә алмады, җиде класс белән калды. Монысына да заманы кушты. Тракторга-комбайнга утырмады, бүтән һөнәргә дә җае чыкмады, хәзергечә әйтсәк, гади колхозчы булды. Дөрес, ул кибән куйды, эскерт салды, ат белән җир сөрде, юл йөрде. Тик игенченең бу эшләре хәзер һөнәргә исәпләнми, һөнәр кешеләре, әнә, механизаторлар, җитмәсә, кин профильле әле үзләре, кирәк икән — токарь һәм слесарь да була алалар. Мактаулы кешеләр. Һәм макталулары урынлы да.

Ә Габделнур ел әйләнә төрле эштә йөри. Сугышта кан коеп алган хәрби бүләкләре бар, крестьян булып тир түккәне өчен бер генә медале дә юк. Шушы гаделсезлек турында мин, авылга бу юлы кайтуымда, колхоз җитәкчеләренә искәрттем, сәбәбен ансат аңлаттылар.

— Эшләсен иде көтүче булып! Күкрәгенә әллә ничә орден таккан булыр идек инде,— диделәр.— Көтүчелекне үзе ташлады бит.

— Үзегез күңелен биздердегез ләбаса,— дип, фикеремне расларга тырышып карадым мин.

Тик файдасы тимәде. Өстәвенә, үзенә бүләк юллап йөрүемне белгәч, Габделнур мине әрләп ташлады:

— Үз эшеңне бел, кирәкмәгәнгә кысылма!— диде ул, жигүле атын безнең капка төбенә туктатып.— Мин сорадыммы, берәрсе куштымы? Әллә үзеңнең кыбырсып йөрүеңме?

Габделнурның мине беренче ачулануы иде бу, шуңа күрә мин аптырый калдым.

— Утыр, атларга клевер чабып алып кайтасы бар.

— Бик теләп барам, ләкин торып кына йөрүем әле, ашамаган да,— дидем мин, аның ачуы тиз йомшаруына сөенеп.— Бергаләп чәйләп чыгыйк.

— Басуда эчәрсең чәеңне, әнә, шешә белән алдым, икмәге-мае да төенчектә.

Юл барганда без сөйләшмәдек, авылның иртәнге табигатенә хозур кылуыма комачаулыйсы килмәде бугай аның. Хәер, бу матурлыкны күреп беркайчан да туймас, кырда йөрү һәрчак тансык кебек итеп күзәтте ул да сихри тыныч дөньяны.

Габделнур чапкан клеверны мин, тырмалап, арбага төйи бардым. Бераздан:

— Мә әле,— дип чалгыны миңа тоттырды ул,— селтәнгәләп жибәр.

Аның кулында чалгы клеверны төптән кырып кына сала иде, минем арттан исә киселмәгән сабаклар тырпаешып кала.

— Үтмәсләнде бугай ла бу,— дидем мин, брак эшемне акларга ниятләп.

— Шулаймы?! Кайра соң.— Минем кайравымны ощатмады, янавычны кулымнан тартып ук алды.— Нигә елатасың чалгыны?— дип, үзе кайрады. Баш бармагын чалгы йөзенә тидергәләп, аның үткенлеген тикшерде.— Шәп бу! Болай ук үткен булганы да юк иде әле.

Әмма киселмәгән сабаклар, иелгән жирләреннән торып басып, мине үртәп тирбәлештеләр.

— Онытылган, Габделнур абый, печән чабу. Чалгы тыңламый.

— Сынатасың, энекәш! Жилле егет идең дә, хәзер үзәгең йомшаган.— Ул кинәт кенә мин көтмәгән нәтижә ясады.— Авылны яратам, дисең, крестьян эшен булдыра алмагач, авылны яратуыңнан ни мәгънә синең?! Авылга кайтып урнашучылар ишәя. Жир кешесе саналып та бүтәннәр иккән икмәкне ашап ятучылар, ягъни. Башта урбанлаштылар, хәзер хур-банлашалар. Бәхетсез жаннар алар.

— Фәлсәфәң дөрес тә кебек. Ләкин авылга кайтып яшәргә миңа гына рөхсәт итәрсеңдер, шәт,— дип, шаяртуга бормакчы булдым мин.

— Кайтма. Хәйләкәр булмакчылар, әй, керосин лампалары яндырганда клублар ишелгәндә, чиреңне имчеләрдән өшкерткәндә шәһәргә качтылар, хәзер, авыл үзенең уңайлыклары белән шәһәргә тиңләшкәч, тыннары кысыла башлаган, табигать кочагына ансат кына чummакчылар, әй?

— Күңелеңне тарайтма, Габделнур абый, сиңа килешми, синең сыйфат түгел монысы,— дип, мин үз ягымны каермакчы булдым.

— Шулай да бөтенләйгә кайтма. Синдә крестьянлык тәмамысы беткән. Бер көнгә иртәнге чәен калдырып, басуга чыгасы түгел, әй. Вәйт син аны, дус бит әле үзе! Шәһәреңне гүзәл итәсе урында, иртәнчәк йөгереп йөр шунда бала-чага сыман. Телевизордан шуңа өйрәтәләр бит сезне. Әйтерсең, йөгерүне жир казу янсә ки урам себерү алыштыра алмый, әй. Шәһәрегез тузанга чумган. Йөгереп йөриләр, әй. Ярар иде йөгергәнгә карап бүксәләрегез кимесә, әй. Күперә генә барасыз лабаса.

Монысы белән Габделнур минем авызны каплады, эндәшмәвем хәерлерәк иде.

Ул үзе чапкан клевер өстенә кечкенә генә табын жәйде.

— Әйдә, тамак ялгыйк. Мин дә чәйләмәгән әле. Басуда ризык тәмлерәк була. Аннары, печәнне иртәнчәк чабарга яратам мин, шуңа ашыктым.

...Габделнур атны юлга чыгарды, дилбегәне печәнгә кадаган чалгы бөгәлҗәсенә эләктерде. Без арба артына төшеп җәяүләдек.

— Миңа бүләк бирмәделәр дип ялгышасың син, энекәш,— диде ул, көтмәгәндә иртәнге сөйләшүгә әйләнеп кайтып.— Сәгатьләр белән бүләкләделәр мине.

— Беләм. Шул ике сәгать көтүчелектән гайрәтеңне чигерде бит синең.

— Гайрәтне чигермәде, ә ачуны куптарды. Яман купты ачу! Бер җәй колхоз сыерларын көтеп, бүләккә ике сәгать Габделнур дустыңа! Берсен район слетында, икенчесен колхозның отчет җыелышында бирделәр. Икесе бер үк төрле сәгатьләр. Ике кулына ике сәгать таксын, дигәннәрдер, әй, мине ахмакка санап мыскыл итүләре булгандыр, дип уйладым. Күрмәгәнен күрсен көтүче, янәсе. Көтү алмадым алдагы җәйдә, беренче һәм соңгы мәртәбә колхоз башлыкларының сүзен тыңламавым шул. Ә бу эш ошаган иде, хәзер дә теләк бар, дөресен әйткәндә.

— Үзең белән киңәшмичә председательгә сүз кушып ялгыштым,— дип гафу үтендем мин.

— Әй, оныт инде син аны! Алар минем ничек эшләгәнне белә, җайлары юктыр. Аларны гаепләмә. Авыл кешесе бүләк өчен генә эшләсә, игенче була димени ул. Менә, карале, улларым, бер булып, туган көнемә бүләк иттеләр бу сәгатьне. Төп-төгәл йөри, әй! Шуңа карап, хет бөтен дөнья вакытын дөресләә, әй! Суга тыксаң да, теркелди, караңгыда да җемелди. Үзебезнең Чистай сәгате.— Ул, бала сыман сөенеп, сәгатен куенына яшереп кенә карап алды.— Дөм караңгыда шәп күрсәтә, хәзер кием астында да барыбер якты керә.— Габделнур йөктән төшәргә селкенеп барган сабакларны эткәләп куйды.— Озакка кайттыгызмы?

— Ял көннәренә генә.

— Озакка түгел икән.

— Күреп китәсе килә бит. Вак-төяк йомышлар да җыелды.

— Кичен чәйгә керегез.

— Ярар.

Чәйдән соң без аларны малаебызның туена чакырдык.

— Сезгә дә туйлар уздыру заманы җиттемени?— Габделнурның моңсулануы сизелде.— Уза шул гомерләр... Кайчанрак туй итмәкче буласыз?

— Ноябрьда. Бәйрәм алдыннан. Төгәл көнен хәбәр итәрбез.

— Миңа ялны ел да ноябрьда бирәләр, димәк, гулять заманы. Барабыз! Шәһәрчә туйны күптән күрәсе килә иде. Карагыз әле, сарык чалып алып барырбыз, анысы үз абзарыбызда. Әйтегез, тагын нәрсәләр кирәк булыр соң?

— Берни дә кирәкми. Туйны ресторанда үткәрәбез, барысын да шунда әзерлиләр.

— Монысы җайсыз икән... Нигә өегездә түгел?

— Малай бер генә, кызлар икәү. Малай өйләнә, кызларны кияүгә бирәсе. Бу юлы олы туй безнең яктан. Шаулатырга-гөрләтергә исәп!

— Һе...

Иртәгесен без тагын атларга клевер алып кайттык. Габделнур бүген сөйләшмәде дә диярлек. Авылга җитәрәк:

— Кеше күп булачак икән анда, туйда, дим,— дип хафаланыбрак әйтеп куйды.

— Зал тулы булыр, шәт.

— Нәрсә киярга, дип борчылмыйм, затлы кием бездә дә бар. Ләкин ни-нәрсә дип сүз әйтермен икән, шунысына баш җитми.

— Ни теләсәң, шуны әйт. Синең иркең.

— Әгәр ничек гашыйк булуымны сөйләсәм? Туйда ярар бит мәхәббәтне искә төшерергә?

...Беләсең, ярлы идек, дүрт бала үстек, олысы мин идем. Әмма гыйшык дигәнең баюыңны көтми, вакытны чамалап тормый икән. Сабан туе житкәндә генә гашыйк булдым да куйдым бит шушы Маһруйбикә жиңгәнә! Йокы качты, күңелдән куалап та чыгарып булмый шул көлеп туймас жанны, әй. Дөресен әйткәндәме, куасы да килми, янымнан жибәрмичә күзләренә гел карап торыр идем шул чибәркәйнең...

Житте сабан туе. Ә чалбарның ямаулары катлы-катлы, тишекләре, кем әйткәндәй, яп-яңа, күлмәк сыпылырга тора, кәрәшкә керәп биленнән тотуларына умырылып кына төшәчәк. Беләм, Маһруйбикә бернечеләрдән булып барачак сабан туена, аның киемнәре минекеннән әйбәт. Мине юк дип тормас, башка малайлар белән житәкләшеп әйлән-бәйләнгә уйнар, ышан син кыз халкына...

Печәнлеккә мендем дә бөгәрләнеп яттым. Житәкләшеп уйнасын Маһруйбикә күңеленә ошаган малайлар белән, култыклашып та йөрсен, бу дөньяның кызыгы бармыни, өсте-астына әйләнсен дөньясының...

Әни дәшә, соңга каласың, ди. Әтиеңнең чалбарын кыскартып теккән идем, күлмәген дә, ди, киеп карале, таман булырлар, шәт, ди. Маһруйбикәләр сабан туена киттеләр инде, ди.

Сизгән инде ана күңеле, сизмиме соң!.. Тәки бер генә малай белән дә житәкләштереп уйнатмадым шул сылу Маһруйбикәне, әй! Әнигә рәхмәт, сабан туена киеп төшәрлек киемнәрне вакытында юнәтеп бирде. Мине үзенә гашыйк иттереп тинтерәткән шул Маһруйбикә жиңгәң белән тигез гомер иткән көнебез, әй. Үз күз алдыңда моңысы...

— Юк, аңламас хәзерге яшьләр минем гыйшыкны,— диде Габделнур, шакмаклы кепкасын кулына алып. Аның кыска чәчләре кояшта жемелдәде.— Авылча гашыйк булган, диярләр.

— Сөйлә соң шуны. Яшьләргә бер сабак булыр.

— Аңламаслар. Авыл гыйбаты, дип көләрләр. Телевизордан киноларны карыйсыңдыр, хәзерге яшь-жилкенчәк өлкәннәргә, картлач, дип кенә жибәрә.

Озатырга кергәч, Габделнур, мине читкә чакырып, туйда әйтергә теләгән тостының яңасын сөйләде...

— Белмим шул, килешерме икән туйда мондый хикәят сөйләү,— дидем мин, Габделнурга кырт кисеп каршы төшәргә базмыйча.

— Менә, менә, әле сиңа моның мәгънәсе барып житми, яшьләр аны күптән аңламас. Ә речемнең мәгънәсе мондый — нинди генә кыен хәлдә калсагыз да, беркайчан да беркайчан да кешелеклелегегезне жуймагыз.— Габделнур миңа кулын селтәде.— Син дә аңламагач... Ярый, юлыгыз уң булсын,— дип исәнлек теләп чыгып китте.

...Туйга ике көн алдан килделәр алар. Габделнур белән ябык балконда тәмәке көйрәтеп, гадәтчә күп кенә нәрсәләр турында сөйләштек.

— Сүз әйтмәскә булдым мин туйда, энекәш,— диде ул шундый бер әңгәмәдә.— Беләсең килсә, жырлап биергә ниятләдем! Шуңа күрә үз гармунымны алып килдем.

— Бигрәк шәп!

— Жырлыйм! Булдырам мин жырларга. Көтү көткәндә бер жәйдә дә әллә ничәмә жыр уйлап чыгардым мин.

— Яшьләрнең күңеленә сеңеп калыр жырың-теләгең.

Әмма түй көнне Габделнурның теләге тагын үзгәргән иде.

— Сөйләмим дә, жырламыйм да.— Ул көзге каршында күлмәк якасын рәтли, аның жил ашап каралып, жыерчыклар төшкән йөзен уй баскан иде. Аркасы белән борылып, яңа костюмының тәненә ятышлымы утыруын карады. Гәүдәсе таза-нык аның, сукса тимер өзәр чагы узмаган әле.— Балконыгызда көйләп-жырлап карадым, мескен чыга тавыш. Яшелгә буялуы килешә балконыгызның, әмма барыбер дә жәйге кыр түгел ул, бер адым гына атла — аска мәтәләсең. Ресторанда да киң-

лек булмаячак. Җырлау өчен миңа озын юллар, көтү йөри торган болын-басулар кирәк икән. Минем җырны минем бәхет җире тыңларга тиеш икән, әй, энекәш. Колхоз көтүен алмыйча булмас киләсе җәйдә. Чын, әй. Нигә, көчең җитмәс, дисеңме? Җитә!— Габделнур көлемсерәп куйды.— Синең, биштәреңә бәрәңге тутырып, станциягә хәтле шул йөкне күтәреп барып, шәһәрдә ачлы-туклы укуың газаплары турында сөйләмәкче, сезнеңчә әйтсәк, авырлыклар каршында баш имәгез, димәкче идем, фикеремнән кире кайттым. Яшьлегем төсе итеп, күлмәк җиңенең зәңгәр бизәкле каптырмаларын әле дә саклыйм мин. Яшьләргә шуны әйтимме әллә, дигән идем. Кирәкмәс. Туй халкыгыз ала-кола. Аласы да аңламас, коласы да аңламас, дигәндәй. Бәхет җире турындагы сүземне дә аңламаслар. Бәхет җире... Кайда ул? Кешенең күңелендәме, әллә бер инәгә бер сыер тия торган елга аръягындамы? Әмма ки шунысын тәгаен беләм: бар ул бәхет җире, һәм һәркем аны үзе табарга тиеш. Синең малаең белән киленеңә дә кагыла бу, шуны белеп тор. Тик бәхет җиренә, энекәш, солдат чактагыча әйтсәк, бүтән кеше куйган ориентир белән барып булмый! Ориентирын да үзең тап, сукмагын да үзең сал!

...Габделнурның быел җәен әйткән сүзе кылт итеп исемә төште.

—Кайтма!— дигән иде ул кырыс кына, мин авылга бөтенләйгә кайтып яшәү турында сүз кузгаткач.

Болай кистереп әйтергә аның хакы бар иде. Яшьләргә туйда бәхет җире, ул җирнең серләре турында сөйләргә дә аның хакы зуррак. Чишсен иде Габделнур әнә шул серләрне, малай белән килен дә ишетсен иде аның сүзләрен, сөйләсен иде минем өлкән дустым Габделнур!

Юк, Бәхет җиренә илтә торган юлны күрсәтсен, димим. Ләкин аның теләкләрендә шул бәхет җире сукмагының төсмере чагылмыйча калмас иде.

Ашыкмыйк, бераз сабыр итик, туй башланыр чак җитеп килә икән ләбаса...

Рәдиф Гатауллин

# МӘХӘББӘТКӘ-МӘРХӘМӘТ!

## Чистай кызы

*Шигъреми җәйдем аягы астына...*

*Г. Тукай.*

Мин — Чистайда... Бүгенгедә. Уйда — башка чорлар:
җитмеш ел элек булганга кайта һаман уйлар...

Ага Чулман, вакыт ага,— санап сәгатьләрне,
көтә яшь кыз. Өмет өчен бармы сәбәпләре?

Пароходлар килә, китә... Юк, пристань моңсу:
Килми Тукай — Зәйтүнәгә ник күңелле булсын!

Авырттыра минутлары җанны, сәгатьләре...
Нигә кысып тора аны мишәр гадәтләре?—

Юкса чыгып китсә иде үзе Казаннарга!
Анда — Тукайлы газетлар, урамнар, заллар да...

Казан гөрли, һаман нурлы, уты уңайлы күк...
Бөтен төше җанга җылы — һәр җир Тукайлы күк!

Фатих агасы, Әмирхан хат лабаса яза,
ә соң Тукай? Юк бер хәбәр, инде ничә яз ла!

Ага Чулман, ага вакыт... Чистай сәгатьләре...
Барып күреп кайтыр өчен юкмы сәбәпләре?!

— Калфагымны ташлар идем дулкын иясенә,
Чистай, пароходта җитеп Тукай килсә сиңа!

...«Сәйяр» килгән... Кари-артист сәлам алып килгән...
Ә соң үзе? Үпкәлиме? Нигә килми икән?

Әнкәем дим, кызыгызда шундый читен хәл лә...
Ул, шагыйрьгә, үзе башлап, сөям! дисен әллә?

Казанда бит таныштылар. Әй кызарды шагыйрь:
кызык гашыйк... үзен шуңа бәлки атагандыр?

Өстенә конфетти сибеп серпантиным белән
уратканда — җан бәйләнгән, кем соң аны белгән!

Ә нигә әле чәчләре бәйләнми соң чәчкә?—
Менә хәзер, Чистай кызы, көтеп, янып яшә...

Менә хәзер килер сиңа тетрәндерер хәбәр:
татар тетрәр, елар мишәр — уянырлык хәлләр!

Халык пәйгамбәре үлгән! Япь-яшь көе киткән...
Зәйтүнәне калдырган ник? Ул соң нишләр икән?

Чулманга карап еларга, уйланырга кала...
Татар кызы, синең язмыш һай аяныч, бала!

...Сагыныр ул гомер буе Тукайны үзенчә:
татар кызлары исеменнән, хисе — пакь көенчә.

Ул күрсәтми түгәр яшен, эчтә саклар утын —
бер генә очратмас юлда «Тукай» пароходын!

Әдипләр килер... үз улы [1] — истәлекләр сорап,
ул елмаер моңсу гына... Үткән — шундый ерак!

Ул шул изге хискә, моңга багышлар гомерне:
ул Тукайны саклар җанда — бөек яшүсмерне!

...Ә Чистай каласы — башка: ил яшәрә бара.
Шаһит — Чистай сәгатьләре... Вакыт ага. Ярда —
Пристаньда япь-яшь кызлар. Кемне каршылыйлар?
Туктар да пароход, Тукай... Юк, егетләр чыгар,
Кочаклашырлар яшеренми, кеше алдында ук:
саф яшьлектә, ихласлыкта гаеп тамчы да юк!

Үзгәргән дә хәзер — яңа мишәр гадәтләре...
Бәхетләрне саный инде, Чистай, сәгатьләрең!

Мин дә Чистайда... Бүгендә. Әмма уем — ерак...
Кайта — Тукайның бердәнбер сөйгәненә йөрәк.

Аңа һәйкәлме язганым?— Нәни генә ядкарь...
Бөек шагыйрьнең үз җыры, беләм, озак яшәр...

*1984. Чистай*

# Аксакаллар

— Сезне узып киттек, инде
Бик артта калдырдык— дидек,
Юк, һаман алда икән —
Шаккатып торам: сез — абый,
Сез һаман остаз лабаса,
Без һаман бала икән...

[1] Күренекле язучыбыз А. Расих.

Инде мөстәкыйль булдык!— дип,
Горур башны өскә чөйдек,—
Бу Иблис алдау икән:
Акылда да һәм солда да
Сез үрнәк безгә һаман да,
Сез — агай, алда икән...

Зур фикерләр белән килдек,
Яңа киемнәргә төрдек,—
Дип сөйләү — ялган икән:
Сездә күптән алар булган,
Безгә кадәр дә табылган,—
Без — дәвам, ялгау икән...

Инде гыйбрәт бу гомергә,
Кем булма син һәм кай җирдә,—
Аксакал кала икән,
Синнән гел тәҗрибәлерәк,
Яши үсүеңне теләп,
Үзе — гел алда икән!

— Сез безгә һаман абый ла...
Без һаман бала икән!—
Кайчан да шулай әйтергә,
Аксакалыңа кайтырга
Көч таба алсаң икән!

●

Юк шул... Сезне онытып булса икән!
Сез уятып бер көн яшь канны,
Аннан җанны минем елаттыгыз...
Каргамадым (Адәм!) һавамны!
Әрнеп, теләмәдем калагызны
Ут һәм корым каплап алсын дип,
Мин ләгънәтләр Сезгә яудырмадым.
Янсам да бит үзем яндым тик.

Табынганнар белә булыр: алар
Илаһына әллә кизәнгән?
Кояш нуры булып күкләр тартты —
Мин тауларга мендем үзәннән.

Биеклекне күреп беләм хәзер,
Яшьлек эзен карлар каплаган,
Ләкин күрәм ачык: биектә — Сез,
Картаймаган, матур, шат һаман,—
Табынулар шулай саклаган.

Ялган булыр: хәзер Сезгә тыныч
Карыйм, дисәм, юк... Тик, җан атып,
Тауга кабат китәр идемме мин?—
Куркып уйлыйм... Ә бит яшьтә мендем,
Биек мендем ул чак — яратып...

## Үкенеч

Кешеләрнең гаебен табу җиңел!
Күз алдында читләр ялгышы
Ярылып ята...
Шуңа без аларның
Мөмкинлеген үлчәп, язмышын
«Хәл итәбез» күп чак —
Җыр кошына:
— Сынар, дибез, тиздән канаты.
Үзеңнекен исә күрү читен,
Инде ятлар — яки яратып,
Күп чак гаеп табып, бәя куяр...

Ә син, күңел, азмы очындың!—
Үз юлыңда күпме каурый тузгый,
Беркет-кошын хурлап дусыңның.

Кешеләрнең гаебен табу җиңел...

*1984*

## Мәрхәмәт!..

Ник дәшәм бүген дөньяга?—
— Мәрхәмәт, дим, мәрхәмәт:
Тагын хәкарәттә анда —
Төнге Мадрид урамында
Түбән төшкән мәхәббәт,—

Тапталмасын ялгыш, әкерен!
Юкса, ул янмас кабат...
Диварга сыенган — туңган,
«Эштән чыгарылган кыз»дай,
Тузган чәчле Мәхәббәт,
(Тукталдык Фәйзуллин белән...)
Мәрхәмәт, әй, мәрхәмәт!

Парижда күреп янды җан,
Аннан Лондонда — Сохода,
Инде менә Мадридта —
Суык апрель төнендә ул,
Ярым-ялангач фәрештә —
Җиргә төшкән — яр көтә,
Ул чакыра мәгълүм йортка!

Хәкарәттә мәхәббәт...
Мин, аның рыцарь-шагыйре,
Бу хәлендә күреп әле
Нишли алам?! Мең кабат,
Дон Кихотча... юк, Тукайча
Кычкырам бары дөньяга:
— Кит, зинһар, булма харап,
Кайт, сөю, изге исемеңә...
Беләм, егерменче йөздә
Кемнәр сине, мәхәббәт,
Бу хәлгә төшерә... Җиркүләм
Нәфрәт аларга, нәләт!
Җылын шагыйрьләр җанында,
Тузган чәчле, туңган ач зат!—
Мәхәббәткә — Мәрхәмәт!

*1983. Мадрид*

## Күперләр

Яндырыгыз күперләрне!
Хыяллар, алданмагыз,—
Калсын ул җырлар яшьлектә,
Бүгенгә ялгамагыз;
Кырык яшькәчә гомернең
Күңелдә алтын томы:
Ихласлык тарихы итеп,
Хисләрем сайланмасы дип,
Калдырам, яшьләр, аны...

Күперләр янсын — узганга,
Хыяллар, ялганмагыз,
Хушлаша белик — яшьлекне
Кабатлап тик, янмагыз...
Шат көйләр — кырыкка кадәр,
Калдырдык яшел ярны...
Чакыра хәзер аргы як,
Әмма су салкынрак... әллә
Кояшның сүрән чагы?—
Инде өлкәннәр ярында,
Аек карап чынлыкка,
Акылга бәлки, таянып,
Кырыслыгыннан курыкмый,
Җавап бирик тормышка...

Ә беренче алтын томын
Гомернең... нәрсә әйтим,
Сагынсагыз, хыяллар, сез —
Күперләр сузып карарсыз...
Ялганмас кабат ләкин!

## Якында

Без булганбыз шундый якын ла:
Бер поездда, төрле вагонда!..—
Бер тарафка киткән юлыбыз,
Бер сагышны йоткан моңыбыз.—

Төн йокламый уйда килгәнбез.
Уяу килештер — төш күргәнбез.
...Булгансың син күрше вагонда,
Тик перронга чыккан чагымда,
Вокзалда син күземә чалындың.

Каршылаучыңны да таныдым.
Төш бүлендә минем — уяндым,
Күздән җуйгач сине, уйландым...
Гомер юлыбыз да — бер тараф!—
Барабызмы читкә без карап?
Бер-беребезне уйлап яшәп тә
Очрашмыйбыз, үзебез — янәшә:
Бер поездда... Төрле вагонда!
Бергә түгел, әмма — якында...

## Тагын... болан баласы

Йөрәге яна микәнни?—
Шунда әллә дәвасы?
Кар ярып аккан боладан
Сузылып су эчә урманда —
Күрдем болан баласын!

Салкын гына тимәсә иде
Сиңа, урман баласы —
Сеңелем, билгелеме юлың?
Таулар ашамы барасы —
Тирләп кая чабасың?!

Минем дә, болан-балакай,
Әрни җанаш ярасы
Җанда — кар суы да басмый,—
Кайда аның дәвасы,
Ничек аны табасы?!

Язгы суларга текәлеп,
Тагын күпме багасы?!
...Бәлки ярын эзләп арган?
Муенын сузып су эчкәндә
Күрдем болан баласын...

## Кышкы идиллия

Шундый салкын! Агачларда — сыкы...
Син дә бәсле шәлгә уранган:
Тик күзләрең күренә — алар якты!—
Без киләбез төнге урамнан.

Агыйделдән, Юрүзәннән гүя
Казан безне үзе чакырды:
Шигырьләргә, Моңга ул башкала,
Шунда булсын дәвам, ахыры...
Күге нинди! Йолдызлары — якын,
Хыяллар да шуңа балкыймы?..
Син тыңлыйсың: шигырь сөйләп киләм,
Тавышым — батыр, хәтта акыллы...

Нинди бәхет: Шигырь, Җыр сөйләшә,—
Моң тантана итә — юл алган...
Кайнар сулышыңны тоям, юкса
Күзләреңәчә син уранган —
Бәсле пәрдә... Сине кемнән саклый?—
Яман күздән? Кышкы урамнан?!
...Бик биектә хыял! Безнең өстә —
Казан күге... Җилләр — Уралдан...

## УРАЛЬСКИДА ТУКАЙ УРЫННАРЫ



**Уральск (Җаек) шәһәрендә «Казан» кунакханәсе. 1907 елда, мәдрәсәдән чыккач, Казанга күчеп килгәнче, Г. Тукай биредә яшәгән.**

*Тавил Хаҗиәхмәтов рәсеме*

# ШАГЫЙРЬНЕ БЕЗ ДӘ КҮРДЕК

Дачада булды бу вакыйга[1]. Беркөнне әти иртәгә безгә Габдулла Тукайның киләсен әйтте. Без инде аның әсәрләрен белә һәм ярата идек. Шуңа күрә шатлыгыбызның чиге булмады. Олылар өй җыештырырга һәм аш-су әзерләргә керештеләр, ә без, дүрт кыз бала — Сара, Рауза, Зәйнәп һәм мин — күп итеп чәчәк җыярга карар иттек. Дачадан ерак түгел генә елга ага, ә аның аръягындагы тауда төрле-төрле чәчәкләр үсеп утыра иде. Көймә белән чыгып, без күп итеп күгәрчен күзе, кыңгырау чәчәк һәм ромашка җыйдык.

Без корган план буенча Тукайны көймәдә йөртү күздә тотыла иде. Шуңа дип без көймәне рәткә кертергә тотындык: бөтен төшен кырып юдык, чәчәкләр тезеп бизәдек, эскәмияләрен кечкенә паласлар белән капладык.

Кичен әти Тукайны алып кайтты. Мин гаҗәпләнеп, аптырап калдым: ул минем балачак хыялымда озын буйлы, таза һәм сәламәт булып җанланган иде, чынлыкта исә әти янында яшүсмергә охшаган кечерәк кенә, ябык кына бер егет утыра. Өстендә карарак төстәге җиңел җәйге пальто. Әти Тукайны өйгә алып керде һәм безне, ягъни үзенең дүрт кызын, аның белән күрештерде.

Алар әти белән икәү утырып ашадылар, әни исә кунак бик аз ашый дип борчылды. Аннан соң без Тукай абыйны көймәдә йөрергә чакырдык, ләкин ул баш тартты. Елгага кадәрге араны җәяүләп үтү аңа авыр булгандыр дип уйлыйм. Ул бездән нинди шигырьләрен белүебезне сорашты. Без теләп җавап бирдек, хәтта кайберләрен җырлап та күрсәттек. Мәсәлән, «Сөялгәнсең чатта баганага» дип башланган шигырен җырлаганыбыз хәтеремдә. Ул безне рәхәтләнеп тыңлады да соңыннан рәхмәт әйтте.

Тукай туберкулез белән авырый һәм «Ак-кыз» дигән урынга кымыз эчеп дәваланырга килгән иде. Мин «Ак-кыз»ның кайда икәнен һәм кем милкендә булганын белмим[2].

Арабыздан кемдер Тукай абый үзенең түбәтәй киеп, ак яка һәм галстук тагып төшкән фоторәсеменә бер дә охшамаган дип әйтеп куйды. Тукай елмайды да мондыйрак мәгънәдә шаяртып җавап бирде: ул рәсем минннән алынмады, минем шигырьләргә игътибарны юнәлтү һәм аларны яраттыру өчен бүтән кешене төшереп алдылар.

Мин соңыннан аның ике кулын баш артына куеп мендәргә яткан хәлдә төшкән фоторәсемен күрдем. Безгә дачага килгән шагыйрь Габдулла Тукай нәкъ шундый иде.

Безне бүтән бүлмәгә чыгарып җибәрделәр, әти белән Тукай моннан соң озак сөйләшеп утырдылар.

Икенче көнне иртән Тукай белән әти әлеге «Ак-кыз»га китәргә җыендылар. Ул, барыбыз белән дә җылы итеп күрешеп чыккач, тарантаска менеп утырды. Шулвакыт кече энебез Мидхәт (аңа ике яшьләр чамасы булгандыр) аның тезләренә үрмәләп менеп китте. Энебез таза һәм юан иде. Шуңа күрә бу «йөк» Тукайның тезләренә авыр тоелды булса кирәк, ул болай дип әйтте: «Авыр икәнсең син, балам, мин озак тотып тора алмам сине». Олылардан кемдер малайны Тукайның итәгеннән алды, һәм әти белән Тукай кузгалып киттеләр.

Әти кичләрен безгә Тукай турында сөйли иде. Без, көймәдә йөргәндә, әтиебез үтенече буенча Тукайның кемнәр тарафыннандыр көйгә салынган шигырьләрен җырлый идек.

**Нәҗия ӘХМӘРОВА.**

---

[1] Истәлек, рус телендә язылган булып, Үзбәкстанның атаклы рәссамы Чыңгыз Әхмәровта саклана. Аны, татарчага тәрҗемә итеп, журналга И. Нуруллин тапшырды. Нәҗия Әхмәрова (1904) — врач, хәзер пенсиядә. Самаркандта яши. Аның атасы Габдрахман Әхмәров (1869—1933) — Троицк баенда доверенный булган.

[2] «Ак-кыз» — Троицк мулласы Габдрахман Рахманкуловның җәйләве булган авылның исеме.

*Мария Александровна Ульянованың тууына — 150 ел*

**Мөнирә Сәйдәшева,**
тарих фәннәре кандидаты

# ИҢ БӘХЕТЛЕ АНА



*Мария Александровна Ульянова (1835—1916)*

Даһи Ленинның кадерле әнисе Мария Александровна Ульянова гомеренең унсигез елын Казан һәм Казан губернасындагы Кокушкино авылында уздыра. Архив документлары, туганнарының һәм якыннарының хатлары, истәлекләр безгә бу бөек ана образын тирәннән аңларга ярдәм итә. З. П. Кржижановская, Мария Александровнаның бөек шәхес һәм сизгер күңелле булуына ишарәләп: «Революционерлар (әле нинди генә революционерлар!) үстергән ананың гаҗәеп сөйкемле образы бу балалар ирешкән җиңүләргә дә кагылышлы итеп бәяләнергә тиеш,— дип язган иде.— Чөнки Мария Александровнаның гомере балаларыныкына нык бәйле һәм баштанаяк аларга багышланган. Рухи яктан көчле, ачык күңелле, гүзәллеккә омтылучан бу ана кыз һәм улларының дөньяга карашлары, тормыш юллары формалашуга ни дәрәҗәдә тәэсир иткәнлекне хәтта чамалап бетерүе дә кыен».

Мария Александровна Ульянова (кыз фамилиясе Бланк) 1835 елның 6 мартында (искечә стиль белән — 22 февральдә) Петербургта туа. Аның әтисе, Александр Дмитриевич, чыгышы ягыннан мещан була. Ул 1824 елны медицина-хирургия буенча император академиясен тәмамлый. Егерме ел врач булып эшләгәннән соң, дворян исеме бирелә.

Александр Дмитриевич Петербургта да, Смоленск губернасында да, Пермь якларында да хезмәт итә. Авырулар дәвалауда аның үзенә генә хас ысуллары кызыклы. Ул гел даруларга гына таянып эшләүгә каршы чыга, пациентларга да даруны мөмкин кадәр азрак тәкъдим итәргә тырыша. Эчке һәм нерв авыруларыннан котылу өчен, мәсәлән, ул судан файдаланырга киңәш бирә. Пермьдәге Юговский заводында ул хәтта су белән дәвалау йорты да оештыра. Александр Дмитриевич еш кына: «Яшәешнең үзе белән дәвалана белергә кирәк!»— дип кабатларга ярата.

1847 елда Александр Бланк, ялга чыгып, Казаннан 40 чакрым чамасы ераклыктагы Кокушкино авылына урнаша. Шунда ул 1870 елның 17 июленәчә, ягъни вафатына кадәр, яши.

Татарстан дәүләт архивында А. Д. Бланкның 1847 елның 27 ноябрендә Казан губернасының шәҗәрә-кенәгәсенә кертелүе һәм аның Дмитрий, Анна, Любовь, Екатерина, Мария, София исемле алты баласы булганлыгы турында документ саклана. Александр Дмитриевичның хатыны Анна Ивановна бик яшьли, 1838 елда ук дөньядан кичә. Балалар тәрбияләүдә бу гаиләгә Анна Ивановнаның тол калган сеңелесе Екатерина да ярдәм итә. Бик кырыс холыклы булуына да карамастан, Екатерина Ивановна балаларның тирән ихтирамын казана. Ул аларны музыкага, чит телләргә, өй эшләренә һәм үз үзеңне дөрес тоту кагыйдәләренә өйрәтә.

Александр Дмитриевич, көчле рухлы, мөстәкыйльлек яратучы кеше буларак, берәү алдында да баш иярга, берәүгә дә ялагайланырга теләми. Шуңа күрә власть вәкилләренә дә бик ошап бетми ул. Казанның хәрби губернаторы хәтта аның турында яшерен мәгълүматлар җыярга боера. 1850 елның 7 октябрендә Лаешның земский исправнигы хәрби губернаторга А. Бланкның, хуҗалык эшләреннән тыш, кешеләрне су белән дәвалап мавыгуы турында хәбәр итә.

Туры сүзле, битарафлыкны сөймәүчән Александр Дмитриевич балаларын да үзенә охшатып тәрбияли. Ул аларны яшьтән үк һәм физик, һәм әхлакый яктан чыныктырырга тырыша, һичнинди ялкаулыкка, урынсыз иркәләнү-назлануларга юл куймый.

Балалар һәр иртәдә, салкын өйалдындагы аралыктан үтеп, кухняга, иртәнге табында үзләре эчәргә тиешле сөтне җылытырга ашыгалар. Бу өйдә балаларга кечкенә чакта гына түгел, шактый үскәч тә чәй яки кофе эчәргә рөхсәт ителми, чөнки эти кеше бу эчемлекләрне организмга зарарлы дип ышанган була. Гаиләдәге һәр балага аерым түтәлләр бүлеп бирелә, андагы барлык эшләрне алар үзләре башкаралар.

Мария Александровна шушындый шартларда нык холыклы, чыдам, сабыр һәм сау-сәламәт булып үсеп җитә. Кокушкинода яши башлаганда, аңа унике тула. Әтисен ул бик якын күрә, аңа һәрчак ярдәм итәргә тырыша, бакчада эшләргә, яшелчәләр үстерергә аеруча ярата.

Укуда исә Мария Александровнаның тагын да сәләтлерәк икәнлеге ачыла. Дөрес, бу авылда хәтта башлангыч мәктәп тә булмый. Кызны әнисенең сеңелесе һәм әтисе укыталар. Мария Александровна немец, француз, инглиз телләренә өйрәнә, әдәбиятны, тарихны, математиканы, кисү-тегү һөнәрләрен үзләштерә. Шулай ук ул фортепианода уйный, нотага карап җырлый белә.

Кияүгә чыгарына бер ай кала, 1863 елның 15 июлендә Мария Александровна, Самарадагы ирләр гимназиясендә экстерн тәстә имтихан тотып, башлангыч мәктәпләрдә рус, немец, француз телләрен һәм арифметиканы укыту хокукын ала. Аңа мәктәпләрдә эшләргә туры килми килүен, әмма тормышта кызның педагоглык сәләте ифрат киң колач ала, бик күркәм нәтиҗәләр бирә.

Мария Александровна апасының ире И. Д. Веретенников белән бергә эшләүче, Пенза дворян институты инспекторы Илья Николаевич Ульяновка кияүгә чыга. Туйны 1863 елның 25 августында Кокушкинода ясыйлар. Һәм Мария Александровна үзен ире белән бик бәхетле гомер кичергән итеп исәпли. Чорының алдынгы фикерле кешесе Илья Николаевич тормышының утыз елдан артыграк гомерен педагогикага, халыкны агартуга багышлый. Гаиләдә дә ул искиткеч игътибарлы. Бу өйдәге балалар әти белән әни арасында нинди дә низагы булырга мөмкинлеген күз алларына да китермиләр. Мария Ильинична Ульянова истәлекләренә караганда, Мария Александровна белән Илья Николаевич балаларны ничек тәрбияләү турында бервакытта да бәхәсләшмиләр. Кыз-уллары исә һәр мәсьәлә-

дә эти-әнинең «бердәм фронт»та икәнлекләрен бик яхшы сизеп торалар.

Ульяновларның бала тәрбияләү сәләтенә сокланмый мөмкин түгел. Бала күңеленә юл яру, уртак тел таба белү, эшкә өйрәтүне мавыктыргыч ысулларда алып бару — болар һәммәсе шуңа шаһит. Әйтик, бәләкәй Маняшасын бәйләргә өйрәткән чакта Мария Александровна йомгакка кечкенә уенчыклар, конфетлар кыстырып калдыра. Бала бераз эшләп ала да, җеп эченнән аның яраткан әйбере килеп чыга...

Әни кеше күп укыганлыктан, Ульяновлар гаиләсендәге балалар да әдәбиятны, шигъриятне, әкиятләрне яратучан булып үсәләр, чит телләргә, рояльдә уйнарга, җырларга өйрәнәләр. Яңа ел алдыннан чыршы уенчыклары ясарга, Кокушкино тирәсендәге урманнарга чыгып йөрергә, табигатьне кадерләргә өйрәнәләр.

Ульяновлар гаиләсендәге балалар нәкъ менә Кокушкино чорында әхлакый яктан гына түгел, идея-политик яктан да дөрес тәрбия алалар. Монда балаларга үзләрен иркен тотарга мөмкинлек бирелә: төрледән-төрле уеннар, кызыклы бәхәсләр, тыелган җырлар, Мария Александровнаның фортепианода уйнавын тыңлаулар...

Н. И. Веретенников бу хакта: «Тыныч, сабыр холыклы Маша апа безнең кебек балалар белән һәрвакыт бик итагатьле, гадел була торган иде,— дип яза.— Без дә аны бик ярата идек һәм, башкаларга караганда, аны ныграк якын күрә идек. Кокушкинодагы көйсез көннәрдә ул безне рояль янына җыя. Верстовскийның «Аскольд кабере» исемле операсы турында сөйли. Без тын да алмый аның сүзләрен, рояльдә уйнавын тыңлыйбыз. Мин мондый кичләрне мәңге онытмам кебек. Әгәр ясый белсәм, шундый бер кичәне менә дигән итеп рәсемгә төшереп куяр идем: Володя белән Оля, мөкиббән китеп, музыканы, җырны тыңлыйлар. Аларның табигате аеруча музыкаль иде. Кечкенә Митя исә әсәрнең фабуласы белән күбрәк кызыксына, Маша апаның сүзләрен йотып алырдай булып утыра. Өлкәннәр, тамашага комачауламаска тырышып, өй эшләре белән шөгыльләнәләр. Хәер, без, балалар Мария Александровнаның сүзләре, рояльдә уйнавы, җыры белән шулкадәр мавыкканбыз ки, башкаларның нишләве гамебезгә дә кереп чыкмый»...

Бу олы җанлы бөек ананың тышкы кыяфәте турында да төрле истәлекләр сакланган. Мария Александровна бик күркәм, күз карашлары тирән мәгънәле, йөзендә сабырлык һәм шул ук вакытта горурлык та чагыла. Үз-үзен тотышында көч, чыдамлык, кешеләрне хөрмәтләү һәм көрәшүчән рух сизелеп тора.

Мәгълүм булганча, Мария Александровнага авыр, кайгылы хәлләрне дә шактый кичерергә туры килә. 1886 елның гыйнварында Илья Николаевич кинәттән үлеп китә. Шуннан соң ел гына уза, Петербургта Александр IIIкә һөҗүм итүдә катнашканы өчен, Анна белән Александр Ульяновлар кулга алыналар. Ана ашыгыч рәвештә Петербургка китә. Ульяновлар гаиләсенең якын дусты В. В. Кашкадамова бу хакта, Мария Александровна, Сашага каторга җәзасы бирелсә, моны зур бәхеттән санап кабул итәчәк иде, дип искә ала. Ул инде, улы белән бергәләп, гомерлек каторгага китәргә исәплап тә куйган иде: балаларның олылары үзләре генә яшәрләр, кечкенәләрен янына алырмын, дигән иде...

Әмма җәза көткәндәгедән дә катырак булып чыга: Александр Ильичны үлемгә, Анна Ильиничнаны биш елга Көнчыгыш Себергә сөрергә хөкем итәләр. Кыз баланың бу юлда тәмам харап булачагын аңлап, 1887 елның 20 апрелендә Мария Александровна полиция департаментына үтенеч яза: «... 18 апрельдә мин, кызымның

язмышын җиңеләйтүне сорап, бер тапкыр мөрәҗәгать иткән идем. Хуҗалыкны туздыру никадәр генә аяныч булса да, әгәр үтенечем канәгатьләндерелмәсә, кечкенә балаларымны ияртеп, минем үземә дә Көнчыгыш Себергә китәргә туры киләчәк. Кызымны Көнчыгыш түгел, ә Көнбатыш Себергә генә сөреп, Томскида минем белән бергә яшәргә рөхсәт бирсәгез генә дә, без моны Сез галиҗәнапнең дүрт сабые булган гаиләгә карата кылган зур мәрхәмәте дип кабул итәр идек. Инде монысы ярамаса, Сез галиҗәнаптән миңа кызым белән Красноярскида яшәргә рөхсәт сорар идем!..»

25 апрельдә ана полиция департаменты директорына тагын үтенеч җибәрә. Анда: «...коточкыч кайгымны җиңеләйтү йөзеннән кызымны якын туганнарым яши торган Казан каласына яки кызымның кияве (сүз М. Т. Елизаров турында бара — М. С.) урнашкан Сембер шәһәре тирәсендәге Самарага гына сөрергә рөхсәт итмәссезме?» — дигән юллар бар.

Мария Александровна М. Т. Елизаров һәм туган тиешле кешеләре М. Песковский ярдәмендә кызының Көнчыгыш Себергә билгеләнгән сөргенен Кокушкино авылына үзгәрттерүгә ирешә.

Ульяновлар гаиләсе Казанга күчеп килә. Анна Ильинична Кокушкинога җибәрелә, Владимир Ильич исә Казан университетына укырга керә. Ана кызының сөрген чорындагы тәртибе өчен һәм, укып бетергәнче, улын үз карамагыннан ычкындырмаячагына ышандырып, язу бирә. Әмма гаиләдәге тынычлык озак дәвам итми. 1887 елның декабрендә студентларның хөкүмәткә каршы ясалган сходкасында актив катнашкан өчен Владимир Ильич кулга алына һәм полициянең яшерен күзәтүе астында шәһәрдән Кокушкинога сөрелә. Бу чакта Ольга белән Дмитрий Казанда укыйлар әле, шунлыктан Мария Александровнага гел ике арада йөрергә туры килә.

1887 елның 18 ноябрендә Анна Ильинична дустына язган хатында: «Сеңелем (сүз Маняша турында бара — М. С.) минем янда әле. Аны шәһәрдә генә тотарга дигән идем дә, әни ризалашмады. Ул минем ялгыз яшәүнең кыенлыгын тирәннән аңлый... Гомумән, безнең әни миннән көчлерәк», — ди. Анна Ильиничнаның 1888 елның 14 сентябрендә язган башка бер хатында әни Казанда квартира тапты, дигән юллар бар. Бу чакта инде Владимир Ильичка шәһәрдә яшәргә рөхсәт бирелә. Әлеге квартира турында сүзләр В. И. Ленинның музей-йортына (Казанның Ульяновлар урамындагы 5 йорт) карый.

Мария Александровна өйне яшәү өчен бик җайлы иттереп җыештырырга оста була. Ул, гомумән, тик тора белми. Бу хакта Мария Ильинична: «Ул я тегә, я бәйли, я өйгә бик кирәкле башка берәр мәшәкать артыннан йөри, — дип яза. — Буш вакыт тисә, китаплар дөньясына чума, бик күп укый. Укудан туктаган арада рояль янына килеп утыра, музыкага бирелә...»

Китаплар һәм музыка — Мария Александровнаның мәңгелек юлдашлары. Миңа В. И. Ленинның Мәскәү Кремлендәге музей бүлмәсендә бу гаилә байлыгындагы ноталар белән танышырга туры килде. 400 ләп музыкаль әсәрнең нотасы бар анда. Казанда алынганнары да шактый. Аларын тышлыктагы: «Көнчыгыш лирасы. Музыка кибете. Казан.» кебек махсус мөһерләрдән, истәлекле язмалардан танырга мөмкин. Миңа ул ноталар аеруча кадерлерәк тоелды, аларга озаклап сокланып карап тордым. Мария Александровнаның Казанда Вебер, Глинка, Гайден әсәрләрен, романслар уйнап утыруын күз алдына китерергә тырыштым.

Билгеле булганча, Казанда яшәгәндә Мария Александровнага төрле оешмаларга күп санлы үтенечләр белән мөрәҗәгать итәргә туры килә. Володясының укуы өзелеп калгач, ана бигрәк тә борчыла.

Улына югары белем алырга мөмкинлек бирүләрен сорап, кемнәргә генә йөрми ул! Әле анда Мария Александровна балаларының 19 (!) тапкыр кулга алыначакларын, сөргеннәрдә, эмиграцияләрдә газап чигеп йөриячәкләрен һәм, аларның язмышын җиңеләйтер өчен, күпме баш ватачагын уена да кертми.

Бу ана гомере эчендә 200 дән артыграк үтенеч яза. Төрле чиндагы түрәләр янына балалары өчен үтенеч кәгазьләрен тотып кергәндә дә ул бик тыныч, итагатьле һәм сабыр булып кала белә. Ананың үз сүзләренә караганда, нәкъ менә шушы сыйфатлар аңа түрәләрнең, төрмә хуҗаларының хөрмәтен казанырга мөмкинлек бирәләр.

Үзе революционер булмаса да, Мария Александровна балаларының дөньяга карашын, омтылышларын тирәннән аңлый, аларга ярдәмгә әзер тора, алар белән горурланып яши. Киевта дүрт баласы: Анна, Мария, Дмитрий һәм аның хатыны Антонина — барысы берьюлы кулга алынганда, анага инде 70 яшь. Шуңа да карамастан, ул көн саен диярлек, кулына дүрт төенчек тотып, үзенә таныш та булмаган шәһәрнең төрле якларына урнашкан төрмәләре арасында йөри.

Мария Александровна киләчәкнең яктылыгына ышана. Вафатына берничә генә көн калгач, моңсуланып, ул: «...бераздан кабат уянырга мөмкин булса икән!— дип сөйли.— Кешеләрнең ул чакта ничек яшәгәнен күрсәң иде!..»

1916 елның 12 (25) июлендә дөньядан киткән Мария Александровнаны Петербургның Волков зиратына күмәләр. Бу кайгылы вакыйгадан соң гаиләнең бер дусты М. Т. Елизаровка: «Шулкадәр яхшы күңелле Мария Александровна кебек кешенең инде безнең арада юклыгы турында уйлавы да авыр,— дип яза.— Мондый гомер бик сирәк кешеләргә тия...»

Мария Александровнаның гомере исә аның берсеннән-берсе акыллырак балалары тормышында дәвам итә башлый. Әнисе турындагы истәлекләрендә Мария Ильинична болай яза: «Владимир Ильичның кыяфәте әнинекенә охшамаган иде, ...әмма күзләре — нәкъ әниемнеке. Шулай ук кешеләргә карата гаҗәеп сизгер һәм игътибарлы мөнәсәбәте дә — әнидән күчкән гадәт. Владимир Ильичның тормыш юлы да, әлбәттә, бөтенләй башка юнәлештә, нәкъ әнинеке кебек үк туры, максатчан һәм искиткеч якты булып чыкты».

Җанын аямыйча тәрбияләгән балаларының — Владимир Ильич Ленин — дөнья пролетариатының юлбашчысы, миллионнарны якты көннәргә китереп чыгарган икән, Мария Александровнадан да бәхетлерәк ананың булуы мөмкинме?!

*КПССның XXVII съездын каршылап*

## Аяз Гыйләҗев

# ШӘҺӘР ЮЛЛАРЫ АВЫЛГА ИЛТӘ

Сизәсездер, сүз авыл турында булачак.

Әллә башта шәһәргә кагылып чыгыйкмы?..

Тәвәкәллим — иң әүвәл үзем турында! Юк, юк, мактанырга җыенмыйм, курыкмагыз. Мактану егерме-утызда килешә. Ә миңа... алтмыш якынлаша! Ярый, кузгалдык... Яшерен-батырын түгел, үзем турында сөйләргә җыенып байтак газапланып йөрдем... Кызык! Бармый гына!.. Язарга утыруга фикер җебем сәрлегеп туктап кала. Башта аның турында сөйләп бирергә кирәктер, ахрысы? Аннан башка мин кузгатасы гәп тә, уй уртасында булган вакыйгалар да, катнашучылар да ахыргача аңлашылып бетмәячәк. Мәгълүм ки, һәр кеше, аның күңел серләре барЫ тик бүтәннәр белән эшлекле мөнәсәбәттә генә ачылып китә. Кемнең кемлеген эштә, мәшәкатьтә, юлда гына күрәсең. Әгәр гомер юлымда ул очрамаса, бүгенге сүз кузгалыр идеме икән?..

Алай да?.. Нәни генә кереш сүз: мин — авыл баласы. «Авыл кешесе, шәһәрдә яшәсә дә, аның авызыннан ун елга якын бәрәңгесе күренеп тора», дип шаяртырга ярата минем якын дустым, яшьтәшем шагыйрь Шәүкәт Галиев. Кемнәрнеңдер авыл кешесеннән шулай мыскыллап көлүенә ишарә ясый. Заманалар уза тора, мәкальләргә дә яңа мәгънә, һич көтелмәгән төсмерләр өстәлә тора... Ах, дип куясың, авылдан шәһәргә күчкәннәрнең җанында авыл дигән искиткеч күп мәгънәле сүз, бөтенлеге белән, сакланып калсын иде әле! Кашки! Без озак еллар шәһәр белән авыл арасын якынайту турында кайнар нотыклар сөйләдек, монда сүз бары бер якка — авылны шәһәргә якынайту турында гына бара иде. Ниһаять, сүз шәһәрне авылга якынайту турында кузгалды. Бик вакытлы кузгалды, Зәй районының Тукай исемендәге колхоз председателе Исмәгыйль Сәгыйтдинов исә: «Бераз соңгарак калып башламадыкмы икән бу җитди олы сүзне?» — дип тә куйды соңгы очрашуыбызда. Аның сүзенә колак салмыйча ярамый, бер хуҗалыкта егерме җиденче елын эшләп, авылга гомерен багышлаган кеше. Чирек гасырдан артык бер колхозда председатель! Авылның иң катлаулы, кискен үзгәрешләр кичергән чоры аның катнашында, аның күз алдында үткән!

Әйткәнемчә, мин — авыл баласы, авыл — минем бишегем, таүге якты сукмагым, бабамнарның гомер бураэнасы, уйларымның бәреп чыккан чишмәсе, хисләремнең язгы шашкын ташкыны, хатирәләремнең иң мөкатдәсе. Авыл — минем гомер юлымның сихри башланышы, тере чыганагы... Олы юлга, тормыш-көрәш юлына мин Зәйдән, Югары Баграж авылыннан, керәшенстаннан чыгып киткән кеше.

Олы юлга...

Шулай дип яздым да, балачагым, сугыш еллары, сугыштан соңгы авыр чор, шул чорның гүзәл кешеләре, аз сүзле кырыс ирләр, мәңгегә ачылмас кебек кысылган иренле, яулыкларын күзләренә төшереп бәйләгән апа-җиңгәләр күз алдымнан терелеп узды. Сезне калдырып Олы юлга чыгып киттем дип әйтүем, зинһар, рәнҗету булмасын! Сезнең белән дә мин Олы юлда булганмын, гаҗәеп маҗаралы, истәлекле һәм сөенечле булган ул авыр еллар! Кырык биштә, сугыш тәмам булган елда мин сездән аерылдым...

Мәктәп дәреслекләрендәге бер мәсьәлә хәтергә төште әле.

«А» станциясеннән поезд чыга юлга. «Б» станциясеннән икенчесе кузгала. Ике поездның да кузгалу вакыты, тизлеге бирелгән. Аларның кайчан һәм нинди ераклыкта очрашуларын табу сорала. Поезд күргән юк, безнең төбәк кара як санала, күбрәк шул сихри ерак юллар, ыжгырып көн-төн алга барган паровозлар турында уйлап утыргангамы, бу мәсьәләне чишү миңа ифрат газаплы күренә иде. Чынлап баксаң, аның асылы бик гади булган икән! Чыга поезд, бара, тизлек бирелгән, юллар салынган, диспетчерлар, дежурныйлар хәрәкәтеңне күздә тоталар, семафорлар бер кабына, бер сүнә! Чап та чап!..

Әлбәттә, чабачак алар, очрашачак та!

Ә менә син, моңарчы беркем белмәгән, барлыгын да күрше-тирә авыллар гына ишеткән Югары Багражавылыннан әллә кайларга барып җитмәк, әллә нинди бөек эшләр майтармак булып чыгып китәсең. Аякта — чабата-оек, җилкәдә биштәрле капчык. Капчыкта — Тукай, Такташ китаплары, бер кыерчык ипи һәм чүлли шешәсенә тутырган сары май. Хәтерлисезме, Әмирхан Еникинең «Матурлык» дигән бөек хикәясендәге ярлы шәкерт Бәдретдинне?! Майны без белән чеметеп ашый торган ярлы баласын?! Без исә майны нәзек очлы чыра белән ашый торган идек. Безнең замандагы авыллар әле әнә шундый иде...

Чыгасың Олы юлга. Тормыш әзерләгән дә юк түгел, сиңа унҗиде яшь, о, авыл өчен зур яшь инде бу! Тормышның бал түгеллеген яхшы аңлыйсың, авыл кешесенең җаны синең өчен ап-ачык, крестьян хезмәтенең бар ягын син тормыш дигән китаптан укып үзең белдең, үзең өйрәндең. Авыл сине кеше итеп озатты. Яшәү авыр, юллар чуалчык булса да, авыл кешесе синең өчен, барыннан да элек, ифрат тырыш, намуслы, киң күңелле, гади кеше. Аның бер пешерерлек умач оны өчен никадәр тир түккәнен син үзең күрдең, сугыш елларының хәтәрен бергә кичердең, алар белән бергә җигелеп бәрәңге ызанында сука тарттың. «Трактор-трактор... сука бабай, ерак тор! Синнән артык эшләгәнне читтән генә карап тор!» — дип, күңелле җырлый-җырлый, без тәртә арасына үзебез кердек.

Алай да, алай да... Никадәр кыен ашасам да, яшьли буразна арасына тәгәрәп керсәм дә, мин күңелемдә авыл турында Олы уйлар төяп Олы юлга чыккан кеше. Мәңге сүнмәс кайнар мәхәббәт алып...

Аннары, аннары...

Олы юлдан атлар уза,
Безгә кала тузаны.
Алда да гомерләр бардыр —
Сагындыра узганы...

Алтынчы дистәне тутырып килгәндә, үзеңне тудырган авыл турында бары тик матур уйлыйсы гына килә! (Аз гына, бер-ике сүз белән генә мактанмыйча да эш барып чыкмас кебек, кичерерсез!)

Гомерем буе авылга тугрылык сакладым дисәм дә ялгыш түгел, кешеләрен олыладым, әсәрләремдә эшсез-ялкауларны, яңа заман мещаннарын шактый тукмасам да крестьян турында күбрәк яхшы сүз әйтергә тырыштым. Авыл кешесенә мөнәсәбәт — минем өчен кешеләр белән аңлашу чарасы булып калды. Авызыннан бәрәңгесе күптән күренмәсә дә, авыл хезмәтеннән җирәнгән, җирдән аерылган, туган төбәген бөтенләй ташлаган, яхшы чактамы, кыен чактамы аңа хыянәт иткән кешеләрдә мин рухи кимлек, ярлылык күрдем. Иленнән аерылганнарны мин бер чакта да тулы бәхетле итеп исәпләмәдем! Юк, һәркемнең дә авылда туып үз төбәгендә үлгәнче яшәвен теләмәдем, шәһәргә күчеп, анда әллә нинди катлы-катлы чиннар, дәрәҗәләр алып та соңгы чиктә авыл турында кайгыртып була, бер җае чыга аның, авыл мең төрле ярдәмгә мохтаҗ һәм ярдәменең төрле-төрле юлларын табып була!

Олыгайган саен авылга мәхәббәтем сүрелмәде, көчәя барды, ачыкланды, авыл турында кайта-кайта бөтен гомерем буе яздым. Очрашуларда якташларыма, кадерле юлдашларыма иң-иң газиз сүзләремне әйтергә ашыктым...

Аның белән (хәзер сүз аңа борылачак!) сиксән дүртнең февралендә очраштым. Уйламаганда, көтмәгәндә.

Түбән Камага, атаклы «Җидегән чишмә» клубына кунакка дәшкәннәр иде. Очып бардым, канатланып йөрдем, сөенеп таныштым. Нефтехимиклар каласында шатланырлык хәлләр күп иде. Истәлекле очрашулар, дулкынландыргыч танышулар, күңелне кузгата торган әңгәмәләр күп булды. Заводларга кердек, юлларга чыктык, авылларга бардык.

Без аның белән шунда таныштык. Ул дигәнем — Рәшит Вәлиевич Абдулхәкимов, Түбән Камадагы «Жилстрой» трестының начальнигы, Татарстанның атказанган төзүчесе! Шәһәрдә йортлар төзи трест, больницалар, кибетләр сала, институт бинасын тәмамлап килә. Йортларның матурлыгына хәйран калып тамаша кылып йөрдем, уртак сүзләр күп булды. Шунда Рәшит Вәлиевичнең кайбер фикерләре хәйран калдырды.

«Безнең бабайлар революция ясаган. Тарих тәгәрмәчен үзләре теләгән якка борып җибәрә алган. Дөньяның йөзен, тарихның агышын үзгәрткәннәр. Безнең әтиләр Ватан сугышында җиңеп чыкканнар. Көч-гайрәтләре белән дөньяны таң калдырганнар. Безнең буын исә Яңа авылны тудырырга тиеш. Хәзер илдәге иң мөһим, иң катлаулы һәм иң авыр эш — авылда. Авылның язмышын яңартырга вакыт! Төп бурыч хәзер шул!»

Кем сөйли бу сүзләрне? Авыл кешесеме, әллә шәһәрдәге зур төзү оешмасының җитәкчесеме?!

«Шәһәрдә күпме яшәсәм дә авылны һаман оныта алмыйм. Бу — бер кылану яки матур сүз сөйләү генә түгел. Һаман-һаман бер төш күрәм мин. Офыктан-офыкка сузылган арыш кыры икән. Кырның арышныкы икәне дә ап-ачык. Шул арыш арасындагы тар сукмактан

кайдыр йөгерәм, һич тукталып тормыйм, чабам-чабам, башаклар түшемә үреләләр, тезенмә сәлам тырный... Кыр өстендә килеш уянам».

Һәм ул үтә җитди итеп өстәде:

«Мөгаен, мин начар председатель булмас идем. Күңелемнән һаман шул уй китми, тормышка ашмаган, инде ашмаслыгы да ачыкланган хыял бимазалый...»

Хезмәте белән озак елларга авылдан аерылган, авыл хуҗалыгы белән балачагы аша гына бәйләнгән икенче кеше авызыннан шуңа охшашрак сүз ишетәм. «Җәлилнефть» идарәсенең начальнигы Шәфагать Фәхразович Тәхәветдинов кызып-кызып ярдәмче хуҗалыкка җир-сулар алырга ниятләп даулашып йөргәндә болай дигән иде:

«Авыл хуҗалыгында эш күрсәтәсе иде! Кайбер хәсрәт җитәкчеләрнең җебегәнлеге, сүлпәнлеге, ахмаклыгы белән очрашасың да... эх, эшләп күрсәтәсе иде шуларга! дип, кул кычыта! Тирә-якта никадәр мөмкинлек бар, җирдә алтын ята, иелеп алырга гына иренәләр!»

Үз буыныңның бурычын, үз чордашларының яшәү мәгънәсен Р. В. Абдулхәкимов мин уйламаган, көтмәгән яктан китереп куйды.

Авыл... Авыл хуҗалыгы. Авыл язмышы...

Нигә алай?! Нигә Рәшит Вәлиевичнең төшенә һаман арыш кыры керә!? Ни бимазалый аның күңелен? Хәзерге хезмәтеннән канәгать түгелме? Эшен яратмыймы? Алай дисәң, Рәшит Вәлиевич Абдулхәкимов шәһәрдә абруйлы кеше. Хезмәт хакы да әйбәт кенә Яшәгән урыны менә дигән. Гаиләсе түгәрәк, тәгәрәп ике кызы үсеп килә. Эше — муеннан! Эше мактаулы!.. Күңел барыбер нидер эзли. Күңел туймый. Күңел тынычланмый. Тәҗрибәмнән чыгып беләм, андый кешенең күңел җепләре тагы да олырак, тагы да катлаулырак тормыш мәсьәләләренә барып тоташа торган була. Андый кешенең күңеле хәрәкәттә...

Рәшит Вәлиевич Түбән Камага 1965 елда Казанда институт тәмамлап килеп урнаша. (Студент чагында практиканы шунда уза да шәһәрнең киләчәгенә гашыйк була!) Монда эшлисе эшләр ничәмә-ничә елларга җитәчәк әле!..

Килә, урнаша. Башта — гади мастер. Мастер — эшче белән эшне берләштерә торган бәйрә, җаваплы зат. Мастер булып эшләү—төзелештә иң мөһим практика узу, мәктәп. Институттан соң һәркем мастерлык мәктәбен узарга тиеш. (Абдулхәкимов шулай дип саный.) Аннары — прораб. Өлкән прораб. Техник—производство бүлеге начальнигы. Ниһаять, төзелеш идарәсенең баш инженеры. «Инженер» сүзенең нигезендә «хәрәкәт» мәгънәсе ята, алга илтүче, хәрәкәтләндерүче...

Егерме ел шушы шәһәр төзелешенә багышланган. «Әгәр мин йөргән эзләрне ничек тә булса сызып күрсәтсәң... ничә кырмыска оясы килеп чыгар иде икән?!»

Егерме ел төрле эштә, әмма бер шәһәрдә. Эше эленке-салынкы барса, коллективлар, яңаша оешмалар белән уртак тел табалмаса, бер шәһәрдә нәтиҗәле һәм уңышлы эшли алыр идеме Абдулхәкимов?!

Хезмәт кешесенең, җитәкченең түбәннән күтәрелүе, үз чамасында баскычның һәр аратасында тукталып торуы файдага түгел мени?! Арата — биеклек ул, һәр биеклектән җир һәм күк төрлечә күренә. Туктап торган арада дөньяга карап уйланырга да өлгерәсең: югарыга карап фикер йөрт тә түбәнгә карап шөкер ит! Уеңы-чыны бергә татар фәлсәфәсенең!

Төзелеш факультетында укысам да, институт елларым доцент Сладков җитәкләгән архитектура түгәрәге белән бәйләнештә узды. Бер утырышны да калдырмадым! Соңыннан төзелешнең кайсы тармагында гына эшләсәм дә, архитектураны белү, нечкәлекләрен аңлау зур ярдәм итте... Турысын әйткәндә, тормышымның күп тармакларыннан уңдым. Түбән Каманың гүзәл төзелешләренә катнаштым. «Кама» гостиницасы безнеке, ничә мәктәп, больница гына салдык! Һәрберсе күркәм объектлар. Андый корылмалар бик күп төзүчеләрнең төшенә дә керми. Эш никадәр катлаулы, авыр икән, мин шул чаклы куанам! Җаным җәя бавы кебек киеренке торганны яратам... Түбән Камага килеп уңдым дидем...

Байтак еллар Евгений Никифорович Королев кул астында эшләдем. Социалистик Хезмәт Герое, акыллы һәм таләпчән җитәкче, чын мәгънәсендә бик күпләргә остаз булган кеше. Ул кешенең үзе белмәгән мөмкинлекләрен ача, дәртләндерә, кыюлык өсти торган зат, яшьләрне гел алга әйди, бар белгәнен, бар булганын юмарт рәвештә бүлеп бирә. Йөрергә һәм йөгерергә өйрәнгәндә янында кем булу бик мөһим ич. Кыюк атлап китүең дә бар. «Б» станциясенә барып җитеп кара аннары! Ул һәрбер җитәкчедән — бригадирдан башлап идарә начальникларына кадәр — һәркемнән эшкә иҗади мөнәсәбәт таләп итә иде. Гади эшчедән дә! Эш дәверендә синең кирпечне ничек тотуыңнан ук кемлегеңне күреп ала, ялгышсаң, вакытында төзәтә, алга омтылышыңда уңай шартлар тудыра. Төзелешнең талантлы остасы иде Евгений Никифорович. Хәзер ул ялда. Ул мине үйләрнең югарысына күнектерде, икеләнүне, каушап калуны бер чакта да гафу итмәде, олы эшләрнең күп очракта бер кеше ихтыяры белән җиңеп чыга икәнлеген инандырды, кирәген белеп кенә каты куллы, чама белән генә каты телле була белде. Яшь чагында, эш башлаганда кемнән

акыл, хәер-фатиха алуның ничаклы мөһим икәнен мин аның янәшәсендә эшләгәндә аңладым...

Төзелеш минем хыялым иде. Яңа шәһәр төзи башлау кадәресе чамасыз зур горурлык та иде.

Эш хәзер дә җиңел түгел, ансат башланмады да. Мин килгәндә, трестта шактый буталчык чор иде. Кем сүзе беләндер төзелеш идарәләрен бетерергә җыеналар, күп звеноларда таркаулык, шик-шөбһә хөкем сөрә иде. Без трестның яшәргә хакы барлыгын хезмәтебез белән расладык. Хәзер карагыз, тирә-якта — бәхетем, горурлыгым, мактанычым, яшәү мәгънәм булган корылмалар. «Җәлил» кинотеатры... Автовокзал. Соңгысының проектын да үзем башкардым. Бигеш аэропорты. Яңа Техника йорты. Гаҗәеп пулат! Әкиятләрдә генә тасвирланган хыялый сарай. Матурлык дөньясы. Больницаның уникаль хирургия корпусы. (Моның чыннан да матур, эш өчен гаҗәеп уңайлы икәнен шәһәрнең баш хирургы игле һәм сабыр карашлы Гамир Гарифович Исмәгыйлов та раслады.)

Мин аерата мәктәпләр, балалар бакчалары төзелешен яратам.

Иң соңгы эшләр тәмамлана. Мәшәкатьләр, борчылулар онытыла. Тәрәзәләр юылган, пәрдәләр эленмәгән әле, җиһазлар куелмаган, шуңадыр бөтен почмакларга ак яктылык кереп тулган... Киңәеп калган коридор буйлап акрын гына барасың... Тәрәзәләр — бала күзе кебек яктырып, өмет белән сиңа текәлеп калалар... Уйларның иң татлысы, иң газизе генә иңә шулчак күңелгә! Анда-монда качып калган вак-төяк житешсезлекләр дә күңелгә ук булып кадала, матур булсын дип тырышасың, шушы гүзәллекнең киләчәктә балаларга да йогынтысы тими калмас дип өметләнәсең. Төзүче киләчәк дөньяны бары тик имин, тыныч итеп күрергә генә тели дә!..

Тагын бер горурлыгым: Түбән Камада күбесенчә кирпеч йортлар салдык. Кирпеч корылмалар. Безнең шәһәрдә союзның башка бер каласында да очрамаган уникаль кирпеч йортлар бар. Яшәү өчен дә уңайлы, күрер-күзгә дә рәхәт. Шәһәр матурлыгы — төзүченең киләчәк буыннар алдында отчеты...

Шәһәрдәге яшеллеккә генә игътибар итегез...

Беренче мәртәбә эшкә чыгуым 1965 елның 14 гыйнварында булган. Туган көнемдә. Үз бәйрәмем бөтенләй хәтердән чыккан! Инде соңыннан, киләчәккә карап, хатирәләр белән дә яши башлагач кына ул көн искә төште. Туган көнем телгә килгәч, туган якларны, яшеллекне сөйләмичә узып булмый. Чөнки балачагым белән Түбән Кама яшеллеге арасында турыдан-туры бәйләныш бар. Хәзер аңлатам...

Татарстаннан читтә тудым, Сергач районында, Метрәвыл дигән авылда, русча Андреевка дип йөртәләр. Авыл мәктәбендә укып йөрим шулай, берзаман безгә директор итеп Казаннан Блинов фамилияле кешене җибәрделәр. Кызганычка каршы, исеме хәтердә калмаган. Тынгысыз җан булгандыр инде, безне бер дә тик тотмады. Спорт ярышлары оештырды, түгәрәкләр, гел эштә идек, гел хәрәкәттә. Мәктәп белән авыл арасы — ярты чакрымнар булыр — бушлык. Шушы буш араны парк итеп үзгәртергә карар чыгардык. Директорыбыз башлап йөри, телендә гел — «парк зонасы». Һәр класска аерым-аерым кишәрлек бүлеп бирделәр. Һәр укучының үз бүлеме, үз җире булды. Шунда агач утыртырга һәм үстерергә кирәк. Урман — 5 километрда. Гомергә онытасым юк, урманга агач алырга барырга җыенгач, әнием миңа иске шәлен бирде. Болай диде ул: «Балам, олан, яшь агачларның тамыры имгәнмәслек итеп шәлгә төреп, кадерләп, иплән кенә алып кайт!..» Иске шәл хуҗалыкта нигә булса да ярар иде, әнинең юмартлыгы һәм шул чакта әйткән сүзләре күңелемне тетрәтте. Яңалыкка сусаган күңелгә шифалы яңгыр булып төште ул сүзләр!

Әни шәленә урап беренче агачымны — миләш куагы алып кайтып утырттым. Һәр көн мәктәпкә барганда һәм кайтканда шул агачка сәлам биреп узам, корыга китсә, су сибәм. Олырак малайлар «Рәшиткә агач җене кагылган», дип мыскыл итсәләр дә мин шул гадәтемне ташламадым. Берсе янына икенчесен алып кайттым, өченчесен, үз кишәрлегемдә буш урын калмады. Малайларның мыскыл итүе сәбәп булдымы, мин шул яшь урманда ялгызым йөрергә ярата башладым: йөрим, йөрим, йөреп туймыйм. Хезмәтнең нәтиҗәсен күрү рәхәтлеге аңга шул чакта сеңеп калмадымы икән?!.

Әтием дә агач утыртырга яраткан, янбакчада аның истәлеге булып шомырт, миләш агачлары үсеп утыра. Алдагы көздә мин урманнан үз бакчабызга да байтак куаклар — шомырт, миләш алып кайтып утырттым. Шуннан бирле миләш агачын якын күрәм. Дус-иш арасында «миләш—минем үземә охшаган агач!» дип шаярткалыйм.

«Миләш — минем тормышым кебек матур, хезмәтем кебек файдалы, минем язмышым кебек ачы», дип куям...

Яшеллек турында сөйли идем...

Килгәч тә 2 нче мәктәпне төзеп тапшырдык. Мәктәп тирәсен агач белән бизәдек. Хәзер алар 10-15 метрлы зифа каеннар булып үсеп җитте. Мин әле дә, вакыт сыйдырса, шул агачларга сәлам биреп узам. Ул каеннәрнең шаһитлары! Эшли башлаганнан бирле, 20 ел

дәвамында, Түбән Кама туфрагына 100 мең төп агач утырттык. Йөз мең төп! Үзе бер карурман. Һәммәсе дә гади миләш агачыннан, Блинов агай дәртләндергән «парк зонасы»ннан башланды дип әйтер идем... тыйнаксыз дип әйтерләр. Яшеллек — безнең трестның горурлыгы!»

Тормыш итәргә әзерләнгәндә ата-ананың сизгерлек һәм киң күңеллелек күрсәтүе никадәр кирәк! Җирдә мәрхәмәтле, шәфкатьле җаннар күпме булса, без һәммәсе өчен дә беренче нәүбәттә изге ата-аналарга бурычлы. Гаилә — иң саф чишмә чыганагы, тормышның иң тәэсирле, мәңге онытылмас якты кузәнәге.

Рәшит Вәлиевичнең ата-анасы турында сөйләгәннәрен тыңлап мин шундый нәтиҗә ясадым...

Ярый, хуш, узганы мәгънәле, бүгенгесе бөтен, киләчәге ныклы-өметле, нигә кирә соң аңа чуар төшләр?! Нинди ымнар, каян килеп аның күңелен чиртә?! Әше күркәм, җаны тыныч, тагын ни кирәк аңа?!

«Өч-дүрт елда без «Жилстрой» коллективын ике мең кешегә җиткердек. (Мине 1973 нче елда трест начальнигы итеп билгеләделәр.) 5 төзү идарәсе оештырдык. Химия үсә, киңәя барган саен шәһәребезгә торак йортлар, социаль-культура объектлары күбрәк кирәк була бара иде. Эш яңа темп таләп итте, ә мөмкинлек чикләнгәнрәк иде. Читтән «ашыгыч ярдәм» ала башладык. Башкалабыз Мәскәү 13 йорт җибәрде (барысы 65 мең квадрат метр), Тольяттидан — 4, Яңа Чабаксардан 6 «бүләк» йорт алдык. Чаллы йортлар төзү комбинаты 1 млн. квадрат метрга якын торак йортлар җибәрде. Бу комбинат турында аерым сүз әйтергә иде...»

Чаллы йортлар төзү комбинаты, аның җитәкчесе мәшһүр төзүче-философ Марат Шакирович Бибишев яшь Абдулхакимовның кеше һәм төзүче буларак җитлегүендә хөрмәтле бер урын тота. Аларның очрашуы, белешүе, бәхетле сәгатьтә, бәхетле йолдызлар астында була!

Рәшит Вәлиевичнең үзен тыңлап карыйк:

«Чаллыдагы грандиоз төзелеш түбәнкамалылар өчен дә искиткеч вакыйга иде. Мин еш кына анда барам, җитәкчеләр белән очрашам, тәҗрибәле төзүчеләр — мәскәүлеләр белән фикер алышам, өйрәнәм, чагыштырып карыйм. Кемдә яхшы, кемдә шәбрәк, кемдә төзелешнең иң прогрессив ысуллары — шулар янына барырга ашкындым. Комбинат җитәкчесе Марат Шакирович — минем рухи атам, дисәм дә, хата булмас. Шәһәр төзелеше җәһәтеннән мин аннан бик күп файдалы киңәшләр ишеттем. Шуның өстенә авыл турында уйларга, авылның бүгенге яшәешенә башкачарак күз белән карарга да ул этәрде, күңелгә өеткыны ул салды, кыскасы, күземне ачты. Авылда туып, авылны сагынып яшәсәк тә без аның язмышы турында тирәнтен уйлый алмыйбыз икән әле! Авылның хезмәт кешесен Бибишев кадәр аңлый да алмыйбыз икән! «Әйе, диде ул, заманча шәһәрләр салу — горурлык. Үзеңнән соң киләчәк буыннарга шәһәр бүләк итү — зур мәртәбә... Шуны да онытмасак иде — без Татарстан җирендә яшибез. Зур төзелешләр, яңа калалар, республикабызга бик күп яңа кешеләр дәшеп китерәчәк. Кемдер төпләнер, кемдер китеп барыр. Без гомергә монда яшисе. Без шушы җирнеке. Шәһәр-шәһәр дип янсак та безгә авылны онытырга ярамый! Авылны! Бүгенге авылның хәле катлаулы. Колхозчының, совхоз эшчесенең хәлен җиңеләйтәсе иде... Авыр фронт юлларында авыл егетләре илгә тугрылыкларын, кыюлыкларын соңгы тамчы каннары белән раслап күрсәттеләр. Күпмесе һәлак булды?! Нигездә алар пехотада иде, гади солдатлар, иң авыр сызыкта. Бик азы гына исән кайтты аларның. Ятим калган авыллар тормышында бу югалту үзен нык сиздерә. Яшьләр кичәге сугышчыларны, авылларны язмыш ирегендә калдыралар. Авыл кешеләренең исә яхшырак, тулырак тормыш белән яшәргә хаклары бар! Күпме корбаннар бәрабәренә яулап алынган бәхетнең тулы булуы яхшы. Авылларны шәһәргә каршы куярга җыенмыйм, мәгәр без барыбыз да бүгенге авыл кешесе алдында бурычлы әле».

Мәгънәле сүзләр! Чын сүзләр! Ир кеше уйлары!.. Һәм алар бәрәкәтле туфракка барып төшәләр — Рәшит Вәлиевичнең күз аллары яктырып, офыгы киңәеп китә. «Шәһәрдән торып та авыл кешеләренә ярдәм итеп була икән ләбаса!»

Бибишев авызыннан ишеткәч ул беравык хәйран калып тора: бу сүзләр аның уйлары белән таңгал килә ич! Төзүче буларак ул еш кына авылда йорт салулар, аның мәшәкате, чыгымнары, күңелле өмәләре турында еш уйлый иде.

Авыл кешесе гомерендә йорт салып керергә тиеш. Бу — авыл кагыйдәсе, какшамас законы. Йорт салу — нигезеңне ныгыту, ата-бабадан килгән йоланы тоту, әгәр син шуны эшли алмасаң, төшеп калган адәм. Баяң сукыр бер тиен. Йорт салыр вакыт җитә башлагач кеше иң әүвәл бура кайгырта. Каян юнәтергә?! Үзеңә бураргамы, әзерне сатып алыргамы? Ниндине? Бура артыннан йөргәндә хуҗа акрын-акрын такта-токтасын, кадагын-кирпечен, нигез ташын, тәрәзә борысльнка иманен, мич капкачын, юшкеләрне берәмтекләп юнәтә, җыя бара. Йорт салып керер өчен еллар буе әзерләнәләр! Ниһаять, аның үз морҗасыннан үз төтене чыга башлый, хуҗаның абруе арта, аның хакында: «Ә, улмы? ул,

җаным, шыгырдап торган нараттан уналты ниргәле, алты почмаклы йорт җиткезеп кергән егет булыр!» — дип сөйли башлыйлар. Әгәр бераү гомерендә ике тапкыр йорт җиткерсә, аның даны буыннан-буынга күчә. «Йорт җиткереп улын башка чыгарды!» дип мактыйлар аны.

Элекке елларда авыл кешесенең ярты гомере йорт салу мәшәкате белән уза иде. Йорт салу мәшәкате аны ярым картайта, чиен чыгара, йокысыз калдыра, тамактан яздыра, бурычлы итә... Байтак җилбәзәкләр йорт торгызудан шүрләп шыпан-шыпан гына, башка мең төрле сәбәп табып авылдан ук чыгып таялар иде. Шәһәрдә һәммә кеше калач ашый, әзергә-бәзер яши, җиңел-ансат кына квартиралы була, ал да гөл дип белә иде авыл агае. Шәһәрләрдә дә квартира мәсьәләсенең шактый катлаулы, шактый мәшәкатьле эш икәнен белми иде әле ул. «Шәһәр агайнесе ансат кына, житез генә кулына ордер һәм ачкыч тотып әзер фатирга керә дә утыра. Өч бүлмәле аның квартирасы, яки икеле, салкын су трубадан килә, кайнар су гөжләп тора, газы, ваннасы, һәм... бөтенесе җып-җылы, үзендә! Аерма бармы? Бар!»

Шәһәр кешесе алдында авыл агае ким кеше булып кала... Әйтик берзаман ул каклаган казын тотып шәһәрдәге туганына кунакка килә. Юл буе күңеле уйный, теле кычыта: өр яңа нарат бурасы белән мактанырга ашыга ул! Шәһәр квартирасына килеп кергәч аның авызы беразга йомыла: «Менә кая киткән икән эшләр!»

Бу тарихи тигезсезлек гомер-гомергә килгән.

Авыл кешесенең (кайберәүләрнең!) беренче җай чыгу белән койрыкны сыртка салып шәһәргә күчүендә бу тигезсезлекнең тәэсире бар! Исмәгыйль Сәгытдинов: «Соңгарак калдык, безнең яшьләр Чаллыга барып яңа квартираларга нялөшеп өлгерделәр, хәзер аларны җылы түрләреннән берничек тә кузгата алмыйсың!» Хак сүзгә җавап юк! (Исмәгыйль Сәгытдинов «түр» димәде, бик популяр башка сүз кулланды, сүзе үткен иде мәгәр!)

Була, авылның иң уңган, хуҗалыклы кешесе йорт торгызу өчен, арьы чабып, бире килеп тир түгеп йөргәндә, авылның иң булдыксыз, ике бозауга кибәк аера белмәгән Гыйльметдине шәһәргә барып өч бүлмәле фатир алган. Гарьлекме? Нинди генә әле!.. Әйе, мин юри, чак кына күңелләрне чеметер өчен буяуларны куертып та җибәрдем, мәгәр дөрес сүз җанга якын!

Рәшит Вәлиевичнең күңеле нидер эзли иде. Бар да бар кебек югыйсә, һәммәсе җайланып бара, трест үсә, ныгый, Түбән Каманың үзендә йортлар салу комбинаты худка китте. Файдалан, төзе, яшә! Тынмас күңелләргә нидер җитмәс була. Бу прогрессның, алга барышның шарты. Шул чакта аңа горком секретаре шалтырата: «Каенлыга барып кайтыгыз. Аларга бер-бер ярдәм күрсәтеп булмасмы?»

Көз. Эч пошыргыч яңгыр пыскаклап тора. Мондый чакта авыл юллары ямьсез, котсыз тоела. Юлаучылар аз, кырлар буп-буш булса да көн уртасында эңгер-меңгер куерып ята, үзеңне ятим, ялгыз итеп сизәсең андый чакта. Тик Рәшит Вәлиевич күңеле белән каядыр ашкына, Каенлыга барып җитәргә ашыга, горком секретаренең сүзе аны кузгатып җибәрде, тик юллар пычрак, борылыш саен баткак, туктап төшәргә, корырак урынны сайлап машинаны этәргә туры килә. Каенлы авылы турында трактор тора. Күшегеп беткән тракторчының аларны күргәч авызы ерыла.

«Сез Абдулхәкимовмы?» «Мин». «Мине сезне тартып алып кайтырга җибәрделәр. Төш вакытыннан бирле көтәм». «Волга» машинасын тракторга тагалар, чайкала-чайкала, кара дулкыннар тәгәрәтеп, пычрак диңгезенә кереп китәләр. «Кара диңгезне кара диләр, менә кайда ул Кара диңгез!» дип шаярта шофер... Абдулхәкимов борыла-борыла як-ягына каранып бара, ник бер җирдә каен агачы булсын да берәр җирдә ут елтырасын! Баткак юл да, дөм караңгы авыл... Барып җиткәннәрен тракторчы килеп әйткәч кенә абайлыйлар. Монда аларны урамда көтеп торалар икән...

• • •

Хәзер нәни генә тыныш ясап алыйк.

Онытмагыз: Рәшит Вәлиевичне зар-интизар булып Каенлыда көтәләр. Шактый караңгыда башланса да бу юлның азагы ял-якты һәм бик бәхетле булачак. Чак кына түзем булыгыз!

Шушы тынышта мин үзем турында сөйләргә җыенам. Ни өчен Рәшит Вәлиевич белән шулай нык кызыксынуымның, февральдән соң Түбән Камага кат-кат килүемнең, аның белән бик күп авыл юлларын узуымның сәбәбен ачыклап бирергә вакыт.

Замандаш тәнкыйтьчеләр иҗатыма бик игътибарлы булдылар, бер генә әсәрем алар күзеннән читтә калмады, рәхмәт аларга! Тузан кагам дип тун җиңен өзеп төшергән чаклары да булгандыр, нишлисең, дөнья төрлесен күрсәтә. Шулай да бер принципиаль мәсьәлә алар игътибарын җәлеп итеп бетерә алмады шикелле. «Бераү», «Качак», «Өч аршын җир» әсәрләрендәге тематик бергәлеккә аларның күзе җитеп бетмәде сыман. Бүген минем юл башымдагы шул әсәрләргә борылып кайтасым килә. Алар минем йөз аклыгым, йөрәк

талпынышым иде. Алардан башка бүген кузгаткан сүземнең эчтәлеге тулы булмас, фикерләрем арзан, үзем һәр искән җилгә ияреп йөрүче җиңел холыклы кеше булып күренәчәкмен. Язучы иҗатының кыйммәте — бөтенлегендә. Бөтен генә бөтен булып яши ала. Ихлас дөрес әйткән шагыйребез: «Сез үлсәгез мин дә онытылырмын, яшәсәгез мин дә яшәрмен».

Авыл, аның ул чактагы көне һәм киләчәге мине гел-гел борчып торган икән. Җир кешесе бүген нинди булырга тиеш? Таянып нокталары кайда аның? «Таянып ял итә торган талларын кисмәгәннәрме?» Тормышның заман тудырган катлаулы чәбәләнешләренә аның мөнәсәбәте нинди булса хәерлерәк?!

Әсәрләр байтактан язылган, күптән басылган, хәзерге заман укучысының бардыр белгәне, белмәгәне дә җитәрлектер, шул сәбәпле югарыда исемнәре саналган повестьларга әйләнеп кайтыйкчы бер! Язылган елларына игътибар итегез. «Качак» белән «Берәү» 1958-59 елларда язылган. «Өч аршын җир»не Мәскәүдә укыганда 1962 нченең көзендә язган идем. Нигездә бер-берсеннән бик нык аерылып торган бу әсәрләрне берләштерә, бер итә торган җитди мәсьәлә булмаса, бүген аларны телгә алып торыр идекме? Әнә шул бергәлекне, уртаклыкны тәнкыйтьчеләр абайламый калды шикелле. Өч әсәрдә дә җир кешесенең туган җиренә хыянәте турында сүз бара.

«Качак». Әсәргә кискен һәм икеләнергә урын калдырмастай исем биргәнмен. Балчыклы авылыннан сыер савучы Тәнзилә исемле кыз авылыннан качарга ниятли. Сәбәбе җитди. «Тәнзилә үз фермаларын уйлап алды. Өч ел йөреп, күреп күнегелгән урыннар бөтен ваклыклары, су тамып торган юка такта түшәмнәре, кыйшайган яңаклы ишекләре, саламнары бүселеп-бүселеп торган түбәләре белән күңелдә калыктылар». Шушы күңелсез манзарага өстәмә буларак хикәядә арык сыерлар, шул арык сыерлардан савылган тәүлеклек алты литр сөт әрнеп телгә алына. Председатель дә юньсез! Тупас. Шәһәрдән кунакка кайткан апасы Гөләндәмне станциягә кадәр дә озата бара алмый Тәнзилә, председатель җибәрми. Ә Гөләндәм шәһәрдә калач ашый! Ансатрак яшәп, тәмлерәк ашый...

Нәтиҗә ясап мин Тәнзиләгә хөкемнең иң усалын чыгарганмын, яшь кызны «качак» дип атаганмын. Аның шушы котсыз авылны, шөкәтсез ферманы ташлап китәргә теләвен гаепкә алганмын... Әгәр барыбыз да ташлап китсәк... Барыбыз да җиңел юлга бассак — Җиребезгә, туган төбәгебезгә хыянәт итсәк — кем тормышны үзгәртер?! Кем яхшыртыр аны?! Тумыштан Җиргә хуҗа булырга тиешле, табигать авыл кырларына-тугайларына мәхәббәтле йөрәк биргән җаннар да аны ташлап китә башласа, дөнья кай якка үзгәрер?!

Тәнзилә яшәгән елларда актив миграция башланмаган иде әле, аның беренче яралгылары гына да мине шөбһәгә төшергән!

«Берәү» повестенда кырчы-игенче баласы, туган ягын, кешеләрен аерым бер сизгер мәхәббәт белән ярата ала торган Исхак Батуллин турында сүз бара. Сугыш елларында егет булып җиткән Исхак кырларның ятимлеген, ташландык басуларны күреп әрнеп, җаны кыйналып үсә. Шул кырларга яңача рух өрер өчен, тергезер өчен авыл хуҗалыгы институтына барып укый. Җиңел адым булмый егет өчен! Кемнәрдер авыл хуҗалыгына гомерләрен багышларга теләгән яшьләрдән ачыктан-ачык көләләр. Исхак гашыйк булган кыз, аның кайда укуын белгәч, араны кырт өзә. Юридик мәктәпкә урнашып, җылыга ояларга омтылган Тазюков, дөнья барышын үзенчә аңлатып егеткә болай ди: «Ни пычагыма сиңа ул сельхоз?! Колхозда интегеп җенең өзелмәдемени әле синең? Күтәрәм атлар торгызып, корчаңгы сыерлар тазартып туймадыңмыни?» һәм егетне авылдан качарга үгетли. Бу ялгыз бер обыватель авазы гына түгел, шул чакларда байтак күңелләрдә туган куркынычлы — хәвефле өн иде!! Исхак колагы төбендә башкача өндәүләр дә яңгырый. Калдау калган, шайтан таягы белән билчән басып бетергән кыр янәшәсендә Имәнле урам очында яшәп яткан яралы партизан Нурулла да үзенчә фикер йөртә. «Төнлә уянам да тыңлап ятам. Әгәренки тамуг дигән нәрсә булса, аның җиле дә шулай шаулыйдыр дип уйлыйм. Коточкыч бит!.. Җиргә ятып җылыйсыларым килә... Көз бит, көз... Кыр тулы чүмәлә, кибән, ындыр тулы эскерт, ишегаллары тулы көшел, келәтләр тулы тау-тау икмәк була торган иде. Көз җитә башласа, тәрәзәмне япмый идем мин... һай, бу басулар! Кыр янында яшисем килеп шушы Имәнле очыннан күчмәдем дә мин... һай, бу кырлар! Аларны адәм төсенә кертkәнче чиең чыгар әле... һай, бу кырларның туфраклары... Шундый бер чакта йөрәксенеп агроном булырга йөрисең икән, молодецтан башка сүз юк сиңа. Вәт. Их, егәрләрем булса, мин... кыр тутырып бодай чәчәр идем. Офыктан офыкка бодай кыры булсын иде...»

Без бер тапкыр иген кырларының төп хуҗаларыннан аерылып калганын күрдек инде. Кырык бердә аларны фронт юлларына озатып калдык. Кыр ятим калганда ниләр булганын да кичердек. Исхак шул буын вәкиле. Шулай да авылына, туган кырларына, дүрт күз белән аны көтеп торган сыңар күзле партизан Нуруллага да хыянәт итә, Казанда, министрлыкта эшкә урнашып кала.

Бәхетлеме Тәнзилә? Юк! Исхак бәхетлеме? Һич! Аерылу газабы, хыянәт газабы аның тынгысыз күңелен өзлексез кимерә. Газап утында яна игенче йөрәге. Кыр гына түгел, игенче йөрәге дә ятим калган бу очракта!..

Жиргә хыянәтнең формалары төрле-төрле булуы ихтимал. Тарихның ашыгып алга ыргылган мизгелләрендә кыр да үз улларын ныклыкта сыный! «Өч аршын җир» повестенда Мирвәли җиргә якын торганда тере күңелле, ачык җанлы кеше, туган җиренә хыянәт итә. Авылдашлары, тормыш, чынбарлык аңа да аяусыз хөкем чыгаралар.

Ир исеменнән, җир исеменнән хөкемне аңа авылдашы, яшьтәше, балачак дусты һәм адашы Мирвәли игълан итә. Хыянәтченең авылда калырга ниятен белгәч алар арасында шундый әңгәмә булып ала:

«— Калырга кирәк дисең инде син... Уйларга кирәк моны! Син миңа үпкәләмә, үткәннәрне искә төшергәнне кайчак үзем дә яратмыйм. Шулай да әйтик, авыл халкы җәбер-җәфаны байтак күрде. Ул сугыштан соңгы интеккәннәрне күрсәң син! Хезмәт көненә берни бирмиләр иде диярлек. Налоглар, заемнар белән җәфаладылар. Еллар буе берни бирмәделәр, еллар буе барын бездән сорадылар. Партиягә рәхмәт, ниһаять, колхозчыны кешегә саный башладылар. Күзебез ачылды, җитәкләп безне көр тормышка чыгардылар...»

Хыянәтче Мирвәли дә үз сүзен әйтеп калырга тырыша! Тыңлыйк!

«— Миңа күп кирәкми инде хәзер. Күрәсең ич, картаелды. Яшисе яшәлгән дигәндәй, миңа хәзер өч аршын җир җитә!»

Партиянең авыл хуҗалыгында бәрәкәтле борылыш ясап, мәгълүм карарлар чыгарган дәвердә бара бу әңгәмә һәм Җир хуҗасы Хыянәтчегә мондый җавап юллый:

«— Өч аршын сорыйсыңмы? Кадерле ул туган җир! Ай, кадерле! Күрше авылдашлар аның өчен башларын безнең гомердә генә чит җирләрдә салдылар. Берлинда, Будапештта. Каты бәгырьле димә, минем ул җир өчен чын-чынлап даулашырга хакым бар! Өч аршын җир!.. Күп сорыйсың син, Мирвәли! Менә хәзер сорыйсың! Ә нигә качтың син Карасурадан? Әйт әле!

— Кимсеттеләр мине, җәберләделәр,— дип мыгырданды ул.

— Ә безне?.. Еллар буе кара тир түгеп эшләп берни алмаганда безне кимсетмәделәрме? Әрнемәдекме? Тик туган җиребезне каһәрләп мәртәткә әйләнеп качмадык!»

Монда да шул ук кискен, аяусыз хөкем: «Чыгып качмадык!»

Өч әсәрдә өч төрле кеше, өч язмыш, өч характер, өч төрле тарихи һәм тормыш шартлары, геройлар өчен бер нәрсә уртак: алар үз идеалларына хыянәт итеп авылдан качалар. Бу әсәрләрдә генә түгел, алардан шактый соңрак язылган, Зәй ГРЭСы төзелешенә багышланган китапта да мин ашыгып-ашыгып колхозларын ташлап киткән кайберәүләргә шактый «чирттереп» узганмын.

Ах, ул «бөек күченеш» чоры, 60-70 еллар! Ах, ул катлаулы миграция! Плакатлар ашыгып-ашыгып кешеләрне авылдан шәһәргә өндиләр, оргнабор вәкилләре сандугач булып сайрый, директив оешмалар төрле вәгъдәләр биреп завод-фабрикаларга кеше чакыралар. Нефтьче җитәкчеләрдән берәү, җитди рәвештә: «Кайчан романыңны бастырасың инде, безгә эшчеләр җитми?!» дип сорады. Романда мин авыл кешеләрен нефтькә өндәргә генә тиеш булганмын икән!..

Кирәк иде, беләбез, аңлыйбыз. Тик аңлау бер яклырак булып чыкты: авыл бик күпләргә саекмас кое булып тоелды. «Чумырып алган саен суы яхшыра!» Әсәрләремнең берсендә «озакламас, без шәһәрдән авылга кеше өнди башларбыз», дип язып узганмын.

«Качак»та мәгънәле генә бер урын бар. Тәнзиләләр «тәҗрибә уртаклашырга» күрше көчле, бай колхозга баралар.Фермалары да шәп боларның, якында гына бакча эчендә терлекчеләр өчен уңай йорт. (Хыялым шуннан арыга уза алмаган!) Бәхетле колхозның бәхетле сыер савучысы Бибинур Тәнзиләгә болай дип сөйли:

«... авылны чыктылар, авыл очындагы бушлыкта җиде-сигез бураны күргәч Бибинур адымын акрынайтты:

— Күрәсезме? Төзиләр! Дүртесе каладан кайтты. Авылдашлар, механизаторлар. Колхозга кабул иттек үзләрен,— диде ул бераз тантаналы төс белән».

Ул елларда авылларда буш ихаталар юк иде, шәһәрдән авылга кайткан кешеләрне авыл очына, бушлыкка — яңа нигезләргә чыгарганмын.

Шулай булган...

Берзаман йортлар шомлы бушап, тынып калды. Зәй-Кама буе халкы башта Зәй, Түбән Камага, аннары тоташ чылбыр булып Чаллыга агылды. Кирәк!... Авылларда йортлар шалкан бәясенә төште, тәрәзәләргә аркылы-торкылы такта кадакланды, ишегалларын кычыткан, алабута басты. Эшче куллар җитми башлады. Ниһаять, авыл турында җитди, бу юлы яңа яктан, сүз башланды: кадрларны авылда ничек калдырырга да аларны ничек җиргә беркетергә? Башта җиңелрәк карадык: «ах, яшьләр китәме? күңел ачу урыннары юк, шуңа ташлыйлар авылны!»

Хәзер гаҗәпләнәм, нигә эшне, җаваплы мәсьәләне хәл итүне «ял» төшенчәсеннән башладык икән?! Без үскәндә дә авыл культура учаклары мактанырлык биналарда түгел иде, әмма тормыш аларда чын мәгънәсендә кайнап тора иде!... Шулай итеп авылга беренче үзгәреш дулкыны килеп кагылды: ярышып-ярышып, кем әрмәннәргә биш бәя биреп, кем урыннардагы шабашникларга ялынып-ялварып клублар, культура сарайлары

сала башладылар. Сәхнә артларына гыжылдавык тавышлы ялтыравык пианинолар менеп утырды, биллиард алып кайтарып куйдылар, баерак колхозлар оркестр юнәттеләр. Клуб ишекләре ачык, үсмерләр шалт та шолт биллиард шарлары куа, кинолар көн саен күрсәтелә, яңа ачылган культура институтыннан авылларга яшь белгечләр — режиссерлар, китапханәчеләр, дирижерлар кайта башлады.

Тик яшьләр авылда калырга ашыкмады, алар берәм-берәм һаман шәһәр ягына каерылдылар. Яшьләр генә түгел, зурлар да китте, тормышлары җайланган механизаторлар, сыер савучылар сәфәр чыкты, ирләр китеп бер-ике ел әл-хәл алды да гаиләсен чакыртты. Авылда эшкә ярамаган карчык-корчык, пенсионер ялгызаклар күзгә күренеп артты. Колхозлар мәктәпләргә якынаерга тырышты. «Колхоз мәктәптән башлана!» дигән акыллы лозунг шул елларда туды. Авылда тәэминат яхшырды, шәһәрдә очрамаган дефицит әйберләрне авыл кибетләрендә җиңел генә алып була башлады. Авыл хезмәтчәннәренең тормыш шартлары, хезмәт мөмкинлекләре яхшырды, хезмәткә түләү елдан-ел күтәрелде. Колхозчыларны бүләкләделәр, путевкалар биреп ял йортларына, санаторийларга озаттылар, теләгәннәр чит илләргә сәяхәткә чыгып йөри башладылар.

Яңадан-яңа машиналар кайта торды, ил авылдан бер нәрсә кызганмый башлады. Кул эше кимеде. Тик яшьләр һаман авылда калмады. Социологлар төн йокыларын калдырып баш ваттылар. Санадылар, исәпләделәр, нәтиҗә ясадылар... Нәтиҗәләр әлегә шатланырлык түгел иде.

Монда бер мөһим моментны чак кына исәпкә алып бетермәдек шикелле. Психологик моментны! Авыл хуҗалыгының артталыгы, сугыш елларында һәм сугыштан соңгы авыр елларны тиз генә оныта алмады халык күңеле. Хак, дөрес, героик еллар иде алар, мактауга, данга лаек еллар, тиңдәшсез көч түгелгән бөек еллар иде! Ләкин ул еллардан батырлык рухы гына түгел, авыр истәлек булып ямьсез сөземтә дә калды. «Үзем кыен ашадым, түздем, бала-чагам күрмәсен, мин кичергәнне татымасын, авылдан читтәрәк булсын!» Бу фикерне бала-чага колагына бөтен ата-аналар тукымадымыни?!

«Теләсә ничек яшәсеннәр, китсеннәр генә!»

Янәшәдә генә яңа калалар үсеп чыкты, биек-биек йортлар калкыды, ул йортларда каттан-катка лифтлар сызгырып йөрде, краннардан кайнарымы, салкынымы су чәчрәп агып торды. (Бер тапкыр ишле кер юар өчен күпме кайнар су кирәклеген тракторчы хатыныннан сорап бел!)

Иң ышанычлы, иң фидакарьләр дә икеләнде. Әйе, авылда зур үзгәрешләр бара. Әйе, тормыш күзгә күренеп яхшыра. Әйе, клублар салына, кибетләр бай... Шулай да шәһәрдә уңайрак. (Читтән караганда... күршенеке күркә... Агыйделнең аръягында бер энәгә бер сыер!) Уңай яклары да бар: сменалы эш, әзер квартирага кереп утырасың, юллар төзек, мәктәпләр якын, телефон кергән... һәм җиргә бирелгән авыл агае да, җилкәсен кашып, кала юлына каерылып карый башлый...

Авыл... Бүгенгесе ничек аның? Иртәгәсе нинди булыр? Бүгенге тырышлар урынына кыр түренә иртәгә кем узар? Бу турыда кайгырту безнең уртак эшебез. Халык күңелендә калган психологик юшкынны юып, кырып төшерү дә безнең уртак бурыч. Рәшит Вәлиевич әйткәндәй: «Безнең буын авыл проблемасын хәл итәргә тиеш. Авыл проблемасы — Азык-төлек программасын хәл итү дә ул!». Без, язучылар, эмоциональ якка күбрәк игътибар бирсәк, Абдулхәкимов — эш кешесе, зур хуҗалыкның җитәкчесе, аның теләгеннән, ихтыярыннан байтак нәрсәләр үзгәрә ала. Моның шулай икәнен без алдагы очрашуда күрербез...

* * *

Чират — «В» станциясенә...

«В» станциясеннән, ягъни «Кызыл Зәй» совхозының үзәге Каенлы авылыннан... юк, әлегә поезд түгел, гап-гади трактор чыга да... олы юлдан Р. В. Абдулхәкимов утырган машинаны сөйрәп кайта. Контора янында туктата. Трактор да, тракторчы да шунда ук юк булалар. «Абдулхәкимов килер дә естән-остән генә сорашып моннан ычкыныр», дип шүрләгән совхоз директоры аңа шулай боерык биреп куйган була. Директор Габделбәр Әхмәтшинның зар-моңы җитәрлек һәм... истә-оста югында Рәшит Вәлиевич совхозга җир төшә...

Да-а-а, Габделбәр Салиховичның көймәсе комга терәлгән, ни алга, ни артка...

Әхмәтшин шушы як егете, Кызыл Чапчак авылында туып-үскән. Авыл хуҗалыгы институты, МТС, сельхозтехника бүлеге. Нормировщик, агроном, ниһаять, Сухарево авылында «Память Ильича» совхозында баш агроном. (Бу совхоз исемен хәтерегездә калдырырга тырышыгыз!) Бара-бара, 1973 елда аны совхоз директоры итеп билгеләделәр. Гади, гадәти биография.

Ул кабул итеп алганда совхозның хәле әллә кем түгел. Юк, юк, бар яктан да начар дип булмый! Һич! Партия һәм хөкүмәтебез авыл хуҗалыгы ихтыяҗларын төрле яктан канәгать-

ләндерергә омтылалар. 60, 70 елларда кырларга моңарчы күрелмәгән куәтле тракторлар, комбайннар, тагылма җайланмалар кайтып тулды, хуҗалыкларның экономик хәле ныгыды, җирне фән нигезендә эшкәртә башладылар. Эш бер ноктага — кадрлар җитмәүгә кайтып калды. Бер саный директор — уфтана. Ике саный — каушап кала. Әгәр совхозда эшче көчләр саны 1970 елда 1106 кеше булса, 1973 нче елда нибарысы 720 кеше калган! Ике авыллы хуҗалыкта эшләүче шул кадәр кеше! Төпкә җигелеп тартучы 60—70 кеше ел саен китеп тора. Ел уза, тагын бер ел, эшләрлек кеше совхозда 540 ка кала!

Гаиләләп-гаиләләп китүләр кими барса да (инде китәрлек гаиләләр юк дәрәҗәсендә!) яшьләр тоташтан шәһәр ягына каерыла. Сыер саварга кеше юк, яңа гына кайткан трактор-баһадирлар нясез тора. Армиядән кайткан егетләр белән аерым-аерым сөйләшеп карый директор, һәр егетнең сүзе шуңа кайтып кала: «Калыр да идем, торыр урын юк. Картлар белән яшисе килми».

Совхоз үз көче белән ел саен бер-ике йорт җиткереп куя, әмма бу диңгездән бер тамчы...

«Соңгы чиккә килеп терәлгәнне аңладым. Болай барса, иртәгәге көн юк. Тулып ташысын өчен бер тамчы гына җитми тора. Озакламый ул тамчы да тамды... чиләк түгелә башлады!» дип искә ала хәзер Габделбәр Салихович.

Күзләрнең берсендә, кыр эшләре тәмамлангач директор көньякка ялга бара. Дәвалана. Кайта. Партоешма секретаре белән сөйләшеп утырганда, кемдер урамнан, баганага кадакланган бер язуны кубарып кертеп бирә. Карасалар, бәет... Менә ул:

## «КАЕНЛЫ АВЫЛЫ МАҖАРАЛАРЫ»

Каенлы авылын су баскан
Коткарыгыз тизерәк!
Урам аркылы чыгарга
Болотный итек кирәк.
Отпускадан, ял йортыннан
Директор кайткан диләр.
Каенлы урамына кайткач
Биленнән баткан диләр.

Безнең директор бу хәлне
Искә алачак, диләр.
Җәйгә чыккач урамнарга
Асфальт салачак, диләр.
Асфальт юллар салыр өчен
Урамнар бик тар икән.
Коры юлдан, тигез юлдан
Йөрер көннәр бармы икән?!»

Директорның беренче уе — тиз генә чыгып китеп, бәет авторын эзләп табу була. (Әлбәттә, гонорар түләү өчен түгел инде!) Аннары, кәгазьне ертып ташлап бөтенесен уенга алырга ниятли. Юк, ертмаган, сиксән дүртнең августында сейфтан алып күрсәтте. Саклый! Уйлый-уйлый да, тагын бер кат яңгырда дымланган кәгазьгә йотыла. Һәммәсе дөрес шул, хак! Урамнар ерып йөрерлек түгел, авылның бер очыннан икенчесенә узам димә, саз, лай, кичләрен дөм караңгы, җитмәсә нәкъ контора каршында гына җәһәннәм базы шикелле сулы чокыр казылган. (Директор тәрәзә каршысына барып баса: чокыр күренеп тә тора!)

Бәет түгел, соңгы чик була бу!

Юллар көтеп тә торыр, дип исәпли Әхмәтшин, ашыгыч рәвештә йортлар, күп итеп торак йортлар сала башларга кирәк! Юл дигәннән, ата-бабалар йөргән, балалары да йөрер. Юл төзерлек үк байлык та, чама да юк әлегә. Торыр урын булсамы?.. Һәркемнең күзенә туры карап сөйли алыр директор. (Бер мәлгә генә аның күңелендә ачы уч тойгысы да кузгалып ала; эченнән генә Каенлы кешеләренә ачу белдерә: «Әһә, китәсезме? Качасызмы? Совхозны калдырасызмы? Ятим итәм дип уйлыйсызмы? Менә йортлар гына салыйк, эшләрлек кешеләр теләсә каян киләчәк безгә!»)

Иртәгесен ул туп-туры партиянең шәһәр комитетына юл тота. Олы юлга аны да трактор белән чыгарып куялар. Анда да юллар турында уйлый алмый әле Әхмәтшин. Анысы артык ерак хыял... Нидер эшләргә, бүгеннән ашыгыч чара күрергә кирәклеген генә чамалый ул.

Горком секретаре Илдус Харисович Садыйков каенлыларның хәлен яхшы белә, хәбәрдар, алай да директорны бүлдерми, ашыгыч эшләрен куеп торып моң-зарын тыңлап бетерә. Ярдәм уйларга вәгъдә бирә. Шул көнне үк Абдулхәкимовка шалтырата: «Каенлыга барып кайтыгыз, аларга берәр ярдәм күрсәтеп булмасмы?»

Директор белән начальник кич буе сөйләшәләр... Сүз беткәч трактор да, тракторчы да юк... Ах-ух килгән була Әхмәтшин, яңа баштан хәлен сөйләргә керешә, иртәнгә кадәр сузыла бу әңгәмә. Иртән таң белән, караңгылы-яктылыда Рәшит Вәлиевич Каенлы урамнарын урап килә, атаклы чокыр янына басып озак кына уйланып тора.

«Минә алда конкрет бурыч. Авыл эреп, бетеп бара, таркала. Директорның бер фикере дөрес: әгәр болай барса, иртәгә эшләргә кеше калмый. Мәгәр берсе ялгыш: «Йортлардан башларга кирәк эшне, торактан!» дип, директор хаталана. Иң әүвәл юллар уздырырга. Юллар!.. Юл — тормыш ул, дигәннәр. Борынгылар сүзе. Каенлыда гына түгел — гомумән, Татарстанда авыл юллары бер җирдә дә мактанырлык түгел. Халыкның теңкәсенә тигән нәрсә — юллар. Тормыш яхшырсын дисең икән — юлларың төзек, каралган булырга тиеш. Юл нәни генә, ун-унбиш төтенле авылларны да зур шәһәрләр белән, ил белән

тоташтыра ала һәм бу авылга мөнәсәбәт шунда ук үзгәреп китә. Авыл кешесенең офыгы киңәя, аның үз-үзенә ышанычы, кадере арта. Авыл кешесенең икеләнүләренә чик куярга кирәк! Җирдән аерылып, суынып бетмәгән ич аларның җаннары! Күр инде, шул ук авыл кешеләре шәһәрләргә күчәләр дә ашыгып-ашыгып җир, бакча өчен участок эзли башлыйлар. Уч төбе кадәр җирдә ял көннәрен уздыралар, көннәр буе җилкә турайтмыйча казыналар, сыныйлар, тәҗрибә уздыралар, ярышып-ярышып яшелчә-җимеш үстерәләр. Ташландык чокыр-чакыр таш араларын яулап алып гөлбакча итәләр!»

Бу момент Абдулхәкимовны аерата уйландырды.

«Һәркемнең күңелендә Җиргә мәхәббәт ята. Җиргә мәхәббәтне бары тик хезмәт аша гына белдереп була. Китүчеләр, икеләнүчеләр канында да ул мәхәббәт бар! Кемдәдер ул хис йокымсырап ятадыр, дөнья мазасы белән тупасланганрыр, уятырга кирәк аны, заманга, тормышка яраклаштырып уятырга кирәк... Юлсыз авылны якты көнгә, киңлеккә чыгарып булмаячак. Урамнарны тигезләргә, асфальт җәяргә. Ишегалларының да бер өлешен асфальт белән капларга. Кибетләргә затлы киемнәр, хатын-кызларга биек үкчәле кыйбатлы туфлялар кайтарып тутырдык. Авыл урамына киеп чыгарлык та булмагач ни пычагыма ул затлы киемнәр?! Сыер савучы эштән кайтсын, юынып, душ алып, өс киемен алыштырсын, зиннәтле муенсаларын таксын да тек-тек басып кына шәп клубка барып Казан артистларының концертларын карап кайтсын. Барган-кайткан чакта урамнар ялт итеп, көлеп-балкып торсын. Аның затлы киемнәрен бөтен халык күрсен, киң урамнарны иңләп узуын күреп, кала кунаклары көнләшсен. Һәр авылда, олымы ул, кечеме, ял урыны, очрашу урыны бакча булырга тиеш. Шунда ук буа. Буа өстендә дулкыннар йөгереп күңелне кымырҗытып торсын. Авыл кешесенең күңеле, киңлек ягыннан, шәһәр кешесенекеннән бер мыскалга да ким түгел! Димәк, кеше шәһәрдә яшәп тормыштан нинди гүзәллек, нинди җиңеллек ала алса — авылда да ул шуларны алырга тиеш. Менә шунда гына кадрларны авылларга беркетү проблемасы өлешчә хәл ителәчәк. Өлешчә! Иртәгә әле аның бүген артык күзгә бәрелмәгән, йөзләрчә вак-төяк яки эре проблемалары туар...

Юллар салгач кына йортларга тотынырга кирәк.

Йортлар. Йорт. Яңа төр крестьянның яшәү урыны. Нинди булыр ул? Яңа йортның хуҗасы кем булыр? Крестьянлыгыннан китеп тулысынча эшчегә әйләнерме, әллә урталыкта Яңа кеше, җитлеккән социализм кешесе туармы?

Борынгы заманда корымлы мәгарәдә яшәгәннәр бер төрле булганнар. Карындык тәрәзәле, җир идәнле тәбәнәк йортта яшәүчеләр икенче төрле. Кочакка сыймаслык нарат бүрәнәләрдән йорт салып керә алган Хуҗаның рухы инде бүтән! Ул Җирдә, мәңгелек нигезендә нык басып тора ала. Иртәгәге көн крестьяны кем булыр? Аңа нинди йортлар ошар? Йортларны проектлаудан элек аның иртәгәгә киләчәк хуҗасын ныграк белергә иде!»

Әлбәттә, моңа охшашлы сораулар бер Абдулхәкимовның тынгысыз күңелендә генә уянмадылар, күп өлкәләрдә төрле-төрле сынаулар бара, тикшерәләр, өйрәнәләр, ашыгалар. Татарстанда тәҗрибә-авылларга нигез салына, өлкә проект оешмаларының рекомендацияләре бар, шуларга нигезләнеп кайбер районнарда берәр катлы йортлар, коттеджлар өлгертеп киләләр, яшиләр. Нигездә, әлегә укытучы-врачларга, авыл хуҗалыгы белгечләренә исәп тотып салына ул йортлар. Ә хәзер яңа сүз кирәк. Яңа сүз. Шул сүзне әйтеп колхозчыларны, совхоз эшчеләрен, аерата яшьләрне җиргә өр-яңадан беркетергә вакыт. Яңа ысуллар, яңа тормыш чаралары белән...

Авылдан киткәннәр белән аңа еш кына сөйләшергә туры килгәли, Рәшит Вәлиевич һаман бер сорауны бирми калмый: «Нигә киттегез? Нигә авылны ташладыгыз?» Сорау бер, ә җаваплар төрле-төрле. Берәүләр мәктәп ерак булганга авылдан киткән: «балаларга йөрергә уңайсыз». «Кибет, медпунктның да якын булмавы читен». Күпчелек «күңелгә ошаган эш юк», дип тә җавап бирә. Икенчеләр «мал асрарга җәй юк»лыктан зарланалар.

«Күңелгә ошаган эш юк».

Торак йорт, юллардан соң бу иң җитди, иң кыен мәсьәлә. Замана тудырган мәсьәлә.

Хәзерге авылда кем яши? Асылда аларны дүрт төркемгә аерып булыр иде. Авыл интеллигенциясе — укытучылар, врачлар, фельдшерлар. Яшьрәк чакта алар мал-туар асрарга теләмиләр. Аларга бары тик нәкъ менә шәһәрчә квартиралар, шәһәр шартлары кирәк. Икенче төркем күп санлы авыл пенсионерлары. «Су ташыйсы, мич ягасы булмасын иде. Аптека, больница, саклык кассасы, авыл советы, кибете-мазары да якында булсын». Менә аларның төп теләкләре. Нишлисең, көне килә, дөнья белән бәйләныш ешрак аптека, медпункт һәм саклык кассасы аша уза... Өченче төркем — күңеле, хыялы белән авылга беркекән нык халык: механизаторлар, сыер савучылар, терлекчеләр. Болары әле үзләре дә йорт сала. Аларга «мал йөртерлек урын булсын, кышка утын-печән зары калмасын, яшелчә-җимеш үстерерлек җәй да кирәк, тормыш булгач кош-кортсыз да ярамый. Умарта да читт түгел».

Дүртенче төркемгә мәктәпне шунда бетереп, армиядә хезмәт итеп кайткан егетләрне кертергә була. Егете бар икән — кызы табыла. Яшьләр, яңа өйләнешкәннәр, боларда сыер-

сарык мазасы юк, мич ягасылары да килми, әзергә-бәзер, үз бәхетләренә үзләре чумып калалагыча яшәргә омтылалар. Эш булсын да яшәр урын булсын!

Иң элек шушы төркемгә якынаерга кирәк: яшьләрне авылда калдырырга... Шәһәргә охшаган авылда дип ачыкларга кирәктер бәлки?..

Һәр гаиләгә йорт салу... Озак та, кыйбат та!

Каенлы хәле белән ныклап танышкач Абдулхәкимовның күңелендә ныклы карар өлгерә: эшкә тотынырга! Авылга мәхәббәтне материаль көчкә әверелдерергә!

Шулай уйлагандырмы бу мизгелдә Абдулхәкимов, әмма аның тәкъдиме белән «Жилстрой» тресты «Кызыл Зәй» совхозының үзәген төзергә керешә. Башта бар халыкны сөендереп юллар уздыралар, 36 квартиралы өч катлы йорт сала башлыйлар. Эшче куллар трестның үзеннән дә артмый, совхоз, сызланып булса да, ундүрт кешесен төзелеш эшенә укырга җибәреп кайтарта. «Башлаган эш — беткән эш», ди татарның тәвәккәле. 1977 нче елда йорт өлгерде. Бу көнгә квартир сорап язылган гаризалар саны җитмештән ашып китте. Квартираларны иң элек яшьләргә — армиядән кайтып өйләнгән, ирле-хатынлы совхозда эшләрлек гаиләләргә бирәләр. Ишле гаиләләрдән дә яшьләрне аерып чыгаралар. Читтән килгәннәрне дә кабул итмичә булмый — белгечләр җитми, алары каян килсә дә риза! Рәхим ит, квартир ал, эшлә генә, туган!

Квартиралар җылы, үзәктән ягулы, су өзмәс килеп тора, канализация хәвеф-хәтәрсез генә эшли, кибет, аптека, авыл советы шунда, совхоз конторасы да янәшәдә генә. Каенлы авылының шәһәрчә үзәге туды! Урамнар асфальт, теге каһәр суккан чокырның эзе дә калмаган! Яшәп була! Кешечә яшәп була Каенлыда! Заманча тормыш корып була.

Яши-яши шул да беленде: мал-туар өчен абзарлар кирәк икән. Торак йорттан ерак та түгел кирпечтән, менә дигән нык мал абзарлары өлгерттеләр. Печәнгә киштәсе бар, куян, дуңгыз, кош-корт өчен махсус бүлемнәре җитәрлек, ышык, ут кергән сарайлар.

Квартир хакы арзан — өч бүлмәсенә 17—18 сум түлиләр. Әһә, тагын бер нәрсә онытылган икән — мунча! Сагыналар мунчаны каенлылар һәм 1978 нче елда 20 урынлы мунча да өлгерә. Тормыш бар җәһәттән түгәрәкләнә.

«Килүчеләр белән җирле халык арасында башта татулык җитенкерәмәде, инде бу аерма бетеп бара дигәндә, читтән килүчеләр бер-ике елдан таралып та беттеләр. Күченеп йөрүче халык та бар икән! Төп игътибарны үзебезнең яшьләргә, мәктәпкә юнәлттек һәм оттырмадык»,— диде Габделбәр Әхмәтшин.

Без 1984 нче елның август аенда Рәшит Вәлиевич белән совхозның бүгенгесе белән танышып йөрибез. Бүгенгесе. Ул монда хәзер үз кеше, олысы-кечесе аны белә, хөрмәт итә.

«Каенлы безнең өчен сыналу, тәҗрибә кыры булды», диде ул йорт-урамнарны карап йөргәндә. «Бөтен тармактан тәҗрибә, акыл туплау булды».

Йортлар салу, яшьләрне уңайлы арзан квартиралар белән тәэмин итү чыннан да үзенүзе аклыймы? Дөрес юлмы бу? Файдалы башлангычмы? Артык иркәләнеп китмәсме безнең авыл яшьләребез?! Һич шик калмасын ки, торак йортлар салу тылсымлы таякка хуҗа булу түгел, бер селтәнүдә авылның бүгенге проблемаларын чишә алмассың! Мәгәр юллар салу, авылны кешечә төзекләндерү, совхоз эшчесенең яшәү урынын — шәһәрнең бер почмагы итеп үзгәртү, Каенлы тәҗрибәсеннән чыгып нәтиҗә ясаганда дөрес юл икән! Аз-маз саннарга мөрәҗәгать итик.

«Жилстрой» тресты Абдулхәкимов җитәкчелегендә, аның проектларына нигезләнеп, 1975 елдан башлап бүгенге көнгә Каенлыда барлыгы 150 квартира төзегән. Шуларның унысы коттедж тибында. (Инде тагын 30 квартира кирәк.) Соңгы елларда йортлар янәшәсендә генә мал-туар асрарлык абзар-сарайлар да салынган. Бер генә хуҗалык та абзардан баш тартмаган. Бу бик мөһим күрсәткеч! Димәк, бүген булмаса, иртәгә алар хуҗалыгында да сыер мөгрәр, сарык бәтиләре чабып йөрер.

Игътибар итик: 1978 елда совхозда мәктәпкәчә балалар саны 199 булса, 1983 елда аларның саны 270 кә җиткән.

1978 елда авылда 22 туй узса, 1983 елда 38 туй шаулап-гөрләп узган. 1984 елның августына 26 пар яңа тормыш корып җибәргән. (Әле август кына, туйлар чоры алдарак, күзге байлык белән!)

Шушы елларда 11 авылда дүрт клуб, биш кибет файдалануга тапшырылган.

Хәзер иң мөһим пунктка — сигезьеллыкны яки урта мәктәпне тәмамлаган яшьләрнең авылда калуына игътибар итик. 1979 елда яшьләрдән 17 кеше совхозда эштә калган. 1980 елда — 23, 1981 елда — 29, 1982 елда — 31, 1983 елда — 34 кеше мәктәптән соң совхозда калса, 1984 елда бу санның 45 кә җитүе көтелә. Шактый эчтәлекле, куанычлы саннар минемчә!

Шуның дәвамы буларак, совхозда эшләүчеләрнең уртача яше дә уңай, өметле якка борылган. 1973 елда 17 яшьтән 25 яшькәчә эшчеләр саны — 42 булса, 1984 елда бу

сан 113 кешегә җиткән. 1978 елда 25—40 яшьтәгеләр нибарысы 74 кеше булса, 1984 елда 218 кешегә җиткән. Бу яшьтәгеләр — совхозның алтын фонды, белемле, әзерлекле, төрле яктан камил сәламәт яшьләр. Әле кырда-фермаларда күкрәтеп эшли торган 40—50 яшьтәгеләр саны да сизелерлек арткан. 1978 елда алар 193 кеше булса, 1984 елда 233 кеше! Илле яшьтән узганнар кимегән: 1978 елда алар 218 кеше булса, 1984 тә алар 96 га калган.

Бүгенгә генә түгел иртәгә дә совхозның бөтен тармаклары ышанычлы кадрлар белән тәэмин ителгән, ныгытылган.

Тагын үтә әһәмиятле, хуҗалык торышының көзгесе булган санны шушы урында теркәп китү зарурый булыр: әгәр «Кызыл Зәй» совхозы 1979 елда гомуми валовой продукцияне 1 миллион 971 мең сумлык җитештерсә, бу төп сан 1983 елда 2 миллион 700 мең сумны тәшкил итте.

Саннарның да музыка кебек яңгырап торган чагы була!

* * *

Чираттагы станциядән безгә каршы тагын бер кеше кузгалырга тиеш иде, фәлән-фәлән вакытта, фәлән-фәлән урында күрешергә дип телефон аша вәгъдәләр бирешкән идек. Әмма Сухарево авылына урнашкан «Память Ильича» совхозының директоры Камил Заһретдин улы Хәйретдинов ул көнне авырып ята икән. Рәшит Вәлиевич белән, күпер янында кодрәт белән генә сакланган чирәмлектә машинаны калдырып директорның өенә юнәлдек. Яңгыр иртәдән бирле өзлексез сибәләп тора, урамда чирәм заты юк, тездән пычрак, машина эзләре йөзеп чыгарлык ермакларга әйләнгән, чалбар балакларын тезгә кадәр сызганып чупырдыйбыз гына!... Озын кунычлы резин итек кигән авыл кешеләре безнең аупән-таупән баруыбыздан көләләрдер кебек. Урамда халык шактый, яңгырга күрә, көтүне иртә алып кайтканнар.

Сухарево — совхозның үзәге, рус авылы, хәзер монда 140 йорт калган. Күрешкәнгә кадәр үк Камил Заһретдинович турында кайбер нәрсәләрне ишеткән идем инде. Нык куллы. Тәләпчән. Тәҗрибәле чын хуҗа. 1970 елдан бирле шушы совхозда директор... Бик шәп җырлый! Апа-сеңелләре, туганнары — һәммәсе дә җырчылар...

Тәҗрибәсенә ышаныпмы, оештыру сәләтенең ныклыгына таяныпмы, Хәйретдинов авыл төзелешенә беркадәр салкынрак караган, дисәк тә ярыйдыр?.. Үзендә кайчандыр баш агроном булып эшләп киткән Габделбәр Әхмәтшин, дөнья кубарып, төзелеш башлап җибәргәндә, Сухаревода, совхозның башка авылларында да әлегә шылт иткән тавыш та ишетелми. В. Ян сүзләрен чак кына үзгәрткәндә «В великом Сухареве все спокойно». Дөрес, үз көчләре белән ел саен 3-4 квартир мәтәштерәләр, ара-тирә яшь гаиләләрне бәхетле итәләр, читтән килгәннәрне дә совхозга теләп кабул итәләр. Килүчеләрнең һөнәрләре яхшы, гадәтләре генә бераз сәер икән! Беренче хезмәт хакы алганчы савылып эшкә йөриләр, акча кулга кергәч, башлана мәрәкә!.. Килгәннәрне ашыгыч рәвештә озатырга һәм баш кашып уйларга туры килә. Үз көчеңә, үз төбәгеңә, үз кешеләреңә таянырга кирәк! Берүк вакытта аларның ышанычын югалтмаска! Төп юнәлеш шул.

Яңа тормыштагы үзгәрешләр нык куллы, оста җитәкчене дә аптырашта калдыра. Егерме ел элек сыерлар саны 430 иде, хәзер аларның саны 1100 башка җитте. Ул чакта нибарысы унике комбайн иде, хәзер биш мәртәбә күбрәк. Эш елдан-ел арта тора, бурычлар зурая, ә эшче куллар ел саен 70-80 кешегә кими бара. Мәсәлән, 1984 нче елда гына совхозның 68 эшчесе пенсиягә чыга, шуларның 22 се сыер савучы!

Уйланырсың, кодагый!

Бүген шулай, ә иртәгә? Кызганычка каршы, бүгенге көнгә кадәр совхозда урта мәктәп юк, сигезьеллык кына. (Урта мәктәп салуны кичектерергә һич ярамый! Соңга калу — киләчәкне оныту дигән сүз!)

«Память Ильича» совхозына да ярдәмгә «Жилстрой» тресты килә.

«Каенлы безнең тәҗрибә мәйданы булса, Сухаревода киң плацдармда һөҗүм башладык», ди Рәшит Вәлиевич.

Совхозның яңа урамын директор үзе күрсәтергә тиеш иде, авыру кешене борчып тормадык, кереп, сәламләшеп, хәл-әхвәл алышканнан соң, тагын бер кат тездән пычрак ярып кичәге көнне уздык та, күпер чыгып бераз баргач сулга борылдык һәм туп-туры... кая дисезме? — туп-туры киләчәккә атладык.

«Каенлыда күп нәрсәгә ышандык. Җөмләдән берсе: анда-монда биш-алты йорт салып кына совхоз-колхозларны квартира кытлыгыннан коткарып булмый. Комплекслы, киң колачлы төзелеш башлап авылларны әр-яңадан, тулаем үзгәртеп корырга кирәк! Бу һәр яктан уңайлы. Шуны истә тотып Сухаревода йөз йортка нигез салдык. Йөз! Хәзергә шуларның 24 ен файдалануга тапшырдык. Яңа елга тагын байтак йортлар әзер булачак. Комплекслы итеп, масштаблы башлап җибәрү эшне тизләтә, төзелеш арзанга да төшә».

Рәшит Вәлиевич белән без Киләчәк урамы буйлап барабыз.

Иң элек матурлыкка хәйран каласың! Йортлар гаҗәеп гүзәл, һәрьяктан уңай тоелган проектлар белән төзелгән. Ак, кызыл кирпечләр алмаш-тилмәш тезелеп яткан, җекләр пөхтә итеп сыланган. Урам уртасы асфальт, урам кырында ике якта да тигез тротуарлар, ишегалларында я асфальт, я вак таштан җәймә ябылган. Урам як коймалары «гаскәр кеби» тигез, матур булып күз явын алып утыралар... Өй эченә кергәч, тәмам һушсыз каласың! Өй эче шәһәрчә дә, авылча да бизәлгән. Өч киң-киң бүлмә, һәммәсе аерым-аерым. Кышкы һәм җәйге верандалар. Санузел, ванна, ябык чолан. Өй уртасында кукыраеп зур мич утыра. Аны-моны киптерергә мич башы да бар! Чын мич! Бәлеш пешер, дурычмагын, кыстыбыен өлгерт — җайлы духовкасы булу өстенә ипи салырлык мич төбе дә бар! Теләсәң, нәни, махсус мичкә ягып тиз генә су җылытып ал!.. Идән астында — бетон белән эчләнгән баз. Хуҗалык абзарларына арт ишек чыга.

«Һәр йортны — бүгенге хуҗалары кирәксенәме-юкмы,— абзарлы, җылы сарайлы итеп салабыз. Йорт алган кеше чын хуҗа икәнен сизсен, мал-туар да, кош-корт та асрасын. Без төзегән йортлар тәрбияче ролен дә башкарырга тиеш!»

Рәшит Вәлиевичнең мал асрау урыннарына аерым бер игътибары, әйтергә яраса, мәхәббәте барлыгын аерата искәртеп китәсем килә. Мал абзарларын шундый нык, пөхтә, бөтен ягын уйлап төзегәннәр ки, шаккатып торасың! Ышанам: бу бәхетле нигезләрдә бары тик бәхетле, җиркәебезгә тугры булган, бала-чагаларын, оныкларын шушы тугрылык чолганышында тәрбияләячәк яңа авыл кешеләре яшәр!..

Әле шушы әзер егерме дүрт йорт та таң калдыра, йөз йорт салынып беткәч, беренче урам белән параллель тагын бер урам сузылгач, бу тирәнең манзарасы әкияттәгедәй булыр. Әле икенче урам юк, ул проектта гына, Рәшит Вәлиевич урам буласы урынны күрсәткәч берара аптырап калдым: ике яңа урам уртасыннан тирән генә чокыр узган. «Моны күмәсезме?» дип сорадым. «Юк! — диде, өзеп, Рәшит Вәлиевич,— буа буып, су тутырабыз. Ярларына агач утыртабыз. Һәр авылга парк зонасы кирәк. Уртада Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга һәйкәл куярбыз».

Рәшит Вәлиевичнең авыл һәйкәлләренә мөнәсәбәтен мин февральдә үк белеп киткән идем. «Ни өчен һәйкәлләр шәһәрнең бизәге, аның тарихын олылаучы хатирәләр булып торалар да, ни өчен авылларда һәйкәлләр юк дәрәҗәсендә? Сугышта һәлак булганнарга гына түгел, беренче колхозчыларга, беренче председательләргә, халык мәхәббәтен яулап алган җитәкчеләргә, алдынгыларга авылларда мәңгелек һәйкәлләр торырга тиеш. Һәйкәлләр горурлык тәрбияли, яшьләрне авылда ныгытуның, эшче көчләрне җиргә бәйләүнең ышанычлы бер юлы да алар».

Кышын без шәһәрдән ерак та түгел Прости дигән авылга Советлар Союзы Герое Никита Фадеевич Кайманов истәлегенә куелган һәйкәлне карарга барган идек. Февраль, чалт аяз көн иде. Герой каршысына басып уйланып тордык. Һәйкәлне дә Рәшит Вәлиевич корган, аны комплекслы итеп планлаштырган, бер кырыйда герой хатирәсенә багышланган тыйнак кына музей да оешып килә.

«Кечкенә авылларда да һәйкәлләр булсын! Аларда да олы кешеләр яши. Алар үзләренең олылыгына ышанып яшәсеннәр!»

Сухарево — киләчәк авылы, иртәгәге көнебез авылы. Хыялларның чынбарлыкка әверелеп, грандиоз планнарның тормышка аша баруын шушы авыл мисалында да күреп була. Крестьян бик күп мәшәкатьләрдән котыла, ул дәүләттән йорт, каралты-кура ала. Аңа эшләргә дә, ял итәргә дә шартлар тудырыла.

Хәзер безнең алга тагын бер сорау килеп баса: Сухарево мисалы искиткеч шәп, тик менә ул бөтен авыллар өчен дә кабул ителерлекме? Шушымы авылларның якты киләчәген билгеләүче дөрес юл? Әкияттәгедәй йортларда яши башлагач кешеләр чыннан да без көткән, без теләгән яңа хуҗаларга әйләнерме? Бәхетле булырмы алар?

Тагын саннарга мөрәҗәгать итәргә туры килә.

Өч бүлмәле бер йорт әлегә утыз мең сумга төшә. Утыз мең! Сухарево авылын төбетамыры белән үзгәртеп кору дәүләттән 15 миллион акча чыгара. Әлегә ул кадәр акчаны бер колхоз да, совхоз да үзе түли алмый, чыгымнарны тулаем дәүләт күтәрә. Бер Сухаревога шул кадәр акча... Түбән Кама районында эресен, вагын санап барлыгы 68 авыл бар. Димәк, бер шушы районның авылларын киләчәккә әзерләү өчен якынча бер миллиард сум акча кирәк. Ә Татарстанда ничә район?.. Саный башласаң, эшләр әнә кая китә! Санамыйча да ярамый — акча санаганны ярата! Димәк, бу — дөрес юл, әмма артык кыйммәтле юл.

Рәшит Вәлиевич болай ди:

«Хәзер халык кулында акча күп. Шуны исәпкә алып, авылларда да йортларны кооператив тәртибендә салуны оештырырга кирәк. Хуҗа акча түли, җитмәгән очракта ссуда ала, дәүләт аңа йорт салып бирә. Сухарево безнең горурлыгыбыз, трестның мактанычы, әмма ул безгә байтак кына ачы сабак та бирә! Бер генә мисал! Бәрәңге бакчаларын ихата тирәсендә калдырдык, нәтиҗәдә, йортлар бер-берсеннән шактый еракта утыралар. Бер караганда ма-

тур, уңайлы... Санап карасаң, гел юк өчен асфальт урамны озынга сузарга туры килде. Канализация, коммуникацияләр күпме өстәмә чыгым сорады. Йорт яннарында яшелчә-җимеш өчен нәни генә участоклар калдырып, бәрәңге бакчаларын читкә чыгарырга кирәк. Аннары!.. Иң мөһиме! Авыл төзелешенең ике формада булуы файдалырак: күп катлы йортлар да салырга, коттеджлар да...»

• • •

Әйе, кеше кайда гына яшәсә дә, басып торганы — Җир. Җир кешесе җирдәге хезмәте аша бәхетен табарга, рәхәт яшәргә тели. Авыл кешесеме ул, шәһәр кешесеме — мөмкин булган формалары аша җир белән арадашлыгын өзмәскә тиеш. Бу проблеманың көн тәртибеннән төшкәне юк, тиз генә төшәре дә күренми. Шушы очеркны язып утырганда «Комсомольская правда» газетасында кичкенә генә, әмма бик аяныч хат басылып чыкты.

«Кайсыдыр авылларда яшьләрнең әйбәт эшләүләре, рәхәт яшәүләре турында языла. Укыйбыз да көнләшәбез. Ә без менә соңгы чиккә җиттек: авылдан китәбез...

Күп яшьләребез механизатор булып эшли. Яңа техника вәгъдә иттеләр дә оныттылар. Һаман иске-москы тракторда йөрибез, атлаган саен ватыла алар! Нәтиҗәдә, хезмәт хакы бик аз эләгә. Ә юллар, юллар... Җәяү үтәм димә, машинада узар хәл дә юк, фермаларга вертолет белән барсаң гына!..

Шулай да туган авыл белән аерылышу җиңел түгел.

Сөләйманов, Шаңгәрәев... — барлыгы 10 имза.
Зәй-Каратай авылы, Лениногорск районы,
Татарстан АССР».

Зәй-Каратайда булганым бар! Искиткеч матур авыл иде заманында. Тауларында йөзем үсә! Җирнең оҗмахы булыр мөмкинлеге бар авылның... Егетләр шуны ташлап китәләр. Димәк, җаннарына якын эш бирмәгәннәр аларның... Ә юллар, юллар...

«Юллардан башларга кирәк!» ди Рәшит Вәлиевич... Нигә шул яшьләрне оештырып юллар сала башламаска?.. Чувашстанда булдык, бер районда нәни генә өч асфальт заводы эшләп утырганын күргәч... Татарстан юллары искә төште...

Юк, «Жилстрой» начальнигы Рәшит Вәлиевич Абдулхәкимовны «оҗмах кошы» итеп тасвирларга теләмәдем. Бардыр, аның да хаталары бардыр, ялгышлары да очрыйдыр, эш кешесендә хезмәт дәверендә төрлесе була. Әмма аның авылга, авыл хезмәт ияләренә, авыл төзелешенә мөнәсәбәте мине, монда телгә алынган байтак иптәшләрне БЕРГӘ очраштырды. Мин монда авыл төзелешенә катышкан, гүзәл йортлар, ышанычлы юллар салган ташчыларны, мич чыгаручыларны, механизаторларны, тракторчы егетләрне, уңган бригадирларны телгә алмадым. Бар алар, искиткеч гүзәл кешеләр бар трест системасында! «Жилстрой» бик күп эшче, җитәкче кадрларны тәрбияләп чыгарган урын. Алар турында язарга да, алдынгылар тәҗрибәсен өйрәнергә дә кирәк.

КПССның Татарстан өлкә комитетының IV пленумында (28 сентябрь 1984 ел) ясаган докладында КПСС өлкә комитетының беренче секретаре иптәш Г. И. Усманов болай диде:

«Быел (...) авыл хезмәтчәннәре өчен торак төзелешенә капитал салу 1983 нче елга карaганда 30 процентка күбрәк булды... Бүген канәгатьләну белән әйтергә мөмкин: партиянең күп кенә шәһәр һәм район комитетларында бу гаять мөһим проблемаларга мөнәсәбәтне үзгәрттеләр һәм авылларны социаль үзгәртеп кору эшен җитди активлаштыра алдылар. Мондыйларга Арча, Лаеш, Түбән Кама, Тукай районнарын кертергә мөмкин. Аларда шактый зур күләмле төзелеш эшләре алып барыла, торак йортлар, социаль һәм культура-көнкүреш объектларын коруга зур игътибар бирелә. Бу районнарның, алардагы хуҗалык җитәкчеләренең эше һәрьяклап мактауга һәм рәхмәткә лаек».

Искиткеч урынлы һәм дөрес бирелгән бәһа бу!

Әйе, өстәп шуны да әйтергә кирәк. Яңа Чишмәдә төрлесе төрле яктан килә торган юлларга, төрле почмакта башланган төзелеш эшләренә, мәйданнарга, чәчелеп яткан техникага карагач, бер уй күңелгә килде: Татарстанда махсус Авыл төзелеше эшләре министрлыгы оештырырга вакыт җитмәдеме икән?

Заман бездән зур эшләр сорый. Зур эшләргә исә үзәкләшү, оешканлык һәм югары хезмәт энтузиазмы аша гына ирешеп була икәнен без инде күптән беләбез.

*Август — октябрь, 1984 ел*
*Түбән Кама — Яңа Чишмә — Казан*

**Мөҗип Низамиев,**

Татарстан культура министры урынбасары,
II Бөтенсоюз үзешчән сәнгать фестивален
үткәрү буенча республика оештыру
комитеты председателе урынбасары,
РСФСРның һәм ТАССРның атказанган
культура работнигы

# СҮНМӘС БАЛКЫШ

Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның калын-калын томнары — безгә, килер буыннарга калдырган биниһая кадерле һәм кыйммәтле мирасы белән яңадан танышып утырам. Үзе дә, җырлары кебек үк, «халкымыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә рәүшан көзгесе» һәм мәңге сайрар сандугачы булган сөекле әдибебез 1910 елда Казанның Шәрык клубында халык әдәбияты турында лекция укыганда бик тә хикмәтле сүзләр әйтә:

«...Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул. Ул әле, әллә нинди кара көчләр басканга күрә генә, бу күренештә йөри...»

Халык таланты алдында чиксез хөрмәт белән баш иеп әйтелгән әлеге канатлы, мәңге үлмәс сүзләр, Бөек Октябрь социалистик революциясе миллионнарча гади хезмәтчәннәрне «кара көчләр» изүеннән мәңгегә азат иткәч, тагын да көчлерәк, мәгънәлерәк яңгыраш тапты. Чөнки яулап алынган ирекле тормыш, рухи ирек табигый рәвештә йөзләрчә һәм меңнәрчә кешеләрдә иҗат итү — сынлы сәнгатьтә, музыкада, әдәбиятта үзләрен күрсәтү омтылышын тудырды. Социализм халыкның Тукай әйткән гаҗәп сыйфатларын яңача балкытты. Ул хезмәт ияләренә рухи кыйммәтләргә киң юл ачып кына калмады, ә бәлки аларны культураның турыдан-туры иҗатчылары да итте. Бөек Октябрь һәм ленинчыл милли политика җимеше булган безнең Татарстан да, экономика-көнкүреш өлкәсендә җиңүләр яулау белән бергә, культура өлкәсендә дә ныклы, ышанычлы рәвештә алга атлый.

Республикабызда культура һәм сәнгать уку йортларының тулы бер комплексы эшли, башкалабызда консерватория, культура институты, Брежнев шәһәрендә сәнгать училищесы, Алабугада культура-агарту училищесы, Әлмәт, Түбән Кама шәһәрләрендә музыка училищелары, Казанда театр, музыка, художество училищелары культура һәм сәнгать оешмалары өчен кадрлар әзерлиләр. Моннан кала шәһәрләребездә һәм авыл районнарында 85 ләп музыка һәм художество мәктәбе эшли, колхоз һәм совхозларда аларның 60 ка якын филиалы ачылды.

Социалистик чынбарлык В. И. Ленинның «Бер җирдә дә халык массаларының чын культура белән бездәгедәй кызыксынганнары юк; бер җирдә дә культура мәсьәләләре бездәге шикелле әнә шулай тирәнтен һәм эзлекле куелмый», дигән сүзләренең дөреслеген ышандырырлык итеп раслый бара. Бөтен халыкның белем һәм культура дәрәҗәсе бик нык күтәрелү, художество иҗатының моңарчы тарихта күрелмәгәнчә киң колач җәюе, хезмәт ияләренең рухи ихтыяҗлары һаман тулырак канәгатьләндерелү — социалистик культураның мөһим казанышлары әнә шундый.

Халык иҗатының искиткеч колач алуы, дип әйткән иде К. Маркс, социализм һәм коммунизм шартларында җәмгыять үсешенең объектив законы. Үзешчән сәнгатьне миллионнарча кешеләрне идея ягыннан баету, әхлакый яктан тәрбияләүнең, аларның ихтыярын, хисләрен һәм фикерләрен чагылдыруның куәтле чарасы, хезмәт ияләре өчен

яшәү көче бирә торган шатлык һәм рухлану чыганагы итеп карап, Коммунистлар партиясе һәм Совет дәүләте аны үстерүгә һәрвакыт зур игътибар биреп киләләр. Клуб, уку өйләре, культура йортлары һәм сарайлары төзү, үзешчән сәнгать коллективларын музыка кораллары һ. б. кирәкле әйберләр белән тәэмин итү, түгәрәк җитәкчеләрен махсус югары һәм урта уку йортларында әзерләү, һәвәскәр артистларга даими иҗат ярдәме күрсәтү Совет властеның беренче көннәреннән үк партия һәм совет органнарының контроленә алынды. Хәзер илебез хезмәт ияләренә культураның барлык өлкәләрендә искиткеч киң дәрәҗәдә иҗат итү мөмкинлекләре тудырылды. Коммунистлар партиясенең идеологик җитәкчелеге тайпылышсыз рәвештә партиялелек һәм халыкчанлык принциплары нигезендә эш итүче, үз иҗатларында социалистик реализм методына таянучы һәвәскәр художникларның идея ягыннан үсешен тәэмин итә.

Үзешчән сәнгать алдына партиябез куйган бурычларны тормышка ашыру өчен СССРның яңа Конституциясендәге «Социаль үсеш һәм культура» дигән бүлектә гражданнарның иҗат көчләрен, сәләтләрен һәм талантларын үстерү һәм куллану өчен реаль мөмкинлекләр гарантияләнүе бик әһәмиятле.

Рухи культурабызның югары дәрәҗәсе, хезмәт ияләренең үзешчән сәнгать иҗатында күпләп катнашуы советча яшәү рәвешенең характерлы үзенчәлегенә әверелде. Нык үскән социалистик җәмгыятьтә үзешчән сәнгать политик максатчанлыгы, массовыйлыгы, күпмилләтлелеге, жанр ягыннан күп төрле булуы белән аерылып тора. Күп бизәкле һәм тирән эчтәлекле үзешчән сәнгать алдынгы марксизм-ленинизм идеологиясен чагылдыра, җәмгыятебезнең социалистик культурасын киң пропагандалый.

Бездә утызынчы еллардан башлап кызыклы шундый күренеш күзәтелә: социалистик җәмгыятебез үсешенең аерым этапларын халкыбызның иҗат көчләренә смотрлар төсендә билгеләп үтү гүзәл бер традициягә әверелде. Мисал эзләп ерак китәсе юк. Әле һәркем хәтерлидер, Бөек Октябрьның 60 еллыгына багышлап, 1975—1977 еллар дәвамында өч турда үткәрелгән Беренче Бөтенсоюз фестивале халык талантларының совет чорында ничек чәчәк атуын тулы гәүдәләндерде, нык үскән социалистик җәмгыятьтә кешенең нинди иҗади биеклекләргә күтәрелә алуын ышандырырлык һәм ачык итеп дәлилләде. Әлеге фестиваль — халык талантларына смотрның иң массовыена әйләнде. Өч меңнән артык хор, музыка, хореография коллективлары, халык театрлары, студияләр, агитбригадалар, 80 мең эшче, колхозчы һәм башка күп төрле һөнәр ияләре, студентлар, укучылар, хәрби хезмәткәрләр лауреат исеме яулап алдылар.

Татарстан өчен дә бу фестиваль үзешчән сәнгатьнең тагын да массовыйрак булып үсүенә, репертуарларның иң яхшы әсәрләр белән баюына һәм катнашучыларның башкару осталыгы күтәрелүгә ярдәм иткән бик әһәмиятле вакыйга булды. Республикабызда яшәүче 300 меңнән артык кеше концертларда һәм спектакльләрдә, агитбригада программаларында, күргәзмәләрдә һәм конкурсларда үз осталыгын күрсәтте. Үзешчәннәр иҗатында республикабыз хезмәтчәннәренең Ватанга, Коммунистлар партиясенә, Ленинга мәхәббәте, гражданнар һәм Бөек Ватан сугышлары героикасы, эшчеләр сыйныфының данлы революцион, сугышчан һәм хезмәт традицияләренә тугрылык ачык чагылды.

Халык талантларына смотр үзешчән сәнгатьтә катнашучыларның сафын сизелерлек үстерергә ярдәм итте. Бу вакыт эчендә аңа тагын 65 мең үзешчән кушылды. Фестиваль барышында, бигрәк тә авыл районнарында, культура сарайлары һәм йортларының, клубларның материаль-техник базасын ныгыту буенча зур эш башкарылды. Минзәлә, Октябрь, Актаныш, Чистай, Апас, Куйбышев һәм Балтач район культура йортларының яңа биналары файдалануга тапшырылды. Бөгелмә, Алабуга район культура йортлары махсус биналар алдылар, колхоз һәм совхозларда 140 клуб һәм культура йорты салынды, 380 клуб учреждениесе капиталь ремонтланды. Культура учреждениеләрен төзүдә һәм ремонтлауда, үзешчән коллективларны тиешле җиһазлар белән тәэмин итүдә колхоз һәм совхозлар да актив катнашты.

Бөтенсоюз Фестиваленең Ульяновскида үткәрелгән III турының аерым жанрлар буенча конкурсларында республикабызның үзешчән сәнгать коллективлары 4 зур һәм 194 кечкенә алтын медаль алдылар. 15 коллектив һәм аерым башкаручы Бөтенсоюз фестивале смотры лауреаты исеменә лаек булды. 26 коллективның һәм аерым башкаручыларның осталыгы Бөтенсоюз фестиваленең I—II дәрәҗәле дипломнары, 48-е Бөтенроссия фестивале дипломнары белән бәяләп үтелде. Лауреатлар арасында Арча район культура йортының татар халык уен кораллары оркестры, ТАССРның X еллыгы исемендәге культура сараеның «Яшьлек» халык хореография ансамбле, Куйбышев исемендәге Казан химия заводының «Саз» халык вокаль ансамбле, Төзүчеләр культура сараеның халык бию театры, Арча районының Наласа культура йорты, Минзәлә район культура йортының халык уен кораллары оркестрлары, Урицкий исемендәге культура йортының рус халык уен кораллары оркестры, Актаныш район культура йортының ирләр вокаль ансамбле, Буа район культура йортының халык җыр һәм бию ансамбле, Саба һәм Баулы район культура йортларының бию коллективлары, солистлар Миләүшә Юнысова, Фи-

рая Измайлова, Ринат Хәлиуллин, нәфис сүз осталары Бухарест Гарипов, Гүзәл Галиева, Камил Сәфәргалиев һәм башка бик күпләр бар иде.

Халык театрларына, театр коллективларына һәм үзешчән агитация бригадаларына, зона смотрларында Арча районының Әтнә культура йорты халык театры, Сарман, Аксубай район культура йортларының үзешчән агитация бригадалары, Буа районының Адав-Толымбай культура йорты, Сәетгалиев исемендәге культура сарае Бөтенсоюз фестивале лауреатлары исемен алдылар. Азнакай район культура йортының, Брежнев шәһәр культура йортының халык театрлары, Мөслим культура йорты агитбригадасы Бөтенсоюз фестиваленең I дәрәҗәле дипломына лаек булды.

Фестивальнең III турында оештырылган күргәзмәгә һәвәскәр рәссамнарның һәм декоратив-гамәли сәнгать осталарының әсәрләре киң тәкъдим ителде. Иң яхшы әсәрләр Бөтенроссия һәм Бөтенсоюз күргәзмәләрендә күрсәтелде. Шулар арасыннан А. Фомина, А. Свергузин, В. Быковский, Н. Хәбибуллин, И. Имамов, М. Бикбулатова, А. Доброхотова, Р. Мөбәрәков әсәрләренә югары бәя бирелде.

Кино-фото сөючеләрнең Бөтенроссия конкурсында 9 авторның хезмәте күрсәтелде һәм алар Бөтенроссия фестиваленең I—II дәрәҗәле дипломнары белән бүләкләнделәр.

Үзешчән сәнгатьнең Беренче Бөтенсоюз фестиваленнән соң алты ел вакыт узды. КПСС Үзәк Комитетының фестивальдән соң ук, 1978 елда кабул ителгән «Үзешчән сәнгать иҗатын тагын да үстерү чаралары турында»гы карарын үти барып, республикабызның партия һәм совет органнары, профсоюз һәм комсомол оешмалары, культура учреждениеләре хезмәт мияләренең үзешчән сәнгатен киң җәелдерү, аларны хәзерлекле белгечләр, музыка кораллары һәм техник средстволар белән тәэмин итү буенча зур эш башкардылар. Бу елларда 5 район культура йорты, 4 культура һәм техника сарае, 220 урында авыл культура йорты салынды. Һәр җирдә культура комплекслары һәм узәкләшкән клуб системалары төзелде. Колхоз һәм совхозларда «Авыл клубы, китапханә, киноустановка СССРның Азык-төлек программасын үтәүдә» дигән махсус социаль-культура планнарын тормышка ашыру үзешчән сәнгатьнең тормыш белән бәйләнешен көчәйтте, концерт, театр, агитбригада коллективларының сугышчанлыгы, башкару осталыгы күтәрелүгә булышлык итте.

Шунысы аеруча куанычлы: соңгы елларда авыл үзешчән сәнгатендә сыйфат ягыннан бик яхшы үзгәрешләр булды. Авыл хуҗалыгы материаль-техник базасының киңәюе, аның индустриаль юлга күчә баруы, югары житештерү культурасы керү, совет авылында яшәүчеләрнең җәмәгать активлыгы һәм инициативасы, белеме һәм гомуми культурасы үсү, тормыш дәрәҗәсе күтәрелү авылда үзешчән сәнгатьнең массовыйлыгын арттыруда, аның художество дәрәҗәсе күтәрелүдә дә чагыла. Урыннардагы партия оешмалары, халык депутатларының район һәм авыл Советлары башкарма комитетлары халык иҗатын үстерү, үзешчәннәрнең профессиональ осталыгын күтәрү мәсьәләләре белән активрак шөгыльләнә башладылар. Бу җәһәттән Казан, Брежнев шәһәрләре, Арча, Сарман һәм Актаныш районнары тәҗрибәсе игътибарга лаек. Әлеге районнарда һәм шәһәрләрдә күп кенә партия һәм комсомол работниклары, предприятие, колхоз, совхоз җитәкчеләре үзләре дә үзешчән сәнгатьтә актив катнашалар һәм табигый ки, аңа һәртөрле ярдәмне күрсәтәләр. Халык талантларын үстерү, хезмәт мияләрен идея-политик, эстетик һәм әхлакый тәрбияләүдә үзешчән сәнгатьнең ролен күтәрү проблемалары партиянең шәһәр һәм район комитетлары бюролары утырышларында, башлангыч оешмаларда, халык депутатларының шәһәр һәм район Советлары сессияләрендә һәм башкарма комитет утырышларында даими рәвештә тикшерелә.

Мондый күренешнең нәтиҗәләре дә куанычлы. Республикабызның Сарман районын гына алыйк. Бирөдә үзешчәннәрнең саны 11 меңнән артык. Районның һәр өч кешесеннән берсе, концерт һәм спектакльләрдә, күргәзмә һәм конкурсларда актив катнашып, халыкка культура хезмәте күрсәтә. Сарманлыларның дәртле җырлары Казан, Ульяновск, Мәскәү, София сәхнәләрендә яңгырый. Алар опера һәм балетлардан ария һәм сюиталар башкаралар, күп тавышлы хор өчен язылган әсәрләр җырлыйлар, катлаулы музыка коралларында уйныйлар.

Район үзешчәннәре арасында йөзләрчә җыр, бәет, такмак осталары, биючеләр, рәссамнар һәм музыкантлар бар. Һәвәскәрләр тарафыннан районның үз кешеләре — Дамир Гарифуллин, Валерий Әхмәтшин, Әзһәр Габиди, Рафис Уразаев, Мөсәвир Гатауллин, Миргасим Гаскәров иҗат иткән җырлар җырлана.

Әйе, Сарман җире нефтькә һәм икмәккә генә түгел, талант мияләренә дә бик бай. Аларның байтагы бүгенге профессиональ сәнгатьнең, әдәбиятның күренекле вәкилләре булып танылды.

Сарман үзешчән сәнгать осталарының соңгы еллардагы уңышлары турында аеруча шатланып сөйләргә мөмкин. I Бөтенсоюз фестиваленең беренче дәрәҗәле, Россия Федерациясе фестиваленең лауреат дипломнарына лаек булган район бию коллективы һәм «Сарманда сабан туе» программасы белән Бөтенсоюз фестивалендә лауреат исеме һәм зур алтын медаль алган, Мәскәүдә йомгаклау концертларында катнашкан район культура йорты агитбригадасы да үз осталыкларын көннән-көн камилләштерә баралар. «Яшьлек» җыр һәм бию ансамбле Болгария Халык Республикасының Г. Димитров исемендәге яшьләр үзәгендә үткәрелгән халыкара фестивальдә дүрт алтын, җиде көмеш (!) медаль белән бүләкләнде.

Теләнче Тамак культура йорты халык театры. Ләке культура йортының «Игәнә» фольклор ансамбле, Азалак авылының художество-агитация бригадасы, Саклаубаш, Яңа Бүләк, Иске Дөреш, Нөркәй, Ләшәү-Тамак, Рангазар, Иске Минзәләбаш үзешчән коллективлары да башкару осталыкларының көннән-көн арта баруы, һәркайсының кабатланмас үз йөзе булуы белән аерылып торалар.

Мондый сөенечле мисалларны һәр районнан күпләп китерергә була. Хәзерге вакытта республикабыз колхозлары һәм совхозларында гына да 1300 дән артык хор коллективы эшли, алар 40 меңгә якын һәвәскәр җырчыны берләштерә. Мең ярымнан күбрәк бию ансамблендә 20 меңнән артык биюче катнаша, 2 мең ярым драма коллективларында 35 мең үзешчән артист уйный. Клубларда һәм культура йортларында 300 дән артык халык уен кораллары, тынлы һәм эстрада оркестрлары, меңнән артык агитация-художество бригадалары чыгыш ясый, йөзләрчә сәнгать түгәрәкләренә күп санлы рәссамнар, фото һәм киносөючеләр йөри. Гаилә ансамбльләренең киң таралуын да куанычлы күренеш, сыйфат үзгәрешләренең бер билгесе дип санарга мөмкин. (Мондый үзешчәннәр Сарман районында аеруча күп очрый.) Ансамбльдә җырлау һәм музыка белән шөгыльләнү көнкүрешнең аерылгысыз өлешенә әверелде. Зур инструменталь коллективларның, тынлы һәм халык оркестрларының, җыр һәм бию ансамбльләренең, һәвәскәр композиторларның саны арта, осталыгы үсә бара.

Һәвәскәр композиторлар дигәннән, 1983 елның апрелендә, аларга багышлап I республика фестивален үткәрү дә зур роль уйнады. Фестивальдә катнашкан һәвәскәр композиторлар төрлесе төрле төбәктә яшиләр. Һөнәрләре дә төрле. Әмма аларны җырга-музыкага булган тирән мәхәббәт бер максатка берләштерә. Шунысы куанычлы: өлеге авторлар иҗат иткән әсәрләр заманыбыз сулышын тоеп язылганнар. Алар иҗатында кызу темплар белән алга баручы җәмгыятебезнең уңышлары да, замандашларыбызның якты уй-хыяллары да күркәм чагылыш таба. Тагын шунысы үзенчәлекле: һәвәскәр композиторлар җырның төрле жанрларында, төрле уен кораллары өчен иҗат итәләр. Башкаручыларның осталыклары да күзгә күренеп камилләшә. Брежнев шәһәренең «Автозаводец» клубы каршындагы «Малахит», Мамадыш шәһәренең Ушмы аръягы культура йортындагы «Нократ» вокаль-инструменталь ансамбльләренең һәвәскәр композиторлар белән тыгыз элемтәдә эшләүләре һәм аларның әсәрләрен зур осталык белән башкарулары күңелдә соклану хисләре уята.

Һәвәскәр композиторлардан И. Закиров, С. Әхмәтова, З. Сәгыйтов, Е. Кувайцев, Ф. Барнев, Р. Вәлиуллин, В. Әхмәтшин һәм башка бик күпләр иҗат иткән җырлар яшьлеккә, тынычлыкка, бүгенге матур тормышыбызга мәдхия булып, сугыш уты кабызырга маташучыларга көчле нәфрәт авазы булып яңгырыйлар.

Шуны да искәртеп үтәргә кирәк: авыл үзешчән сәнгатенең уңышы шактый дәрәҗәдә балалар музыка мәктәпләре, халык театрлары, һәвәскәрләр берләшмәләре һәм авыл культура йортлары челтәре киңәю, бу эштә интеллигенция вәкилләренең — укытучы, врач һәм авыл хуҗалыгы белгечләренең актив катнашуы белән бәйләнгән.

Балалар ансамбльләре дә торган саен уңышлырак чыгыш ясыйлар. Азнакай техника йортының «Ләйсән», Буа районының Кул-Черкен авыл культуры йортының «Әйлән-бәйлән» җыр-бию ансамбльләре (аларның һәр икесен дә ТАССРның атказанган культура работнигы, Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты Алсу Гарифуллина оештырды) республика, Бөтенсоюз телевидениесе һәм радиосы аша чыгыш ясап, миллионнарча тамашачыларның кайнар мәхәббәтен яуладылар. Актаныш район культура комплексы, Сарман район культура йорты, Саба районының Алан, Арча районының Кенәр культура йортлары каршындагы балалар ансамбльләренең дә (җитәкчеләре — Татарстанның атказанган культура работнигы А. Закиров, З. Фәхрисламов, Ф. Хәсәнова, В. Булатова) үзенчәлекле аһәңе көннән-көн ныграк яңгырый.

Фольклор ансамбльләре дә үсеш-яңарыш чорын кичерә. 1981 елның декабрендә булган фольклор бәйрәме халык талантларының эчке рухи байлыгын, кабатланмас матурлыгын тагын бер мәртәбә ачык күрсәтте. Апас район культура йортының татар халык көйләрен башкаручы әбиләр хоры (ул «Сада» ансамбле дип йөртелә), Лаеш район культура йорты һәм Минзәлә районының Николаевка культура йорты каршындагы рус

халык хорлары, Аксубай районыннан Иске Тимошкино авылының һәм Октябрь районыннан Мичурин исемендәге колхозның чуваш халык җыр һәм бию ансамбльләре, Арча районының Шурабаш культура йортының удмурт халык җыр һәм бию ансамбле, Сарман районыннан Ләке авылының һәм Алабуга районыннан Азин исемендәге колхозның керәшен татарларыннан торган җыр һәм бию ансамбльләре чыгышлары халыклар дуслыгына гимн булып та яңгырый.

Милли культураларның үзара йогынты ясау һәм бер-берләрен баету процессы елданел тирәнәя бара. Әлеге күңелле күренеш татар, рус, мари, чуваш, удмурт, украин һәм башка милләт вәкилләре чыгышларында бик ачык чагыла. Алар, милли сәнгатьнең табигатен кадерләп саклаган хәлдә, башка халыкларның казанышларыннан иҗади файдаланалар.

Моны раслаучы ачык дәлилләрнең берсе — татар хор сәнгатендә күп тавышлылыкны үзләштерү. Хор коллективларының, вокаль ансамбльләрнең күпчелеге хәзер күптавышлы хор әсәрләрен уңышлы башкара. Күп кенә милли бию коллективлары шулай ук милли сәнгатьне иҗади үстерү, башка халыклар биюләренең хәзерге хореографик техникасын үзләштерү нәтиҗәсендә югары башкару осталыгына ирештеләр.

Үзешчән иҗатның сыйфаты яхшыру белән бергә, сәнгать сөючеләр даирәсе дә нык киңәйде. Хәзер теге яки бу үзешчән коллектив аерым авыл клубы һәм культура йорты тамашачылары алдында чыгыш ясау белән генә чикләнми, һаман саен зуррак аренага чыга. Соңгы елларда, мәсәлән, Мамадыш, Әгерҗе, Сарман, Буа, Аксубай, Актаныш, Мөслим, Октябрь, Зеленодольск, Саба, Баулы, Минзәлә районнары һәвәскәрләренең тугандаш социалистик илләрдә чыгыш ясаулары һәм һәркайда югары бәягә лаек булулары әнә шуны ачык дәлилли.

Совет халкының Бөек Ватан сугышында җиңүенә 40 ел тулуга багышланган II Бөтенсоюз смотры Октябрь революциясе кабызган иҗат ялкынын — мәңге сүнмәс балкышны — тагын да көчлерәк дөрләтеп җибәрде. Үзешчән сәнгатьтәге мондый яңа балкыш һәркемнең зур җаваплылык тоюыннан киләдер. Ә фестивальнең максаты чыннан да җаваплы — күп миллионлы корбаннар бәрабәренә Ватаныбызның бәйсезлеген саклап калган, фашизмны тар-мар иткән, тынычлык урнаштырган һәм дөньяның прогрессив көчләре белән бергә бүген дә тынычлык сагында уяу торучы халкыбызның тиңдәшсез батырлыгына дан җырлау һәм, билгеле, үзешчән сәнгать хәзинәсен дулкынландыргыч, тирән эчтәлекле яңа репертуар, спектакльләр һәм концертлар, театрлаштырылган бәйрәмнәр, тематик кичәләр, агитация-художество бригадалары, сюжетлы бию программалары, һәвәскәрләрнең яңа фильмнары һәм картиналары белән баету. Бу смотрның үзенчәлеге тагын шунда: анда төп игътибар зона, республика, союз конкурслары уздыруга түгел, ә үзешчәннәрнең хезмәт һәм ял урыннарындагы башлангыч оешмаларында методик ярдәм күрсәтүгә, һәвәскәрләрнең башкару осталыгын күтәрүгә һәм репертуарларын баетуга юнәлдерелә. Фестивальнең йомгаклау концертлары авыл һәм поселок, район һәм шәһәр күләмендә үткәрелә. Республика смотрын уздыру буенча оештыру комитеты һәм жюри членнары лауреатлыкка кандидатларны нәкъ менә урыннарда табарга һәм билгеләргә тиешләр.

Шунысы куанычлы: республикабыз әлеге смотрга зур тәҗрибә туплап, иҗат көчләре чәчәк аткан хәлдә килде. Ләкин бу тынычланырга хокук бирми. Илебез тормышында зур вакыйга булган бу смотр безнең алга җитди бурычлар куя. Шуларның иң әһәмиятлесе үзешчән сәнгать смотрын оешкан төстә, югары идея-художество дәрәҗәсендә үткәрүдән, массаларны партиябезнең XXVI съездында, КПСС Үзәк Комитетының аннан соңгы Пленумнарында куелган бурычларны тормышка ашыруга туплауда үзешчән сәнгатьнең әһәмиятен тагын да күтәрүдән гыйбарәт.

Бөтенсоюз смотрының программасы киң һәм күпкырлы. Планлаштырылганча, 1983 ел азагында һәм 1984 елның январь айларында барлык хезмәт коллективларында үзешчәннәрнең халык алдындагы отчет концертлары һәм спектакльләре конкурсы үткәрелде. Узган елның февраль-март-апрель айларында район үзәкләрендә һәм шәһәрләрендә ярышучы колхозлар, совхозлар, предприятиеләрнең үзешчәннәре көч сынашты. Клубларда һәм культура йортларында февраль аенда — хәрби-патриотик, апрель аенда — героик-революцион, майда — Бөек Ватан сугышына багышланган җыр бәйрәмнәре гөрләп узды. Октябрьда исә хезмәткә һәм СССР халыклары дуслыгына багышланган җыр бәйрәмнәре үткәрелде. Көзге һәм кышкы айларда үзешчән сәнгатьнең театр, хор, музыка, бию, эстрада, цирк жанрлары буенча агитация-художество бригадалары смотрлары уздырылды. Шул ук 1984 елның октябрь-ноябрь айларында — районнарда, декабрьдә Казанда үзешчән рәссамнар һәм декоратив-гамәли сәнгать осталары һәм фотосөючеләр күргәзмәләре, киносөючеләр эшләгән фильмнар конкурслары оештырылды. Халык талантлары — оста куллар эшләгән әйберләргә күргәзмәләр уздырылды.

Үзешчән авторларның Бөек Җиңүгә 40 ел тулуга багышланган әсәрләренә конкурс игълан ителгән иде. Аңа 1985 елның февралендә йомгак ясалды. Смотр рамкаларында балалар һәм яшьләр өчен Бөтенсоюз театр атналыгы, музыка һәм китап атналыгы, «Һәрвакыт булсын кояш!» девизы астында балаларның рәсем конкурслары да уздырыла.

Әйткәнебезчә, үзешчәннәрнең Бөтенсоюз фестивале республикабызда, халык талантлары бәйрәме төсендә, зур оешканлык белән башланып китте. Аны ачуда Бөек Ватан сугышы батырлары, унберенче бишьеллык геройлары, сәхнә ветераннары актив катнашты. Зеленодольск, Әлмәт, Алабуга, Мамадыш районнары колхоз һәм совхозларында, предприятие һәм учреждениеләрендә смотрны ачу тантаналары СССР Конституциясе көнен, Авыл хуҗалыгы работниклары көнен, Ленин комсомолы туган көнне тантаналы төстә билгеләгән вакытта, халык массаларының актив катнашында, театральләштерелгән җыр һәм хезмәт бәйрәмнәре төсендә үткәрелде.

Аксубай, Мөслим, Тәтеш районнарында Бөтенсоюз смотры үзара ярышучы хуҗалыкларның иҗади отчетлары белән башланып китте. Питрәч районында әлеге смотрны ачу Вахитов исемендәге колхозның һәм «Колай» совхозының оста куллары хәзерләгән төрле әйберләр һәм кулинария күргәзмәсен караудан башланды. Аннан соң «Ленино-Кокушкино», «Шигали»,«Үшнә» совхозлары, Ленин, Тукай, Гаврилов исемендәге колхозлар, кош фабрикасы, район мәгариф бүлеге, үзәк больница һәм башка коллективларның үзешчән сәнгать осталары, бай эчтәлекле, мавыктыргыч программалар белән чыгыш ясап, нур өстенә нур өстәделәр.

Буа районында да смотрны ачу хезмәт һәм тынычлык бәйрәме төсендә узды. Анда район, колхоз һәм совхоз, предприятие һәм учреждение җитәкчеләре, партия һәм комсомол оешмалары секретарьлары, сугыш, хезмәт, партия һәм комсомол ветераннары, күпьеллык бай тәҗрибәләре булган сәхнә осталары, культура работниклары, хезмәт алдынгылары катнашты. «Ватан», «Чулпан», «Гигант», «Коминтерн», Тельман исемендәге, СССРның 60 еллыгы исемендәге колхозлар һәм «Кыят» тәҗрибә-производство хуҗалыгы партия оешмалары секретарьлары үз хуҗалыкларында Бөтенсоюз смотрының ничек барышы турында рапорт бирделәр. Аннары сәхнә халык талантлары карамагына тапшырылды. Биредә үзешчәннәрдән барлыгы 300 дән артык кеше көч сынашты. Район культура йортының җыр һәм бию халык ансамбле, медицина училищесы хоры, «Коминтерн», «Коммунизм», «Ватан», Тельман исемендәге һ. б. хуҗалыкларның үзешчәннәре үзләренең югары башкару осталыгына ия булуларын күрсәттеләр. Аларның һәр чыгышы тыныч хезмәттә һәм яу кырында үзен батырларның да батыры итеп таныткан совет халкының эчке һәм тышкы матурлыгына дан җырлау иде, тынычлык өчен көрәшкә чакыру белән сугарылган иде. Смотрда катнашучылар Буа районының үзешчән рәссамнары һәм декоратив-гамәли сәнгать осталарының күргәзмәләрен дә яратып карадылар.

Казанда, Сарман, Актаныш, Минзәлә, Апас, Балык Бистәсе районнары колхоз һәм совхозларында, предприятие һәм учреждениеләрендә, уку йортларында һәм мәктәпләрендә дә үзешчән сәнгать коллективларының отчет концертлары зур уңыш белән бара.

Смотр барышында, халык иҗатын бөтен тулылыгы белән балкыту максатыннан чыгып, кызыклы конкурслар игълан ителә. Зәй шәһәренең смотрны оештыру комитеты, мәсәлән, коллектив белән ял итүне иң яхшы оештыруга конкурс игълан итте. Әлеге конкурска, иң беренче булып, автоагрегат заводы коллективы «Бөтен гаилә белән ял итәбез» дигән кызыклы программасын тәкъдим итте. Күмәкләшеп ял итү завод эшчеләре һәм инженер-техник работниклары иҗат иткән сынлы сәнгать, декоратив-гамәли сәнгать һәм фоторәсемнәр күргәзмәләрен караудан башланды. Предприятие хезмәтчәннәре һәм аларның гаилә членнары бу көнне «Без бергәләп җырлыйбыз да биибез, күмәк булгач, моңаюны белмибез» дигән мавыктыргыч программада катнаштылар, «Социалистик ярышта җиңүчеләрне хөрмәтлибез» дигән театральләштерелгән концерт карадылар. «Әти, әни һәм мин — спортчылар гаиләсе» дигән исем астында үткән спорт ярышлары һәм «Шәһәрем минем» дигән дискограмма да һәркем күңеленә хуш килде.

Һәр төбәкнең үзенә генә хас кабатланмас традицияләре, талантлары бар. Алар күңелендә кабынган иҗади ялкын, салават күперендәгечә, төрле төсләргә кереп балкып, меңләгән тамашачыларны сокландыра.

Халкыбыз талантларга бик бай. Аларның саны елдан-ел арта бара. Үзешчән сәнгатьтә төрле һөнәр ияләре бик теләп катнашалар. Брежнев шәһәреннән КамАЗ төзелеше ударниклары Надежда Кондратова, Булат Сәләхов, Куйбышев районыннан ярдәмче мәктәп укытучысы Юлия Малинина, Буа районының «Кыят» совхозыннан баш зоотехник Михаил Чекелев, Чистай районының Тукай исемендәге колхозыннан терлек азыгы хәзерләү буенча баш белгеч Әнәс Саттаров, Әлки районыннан «Сельхозтехника» берләшмәсе механизаторы Марс Ибраһимов, Аксубай урта мәктәбеннән чит телләр укытучысы Валентина Янелкина һәм башка бик күпләр... Алар арасында хуҗалык җитәкчеләре, партоешма секретарьларының да булуы аеруча күңелле күренеш. Актаныш районының «Гигант», Нур Баян исемендәге колхозларының партоешма секретарьлары А. Шакиров,

Р. Гыйльфанов, Буа районының «Коминтерн», Аксубай районының Вахитов исемендәге, Мөслим районының XXII партсъезд исемендәге колхозлары председательләре Ф. Хайсаров, И. Камалов, Х. Мирзаянов үзешчән сәнгатькә җаны-тәне белән гашыйк кешеләр рәтенә керәләр. Алар күңелендә кабынган иҗади ялкын башкалар күңеленә дә күчеп дөрли, халык талантларының тагын да күбәюенә китерә.

Актаныш районының Сәфәр культура комплексы үзенең драма коллективы белән тирә-юньдә дан тота. Мәктәп директоры Р. Шакиров җитәкләгән әлеге драмтүгәрәккә укытучылар, сыер савучылар, механизаторлар бик теләп йөриләр. Шулай ук Буа районыннан «Коммуна» колхозының дуңгызчылык фермасы коллективы да үзешчән сәнгатьтә бөтен составы белән катнаша. Мөслим районының «Маяк» колхозындагы Чакмак фермасы коллективы да үзешчән сәнгать өлкәсендә мактаулылар рәтендә йөри. Алар район фермалары арасында барган социалистик ярышта да, сәхнәдә барган бәйгедә дә еш кына беренчелекне яулыйлар.

Безнең үзешчән сәнгатьнең нәтиҗәлелеген, гражданлык өлгергәнлеген раслау өчен мондый мисалларны күпләп китерергә була. Хезмәт һәрвакыт хөрмәт ителә. Үзешчән сәнгать өлкәсендә ирешкән уңышлары өчен бик күпләр Ватаныбызның югары бүләкләренә лаек булдылар. Шулар арасыннан Актаныш район культура йорты директоры, Ленин ордены кавалеры, РСФСРның атказанган культура работнигы Хәмит Раянов, Брежнев һәм Әтнә халык театрлары режиссерлары, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены кавалерлары һәм ТАССРның атказанган культура работнигы дигән мактаулы исемгә лаек булган Мансур Кашапов, Гомәр Мәрдановны беренче булып телгә аласы килә. Балтач районының Чепья культура йортының җыр һәм бию ансамбле җитәкчесе Ф. Гыйльманов, Азнакай районының Тат. Шуган авылындагы үзешчән киностудия җитәкчесе Ф. Маннанов, Аксубай халык театры режиссеры, художество-агитация бригадасы җитәкчесе Г. Макарова, республика халык иҗаты һәм культура-агарту эшләре фәнни-методик үзәгенең бал биюләре буенча художество җитәкчесе В. Рычков һәм башка бик күпләрнең күкрәкләрендә хөкүмәтебезнең орден һәм медальләре ялтырый. Дистәләрчә үзешчәннәр РСФСРның һәм ТАССРның атказанган культура работнигы дигән мактаулы исем йөртәләр.

Бөтенсоюз смотрын үткәрү буенча республика оештыру комитеты үзенең чираттагы утырышында смотрның барышына кагылышлы мәсьәләләрне карады. ТАССР Язучылар һәм Композиторлар союзлары утырышларында һәвәскәрләр өчен пьесалар, шигырьләр һәм җырлар язу, культура шефлыгын көчәйтү планнары тикшерелде. Республика халык иҗаты һәм культура-агарту эшләре фәнни-методик үзәге халык уен кораллары, бию коллективлары, дискотека, агитбригада җитәкчеләренең, үзешчән рәссамнар һәм киносөючеләр семинарларын үткәрде. Үзешчәннәр эшләгән кинофильмнарга һәм дискотека программаларына конкурслар оештырылды. Кыскасы, смотр көннән-көн киңрәк колач җәя. Ул үзешчән сәнгатьнең тагын да массовыйрак булып үсүенә, репертуарның иң яхшы әсәрләр белән баюына, анда катнашучыларның башкару осталыгын күтәрергә ярдәм итә. Смотр Максим Горькийның халык иҗатында чиксез байлык ятуы турында әйткән сүзләрен торган саен ныграк раслый. Үзешчән сәнгатьнең II Бөтенсоюз фестивале формасы белән милли, эчтәлеге белән социалистик булган совет культурасының зур тантанасына әверелде. Халык иҗаты чишмәсе мәңге саекмыйча, тирә-юньгә сафлык һәм гүзәллек өстәп, зур дәрт белән ургып торуын дәвам иттерә. Ул меңнәрчә, миллионнарча күңелләрне үзенең тылсымлы шифасы белән нурландыра, аларны партиябез билгеләгән җитди бурычларны, олы планнарны уңышлы тормышка ашыруга рухландыра.

## Мәрди Рафиков

# ИЛ КЫЗЛАРЫ

Вакыт. Еллар... Галина Петровнага әле кайчан гына унсигез иде. 1943 ел. Буада медицина училищесын тәмамлады. Күңеле шатлык белән тулган, канатлана, матурдан-матур хыялларга урала, ак халатлы Галяны палатадан-палатага очыртып кына йөртә. Диплом аласы да эшкә генә керешәсе калды.

Ләкин Галяга диплом урынына хәрби комиссариаттан чакыру җибәрделәр. Ашыгыч иде. Юл әйберләрен барларга әнисе булышты. Тегесен китерә, монысын төреп сала. Кызының: «Әни, кирәкми, авыр була»,— дип ялваруына гүя колак та салмый. «Ин, кызым, биштәрең авырлыгыннан курыкма, хәсрәтнең авыры күнмасын җилкәгә»,— ди.

Станциягә өчәү бардылар: бер якта — әнисе, икенче якта — әтисе. Петр Николаевич кызының биштәрен үзенә алган. Күнегәсе юк, теге чакта, Совет дәүләтен аклардан һәм интервентлардан чистартканда, инде мылтык та, бөятләп төрелгән шинель белән биштәр дә йөрткән кеше, элекке сугышчы, көч-куәтендә булса, алтмышның өстенә басмаса, бүгенге эшелон белән үзе дә фронтка китәр иде. Вакыты узган шул, кызын гына озата. Төпчек кызын!

Башкалар да якыннарын, туганнарын озата килгәннәр. Станция мәйданы мыжлап тора. Бер якта тальян моңлана. Фронтка җыенучы кешеләр туганнарының, дус-ишләренең кадерле теләкләре белән бергә туган якның тальян моңын да алып китәләр.

Вагоннарга утырырга фәрман бирделәр. Галя да әти-әнисе белән саубуллашты, станциядә күренгән танышларына кул изәде. Әнисен тагын бер кат кочаклап кысты, әтисенең тирән җыерчыклы битеннән үпте, аннары, биштәрен кулына алып, вагонга таба атлады. Ата белән ана басып калдылар: «Хәерле юлга, кызым, исән-сау каршыларга насыйп булсын!»

Мария Ивановнаның күзләре яшьләнмәде. Хатын-кызның табигате шундый, ул шатлыкны да, хәсрәтне дә күз яше белән белдерүчән. Алай җиңелрәк. Ләкин чишмә суы да артык түгел, күз яшенең дә исәбе бар, бетмәс димә! Ә Мария Ивановна — саубуллашуларны, хәтта хушлашуларны күп күргән ана, һәркайсы күз яшен сыккандыр.

Ана сигез бала биләде. Сигезе дә кыз иде. Бәхетемдер дисә, өчесенең гомере кыска булды. Кайнар күз яше белән кичерде Мария Ивановна бу хәсрәтләрне. Башка кызлары сылу булып, таза булып, күңелне сөендереп үстеләр. Зоя медицина институтын тәгәлләде. Елена педагог белеме алды. Тамара урман институтында укыды. Кызларының башкалары да тыныч тормышта колачлап эшләргә әзерләнделәр. Ләкин көтелмәгән вакыйгалар кайчак бөтен хыялларны җимерә. Ә фашист гаскәрләренең Совет иленә басып керүләре бигрәк тә авыр хәбәр иде. Бу Буа шәһәрендә яшәүче Быковлар гаиләсенә дә ачы җил булып үтте. Врач кызларын — Зоя Петровнаны ашыгыч рәвештә хәрби хезмәткә чакырдылар. Ил дошманга каршы күтәрелгәндә, врачлар күп кирәк иде, әлбәттә. Чөнки сугыш ярасыз булмый, ә җәрәхәтләнгән сугышчы фронтка яңадан врач ярдәмендә генә кайта ала. Бу хәлне Петр Николаевич та, Мария Ивановна да яхшы беләләр, шуңа күрә кызларының ир-егетләр белән бергә Ватан азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен көрәшкә китүенә гадәти нәрсә итеп карыйлар, аңа иң изге теләкләрен белдерәләр иде.

Зояны Быковлар бергәләп озаттылар. Кызлар да өйдә иде. Иң кечкенә Галя апасына бигрәк тә кызыгып карады: «Их, аның урынында булса икән бүген! Быковларның дошманга булган бөтен нәфрәтен үзе белән алып китәр һәм илбасарларга чын-чынлап утлы сабак бирер кебек иде. Тик ул әле училищеда гына укый, ул әле яшь. Әмма аның да көне килер». Саубуллашу минутларында кызлар барысы да шулай уйлаганнардыр. Алар, апаларын озаткач, бергәләп әниләрен юатырга керештеләр. Мария Ивановна ул чагында күз яшенә ирек бирде. Фронтка киткән кызы өчен тирән борчылу, янындагылар өчен шатлану икесе бергә булгандыр.

Озак көттермичә Зоядан өчпочмаклы хат килде. Хәрби врач, кыр госпиталенең хирургы икән. Димәк, туп гөрселдәүләрен, бомбалар сызгыруын ишетеп эшли, димәк, иң авыр яралыларның тормышын саклап кала. Вакытлыча сафтан чыккан яралыларны, беренче мөмкинлек булу белән, тылга җибәрәләр, аларны Елена Быкова кебек санитар кызлар озата бара. Бу батыр кызлар яралыларны Кызыл Хач җәмгыятенең билгесе төшерелгән вагоннарга кабул иткәндә иминлекләрен сакларга ант итәләр, дошман самолетлары эшелонны бомбага тотканда да авыр яралы кызылармеецларны тынычландырырга тырышалар. Кайчагында үз гомерләрен куркыныч астына куярга туры килә.

Санитар поездларда шәфкать туташы хезмәтен үтәүче кызыл армеец Елена Петровна Быковлар гаиләсендә икенче кыз иде. Апасыннан соң озак та тормады, хәрби комиссариаттан чакыру килде. Педагог кыз шинель киярга тиеш иде. Быковлар Еленаны җыелу пунктына гаилә белән озата бардылар. Өч сеңлесе дә монда иде. Юл буе сөйләшеп туймадылар. Апалары хат язып торырга булды. Аннары эти-әниләрен тыңладылар. Мария Ивановна аналарга хас сабырлык белән әйтте теләген: «Исән бул, кызым, бурычыңны үтәп кайт. Бергә-бергә каршыларга насыйп булсын!»

Мария Ивановна өченче кызына да чакыру киләчәген сизми иде әле. Анысы да тиз беленде. Урман белгече исемен алган Тамара Петровна фронтка китәргә әзерләнде. Биштәре сеңелләре ярдәме һәм әнисе күзәтүе астында тутырылды. Юл өчен иң кирәген салдылар: кашык, кружка, энә-җеп, сөлге... «Ярар,— диде Тамара, сеңелләренә күз кысып,— бөтенләй тутырмыйк. Патрон салырлык урын калсын».

Әти-әнисе, ике сеңлесе Тамара Петровна белән станциядә саубуллаштылар. Поезд кузгалганчы сүзләре бетмәде. Тамара хатны бик тиз язарга вәгъдә итте. Ә кайдан язар?— әлегә билгесез иде. Фронт зур, аның һәр җирендә дошман белән канлы бәрелеш бара. Урманчыга да урман утыртырга кушмаслар. Кулында — мылтык, биштәрендә патрон, граната булыр.

Тамара Петровнаны зенитчылар сафына куйдылар. Мария Ивановна, кыр почтасыннан килгән хатны укыгач, уйга калды. Йөзендә үз баласы өчен тирән борчылу галәмәтләре иде. Җирне урманнар белән бизәргә яраткан, якты кояшны күреп туймаган яшь кыз — аның Тамарасы сөремле күкне күзәтә, җир өстенә үлем чәчүче дошман самолетларын эзли, шул хәшәрәтләргә туптан ата. Әй язмыш, шинель кидертеп, кыз балага нинди сынаулар биргәнсең! Калтыранып, куркып кына калмасын, җиңәргә язсын!

Өйдә Петр Николаевич эштән кайтканын зарыгып көтәләр. Ул гражданнар сугышыннан соң элемтәче булып киткән иде. Гади элемтәче. Телефон чыбыклары суздылар, шул линия аша кешеләрне сөйләштерделәр. Аннары Петр Быков мастер булды. Аның инде махсус урта белеме дә бар иде. Бөек Ватан сугышы башланганда Петр Николаевич — почта начальнигы. Ул Буа район элемтәсенә җитәкчелек итә иде. Эше бик киеренке, бик тыгыз булса да, армиядәге кызларыннан килгән хатлар турында онытмый, үзе белән ала кайта. Өйдәгеләр шуны зарыгып көтәләр.

Бер көнне Петр Николаевич дүртенче кызы Людмилага чакыру кәгазе алып кайтты. Ата-ананың хәленә төшенгән кеше дөрес аңлар: рәттән дүрт кыз баланы фронтка озату, алар өчен борчылып яшәү ансат түгел. Буй җиткезгәннәр, сылулар, кияү көтәр чаклары бит, юк, туй күлмәге урынына, кызлары шинель кияләр дә утлы фронт юлына чыгалар. Илнең азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен барган авыр сугыш, дошманны тизрәк кырып бетерү өчен барган сынаулы көрәш шуны таләп итә.

Людмила Петровна өчен дә юл хәстәрен тиз күрделәр. Фронтка китүчеләрнең җыелу урынына барыр вакыт якынлашты. Борынгы гадәт буенча, юлга кузгалыр алдыннан беравык өйдә тын утырдылар. «Хәерле сәгатьтә!»— диде аннары Петр Николаевич. Кузгалдылар. Людмиланың биштәрен Галя алды. Станциягә кадәр сөйләшмичә бардылар. Әйтерсең лә, сүзләре беткән иде. Ә поездга утырганда кочаклашып саубуллаштылар. «Ярар, әни,— диде Людмила,— бездән генә калмаган. Ил белән!»— диде. Ул китте, Быковлар өйләренә өчәү генә кайттылар. Людмиладан да өчпочмаклы хат килеп төште. Хәрби киемнәр алуы турында яза. Оборона заводларын саклаучы частька билгеләгәннәр. Конвертта кыр почтасы штемпеле булса да, фронттан ерактарак икән Людмила. Кирәк тапсалар, хәрәкәттәге армиягә дә җибәрерләр. Хат тыныч язылса да, ата-ана балалары турында кайгыртмый булдыра алмый.

Әни кеше өчен бигрәк тә авыр сынау вакыты иде бу. Беренче бала — ананың соңгы курчагы, ә төпчеге аның иң кадерле юанычы, диләр. Гомер кичергән ата-ана гадәттә шул төпчеккә сыена, аның янында, аның җылысы белән яшәргә омтыла. Галя Быковлар гаиләсендә бишенче, төпчек кыз иде. Поезд кузгалды, ул үзе белән фронтка шушы төпчек кызны да алып китте. Ирле-хатынлы Быковлар эшелон күздән югалганчы карап тордылар. Бу юлы өйгә, Буа шәһәренең Роза Люксембург урамындагы 18 нче йортка алар икәү генә кайттылар. Хәзер шинель кигән биш кызның бишесеннән хат көтеп, исәнлекләрен белеп юанасы гына калды.

* * *

Вакыт. Еллар... Алкын судай акканнар. Вакыт сугышка унсигездә керүчеләрнең дә чәчләренә чал яккан, битләренә тирән-тирән җыерчыклар сызган. Ләкин солдатлар картаймыйлар. Хатирәләре картаерга юл куймый.

1984 нең язы. Галина Петровна Журавлева белән аның Буа шәһәрендәге квартирасында сөйләшеп утырабыз. Быковларның бу төпчек кызлары да хезмәт юлын тәгаллап тыныч кына ялга чыккан инде. Шуңа кадәр шәһәр больницасында медсестра булган.

— Теге чакта,— ди Галина Петровна, сугыш елларына кайтып,— безне Казанда оешкан кыр госпитале составында турыдан-туры фронт сызыгына җибәрделәр. Кызыл Армия бөтен фронт буйлап һөҗүмгә күчкән иде инде. Сугыш дәһшәте белән Белоруссиянең Гомель шәһәрендә очраштык...

Госпитальгә Гомель шәһәрендә эшелоннан төшәргә һәм, төн караңгылыгыннан файдаланып, фронт сызыгыннан өч чакрымдагы урманга урнашырга боерык бирелә. Медицина җиһазларын машиналарга төйи башлаганда, дошман самолетлары килеп чыга. Алар станцияне бомбага тотарга, эшелоннарны юк итәргә ниятлиләр. Зениткалар ут ача, өермә куба. Унсигез яшьлек медсестра Галина Быкова беренче яралыларны шунда күрә, сугышчан иптәшләрен югалту ачысын шунда татый.

Кыр госпитале хәрәкәттәге частьлар белән янәшәдәге землянкаларга, сарайларга урнаша. Яралыларны сугыш кырыннан ук кабул итәргә, операцияләрне тирә-якта снарядлар ярылганда, баш өстендә бомбалар сызгырганда ясарга, врачларның, санитарларның үзләренең дә эш өстендә һәлак булуларын күрергә туры килә. Ләкин сугышта зарланмыйлар, арымыйлар, анда аяусызлык белән көрәшәләр генә. Галя да шуңа өйрәнә. Кыр госпитале кайчак азат ителгән шәһәрләргә урнаштырыла. Госпиталь бинасының түбәсенә Кызыл Хач җәмгыятенең билгесе куела. Ләкин фашистлар ул йортларны да еш кына бомбага тоталар. Андый вәхшилек беркайчан да онытылмый. Галина Петровна бу вакыйгаларны сугыш уты кабызучыларга нәфрәт белән искә ала.

Санитар кыз Совет гаскәрләре составында Польша җирен азат итүдә катнаша. Аннары котырган дошманның үз өненә барып чыгалар.

— Берлинны штурмлау башланганда безнең кыр госпитале Кюстринда иде,— ди Галина Петровна.— Без, мондагы яралыларны кабул иткәндә, үзебезне Берлинны штурмлаучы алдынгы частьлар составында сиздек...

Быковларның төпчек кызы, хәрби санитар Галина Петровна, Берлинда да йөри, солдатларча горур басып Җиңү байрагына честь бирә, җиңү шатлыкларының шаһиты була һәм ГДРда 1951 елга кадәр хезмәт итә ул.

Галина Петровна беразга тынып калды, тагын ни әйтим дигән сыман, миңа тутырып карады, чал керә башлаган коңгырт чәчләрен ике кулы белән сыпырып-төзәтеп куйды, аннары капылт торып түр тәрәзәсе буендагы шкаф янына китте һәм аннан бер кочак альбом китерде. Иң кадерле нәрсәсен эзләгәндәй, ашыга-ашыга актарып бер рәсем алды.

— Бу — без, уртада — әни.— Галина Петровна күрсәтеп куйды.— Соңгы рәсемебез.

Буа шәһәре биш солдат анасы, егерме ел буе балалар бакчасында сабыйлар тәрбияләгән олы җанлы Мария Ивановна белән мәңгегә хушлашкан. Буалылар Быковларга хөрмәт йөзеннән алар яшәгән йортка истәлек тактасы кую мәсьәләсен күтәрделәр. Халык киң күңелле, илгә намуслы хезмәт итүчеләрне ярата һәм хөрмәт итә.

Биш солдат атасы Петр Николаевич та якты дөньяда юк икән инде. Кызларын берәм-берәм көтеп алган, бергәләп шатланганнар. Фронт хәлләрен сорашкан. Тыныч тормышта да бераз яшәгәч, дөнья куйган.

Бертуган кызлар төп нигезгә ел саен җыела торган булганнар. Ә бер елны Бөек Ватан сугышында күп афәтләр күргән элекке хәрби врач Зоя Петровна Душинская туганнары белән очрашуга кайтмаган. Аның Днепропетровск шәһәрендә авыру баланы коткарып үзенең һәлак булуы турында хәбәр килгән. Быковларның өлкән кызлары соңгы сулышына кадәр үз һөнәренә тугры калган.

Коммунист Елена Петровна Быкова сугыштан соң Мәскәү шәһәренә урнаша, әнисе кебек, балалар бакчасында тәрбияче һәм мөдир булып эшли. Педагог район Советына депутатлыкка сайланып халыкның ихтирамын казана.

Быковлар кызларын тыныч көннәрдә хезмәт итү өчен укытканнар иде бит. Кызларның үз хыяллары да шундый иде. Үз һөнәрләренең ләззәтен сугыш елларын кичергәч кенә татый алдылар. Тамара Петровна Гультаева Ленинградта урман инженеры булып эшли. Сугыш елларында күп михнәтләр күргән шәһәр тирәләрен яшелләндерүгә ул зур хезмәт куя. Людмила Петровна Храмушкина исә сеңлесе Галина Петровна белән бергә Буаның үзәк больницасында эшли.

Гомерләрен намуслы хезмәттә үткәргән Мария Ивановна һәм Петр Николаевич Быковлар үзләренә тиң балалар үстергәннәр. Гаиләдә Ватанга кыенлык килгәндә арысландай егетләр белән бер сафка басарлык, халык хуҗалыгы планнарын тормышка ашырганда, хезмәт батырлары белән бер рәттә торырлык ил кызлары тәрбияләнгән.

## Фәүзия Бәйрәмова

# АК ТӨННӘР ИЛЕНДӘ

Карелия турында мин иң беренче тапкыр, мөгаен, әтидән ишеткәнмендер. 1940 елның кышында әти шушы якларда ак финнәр белән бәрелешләрдә катнаша, яралана, гарипләнеп, авылга кайта. Карелия аның балалары — безнең күңелгә дә салкын кар иле, шом, дәһшәт иле булып кереп кала...

Мәктәп елларында инде Карелия урманнар, күлләр иле булып ачылды. Серле иде бу ил, ерак иде, картага карасаң, Ак диңгез буйларына, Финляндия урманнарына хәтле барып җитә аның чикләре. Аннан бирерәк — Ленинград, Ладога, Онега күлләре. Ак төннәр, иксез-чиксез урманнар һәм бозлык чорыннан калган, Карелиянең бөтен мәйданы буйлап сибелгән эреле-ваклы ташлар, ташлар...

Кызыксынуым мәктәп программасына гына сыймый башлагач, Карелия миңа үзенең сәнгате, архитектура ансамбльләре, искиткеч музейлары белән ачылды. Ләкин боларның барысы да укып, телевизордан карап, ишетеп кенә җыйган мәгълүмат иде, һәм мин инде аннан гына канәгать түгел идем. Бик еракта тын гына үзенә тартып, хәтернең бер почмагында урманнары белән моңлы гына гөжләп торган бу дөньяны мин инде үз күзләрем белән күрергә тиеш идем. Һәм беркөнне мин Казанның җылы җәйләреннән Төньяк Карелиянең салкын көзләренә таба киттем.

Инде Ленинград та артта калды, ә поезд һаман югарыга — төньякка таба үрмәли. «Арктика» дип аталган, тәрәзә пәрдәләренә ак аю сурәтләре төшерелгән бу тиз йөрешле поезд Мурманскига бара. Менә Карелиянең башкаласы Петрозаводск та төнге урман уртасына төшеп чумгандай күздән югалды, инде икенче поездга да күчеп утырдык, ә барасы юл әле шактый. Төнлә чик буе постларын үтәбез (мин бара торган шәһәр Финляндия чигенә үк урнашкан). Яктыргач та поезд тәрәзәсеннән күзгә ташланган беренче күренеш — урман да таш, урман да таш. Томан арасыннан уяныр-уянмас кына күлләр карап кала. Бөтен җирдә инде көз, әллә нинди горур, салкын көз. Ыгы-зыгыларга да, кемнәрнеңдер килеп-китүенә дә битараф, меңнәрчә күлләре, урманнары артына сыенган Карелия көзе, Карелия җире. Нигәдер куркып кына, хакым юк кеше кебек кенә аңа аяк басам. Ташларның әкрен генә шыгырдап куюларын ишетәм. «Тагы кем килде?» — диләрме икән?

Поездан төшкән кешеләрне күзәтәм. Бирегә хәзер күп киләләр. Мин яңа гына аяк баскан бу шәһәр Костомукша дип атала. Аны төзүгә Финляндия белгечләре дә катнаша. Шәһәр әле бик яшь. Бу тирәдә тимер рудасының бай катламнары ятуы беленгәч, 1974 елда бирегә тау-баету комбинаты төзелә башлый. 1983 елда Костомукша комсомолның Бөтенсоюз удар төзелеше дип игълан ителә. Шәһәр турында белгәннәрем әлегә әнә шулар. Кемнәрне очратырмын мин биредә? Костомукша, Карелия дигәндә, кемнәрнең сурәтләре еллар үткәч тә хәтердә кабыныр?

Шәһәр урман эченә урнашкан. Тәрәзә алларында горур чыршылар чайкала. Кытыршы кәүсәле каеннар йортлардан бераз читтәрәк, аерымрак утыралар. Ничек үссә, шулай калган. Йортлар, урамнар исә табигатькә җайлап салынган кебек. Газоннарда, купшы чәчәкләр урынына — урман туфрагы, урман үсемлекләре. Кая карама — эреле-ваклы ташлар, ташлар... Йортлар янынннан ук зәп-зәңгәр сулы Қонтокки күле башлана. Аның аргы ягында — урман. Күлдә бары тик ишкәкле көймәләр генә күренә. Димәк, шәһәр өчен бу күлнең мәңге шулай чиста булып калуы бик мөһим.

Кешеләрне күзәтәм. Яшьләр, чибәрләр. Эшлекле, тәвәккәл кыяфәт. Эленкесалынкы йөрүчеләр күренми. Бирегә барысы да эшләргә дип килгәннәр. Шәһәр төзергә. Руда чыгарырга. Руда эшкәртергә. Яшәргә. Балалар бик күп. Икешәр, өчәр бала җитәкләгән ана — биредә гадәти күренеш. Агачлар арасыннан балалар бакчалары

күренеп кала. Сорашып беләм: өч урта мәктәп тә бар икән, төзүчеләр дүртенчесен өлгертеп киләләр. 5 нче профессиональ-техник училище комбинат өчен кадрлар әзерли. Мәктәпне тәмамлаучыларның күбесе әнә шул училищега, аннан соң әти-әниләре янына комбинатка эшкә киләләр. Хәзергә шәһәрдә югары уку йортлары юк. Югары белем алырга теләүчеләр Костомукшаның үзендә үк Төньяк-Көнбатыш политехника институтының читтән торып уку бүлегенә имтихан тапшыра алалар. Киләчәктә Костомукшада тау эшләре һәм политехника институтларының филиалларын ачу күздә тотыла.

Җыйнаклыгы, ак, кызыл, кара төсләрдән генә торган төзелеш панорамасы, чисталыгы, табигатькә якынлыгы белән шәһәр искиткеч матур тәэсир калдыра. Аның үзәгендә — тау-баету комбинаты. Комбинат эшчәнлеге белән танышмыйча, биредә җитештерелгән руда шарчыкларын күрмичә, Костомукшаның илебез экономикасы үсешенә керткән өлешен дөрес бәяләп булмас иде.

Партиянең Костомукша шәһәр комитетында агитация һәм пропаганда бүлеге мөдире Шибанов Михаил Федорович белән шәһәр, аның киләчәге турында сөйләшәбез. Сүзебез һаман комбинатка килеп тоташа. Михаил Федоровичтан комбинат белән танышуда ярдәм итүен үтенәм. Костомукшада чыга торган «Горняк Карелии» газетасы белән элемтәгә керәбез. Редакция хезмәткәрләренең үзләренең дә комбинатка барып чыгасылары бар икән, икенче көнне иртән редакциядә очрашырга килешеп, көне буе комбинатта йөрүне планлаштырабыз. Михаил Федорович комбинатның парткомына шалтыратып, безнең киләсен хәбәр итеп куя. Чөнки комбинат белән кызыксыну көчле, үзәк матбугат та һәрвакыт бу төзелешне игътибарда тота, телевидение, кино студияләре операторлары да биредә еш булалар. Чит ил журналистлары, шул исәптән Финляндия, Германия Демократик Республикасы, Германия Федератив Республикасы, Венгрия, Польша, Голландия, Аргентинадан биредә язучы-журналистлар булып китканнәр, шәһәр, комбинат белән танышканнар.

Комбинат карьердан башлана икән. Менә бу урыннарда әле кайчан гына йөз яшьлек наратлар шаулап үскән, җитез боланнар йөгереп үткән, көзләрендә җир өстен нарат җиләге, күк җиләк каплап киткән. Хәзер исә урман, үз биләмәләрен кешеләргә калдырып, ераккарак чигенгән. Бу урында руда чыгарыла. Аста, җир куенына уелып кергән урында, йөзләгән йөк машиналары, экскаваторлар кайный. Парткабинет мөдире Вера Ивановна Кожевникова биредә еш була ахры, аның йөзендә җитдилек, исәп, план. Миндә — шаккату, соклану, югалып калу. Йөзләрчә тонна йөк сыйдырышлы «Белаз»лар янында безнең «Волга» уенчык кебек кенә күренә. Алар әкрен генә гүләп, руда төяп карьердан күтәреләләр дә эшкәртү цехлары ягына таба китеп баралар. Ара әллә ни ерак түгел: карьер да, цехлар да, автохуҗалык та бер тирәгә урнашкан. Бу исә эшне зур оешканлык, югалтуларсыз алып баруга ярдәм итә.

Комбинатның үзәге — ваклату цехлары. Алар биредә өчәү. Руда «Белаз»лардан вагоннарга бушатыла, аннан ваклату цехларына кереп, порошок хәленә әйләнеп чыга. Шул порошоктан шарчыклар ясыйлар. Илебезнең металлургия комбинатларына шул шарчыклар озатыла. Комбинат үзенең беренче концентратын 1982 елның июнендә биргән. Шушы дәвердә монда биш миллион тоннадан артык шарчык чыгарылган. Комбинат белән бергә кешеләр дә үскән.

Костомукша ул — буш урында, тайгада салынган шәһәр. Халкы — бөтен Советлар Союзыннан җыелган белгечләр. Биредә 29 милләт вәкиле яши. Шәһәр һәм комбинат төзелешендә 200 төрле һөнәр иясе катнаша. Якташларым — Татарстаннан килгән белгечләр белән кызыксынам: Р. Сафин, Г. Фәйзуллин, Р. Шәйдуллин, В. Долматов, Ф. Гафиятуллин, А. Попов, Р. Вәлиев... Горурланып куям. Начар яктан искә алмадылар бит. Читтә, еракта, бер кеше дә бөтен милләтенең горурлыгы була ала. Һәм йөзен дә кызартырга мөмкин. Биредә якташларымны бары мактап кына телгә алдылар. Комбинат буйлап йөрергә җиңел булып китте.

Комбинат белән бергә шәһәр дә үсә, зурая. Хәзер биредә инде шактый кеше яши. Әлбәттә, төзүчеләрнең эшләрендә әле шактый гына тоткарлыклар, авырлыклар бар икән. Мин моны «Костомукшастрой» төзү трестының ачык партия җыелышында бигрәк тә нык тойдым. Коммунистлар төзелештәге җитешсезлекләр турында борчылып сөйләделәр. Измәдән кала, бөтен төзү материаллары бирегә ерактан, илнең үзәгеннән китерелә. Материаль база юк дәрәҗәсендә. Яңа килеп төшкән төзүчеләр өчен яшәү шартлары да бик үк яхшыдан түгел. Шуңа күрәдер, төзелештәге кадрлар еш алмашына. Татарстаннан килгән кайбер белгечләр белән дә шулайрак булган. Кире кайтып китү очраклары да бар. Ә менә ике татар егетенең шушы кыен шартларда да тыйнак, тырыш хезмәтләре күпләрне сокландыра. Ул егетләрне мин берничә тапкыр күрдем, сөйләшеп тордым, Казан хәлләрен сөйләдем, илгә сәламнәрен алып кайттым. Егетләрнең берсе — Урал Шәмсиев. Ул Казанның 3 нче строймеханизация трестында кранчы булган. Монда да кранда эшли. Уралның әти-әнисе Зеленодольск районы Ту-

гай авылында яшн икән. Сүз күбрәк шулар турында барды. Туган яктан ничек кенә ерак китмә, якташыңны күрү белән, аны туганыңдай якын итәсең, аның белән өй хәлләрен, авыл хәлләрен сөйләшәсе килә башлый. Уралның әнисе Мәлика апа белән әтисе Тәфкил абый исеме ул көнне ерак Карелия җирендә кат-кат сагынып телгә алынды.

Актаныш егете Альберт Әхмәтов та кранда эшли. Ике дус Казаннан да бергә килгәннәр, эшләүләре, яшәүләре дә бергә. Карелия җирендә үзләреннән соң матур истәлекләр, биек-биек йортлар калдырып, исән-сау килеш егетләр Казанга да бергә кайтып кererләр әле. Эшләүләре, яшәүләре еракта булса да, телләрендә һаман Казан бит! Туган җир бит...

Туган җир... Еракта, Идел буенда калган Казан искә төшә. Монда, урман эчендә, инде көзге җилләр хакимлек итә, иртәнге якта нарат җиләкләре өстендә ап-ак бәс җемелди. Безнең Татарстанда исә әле урак та тәмамланмагандыр, сап-сары кырлар өстеннән йомшак җилләр исәдер, алар бөтен дөньяга алма исе тараталардыр. Якшәмбе көннәрендә, кичләрен, авылга ялга кайткан яшьләрне поездлар, самолетлар, машиналар тагы эш урыннарына — зур төзелешләргә алып китәләрдер. Татарстан — гигант төзелешләр мәйданы. Кама буйлары моңарчы күрелмәгән зур төзелешләрдән гөләп тора. Бәлки, Карелиядә табылган металл рудасы да Кама автомобиль заводыннан куәтле йөк машинасына әйләнеп чыгадыр. Рус, татар, украин, башкорт, карел — бөтен совет халкы бүген Кама буе пейзажына да шәһәр һәм завод сурәтләре өстиләр. Инде Алабуга шәһәре янында Кама трактор заводы салына башлады. Ул да шулай бөтен ил ярдәме белән күтәрелер һәм якын киләчәктә илгә куәтле тракторлар бирер! Ә шул төзелешләр өстендә Кама Аланы шәһәре белән бергә күтәрелеп чыккан атом электр станциясе утлары балкыр! Һәм кыр уртасында калалар салып калдырган бу кыю, хыялга бай кешеләр турында җырлар чыгар, истәлекләр язылыр, алар рәхмәт белән искә алыныр...

Еракта яңгыраган көчле шартлау тавышы уйларымны бүлдерә. Костомукшада мин бу шартлауларга ияләнеп барам инде. Алдан сигнал рәвешендә бирелгән яшелле-зәңгәрле ракеталарны күреп тә сискәнмим. Карьерда шулай шартлату эшләре алып баралар. Бу урман-күлләрнең, шул тирә авылларда яшәүче карт-карчыкларның күптән инде моңдый шартлауларны, шау-шуны ишеткәннәре булмагандыр. Ә кайчандыр зур юл өстендә утырган Костомукша авылында шартлау-януларның ниндиләре генә булмаган да, бәла-казаларның ниндиләре генә килеп кагылмаган аңа!

Костомукша урынында да кайчандыр карел авылы булган. Россиягә төньяктан кем генә басып керсә дә, юл бары тик Костомукша авылы аша гына үтә икән. XVIII гасырда шведлар бу авылны яндырып, җир белән тигезләп киткәннәр. Гражданнар сугышы елларында да авыл кулдан-кулга күчеп йөргән. Бөек Ватан сугышы елларында исә Костомукша соңгы тапкыр яндырылган һәм инде яңадан терәкләнеп китә алмаган. Янындагы Контокки авылында әле тормыш барган, ә Костомукшага ул яңадан дистәләгән еллардан соң гына әйләнеп кайткан. Инде шәһәр булып, комбинат булып, төрле милләт вәкилләре булып әйләнеп кайткан. Һәм Калевала районы кареллары да әкренләп шушы шәһәргә җыела башлаганнар. Шундыйларның берсе — язучы Павел Романович Леонтьев. Аның турында редакциядә дә, партиянең шәһәр комитетында да, комбинатта да күп ишетергә туры килде. Ул биредә үзенең тарихи язмалары белән танылган. Павел Романовичның «Вяйнола юллары буйлап» дигән тарихи-этнографик очеркларын минем үземә дә укырга туры килде. Бу язма карел-фин халкының данлыклы «Калевала» эпосының язып алынуына 150 ел тулуга багышланган булса да, ул әле тагы бик күп нәрсәләрне яктырта. Бу язмада карел халкының сабыр холкы, зирәк акылы зур итеп, горурлык белән тасвирланган. Автор балык тоту, җир эшкәртү, аучылык кебек хезмәтләргә җентекләп тукталган. Шул авыр эш арасында билгеләп үтелгән борынгы бәйрәмнәр искә алынган.

Әнә шул язмаларны укып чыккач, миндә Павел Романовичның үзе белән очрашып, бер сөйләшеп утыру теләге туды. Язганнарын укып, мин аны төрлечә күз алдына китергән идем. Үзен күреп сөйләшкәч, хәтердә аның акыллы, моңлы күзләре торып калды. Һәм язмалары. Һәм планнары. Һәм борчылулары. Казаннан декоратив сәнгать турында китап алып барган идем. Павел Романович аны бик игътибар белән карап чыкты, киемнәрдәге һәр чигешне, тәрәзә, капка-коймалардагы һәр бизәкне җентекләп тикшерде. Бигрәк тә аны агачтан сырлап, кисеп эшләнгән бизәкләр кызыксындырды. Аннан үзе дә миңа карел халкының декоратив сәнгате буенча альбомнар күрсәтте. Һәм ни гаҗәп, безнең Казан арты йортларындагы бизәкләр белән ерак карел авыллары йортларының бизәкләрендә бик күп уртак яклар бар. Ерак тарихка мөрәҗәгать итсәк, анда бу сорауга да җавап табарга була. Фин-угор халыклары бу тирәләргә ерак Урал, Идел буйларыннан күчеп киләләр. Үзләре белән туган телләрен, гадәтләрен, һөнәрләрен, җырларын, бәйрәмнәрен алып киләләр. Идел буйларыннан килгән марилар, удмуртлар,

мукшы-эрзяларда да бу гадәтләр, бу бәйрәмнәр, бу һөнәрләр күренеп-күренеп китә. Татарстан территориясендә дә җирле фин-угор кабиләләре яшәгәнлеге билгеле. Бизәкләрдәге уртаклыклар да бәлки әнә шул хакта сөйлидер? «Калевала» эпосында имән агачы бик еш телгә алына, ләкин ул Төньяк Карелиядә бөтенләй үсми. Дәваларның да дәвасы булган бал турында да (эпоста ул хакта да сүз күп) шуны ук әйтергә мөмкин. Күз карашы җитмәс иген кырлары, сабан тургайлары да биредә юк. Ә эпос нәкъ әнә шуларның гүзәллекләрен тасвирлауларга искиткеч бай. Бәлки, халкы белән бергә, кайбер шигъри юллар да Төньяк Карелиягә Идел, Урал буйларыннан күчкәннәрдер? Ерак Карелиядә Идел дип аталган кечкенә генә шәһәрнең булуы да минем өчен ачылмаган сер булып калды.

Әнә шундый уйлар белән Костомукша шәһәренең музеена юнәләм. Ул әлегә кечкенә генә шәһәр кинотеатрының чардагына урнашкан. Ләкин Карелия турында, карел халкы турында бу музейдан да күп нәрсә алырга була. Бер почмактан карел халкының үткәне тын гына карап тора. Гади генә тоелган, ләкин йөз еллар буе кешегә тугрылыклы хезмәт итеп килгән аучылык һәм балыкчылык кораллары. Ак киндергә чәчәкләп тә, шакмаклап та чигелгән хатын-кыз киемнәре. Агачтан кырып, шомартып ясалган табак-савыт. Гомер буе җеп эрләп тә, кояшлы бизәкләрен җуймаган кабалар. Минем зиһенемә аша тын гына шуып, алар тагы үз дөньяларына — үткәннәргә китеп югалалар.

Түрдә — икенче Карелия, яңа Карелия. Менә Карелия Хезмәт Коммунасы оештыру буенча 1920 елда В. И. Ленин үзе кул куйган карар. Менә Совет Карелиясе тарихында якты эз калдырган ленинчы-революционерларның рәсемнәре — С. М. Киров, А. В. Куусинен, А. В. Шотман. Менә илебезнең төньяк чикләрендә Карелия партизаннары күрсәткән батырлыклар турында язмалар, документлар, рәсемнәр. Пуля үтәли чыккан партбилетлар, мәңгегә салынган каскалар үлем алдыннан язылган хатлар.

Костомукша шәһәренең макетыннан күзне алып булмый. Бер фокуска җыйгач, шәһәр бигрәк тә матур күренә икән. Инде биредә билгеләнгән күп йортлар салынган, шәһәр урман эченә таба үсә. Иске һәм яңа бизәкләре, төрле милләт халкының гореф-гадәтләре, төрле телләре белән, авыр тарихы һәм киләчәккә якты өмете белән шәһәр иртәгесе көнгә атлый.

Карелия җирендә соңгы очрашуым укытучылар коллективы белән булды. Укытучылар да бирегә бөтен Союздан җыелганнар, һәркем үзе белән педагогика өлкәсендә булган иң зур ачышларын, яңалыкларын, уйлануларын алып килгән. Үзәктән ерак шартларда, һәрберсе төрле җирдән җыелган төрле холыклы, төрле милләт балалары белән эшләү өчен өр-яңа алымнар, сабырлык, ныклы әзерлек кирәк. Шәһәрнең чит ил белгечләре белән берлектә төзелүен, капиталистик дәүләт белән чиктәш булуын да истә тотсаң, һәм педагоглардан, һәм идеология хезмәткәрләреннән зур җаваплылык, политик сизгерлек сорала. Бүгенге мәктәпләрдә киләчәктә Костомукшада яшәячәк буын тәрбияләнә. Бу җаваплы, олы, дәвамлы эшне башкаруда яшь шәһәргә ярдәмгә Карелия язучылары да килә. Яакко Ругоев, Антти Тимонен, Николай Лайне, Пекка Перттү, Ортье Степанов әсәрләре белән дә, халык алдында ясаган чыгышлары белән дә әнә шул тәрбия мәсьәләсенә, идеологик проблемаларга зур игътибар бирәләр.

Костомукша карелча — үч алу урыны дигән сүз. Бу аңа тарихтан калган исем. Ләкин Костомукша бүген үзенең икенче тарихын яза. Элекке үч алу урынында — бүген халыкларның дуслык шәһәре, дуслык төзелеше.

Карелия — кар иле. Карелия — урман, күлләр иле, Карелия — дуслык иле. Шул турыда үз илемә дә кайтып сөйлисем килеп китте...

## Тәлгат Галиуллин

# УРТАК ЕЛГА—КАТЛАУЛЫ УЙЛАР...

### АВСТРИЯ РЕСПУБЛИКАСЫНА СӘЯХӘТ

Безнең делегация Европада укытучылар әзерләүгә, аларның белемнәрен күтәрүгә багышланган IX конгресста катнашты һәм илебез тормышында олы бер иҗтимагый-сәяси вакыйга булган мәктәп реформасы турында чыгыш ясады.

Делегация нибары өч кешедән тора иде. Җитәкчебез — РСФСР мәгариф министры урынбасары Дмитрий Михайлович Забродин. Чит җиргә чыгу — аның өчен гадәти күренеш. һәр елны ул берәр илдә булып кайта. Шуңа күрә аның өчен Австриягә бару Казан яисә Алабуга педагогия институтларының хәл-әхвәлләрен белешеп кайту белән бер тирәдер дип уйлаган идем дә, юк, алай түгел икән. Олы гәүдәле, таза һәм мәһабәт сынлы, күпне күргән бу профессор да дулкынлана. Бер генә детальне дә онытмаска, күздән ычкындырмаска тырыша. Җаваплылык хисе карашыннан ук сизелеп тора.

Делегациябезнең икенче әгъзасына — Мәскәүнең В. И. Ленин исемендәге педагогия институтының кафедра мөдире, профессор Борис Александрович Абрамовка исә Австрия күптәннән таныш икән.

Хикмәт аның монда берничә тапкыр командировкада булуында гына түгел. Без барасы илгә, Бөек Ватан сугышы елларында дөньяның иң әшәке төрмәләре исемлегендә калган Маутхаузенга дүрт елдан артык гомерен бирә ул.

Борис Александрович сугыш башланган фаҗигале таңны чик сакчылары сафында Брестта каршы ала. Фашизмның мәкерле иң беренче һөҗүме алар җилкәсенә төшә. Шул бәрелешләрдә каты яраланган, аңын югалткан Борис Александровичны әсир итеп алалар. Беркадәр Брест госпиталендә (түшәмсез калган клуб иданәндә) яткыргач, аларны, хайваннар ташый торган вагоннарга төяп, Австриягә озаталар. Әсирлек елларын искә төшерү авыр, әрнүле. Монда нинди генә кимсетелүләргә, физик җәзалауларга, рухи мыскыллауларга дучар ителми адәм баласы?! Борис Александрович өчен хәлләрне кабат искә төшерү дә бик кыен.

Хәзер Борис Александрович Абрамов — немец теле грамматикасы буенча илнең иң абруйлы галимнәреннән берсе. Алтынчы дистәне ваклый баруына да карамастан, ул гәүдә җыйнаклыгын да, рухи ныклыгын да саклаган. Сабыр, һәр сүзен үлчәп, уйлап кына әйтә. Ул кара-тут йөзен бизәүче мыегын төзәтеп-төзәтеп куя. Тормышның кадерен, тәмен белеп яшәүче икәнлеге әллә каян күренеп-сизелеп тора. Кыскасы, без барасы илгә аның үз мөнәсәбәте бар.

Күрше ил. Дунай елгасы уртак. Миңа үз илебездә дә Дунай буенда йөрергә туры килгән иде. Ул минем күңелдә безнең Идел, Кама, Вятка кебек үк якты елга булып калды. Ә хәзер йөрәктә ниндидер җиңелчә сагыш. Елга шул ук. Әмма аның буена урнашкан илләрнең тормышлары төрле-төрле, кешеләренең дә карашлары үзгә. Елгалар уртаклыгы фикерләр, уйлар бердәмлегенә алып килсә иде дә бит. Гел алай булмый шул.

Минем өчен Австрия гыйбрәтле тарихы, дөнья культурасына керткән казанышлары, атаклы композиторлары белән кызыклы.

Үз чорында Европаның бик күп халыкларын кул астына җыеп, изеп яшәгән дәһшәтле Австро-Венгрия империясе Беренче бөтендөнья сугышында Россиягә каршы коалициядә катнаша. Мәгълүм булганча, җиңелү империянең таркалуына китерә.

1918 елда Австриядә коммунистлар партиясенә дә нигез салына. Әмма демократик үзгәрешләр тирәнгә китә алмый. 1929—1933 елларда бөтен капиталистик илләр башына төшкән экономик кризис Европада, шул исәптән Австриядә дә, фашизмның көчәюенә алып килә.

1938 елда Австрия Германия составына кертелә, янәдән безнең илгә каршы блокка әләгә һәм, мәгълүм булганча, азатлыкка, бәйсезлеккә, гуманизмга каршы кара тәре күтәргән башка басып алучылар белән бергә тар-мар ителә.

Австрия җирендә совет кешеләренең каны күп коела. Бу илдән фашистларны куып чыгарганда, безнең армия утыз меңгә якын кешесен югалта. Маутхаузен төрмәсендә газап чиккән 33 мең кешене дә онытырлык түгел. Күңелдә утлы нәфрәт уятырлык саннар. Ирексездән Сибгат Хәкимнең «Дуга» поэмасындагы мәгълүм юллар искә төшә:

Шунда, кырда уйлар киерелгәндә,
Низам белән сәер, ят теленең
Җәйге төндә ачык яңгыраган
Чит сүзләрен тыңлап яттым мин.

Колакка ят, имаңнарга ул ят.
Нигә ул ят? Серен тап, гайрәт.
Бәрелеп-сугылып йөри кырда сүзләр,
Кабул итми кебек табигать.

Бу — сугышта туган вакытлы хис,
Әй, юләр син, күңел, әй, юләр.
Әйт, кайчаннан бирле сиңа ул чит,
Сиңа ул ят Гете, Гейнелар?

Дөнья Австриянең Бетховен, Брамс, Штраус кебек бөек улларын да белә бит! Без аларның каберләрендә булдык. Һәркайсына чәчәк бәйләмнәре куелган — олы улларына халыкның хөрмәт билгесе.

Сәнгать элек-электән бер-берсенең телен, гореф-гадәтен белмәгән халыклар арасында да үзара аңлашу, аралашу, дуслашу чарасы булып тора, шәхси һәм иҗтимагый явызлыкка каршы чыгучы объектив көчтән санала. Сәнгать кешедә акыллы башлангычны үстерүгә хезмәт итә, күңелләрдә матурлыкка ихтирам тәрбияли.

Австриядә туып үскән, шунда ук иҗат та иткән мәшһүр композиторларның колачлы һәм моңлы, сугышчан һәм тирән музыкасы хәзер дә миллионнарны дулкынландыра, тәэсирләндерә. Алар үз халыкларының рухи дөньясын ачу аша интернациональ киңлекләргә чыгалар.

Вена шәһәренең үзәк паркларының берсенә «вальс короле» Штраус исеме бирелгән. Халык һәр кичне ял итәргә шунда агыла. Еш кына анда Штраус әсәрләре яңгырый. Кешеләр музыка дөньясына чумалар, ләззәт, моң алалар, дөнья матурлыгын гына түгел, хәтта үз күңелләрен дә тирәнрәк аңлый башлыйлар. Музыка төрле илләрдән килгән, төрле телдә сөйләшүче, төрле раса халыкларын бер-берсенә якынлаштыра. Һәм шунда, кай-моң дөньясына чумган кешеләр арасында, гуманизмга ачу тотып, тынычлыкка каршы утлы күсәк күтәреп чыгу турында хыялланып йөрүчеләре дә бардыр, дип уйлыйсың. Бу төшенчәләрне бергә сыйдыруы кыен.

Австриянең чикләре барлык илләр өчен дә диярлек ачык. Политикада битарафлык, олы дәүләтләр арасындагы конфликтларга катнашмау политикасы уздырылса да, экономика, сәүдә өлкәсендә ул капиталистик илләргә, бигрәк тә Германия Федератив Республикасына бәйле. Әйләнеештәге товарларның күп өлеше читтән кертелә. Кечкенә генә кибеттә дә Тайвань белән Гонгконг, Сингапур белән Көньяк Корея әйберләре янәшәсендә Америкада, Англиядә, Франциядә эшләнгән товарлар сатыла. Бәяләрне куйганда төп рольне сыйфаттан бигрәк, продукцияне эшләп чыгарган фирманың, корпорациянең абруе уйный. Ярымкустарь цехларга тамырларын бөтен капиталистик дөньяга сузган Адидас, Мальборо, Ланком, Филиппс, Рэнглер, Сафари кебек берләшмәләр белән ярышуы шактый кыен.

Бәяләрнең бозылган үлчәү шикелле калтыранып, туктаусыз үзгәреп торуы урта хәллеләрне ярлылар рәтенә төшереп, байларны тагын да баета бара.

Чит капиталның экономик йогынтысы, басымы аркасында Австриягә нейтральлеген саклау елдан-ел кыенлаша. НАТО даирәләре, бигрәк тә ФРГ Австрияне политик һәм хәрби авантюралар ятьмәсенә кертергә омтыла.

1984 ел башында уң көчләр илдә ракеталар урнаштыру өчен көрәшләрен активлаштырганнар. Америка хөкүмәте дә Австриягә хәрби-техник һәм материаль ярдәмен кызганмый. Бу яктан, АКШның Австриядәге илчесе Хелен фон Даммның илне НАТО системасына кертү юнәлешендәге тырышлыгын аерыча ассызыклап күрсәтәләр. Илченең кулын президент үзе юнәлтә, диләр. Чөнки алар, әле Рейган Калифорниядә губернатор чакта ук, дус булганнар, Хелен сайлау кампаниясендә дә бик актив эшләгән.

Шул рәвешле, АКШтан авыр танклар, артиллерия, элемтә чараларын сатып алган Австрия Американың хәрби-промышленность комплексына тыгызрак бәйләнә бара. Халыкны куркытуга, яшьләрнең аңын агулауга зур көч куела. Тамчы ташны да тишәр,

ди халык. Бу җәһәттән Австрия матбугатының социалистик дәүләтләргә каршы юнәлтелгән коткысын телгә алырга мөмкин. Мәсәлән, журналист Г. Вайланд «Австрия белән кем идарә итә?» исемле китабында илгә турист булып килгән совет солдатларының Венаны билән алу күренешен сурәтли. Төп идарә нокталарына ирешкән солдатларга танклар төркеме ярдәм итә. Ә илне яклау чаралары, янәсе, юк. Киная ачык.

Кыскасы, агрессив көчләр, ил халкын коммунизм белән куркыту өчен, һичнинди чарадан да чирканмыйлар. Шулай да әлегә барлык илләр белән дә мөнәсәбәтне бер дәрәҗәдәрәк тотарга омтылу — Австрия тормышының төп үзенчәлеге.

Илдә киләчәк турында җитди уйлаучы, борчылучы кешеләр күп. Прогрессив көчләр илнең мөстәкыйльлеген саклау, империализм тегермәне ташлары арасына эләкмәү өчен көрәшә.

Сугышка каршы протест еш кына бик сәер төсләрдә алып барыла. Безгә Вена урамнарында кичләрен төрле чүпрәкләргә төренгән яшь музыкантларны күп күрергә туры килде. Алар төрле телләрдә лозунглар, җырлардан өзекләр кычкыралар, шаугөр киләләр. Ә ял итүчеләр, туристлар, кызык эзләп, бер группадан икенчесенә атлыйлар. Гади ак чүпрәккә төренгән, бер кулына агач таяк, икенчесенә кызыл алма тотып, Вена асфальтыннан яланаяклап атлаган сәер ир дә еш кына тукталыш ясап, җыелган халыкка вәгазь сөйләп ала. Әлбәттә, бу «мөгез чыгару»ларны рәсми властьлар җитди кабул итми. Тамашалары өчен азмы-күпме акча җыюны да күздә тотучы (акчаны иске фуражкага бик чибәр туташ сорап йөри) бу халыкны куып тарату өчен берничә полисмен да җитәр иде. Юк, бирелә мондый чыгышларга, әйдә, юана бирсеннәр, дип кенә карыйлар, баланың ничек юануы мөһим түгел, еламасын гына, янәсе. Әмма урамга яшь коммунистлар, социалистлар, католиклар берләшеп чыкса һәм җәмгыять алдында җитди таләпләр күтәрсәләр, җитәкче әһелләр нык кына борчыла башлыйлар.

* * *

Безнең делегация катнашкан конгресс Югары Австриянең башкаласы Линц шәһәрендә барды.

Вена белән вакытлыча саубуллашып, йомшак урынлы, җайлы вагоннарда сәяхәткә чыгып киттек. Күзгә сабыр табигать. Вак куаклар белән капланган калкулыклар арасындагы тигезлекләргә бодай, кукуруз, чөгендер чәчелгән. Бер-ике катлы таш йортлар тезелеп киткән. Тау итәкләрендә — чиркәү һәм монастырьлар. Әрем, алабута үскән бушлык күрмәссең. Җирнең һәр аршыны исәптә, файда китерә. Еракта күлләр, елгачыклар ялтырый. Тагын да арырак атаклы Альп тауларының кар түбәләре кукыраеп утыра, ак чәшке тиресеннән тегелгән ак бүрек кигәннәрмени?!

Безне Линц шәһәрендә педагогик академия ректоры профессор Шперрер әфәнде каршы алды. Ирләргә хас эре, кырыс йөз. Кызыл күлмәк каешсыз ак чалбарга кыстырылган. Рәсмилек сизелми диярлек. Машинасын үзе йөртә. Ярты сәгатьтән соң инде без ак мебель белән җиһазландырылган иркен кабинетта әңгәмә куертып җибәрдек.

Минем исем-фамилиямне хәтерли алмый интеккәч, ул «сез кайсы милләттән» дип сорарга мәҗбүр булды. «Татар» дигәч, бераз сәер итеп миңа гына түгел, хәтта ишеккә дә карап куйган кебек тоелды. Тәрҗемәчебез, бу татарлар — башка халык, аларның басып алучыларга мөнәсәбәтләре юк, дип аңлатырга ашыкты. Коллегам минем үземне тотышымда да агрессив ниятнең булмавына ышангач, тынычланды, кечкенә өстәл янына чакырды.

Конгресс Линц шәһәренең педагогик академия бинасында, аның иң зиннәтле аудиторияләрендә барды.

Европада укытучы кадрлар әзерләү, белемнәрен күтәрү эшен яхшырту максаты белән дөньяга килгән ярым рәсми, ярым үзешчән бу оешма бай меценатлар керткән акча исәбенә яши. Ул һәр елны Көнбатыш илләренең берсендә җыелып фикер алышу уздыра. Һәр елны сайланып куела торган президентның ярдәмчеләре ел дәвамында төрле ил педагоглары белән язышалар, булачак киңәшмәнең программасын төзиләр.

1984 елның сентябрь аенда үткәрелгән конгрессның төп яңалыгы шунда иде: аның эшендә беренче тапкыр социалистик илләр вәкилләре катнашты. ГДР, Болгария, Чехословакия һәм бигрәк тә СССР делегацияләренә игътибар гаять зур булды, докладлары бинниһая кызыксыну уятты. Конгресста катнашучылар үзләре үк безнең ил хакында Көнбатыш информация органнары аша гына ишетүләрен танырга мәҗбүр булдылар. Ә ул белешмәләрнең ни дәрәҗәдә объектив икәнлеген без яхшы беләбез.

Безнең мәктәп реформасы турында да алар имеш-мимешләр аша гына хөкем йөртәләр. Шуңа күрә совет делегациясенең бу хактагы чыгышы зур игътибар белән тыңланды. Сораулар да аз булмады: реформаны укытучылар ничек кабул иттеләр? Уку һәм укыту барышында теоретик һәм гамәли мәсьәләләр үзара ничек яраша? Педагогия

институтында алган дипломның абруе университетныкыннан түбәнрәк бәяләнмиме? Студентларның педагогик практикасы ничек оештырыла? Укытучыларның белемен күтәрүдә эффектлылык ничек билгеләнә?

Тыңлаучыларны Советлар илендә яшь буынга тәрбия бирү алымнары, педагогика фәне казанышлары, мәктәп тормышында әдәбият һәм сәнгатьнең тоткан урыны кебек мәсьәләләр кызыксындырды. Үзләре өчен яңа дөнья, яңа кыйтга ачкандай, тын да алмый утырдылар.

Чөнки совет мәктәбе дөньяви эчтәлеге белән генә түгел, ә формасы буенча да Көнбатыш илләрдәге уку-укыту системасыннан нык аерыла. Аның эшчәнлеге нигезендә халыклар арасындагы демократик тигезлек, барлык балаларга да уртак социалистик тәрбия, материалистик белем бирү идеясе ята. Без бу хәлгә шул чаклы күнеккәнбез, мәктәпнең башкача булуын күз алдына да китерә алмыйбыз.

Чынлыкта исә, бай белән ярлы баласын яшьтән үк аерып-аерып кую идеясенә корылган мәктәп системалары бар. Көнбатыш Европа илләренең, аларның элекке колонияләренең күбесендә мәктәп структурасы бик катлаулы. Австриядә, мәсәлән, белем бирүнең башлангыч звеносы итеп балалар бакчасы санала. Балалар алты яшьтән 4 еллык башлангыч мәктәпкә керәләр. Шуннан соң белем алу юллары аерыла: берәүләр — «халык мәктәбе»нә, икенчеләре уку программасы катлаулырак булган «үзәк мәктәпкә» юл ала. Дәүләт мәктәпләре белән бергә үк хосусый һәм чиркәүгә караган укыту оешмалары яшәп килә. Дин һәр мәктәптә дә мәҗбүри өйрәнелә.

Кайбер мәктәпләрдә латин теле дә керә. Бу балалар алдында гимназия ишекләре ачык. Ә гимназияне тәмамлау (анда уку срогы 2—3 ел) югары уку йортларына керү мөмкинлеген бирә. Гимназиядә уку яшүсмернең булачак һөнәренә бәйле рәвештә алып барыла (гуманитар, табигать фәннәре, математика). Кызларга чит телләр, күбрәк инглиз, француз, итальян телләре һәм йорт эшләре дә өйрәтәләр.

Австриядә белем бирү белән Федераль Мәгариф министрлыгы җитәкчелегендәге җирле мәктәп советлары идарә итә. 1966 елда һәр балага гомуми урта белем бирү законы кабул ителсә дә, 1969 елда бу процесс туктатыла.

Укытучыларны Австриядә педагогик академияләр һәм өлешчә университетлар әзерли. 14 педагогик академиянең дүртесе һөнәр училищелары өчен кадрлар чыгара.

Педагогик академияләрдә студентлар саны зур түгел. Мәсәлән, иң зур педагогик югары уку йортыннан саналган Вена академиясендә дә нибары бер мең студент исәпләнә. Без исә үзебездәге ике мең студенты булган уку йортларын да кечкенәсенәбез.

Вена, Грац, Зальцбург кебек илнең төп шәһәрләрендә урнашкан, XVI—XVII гасырларда ук ачылган университетлар — югары культурага ия, абруйлы уку йортлары. Ике миллионлап китапны туплаган Вена китапханәсенә беренче китаплар, документлар XV гасырда ук килеп керә. Вена операсының зур тарихы турында әйтеп торасы да юк.

Австриянең уку йортлары эшчәнлеге, архитектура, сәнгать казанышлары белән танышкач, янәдән бер уйланып куясың: фән, белем казанышлары, сәнгатьнең көче чик кануннары һәм вакыт аралыгы белән санашмыйча, тереклекнең үзе кебек үк, киләчәккә үтә. Алар мәңгелек. Венада университет, китапханә биналары калкып чыкканнан бирле Австрия җирендә күпме тираннар алышынган, ничәмә дәһшәтле сугышлар булып үткән. Инквизиция, алар йөзендә төп дошманнарын күреп, белем, китап һәм галимнәр белән көрәштә бернинди алымнан да тартынып тормаган. Әмма бу чишмәләрнең суын бернинди көч тә туктата алмаган. Белем мәгарәсе, кеше зиһененә, акылына үлмәс һәйкәл булып, китап санына, кулъязмаларга байый килгән. Бу бөек, илаһи көч һәрвакыт тынычлык сагында тора, сугыш катастрофасына каршы көрәшә.

* * *

Венаның үзәк урамнарында үзеңне ачык һавадагы олы бер музейда йөргәндәй хис итәсең. һәр адымда тарих сулышы сизелеп тора. Төрле стиль белән төрле чорларда салынган биналар: Ратуша, университет корпуслары, императорларның җәйге һәм кышкы резиденцияләре, дөньяда атаклы Вена операсы (без анда «Аида» операсына бардык, үзәк партиядә гастрольдәге Елена Образцованы тыңладык. Хәзер дөньяның иң яхшы җырчыларыннан саналган бу актрисага «эләгү» Мәскәүдә бик кыен), яшькелт, сары, аксыл мәрмәрдән салынган, алтын йөгертелгән һәйкәлләр, чәчәккә күмелгән парклар үзенә бер илаһи атмосфера тудыра. Шәһәр тәзеклеге, чисталыгы, ялтыравык витриналары, әллә каян кычкырып торган рекламалары белән үзенә тартып тора.

Вена берничә калкулыкка урнашкан. һәркайсыннан алтынсу гөмбәзле манаралар, зиннәтле сарайлар, Дунай аша сузылган челтәрле күперләр күренә. Башкалада илнең төп мәдәни һәм сәяси тормышы, промышленность һәм финанс көчләре тупланган.

Венада — халыкара ярминкәләр, конгресслар гадәти күренеш. Атом көчен тыныч максатларда файдалану үзәгендә (МАГАТЭ дип атала торган дөньякүләм оешма) безнең ил егетләре дә эшли.

Австрия халкы тыштан тыныч, сабыр табигатьле. Һәркем үз шөгыленнән канәгатьлек, ямь табып эшли бәлә. Урам себерүче дә, ресторан ишек төбен саклаучы да, урамда газета-журналлар сатучы да (дөрес, кечке газеталарны гарәп малайлары тарата), стена акшарлаучы да үз эшен горурлык белән башкара.

Әмма бу тирәлектә хезмәт ияләренең янәшәсендә үк бозыклык, мораль бушлык, азгынлык, өметсезлек кебек хәлләр дә рәттән атлый. Монда һәр нәрсә дә сатыла һәм сатып алына. Нерв, психик чирләр белән авыручылар саны арта бару да тормышның җиңел түгеллеге, яшәү өчен туктаусыз көрәш алып барырга кирәклеге хакында сөйли.

Халыкның гадәтләре турында сүз башлагач, кунак кабул итү мәсьәләсенә дә кагыласым килә. Бу яктан безнең совет кешеләреннән дә киң күңелле халык дөньяда юктыр, мөгаен. Без кайчак кунак табыннарын төрледән-төрле нигъмәтләр белән сыгылдырып, бүләк-күчтәнәчләр әзерләп, чама хисе турында хәтта онытыбрак та җибәрәбез.

Советлар илендә кунакта булу бәхетенә ирешкән чит ил кешеләре безнең кызыл һәм кара уылдыкларны, токмач-пилмәннәрне, бәлеш-өчпочмакларны, гөмбәләрне һәм шуларны күбрәк үзләштерергә ярдәм иткән шәрабларны сагынып, дәртләнеп, сүз житмәсә, куллары, иреннәре белән күрсәтә-күрсәтә сөйлиләр. Әмма... бу шөгыльдә бездән үрнәк алырга һич кенә дә ашыкмыйлар. Нишлисең, татар халкының «кунак ашы каракаршы» дигән мәкален белмиләр шул алар. Менә бер мисал. Линцта конгресс тәмамлангач, барлык делегатлар хөрмәтенә кабул итү мәҗлесе уздырдылар. Билетлар алдан сатылды. Очрашу өчен бик мәһабәт бина билгеләнгән: иркен бүлмәләр, мәрмәр баганалар, киң тәрәзәләр, кызыл агачтан ясалган авыр ишекләр... Ялтыравыклы шоп-шома паркетта түшәмдәге затлы люстраларның һәр лампочкасы, һәр детале көзгедәгедәй күренеп тора. Ап-ак эскәтерле өстәлләргә матур-матур шешәләр тезелгән: һәр кешегә берәр шешә сыра, су, ширбәт куелган. Рәхәтләнеп ике сәгатькә суза аласың. Шул вакыт эчендә син рәсми чыгышларны ишетергә, конференциягә катнашучыларны бүләкләүдә катнашырга, немецчә хор тыңларга тиеш. Шуннан соң гына күрше бүлмә өстәленә тезеп куелган бутербродларны авыз итә аласың. Тәлинкәңә колбаса, ветчина, кабак боткасы ягылган ипи телемен куясың да, янәдән үз өстәлеңә кайтасың. Шуннан соң бокалларга шәраб та салып чыгалар. Әлбәттә, ашамлык бик тиз «эри», әмма бутербродлар өстәленә кабат баруны килештермиләр. Сәхнәгә янәдән тирә-юнь авыллардан килгән хор чыга, фольклор әсәрләре яңгырый...

Аның каравы, кунакларның акча янчыкларын бушату юнәлешендә һәркайда, һәрдаим төпле һәм планлы эш алып барыла. Әйтик, син кибет бусагасын узып, берәр товарга күз ташлавыңны гына сизсәләр дә, шул мизгелдә үк яныңа берничә клерк килеп җитә. Берсе малын мактый, икенчесе аны тәрергә әзерләнә, маймыл рәсеме төшерелгән кавырсын пакет тартып чыгара. Әгәр дә син, ошап бетми, дигәнрәк тәстә башыңны чайкасаң, башка бүлекләргә чакыру-ялвару башлана. Шуңа күрә, үтмәстәй йомышың булмаса, кибеткә кермәвең хәерлерәк.

Хәтта фәнни конференциянең тәнәфесендә дә, коридорда тукталып калсаң, синең ялгызлыкны, моңсулыкны уртаклашырга теләгәндәй, яныңа җирән чәчле мөлаем гына кыз йөгереп килә. Ул сиңа бизәкле кәгазьгә басылган язу кисәге тоттыра һәм, башкарган гамәлеңнән бик канәгатьләнеп, рәхмәт әйтеп, вакытын кая куярга белми интеккән икенче берәүне сөендерергә ашыга. Ниһаять, кунак мәҗлесенә яисә театрга чакыралар икән, дип, язманы укырга керешәсең. Тик кәгазьдәге һич уйламаган, көтмәгән әчтәлек белән танышкач, аптырап каласың. Кәгазьнең максаты әлеге дә баягы — акча юнәтү икән: «Рейн җәмгыяте сездән талантлы балаларны тәрбияләү фондына акчалата ярдәм итүне сорый.»

* * *

Бу илдә без нибары бер атна булдык. Шундый кыска вакыт арасында бар теләгәнеңне дә белү мөмкин түгел, әлбәттә. Әмма күп тапкыр ишеткәнче бер тапкыр күреп кайт, дигән хакыйкать тә бар бит әле. Күргәннәребез исә шактый гыйбрәтле иде.

# ДИҢГЕЗЧЕ ЕГЕТ МОҢЫ

Фаил Шәфигуллин — замандаш язучыбыз. Шуңа күрә, мөхтәрәм әдипләребезгә мөрәҗәгать иткәндәй, аның исеме янына «танылган», «күренекле» кебек эпитетларны куеп сөйләшү ничектер уңайсызрак, гадәткә кермәгән бер эш булып тоела. Гәрчә безнең бөтен күңелебез шуны таләп итә, безнең бөтен җаныбыз әлеге зур талант каршында баш ияргә омтыла... Язучы иҗатына карата тыйнаклык саклавыбызның тагын бер сәбәбе, күрәсең, гаять бай һәм күпкырлы бу талант көченең бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән һәм лаеклы бәясен алмаган булуындадыр... Хәер, җиңелчә бер караш ташлау белән генә әлеге иҗатның бөтен нечкәлекләрен иңләп күзаллау мөмкин дә түгел. Кайта-кайта уйланасы, кайта-кайта ачасы яңа шигъри тылсымнарга гаять бай ул иҗат!

Ф. Шәфигуллинның юмористик һәм сатирик әсәрләре, лирик шигырьләре, нәниләргә, балаларга, яшүсмерләргә атап язылган моңсу повестьлары, якты хикәяләре авторның гаҗәп киң колачлы әдип булуы турында сөйли. Әмма хикмәт жанр төрлелегендә һәм язылган әсәрләрнең күләмендә генә түгел. Татар әдәбиятына Фаил Шәфигуллин дистәгә якын үрнәк хикәя бүләк итте! Инде моңа сокланмыйча калып булмый, инде бу иҗат яныннан битараф көе үтеп китү мөмкин түгел.

Ф. Шәфигуллинны без, шагыйрь буларак, киләчәк бәхеткә — «еллар каршына» — йөгереп баручы сизгер йөрәкле, нечкә күңелле, тынгысыз замандашыбыз итеп күрәбез:

Кем ул төнлә факел тотып чаба
Киләчәккә, еллар каршына? —
«Уяу булыгыз, кешеләр!» дигән сүзләр
Уелып кала мәйдан ташына.
(«Мәңгелек ут»)

Әдәбият мәйданына ул җанлы тормыш эченнән: иген кырларындагы тракторлар гөрелтесе, чиксез диңгез дулкыннары шавы, «төнге смена»ның йокысыз станоклар җырына кушылып килеп керде. Аның шигырь юлларында да хезмәт кешесе күңелендә чагылыш тапкан әнә шул кырыс һәм ягымлы поэтик авазлар ишетелә.

Алтын чәчле башын җиз рамнарга,
Өлгеләргә куеп,
Кояш кызыгып карый кайчагында
Ут һәм тимер туен.
(«Завод җыры»)

Әлеге хезмәт туеның түрендә, табигый ки, гади хезмәт кешесе тантана итә:

Бар нәрсәгә көче җиткән
Мифик алла, титан төсле,—
Яраткан да тимер дөнья,
Тик елмаеп тора кеше.
(«Кою цехында»)

«Яшьлек эзе шәһәр белән авыл арасында» калган лирик герой Кешегә һәм Тимергә дан җырлый. Тимердә ул социаль мәгънә — җирдә яңа тормыш коруның нигез символын күрә — «Тимер кискән кешеләргә ышанган бит бөек Ленин» («Тимер»). Лирик геройга «тугайларсыз, бодайларсыз, тургайларсыз» яшәү җиңел түгел. Әмма ул тимер богаулар, «тимер читлек»кә төренгән төрмәләр, «тимер йөзле бомбалар, тимер күзле пушкалар» барында тынычланып кала алмый — «син кисмәсәң, кисәр тимер сине үзе». Шуңа күрә аңа, «тимер рухлы» хезмәт кешесенә, җансыз тимерләрнең әле күп төрлесен кисәсе — тиша-

се бар. Шуңа арыш, чишмә, сандугачларны да «онытып» ул тимер игәүләү белән мәшгуль; шуңа бу «галиҗәнап» эшче сыйныфына ул аерым бер мәхәббәт белән карый: шуңа аның йөрәгендә бар нәрсәдән өстен булып «эшче горурлыгы» яши.

Поэзиягә Ф. Шәфигуллин диңгез дулкыннары җырын, диңгезче кичерешләренең тынгысыз яшәешен дә алып керде.

Акчарлаклар ярга очты,
Дулкын шавы — янау катыш,
Үксеп куйды корыч мачта,
Әйтерсең, бер зәгыйфь камыш.

Диңгез тулы хәвеф, әмма кеше һәркайда да кеше булып кала: ул хәрәкәт итә, хыяллана, көрәшә — корабына «кургаш башлы таулар белән китереп орган» давылларга каршы тора. Шунысы кызыклы: диңгездә дә ул — җир баласы, Ватан баласы. Кешене яшәтүче, «давыл кичкәндә җылытучы» көч — «туган җирне сагыну» тойгысы — бер генә минутка да аның күңеленнән чыгып тормый. Шуңа лирик геройның, бер мачтасы сынган корабны очраткач та, әтисе үлгәннән соң боегып калган өйләрен искә төшерүе, я булмаса, «Чукотка» шигырендәгечә, ерак бер җир кисәген күреп, «шушы ярдан башлана Ватан...» дип уйлануы очраклы түгел. Нәкъ шуңа бит, гади генә диңгез күренешләре дә герой күңелендә кешеләр язмышына бәйле төстә аерым бер мәгънә, фәлсәфи бер фикер юнәлеше ула... Әйе, «дулкынга дулкын бәрелгәч», дулкынны дулкын йотып кына калмый, ә бәлки «дулкынга дулкын сарылгач, дулкыннан дулкын да туа» («Дулкынга дулкын»)...

Диңгез дулкыннары эчендә дә гомум кешелек язмышы турында поэтик фикер йөрткәне өчен дә бит шагыйрь заман проблемаларының «кыл уртасына» килеп керә ала:

Сулдан Ватаным озата,
АКШ — уңнан.
Безнең кораб йөзеп бара
Кыл уртадан. («Диңгез эскизлары»)

Әмма сулар нейтраль булсалар да, «илләр алай түгел», материклар бер-берсенә шундый якын торсалар да, күңелләр бер булып оешмый. Күкне генә түгел, әледән-әле җанны да «утлы кылычлар» — прожекторлар телеп тора... Самолеттан «уйнап кына... ут яудырып» тюлень балаларын канга батырып китеп барудан тәм тапкан кешеләр яши янәшәдә — «йокламагач Америка, Азия дә йоклый алмый...»

Чиксез океан суларында шагыйрь «бунтарь җанын, яшьлек хыялларын дулкын итеп, мәңге диңгез булып шаулаган» фидакарь җаннар белән очраша («Беринг диңгезе»), «яхшы ният белән килгән» ак тәнлене сагынган папуаслар җырын ишетә («Миклухо-Маклай»), иң хәтәр минутларда ярдәм кулын сузган интернациональ дуслыкны күрә («Немец егете»). Авторның «Төньяк балкышы» шигыре дә диңгез киңлекләренә үтеп кергән халыклар дуслыгының бәйрәм тантанасы булып кабул ителә:

Җем-җем, гөлт-гөлт,
Зәңгәр, яшел, кызыл, сары...
Гүя анда бар илләрнең
Байраклары...
Байраклары белән шулай
Җилфер-җилфер
Илләр, бәлки, берсен-берсе
Сәламлидер.
Континентлар бер-берсенә
Бирәдер кул.
Чыгып тынычлык кояшы
Сибәдер нур...

Кеше һәм Кешелек язмышы турында борчылу, яңу — Ф. Шәфигуллинның бер диңгез шигырьләренә генә карамый, ул аның бөтен «җир шигырьләре»нең дә үзәгендә ята.

Шагыйрьнең иң зур дошманы — таш бәгырьле кешеләр:

Шыр ялангач кыргый кыяларда,
Ташларда да ник гөл үсә соң?
Таш бәгырьле кешеләр, дигән сүздән
Оялалар ташлар, күрәсең.

Аның «җуйма, диеп, сандугачларыңны!» — кычкырасым килде Казанга...» дип язуы да тикмәгә түгел, билгеле («Күңелемдә яши бер хатирә...»). Гамьсезлек белән шигърияткә бергә сыеша алмавын әдип бик яхшы төшенә. Һәр шигыре белән, әйтерсең лә, ул безгә әнә шул хакта кисәтә-искәртә.

Шагыйрь йөрәге сизгер барометр сыман,— һәрбер аваз дулкыны, һәрбер төс үзгәреше аның күңелен хәрәкәткә китерә: «яумый узган болыт артыннан» йөгерешкән яшь уҗымнарны күреп ул җаны белән сызлана («Этюд»), давылда сынган наратны иңнәрендә тотып торган ак каенга карап, сугыш елларын — ут сызыгы аша яралы солдатны алып чыккан шәфкать туташын күзаллый («Шәфкать туташы»), диңгез кебек үк офыктан офыкка җәелеп аккан башаклар җыры аңа яшәү дәрте, рухи ныклык китерә («Арышлар»), бер уч печән исе аны сөю белән тулы яшьлек хатирәләренә алып кайта («Бер уч печән»); аның күңеле бәсле тәрәзәләр аръягында тамчы тамган тавыш ишетә («Авырып ятканда»), җаны тальян гармун моңы булып «җәйге зәңгәр кичләрдә» кешеләр күңеленә килеп керә («Мин гармун булыр идем»). Болар барысы да шагыйрьнең җирне, тормышны, кешеләрне бирелеп яратуы турында сөйли. Алар өчен ул яна, борчыла; алар бәхете өчен ул актив көрәшә; шушы бөек идеал өчен яши алуы белән чын-чынлап горурлана белә:

Кайлардадыр дөм кара төн, җил, гарасат,
Күңелләргә шом салып тик яшен яшьни.
Кояш чыкмый калса, яңа көн ясарга,
Әле ярый, җирдә коммунистлар яши.
(«Коммунистлар»)

Ф. Шәфигуллинның таланты үзенең бөтен зурлыгы белән проза әсәрләрендә — хикәя, повестьларында ачылып китте. Язучының беренче хикәяләр китабы 1968 елда басылып чыга һәм тиз арада киң катлам укучыларның игътибарын җәлеп итә. Аның бүгенге көнгәчә дөнья күргән ун китабының җидесе әнә шушы чәчмә жанрга карый.

Ф. Шәфигуллин чәчмә әсәрләренең иң элек күзгә ташланган үзенчәлеге — аларның чынбарлыкны ике аспектта — лирик һәм юмористик башлангычка нигезләнеп танып белергә омтылуында. Биредә тагын шунысы игътибарга лаек — авторның юмористик-сатирик хикәяләре тулысынча диярлек олыларга багышланса, җитди лирик кичерешләргә таянып иҗат ителгән хикәя-повестьлары, шулай ук, бөтенләе белән дип әйтерлек, балаларга һәм яшүсмерләргә адресланган.

Юмор һәм сатира — Ф. Шәфигуллин иҗатының иң асыл үзлекләреннән берсе. Аның бу сыйфаты кайбер шигырьләрендә һәм «шигъри охшатулар»ында да күренеп алган иде. Кыска хикәяләрендә исә авторның әлеге таланты чынлап торып ачылып китә.

Ф. Шәфигуллин юморы, беренчедән, үзенең табигыйлеге, ясалмаган булуы, геройлар психологиясенең эчке үсешенә хилафлык китермәве, киресенчә, шуларның эчке хасияте үзенчәлегеннән килеп чыгуы белән күңелне җәлеп итсә, икенчедән, тормышның үзе кебек үк гаять күпкырлы һәм күптөрле чагылышта яшәве белән кызыклы. Гади сүз уйнату, шаяртулардан, җиңелчә моңсулык белән кушылган елмаю-көлемсерәүләрдән алып әче сатира-сарказмгача булган нинди генә көлү төсмерләре очрамый биредә! Һәр хикәядә үзгә бер герой, аңа карата үзгә бер мөнәсәбәт, үзгә бер эстетик ачкыч...

«Әни кунакка киткәч» хикәясенең нигезендә «логик адаштыру» ята.

«Бердәнбер улы Әптәз үкереп елап кайтып кергәч, Әкмәл абыйның да күзләренә яшьләр килә.

— Шул инде,— дип уйлады ул эченнән генә,— кая барсаң да, әнисез баланы рәнҗетәләр. Әнисен әйтер идем, баланы ялгыз калдырып, өчәр көн кунак булып ята. Ну, бу хатын-кызны!..

— Ашарга китеримме, улым?

— Бәйлән-мә...— дип, иңнәрен калтырата-калтырата елавын гына белде Әптәз».

Баланың күптөрле капризлары шул рәвешчә дәвам итә. Ул бер генә төрле юатуларга да бирелми. Күлмәген дә алыштырттырмый, чалбарын да үтүкләтми, әтисе биргән... коньякны да эчми, тәмәкесен дә көйрәтми, хәтта үзенә әле яңа гына алынган гитарага да исе китми... «Эч пошырма-а-а... Йә, ачу ара ипи шүрлегеңә менеп төшәрмен...» дип, әтисенең бөтен тырышуларын гел читкә этәрә килә. «Кайсы юньсезе генә тиде минем бердәнбереме?..»— дип өзгәләнә әтисе. Ниһаять, Әптәз: «Әсмабика!»— дип ачыргаланып кычкыра һәм янә мендәргә каплана.

— Кайсы Әсмабикә, улым?

— Который практикага килде... а-а-а...

— Нишләтте, улым, нишләтте Әсмабикә сине? Кимсеттеме? Хатын авергансың, дидеме? Әлимент түлисең, дидеме?..

— Обманула-а-а... Сначала каш сикертеп башымны әйләндереп йөрде... А теперь әйтә, что Уфада ирем белән малаем бар... уа-уа-уа...»

Шулай итеп «томан» тарала: безнең күз алдында тормышыбызның бер күренеше — кәләсене дә, елыйсыны да китергән чып-чын «замана баласы» пәйда була.

Чынбарлыкның һәм кеше халәтенең эчке охшашлыгын «шагыйрьләрчә» нечкә һәм төгәл күреп ала белә Ф. Шәфигуллин. Бу төр образ-алымнар да шулай ук аның иҗатында чынбарлыкны художестволы танып белү чарасына әвереләләр, герой психологиясенең асылын ачуда, характерның эчке үсеш сызыгын билгеләүдә алар гаҗәп төгәл ориентир хезмәтен үтиләр.

Язучының «Бер мәхәббәт тарихы» хикәясен искә төшерик. Биредә автор: «Элек мин кызлар белән таныша алмыйча иза чигә идем. Аракыны ташлагач, хәл үзгәрде»,— дип укучыны лирик герой белән гомум төстә генә таныштырып куя да, калган бөтен эшне — геройның эчке дөньясын ачуны — әлеге чагыштыру, охшашлык ассоциацияләре башкара:

«Әле беркөннәрдә Фәнзилләр туенда бик озаклап Нәзирәне күзәтеп утырдым. Чәчләрен дә әллә ниләр кыландырып, кырыкка бөтереп бетермәгән, сыра күбеге сыман күпертеп, маңгаена гына төшереп куйган».

Монысы герой күңелендә туган беренче ассоциация! Хикәянең калган бөтен сюжет сызыгы, образлар системасы әнә шул төр образларга бәйле төстә оеша.

Менә «лирик» героебызның кызны озата кайтуы:

«Багана башларындагы лампалар мөлдерәмә тулы әче бал графиннәренә охшаган. Тротуар буендагы чәчәкләрдән тройной одеколон, ликер һәм дә тагын әллә нинди мин авыз итеп карамаган татлы шәраб исе килә«...»— Ай-һай, Нәзирә! Син шешә җыючы Гыймраннан да тибешрәк йөрисең!» «— Гастроном чатына кадәр генә озатыйм әле, Нәзирә?» «Шунда Нәзирә авызыннан, шешәдән бөке атылып чыккандай, хәтәр-хәтәр сүзләр барысы берьюлы шартлап чыкты...»

Шулай итеп, әлеге образлар ярдәмендә төп геройның эчке дөньясы, аның үткән һәм бүгенге язмышы, аны чолгап алган кешеләр, автор карашы һ.б. тулы бер ачык картина булып гәүдәләнә.

Герой психологиясенең нюансларын ачып салган мондый чагыштырулы образларны Ф. Шәфигуллин башка бик күп хикәяләрендә дә гаҗәп уңышлы файдалана:

«Кар җыйгыч көрәкләрдәй зур куллары тун кесәләренә керделәр дә чыктылар, керделәр дә чыктылар...» («Тынгысыз заман»)

«Йөзе өстәл лампасы шикелле янып тора. Сул колагына төшеп тәрәлгән кепкасы өстәл лампасының кыегайган тәлинкәсен хәтерләтә. Аккордеоны тезләренә кадәр сузылып төшкән. Илсур селкенгән саен, тамагына чи бәрәңге утырган каз сыман кызганыч тавышлар чыгара. Телевизор экраны чаклы кул аркасында инә очы кадәр кан табы». («Илсур, торба һәм аккордеон»)

Мондый мисалларны күпләп китерергә мөмкин, әмма китерелгәннәреннән дә ачык аңлашыла булса кирәк: шагыйрьләр яратып кулланган бу төр образлар оста художник кулында зур сурәтләү көченә ия. Алар авторның нечкә психолог, фантазиясе чикләнмәгән, үткен күзле, шигъри җанлы каләм иясе икәнлеген күрсәтәләр. «Көмеш лампа», «Акыллы киңәш», «Әни кунакка киткәч» һ.б. хикәяләрендә язучы бу пародияле образларны әсәрнең тулаем эчке структурасын оештыручы алым итеп тә куллана.

Чынбарлык үлчәмнәренең эчке халәт логикасы белән тәңгәл килмәве язучының психологик образларында,— дөньяны үзенчәлекле төстә кабул итеп, үзенчәлекле төстә яшәгән геройлар тормышын сурәтләвендә бигрәк тә нык сизелеп тора. Әлеге геройларның тел һәм сөйләм рәвешләре дә, уй-фикер йөртүләре дә, холыклары, кылган эшләре дә ничектер икенчерәк, башкалардан аерымрак, азрак сәеррәк һәм калкурак...

Ф. Шәфигуллинның «Сафура, Бәкер һәм трактор» хикәясендәге геройларның сөйләшүе һәм үз-үзләрен тотышына игътибар итик.

Әнә авыл халкы, елап-сыктап, фронтка китүчеләрне озатып кайта. Шулвакыт авыл читендәге өйдән «яшь кенә бер ир белән яшь кенә бер хатын»— безнең геройларыбыз гөрләшеп чыга:

«— Бәкер дим, соңга каласың, чукынчык, йөгер тизрәк...

— Ашыктырма, Сафура... Уйнарга китмим, фронтка китәм. Ишетсен колагың, карап кына йөрт тракторны.

— Ишеттем ләбаса. Йөгер тизрәк, поездга соңга каласың, Бәкер...

— Калмыйм. Алай-болай ватыла-нитә калса, карбюратор белән магнетога тыгылма. Аларына синең баш җитмәс. Бригадирга күрсәтерсең.

— Бар инде, бар... Берәр җиргә китә башласаң, «карбюратор», «магнето» дип теңкәмә тиясең чистый...

— Телеңә салынма, җен хатыны. Алай-болай булса, кайткач, кара аны...

— Курыктым ди бик! Котым очты...

Бәкер кулындагы капчыгын култыгына кыстырып авыл башына кадәр йөгерде дә, артына борылып, хатынына йодрык күрсәтте:

— Подшипникларны эретмә!..»

Әлеге геройларның дөньяга карашларында, бер-берсенә мөнәсәбәтләрендә һәм, гомумән, бөтен холык-фигыльләрендә, дөрестән дә, үзгә бер үлчәм яши сыман. Сугышка чыгып китүчеләр һәм сугышка озатучылар психологиясе әле алардан шактый читтә тора... Хәер, моннан соң да, берсенең сугыш кырларында, икенчесенең тылда дөнья җимертеп йөрүләренә дә карамастан, инде аралашулары хәзер хат аша гына дәвам итсә дә (һәм монда сүз уңаенда гына кайбер бәләкәй «лирик чигенешләр» килеп керсә дә), алар арасындагы мөнәсәбәт, аңлашулар нигездә шул көе кала.

Әнә «сәламсез-нисез илаһи уптым башланган» һәм шулай ук тәмамланган Бәкер хаты:

«Әле иртән генә туры наводка белән немецларның унбер танкысын яндырдык. Соңгы танкка ут капкач, кылт итеп исемә төште. Хәтереңдәме, син миңа ашарга китергән идең. Елга буенда учак ягып чәй кайнаттың, ә мин свечаларне чистартып утырдым. Шунда син сихерче кебек муеныма килеп асылындың. Свечаларнең кулдан ничек төшеп киткәнен үзем дә сизми калганмын... Бу хатны алгач ук барып эзлә. Ишетсен колагың. Эш вакытында сырпалана торган гадәтеңнән биздерәм әле мин сине кайткач. Шабаш... Немец тагын кузгала...»

Ә монысы — шәмәхә карандаш кисәген иренендә чылатып язган Сафураның «лирик» хаты.

«Кодрәт басуын сөреп бетердек. Свечалареңне таптым, тутыкканнар, бензинга салып куйдым. Әйберне кая очрады шунда ташлыйсың да аннары кешене гаеплисең. Окопта мылтыгыңны онытып калдыр тагын!.. Ул танкларны яндырмыйча гына плен алып булмый идеме соң?.. Машиналар җитешми... Оекбашлар җибәрәм, катырып бетермә. Аягыңны юып йөр...»

Әле моннан соң да алар тагын бернична тапкыр хат алышалар. Аларда да сүз, башлыча, шул трактор хакында: Бәкернең кисәтүләре, Сафураның әлеге шикләрнең урынсыз булуы, киресенчә, хәзер тракторның сәгать кебек эшләве, берьюлы ике сабан тартып йөрүе турындагы хәбәрләре... Ә бит Бәкер ике елга якын чолганышта йөри, «бер аягы снаряд кыйпылчыгына бәрелеп» госпитальдә ятып чыга... Сафурасы да, хәер, кимен куймый, ирен — Бәкерне — хәбәрсез югалды диючеләргә дә ул «югалыр, югалтырсың аны...» дип кулын гына селти... Әйе, бу геройлар азрак үзгәрәкләр. Алар «Ватан», «Бурыч», «Җиңү», «Батырлык» кебек зур төшенчәләр белән сөйләшмиләр. Бу тойгы аларның канында, аларның һәрбер адымында. Сугыштагы батырлыкларны да, тылдагы каһарманлыкларын да алар гадәти бер көндәлек вазифаларын башкарган сыман — кабаланмыйча, купшы сүзләр белән тәрми генә эшлиләр. Сугыш алар өчен кирәксез бер афәт, тизрәк үткәреп җибәрергә кирәк булган бер авырлык. Аларның үткәннәре дә, киләчәкләре дә гадәти тыныч хезмәт көне белән бәйле. Сугыш үзе исә аларны рухландыра да, хыялландыра да алмый. Шуңа күрә геройларның иң хәтәр минутларда да, сугыштан да бигрәк, үзләренең үткәнен һәм киләчәген бергә туплаган — аларга чын бәхет китергән гади трактор турында онытмаулары, моны сурәтләгәндә авторның да буяуларны куертыбрак бирүе (хикәянең исеме дә нәкъ шул хакта сөйли) һич гаҗәп түгел. Бу — сәнгать һәм тормыш дөреслеге. Әйе, әсәр геройлары үзләренең индивидуаль йөзләре белән генә түгел, бер үк вакытта гаҗәеп дәрәҗәдә типиклашкан булулары — зур гомумиләштерүләр алып килүләре белән дә аерылып тора. Сугышны әнә шушы җир, хезмәт кешеләре — оптимист рухлы каһарман Бәкерләр, шул фидакарь Сафуралар җиңеп чыкты түгелме соң?! Чыннан да, Сафура әйткәндәй, югалтырсың аларны... Мондый кешеләрнең гомере үлемсез!

«Сафура, тракторы белән дөбер-шатыр авылны чыгып барганда, чак кына бер солдатны бәреп екмый калды. Селкенми дә, хәерсез. Аякларын аерып юл уртасына баскан да тик авызын ерып тора. Түшендә орден-медальләр ялтырый.

Сафура, тракторын туктатып, кулларын йодрыклап, җиргә сикереп төште.

— Нәрсә трактор астына керәсең? Монда кайтып үләргәме? Әнекәчем!.. Бәкер, син ич, чукынчык!..

— Сафура, җен хатыны!..

— Әбәү, мыек үстереп кайткан булган бераү... Җибәр, чукынчык, билемне өзәсең. Кара, кара, үпкән була, оялмый да.

— Кемнән оялыйм, Сафурам,— дип, як-ягына карап алды Бәкер. Тирә-юньдә бераү дә юк, тик биш-алты адым читтәрәк, ир белән хатынның кавышуына шатлангандай, тигез тавыш белән трактор гына тыкылдап тора иде».

Әлеге өч битлек хикәядә интим һәм социаль яшәешнең зур әсәрләр генә сыйдыра алырлык, тормышның бөтен фаҗигасен һәм сөенечен үзендә туплап килгән сәнгать чынлыгы ята. Кырыс кына әйтелгән һәм язылган бу сүзләрдә күпме җылылык, ярату, сагыну яшерелгән. Даһшәтле язмышларыннан кола белгән, үлемнәрдән өстен кала белгән герой-

ларның үз-үзләрен тотышларында, холык-фигыльләрендә, характерларында, сүз-фикер сөрешләрендә никадәр милли үзенчәлек (соңгы очрашу эпизодына гына игътибар итегез), без — укучылар күңеленә ни дәрәҗәдә якын һәм аңлаешлы булган чын совет кешесе рухы сизелеп тора.

Колачлы тематикасы, тирән фәлсәфәсе, нечкә психологиясе, югары эстетик эшләнеше һәм, әлбәттә, милли һәм гомум яңгырашы белән әлеге әсәрне рус әдәбиятындагы Чехов, Шукшин хикәяләре белән янәшә куясы килә. Бу хикәя күпмилләтле совет әдәбиятының гүзәл казанышы. Совет халкының үлемсезлегенә ул тере һәйкәл!

Биредә тагын авторның диалоглар остасы булуын һәм аларда геройларның характерын ачуга гына түгел, ә бәлки герой психологиясенең эчке хәрәкәтен, ягъни аның эчке һәм тышкы көрәш параметрларын күрсәтүгә дә зур игътибар итүен билгеләп үтәсе килә. Язучының үз хикәяләрендә әледән-әле драматургия жанры алымнарына күчеп китүе (аның монолог яисә диалоглардан гына торган әсәрләре дә шактый гына) бер дә юкка түгелдер. Сүз сөреше, әйтелгән һәм әйтелеп бетмәгән җөмлә, ымлык, паузалар ярдәмендә автор укучыны иң кыска юл белән герой психологиясенең «кухнясына» алып керә.

Гаҗәп төгәл тотып алынган бу диалогларда без геройларның характер үзенчәлеген дә, аларның тип буларак эчке хәрәкәтен дә бик ачык күрәбез. Алар күләм ягыннан кыска гына булсалар да, тасвирга гаҗәп зур психологик информация алып киләләр һәм оста художник кулында көчле сәнгать коралына әвереләләр.

Авторның тагын бер әсәренә тукталып узыйк. Ул «Күрше хәлен күрше белә» дип атала. Әсәр героеның характер үзенчәлекләрен җентекләп санап торуның биредә мөгаен кирәге дә юктыр. Хикәя монолог рәвешендә — психологик сурәтләү чараларын алга куеп язылган, шуңа да геройның үз авазын ишетү аның эчке дөньясын, характер үзенчәлеген кузаллауда отышлырак булыр дип уйлыйбыз.

«Чикләвегегезнең стаканы илле тиендер инде? Спекулянтның да спекулянты икәнсең. Ә, егерме тиен? Нигә егерме генә тиен әле дими ни диим, юк бәягә чикләвек сатып торгач».

Әлеге героинябыз, базарга баргач, шул рәвешчә, юлында очраган һәр кешегә «өлеш» чыгарып юлын дәвам итә.

«Йомыркаң бик вак икән, түтәй, карга оясыннан җыеп килдеңме әллә? Тукта, тукта, алмый тор, абзый, кабып карыйк әле башта кәбестәсен. Тфү, әчегән. Авызга капкысыз. Миңа алма кирәк ие. Больнискә алып барырга...»

Башыннан аягынача, эче-тышына логикасызлык чире йоккан, кешеләргә карата әшәкелек, ваклык, яла, гайбәт, зәһәрлек белән тулы җаныннан тирә-юньгә агу чәчеп йөрүче бу натура хикәя азагынача әле тип буларак шактый тулы ачылырга өлгерә. Аның бөтен кыланышларына да тукталып тормастан (гәрчә аларның һәрберсе бер «кәмит», һәрберсе авторның бер табышы), әсәрнең финалын гына искә төшерик: героиня, ниһаять, өч ай элек каты авырып киткән күршесе хәлен белергә больницага барып җитә һәм: «Беткәнсең ич, бөтенләй беткәнсең. Болай булса, терелмәм, дип өмет тә итмә. Армиядән улыңны чакыртып кайтарырга кирәк. Менә алма алып килгән идем дә үзеңә, ашый алмассың шул. Үлемтекләрең бармы, ичмасам? Ай-яй, күзләреңдә яшәү нуры калмаган инде бер дә...» — дип аны юата.

Биредә без Тукайның кайчандыр милли типлардан көлгән әче сатирик авазын ишеткәндәй булабыз. Ф. Шәфигуллинның таш бәгырьлелек белән булган көрәше сатирик хикәяләр жанрында әнә шулай дәвам итә.

Әйтергә кирәк, мондый калку һәм истә калырлык итеп эшләнгән, индивидуаль үз йөзен тапкан һәм типик яңгырашлы юмористик образ-типлар язучы иҗатында аз очрамый. Әдипнең «Чаян»чыларга гына хас үткен күзе, шагыйрьләргә генә хас нечкә күңеле кеше яшәешенең нинди генә серле почмакларына үтеп керми дә, нинди генә уңай һәм тискәре сыйфатларны анализлап күрсәтми. Ф. Шәфигуллин бигрәк тә кешеләрнең үз-үзләренә һәм, әлбәттә, башкаларга яшәргә комачаулаган тискәре сыйфатларына карата рәхимсез:

Әнә бер тиенлек сүзен теләсә кемне бүлеп, теләсә нинди сүз арасында кыстырып, берничә көннәр буена кабатлап йөри торган Илсур («Илсур, торба һәм аккордеон»); әнә ташкүлчим шигырьләре белән редакция хезмәткәрләренең җилегенә үткән, «җанын алган», ахыр чиктә, аларны эштән китәргә мәҗбүр иткән шагыйрь Җан Али («Җан Али»); әнә бөтен дөньяны куадратларга бүлеп кенә күз алдына китерә алган Нургиз («Куадрат Нургиз»); әнә күршесенә гомерендә «ике тапкыр» аяк басып, анда да үз байлыгын кайгыртып көлкегә калган Галиәхмәт абзый («Сарык»); әнә хәйлә-мәкер белән яшәүче, әтисез нарасыйлар исәбенә мал җыюдан да тайчынмаган, аларның сугышта хәбәрсез югалган әтиләренең тунын, кәҗә тиреләрен, җыйган чикләвекләрен үзенә алып, алмашка кәтүк һәм юмарт итеп сыбызгы бирергә яраткан чүпрәкче Әкмәл («Сыбызгы») һ.б.

Күргәнебезчә, язучының көлүе башлыча сатирик юнәлешле — аның күпчелек әсәрләре нигезендә әче көлү ята. Әмма биредә шунысын да ассызыклап үтик. Ф. Шәфигуллин сатирасында, ироniядән дә бигрәк, юмор ягы өстенлек ала. Юк, теш ыржайтып, нәф-

рәтләнеп түгел, кешеләрнең кимчелегеннән кызыклы итеп, гыйбрәтле итеп, елмайтып һәм... җилеккә үтәрлек нечкә итеп көлә белә ул. Еш кына бу көлүнең авыз еру гына булмыйча, әрнетүле, фаҗигале көлүгә әверелүе дә очраклы түгел. Чөнки Ф. Шәфигуллинның юмор-сатирасы тормыш катламнарыннан, геройларның эчке дөньялары, характер хасиятләреннән үсеп чыга. Шуңа аларда, нәкъ тормыштагыча, фаҗига һәм комик башлангыч, елау һәм көлү бергә үрелеп яши. Нәкъ шушы үзлекләре — кызганыч та, көлке дә булулары белән бу хикәяләр Чехов һәм Шукшин әсәрләрен хәтерләтә дә.

Ф. Шәфигуллинның «чиста» юмордан гына торган хикәяләре дә аз түгел. Аларның кайберләренә без алда тукталып та үттек. Болар янына авторның җитди әсәрләренә килеп кергән юмор элементларын — лирик моңсулык белән өртелгән юморны да («Тальян гармун» һ. б.) янәшә куйыйк. Болар язучының киң күңелле, олы җанлы, шаян рухлы каләм остасы булуын күрсәтә.

Җыеп әйткәндә, бу күптөрле, күпкырлы юмористик һәм сатирик образлар Ф. Шәфигуллинның көлү өлкәсендәге бик сирәк очрый торган табигый таланты, зур художниклык көче турында сөйли. Г. Тукай һәм Ф. Әмирханнан соң татар әдәбиятында мондый көлдерү куәтенә ия икенче бер юморист язучы булганын без хәтерләмибез.

Ф. Шәфигуллинның җитди жанрда язылган проза әсәрләре тулаем диярлек балалар әдәбиятына карый. Дөрес, әлеге утыздан артык хикәя һәм алты повестьның укучылары яшь ягыннан бер-берсеннән нык аерылып тора. Бу әсәрләрне тигез дип әйтерлек өч өлешкә, нәниләр, балалар һәм яшүсмерләр әдәбиятына бүлеп карар идек.

Аларны берләштереп торган тагын бер сыйфатка игътибар итик. Ул — Ф. Шәфигуллин иҗатының икенче бер аерылмас үзлеге — лирик моңсулык.

Автор үзе шаяртып язганча, дөньяга килгәч ул башта елмая, аннары гына тирә-юньне яңгыратып елап җибәрә. «Дөнья дигәннәре бик үк кунакчыл каршы алмады мине,— дип яза әдип.— Йә эссе, йә салкын шунда, йә җил, йә яңгыр...» Тормышта аңа һәрвакыт шулай «башта көләргә, аннары ирен турсайтырга» туры килә...

Мөгаен шулайдыр. Хәер, юмористларның сүзләрен нәкъ киресенчә аңларга кирәклеген истә тотсак... без бу фикернең нәкъ киресенә дә бик теләп ышана алабыз. Һич югы, алар бер-берсенә каршы килмичә, берсен-берсе тулыландырып, дәвам итеп кенә тора бугай... Бәләкәй Фаил олы тормыш белән танышып йөргәндә, сабый чактан ук эшләп, көрәшеп яшәгәндә, үзенең романтик бәхетен эзләп ерак далаларга, урманнарга, диңгезләргә барып чыкканда, мөгаен, башта күбрәк лаеш шулпасын татырга, аннан инде, авырлыкларны җиңә-җиңә, аларның күзенә туры карарга һәм хәтта алардан көләргә дә өйрәнгәндер... Бу фикерне авторның җитдилек белән сугарылган лирик әсәрләре дә раслап тора. Аларның һәммәсе реаль дә, хыялый да булган ерак балачак иленә төбәлгән, аларның һәммәсе моңсу, әрнүле, романтик ашкыну тойгысы белән өртелгән. Әлеге шигъри балачак илендә йөргәндә язучы, әйтерсең лә, көлүен дә, шаяртуларын да, усал итеп «тешләшә» белүен дә оныта — ул уйчанлана, җитдиләнә, йомшак табигатьле моңсу лирик Фаилгә әверелә. Җанны иркәләп балачактан искән талгын саба җиле шулай тылсымлап үзгәртәдер мөгаен кешене...

Ничек кенә булмасын, Ф. Шәфигуллин балалар әдәбиятына үз һәм көтеп алынган кеше булып килеп керде. Тиз арада ул балаларның күпне күргән, күп нәрсәне үзләре кебек үк нечкә тойган, олы җанлы киңәшчесенә — алар яраткан «заман» язучысына — әверелде. Аның урта яшьтәге балаларга һәм, аннан да бигрәк, балалар әдәбиятының иң четерекле өлкәсе — нәниләр әдәбиятын үстерүгә керткән өлеше аеруча зур. А. Алиштан соң прозада нәниләр күңелен шул дәрәҗәдә тирән һәм нечкә аңлап, бу өлкәдә шулкадәр рухланып эшләүче һәм әдәбиятыбызны югары эстетик эшләнешле хикәяләр белән баета алган икенче бер башка язучыны шулай ук без белмибез. Инде бу әсәрләргә конкрет тукталып үтик.

Авторның нәниләргә багышлап язылган «Исемең Ләйсән булыр» хикәясе түбәндәгечә — беркемгә дә билгесез бер курчак кичерешләреннән башланып китә:

«Аның янында тезелешеп торган курчакларның да исемнәре юк иде. Шулай да аларны сатып алып бетерделәр. Уенчыксыз киштәдә ул берүзе калды».

Моның сандаллары, «күбәләк канат җилпегәнгә дә сүтелергә тора» дип әниләр үзләренең бәләкәй кызларына әлеге курчакны алып бирергә һич теләмиләр. Сандаллары матур тегелмәгән шул, дип, ахырда, сатучы аны прилавка астына ук ташлый. Ә бит курчакның әле берәр нәни кыз белән уйныйсы, ул кызчыкның матур итеп көлгәнен күрәсе килгән иде. Монда исә көндез дә караңгы һәм куркыныч... «Ара-тирә, тешләрен ялтыратып, тычканнар йөгерешеп үтә...» Курчакны бу тоткынлыктан җыештыручы апаның ялтыр күзле йөнтәс мәзмәе коткара. Ул аны күлмәк итәгеннән эләктереп ала да... ачык калган ишектән җитез генә урамга чыгып йөгерә...

Курчак шунда «зәңгәр чаршаулы бишектә тирбәлә-тирбәлә, офыкка төшеп торган кояшны», «яшел ябалдашлары белән кояш бишеген күтәреп торган мәһабәт агачларны» күреп ифрат сөенә. Мәзмәй аны канәфер куагы төбенә илтеп ташлый да үз юлы белән китеп

бара, ә курчакны, шунда озак ятканнан соң, бер бабай аяклары авырткангa урамны тәрәзә аша гына карап утырырга мәҗбүр булган Ландыш исемле кызчык алдына күтәреп куя.

«Бабай, китер тизрәк, җирдә ята-ята туңып беткәндер ул... Нинди сөйкемле курчак!»— дип Ландыш аны сөенеп каршы ала. «Исемең ничек синең?— дип сорый ул курчактан.— Исемең дә юкмыни әле? Синең исемең Ләйсән булыр, яме. Син минем янда кал, эзләп килсәләр дә, минем янда кал, яме, Ләйсән. Бабай сиңа тәти сандаллар тегеп бирер. Минем аякларым төзәлгәч, без икәү бергә бакчага чыгып уйнарбыз...»Курчак та кызчыкның куенына атылырга тели. Тик ул шунда ук бу теләгеннән оялып китә: «Әгәр дә Ландыш, яңа сандал өчен шулай шатлана икән бу, дип уйласа, нишләрсең? Һәй, сандалларның нигә кирәге бар соң аларның? Шундый килешле исемең, шундый әйбәт дусың булганда, ялан тәпи дә яшәргә мөмкин ич дөньяда...»

Хикәя (ни өчендер бу әкиятне хикәя дип атыйсы килә), шул рәвешчә, тирән мәгънәле символик яңгыраш ала. Андерсен әкиятләренең рухын үстереп, аңа заман төсмере, заман яңгырашы биргән, гуманистик идея белән сугарылган җылы лирик әсәр барлыкка килә. Автор нәни укучылары алдына «Кешенең матурлыгы нәрсәдән гыйбарәт?» дигән мөһим фәлсәфи проблема-сорау куеп, аларның үз телләрендә — конкрет сәнгатьле фикерләү аспектында шуңа җавап эзли. Язучының нәниләр өчен язылган башка хикәяләре дә бу төп сорау — кеше матурлыгы темасының төрле вариантлардагы чишелеше булып тора.

«Ерык авызлы энекәшем» хикәясе «энәгә җеп тагылгандай» абыйсы артыннан йөрүче Нәсим турында. Арттан йөрүе бер хәл, ул күп итеп ашарга ярата һәм шуның аркасында абыйсын да кушып, күрше малайлары «капкорсаклар чыкты, ырый, ырый, капкорсаклар чыкты...» дип үртәргә ябышалар. Чүп өстенә чүмәлә... билгеле инде, Нәсимгә абыйсы алдында боларның барысы өчен дә «натуралата» җавап бирергә туры килә. Әмма ул, моңа карап, үзенең бу ике яраткан эшеннән аерылмый... кычыткан белән үрле-кырлы сикерткәндә дә тавыш-тынын чыгармый, түзә.

Ә бервакыт, зур тырышлыклардан соң, аны ташлап станциягә киткән һәм, машиналары җимерелеп, көчле яңгыр явып, олы юлда бүленеп калган күрше малае белән абыйсына Нәсим ашарга китерә. Малайлар, сөенешеп, ерактан ук аның каршысына йөгерешәләр. Нәсимнең күлмәк астыннан ләпек чәчрәгән кендеген күреп, шунда абыйсы: «Нишләп капкорсак булсын әле ул, һәммәбезнеке кебек матур ич аның эче... Кешегә ияреп кенә йөри ала дип торам мин аны тагын... Ә ул әнә яңгыр димәгән, ерак димәгән — ялгызы чыккан да киткән... яшен ташы белән бер...»— дип уйлап куя.

Күрәбез, идеясе ягыннан хикәя алдагы әсәрне дәвам итеп килә: кешенең күрке сандалында, я булмаса тышкы кыяфәтендә генә түгел. Кешенең төп матурлыгы — аның җанында! Ачыгып, туңып, күңел төшенкелегенә бирелгән малайларның әле иртә белән генә үзләре кычыткан белән өтеп киткән Нәсим каршысына йөгереп барулары тикмәгә түгел. Балалар кешелекле җанны тиз таныйлар. Игелекле кеше каршына алар шулай гомер буе йөгерергә әзер. Кеше, гомумән, күңелендә гомер-бакый игелек тоеп, игелек көтеп яши. Хикәядәге бу символик эпизодка салынган икенче төп фикер әнә шунда, күрәсең.

«Зәңгәр шугалак» хикәясе Ф. Шәфигуллин иҗатында гына түгел, гомумән, татар балалар прозасының иң күренекле әсәрләреннән саналырга хаклы. Бу хикәя авторның нәни укучылары белән матур Кеше турында сөйләшүенең югары ноктасы. Ул алдагы хикәяләрдәгечә геройның теге яки бу характер үзлеген анализлап кына калмый, ә бәлки геройны тулы канлы,бөтен образ итеп, аны вакыйгалар эчендә, дәвамлы процесста «сынап» карый. Шуңа күрә биш битлек бу хикәя бәләкәй бер повестьны хәтерләтә дә.

Хикәянең төп герое Хәмит, өйләрендәге бар кешедән дә иртәрәк торып, һәр көнне урамдагы шугалакны чистартырга чыга. Әллә ничә тапкыр сынаганы бар аның: «шугалак өстендә аз гына кар тузаны булса — бетте» иң оста уенчы Марат борыла да «кәҗәләнеп» бөтенләй икенче шугалакка китеп бара.«Ә Маратсыз уен — уен да түгел». Шуңа Хәмит шугалакны көрәп, себереп кенә тора да. Тикмәгә генә Зәңгәр шугалак дип йөртмиләр бит аны... Әмма Хәмит боз өстен чистартып кына калмый,— абыйсы Самат уянганчы, аның тимераякларында шуарга да өйрәнә...

Ике айлап вакыт үтә. Хәмит һәр көнне шугалак чистарта, аннан күңеле булганча тимераякта шуа. Менә ике ай инде Зәңгәр шугалакта Түбән оч белән Урта урам — Марат белән Самат командалары арасында кискен көрәш бара. «Боз читендәге кар өемендә тынгысыз аяклар тыпырдый, кызыксынучан күзләр ялтырый. Алары — тамашачылар. Алары — тимераякта шуа белмәүчеләр. Әнә араларында Хәмит тә бар». Аның күзе — Маратта. Кайвакыт ул, үз командаларына гол кергәч, «үз-үзен белештермичә, бозга сикереп төшә... Тик тагын шул абыйсы. «Син генә калган идең, бар, башыңны карга тыгып куйганчы, сыпырт моннан». Нишлисең, олылар белән әрепләшүдән ни мәгънә? Хәмит яңадан кырыйга: тамашачылар янына чыгып баса...

Көннәр үтә ›ора. Әмма төн буе буран котырганда да шугалак өсте ялт иткән була. Тамашачылар һаман да Маратны «попуаслар Миклухо-Маклайны каршы алган кебек: «О, Марат, О‚Марат»,— дип ерактан ук «ура» кычкырып каршы алалар». Шугалакны кем чистартканлыгы хакында ник берсе бер кызыксынып карасын... Әмма Маратны күрү белән Хәмитнең бу күңелсез уйлары... иртәнге томан кебек тарала». «Аның күз алдында зәңгәр боз, алка һәм сихерле тимераяклар гына торып кала». Аны инде кем капкасына ничә алка керүе дә әллә ни кызыксындырмый. Бөтен игътибары — Марат хәрәкәтләрендә. Аның голларын гына ул голга саный. Аның хәрәкәтләрен ул күңеленнән кабатлап бара: «Хәзер Марат уңга сикерергә тиеш, хәзер бер аягын күтәреп, күз иярмәс тизлек белән артка талпынырга һәм бер урында зырылдап әйләнергә тиеш. Барысы да дөрес... Гол!» Самат, хәрәмләшәсең, дип таягын атып бәрә... Аның өчен Хәмит уйнамакчы. Тик шунда, абыйсына кушылып, «чәүкә баласы, иң элек такыр юлдан тәпи-тәпи йөрергә өйрән» дип аны Марат та мыскыл итә. Гарьлегеннән елар-еламас булып торган Хәмиткә әтисе әнә шул чагында өр-яңа тимераяклар китереп тоттыра. Менә шунда уйнап күрсәтә дә инде ул малайларга... Нинди генә хәйләле хәрәкәтләр ясап карамый Марат, әмма «кая гына барса да, аның юлына өермәдәй бөтерелеп Хәмит килеп чыга һәм — алкадан җилләр исә».

«Кышын көннәр кыска. Акрынлап караңгы төшә. Тәрәзәләрдәге, багана башларындагы, урам чатларындагы электр утларының шәүләләрен үзенә җыйган боз өсте, зәңгәр очкыннар чәчеп, җем-җем итеп яна башлый... Хәмит аңламый — әллә Зәңгәр шугалактан агыла бу якты йомшак нурлар, әллә үзенең нәни йөрәгеннән ташып чыга»...

Хикәя үзе дә әнә шундый нурлы хикәя булып күңелгә иңә. Монда күңел матурлыгы, яктылык, җылылык... Монда характерлар аерымлыгы, монда характерлар көрәше. Нинди генә проблемалар кисешмәгән бу кечкенә хикәядә?! Үз-үзеңне җиңү, хезмәткә мәхәббәт, түземлелек, тыйнаклык, олыларга ихтирам, үзеңне ярату хисеннән өстен булу, оптимистлык, максатка бирелгәнлек... хикәянең заман темасы һәм заман рухы белән сугарылуы... олылар белән балалар арасындагы уртаклык һәм бөтенлек... Реальлек һәм романтик рух гармониясе... Кыскасы, биредә автор нәни геройларының тулы канлы тормышларын сәнгатьле чагылдыруда классик бер камиллеккә ирешә.

Язучының урта яшьтәге мәктәп балалары өчен язылган әсәрләре укучыны олы дөньяга алып чыга. Бу табигый дә. Балаларның бу яшьтә күрү офыклары бермә-бер киңәя, аларны кызыксындырган мәсьәләләр дә артканнан-арта, төрләнә һәм катлаулана бара.

Авторның «Акмөгез», «Беренче кар», «Ликандр», «Бал», «Кырмыска турында баллада», «Кәҗәмөгез йолдызлыгы» һ.б. хикәяләре балага табигать серләренә төшенергә, аның матурлыгын күрә һәм аңлый белергә ярдәм итә. Бу әсәрләрдә табигать белән кеше арасындагы бөтенлек, уртаклык җепләренең ныклыгын һәм әлеге дуслык-бердәмлекне саклау кирәклеген искәрткән күп төрле проблемалар урын ала. Алар барысы да уртак максат — шигъри күңелле, матур җанлы, патриотик рухлы чын кеше тәрбия итү хисе белән сугарылган.

Ф. Шәфигуллинның укуга һәм хезмәткә мәхәббәт тәрбияләгән, баланың мораль йөзе турында кайгыртып язган әсәрләреннән «Ярдәмче», «Хыянәт», «Сугышчан бурыч» һ. б. хикәяләрен аерып карарга мөмкин.

Соңгы хикәя үзендә чагылыш тапкан педагогик тәрбиянең оригиналь чишелеше белән истә кала. Бик күп ата-аналар кебек үк, Кәбирнең ...ә әти-әнисе бердәнбер улларын киләчәктә укымышлы да, эшчән һәм игелекле дә итеп күрәселәре килә. Шуңа әнә өйдә Кәбир өчен бөтен шартлар тудырылган да. Ашыйм дисә, ашарына, киим дисә, кияренә — һәммәсе баштан ашкан. Уллары «2»ле алса, ата-ана хәзер йөгерешеп мәктәбенә барып җитә. Өйдә дә балага күз-колак булып, вакытында уйнатып, вакытында аңа дәрес әзерләргә кирәклеген исенә төшереп, кыскасы, аны даими игътибар үзәгендә тотып, олылар зур тәрбия эше алып баралар. Күрәбез, чып-чын бүгенге балалар һәм бүгенге әти-әниләр...

Бервакыт әти-әнисе кунакка киткәч, өйдә хуҗа кеше булып Кәбирнең әбисе кала һәм шунда Кәбир өчен «эш-мәшәкать белән тулы тынгысыз көннәр башлана»: аңа ашарына әзерләргә дә, төймәсен тагарга да, ботинкаларын чистартырга, дәресләре турында уйланырга, хәтта китапларын тутыру эше белән дә шөгыльләнергә туры килә.

Аның каравы Кәбир математикадан «2»ле алып кайткач... әбисе аны ник бер орышырга уйласын... Кәбир «2»ле алуын әйткәч тә әле ул: «Нигә... үзеңнең начарлыгыңны сөйләп мактанып торасың...» дип, үтемле генә бер әйтеп кую белән чикләнә... Кәбир зәгыйфь кенә тавыш белән: «Әби, Сәкинә апа сине мәктәпкә чакыргание»,— дип сүзне үзе дәвам итәргә мәҗбүр була.

«— Нигә чакыргание, улым?
— Мин «2»ле алганга.

— Син «2»ле алганга нигә мине чакыра икән соң ул?
Кәбир дәшмәде, башын тагын да аскарак иде...»
Ниһаять, аларга укытучылары үзе килә. Әби урамга чыгып таярга маташкан Кәбиргә:
«— Улым, кая барасың, әнә синең янга укытучың килгән.

— Мин сезнең янга да килдем, әбекәй,— диде укытучы кыз...— Кәбирнең әтисе белән әнисе өйдә юк икән... Инде бөтен җаваплылык сезнең өскә төшә.

— Нишләп миңа төшсен, кызым? Җаваплылык Кәбирнең үзенә төшә. Зур ич инде ул безнең Кәбир. Аның яшендә бабасы, мәрхүм... партизаннарга ияреп, сугышчан бурычлар үтәп йөрде...»

Әлеге сөйләшү Кәбирнең елавы белән тәмамлана.
«Укытучы Кәбирне юатырга ымсынган иде дә, Мәгълүмә әби аны бүлдерде:

— Тимә, еласын. Ояла, гарьләнә, елый белгән кешедән рәт чыга аннан...»

Шулай итеп, әби «бүгенге» педагогиканы тиешле юнәлешкә борып куя. Кызганычка каршы, тормышыбызда мондый әбиләр шактый азаеп бара... Ә елавын онытып барган Кәбирләр, ни хикмәттер, безнең заманда артык күбәеп, типиклашып китте... Үз өсләренә төшкән башка бик күп бурыч-вазифалар белән беррәттән, алар бу эшне дә әти-әниләренә тапшырдылар, күрәсең. Әлеге хикәя баланы гына түгел, без — тәрбиячеләрне дә, чын-чынлап уйландыра. Яшь гражданнарны баласытып карауның тормышта һәм педагогикада бервакытта да әле уңай нәтиҗәләргә китергәне юк. Киресенчә, балага ышанып карау, аңарга җаваплылык тойгысын сиздерү — тәрбиядә зур көч булып тора. «Миңа уйларга кирәк» хикәясе нәкъ әнә шул яктан гыйбрәтле дә. Иптәшләренә берьяклы — өстән бәя бирергә өйрәнгән геройның бередә шактый уңайсыз хәлдә калуы һәм үз характеры турында тирән кичерешләргә бирелүе бик табигый. Үз-үзеңне яхшылап аңламый торып, башкаларны аңлау да, аларга тиешле бәя бирү дә мөмкин түгел, үз-үзеңә анализ ясый белү генә синең мөстәкыйльлегең, шәхес буларак өлгерә башлауда беренче адым атлавың турында сөйли.

Язучының «Солдатлар кайта» хикәясе татар совет балалар әдәбиятының соңгы елларда иҗат ителгән классик үрнәге булып тора.

Әсәрнең сюжеты катлаулы түгел. Ике малай тракторга керосин алырга дип ат белән юлга чыга. Күпердә, арт көпчәкләре батып, азапланып ятканда, аларга фронттан кайтып баручы бер солдат ярдәмгә килә — көпчәкләрен күпер ярыгыннан чыгарыша... Шушы гади сюжетка автор сугышның бөтен фаҗигасен сыйдыра алган. Ике малайның характер үзенчәлекләрен дә, уртак язмышларын да, исемсез солдатның рухын, бөтен тирә-юнь табигатьнең сугыштан әлсерәп, иркен бер сулыш алуын, кыскасы, шул елларның бөтен кайгы-нәфрәтен, шатлык-сөенечен үз эченә ала бу әсәр...

Язучының образлы фикерләвенә игътибар итегез.

«Атның кабыргалары мичкә кыршаулары кебек бүселеп-бүселеп чыккан. Ыңгырчак астындагы ярыклардан кош очып чыгарлык. Камыты да буш. Тауга түбән төшкәндә муенына аркылы килә».

Атны гына түгел, тимер мичкә куелган кабык арбаны да бу ике яланаяк-яланбашлы малайны да автор әнә шундый кыска, төгәл образлы тасвир аша җанландырып бирә. Малайларның зуррагы — уйчан йөзлесе — кулына сүс дилбегә тоткан. Кечерәге —«лаеш шулпасын азрак эчкәне»— чебиле аякларын илтифатсыз гына селкеп, чыбыркы сабын тидереп, тәгәрмәч тырнакларын кырдырып бара, әледән-әле олырак малайга эндәшә.

«— Хәмис дим, карале, Хәмис, бер-ике пот солы ашатсаң, мин әйтәм, танып та булмас иде Акъялны, ә!..
— Һе, әйттең, бер-ике пот солы...
— Ярты пот булса да әле, әйеме?..
— Соң... На, Акъял, на... бөтенләй йоклады, кара!
— Арыган ул, Хәмис. Төнлә тырмага җиккәннәр аны.
— Беләм.
— Ярый инде крәчинне апкайтып җиткерәлсә...
— Апкайта.
— МТС тагын бер трактор бирсә, чәчү ике-өч көндә бетәр иде инде, име Хәмис?
— Бирер, тот капчыгыңны... Син генә иең ди...
— Әле берсен ничек бирделәр диген, име?
— Син бик күп сөйләшәсең, Бәхи. Җитәр инде.
— Саруны кайнатасың, диген...
— На, на, Акъял, кара инде бөтенләй йоклады...
— Ишеттеңме, Хәмис, Кайбычта солдатлар кайта башлаган, ди.
— Кайбыч район үзәге бит ул...
— Шунда әтиең кайтып төшсә, нишләр идең, Хәмис?
— Үлгән кеше ничек кайтсын...

Хәмис дилбегәне тарткалаган була. Аның керфекләре арасыннан берничә яшь бөртеге сыгылып чыга...

Әлеге өзектән авторның осталыгын тагын бер кат күрәбез. Никадәр җитди мәгънәләр хакында сөйләшеп бара бу ике яланаяклы малай. Үзләре турында түгел, колхоз язмышын кайгыртып, әтиләре, ил язмышын кайгыртып... Аларның сүзсез кичерешләре, арба тәгәрмәченең авыр шыгырдавына кушылып, безнең җанны әрнетә.

Менә шундый авыр һәм киеренке вакытта алар янына таныш булмаган бер солдат килеп чыга.

«Адымнары... нык, куллары нинди зур аның. Шулай буладыр инде ул фашистларны чәнчелдергән чын солдат! Шәмәхә күзләрендә йомшак елмаю. Маңгаенда җәрәхәт эзе». Әнә ул борыннары йомшаган малайларның башларыннан сыйпап» уза, баткан тәгәрмәчләрне карый, «Нык утыргансыз!» дип, бил каешын төзәтеп куя.

«Әллә тургай җырыннан, әллә тугай яшеллегеннән, әллә малайлар күңеленнән исергән инде солдат — атлаган уңайга чайкалып-чайкалып китә. Үзе бертуктаусыз елмая, зур учлары белән әледән-әле күзләрен сөрткәли...»

Солдатның дымлы керфекләрендә без аның утны-суны кичкән олы җанын гына түгел, бер үк вакытта, сугыш фаҗигасен дә, яшәү һәм тыныч тормышның нинди зур, газаплы, көтеп алынган татлы бәхет булуын да бик ачык төсмерлибез. Әлеге 3—4 битлек хикәядә күләмле әсәрләргә генә сыярлык тирән мәгънә, хис, шигърият яшеренгән. Иң әһәмиятлесе шунда: бу фәлсәфи мәгънәне бала үз телендә, үз күңеле аша үткәргәндәй, кичереп кабул итә. Татар совет балалар әдәбиятының тарихи-социаль темаларны нәни укучыга җиткерә белү осталыгы традициясенең ни дәрәҗәдә югарылыгын әлеге хикәя бик ачык раслый булса кирәк.

Ф. Шәфигуллинның әрнүле сугыш елларына, үзенең балачагына кайтуын бигрәк тә аның олы яшьтәге мәктәп балалары һәм яшүсмерләргә багышланган повестьларында һәм лирик хикәяләрендә күрәбез.

Язучының сугыш һәм сугыш арты елларына туры килгән балачагы һәм яшьлегенең катлаулы кичерешләргә бай биографиясе, шулай ук әлеге кичерешләрне тирәнрәк итеп, масштаблырак итеп ачу теләге, кыска жанрны үзрәк иткән әдипне повесть жанрында каләм сынап карауга да этәргән... Нәтиҗәдә, ул үзенең яшьлек елларының кайтавазы булган «Бер малай, өч аргамак», «Бәхет йолдызы астында» һәм «Өй салуның ние бар», «Ак маңгайлы бүреләр» исемле повестьларын иҗат итә. Аларда автор малай һәм яшүсмер геройларының икмәк өчен, яшәү өчен булган көрәшләрен, үзләре ач көе дә, фронт өчен, Ватан өчен, халык өчен, тугрылык һәм якты идея өчен җаннарын бирергә әзер торуларын сурәтли. Бу көрәштә аларның фидакарьлеге, эчкерсез самимилеге, рухи матурлыгы кызыл җеп булып сузыла. Әлеге яшь геройларның үз күңелләрендә тормыш романтикасының чакырулы авазын ишетүләре, шул чакыру белән ерак диңгезләргә, ерак далаларга, ерак урманнарга чыгып китүләре, һәртөрле каршылыкларны вата-җимерә хакыйкатькә юл ярулары, әти-әниләре кебек үк, халык бәхете өчен изге көрәшкә килеп кушылулары зур сәнгать осталыгы белән тасвир ителә. Вакыйгаларның, кичерешләрнең бер үк вакытта романтик һәм реаль тормыш — тарихи чынлык белән сугарылуы — аларның тәэсир итү көчен тагын да арттыра.

Ф. Шәфигуллинның яшүсмерләр өчен язылган лирик хикәяләре дә, асылда, шушы бербөтен художестволы автобиографиянең төрле кыйпылчыклары сыман, дөресрәге, шушы зур бер лирик герой образын барлыкка китергән төрле тестәге нигез ташлары булып кабул ителә. Язучының «Авылым сандугачы», «Тальян гармун», «Ислемай» һ. б. хикәяләре әнә шундыйлардан. Аларда һәм язучының башка бик күп әсәрләрендә автор үзе, шулай ук аның замандашларының, беренче мәхәббәт тойгылары, аларның әхлак йөзе, аларның шатлык-борчу, теләк-идеаллары нык истә калырлык итеп гәүдәләндерелә.

«Әлфинур» һәм «Сыерчык бураны» повестьларында язучы тормышта беренче мөстәкыйль адымнарын атлаган замандашларыбыз — яшүсмер егет һәм кызларның күңеленә, катлаулы, каршылыклы, әмма кызыклы рухи дөньясына үтеп керергә һәм аны укучыларга да бөтен табигыйлегендә күрсәтеп бирергә омтыла.

Нәниләр һәм балалар әдәбиятында күңел матурлыгы турында сөйләшә башлаган сүзен язучы яшүсмерләр әдәбиятында яңа бер колач, күтәренкелек белән дәвам иттерә. Безнең алда илленче-җитмешенче еллар яшьләренең җанлы образы күз алдына килеп баса.

Ф. Шәфигуллин әнә шундый гаять киң диапазонда иҗат эшчәнлеге алып барган, әдәбиятта бүгенге яшьләргә зур фидакарьлек үрнәге күрсәтүгә ирешкән олы йөрәкле әдипләрнең берсе. Аның юмарт иҗаты һәркемгә дә тигез үз өлешен чыгара: олылар өчен ул җылы юмор һәм гаҗәп үткен сатирик әсәрләрен, яшүсмерләргә канатлы һәм ашкынулы романтика белән сугарылган фәлсәфи-патриотик шигырьләрен, моңсу повестьларын, оптимист рухлы лирик хикәяләрен, балаларга табигать һәм кешелек язмышын кайгырткан җитди уйлануларын, нәниләргә матурлык турындагы хикмәтле, җылы лирик хикәяләрен бүләк итте. Тиз арада Ф. Шәфигуллин үзен талантлы заман язучысы, зур художник итеп таныты, күпкырлы иҗаты белән әдәбиятыбызны классик әсәрләргә баетты.

Равил КУКУШКИН.

# ТАШНЫ ҖЫРЛАТУ АВЫРМЫ?

Август аеның иң соңгы көннәре дә якынлашып килә. Бакчалардан хуш исләр бөркелә. Өлгереп пешкән алмаларының авырлыгыннан алмагачның ботаклары җиргә хәтле сыгылып төшкән. Алмагач яңа гына бәби тапкан ананы хәтерләтә: арыган да ул, шул ук вакытта чиксез бәхетле дә.

Казан урамнарына кичке караңгылык төшеп килә. Көндезге эсселек әкрен генә сүрелә бара, машиналар гөрелтесе тына. Шәһәр, моңаеп, уйга тала сыман.

Тимер юл вокзалының перронында урта яшьләрдәге мөлаем йөзле бер ханым басып тора. Ул өстенә челтәрләп бәйләнгән аксыл йон кулмәк кигән. Шома итеп таралган чем-кара чәчләре, сибелешеп, иңнәренә төшкән. Нәфис колак яфракларында түгәрәк алтын алкалар ялтырый. Аның нурлы йөзендә, сыгылмалы, сылу гәүдәсендә, гомумән, бөтен кыяфәтендә сүз белән генә әйтеп бетергесез ниндидер нәфислек, нәзакәтлелек чагыла. Бу ханымның исемен Татарстанда гына түгел, бүтән республикаларда да яхшы беләләрдер. Ул — Рада Хөсәеновна Нигъмәтуллина, беренче татар хатын-кыз скульпторы. Аның коңгырт күзләрендә соңгы шәфәкъ нурлары уйный. Күзләрендә — уйчанлык. Ханымның карашы бик еракка, офыкларга таба, шул тарафларга китеп барган «Татарстан» поездына юнәлгән. Поезд аның кече кызы Маринаны Мәскәүгә, СССР Художество академиясенең В. И. Суриков исемендәге институтына скульпторлыкка укырга алып китте. Ананың йөрәге сызланмыйммы, сызмыймы соң мондый чакта! Бу вакыйга аның күңелендә хисләр давылын куптарды. Бераздан ул, тәмам күңеле нечкәреп, тойгылар иркенә бирелде.

«Кызым, балам, дәвамым минем...— дип уйлады ул бик нык дулкынланган хәлдә.— Син, балам, мин йөргән сукмаклардан, минем эзләрем буйлап атларсың. Мин караган күккә минем күзләрем белән багарсың. Мин эшләгән остаханәдә иҗатның газабын да, ләззәтен дә татырсың, насыйп булса...»

Кичке җылы җил аны тулы, йомшак иңнәреннән кочты. Әллә үзенчә юатмакчы, әллә йөрәк серен белмәкче булды?! Әмма ханым бу тымызык җилнең иркәләвен сизми дә иде кебек. Ә күңелендә моңлы бер көй бөреләнеп, туып килә. Әллә сагыш, әллә әрну, әллә юксыну...

Ниләр генә көтә икән аның сөекле кызын олы гомер юлында? Хәер, ул бит инде сабый бала түгел, аңа инде егерме яшь тулды. Ә менә аның үзенә, Радага әнисеннән аерылып, туган авылы Балчыклыдан бөтенләйгә чыгып киткән чакта әле унбиш тә тулмаган иде ләбаса. Ул да шулай, укырга дип, Казан каласына килгән иде. Өстендә — сырма, башында — чуклы соры шәл, аякларында — калош. 1946 елда булды бу хәл. Сугыштан соңгы авыр бер чорда. Ярый әле Казанда якын туганнары яши иде. Әнисенең бертуган сеңлесе, Татар дәүләт академия театры артисткасы Галия апасы Нигъмәтуллина белән аның тормыш иптәше Хәким ага Сәлимҗанов дөнья күрмәгән яшь кызны шунда ук үз канатлары астына алдылар.

«Мәрхәмәтле, киң күңелле кешеләр...»— дип уйлый Рада Хөсәеновна Казан елгасы ярларына таба атлый-атлый. Ерак хатирәләр, җанлангандай, аның күз алдына килеп баса...

* * *

...Әле генә кайтып кергән Хәким ага, аш бүленергә өлгермәгән чип-чиста тәлинкәләрне күреп, шаян гына елмаеп куйды:

— Син, әнкәсе, кадерле кунакны әллә инде татлы сүзең белән генә сыйларга уйлыйсыңмы?..

Галия ханым, шаяртып сөйләнә-сөйләнә, пилмән бүлергә керешкән иде, кемдер итагатьле итеп ишек шакыды.

— Әйдәгез, әйдә, дуслар өчен ишек һәрвакыт ачык! — диде Хәким ага көр тавыш белән.

Рада кунакны бер мәл зур игътибар белән карап торганнан соң, аның бүтән кешеләрдән ни беләндер нык аерылганын, гадәти-гади генә кеше булмаска тиешлеген тойды. Бу кешенең гаять килешле, тигез маңгаенда — уйчанлык һәм сабырлык. Куе кашлары арасына яткан тирән сыр аның бөтен уй-фикерләрен яшереп саклый сыман. Ә күзләре... Раданың моңарчы әле беркемдә дә андый күзләрне күргәне юк иде бугай. Ниндидер шатлыклы сагыш чагыла иде бу күзләрдә. Сизгер борын яфракларын, мәһабәт ягенә таба сызылып төшкән ике җыерчыкны, ачса, «кош очып чыгардай» нәфис иреннәрне күңеленә сурәтләп өлгерде Рада.

— И Салих дус, син икәнсең әле! — дип шатланды йорт хуҗасы.— Мактап кына йөрисең икән! Әйдүк, түрдән уз, менә монда, бирегә утыр. Менә, кадерле сеңлебез Раданың килүе хөрмәтенә пилмән дә бөккән идек әле. Әйдә, җитеш, авыз ит...

Әмма кунак утырырга ашыкмады. Иң элек зур ихтирам белән Радага ике кулын сузды. Аның куллары йомшак һәм җылы иде. Бармаклары нәфис, нечкә, гаять җанлы... Аның учлары арасында Раданың нәни генә кулы кечкенә кош сыман югалды да калды. Мәрхәмәтле куллар... Тыңдашсез куллар...

«Исәнмесез! Мин Салих Сәйдәшев булам»,— дигән тавыштан Рада сискәнеп китте. Аның шундый сәеррәк тоелган бер гадәте бар: вакыт-вакыт ул онытылып, хыялында туган күренешләргә яки истәлекләргә бирелеп, бераз дәшми тора.

Әйтәсе килгән бик күп сүзләр тел очында гына тибрәнеп торса да, әйтә алмады Рада. Бары тик кыяр-кыймас кына: «Рада»,— дип пышылдады. Шуннан соң Салих Сәйдәшев нәкъ Раданың каршысында торган урындыкка ашыкмый гына килеп утырды...

Кыз әле бүген генә аерылышкан туган авылын исенә төшерде. Тал яфракларының шыбырдашуында, чишмәләрнең, җаннарны иркәләп, челтер-челтер агуларында Сәйдәш моңнарын ишеткән икән бит ул ләбаса! Ул моңа кадәр шушы моңнарга исем генә таба алмый йөргән икән бит!..

Рада, ниһаять, уйларыннан арынып, олыларның сөйләшүләренә колак салды.

— Кичә. Төнлә белән...— Сәйдәшнең тавышы нечкә җептәй өзелергә җиткән сыман иде. Сүзләреннән дә бигрәк, бу әрнүле тавышның авазлары тетрәндерде нечкә күңелле кызны. Кинәт кенә Сәйдәшнең коточкыч олы кайгысы барлыгын аңлап алды ул.— Мәктәптә балалар шукланып ишекне кинәт ачып җибәргәннәр. Ишек улымның башына бәрелгән... Аңын югалткан, балакаем... Шуннан соң больницага илткәннәр. Һушына да килә алмады... Ярый әле кичә төнлә сакларга үзем барган идем. Үз кулларымда...— Сәйдәшнең тавышы кинәт өзелде. Ул, сабырлыгын җуеп, ике кулы белән йөзен каплады да өстәл өстенә иелә төште. Кечкенә улы Эмильнең үлем белән тартышып яткан минутлары күз алдына килдеме икән, колагына сабыйның әрнүле ыңгырашулары ишетелдеме икән?.. Өстәл артында утырганнарның берсе дә аңа сүз катарга җөрьәт итмәде.

Шуннан соң Сәйдәш озак утырмады. Салган ашына да кагылмыйча, Хаким агага: «Әйдә әле, бәгырь, урап керик әле»,— диде дә чыгып китте.

* * *

Раданың, төнлә урын өстенә яткач та, күзенә бик озак йокы кермәде. Авыр гына йөзеп барган каракучкыл болытлар арасыннан вакыт-вакыт күренеп киткән айга карап ятты. Айның йөзе нигәдер бик сагышлы булып тоела иде аңа.

Янәшәдәге койкада яткан Галия апасы да йоклый алмый иде, ахрысы. Аның зур итеп ачылган күзләрендә әледән-әле ай нурлары чагылып ялтырый иде.

— Галия апа,— дип әкрен генә эндәште аңа Рада бераздан.— Сез дә йокламыйсыз бугай әле?..

— Юк, бала, йокламыйм,— дип җавап кайтарды Галия ханым йомшак тавыш белән.— Бар йокыларым качты әле,— дип өстәде бераз дәшми торганнан соң.

— Минем дә күңелем ни өчендер шомлана,— дип әйтеп куйды Рада.

Күктәге ай да, болытлар да, гомумән, бар табигать тә аның белән бергә шомлана, гасабилана иде шикелле. Авыр болытлар Төньяк боз океанында йөзгән мәңге эремәс айсбергларны хәтерләтә иде аңа. Алар, әллә кайдан, офык артыннан күтәрелеп, таулардай ишелеп-ишелеп, бер-берсенә бәрелешә-бәрелешә аның өстенә килә күк. Менә хәзер аның өстенә аварлар да аны сытарлар, юк итәрләр сыман.

Кызның йөрәге куркудан, шартлаган шар сыман, шиңеп, убылып төшә шикелле. Ул үзен бик тә көчсез, хәлсез, мескен итеп хис итә башлый. Шул чагында кайдадыр бик якында, янәшәдә генә үзәк өзгеч көй ишетелә.

— Салих абыең скрипкада уйный,— ди Галия ханым әкрен генә, авазларны «куркытмаска» тырышкандай.

Рада бөтен җаны белән музыка иркенә бирелә. Тирә-юньдәге бар нәрсә эреп юкка чыга, бары тик шул гүзәл музыка гына, күкләргә кадәр ашып, бар җиһанга тарала.

Раданың күз кабаклары авырайганнан-авырая бара. Керфекләре йомыла. Ул җәйге җылы көндә диңгездә коена икән. Кояшка таба йөзә, ә аннары, арып-талгач, кулларын киң җәеп, күк йөзенә карап ята. Ә дулкыннар аны тирбәтә-тирбәтә, әллә кая, әкияти гүзәл дөньяга алып китә...

* * *

Татарстан урамында урнашкан сиксәненче мәктәп бинасы. Икенче каттагы 8 «А» классының уку бүлмәсе. Рәсем дәресе бара.

Рада, карандаш очын тешләп, карашын тәрәзәгә төбәгән килеш уйга талган. Күктә үтә күренмәле җиңел болытлар йөзә... Әбиләр чуагының соңгы көннәре! Тәрәзә пыяласына сарышып торган тупылның сары яфраклары, табигать симфониясенә кушылып талгын гына шыбырдаша. Җил искән саен бер талпыну, бер омтылыш... һәм шунысы кызыклы: кабатлану юк табигатьтә. Ә шул ук вакытта нинди бердәмлек, нинди гармония!

Рада портрет ясый. Иң элек ул очлы карандаш белән ватманга түгәрәк йөзнең рәвешен билгеләп куя. Бераз кабарыбрак торган бит урталарындагы күләгәләрәк урыннарны икенче, йомшак карандаш белән буйый. Бит алмаларында якты таплар калдыра. Рада, исендә калган сурәт буенча, Сәйдәш портретын ясый... Иң кыены — күзләр икән. Күзләрдәге сагышны бирә алмый изаланды. Куе кашлар... Кабарынкы авыр кабаклар... Күз төпләрендәге тирән уелмалар...

Ничек итеп күрсәтергә соң күз алмасы үзәгендә яшеренеп яткан сагыш чаткысын?! Әллә иң эчтә янган ут бөртегендәме ул? Әллә күз читендә җемелдәгән бер бөртек күз яшендәме?

Рада композиторның күпереп торган чәчләрен ясый. Табигатьтәге иң нечкә авазларны да ишетә торган нәфис колакларын. Шуннан соң башын бераз арткарак ташлап, портретка караш сала. «Ә шулай да нидер җитешми монда,— дип уйлый ул канәгатьсезлек хисе белән.— Рәсем ни өчендер җансыз чыккан. Тормыштагы сыман түгел».

Кызның үз-үзенә ачуы чыга. Ул кәгазь битен кулына ала, ертмакчы булып, кискен бер хәрәкәт ясый. Әмма шул чагында укытучы, йомшак кына орынып, аны туктата.

Раданың коты оча. Укытучы аны шелтәләр, бик күп төзәтмәләр ясар дип курка ул. Ләкин...

— Яхшы, бик яхшы!..— ди укытучы көтмәгәндә. Кызның тәненә җылы йөгерә. Аннары укытучы, үзенең өстәле янына үтеп, портретны бөтен класска күрсәтә.— Нигъмәтуллина күренекле композиторыбыз Салих Сәйдәшевнең сурәтен төп-төгәл, нәкъ тормыштагы шикелле итеп бирергә омтылмаган, ягъни копия ясамаган. Талант иясенең образын ул үзенең күңел күзе белән күргәнчә тасвирлап бирергә тырышкан. Дөрес, бу портретның кимчелекләре дә җитәрлек әле. Ләкин укыган, махсус белем алган очракта, сез, Нигъмәтуллина, андый кыенлыкларны гына җиңәрсез дип ышанам...

Укытучының, профессиональ рәссамның әлеге мактау сүзләре яшь кызның күңелен үстереп җибәрә, үз-үзенә ышанычын бермә-бер арттыра, уйланырга этәрә. Димәк, аның сәләте бар. һәм ул аны аңлы рәвештә үстерергә, аны баету өстендә даими рәвештә эшләргә тиеш!..

Шушы уйланулар, тора-бара, яшь кызны төпле бер фикергә китерде, алдан ук аның киләчәк язмышын билгеләп куйды. Шул дәрестән соңгы көннәрне кызның йөрәге бер теләк, бер максат белән талпынды; күңелендә яшәгән Сәйдәшнең якты сурәтен чын рәссамнарча гәүдәләндерәсе килә иде аның. Ә моңа ирешү өчен бер генә юл — художество училищесына укырга керү юлы гына бар иде. һәм Рада, бар тырышлыгын туплап җиң сызганып, эшкә керешге: уйланды, эзләнде, Сәйдәш портретының дистәләрчә эскизларын ясады. Ниһаять, теләгенә ирешге.

Кадерле кызын беренче уңышлары белән котларга дип авылдан әнисе, Гөлсем апа да килеп җитте һәм шул килүеннән бүтән китмәде, бөтенләйгә Казанда яшәргә калды. Авыр уку юлларында кызына бераз ярдәме тияр дип уйлады бугай ана.

* * *

Көннәрдән бер көнне хуҗаларның кызлары Гадилә көньяктан ике баласы белән кунакка кайтып төште. Фатирдагы ике нәни генә бүлмә шыгрым тулды. Аяк басарлык урын калмады. Шул көннәрнең берсендә аларга Сәйдәш сугылды.

— Сәлим,— диде ул (ул Хәким абыйны яратып, үзенчә «Сәлим» дип йөртә иде).— Синең өең тулай торакка әйләнде бит. Инде ни эшлисең, бәгырь?

— Белмим инде, Салих дус,— дип җавап бирде Хәким ага нык каушаган кыяфәттә.

— Алай булса, Сәлим,— диде Сәйдәш тәвәккәлләп,— мин үземнең бер бүлмәне бирәм. Без Асия ханым белән икәүдән-икәү яшибез, безгә калган бүлмә дә бик җиткән. Ә син Гөлсем апа белән Раданы шунда урнаштырырсың.

Хәким ага аптырабрак калды:

— Рәхмәт, Салих, бу яхшылыгыңны мәңге онытмам,— дия генә башлаган иде.

— Ярый, остарма инде, бәгырь,— дип бүлдерде аны Салих абый йомшак кына.

Шулай итеп Радалар Салих абыйларына күченделәр дә куйдылар.

Сәйдәш фатирының ишеген тәүге мәртәбә Рада изге бер тойгы белән ачып керде. Пакьлек, сафлык хөкем сөрә иде монда. Сулаулары да ничектер җиңел иде биредә.

Киң, кәрән төстәге идән такталарына сак кына басып, алар йокы бүлмәсе һәм уң якта калган зал ишеге буеннан үз бүлмәләренә үттеләр. Бер тәрәзәле кечкенә генә бүлмә иде бу. Тәрәзәсеннән, уч төбендәге кебек, театрның фойесы күренеп тора. Тәрәзә театрның стенасына терәлеп диярлек торганга күрә, кояш монда бөтенләй дә карамый, ахрысы. Биредә тимер караватъ, бизәкле клеенка капланган дүрт почмаклы өстәл, аркалары сорнайга охшатып ясалган ике урындык һәм арты белән мичкә үк терәтеп куелган савыт-саба буфеты — бөтен булган җиһаз шул иде.

Гөлсем апа төенчекләрне ашыкмый гына чиште дә бүлмәне үзенчә бизи башлады. Шулай итеп, Сәйдәш бүлмәсендә яңа тормыш башланып китте.

* * *

*Син минем җан сердәшем,*
*Җан моңдашымсың, мандолин!...*
Ш. Бабич

Кышкы озын кичләрнең берсе. Мичтә чарт-чорт итеп каен утыны яна һәм әкрен генә мандолина чирткән тавыш ишетелә. Гөлсем апа уйный, ә Рада, аны тыңлап, өстәл артында утырган килеш эскизларын караштыргалый, ара-тирә карандашы белән ватманга сызгалый, Сәйдәш портретына яңа чалымнар өсти. Ул да түгел, итагатьле генә ишек шакыган тавыш ишетелә. Бусагада Сәйдәш үзе күренә. Кулы белән, «Борчылмагыз, дәвам итегез», дигәндәй бер хәрәкәт ясап, аяк очларына гына баса-баса, бераз бөкрәя төшеп, түргә уза, әкрен генә, йоклаган сабый баланы уятырга курыккандай, почмакта торган утыргычның иң кырыена утыра да уйга чума, тынып кала.

Ә моң агыла да агыла. «Әллүки, бәллүки...» Сәйдәш аны бирелеп, сихерләнеп тыңлый. Абажурдан төшкән тонык ут аның моңсу күзләрен яктырта. Аларда тулы бер язмыш чагыла сыман. Сәйдәшнең үз язмышы гына түгел, ә бәлки әлеге моңлы көйне гасырлар буе үз йөрәгендә саклаган халык язмышы күренәдер шикелле.

Рада Сәйдәштән күзен алмый. Менә Раданың күзләренә яшь пәрдәсе төшкәндәй була. Уйланып утырган Сәйдәшнең гәүдәсе кинәт ерагая, зурая, һавага күтәрелә башлагандай тоела, якты бер сурәткә әверелә.

Рада ярым саташулы бу ләззәтле хәленнән айныган чагында Сәйдәш инде һәрвакыттагыча тавышсыз-тынсыз гына чыгып киткән була. Ә Раданың күңелендә әйтеп бетерgесез татлы бер хис сакланып кала. Ул хисне башкаларга да җиткерәсе килә. Әмма ничек итеп? Моның өчен нинди-дер үтә йомшак, үтә җанлы материал табарга кирәк? Нинди материал икән? Шул чагында Балчыклы авылындагы чишмә — зәңгәр күзкәйнең төбендә яткан ап-ак йомшак балчык исенә төшә аның. Һәм ул дәртләнеп, канатланып китә. Әйе, әйе, бары тик ул гына әйтеп бирә алыр күк аның күңелендә яңгыраган моңны! Чөнки моң үзе дә чишмә кебек бит. Кайнар бер чишмә шикелле.

* * *

Рада училищеда әйбәт кенә укып йөрде. Әмма аның күңелендә һаман ниндидер канәгатьсезлек хисе яши иде. Нидер җитми иде аңа, җаны һаман нидер эзләнә иде. Кайчакларда ул, үзенә-үзе тынгы таба алмыйча, шәһәр урамнарына чыгып китә, ярсу йөрәген тыярга теләп, мәйданнарда онытылып йөри иде. Аның күңелен кинәт әллә нинди хыяллар биләп ала, өермәдәй, аны үз иркендә бөтерә башлый. Моның нинди галәмәт икәнен әле ул үзе дә ачык кына белми иде.

...Беренче курсны тәмамлап йөргән вакытлар иде. Көннәрдән бер көнне аларның аудиторияләренә Художниклар союзы идарәсе председателе, татар халкының беренче скульпторларыннан булган Садри ага Ахун килеп керде. Һәм ул, студентларга мөрәҗәгать итеп, болай диде:

— Иптәшләр, тиздән безнең училищеда скульптура бүлеге ачылачак. Сезнең курстан шунда күчәргә теләүчеләр юкмы?

Рада шунда ук үзенең күңелендә ниндидер киеренкелек сизде. Ничәмә-ничә ел күңеленең иң яшерен почмакларында җыелып килгән билгесез хисләр хәзер кинәт

давыл булып куптылар. Менә бит ул — әле үзе дә ачык аңлап бетерә алмаган теләк! Менә ул — киләчәк зур бәхет юлы!

Рада кулының ничек күтәрелгәнен үзе дә сизмәде.

Аудиториядә нигәдер тып-тын иде. Ул иптәшләренә борылып карады. Җиде кул. Җидесе дә — егетләрнеке. Кызлар арасыннан — ул берүзе. Рада кинәт уңайсызланып китте. Кулын төшерергә дә, төшермәскә дә белмәде.

— Әйе,— диде Садри Ахун бераз уйланып торганнан соң.— Бу, билгеле, хатын-кыз эше түгел. Шуның өстенә, бик зур физик көч тә таләп итә. Измәне, кулларыңны батырып, изәсе бар. Каркасларны да үзең бөгәсең. Шуңа күрәдер, бездә әле бер генә дә хатын-кыз скульптор юк.

«Ә русларда Голубкина, Мухиналар бар бит...»— дип уйлап куйды Рада. Билгеле, гадәти түгел иде бу омтылыш. Аны аңламаулары да бик ихтимал. Ә шулай да, бер күтәргән кулны төшерергә теләмәде Рада. Ни булса, шул булыр, диде ул, тәвәккәлләп.

* * *

Садри ага Ахун кызның сәләтенә аеруча игътибар иткән иде, ахрысы. Ул аны үстерүгә үзеннән зур тырышлык куйды. Гомуми дәресләр белән генә канәгатьләнмичә, һәр көн саен диярлек Раданы махсус рәвештә бер-ике сәгатькә калдырып эшләтә торган булып китте. Кызның эшчәнлеге, тырышлыгы охшый иде булса кирәк аңа. Ул аның иҗат иткәнен сәгатьләр буе күзәтергә ярата иде.

Кыз да, билгеле, үзенә карата бу җылы мөнәсәбәтне бик тиз аңлап алды һәм остазының һәр сүзен күңеленә сала барды. Аның үз сүзләре тәҗрибәле сынчының фикерләре белән аваздаш икәнен белгәч, көннәрдән бер көнне ул аңа үзенең иң изге серен чиште: аның Сәйдәш сурәтен ясыйсы бик килә. «Мөмкинме бу?»— дип сорады ул остазыннан.

— Нигә мөмкин булмасын. Бик мөмкин,— диде Садри ага.— Әмма... агач биегрәк үскән саен аның тамырлары киңрәк, тирәнрәк җәелә бара. Шуңа күрә күңелеңдә туган иң изге, иң кайнар хисләрне ташка күчерә алырлык дәрәҗәгә үсәр өчен би-ик күп тырышлык кирәк булачак.

Һәм Рада тырышты... Сәгатьләр буе ул Сәйдәшнең бюсты өстендә эшләде. Маңгаена тир бөртекләре бәреп чыкты, ә ул аларны сөртергә дә онытты. Бармак очлары оеп, берни дә тоймас хәлгә җитә иде. Кулларына юеш балчык сарыла, торган саен ул авырая, авырая бара иде. Әмма Рада бирешмәде. Әмма озак эшләгәнлектән, аның күз аллары караңгылана башлый иде. Шул чагында Садри ага, аның янына килеп, иңенә кулын сала да аталарча җылы тавыш белән:

— Аргансыңдыр, бар кайт инде,— дип әйтә иде.

Рада җыена да саубуллашып чыгып китә. Ә Садри ага Ахун әле генә төгәлләнгән Сәйдәш бюстының яңа бер вариантына текәлеп карап тора башлый. «Кайдан килгән бу яшь кызның йөрәгенә шулкадәр моң? Кайда аның чыганагы?»— дип уйлый ул гаҗәпләнеп.

* * *

Рада Хөсәеновна, ул көннәрне уйлап, көлемсерәп куйды. Ничек җөрьәт итте икән ул шул чагында Сәйдәшнең бюстын натурадан ясап, аннары аны Сәйдәшкә илле яшь тулган көндә сәхнәгә, халык алдына чыгып, композиторның үзенә бүләк итәргә? Халык гөрләтеп кул чапса да, Сәйдәш үзе дә бала сыман куанса да, ул бит әле бары тик өйрәнчек кенә әсәр булгандыр. Ә менә шуннан соң озак еллар үткәч ясалган Сәйдәш бюсты — (ул хәзер Татарстан сынлы сәнгать музеенда) чыннан да сәнгать әсәре дип атап буладыр, мөгаен.

...Ул Казан елгасы буенда агымсуга карап тора иде. Әнә еракта ак җилкәнле көймә күренде. Рада иске бер танышын, дустын күргәндәй булды. Үткәннәрдәге бер хатирә, кинәт исенә төшеп, ак җилкәндәй күңеле буйлап йөзеп үтте...

* * *

Бармакларын чыныктырыр, эшкә өйрәтер өчен Радага бик күп күнегүләр ясарга кирәк иде. Ләкин моның өчен натурщигы юк иде. Дөресрәге, натурщигы да табылыр иде, әмма түләр өчен акчаны каян аласың?! Рада шулай да әмәлен таба. Өйдә беркем дә юк чакны туры китереп, залга кереп бикләнә дә, трельяжга карап, үзенең сынын ясый башлый. Әмма изүләре ябык озын җиңле күлмәк аңа комачаулый. Ул сәдәфләрен

чишеп җибәрә, җиңнәрен кайтарып куя. Яшь кыз, онытылып, иҗат итә. Ә ят күзләрнең аны каршыдагы театр тәрәзәсеннән күрергә мөмкин икәнен онытып җибәрә. Кыз моны сизми, ул хыял иркендә йөзә...

Икенче көнне Рада әле генә кайтып кергән Сәйдәшнең әнисе белән коридорда йомшак кына сөйләшүен ишетә.

— Гөлсем апа,— ди Сәйдәш.— Минем залда пәрдәләр юк иде бит. Әлегә кадәр мин моңа ничектер бер дә игътибар итмәгәнмен, ахрысы. Ә менә хәзер күземә чалынды. Шушы ак бәздән бүлмәгә пәрдәләр тегеп куймассызмы икән?— дип ул Гөлсем апага бер төргәк суза.

Шулай итеп Салих абыйсы Раданың күңеленә илһам иңгән изге минутларын чит-ят күзләрдән томалап куя. Ак пәрдәләр, ачык тәрәзәдән кергән җилдән җилкәндәй киерелеп, аның илаһи мизгелләренә дәрт бирәп торды...

* * *

Ленинградта декабрь салкыннары... Художество академиясенең тулай торагына кайтып җиткәнче Рада бик нык туңды. Тулай торакның биек баскычыннан йөгерә-йөгерә менде. Сумкасын урындыкка куеп, пальтосын сала гына башлаган иде, өстәлдә яткан конвертны күреп алды. Кулына алгач, аның Казаннан икәнен белде. Күптән язмаган иде әнисе. Ниләр бар икән?

«Кызым, сине борчымам дигән идем дә... Язмыйча булдыра алмыйм. Менә үзем язам, ә үземнең күз яшьләрем мөлдер-мөлдер хатыма тама. Нәрсә язганымны үзем дә рәтләп күрмим.

Салих абыең авырый дип язган идем бит мин сиңа. Бераздан, син Ленинградка укырга киткәч, аның авыруы тагын да көчәйде. Дуслары аны җыйнаулашып Мәскәүгә дәваланырга җибәрергә булдылар. Сәйдәшне юлга озатырга бик күп кеше килде, язучылар, артистлар... Хушлашканда Сәйдәш аларга Муса Җәлил сүзләренә язылган иң соңгы әсәрен — «Җырларым»ны уйнады...

...Нык бул, кызым! Казанда бик авыр кайгы бар бит әле. Салих абыең... Син бит аны бик ярата, якын күрә идең... Ул... юк инде...»

Раданың йөрәге туктап калгандай булды, күзләрен яшь пәрдәсе томалап алды. Үкси-үкси ул мендәренә йөзтүбән капланды. Гүя аны кара упкын йотты...

...Кемдер аның җилкәсенә орына, чәчләрен сыйпый иде. Бүлмәдәш кызлары икән. Кызлар да тып-тын калганнар.

— Кемең иде соң ул синең? Әтиең идеме әллә?— дип сорады берсе кыюсыз гына.

Авыр хәсрәт Радага сүз әйтергә дә ирек бирмәде... Хәер, кем дип әйтсен ул Салих абыйсын? Кем?.. Бу сорауга җавабын ул гомере буе эзләячәген инде хәзер үк сизенә иде.

* * *

«Сәйдәш юк инде»... Әлеге хакыйкать белән бер дә килешәсе килми иде Раданың. Ул һаман, тере килеш, гел аның күз алдында басып тора иде сыман. Төннәр буе йоклый алмый изаланды Рада. Бары тик бер теләк, бер максат яшь аның йөрәгендә: Сәйдәшне күрү теләге.

Менә бүген дә, бик озак йоклый алмыйча ятканнан соң ул өстенә сырма бирканде дә (әле колхоздан, бәрәңгедән кайтып кына кергәннәр иде), остаханә ачкычларын алып, төн уртасында тулай тораклан чыгып китте.

Аларның укытучы-остазлары Михаил Константинович Аникушин бик мәрхәмәтле һәм ярдәмчел кеше иде: курсташы һәм якын дусты (соңыннан ул аның гомерлек тормыш иптәше дә булды) Виктор Рогожин белән икесенә үзенең эш бүлмәсенең ачкычларын бирәп торды.

Остаханәдә Рада өстәл тартмасыннан капшанып кына бер шәм тапты һәм, кесәсеннән шырпы алып, ут кабызды. Рада үзен тирән бер мәгарәдә сыман хис итте. Ул еш-еш сулый, бит алмалары уттай яна, күзләрендә ялкын телләре уйный иде. Шәмне янәшәрәк урнаштырып, ул ашыга-ашыга (әйтерсең, кемдер аның артыннан куа иде) балчык изәргә кереште.

Менә, бар көчен туплап, шактый ук юан тимерчыбыктан каркас ясады. Аның бөтен уйлары бер утлы ноктага тупланган иде хәзер. Күз алдында бер-бер артлы җанлы картиналар туа торды. Сәйдәшнең һәр хәрәкәтен, ишарәсен күрә, һәр сүзен ачык ишетә иде күк ул хәзер.

Рада, үзен-үзе белештермәгән хәлдә, каркаска балчык тутыра башлады. Аннары сынны ясарга кереште. Менә Сәйдәшнең күкрәге. Дөп-дөп тибеп торган ярсу йөрәк. Раданың бармаклары хәтта аны тоя да кебек. Менә аның киң җилкәсе, баһадир төз сыны. Менә ул Салих абыйсының киң һәм якты маңгаен ясый. Киеренке рәвештә бөгелеп киткән кашлар. Авыр күз кабаклары бераз йомыла төшкән, алар гүя күзләрдәге уй-хисләрне

яшереп калырга тырышалар. Нинди генә кичереш-тойгылар чагылмый аның күңел көзгесе — күзләрендә. Ничек итеп күзләренең зәп-зәңгәр төсләрен, карашларының җылысын таштa күрсәтергә икән?! Ничек итеп?

Менә аның клавишларда йөгереп йөргән, дирижер таякчыгын серле итеп тоткан нечкә озын бармаклары. Рада ике аккош сыман очып йөргән ап-ак кулларны күз алдында күргәндәй була. Ә Сәйдәш тыныч. Ул нидер тыңлап утыра. Әллә яңа гына күңелендә шытып килгән музыкасына колак сала инде?!.

Төн узганны сизми дә калды Рада. Төне буе, иләсләнеп, эшләп чыкты. Һәм, ниһаять, таң атканда сын әзер булды.

Рада, аруыннан егылырга җитешеп, бетон идәнгә сырмасын җәя дә, бар дөньясын онытып, тирән йокыга китә. Ул бу төндә ап-ак бөркетне, иркенлеккә чыгарып, биек күкләргә очырганын белми әле.

• • •

...Рада Хөсәеновна шәһәрнең борынгы өлеше белән яңа өлешен тоташтырган Ленин күперенә аяк басты. Аның күңелендәге хәтер күпере дә үткәннәре белән киләчәген тоташтыра иде кебек.

Шуннан бирле утыз ел чамасы узып та киткән ләбаса... Ничек яшәде, ниләр кылды соң ул Рада шушы вакыт арасында?

Сәйдәш белән янәшә бары тик биш кенә ел яшәсә дә, бу чор аның бөтен гомерен дә, иҗат юлын да билгеләде түгелме соң? Әйе, Рада күп әсәрләр иҗат итә алды шушы утыз ел дәвамында. Уңышлары да шактый булды.

Рада Хөсәеновна үзе тудырган әсәрләрне хәтереннән барлады: «Дөньяда тынычлык кына була күрсен», «Бишек җыры», «Әллүки», «Әпипә», «Хәтер», «Хуҗа Насретдин»— татар халкының сөекле уллары Габдулла Тукай, Муса Җәлил, Һади Такташ, Абдулла Алиш һәм Салих Сәйдәшевнең бала чакларын тасвирлаган скульптура портретлары. Алар Казанда гына түгел, ә бәлки башкалабыз Мәскәүдә дә, кайберләре хәтта чит илләрдә оештырылган күргәзмәләрдә дә күрсәтелде. Ул ясаган һәйкәлләр шәһәр мәйданнарында да калкып чыкты.

Ә хәзерге вакытта ул Җәлилчеләрнең образлары өстендә эшли. Татар дәүләт академия театрының яңа бинасы өчен берничә скульптура әзерли.

Яңа әсәргә алынган чагында ул, гадәттә, күңелендә ниндидер моңлы бер көй туып килүен сизә. Бу көй Сәйдәш музыкасыннанмы?

Рада Хөсәеновна Сәйдәшнең якты истәлеге алдында үзен чиксез бурычлы итеп тоя. Бәлки шуңа күрәдер дә иптәше Виктор Рогожин белән бергәләп, Салих Сәйдәшевнең образы өстендә эшләвен дәвам иттерә. Озакламый ике кызлары, ике яшь скульптор да бу эшкә кушылып китәр дип ышана ана күңеле.

...Рада Хөсәеновна күпер аша киң урамнарга чыкты. Бу көнне ул үзенең гомер күперен кичеп чыкты шикелле. Үткәннәрнең хатирәләре, якты йолдыз булып, аның киләчәккә барыр юлын яктыртты.

**Фирдәвес ӘҺЛИУЛЛИНА.**



# ФИДАКАРЬЛЕК

*Күптән түгел күренекле әдибебез һәм галимебез Нәкый ага Исәнбәткә 85 яшь тулды. Шул уңайдан бер төркем яшь язучылар Н. Исәнбәт белән очраштылар. Аксакал әдибебез яшьләрнең күп сорауларына җавап бирде. Түбәндә шул әңгәмәнең язмасы һәм әдип-галимебезнең яңа басылып чыккан «Балалар фольклоры» исемле хезмәтенә рецензия урнаштырыла.*

**Сорау:** Нәкый ага, яшь иҗат көчләренә Сезнең нинди теләкләрегез бар?

**Җавап:** Билгеле, бер очрашуда гына бар теләкләрне әйтеп бетереп булмас. Шулай да кайберләренә булса да тукталып үтим. Иң беренче чиратта, вакытны бушка уздырмыйча, көчне вак-төяккә сарыф итмичә, мөмкин кадәр зуррак, ягъни актуальрәк, мөһимрәк эшләргә алынырга иде. Ә эшлисе эшләр бик күп әле безнең алда. Шулардан берсе — халкыбызның тарихын, әдәби мирасын өйрәнү һәм пропагандалау мәсьәләсе. Моңа игътибар итүемнең сәбәбе шунда: кайвакытта яшь авторлар тарафыннан иҗат ителгән әйберләрне укыйм яки карыйм да уйга калам. Уйланырга, хәтта борчылырга да сәбәпләр җитәрлек. Кайбер очракларда тегә яки бу авторның мәдәниятебез тарихыннан бик аз яки, гомумән, хәбәрдар булмавы ачыклана. Моның объектив һәм субъектив сәбәпләре күптер, әлбәттә. Ләкин алар киләчәк гасырда да яшәячәк һәм иҗат итәчәк кешеләр бит. Һәм алар күп гасырлы әдәби мираска, бөтен халык иҗатына хуҗа булып калачаклар. Бу хәзинәнең язмышы турында уйлыйм да, сорау туа: яшьләребез кадерен белерләрме икән аның, үзләреннән соң килгән буыннарга да илтеп җиткерә алырлармы?

Халкыбызның катлаулы тарихына, әдәби мирасына мөнәсәбәт яшьләр иҗатында төрлечә чагылыш таба. Мәсәлән, кайбер шагыйрьләребез әсәрләрендә патриотизм хисләрен, ягъни туган илгә, телгә һәм халыкка мәхәббәт кебек олы төшенчәләрне «Безнең бабайлар — «болгарлар!» дигән тезиска гына кайтарып калдыралар шикелле. Бабаларыбызның борынгы болгарлар, төгәлрәк әйткәндә «анабыз болгар, атабыз кыпчак» икәнен һәрвакыт истә тоту — әлбәттә, күркәм, кирәкле сыйфат. Әмма болай декларатив рәвештә әйтү генә әле бик аз. Мондый төшенчәләрнең бөтен тирәнлегенә җитеп, киңлеген иңләү, шуларны укучылар күңеленә уйдырып салу өчен шигъри штамплар гына да җитми. Бу олы юлда фикерләр иң элек һәр иҗатчының үз йөрәге аша чыккан хис һәм белемгә нигезләнгән айнык акыл белән сугарылган инану, дөресрәге, шушы ике көчнең бердәмлегә булырга тиеш. Шушы инануы булганда гына иҗатчы халык күңеленә юл табар дип уйлыйм.

Халык авыз иҗатын, әдәби мирасны өйрәнү, әлбәттә, үзмаксат түгел. Бу безнең хәзергебез һәм киләчәк көннәребез өчен кирәк. Фикеремә иллюстрация рәвешендә бер генә мисал китереп үтим. Менә Т. Миңнуллинның «Кәрлә — мәктәп баласы» исемле балаларга атап язган әкият-пьесасы. Беренче карашка гадәти әсәр кебек: шул ук Убырлы карчык, Дию, Шүрәлеләр... Ләкин халык әкиятләренең бу «штатный геройлары» борын заманнарда түгел, ә безнең чорда яшиләр һәм авторның ихтыяры белән безнең заманга хас уй-фикерләрне, безнең өчен мөһим эстетик идеалларны балалар күңеленә салуга хезмәт итәләр. Әгәр драматург мифологияне, халык авыз иҗатын белмәсә, шуларны җентекләп өйрәнмәсә, һичшиксез мондый әсәрне иҗат итә алмаган булыр иде.

**Сорау:** Язучы буларак Сез аеруча драматургия өлкәсендә халкыбызның мәхәббәтен казандыгыз. Шул уңайдан драматургиягә килүегез турында бер-ике сүз әйтмәссезме?

**Җавап:** Драматургия өлкәсендә җиң сызганып эшләүгә, икенче төрле әйткәндә, социаль заказ этәрде дип уйлыйм. Һәм бу ул вакытларда, ягъни егерменче елларда бик табигый иде. Чөнки Октябрь революциясенең беренче көннәреннән үк масса арасында тәрбия һәм пропаганда эшләре алып баруда иң үтемле чараларның берсе — спектакльләр куюю булды. Ул вакытта барысы да сәхнәдә уйныйлар: укытучымы ул, язучымы яисә инженермы — барыбер спектакльләр куюда актив катнаша иде. Клубларда һәрбер лекция, докладтан соң, кагыйдә буларак, спектакль күрсәтелә... Ләкин совет чорында язылган татар пьесалары ул вакытларда юк дәрәҗәсендә бик аз иде. Шуңа күрә сәхнә әсәрләренә ихтыяҗ бик зур булды. Дөрес, беренче сәхнә әсәрләрем революциягә кадәр язылганнар. Ләкин драматург буларак мин нәкъ менә совет чорында формалаштым дип әйтә алам. Үзегез уйлап карагыз: ничек итеп язмыйсың ди ул Мулланур Вахитов, Муса Җәлил кебек олы затлар турында. Алар хакында берне генә түгел, бишәр пьеса язарга кирәк.

**Сорау:** Нәкый ага, хәзерге татар драматургиясе турындагы фикерләрегез белән дә уртаклашсагыз икән.

**Җавап:** Гомумән алганда, драматургия әдәбиятыбызның һәм мәдәниятебезнең иң алдынгы тармакларының берсе дип уйлыйм. Моңа мисал итеп, узган елда Үзәк телевидение аша ике татар совет драматургының өч әсәре күрсәтелүен әйтеп үтәргә мөмкин булыр иде. Әмма ләкин борчылырга да сәбәпләр юк түгел, минемчә. Бездә драматургия йөген башлыча урта буын авторлар: Туфан Миңнуллин, Аяз Гыйләҗев, Илдар Юзеевлар тартып бара дип әйтердек. Ә менә яшьләр бу йөкне тартырга бик үк атлыгып тормыйлар кебек. Дөрес, Ризван Хәмид шактый өлгерлек күрсәтте. Тагын каләм сынап караган ике-өч исемне атап булыр иде, әлбәттә. Ләкин, ничек кенә булмасын болар аз әле. Яшьләрдә тормышыбыздагы теге яки бу күренешләргә чын күңелдән борчылып яки шатланып, казанышларыбыз өчен горурланып язу җитенкерәми дигән фикер туа миндә. Бәлки мин ялгышамдыр?..

Аннан соң тамашачы турында да еш уйланам мин. Кемнәр алар, театрга йөрүләре ни рәвешле? Максатлары нәрсәдә? Репертуар аларны канәгатьләндерәме? Менә шул турыда да, хәзергечә әйткәндә, үзенә күрә бер социологик тикшеренү үткәрәсе иде. Минемчә, тамашачыны ныграк белүнең файдасы булмый калмас. Һәр ике тараф өчен дә — драматургка да, тамашачының үзенә дә.

**Сорау:** Нәкый ага, Сез бит әле әдәби һәм фәнни җәмәгатьчелекне урта гасыр татар әдәбиятының күренекле вәкиле Мөхәммәдьяр белән дә таныштырган кеше...

**Җавап:** Мөхәммәдьяр әсәрләре белән мин беренче тапкыр кырыгынчы еллар башында очраштым һәм аларны матбугатта чыгаруга ирештем. Моның белән горурланам, әлбәттә. Дөрес, узган гасырның урталарында күренекле рус галиме, тюрколог И. Н. Березин Мөхәммәдьяр дигән шагыйрьнең булуын исемләп белмәсә дә, ул чорда «Төхфәи мәрдан» дигән бер әсәр язылган булуын белгән. Ләкин авторы кем булуын һәм аның тагын «Нуры содур» дигән әсәре дә булуын әйтә алмаган иде. Ул шагыйрьнең «Төхфәи мәрдан» поэмасына югары бәя биргән һәм андагы мәкальләрнең, фразеологик әйтемнәрнең кайберләрен тәрҗемә итеп бастырып чыгарган иде. Ләкин болар татар укучыларына барып җитә алмаган, шуңа күрә тиешле дәрәҗәдә яңгыраш та тапмаган иде. Шуннан соң Мөхәммәдьяр турында бер гасырга якын сүз булмый торды.

Мөхәммәдьяр иҗатын әле ныклап өйрәнәсе бар. Минемчә, иң элек, шагыйрь әсәрләренең сакланып калган нөсхәләре нигезендә аларның фәнни тикшерелгән текстларын төзисе бар. Миндә мәсәлән, «Нуры содур»ның ике кульязма нөсхәсе һәм тагын өченче бер әсәреннән бик иске кульязма өземтә бар. Шулай ук, киң катлау укучыларыбыз өчен, шагыйрь әсәрләренең хәзерге әдәби телгә күчерелгән вариантларын бастырып чыгару да зарур.

Мөхәммәдьяр, аның әсәрләре турында сүз чыккач, шуны да әйтеп үтәсе килә: билгеле ки, борынгы чор татар әдәбиятын, һәм, гомумән, аның тарихын тикшерү, өйрәнү өчен иң элек беренче кул чыганаклар — язма текстлар кирәк. Шуңа күрә мин яшьләрне әлегәчә халык арасында таралып яткан әдәби, тарихи ядкарьләрне тагын да активрак эзләп җыярга, аларны мөмкин кадәр күбрәк саклап калырга өндисем килә. Археографик экспедицияләр оештыруда башка фәнни үзәкләрдә кулланыла торган уңышлы алымнарны да безгә корал итеп алырга кирәк дип уйлыйм.

**Сорау:** Нәкый ага, моныкы инде традицион сорау: Сез хәзер нинди эш белән мәшгуль?

**Җавап:** Хәзергесе көндә үз алдыма куйган бурычларның иң зурысы итеп, татар теленең фразеологик әйтемнәре сүзлеген төзеп бетерүне саныйм. Күп төрле сүзлекләр арасында фразеологик әйтемнәр сүзлеге үзенә аерым бер урын алып тора. Теге яки бу телнең үзенә генә хас булган тәсмерләрен, шигъри алымнар байлыгы хасиятләрен чагылдыру җәһәтеннән караганда, нәкъ менә фразеологик әйтемнәр сүзлеге бик кызыклы һәм зур роль уйный. Фразеологик әйтемнәр һәр телнең бары тик үзенә генә хас формалы милли байлыгы итеп карала. Бездә бу өлкәдә бернәрсә дә эшләнми дип әйтеп булмый: кайбер теоретик тикшеренүләр күренгәләде, кечерәк булса

да җыентыклар чыккалады. Әмма әлегә фразеологик әйтемнәребезнең чагыштырмача тулы сүзлеге чыгарылды дип әйтә алмыйбыз, әлбәттә. Телебез бик бай, сыгылмалы, кеше күңеленең иң нечкә халәтләрен дә, һәртөрле шигъри һәм катлаулы фәнни төшенчәләрне дә бирә алырлык маһир тел ул. Шуңа күрә телебез җәүһәрләрен үзендә туплаган һәртөрле характердагы сүзлекләр төзү — безнең алда күп белгечләрнең тырышлыгын көтеп торган мөһим бурычыбыз. Фразеологик сүзлек исә шул зур бурычның бер өлешен тәшкил итә.

Әңгәмәне **Җәүдәт МИҢНУЛЛИН** язып барды.

# БАЛАЛАР ФОЛЬКЛОРЫ

Нәкый Исәнбәт — татар совет әдәбиятының гына түгел, ә татар фольклористикасының да нигез ташларын салышуда катнашкан аксакал әдип һәм галим. Шул исәптән балалар фольклорын җыю һәм өйрәнү өлкәсендә дә ул — күп көч салган һәм иң тирән буразналар ярган кеше. Балаларның тел һәм уен сәнгатенә яшьтән үк гашыйк булгангадыр инде — бу төр иҗат белән Н. Исәнбәт революциягә кадәр, ягъни мәдрәсәдә укыган елларында ук кызыксына башлый. Аның аеруча борынгы үрнәкләрен дә җанлы кулланышта булган чагында язып ала.

Булачак галимнең һәвәскәрләрчә башланган җыю-туплау эшчәнлегенә соңыннан фольклор сәнгатенең серләренә төшенергә омтылу, балалар иҗатын гыйльми нигездә өйрәнү эшчәнлеге килеп кушыла. 1941 елда басылып чыккан «Табышмаклар» һәм «Балалар фольклоры» дигән хезмәтләр моның беренче карлыгачлары була. Н. Исәнбәтнең татар фольклористикасындагы күпкырлы эшчәнлеге дә асылда шушы хезмәтләрдән башланып китә.

Моннан соңгы елларда Н. Исәнбәт, сүз-тел энҗеләрен эзләп, халык иҗаты диңгезенең иң тирән катламнарына үтеп керә, берсеннән-берсе кызыклы һәм тирән эчтәлекле гыйльми тикшеренүләре белән татар фольклористикасының иң биек түбәләрен яулауда катнаша. Кырык меңгә якын мәкаль-әйтемне эченә алган өч томлык хезмәт, янә дә гаять күп табышмакларны бергә туплаган җыентык һәм ахыр килеп, аларда кереш итеп бирелгән күләмле фәнни-тикшеренү мәкаләләре — моның ачык мисаллары. Ләкин олы галим, үзе әйтмешли, Нәкыш булган чагында гына түгел, ә Нәкый абый булгач та, хәтта Нәкый бабай булганнан соң да, күңеле һәм иҗаты белән, барыбер балалардан аерыла алмады һәм балалар фольклоры өлкәсендә кайта-кайта эшләде. Аерым алганда, ул түбәндәге исемнәрдә бер-бер артлы тагын дүрт җыентык чыгарды: «Ни өчен ни булган яки утыз ялган» (1956), «Нәниләр шатлана» (1967), «Балалар дөньясы» (1970), «Отканга мәкаль, тапкырга табышмак» (1973).

Әле күптән түгел генә басылып чыккан «Балалар фольклоры» (Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1984, 25 басма табак) дигән тупланма галимнең әлеге җыентыклар һәм аларга кермәгән материаллар нигезендә төзелгән күп еллык хезмәт нәтиҗәсе булып тора. Татар балаларының тел-уен иҗатын ул гаҗәп бай һәм күпкырлы итеп күз алдына бастыра. Билгеле, җыентыкта фольклор үрнәкләрен классификацияләүдә һәм аерым төрләргә бүлеп урнаштыруда үзара уртак, бердәм принциплар табылып бетмәгән. Шуңа күрә дә материаллар анда төрле принциплардан: әйтик, тематик принциптан («Бала һәм табигать»), жанр принцибыннан («Мәкальләр һәм табышмаклар») яки функция-вазифа принцибыннан («Җырлы-сүзле йөз төрле уен») чыгып төркемләнгәннәр. Әмма бу очракта иң мөһиме — җыентыкның балаларга бәйләнешле традицион һәм хәзерге фольклор үрнәкләрен иңләп алуында һәм моңарчы төрле чыганакларда чәчелеп яткан яки бөтенләй билгеле булмаган материалларны бергә туплап бирүендә.

Хәзерге совет фольклористикасында балалар фольклорын функциональ яктан, ягъни нинди вазифа башкаруыннан, куллаңыш максатыннан чыгып төркемләү гамәлгә кергән. Шушы уртак принциптан чыгып, балаларга бәйләнешле тел-уен иҗатын, гадәттә, зур өч төркемгә бүлеп йөртәләр: 1) бала багу фольклорына, 2) сүз уены яки сүз белән күңел ачу фольклорына һәм 3) хәрәкәтле уен фольклорына. Боларның беренчесе балаларга багышлап зурлар тарафыннан тудырылган иҗаттан гына тора. Соңгы икесе исә, башлыча, балаларның үз иҗатына нигезләнә һәм өлешчә өлкәннәр иҗаты катнашкан материалларны да үз эченә ала. Н. Исәнбәтнең җыентыгында да төп материал, төрле принципта төркемләп урнаштырылуына карамастан, шушы өч төркемгә карый һәм асылда шулар эченә кереп бетә. Мәсәлән, «Җырлы-сүзле йөз төрле уен» бирелгән «Кәк-кү, чыпчык» дигән һәм баланы аркага асылындырып башкарылгын такмазалар, шулай ук төрле исемдәге бармак уеннары асылда беренче бүлеккә, ягъни

бала багуга бәйләнешле материаллар янына соралып тора. Беренче бүлектә «Әйтешләр» исеме астында бирелгән кайбер текстлар исә (әйтик, «балтаңны ал да йөгереп чык» дип тәмамланганнары), киресенчә уеннар бүлегендәге санамышлар төркеменә карый, чөнки, әйтеш алымына нигезләнсәләр дә, жанр ягыннан алар санамышларга керәләр һ. б.

Бала багу иҗаты сабыйның бишектән алып үз көнелен үзе күрә һәм үзлегеннән иҗат итә башлауга кадәрге чорын эченә ала. Баланың теле һәм дөньяга күзе ачылуга багышланган иң тәүге фольклор үрнәкләре һәм иң беренче уен күнекмәләре әлеге иҗатның иҗтимагый-педагогик асылын, төп эчтәлеген тәшкил итә. Н. Исәнбәт җыентыгында алар аерым жанрларга һәм берничә уен төренә яки тематик төркемнәргә бүленеп бирелгәнчәр. Бишек җырлары һәм баланы уятканда, үчти-үчти яки дөнки-дөнки сикерткәндә, чәбәкәй иттергәндә, тәпи йөртергә өйрәткәндә, биеткәндә, телен ачтырганда һәм сөйләмен төзәткәндә әйтелә торган такмазалар әнә шундыйлардан. Болардан аерым авазларны дөрес әйттерүгә хезмәт итүче текстлар матбугатта беренче тапкыр игълан ителәләр һәм балаларны сөйләмгә өйрәтүдә менә дигән чыганак булып торалар.

Ә менә баланы беренче тапкыр мунча кертәкәндә кендек әбисе тарафыннан әйтелгән такмаза халыкның борынгы педагогик карашларын һәм магик ышануларын гәүдәләндерүе ягыннан әһәмиятле. Мондый келәү характерындагы текстларны заманында профессиональ сер итеп саклаганнар, һәм шуңа күрә дә җыентыкта бер текст кына китерелгән дә. Әйтергә кирәк, университетның татар филологиясе бүлеге студентларына да бер фольклор экспедициясе вакытында кендек әбисе такмазаларының шундый бер үрнәген язып алырга насыйп булды.

Сүз уены яки сүз белән көнел ачу фольклорында балаларның үз иҗаты төп урынны алып тора. Бу төр иҗатның үзенчәлеге хәрәкәтле уеннан бигрәк сүздә, сүз белән уйнауда ягъни такмаклап яки такмаза әйтеп, көйләп яки сөйләп көнел ачуда. Дөрес, әлеге төр фольклорда күпмедер дәрәҗәдә хәрәкәт тә катнашырга мөмкин, ләкин ул уенны оештырмый, ә сүзгә буйсынып килә.

Сүз белән көнел ачу фольклорының иң борынгы үрнәге — эндәшләр һәм чакырулар. Н. Исәнбәт дөрес билгеләгәнчә, мондый жанрларда кош-кортлар, җәнлекләр, бөҗәкләр кеше телен аңлый дип ышану эзләре ярылып ята, табигать көчләрен җанлы итеп күзаллау һәм аларга ялварып, хәтта корбан биреп («симез үгез суярмын, маен сиңа куярмын», «кара сарык суярмын, ботын сиңа куярмын») кешегә хезмәт иттерергә омтылу сизелеп тора. Ләкин кайчандыр зурларның календарь йола иҗаты җирлегендә, я булмаса элгәре күзаллаулар йогынтысында туган мондый текстлар күптән инде магик мәгънәләрен югалтканнар һәм юану, көнел ачу чарасына әверелгәннәр.

Җыентыкта кош-кортларның, җәнлекләрнең һәм үсемлекләрнең үзләрен сөйләштерүгә корылган текстлар да урнаштырылган. Әйтик, әтәч белән тавыклар ни дип әйтә, үрдәкләр ни дип бакылдаша, карга ни дип карылдый, кабак каенга ни ди һ. б. Моңарчы бер җирдә дә басылмаган әлеге иҗат үрнәкләре безне балалар фольклорының хәзергә аз билгеле төре белән таныштыра һәм һичшиксез үзенә бер жанр тәшкил итә.

Сүз белән көнел ачу фольклорының күпчелек өлешен җыентыкта такмазалар алып тора. «Такмаза» төшенчәсенең татар фольклористикасында киң һәм тар мәгънәләре бар. Киң мәгънәдә алганда, такмаза даими үлчәме һәм тотрыклы строфалары булмаган, сөйләп башкаруга яки тезеп әйтүгә корылган шигырь формасын белдерә. Мондый формага нигезләнгән текст бик еш тоташ, үтәли формада була, ягъни эпос-дастаннарда кулланыла торган тирада — толгау формасы кебек, юллар бер-бер артлы тезелеп яки дулкын-дулкын булып сарылып киләләр. Бу дастаннарның да, шулай ук такмазаларның да импровизация белән тыгыз бәйләнүеннән килә торган сыйфат булса кирәк. Н. Исәнбәт такмазаларны «рифмалы булып, тезмә юллардан торса да, такмак шикелле иҗек үлчәүләренә буйсынмый, ирекле формада төзелгән була» дип билгели дә. (Балалар фольклоры. Казан, 1941, 42 б.) Бу бик кызыклы күзәтү. Төрле жанр текстларының еш кына такмаза дип йөртелүенең сәбәбен без шушы күзәтү җирлегендә генә аңлый алабыз (мәсәлән, чакыру такмазалары, санамыш такмазалары һ. б.), ахыр килеп, ирекле шигырь башлангычларын да күпләп такмаза текстларында табабыз.

Такмазаның тар мәгънәсе сүз уены иҗатының аерым бер жанрын белдерә. Мондый жанр текстлары форма ягыннан даими үлчәмгә һәм тотрыклы строфаларга нигезләнмиләр, эчтәлекләре ягыннан җор һәм юмористик эчтәлекле булалар. Такмаза жанры үзе берничә жанр төркемчәсенә бүленә: әкиятсыманнарга, чуалтмышларга, шаккатыргычларга, чылбыр такмазаларга. Боларның баштагы икесен термин буларак Н. Исәнбәт керткән иде. Ләкин соңгы китабында галим такмазаларны күбрәк тематик яктан бүлә һәм моңарчы беркайда да күренмәгән күпсанлы текстлар тәкъдим итә. Ашау-эчүгә бәйләнешле һәм авыл исемнәренә чыгарылган такмазалар әнә шундыйлардан.

Чылбыр такмазалар (җыентыкта аларның бер өлеше «уймак такмазалары» дигән исем астында бирелгән) фикерләү үзенчәлекләре ягыннан гаять кызыклы. Алар архаик сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтләренә нигезләнгән мәгънәви-семантик тәңгәлләр тезмәсеннән торалар («ул камчыны җиргә суктым, җир миңа чирәм бирде; ул чирәмне казга ашаттым, каз миңа күкәй бирде»). Соңгылары градацияләнеп үсүче сан-сыйфат үзгәрешләрен гәүдәләндерәләр һәм, буын-буын булып үрелеп, үзенчәлекле толгау-сарын ритмы барлыкка китерәләр.

Сүз уены фольклорының тагын берничә традицион жанры бар. Атап әйткәндә: сайравычлар, әйтешүләр, үртәвечләр, ияртмешләр, тиз әйткечләр яки тел көрмәвечләр, алдавычлар һәм күбесенчә зурлар катнашлыгында иҗат ителгән алдавыч әкиятләр. Алдавычларны исәпкә алмаганда, бу жанрларның барысы да җыентыкта чагылыш тапкан һәм сайравычларның, ияртмешләрнең, алдавыч әкиятләрнең үрнәкләре беренче тапкыр шулай киң итеп бирелгән.

Алда әйтелгәнчә, балалар иҗатының өченче төркеме хәрәкәтле уен фольклорына нигезләнә. Монда инде сүз-текстлар хәрәкәтле уеннар (кара-каршы сафларга тезелү, түгәрәк әйләнү, бию, йөгерү, куышу, тән хәрәкәтләре ясау, театрлы уеннар башкару һ. б.) белән үзара керешеп килә. Димәк, хәрәкәт бу төр иҗатның, сүз-текст кебек үк, зарури шарты, уенны оештырышучы даими сыйфаты булып тора. Н. Исәнбәт күрсәткәнчә, берничә башлангычның әнә шулай бер үк уенда бергә кушылуы яки үрелүе балалар фольклорының синкретик табигатен белгели, һәм бу үзенчәлек хәрәкәтле уен иҗатында аеруча киң чагыла.

«Балалар фольклоры» җыентыгында әлеге иҗат үрнәкләре «Җырлы-сүзле йөз төрле уен» дигән баш астында аерым бүлек итеп бирелгәннәр. Аларның бер өлеше зурларның гаилә-көнкүреш йола иҗатына, борынгы туй-никах мөнәсәбәтләренә барып тоташа. Мәсәлән, «Ак тирәк», «Кабыргалы камчылы», «Зимчәчәк», «Шали камыш» кебек уеннар шундый. Мондый уеннарда элек бер як кыз бирүче як булып, икенче як исә кияү ягы, ягъни кыз-кәләш сайлаучы як булып чыгыш ясаган. Шунда ук егетнең яки кызның никах сынавы үтүе, кияүнең булачак кәләше белән көрәше дә чагылыш тапкан. Соңга таба бу уеннар, үзгәреп, ике якның бер-берсе арасыннан иптәш сайлавы һәм үзара көч сынашуы рәвешен алганнар. Ләкин аерым сүзләрендә һаман да борынгылык эзләре, кинаяле-символик образлар сизелеп тора. Мәсәлән, «Кабыргалы (кайбер якларда: «караңгылы» — М. Б.) камчылы, тама торган тамчылы» дигән гыйбарәдә яшенле яңгырның сурәте-картинасы абайлана.

Н. Исәнбәт балаларның уеннарын «иҗтимагый шөгыль» дип атый, чөнки уен балаларны рухи һәм физик яктан чыныктыра, аларны киләчәк тормышка һәм хезмәткә әзерли. Театрлы уеннар да, хәтта әкиятләрдән алынганнары да, җитди шөгыль үрнәге, реаль чынбарлыкны күзәтү нәтиҗәсе булып торалар. Мондый уеннарда балалар бер-берсенә кунакка йөрешәләр, көтү көтәләр, яшелчә уңышы җыялар, сәүдә итәләр, почта җибәрәләр, төрле «дошманнары» белән көрәшәләр, хөкем чыгаралар һ. б. Театрлы уеннарның иң мөһим сыйфаты, Н. Исәнбәт билгеләп үткәнчә, драматик характерда булуларында, ягъни аларда тамаша-кыланышның, пантомима-драматик хәрәкәтнең зур урын тотуында һәм балаларның шартлы рәвештә төрле рольләрне башкаруында. Менә шуңа күрә дә бу төр иҗат киләчәктә татар халык драмасының гомуми табигатен һәм аерым чыганакларын ачыклау, импровизациянең үзенчәлекләрен өйрәнү өчен дә, һичшиксез, әһәмиятле чыганак булачак.

Драматик уеннарның бер өлешен башлап, оештырып җибәрүче, уенда көтүче яки гөрләүче билгеләү өчен хезмәт итүче жанр — санамышлар. Алар, гадәттә, такмаза формасына нигезләнәләр һәм әйбер исемнәрен яки аларның сыйфатларын тезеп санап баруга корылалар. Н. Исәнбәт санамышларда борынгы ышануларның калдыклары һәм төрле тарихи чор катламнары аеруча киң сакланып калган дигән фикер үткәрә һәм моны конкрет мисалларда исбатлый. Беренче карашка мәгънәсез, эчтәлексез күренгән мондый текстларның бер өлеше, чыннан да, яшерен яки күчерелмә атамалар белән санау алымына һәм төрле мифологик күзаллауларга барып тоташалар, я булмаса балаларның ата-бабаларыннан отып алган төрле пароль-команда сүзләрен гәүдәләндерәләр булса кирәк. Дөрес, «Тимер казык — олатаң» дигән гыйбарәдән чыгып, котып йолдызы элек безнең ерак бабаларыбыз өчен нәсел башы, ягъни тотем җисем һәм хәтта иң борынгы ил-йорт булган, дип исәпләү ышандырып бетерми. Асылда монда сүз тимер казык йолдызының олылануы, культлаштырылуы турында гына бара кебек.

Янә шунысы кызыклы һәм әһәмиятле: галим байтак санамышларның чыганагын бер үк төпкә, берничә тамырга кайтарып калдыра. Бу, һичшиксез, балалар фольклорының искиткеч тотрыклы һәм күчемле табигатеннән, борынгы образларны һәм формаларны саклаучы, яңа шартларда дәвам иттерүче иҗат булуыннан килә.

Хәрәкәтле уен фольклорына караучы тагын бер катлам — җырлы-биюле уеннар. Бу төр иҗатта уен-бию, сүз-текст һәм көй-музыка бергә берләшеп килә. Җырлы-биюле уеннарның кара-каршы сафларга тезелеп башкарыла торганнары да («Наза», «Ак тирәк»), шулай ук әйлән-бәйлән тәрәнә караганнары да («Әйлән би, сәйлән би», «Ак калач», «Ахшару», «Куянкай») бар. Мондый уеннарның бер өлеше зурлар иҗатыннан күчкән һәм балаларның үз иҗаты белән кушылып киткән. Ләкин җыентыкта ни өчендер җиткән егетләр һәм кызлар тарафыннан гына башкарыла торган уен-бию җырлары («Чәчү, чәчү», «Аллария-лария», «Ямьле Зәйнең буйлары»), һәм зурлар иҗатына гына караган бию такмаклары («Бие, Хәйбулла», «Өммегөлсем», «Иелми, бөгелми», «Әллә, рәлем Җәмилә», «Әйт әле тагы да», «Әттә түдер») урын алган. Ахыр килеп, «Яшүсмер яраткан көйләргә җырлар» дигән исем астында да солдатлар иҗат иткән тарихи җыр үрнәге («Күзге ачы җилләрдә») һәм аерым язучыларның халыклашкан, әмма күбесе зурлар арасында гына җырлана торган җыр текстлары бирелгән. Безнең карашыбызча, «Балалар фольклоры»нда турыдан-туры зурлар иҗатына караган әсәрләрнең болай күпләп урнаштырылуы акланмый кебек.

Җыентыкның бер бүлеге «Мәкальләр һәм табышмаклар» дип атала. Зурлар тарафыннан тудырылган традицион жанр булса да, табышмакларның хәзерге вакытта балалар даирәсенә, сүз уены иҗатына күчкәнлеге бәхәссез. Н. Исәнбәт табышмакларның функциясен зиһен сынашуга һәм нәфислек тойгысы тәрбияләүгә генә кайтып калмавын, ә «әйберләрне бер-берсенә чагыштырып, дөнья һәм табигатьне тану, белем казану» юлларының берсе булуын бик дөрес тотып алган. Төзелешләренә, ничек ясалуларына карап, табышмаклар ике жанр төренә һәм тематик төркемнәргә бүлеп урнаштырылганнар.

Мәкаль жанрын балалар фольклорына кертеп тәкъдим итү исә, безнең уебызча, фольклористикада яңа башлангыч һәм игътибарга лаеклы беренче тәҗрибә булып тора. Монда, билгеле, галим мәсьәләгә педагогларча килә һәм мәкальләрнең балалар тормышына яки психологиясенә аеруча туры килә торганнарын гына аерып бирергә тырыша. Шулай да әлеге жанрның балалар тудырган сүз-уен иҗатына карамавын, сөйләмгә куәт һәм ямь бирүче сүз сәнгате булуын да, һичшиксез, искәртергә кирәк.

Инде «Имеш төбе җимеш яки ни өчен ни булган» дигән бүлектә бирелгән текстлар турында берничә сүз. Җыентыкны төзүче үзе әлеге материалларны «ялган хәбәрләр, әкиятсыман җаваплар» дип кенә атаса да, без аларның бер өлеше, һичшиксез, хәзергә бик аз өйрәнелгән өлкәне — халык мифологиясен гәүдәләндерә дип исәплибез. Заманында ул әкиятләрнең байтагы, безнеңчә, борынгылар тарафыннан ышанып сөйләнгән мифлар һәм мифологик легендалар булган. Һәр халык үзен кызыксындырган «ни өчен? ник алай?» дигән сорауларга җавап итеп, генеалогик-этиологик мифлар иҗат иткән, аларда кош-кортларның, җәнлекләрнең һәм үсемлекләрнең ничек яратылуын, теге яки бу күренешләрнең яки сыйфатларның ничек барлыкка килүен үзенчә аңлатырга тырышкан. Табигатьнең серләренә төшенә барган саен, мондый мифларга ышаныч кимегән һәм акрынлап бөтенләй юкка чыккан. Менә шунда инде миф сюжетлары әкиятләр яки легендалар составына күчкән. Һәм, әлбәттә, шулар үрнәгендә соңыннан язмача яки телдән башка текстлар да иҗат ителгән. Кыскасы, әлеге без сүз алып барган бүлектәге материалларның шактые безнең көннәргә килеп җиткән бик борынгы катлам иҗаты — мифлар яки миф калдыклары булса кирәк. Балалар өчен кызыклы һәм гыйбрәтле текстлар булудан тыш, аларның тагын бер мөһим һәм фәнни әһәмияте әнә шунда.

Җыентыкның ахырында балалар фольклоры турында бирелгән теоретик белешмә төрле бүлекләргә һәм жанрларга ачкыч хезмәтен үти. Анда теге яки бу төр иҗатның табигате, гомуми үзенчәлекләре анализлана. Шул ук вакытта аерым жанрларның поэтикасы, сәнгать үзенчәлекләре хакында кызыклы күзәтүләр ясала. Әлбәттә, поэтика-стильне төрле сурәтләү чараларын санап бару рәвешендә генә тикшерү канәгатьләндереп бетерә алмый хәзер. Чөнки бер үк сурәтләү чаралары, гадәттә, күп төрле жанрларда очрый. Менә шуңа күрә дә теге яки бу жанрның яки әсәрнең сәнгатьчә эшләнешенә, асылына үтеп керү өчен, һичшиксез аның төзелешен, художестволы фикерләү калыбын ачарга кирәк. Ләкин монсы инде киләчәк эше, балалар иҗатын махсус һәм киң планда өйрәнүчеләр бурычы.

Татарстан китап нәшрияты күренекле әдибебез һәм галимебез Н. Исәнбәт тарафыннан төзелгән «Балалар фольклоры» дигән җыентыкны чыгарып, һичшиксез, әйбәт һәм изге эш эшләгән. Бу китап балалар, ата-аналар һәм тәрбиячеләр өчен дә, шулай ук әдәбиятчылар һәм фольклорчылар өчен дә файдалы кулланма булыр дип ышанабыз.

**Марсель БАКИРОВ,**
филология фәннәре кандидаты.

# КАЛӘМДӘШНЕ САГЫНГАНДА

*Абдулла Әхмәтнең тууына 80 ел*

Яшьлеге давыллы елларга туры килгән бер буын язучылар бар. Аларның тормыш юллары да бер-беренә охшаган — гражданнар сугышы, эчке дошманнарга каршы көрәш, колхозлашу еллары, беренче бишьеллыклар...

Кечкенә хикәяләре һәм сәхнә әсәрләре язу белән танылган Абдулла Әхмәтнең иҗаты да нәкъ менә шул бөек төзелешләр чорында башлана. Аның беренче очерклары Магнитогорск төзелешләрендә эшләүчеләргә багышлана. Шул елларда «Магнитогорск ударниклары», «Дөнья гиганты һәм аның баһадирлары» дигән китаплары басылып чыга. Эшчеләр темасын ул соңыннан да (бигрәк тә драма әсәрләрендә) дәвам итә. Аның нефтьчеләр тормышына багышланган «Серләр», «Егет сүзе» дигән драма әсәрләре, «Кара алтын» исемле очерклар китабы дөнья күрә. Татарстан нефтьчеләре турында соңыннан калын-калын романнар, повестьлар, поэмалар язылды, нәфис фильм төшерелде. Абдулла Әхмәт әсәрләре исә безгә бу хактагы беренче әсәрләр булуы белән кадерле.

Абдулла Әхмәт иҗатының күтәрелеш чоры Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы елларга туры килә дисәк, ялгыш булмастыр. Фронт газеталарында эшләгәндә, аның сугышчан очерклары белән бергә кечкенә күләмле хикәяләре дә еш басыла. Аларның солдат күңелен күтәреп, ял иттереп ала торган көлкеләләре дә, ачудан тешне кысып, дошман өстенә ташланырдай көч биргән фаҗигалеләре дә күп була.

А. Әхмәт халык иҗатын өйрәнү белән дә мавыга, фольклор галиме Хәмит Ярми белән бергәләп, халык мәзәкләрен туплаган китаплар чыгара. Шаян сүзгә үзе дә оста булган мәзәкче язучыга аның бу хезмәте фронтта да ярап куя. Газета битләрендә «Хуҗа Насретдин фронтта» дигән бүлек ачып, яраткан героебыз ярдәме белән язучы фашист илбасарлардан ачы көлә. Солдатлар арасында булган төрле кызык хәлләрне дә ул Хуҗа Насретдин мәзәкләренә торырлык итеп хикәяләүгә ирешә. Җитди хикәяләрдән исә күпне күргән, минут саен үлем белән очрашып торган сугышчыларны да тетрәндерерлекләре бар.

Сугышның башыннан ахырына кадәр йөреп, утны-суны кичеп кайткан, фронтта партия сафларына кергән, орден һәм медальләр белән бүләкләнгән Абдулла Әхмәт бу теманы соңыннан да дәвам итеп, фаҗигале һәм героик көннәр турында балалар өчен күп кенә хикәяләр яза. Аның иҗатын бизмәннең ике тәлинкәсенә бүлеп салсаң, «балалар өчен» дигән ягы тартарак төшәр кебек. Абдулла Әхмәтнең балалар әдәбиятына килүе үзе дә очраклы түгел. Ул бала җанлы, аларның телен таба белә, тиз аралашып, алар өчен үз кеше булып китә ала иде.

Сугыштан соңгы елларда, фронтташ язучылар бер-бере белән аралашып яшәгәндә, ул безнең өйгә еш килә иде. Кечкенә кызыбыз ачык йөзле абыйсын күрүгә, каршына йөгереп бара да балалык һөнәрләрен күрсәтергә ашыга. Зәгыйфь тавышы белән җырлаган була, тыпырдап бии. Абдулла абый исә кинәнеп көлә-көлә кул чаба, яраткан сүзе «Ух-ти!»не әйтеп, алдына утыртып сөя. Озак килми торса, матбугат йортында күрешкәндә аның беренче сүзе: «Минем теге матур кыз нишли, үсәме?» булыр иде. Ул үзе дә берсеннән-берсе акыллы, итагатьле ике кыз үстерде. Хикәяләрендәге геройларда үз балаларының характерын чамаларга да мөмкин була иде.

А. Әхмәтнең балалар язучысы булып китүенә яшьлегендә балалар йортында тәрбияче булып эшләү дә, педагогия институтында уку да, А. Алиш белән бергәләп нәниләр өчен пьесалар иҗат итү дә этәргеч булгандыр. Сугыштан соңгы елларда Татарстан китап нәшриятының балалар-яшьләр редакциясендә мөдир, «Пионер» (хәзерге «Ялкын») журналында баш редактор булу да аны яшүсмерләрнең шау-шулы, маҗаралы, серле дөньясында яшәтте.

Аңа кадәр шактый хикәяләр, пьесалар язган булса да, А. Әхмәтне киң җәмәгатьчелеккә таныткан әсәре «Үги кыз» пьесасы булды. Татар халык әкиятләренә нигезләнеп язылган бу әсәр Татар дәүләт академия театрында уңыш белән барды. Муса Җәлил, Гадел Кутуйлар газеталарда уңай рецензияләр язып чыктылар. Балалар әдәбиятын игътибар белән күзәтеп барган, аның уңышларын билгеләп үтәргә һәркайчан вакыт тапкан Муса Җәлил «Үги кыз» әсәрен карагач: «Пьесага хас уңай сыйфат — аның халыкчан образлылыгы һәм чиксез садәлеге. Пьеса ясалма рәвештә фикер-мораль чыгарулардан, аңа ясалма мәгънә тагып куюдан азат булган хәлдә, шул ук вакытта әкиятнең үз художество чаралары аша органик һәм табигый рәвештә ап-ачык мораль фикерне үткәрә»,— дип язып чыкты.

Герой шагыйрь пьесаның уңай ягы дип, ассызыклап аның шул сыйфатын әйтә икән, юкка булмагандыр.

Чыннан да, Абдулла Әхмәтнең ул елларда иҗат иткән «Яңа дуслар», «Яраланган сумка», «Бабай һәм малай», «Абый хаты» һ. б. дистәләрчә хикәяләре тормышчан, балаларча самими, җанлы характерларга бай булулары белән гыйбрәтле иделәр.

А. Әхмәт татар балалар әдәбиятының үсешенә иҗаты белән генә түгел, аны оештыручы булып та күп эш башкарган язучы. Нәшрият эшчесе һәм пионерлар өчен чыгарыла торган журнал редакторы буларак, ул үз тирәсенә талантлы язучыларны туплый алды һәм кайбер әсәрләрнең язылып дөньяга чыгуына турыдан-туры ярдәм итте. Мәсәлән, А. Әхмәтнең якын дусты И. Туктар нәниләр өчен өчәр-дүртәр юллык кына йөз хикәя язды. М. Әмирнең нәни хикәяләре дөнья күрде. А. Әхмәт үзе дә «Әби сөюе», «Баһау һәм бозау» исемле көлкеле хикәяләр иҗат итте...

Сугыш афәтләре кешеләргә тыныч көннәрдә дә кайгы-хәсрәтне салып кына торды. Фронттан йөреп кайткан язучыларның байтагы илле яшен дә тутырмыйча арабыздан китеп барды. Исәннәренең дә сәламәтлеге иртә какшады. Утызынчы еллар комсомолы, партияле фронтовик язучы Абдулла Әхмәт тә озак һәм каты авырып вафат булды. Ә быел аңар 80 яшь тулган булыр иде, һәм без бу шатлыклы көнне көләч йөзле, шаян дустыбыз белән бергә үткәрер идек... Ә хәзер без аны сагынып искә алабыз.

**Ләбибә ИХСАНОВА.**

# Кизәнев

## Ораторга киңәш

Башта башың казанында
Кайнат әйтер сүзеңне,
Тик шуннан соң трибунага
Мендерсеннәр үзеңне.

## Кадернең кадерен белмәү

Бер яшь бозау ике ана имде,
Бик тырышты һәркайсына ярап.
Үсеп җиткәч исә... икесеннән дә
Дәшми-тынмый качты кырын карап.

## Алдакчы чынлыгы

Кайчакта йөзләрчә кеше
Ышана бер ялганга —
Аучысы һәм балыкчысы
Оста алдый алганда.

## Хәмри авылы

Бу авыл тирәсе гүя
Тоташ пыяла кыя:
Фәсхия түти гектардан
Елга... йөз шешә җыя.

## Ике зат турында ике фикер

Бүтәннәрне тәнкыйть итеп Маннур
Яман затлардан санала.

Шуларны ук мактый белгән Фәннур
Үзен мактарлык дан ала.

## Әтәчкә Ата каз киңәше

— Мин дә ничек синдәй ак мамыклы,
Ак каурыйлы була алыйм икән?
— Минем кебек, су буена төш тә
Рәхәтләнеп юын кичен, иртән!

## Әрәмтамак хыялы

Күк тутырып оча сәер тәлинкәләр,
Рәхмәт яусын күз иярмәс канатка:
Марсияннар әллә ризык китерәләр
Туйсын өчен җирдә минем тамак та?!

## Дәүләт җилкәсендә

«Совхоз данлы! Ит планы тулды!»—
Әмма бу дан куык дан бары.
Терлекләргә чөнки комбикорм
Сата ел да дәүләт амбары.

## План буенча

Нәшрият план төзегәндә
Автор тик пионер иде.
Ә китап тик быел чыга:
Автор... пенсионер инде.

## Космик тизлек белән

Бер явыз авыз гайбәте
Зур шәһәргә тарала.
Һәм... йөзләгән якты исем
Өч-дүрт көндә карала.

## Бер әләкче ишегенә язу

— Беләсеңме, хәтта карлыгачлар
Таш тишеп тә оя кора белә

Һәм шушында барча күршеләре
Белән бердәм-тату тора белә?!.

## Бүре була белү

Эшкә керде Төлке булып кына,
Бүре булып утыра инде хәзер:
«Иртәнгегә бер бәрән дә җитә,
Ә әбәткә сарык булсын әзер!»

## Ялгышу

Мактады кәләшен егет
«Ярсу йөрәк, ут күз!» дип.
Инде хәзер тели: «Кайчан
Сүнәр икән мут күз?!» дип.

## Тиң-тигез пар түгелләр

Хатыны — карун: мал җыяр,
Ә ире — мут: туздырыр,—
Өч дистә ел ярышалар...
Кайсы микән уздырыр?..

## Үз мисалынча

— Ни өчен күп китерәм мин
Китап мактау цитатасын?—
Ди бер лектор,— кулланыгыз
Сүзнең күбрәк китапчасын.

## Шөгыльле эшлексез

Әрсез Абдулла уңды —
Муеннан эшкә чумды.
Ә баш... никтер батмады.
Чөнки ул баш лыгырдаудан
Артык бер эш тапмады.

## Самогончы колагына

Самогонны ничек куу...
Кирәген аңла син:
Бу тормышта аның
Эзе дә калмасын!

## Бәләкәй генә үзе...

Шулай бер заман өч егет Татарстан радиокомитетына килеп керә. Бүлмәдә яшүсмер кыз сыман бәләкәй генә, ябык кына кара күзле бер хатын утыра. Өсте-башы бик гади, ясанмаган, буянмаган. Төскә-биткә дә матурлардан түгел. Шулай да ул килеп керүчеләрне бик ачык йөз белән каршы ала:

— Ни йомыш, егетләр,— ди ул аларга.— Кем кирәк иде сезгә?

— Җырчы Гөлсем Сөләйманова кирәк иде безгә.

— Нигә ул сезгә?— ди хатын, бераз елмая төшеп.

— Нигә дип... Күрәсе иде үзен бер... Бик матур җырлый бит. Җыры кебек үк матурмы икән?..

— Әгәр мөмкин булса, зинһар, безнең янга чакырып алып кирәгез әле аны,— ди егетләрнең икенчесе.

— Ярар,— ди кара күзле хатын,— хәзер чакырып керәм... Монда гына иде әле ул. Чыгып китмәгәндер.— Шул сүзләрне әйтә-әйтә ул өстәл өстендә сибелеп яткан әйберләрен сумкасына тутыра да ишеккә таба юнәлә.— Бераз көтеп торыгыз. Беркая да чыгып китәсе булмагыз.

Бер минут уза, ике минут, өч минут... Ниһаять, бүлмәгә Г. Кутуй килеп керә:

— Нишләп басып торасыз монда, егетләр?— дип сорый ул алардан.

— Гөлсем Сөләймановане көтеп торабыз. Чакырырга чыгып киттеләр аны.

— Кем чыгып китте?

— Кара күзле бер апа шунда.

Кутуй шаркылдап көлеп җибәрә:

— Гөлсем апагыз үзе бит ул, үзе!— ди.— Хәзер генә яныгыздан чыгып бара иде.

Егетләр аптырап калалар. Берсе, аңына килеп:

— Я алла, шундый бәләкәй генә үзе! Уч төбенә утыртырлык кына. Ә моңы, ә җыры?— дип сокланып кычкырып җибәрә.

*Өлкән язучыбыз А. Шамов әзерләде*

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

23 январьда узган ачык партия җыелышында «Әдәбиятыбызда детектив жанрын үстерү буенча алда торган бурычлар» дигән темага зур сөйләшү булды һәм шул уңайдан прозаик Мәгъсүм Насыйбуллин иҗаты тикшерелде. Доклад белән тәнкыйтьче Ф. Мусин чыкты. Фикер алышуларда язучылар И. Юзеев, Р. Харис, Р. Мөхәммәдиев, Г. Ахунов, С. Сабиров, Л. Хәмидуллин һ. б. чыгыш ясады. Җыелышта М. Насыйбуллин иҗатына бәя бирелде, детектив жанрын үстерүдәге мөмкинлекләр билгеләп үтелде.

## ӘДӘБИЯТНЫҢ СУГЫШЧАН ЖАНРЫ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

18 январьда Әлмәт язучылар оешмасы, ТАССР Язучылар союзының очерк һәм публицистика секциясе һәм «Казан утлары» журналының берләштерелгән җыелышы булды. Анда иптәш К. У. Черненконың СССР Язучылар союзы идарәсенең юбилей пленумындагы речennән килеп чыккан нәтиҗәләр һәм күрсәтмәләр яктылыгында язучылар, журналистларның вакытлы матбугатта очерклар, публицистик чыгышлар белән катнашулары турындагы мәсьәлә каралды.

Җыелышта очерк һәм публицистика секциясе председателе, язучы М. Зарипов, «Казан утлары» журналының баш редакторы Р. Харис, Татарстан китап нәшриятының баш редакторы урынбасары В. Белокопытов, Әлмәт язучылар оешмасының җаваплы секретаре Ә. Гаффар, язучылар Ж. Рәхимов, Ш. Бикчурин, А. Хәсәнов, Ә. Габиди, К. Әмиров, Э. Мөэминовалар чыгыш ясады.

Җыелышта катнашучылар республиканың нефть зонасы язучылары һәм журналистларының иҗади активлыгын күтәрүгә, вакытлы матбугатта публицистик чыгышларының сугышчанлыгын һәм сыйфатын яхшыртуга, хәзерге заманның актуаль темаларына китаплар язуга юнәлдерелгән карар кабул иттеләр.

## ПОЛИТИК ПОЭЗИЯ КИЧӘСЕ

31 январьда Казанның Яшьләр үзәгендә икенче телевизион политик поэзия кичәсе булды. Ул Бөек Җиңүнең 40 еллыгына һәм герой-шагыйрь М. Җәлил истәлегенә багышланды. Анда фронтовик шагыйрьләр, Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясе лауреатлары, төрле буын әдипләре катнашты. Алар партиягә, комсомолга багышланган, дөньяда иминлекне сакларга чакырган әсәрләрен укыдылар.

Традицион политик шигырь кичәсен Татарстан Язучылар союзының шигъри бәйрәмнәр уздыру комиссиясе председателе, шагыйрь Р. Харис алып барды.

Бу кичә 14 февральдә Казан телевидениесе аша күрсәтелде.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

24 январьда шагыйрьләр секциясенең чираттагы утырышында шагыйрь Г. Рәхим белән очрашу булды. Ул үзенең чыгышында бүгенге татар поэзиясенең бөтенсоюз күләмендә тоткан урыны, Мәскәүдә тәрҗемә ителгән шигырь китаплары һәм Казанда якын елларда басылачак яңа «Татар поэзиясе антологиясе», борынгы шагыйрьләр иҗаты һәм кульязманы хәзерләү барышындагы кайбер эшләр турында сөйләде. Үз иҗат планнары белән дә бүлешеп, шагыйрь үзенең яңа тәмамланган опера либреттосы белән таныштырды. Утырышның икенче өлешендә шагыйрь М. Әгъләмовның яңа шигырьләре тыңланды.

## БӨТЕНРОССИЯ ИҖАТ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

7 февральдә Казанның Актерлар йортында «Театр һәм кино декорациясе сәнгатенең бүгенге торышы» дигән темага Бөтенроссия иҗат конференциясе булды.

Конференциядә сәнгать фәннәре докторы профессор М. Пожарская, СССР Художество академиясенең член-корреспонденты М. Богданов, ТАССР Художниклар союзы идарәсе председателе Ә. Тумашев һәм сәнгать белгечләре чыгыш ясады.

Конференция эшендә КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире Д. Х. Зарипова катнашты һәм чыгыш ясады.

## ДӘРДМӘНД ИСТӘЛЕГЕНӘ

8 февральдә язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында татар поэзиясе классигы Дәрдмәнднең тууына 125 ел тулу уңаеннан әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Кичәне ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин алып барды.

Шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты турында филология фәннәре кандидаты Н. Хисамов сөйләде. Язучы Л. Хәмидуллин, шагыйрьләр Р. Харис, Р. Гатауллин һ. б. Дәрдмәнд иҗатының хәзерге татар поэзиясенә йогынтысы хакында үз фикерләре белән уртаклаштылар.

Дәрдмәнднең шигырьләрен ТАССРның атказанган артисты Х. Җәләлов укыды.

## Ш. БАБИЧКА БАГЫШЛАП

1 февральдә язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында атаклы шагыйрь Шәехзадә Бабичның (1895—1919) тууына 90 ел тулуга багышланган кичә үткәрелде.

Шагыйрьнең иҗат һәм тормыш юлы турын-

да күренекле галим, филология фәннәре докторы профессор Хатип Госман доклад ясады. Аннары шагыйрьләр Зөлфәт, М. Әгъләмов, Ә. Рәшитов, прозаик Р. Батулла шагыйрь тормышыннан кызыклы эпизодлар сөйләделәр, Бабичка багышланган үз шигырьләрен укыдылар. Сүз осталары Х. Җәләлов һәм А. Хафизов Ш. Бабичның лирик һәм сатирик шигырьләрен сөйләделәр, җырчылар Г. Казанцева, Х. Ижбулдин халык җырларын башкардылар. Кичәне шагыйрь Р. Гатауллин алып барды.

## АККОШ КҮЛЕНДӘГЕ ШИГЪРИЯТ БӘЙРӘМЕ

10 декабрьдә язучыларның Аккош күлендәге дачасында шагыйрь Хәсән Туфан исәлегенә багышланган шигърият бәйрәме булып узды. Шагыйрь туган көндә уздырыла торган традицион бу бәйрәмдә Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин, Г. Бәширов, Ә. Еники, И. Юзеев, Ш. Галиев, Р. Харис, Р. Гатауллин, Р. Вәлиев, Р. Мөхәммәдиев, Р. Миңнуллин, С. Маннапов, М. Вәлиев, филология фәннәре кандидаты М. Гайнетдинов һ. б. катнашты.

## ШАГЫЙРЬ ИСЕМЕНДӘГЕ УРАМ

ТАССР Министрлар Советы карары белән, Казан шәһәренең Мәскәү районындагы 12 нче Союз урамы Хәсән Туфан исемендәге урам итеп үзгәртелде.

## ШӘЙХИ МАННУР ЮБИЛЕЕ

Республикабыз җәмәгатьчелеге күренекле татар совет язучысы Шәйхи Маннурның тууына 80 ел тулуны тантаналы төстә билгеләп үтте.

15 январьда бер төркем язучылар шагыйрьнең туган төбәгенә — Мамадыш районының Тулбай авылына килде. Шул ук көнне кич Олыяз авыл культура йортында юбилей тантанасына багышланган әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Кичәдә тәнкыйтьче С. Маннапов, укытучы З. Габдуллина әдипнең иҗаты һәм тормыш юлы турында сөйләделәр, Гомәр Бәширов истәлекләре белән уртаклашты. Әдәби бәйрәмдә ТАССР Язучылар союзы идарәче председателе урынбасары И. Юзеев катнашты һәм чыгыш ясады. Шагыйрьләр Зөлфәт һәм Р. Низамиев яңа шигырьләрен укыдылар.

«Чулпан» колхозы председателе, ТАССРның атказанган культура работнигы Г. Җиһаншин тантаналы шартларда Шәйхи Маннур исемендәге премияләрне тапшырды. Быел әлеге премияләргә «Сезгә ышанам» исемле китабы өчен Салих Маннапов, «Бердәнберем» дигән җыентыгы өчен Нәбирә Гыйматдинова, колхоз культурасын үстерүгә һәм шагыйрь исемен мәңгеләштерүгә керткән хезмәтләре өчен Револь Гыйззәтуллин, колхозның алдынгы савымчылары Фәүзия Шәфигуллина һәм Сәвия Кәримова, культура-агарту өлкәсендәге уңышлары өчен Түбән Козгынчы авыл культура йорты директоры Рәзимә Әхмәдиева лаек булды.

Юбилей тантанасының икенче өлешендә авыл үзешчәннәре башкаруында Ш. Маннур шигырьләре һәм аның сүзләренә язылган җырлар яңгырады.

18 январь көнне Ш. Маннурны искә алу кичәсе Казанда, Татарстан язучыларының Г. Тукай исемендәге клубында уздырылды. Кичәне Г. Бәширов алып барды. Шагыйрьнең иҗаты турында «Казан утлары» журналының җаваплы секретаре С. Маннапов сөйләде. Кичәдә шагыйрьләр И. Юзеев, Ш. Галиев, Ф. Гыйззәтуллина, Р. Гатауллин, М. Галиев һәм сәнгать осталары чыгыш ясады.

## ИҖАТ КИЧӘЛӘРЕ

25 январьда Казанның Актерлар йортында күренекле драматург, шагыйрь һәм галим Нәкый Исәнбәтнең иҗат кичәсе булды.

Кичәне кереш сүз белән Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин ачты. Н. Исәнбәтнең олы иҗаты турында язучы Ә. Еники, РСФСРның халык художнигы Б. Урманче, СССРның халык артисты М. Сәлимҗанов, язучылар А. Гыйләҗев, М. Маликова, М. Мәһдиев, Зөлфәт сөйләделәр.

Кичәнең икенче өлешендә Н. Исәнбәт әсәрләре буенча куелган спектакльләрдән өзекләр күрсәтелде, аның җырларыннан һәм шигырьләреннән төзелгән концерт булды.

10 декабрьдә Казанның Актерлар йортында язучы Роберт Батулланың иҗат кичәсе булып узды. Кичәне Татарстан Язучылар союзы председателе Т. Миңнуллин ачты. Р. Батулланың иҗат юлы турында язучы Н. Фәттах сөйләде. Аннан соң язучы үзенең хикәяләрен, әкиятләрен укыды, тамашачыларның сорауларына җаваплар бирде.

## ОРЕНБУРГТА УКУЧЫЛАР КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

11 декабрьдә Оренбург шәһәренең Х. Ямашев исемендәге китапханәсендә «Казан утлары» журналының укучылар конференциясе булып узды. Конференциядә шәһәрдә һәм якын районнарда яшәүче әдәбият сөючеләр, яшь иҗатчылар, үзешчән сәнгать активистлары, Оренбург татар театры артистлары һ. б. катнаштылар.

Бүгенге татар әдәбияты һәм «Казан утлары» журналының эшчәнлеге турында журналның хатлар бүлеге редакторы шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов, тәнкыйть бүлегенең өлкән редакторы Ж. Миңнуллин сөйләделәр. Журналда басылган әсәрләр турында өлкән укытучылар С. Якупов, Г. Хәсәнова, китапханә каршындагы әдәбият һәм сәнгать түгәрәге җитәкчесе З. Шакиров, китапхана мөдире Н. Мөксинова, әдәбият сөючеләр Л. Рәфыйкова, Я. Катиев, М. Әмиров, Г. Габдерәшитов, Ф. Баширов һ. б. үз фикерләре белән уртаклаштылар. Соңыннан Оренбург өлкә филармониясе каршында эшләүче татар эстрада артистларының концерты булды.

## ПАТРИОТ-ШАГЫЙРЬ ХӨРМӘТЕНӘ

Түбән Камадагы «Җидегән чишмә» әдәби-музыкаль берләшмәсенең 15 февральдә үткәрелгән утырышы совет халкының Бөек Ватан сугышында җиңүенә 40 ел тулуга һәм җәлилчеләр батырлыгына багышланган иде. «Җидегән чишмә» чакыруы буенча Түбән Камага Әминә ханым Җәлилова килде. Ул Җәлил турында истәлекләр сөйләде.

Тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин М. Җәлил һәм аның иптәшләренең тиңдәшсез батырлыклары һәм патриот-шагыйрьнең ялкынлы иҗаты турында сөйләде. Әдәби-музыкаль кичәдә М. Җәлилнең шигырьләре, аның сүзләренә язылган җырлар башкарылды.

Кунаклар «Нефтехим» производство берләшмәсендә эшчеләр һәм шәһәр урта мәктәпләрендә укучылар белән дә очраштылар.

Герой-шагыйрь Муса Җәлилнең якты истәлеген миңзаләләр кадерләп саклый. Сугыш елларында ул хәрби-политик курсларда укыган педагогия училищесы бинасы на 18 февральдә мемориаль такта кую тантанасы булды.

Мәрмәр тактаның өске өлешендә — шагыйрьнең рәсеме, ә астарак: «Бу бинада 1941 елның 7 ноябреннән 1942 елның 1 январена кадәр хәрби-политик курсларда Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты шагыйрь Муса Җәлил укыды», дигән сүзләр язылган.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Совет әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре өчен, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1985 ел, 14 гыйнварь Указы белән язучылар Гамил Афзал, Рафаэль Мостафин, Җәмит Рәхимов һәм Фәнис Яруллинга «Татарстан АССРның атказанган культура работнигы» дигән мактаулы исем бирелде.

Театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен драматург Роберт Батуллинга, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1985 ел, 14 гыйнварь Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

## ХЕЗМӘТЛӘРЕН ХӨРМӘТЛӘП

Совет әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре өчен һәм Татарстан Язучылар союзының 50 еллыгы уңаеннан язучылар Нури Арсланов, Әмирхан Еники, Марсель Зарипов, Илгиз Кәлимуллин, Флүн Мусин, Нонна Орешина, Нурихан Фәттах һәм Илдар Юзеев Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләнделәр.

Совет әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре өчен һәм Татарстан язучылар союзының 50 еллыгы уңаеннан язучылар Рәшит Әхмәтҗанов, Әхсән Баянов, Николай Беляев, Әхәт Гаффар, Рәис Даутов, Нәби Дәүли, Әдип Маликов, Хисам Камалов, Шамил Рәкыйпов, Атилла Расих һәм Фоат Садриев КПСС өлкә комитеты һәм Татарстан АССР Министрлар Советының Мактау грамотасы белән бүләкләнделәр.

# ИСЕМСЕЗ БИЕКЛЕКТӘ

«Столбцы... Белоруссиядәге шушы шәһәрчек 1944 елның язында утлы бәрелешләр шаһитына әверелде. Безнең подразделение һөҗүм вакытында авыр югалтулар кичерде. Туплар тынып торган арада без батырһарча һәлак булган сугышчан дусларыбызны туганнар каберлегенә җирләдек, һәм батальон, үлгәннәргә тиешле хөрмәт белдереп, көнбатышка таба хәрәкәт итәргә әзерләнде...

Бервакыт сугыш каһарманнары күмелгән шундый каберләрнең берсе янына өлкән яшьтәге хатын килеп туктады. Кулларында язның беренче чәчәкләре. Шушы хатынның солдат кабере янында басып торуы әле дә күз алдымда...»

РСФСРның атказанган, ТАССРның халык художнигы Виктор Иванович Куделькин, Бөек Ватан сугышы ветераны буларак, хәтеренә уелып калган бер эпизодны әнә шулай искә төшерә. «Исемсез биеклектә» картинасы нәкъ менә шушы тәэсирләр җирлегендә иҗат ителгән. Халык тарафыннан яратып башкарыла торган мәгълүм җырдан алынган шигъри образ фронтовикның һәрвакыт җанлы булып саклanучы хатирәләре белән органик төстә кушылып киткән. Гомумән, рәссамның сугыш тематикасына багышланган һәрбер полотносында — баштан кичкән вакыйгалар, беренчел кичереш-тойгылар... Әсәрләрнең соклангыч дәрәҗәдәге тормышчанлыгы әнә шуннан киләдер.

Исемсез биеклек... Күптән түгел генә ул сугыш гөрелтесеннән тетрәп торган. Утырган балдай тыгыз кар үзе аша күпме канны җиргә сеңдергән. Күктә саргылт төс өстенлек итә, сугыш сөреме әле дә таралмаган шикелле. Ерακта күренеп торган урман кара шәл чукларын хәтерләтә. Гап-гади бер крестьян хатыны шушы утлы бәрелештә һәлак булган сугышчылар каберенә умырзая чәчәкләре бәйләмен алып килгән. Рәссам үзенең героинясын сурәтләгәндә «күпсүзлелек»тән качарга омтылган: кара шәлъяулык, искерә төшкән кара тун, солдат итекләре... Ниндидер әчке нур белән яктыртылган кайгылы йөз-бит, авыр эштән бераз тупасланган йомшак куллар аеруча «ассызыклап», якын итеп сурәтләнгән. «Кадр»ны астанрак алу фигураның монументальлеген арттырырга ярдәм иткән. Һәм нәтиҗәдә, сугышчы күзенә чалынган гадәти бер күренеш җирлегендә, Ватан азатлыгы хакына корбан булган улларын искә төшереп сагышланучы Ана образы барлыкка килгән. Гадәти бер крестьян хатыны образы Бөек Җиңү хакына миллионлаган балаларын югалткан халыкның мәңге җуелмас хәтере образы дәрәҗәсенә күтәрелгән. Язның беренче чәчәкләрендә чекрәеп янучы зәңгәр йолдызчыклар шатлыклы кырык бишнең язындагы чәчәкләр ташкынының, Җиңү салютының төрле төсләрдә җемелдәүче йолдызчыкларының прообразы буларак кабул ителә.

**Юрий ГОРШУНОВ**,
Татарстан сынлы сәнгать музееның өлкән
фәнни хезмәткәре.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе скульптор Рада Нигъмәтуллина.

**Рөстәм МАНСУРОВ** фотолары.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)